


# Аяз



# Гыйләҗев

**Аяз Гыйләҗев**

**Истәлекләр**

Төзүчесе Искәндәр Гыйләҗев

© Татарстан китап нәшрияты, 2006

© Гыйләҗев И.А. төзү, 2006

Аяз Гыйләҗев: Истәлекләр / Төз. И.Гыйләҗев. — Казан: Татар. кит. нәшр.: 2006.

ISBN 5-298-04008-X

Китапта Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев турында истәлекләр, аның иҗаты һәм сәхнәдә куелган әсәрләре хакында сөйләүче мәкаләләр белән бергә үзенең автобиографик язмалары, фоторәсемнәр урын алды.



Сүзен кистереп әйтә белде

Аяз Гыйләҗев — татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучы.

Ул әдәбиятка аяк баскан еллар — каршылыклы фикерләрнең нык чәкәләшкән еллары булды. Әмма шундый фикер төрлелеге камалышында булган хәлдә дә Аяз Гыйләҗев үз сүзен кистереп әйтеп килә белде. Мондый адымнар ясарга аны үзенең асылында тоткан юлының дөрес булуына ышанганлык кына этәрә алгандыр. Бу дөрестән дә шулай: «Өч аршын җир»ен алыргамы яисә «Җомга көн, кич белән...», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Урамнар артында яшел болын», «Яра», «Йәгез, бер дога!» һ.б. әсәрләре — һәрберсе милләт, ил язмышына битараф булмаган оста каләм иясе кулы белән язылган хәзинәләребез. Аның публицистик язмалары, фәлсәфи фикерләре беркайчан да үзкыйммәтләрен югалтмаслар.

Аяз Гыйләҗев әсәрләренең тәрбияви кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Алар — безнең милләтебезнең рухи байлыгы, милли үзенчәлекләре турында чорыбыз вакыйгаларына бәйләп язылган әдәби әсәрләр. Безнең чор кешеләренең яшәү рәвешләрен киләчәк буыннарга да алып бару вазифасы тапшырылган аларга.

1960—1990 елларда Аяз Гыйләҗев татар театрлары сәхнәләрендә бер-бер артлы пьесаларын куйдыра торды. 1960 еллар башында ук аның щепкинчылар белән иҗат иткән «Көзге ачы җилләрдә» әсәре хәтердә уелып калган. Бу спектакльдә уйнаучы яшь артистлар сәхнәдә чирканчык кына түгел, үз-үзләренә ышаныч алдылар. Шуннан соң, эшләрен уңышлы дәвам итеп, щепкинчылар ярты гасыр дәвамында, Г. Камал театрының төп көчләре булып, театр сәнгатебез үзәгендә иҗат итеп яшиләр.

Аяз Гыйләҗев — гомере буе профессионал язучы буларак иҗат иткән шәхес. Шулкадәр авыр язмыш кичергән кешегә ул елларда иҗат юлында зур каршылыклар булганлыгын без аның чордашлары буларак чамалый гына алабыз, билгеле.

Үз каләм көченә ышанып гаилә тоту да, бәлки, аңа җиңел булмагандыр. Ничек кенә булмасын: ул күпләргә үрнәк булырлык төпле гаилә башлыгы, проза жанрында да, драматургия өлкәсендә дә оста художник, тирән фикер иясе булды. Үзе Язучылар берлегендә җитәкчелек вазифаларын башкармаса да, каләмдәшләре аның фикерләренә һәрвакыт колак салып тордылар, игътибарлы булдылар, исәпләштеләр.

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең мирасын яратып һәм хөрмәт итеп яшәсәк, рухи офыкларыбыз киңәер.

Татарстан Республикасы Президенты

*Минтимер Шәймиев*

ИСКӘНДӘР ГЫЙЛӘҖЕВ

Кереш сүз

Минем әтием — Аяз Гыйләҗев. Бу сүзләрне яздым да аларның мәгънәсе тагын да тирәнрәк икәнлеген аңларга һәм аңлатырга тырышып, уйланып утырдым... Мине нәрсә уйландырды соң? Әтием турында булган фикер-хатирәләремне беркайчан да әйтеп бетерә алмам дип куркам, ахрысы. Шуңа күрә дә мин бүгенге көнгә кадәр әтием турында язмадым да, төрле җирләрдә чыгып сөйләмәдем дә. Әлбәттә, бу очракта сәбәп аның турында искә алырга теләмәүдән түгел, ниндидер дәрәҗәдә минем гаҗәеп олы җаваплылыкны үз өстемә аласым килми... Аяз Гыйләҗевнең шәхесе шулхәтле күпкырлы, масштаблы, тирән, каршылыклы — хәтерем үзенчәлекләреннән чыгып та мин аның турында тиешле дәрәҗәдә әйтә-сөйли алырмынмы икән дип, үз-үземә сорау куям. Шунысын да онытырга ярамый: табигый ки, әтиемә мөнәсәбәтем гаять субъектив. Язучы Аяз Гыйләҗев кемгәдер коллега, дус, әңгәмәдәш, очраклы таныш булган, кемдер анда конкурент, хәтта дошман күргән, күпчелек өчен ул бай телле, талантлы язучы

гына булып кала. Ләкин минем өчен беренче чиратта ул — әти, мине тәрбияләгән, үстергән, җанының зур бер өлешен миңа салган, бүгенге көндә мин бик тә юксына торган кеше.

Тарих барысын да үз урынына куячак, һәр гамәлгә, һәр кешегә үз бәясен бирәчәк. Татар халкы, татар теле, татар мәдәнияте яшәсә, Аяз Гыйләҗев, һичшиксез, аның хәтерендә, шәхсән аның өчен генә билгеләнгән, уникаль бер урын алып торачак. Бу сүзләрне мин атасын бик тә яраткан Аяз Гыйләҗевнең улы буларак кына әйтмим, бу тормышта инде бераз тәҗрибә һәм белем туплаган кеше, тарихчы буларак әйтәм. Чөнки Аяз Гыйләҗев чыннан да бу сүзләргә лаек.

Ул гаҗәеп энергияле кеше иде. Инглизләрнең шундый бер гыйбарәләре бар — «self made man» — «үзен-үзе ясаган кеше», ягъни бу тормышта бары тик үз көченә таянып яшәгән һәм юл тапкан кеше. Минем әти нәкъ шундый иде! Бала чагыннан ук язган, бала чагыннан ук язучы булырга хыялланган. Сугыштан соңгы авыр елларда Казанга килеп, Казанны яулап алуны максат итеп куйган, максатына ирешкән — татар халкының күренекле, яраткан язучысына әйләнгән. Университетка укырга кергән, кулга алынган, яшьлегенең иң гүзәл елларын ГУЛАГ лагерьларында уздырган. Яңадан Казанга кайткан, гаилә корган, журналист булып эшли башлаган. Һәм язган, язган, язган...

Әгәр дә мин: «Һәр кешенең тормышы берничә хәлиткеч этаптан яки циклдан тора», — дип әйтсәм, Американы ачмамдыр, ихтимал. Ул этаплар аның формалашуында, аның үсешендә гаҗәеп зур урын алып торалар. Шул циклларның төсен, эчтәлеген, әһәмиятен бары тик синең яныңдагы кешеләр билгели. Алар белән аралашу, хәтта алар белән янәшәдә яшәү, күңелдә, аңда җуелмас бер эз калдыра. Безнең янәшәбездә һәрвакыт төрле кешеләр пәйда була тора. Кемдер югала, кем беләндер аралашуны көтелмәгән, чамаламаган сәбәпләр аркасында өзәсең. Һәм һәрчакта бу даирә кабатланмас, уникаль... Синең тирәңнән кайберәүләр бакый дөньяга күчә, кемдер әле исән чагында синең тормышыңда үзенең урынын югалта, андыйлар белән аралашу сирәгәя, алар синең күңелеңә якын булмый башлыйлар. Бу — мәңгелек әйләнеш. Шул ук ва-

кытта синең белән гомерең буе бергә булган кешеләр дә бар. Физик яктан юк булсалар да, инде вафат булсалар да — алар барыбер синең белән. Эчтән генә алар белән киңәшләшәсең, аларга таянасың, аларны искә аласың. Андый истәлекләр җаныңның бер өзелмәс өлешен тәшкил итәләр. Әтием янәшәмдә һәрвакыт фикердәшем, киңәшчем булды да, һаман да шулай булып кала...

Балачак аерым мәгънәгә ия булган аралашулардан торса, олыгайгач тыгыз аралашу даирәсе бөтенләй башкача була икән, дип әйтсәм дә ялгыш булмас: мәктәп, университет, аспирантура, фәнни эш белән шөгыльләнү еллары... Ләкин минем

әтием, инде моннан дүрт ел элек вафат булса да, — ул һәрчак, һәр мизгелдә минем белән.

Әтиемнең кайсы сыйфатларын аерып искә алып булыр иде?

Аның эшчәнлеге, гаҗәеп, сокландыргыч эшчәнлеге. Бала чагыбыздан ук безнең нинди дә булса эш белән мәшгуль булуыбызны тели иде, таләп итеп, шуңа ирешергә омтыла иде. Без уянганчы ул эшенә алына, машинка тавышына без уяна идек. Миненчә, әти беркайчан да чын-чынлап ял итмәде — бармаклары авырта башлаганчы ул машинка артында утыра, ә калган вакытта да барыбер язучының фикере кайный тора ич, ихтыярсыз ул уйланып йөри, аның башында туачак әсәрләр була. Иҗади процесс әдипне берничек тә җибәрми, ычкындырмый, бәйдә тота, әсир итә, хәтта эзәрлекли дип әйтер идем.

Әти юмарт кеше булды. Эшчәнлеге кебек үк, аның юмартлыгы да чик белмәде. Биредә мин юмартлык сүзенең киң мәгънәсен кулланам. Кунак кабул иткәндә дә, яшь язучыларга булышканда да аның юмартлыгы ташып торды. Юмартлык, киң күңеллелек аңа кайвакыт кешеләргә объектив караш белән карарга, аларга объектив бәя бирергә дә комачаулый иде. Аны юмартлыгы ялгышырга этәргән чаклар да булгандыр. Кайберәүләрдән күңеле кайтты, кайберәүләр белән аралары өзелде, ләкин әтинең юмартлыгы һичвакыт сүнмәде — чөнки ул оптимист булды, кешеләргә, аларның ях-

шы сыйфатларына ышанып яшәде. Аның юмартлыгында да әтинең гаҗәеп каршылыклы шәхес икәнлеге ярылып ятты: характеры буенча шактый кырыс кеше, тормышның кайбер мизгелләрендә ул бала-чага кебек сентименталь, нечкә күңелле булып китүе — шуның дәлиле.


Минем уйлавымча, кызганыч ки, язучы буларак әти беркайчан да чын мәгънәсендә ирекле кеше була алмады. Гәрчә язучылар арасында ул барыбер иң ирекле фикерләгән, яшәгән һәм иҗат иткән шәхесләрдән булса да. Бу парадокс түгел. Мохит, җәмгыять, тормыш шартлары аны шундый булырга мәҗбүр иттеләр. Бер яктан караганда, Аяз Гыйләҗев — үткен телле, тапкыр, туры, хәтта усал сүз әйтергә әзер язучы. Кайбер түрәләребез дә аның кискен әйтелгән сүзләрен ишеткәләделәр. Шул сүзләр аны кайбер очракларда авыр хәлгә дә куйдылар. Ләкин әти үзен үзгәртмәде, үзгәртә алмады, үзгәртергә теләмәде. Үзгәртсә, ул Аяз Гыйләҗев булмас иде. Димәк, ул ирекле булган дигән күзәтү ясап була шикелле. Икенче яктан, әти тормышында һәрвакыт ниндидер конкрет, төгәл кысаларда яшәргә мәҗбүр булды. Бу кысаларны инде мохит тудырды. Дәүләт, җәмгыять, партия аны урынына утыртырга, төгәл билгеләнгән кагыйдәләргә буйсындырырга теләделәр. Ә ул — гаилә башлыгы, хатынын, балаларын үлеп яраткан ир. Гаиләне тәэмин итү, гаиләне алып бару — аның изге бурычы. Шуңа күрә дә ул шул уен кагыйдәләре каршында кайчак баш иярга мәҗбүр: эчке дөньясы, җаны ирекленкә омтылса да.

Чын, җитди, мәгънәле әдәби әсәрләр иҗат итү өчен язучыга табигый сәләт кенә җитми икән. Язучы өстәвенә максималь ирекле булырга да тиеш. Аяз Гыйләҗевнең сәләте чын мәгънәдә кодрәтле, көчле! Аның каләменнән чыккан әсәрләр — XX йөз татар әдәбиятының горурлыгы, бизәге. Сәләтле кеше буларак, ул гомере буе максималь иреклелеккә омтылды, ләкин барыбер ирешә алмады. Минемчә, аның язучы язмышының төп каршылыгы да, төп фаҗигасе дә шул.

Бу хатирәләр җыентыгын төзүчеләр Аяз Гыйләҗевне прозаик буларак, драматург буларак, шәхес буларак төрле яклап күрсәтә торган материаллар тупларга тырышты-

лар. Алар арасында махсус язылган истәлекләр дә, рецензияләр дә, әтинең үзе язган мәкаләләре дә, әңгәмә язмалары да бар. Басма өчен материалларны шул төрлелек принцибыннан чыгып кына сайладык та. Элегрәк вакытлы матбугатта басылган мәкаләләр да кертелде, кайбер авторларга өр-яңадан Аяз Гыйләҗев турында истәлекләр язып бирергә тәкъдим иттек. Бу җыентыкка әтиемнең бай тормышы, аның иҗаты, аның кешеләргә, халкыбызга, мәдәниятебезгә, телебезгә, халкыбызның киләчәгенә карашларын чагылдыра торган мәгълүматларның зур өлеше кертелде, һәм укучыларыбыз аларны кызыксыну хисләре белән кабул итәрләр дип ышанып калам.





# Чордашларның фикере ташка басылсын





Г.Ахунов белән А.Гыйләҗев бик еш табындаш булдылар

ГАРИФ АХУНОВ

Ян, учагым, ян!

Аяз Гыйләҗевнең романтиклыгы, аның табигатькә һәм кешеләр язмышына битараф була алмавы кырыгынчы еллар ахырында язылып, «Үсү юлы» альманахында басылып чыккан «Ян, учагым, ян!» хикәясендә үк күренгән иде инде.

Аннан соң ул алтмышынчы елларны «Рәтле кешеләр», «Яшьлек юлларында» дигән юка гына ике китап бастырып чыгарды. Бу китапларга карап, тормышка үз карашы, әдәбият-иҗат эшенә ачык үз мөнәсәбәте булган, контраст бизәкләр белән эш итә, әсәр эченә укучыны язгы ташкындай шаулатып алып керә ала торган, җитлеккән прозаик Аяз Гыйләҗевне күрү кыен әле.

Әмма бу китапларда да инде прозабызга яңа бер язучының килүен күреп була иде. Шуннан соң әдип бер-бер артлы хикәяләр, повестьлар, сәхнә әсәрләре язды, прозасын бастырды, пьесаларын республикабыз һәм аннан тыш башка өлкәләрнең театрларында да куйдырды. Аяз Гыйләҗев дигән исем укучылар күңеленә керә, әсәрләре халыкка таныла барды.

Иҗат мәсьәләләренә карата ифрат та җаваплы, принципиаль карашлы Хәсән Сарьян аның бер хикәясе хакында заманында болай дип язган иде: «Аяз Гыйләҗевне язучы итеп таныткан әсәре, миңа калса, «Үги ана яфраклары» дигән егерме генә битлек хикәясе булды. Бу хикәядә бернинди ялган юк, уйдырма юк, авторның һәр сүзе самими, шул сүзләрдән ул, чын тормыш дөреслегенә һич тә хилаф китермәстән, «менә бу

тормышның үзе!» дип әйтә торган, хәтта үзеннән дә гүзәлрәк булган бер тормыш бинасы төзеп куйган.

Бу хикәядә нибары алты кеше яши: каравылчы Мифтахетдин, йөкче Хәнәфи, председатель Шәйхулла, шофер Ибраһим, шофер Галимҗан һәм аның сөйгәне Сөмәя. Бу алтауның хикәя мәйданында биләгән җирләре — төрлесенең төрлечә: бер яки берничә биттә генә күренеп китүчеләр бар, әмма ләкин һәркайсы туп итеп күз алдына килә дә баса». («Социалистик Татарстан», 1978, 15 гыйнвар.)

Хәсән Сарьян, әдипнең әсәрләренә алга таба да бәя биреп, аның иҗатында Мәхәббәт һәм Нәфрәт дигән ике олы төшенчәнең менә шушы хикәядән башлануын әйтә.

Чыннан да, Аяз Гыйләҗевнең утыз еллык иҗатын игътибар белән күздән кичерсәң, аның барлык әсәрләренә — хикәя-повестьларына да, пьесаларына да, публицистикасына да нигез итеп кагылган баганалар — Мәхәббәт һәм Нәфрәт. Сөйгәненә, гаиләңә, иптәшләреңә, илеңә мәхәббәт, табигатькә, барлык тереклек дөньясына, изге күңелле кешеләргә булган мәхәббәт.

«Берәү», «Дүртәү», «Урталыкта», «Кызлар хатлары», «Күзгә-күз», «Язгы кәрваннар» повестьлары, ниһаять, турыдан-туры шул хисне әсәрнең исеменә үк чыгарып куйган «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят» повесте — болар барысы да яхшы белән яманны, изгелек белән явызлыкны, ак белән караны төрле ситуацияләрдә, төрле коллизияләрдә, тормыш тәҗрибәләре һәм белемнәре төрлечә булган кешеләр язмышы аша сурәтләп бирәләр. Бер яссылыкта сурәтләмиләр. Еллар үткән саен, яңа бер әсәрне иҗат иткән саен, язучы тормыш материалларына тирәнрәк үтеп керә, тел бизәкләренә таләпчәнрәк, төгәлрәк була бара, беренче чорындагы күз камаштыргыч буяуларны, кирәксез маҗараларны гап-гади булуы, чын булуы белән үзәккә үтә торган вакыйгалар, логик фикерләүләр, язмышларның табигый үсеше белән алмаштыра.

Менә шуңа күрә дә Аяз Гыйләҗев прозаик буларак соңгы елларда укучылар арасында киң танылды, татар әдәбиятының җитмешенче-сиксәненче еллардагы әйдәп ба-

ручы прозаигына әйләнде.

Аның бер генә әсәре дә игътибардан читтә калмый. «Өч аршын җир» кебек бәләкәй күләмле, әмма ифрат тыгыз язылган повестьта «туган туфрагына төкереп китүче» кешенең йөрәк яргыч фаҗигасе ачыла. Заманында бу повесть тирәсендә, җитди сәнгать әсәре буларак, кылычлар чарпылышты, бер яктан, «Дружба народов» журналының еллык бүләгенә лаек булды. Дөресен әйткәндә, бу әсәр нык уйландыручы, туган җиргә булган мәхәббәт хисен уңай мисалда түгел, гыйбрәтле язмышта раславы белән әле дә бәхәсле булып яши, ләкин яши. Ул бүгенге рус әдәбиятының күренекле «авыл прозасы» вәкилләре В.Белов, Е.Носов, В.Распутин әсәрләре белән янәшә яши, яшәячәк.

«Җомга көн, кич белән...», «Өтәч менгән читәнгә» повестьларын А.Гыйләҗев сиксәненче еллар башында иҗат итте. Бүгенге авылның катлаулы проблемаларын, кешеләр күңелендә яшәгән психологик тирәнлекне, каршылыклы уйларны ачып бирүе белән, заманча, тыгыз һәм үткен сурәтләү чаралары белән ул укучылар күңеленә, бигрәк тә яшь укучылар күңеленә хуш килде.

Аларда заман сулышын кыю ачкан әдип, тапталган юлдан китмәгән. Шуңа күрә дә аларның Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булулары да юкка түгел. Алар, әдипнең күпчелек иҗаты кебек, югары бүләккә лаек әсәрләр.

Прозада Аяз Гыйләҗев елдан-ел үсә, тирәнәя барса, ягъни аның художник буларак үсеше өзлексез дәвам итсә, драматургиядәге язмышы төрле сикәлтәләр, өзеклекләр, уңыш һәм уңышсызлыклар белән аралашып барды. Моңа, билгеле, автор үзе генә түгел, театр эшлеклеләре дә гаепле. А.Гыйләҗев драматургиясе А.Островский һәм К.Тинчуриннар драматургиясе традицияләрен дәвам итә торган драматургия түгел, тамаша драматургиясе түгел, вакыйгалар драматургиясе түгел, кыскасы, — артистлар бик үк уңышлы туры килмәгән очракта да үзен-үзе алып чыга ала торган драматургия түгел. Бездә Островский һәм Тинчурин шәкерте — Туфан Миңнуллин. Ул инде менә

бу ике бөек драматургның эчке пружинасын, сәхнә сихерләрен бик нык үзләштергән,

биш бармагы кебек белә торган, яңа шартларда бик тә уңышлы куллана торган драматург.

Аяз Гыйләҗев драматургиясе — символларга, сүзнең күп мәгънәлелегенә, икенче планга һәм «боз астында барган тормышка» исәп тотып язылган драматургия. Режиссер һәм артистлар шуны аңлыйлар икән, драматургның коллизияләре, әдәби концепцияләре белән килешәләр, шуны үзләренеке итеп яраталар икән, ул чагында Гыйләҗевнең бәхете баса, ул чагында сәхнәдә бер генә кешене дә кабатламаган яңа, кызыклы, көчле характерлар туа. Аның Татар дәүләт академия театрында 1960 елны куелган «Җиз кыңгырау» драмасы әллә ни уңыш казана алмады, шигъри алымнарга корылган «Киек Каз Юлы» да озын гомерле булмады, ә менә бая әйткән мәхәббәт белән нәфрәтне берләштергән «Көзге ачы җилләрдә»сен халык кабул итте. Режиссер Габдулла Юсупов аның тирәнлегенә төшә алды, буыннар язмышын, аларның күчешен һәм шул күчештәге авырлыкларны сәхнә чаралары белән тамашачыга күрсәтә алды. Режиссер Празат Исәнбәт аның «Эңгер-меңгер» әсәрен җылы буяуларга төреп, яшьләргә ихтирам белән карап, карикатура ясамыйча, бик әйбәт итеп тамашачыга җиткерде. Әмма аның пьесаларын аеруча зур уңыш белән Әлмәт дәүләт драма театры, режиссер Гали Хөсәенов ачып бирде. Күрәсең, сәхнә әсәрен язу белән генә эш бетми, драматург үзенең фикердәше, юлдашы, дусты булган режиссерны да табарга тиеш икән әле...

Альберт Яхин белән бергәләп язган «Шамил Усманов» героик драмасы да Татар дәүләт академия театрында яңгыраш таба алды.

Мин бу язмаларда каләмдәшем Аяз Гыйләҗевнең ике әсәренә аеруча иркенләп тукталуны кирәк саныйм. Аларның берсе — «Көзге ачы җилләрдә» драмасы, дөресрәге, спектакле, икенчесе — «Урамнар артында яшел болын» романы.

* * *

Сүзне «Көзге ачы җилләрдә»дән башлыйк.

...Әле пәрдә ачылмаган. Пәрдә артында шаулап поезд килгәне ишетелә. Һәм шул тавыш тамашачыда булачак вакыйгалар белән кызыксыну уята. Поезд чаклы поезд килгән икән, димәк, ниндидер кирәкле бер кеше килгән дигән сүз. Менә без вокзалның эченә керәбез һәм кызыклы ике кеше белән очрашабыз. Аларның берсе — Гандәлиф исемле яшь кенә кыз: өстенә зәңгәр күлмәк кигән, чәчләрен ике толым итеп үргән, хәрәкәтләре кискен, ашыгыч, балаларча. Икенчесе — алтмыш яшьләрендәге аз сүзле, салмак хәрәкәтле кеше, тимер юлчы Ясыйр абзый. Шаулап килеп төшкән поезд, димәк, Гандәлифне калдырып киткән икән. Ул, өч-дүрт чемоданга савыт-саба төяп, үзе белән дөнья-тамаша уй-тойгылар төяп килгән. Аны кемдер алмага килергә тиеш. Ә кемдер дигәне «бик акыллы, бик уңган, бик гадел, аның кебек кеше дөньяда юк!» Сиздегезме эшләрнең кая таба барганын?! Дөньяга гашыйк булып, күзләрен зур итеп ачып карый торган кеше икән ич бу. «Их, абый! Ташла әле эшеңне! Елмай әле бер!» — дип кенә җибәрә ул Ясыйр абыйга да. Яшь артистка Нәҗибә Ихсанова башкаруында Гандәлиф садә күңелле, беркатлы кеше булып күңелгә керә башлый. Тормышта безнең мондый кешеләрне байтак очратканыбыз бар. Алар, әлбәттә, бер сорау бирү белән үк, барлык биографияләрен сөйләп ташлый торган булалар. Алар күңел хисләре ташып чыгудан тартына белмиләр. Аларда кешегә ышану дигән нәрсә гаҗәеп зур! Гандәлиф-Ихсанова да үзенең тормышын, яшьлек җилкенүләре белән кушып, Ясыйр абзыйга сөйләп бирә. Баштарак без аның сүзен кызыксынып тыңлыйбыз, тора-бара сагая башлыйбыз, ә соңыннан күңелгә шом төшә: садә күңелле, шактый ук беркатлы бу кешене төп башына утыртмаганнармы, аның ышанычы белән уйнамыйлармы? Шомлану дөрескә чыга. Штукатурчы кыз Гандәлиф кияүгә чыккан, алты ай бергә торгач, ире, аны калдырып, Зәй ГРЭСына — туган якларына кайтып киткән, алты айга бер хат та язмаган, ләкин Гандәлиф, иренә ахыргача турылыклы булып, аны көткән, эше күптер, вакыты юктыр дип юанган, инде менә төянеп, аның янына үзе кайтып төшкән. Нәрсә белән бетәр аның язмышы, аны моннан килеп алырлармы?

Гандәлифне вокзалдан килеп алмыйлар. Аның ире, Зәй ГРЭСында инженер булып



эшләүче Ибраһим, чәчәктән чәчәккә кунып йөрүче азгын нәфесле бер кеше булып чыга. Пьесаның һәм спектакльнең төп вакыйгасы һәм тамашачыларга әйтергә теләгән төп фикере менә шушы юнәлештә. Бер якта — кешеләргә карата тирән ышаныч, садәлек, сафлык, икенче якта — шул садәлекне мыскыл итүче, шул ышанычны аяк астына салып таптаучы. Бер сүз белән әйткәндә, спектакль кеше бәхетен җимерергә маташучыларны көн яктысына чыгара. (Мәхәббәт һәм Нәфрәт бу әсәрдә дә пьесаның нигезендә ята.)

Инде шушы идеяне тамашачыга җиткерү өчен автор, режиссер һәм художник нинди чаралар куллана? Спектакльдә Гандәлиф янына тагын берничә фаҗигале язмыш өстәлә. Тимер юлчы Ясыйр яшь чагында, кешеләргә гел яхшылык эшләргә теләп, җиде төн уртасында урманнарга барган, абага чәчәкләре һәм тереклек суы табучы куяннар белән тилереп йөргән. Ул заманда аны аңламаганнар, аны мулла чыбык белән суктырган. Ул, сөйгән кызын ташлап, авылдан чыгып качкан, шулай да мәхәббәтемә турылыклы булам дип, гомер буе өйләнми яшәгән. Хәзер менә туган якларына кайтып, тимер юлда эшләп йөри, шулай да аның күңеле тыныч түгел, бәхетсез мәхәббәте аны өзлексез борчып, аның күңелен кимереп тора. РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Хөсәен Уразиков башкаруында Ясыйр гаять дәрәҗәдә кешелекле булып, олы җанлы булып күңелгә сеңеп кала. Кайберәүләр, фикер алышканда, Ясыйрны җитезрәк итәргә дип киңәш бирделәр. Минемчә, моны эшләргә һич ярамый, чөнки ул чагында Ясыйр яшьләр җиңеллегенә кушылып киткән ваемсыз кешегә әйләнәчәк. Спектакльдә Ясыйр-Уразиковның Гандәлиф кайгысын күтәрешүе күңел кузгаткыч чын һәм табигый килеп чыга, Ибраһимның ул укыткан, ул озак вакытлар өмет баглап йөргән кеше булуы һәм ул өметләрнең аяк астына салып тапталуы драманы көчәйтә. Ясыйр Уразиков энесенең әшәкелеген белгәннән соң да кычкырынмый, энесенә нәфрәтле сүзләр яудырмый, хәтта тавышын да күтәрми, чын кайгыру белән кайгырып өзгәләнеп: «Ибраһим!» дип кенә әйтә ала. Менә шундый сабырлык, драманы тиенкы алымнарга кору

образларның мәгънәлелеген бермә-бер арттыра, ышандыра торган итә.

Әсәрне сәхнәгә куючы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе режиссер Габдулла Юсупов мелодрамасыз драма тудыра. Геройларның күңел байлыгын әкренләп, логик рәвештә ачып бирү юлы белән эш итә. Менә шуңа күрә дә төзелештә эшләүче яшьләр Гандәлиф ягына күчеп, аның язмышы өчен барысы бердәй күтәрелгәч, һәм Гандәлиф үзе Ибраһим белән зур юлга чыгудан баш тарткач, зал озаклап, ашкынып кул чаба. Минемчә, бу спектакль — драматургның, режиссерның, художникның принципиаль уңышлары. Художник Әнәс Тумашев спектакльнең эчтәлеген, ритмын ача торган кырыс күренешләр язган: вокзал бинасыннан, җилдә чайкалган яшь каеннан, кайдадыр җемелдәүче кызыл уттан һәм, ниһаять, геройларның өс-баш киеменнән түгәллек, кырыслык, лаконизм сизелеп тора. Тик бер картинадагы бөтен сәхнәне тотып торган ГРЭС каркаслары гына, гәрчә алар сәнгатьчә әйбәт эшләнсәләр дә, Гандәлифнең шәхси драмасыннан читтәрәк калалар.

Режиссер өстенә бу спектакльдә йөкләнелгән тагын бер җаваплы бурычны әйтми үтеп булмый. Спектакльдә ике полюстагы артистлар уйный. Бер якта — озак еллар уйнап, тамашачының ихтирамын яулап алган һәм зур исемнәре булган Хөсәен ага Уразиков, Галимә ханым Ибраһимова, Рәшидә ханым Җиһаншина, Вера ханым Минкина, икенче якта — сәхнәгә яңа гына аяк баскан яшь артистлар. Режиссер Габдулла ага Юсупов, шушы яшьләрнең укытучысы буларак та һәм бу спектакльдә аларны кыю рәвештә кертеп җибәрүче буларак та зур эш эшләгән. Димәк, артистлар белән яшьләрнең ансамбль бердәмлегенә нигездә ирешкән. Гандәлиф ролендә уйнаучы Нәҗибә Ихсанова уенындагы чынлыкны әйткән идем. Әле генә флоттан хезмәт итеп кайткан гармунчы егет Хәнҗәр ролендә уйнаучы яшь артист — Ринат Таҗетдинов буй-сыны белән дә, гармунда үзе уйный белүе белән дә, нәфислекне тоеп җырлавы һәм темпераментлы хәрәкәтләре белән дә матур тәэсир калдыра. Кискен холыклы, сүзен мылтыктан аткандай берьюлы «атып» бетерә торган Сәхи (яшь артист Дамир Хәйруллин) сөйләвен бик табигый алып бара.

Актүти ролендә Татарстанның халык артисткасы Галимә ханым Ибраһимова, Мәймүнә ролендә Татарстанның атказанган артисткасы Рәшидә ханым Җиһаншина тамашачыда ягымлы елмаю, якын күрү тойгысы уяталар.

Яшь артистлардан Наил Дунаев (Ибраһим ролендә) просмотр вакытында шактый ук көчсез уйнавы белән күңелдә уңайсыз тойгы калдырган иде. Премьерадан ул байтак үсте, шулай да әле аның уенына иркенлек җитми, куллар ике якка җәелеп куюдан башка хәрәкәтне белмиләр, тавышы да, ничектер, хиссез. Ул, күрәсең, алдан ук нәфрәткә дучар ителгән кире типны уйлап уйный булса кирәк.

Татарстанның атказанган артисткасы Вера Минкина — малай ролендә искиткеч, хәтта, мин әйтер идем, соклангыч. Малайларның барлык хәрәкәтләрен, сөйләү рәвешләрен чын итеп башкаруы белән ул әсәрнең күңелне баса торган авыр ягын киметә, ләкин шул ук вакытта драманы көчәйтә. Флоттан кайткач, Хәнҗәрнең каенны кочаклап елавы турындагы бер күренешне еламсырап түгел, нәкъ менә малайларга хас ваемсыз шаккату белән сөйләве залны кинәт тын калдыра, күңелләрне тетрәтеп җибәрә. Флаглар һәм фонарь белән уйнавы аркылы (режиссер тарафыннан бик шәп табылган мезансцена бу!) ул тимер юлчы Ясыйр образына яңа штрихлар өсти.

Барысын бергә җыеп әйткәндә, драматург тормыштагы матурлык һәм ямьсезлекне, мәхәббәт һәм нәфрәтне олы һәм кече буын язмышында куйган. Режиссер һәм артистлар аны сәхнә чаралары белән халыкка җиткерделәр...

* * *

Аяз Гыйләҗевнең кодрәтле таланты татар әдәбиятына бик күп үзенчәлекле әсәрләр бирде. Ул бит кырыклап пьеса авторы. Аның драматургиясе арзанлы шаккатыризмга корылмаган, акыллы, тирән мәгънәле фикерләр драматургиясе ул. Татар дәүләт академия театрында аның байтак әсәре куелды. Габдулла ага Юсупов режиссерлыгында «Көзге ачы җилләрдә», Празат Исәнбәт режиссерлыгында «Эңгер-меңгер» спектакльләре генә үз тамашачысын таба алды. Шуңа күрә мин бүген Татар дәүләт академия театры мәгънәгә, акыл сөрешенә корылган әсәрләрне куя алмый, аларга карата

театрның мөнәсәбәте юк, дип әйтер идем. Академия театры тамашага корылган әсәрләрне генә кую ягында тора. Киләчәк буыннар алдында әлеге мөнәсәбәт өчен театр җавап бирергә тиеш булыр әле.

Аяз Гыйләҗев иҗаты — көрәшче иҗат. Ул беркайчан да такыр юлдан бармады.

Рәхмәт әйтсен, тоталитар режим заманында Гарәф Шәрәфетдинов, үзенә авырлык алып булса да, аның китапларын бастырып килде. Юкса партия Үзәк Комитеты җитәкчеләре Аяз каләмдәшебезнең язган бер әсәреннән гаеп эзләделәр. «Өч аршын җир» белән «Язгы кәрваннар» кире яктан мисалга алындылар. «Күзгә-күз» повестена карата аның каләмдәшләре гәзит аша погром оештырды. «Югалган бер көн» спектакленә, Казанның Рус зур драма театры куйган спектакльгә, өлкә комитеты секретаре ничек ярсып ташланды. Мин язучыларның рәисе идем ул чакта, әлеге спектакльне яклагач, секретарь миңа да: «Хватит!» — дип кычкырган иде.

Хәтеремдә әле, Каракалпакстанда Аяз, ишәкне кочаклап: «Синең дә, минем дә бер бүләгебез дә юк. Этләргә күргәзмәдә катнашып койрык болгаган өчен, медаль тагып җибәрделәр», — дип елаган иде. Сабыр иткән морадына җиткән, ди бабаларыбыз.

Мин рәис булып эшләгәндә (1983 елны), ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 1987 елда ул РСФСРның Дәүләт бүләген дә алу бәхетенә иреште. 1993 елның декабрендә аңа Халык язучысы дигән дәрәҗәле исем бирелде.

Аязның берничә әсәре, әйтик, «Урамнар артында яшел болын», «Язгы кәрваннар» Чыңгыз Айтматовның әсәрләре белән аваздаш. Ләкин аларны Аяз Гыйләҗев дөньяның мәшһүр язучысыннан алдарак язган иде.

Гомер буе ат урынына эшләгән, картаймыш көнендә күптөрле дәрәҗәләргә ирешкән кодрәтле каләм иясенә — Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевкә — Ходай Тәгалә күп итеп сәламәтлек бирсен. Ул әле тагын безне яңа әсәрләре белән сөендерсен.

1983, 1998 еллар



МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ

«Кара урман»нан чыккан ул...

Аяз Гыйләҗев... Бу исем әдәбият сөючеләр

өчен... — дип башлап китәр идем, болай башлау

минем әдәбиятка гына түгел, аның укучыларының

да төрле дәрәҗәдәге зәвыкка ия булуларына бер-

нинди мөнәсәбәтем юк икәнен күрсәтә торган җөм-

лә булыр иде.

Аяз Гыйләҗев... Бу исем сәхнә сөючеләр

өчен... — дип башлап китәр идем, болай башлау

инде минем татар театрына гына түгел, аның сәх-

нәдә уйнаган гаҗәеп актерларына да, беркатлы, са-

мими күңелле тамашачыларына да үз мөнәсәбәтем

юк икәнен күрсәтә торган сүз булыр иде.

Аяз Гыйләҗев. Бу исем әдәбият сөючеләр өчен

дә, сәхнә сөючеләр өчен дә төрле чорларда аягын-

да нык басып калган бер шәхес булып чыкты.

...Һәм шул катмарлы чорны намуслы иҗат бе-

лән үткән зур әдип икәнен, халык әдибе икәнен

җәмәгатьчелек танырга мәҗбүр булды.

Вакыт галиҗәнаплары Аяз Гыйләҗевне М.Горький исемендәге РСФСР Дәүләт пре-

миясенә лаек дип санады. Бу инде, әлбәттә, исемнәрнең очраклы гына бергә туры

килүе түгел...

* * *

Безнең туган-үскән җирләр Зәй төбәгенә керә. Районның исеме нигәдер гел үзгәрә

торды. Тик бер нәрсә һәрвакыт безнең белән булды, ул да булса Баграж урманнары.

Эсседән дә, салкыннан да, ачлыктан да, үлемнән дә ул саклады. Кап суктык, кип сук-

тык — дәүләт сатып ала иде. Ишек чыпталары үрдек — Сарман базары ах итә иде.
Чана табаны каердык — үрәчәле чаналарны Мәләкәстән алып калмык далаларына кадәр көтеп торалар иде. Сарманда туган Аяз Гыйләҗев әнә шул урман эргәсендә үскән.
Безнең халыкта урман абагасы турында бик күп легендалар йөри. Имеш, төн уртасында чәчәк ата. Имеш, аның чәчәк атканын күрсәң, бәхетле буласың, теләгең үтәлә. Хуш! Шулай да булсын. Хикмәт анда түгел. Хикмәт безнең Баграж урманнарында үскән абагаларның башка төбәкләрдә үскән туганнарыннан үзгә булуында.
Киров урманнарында — Нократ татарлары арасында йөргәндә, мин алардагы абаганың үлем көткәндәй кара коелып утыруларына шаккаткан идем. Түбән Сирә урманнарында (Свердловск өлкәсе) — кый татарлары арасында йөргәндә, мин алардагы абаганың як-якка түгел, котырып буйга үсүенә исем киткән иде. Башкортстан урманнарында мин аларның балык тәңкәседәй шома, чәчәк кебек купшы булып үсүләренә гаҗәпләнгән идем.
Аяз Гыйләҗев дисәм, минем күз алдыма үзебезнең Баграж урманнарындагы абага килеп баса. Ул артык биек тә, купшы да түгел, якын килсәң, кычыткан кебек өтеп алыр сыман, якын итсә, «парин!» дип, иңбашыңа кулын салыр сыман.
Аяз Гыйләҗев — үзенең туган-үскән җире вәкиле, үз урманының абагасы. Башка бер генә урманда да андый Аяз... (гафу итегез), андый абага үсмәс иде. Башка туфракка күчерелсә дә, андый язучы булыр иде, әмма әдип Аяз Гыйләҗев буларак күп мәртәбәләр һәм төрле-төрле төсләрдәге чәчәкләр атып әдәбият сөючеләргә шулкадәр сөенеч, бәхет китерә алмас иде сыман.
«Өч аршын җир», «Урталыкта», «Язгы кәрваннар», «Җомга көн, кич белән...»,



«Мең чакрым юл», «Үги ана яфраклары», «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Эңгер-меңгер» һәм башка дистәләгән повестьлар, хикәяләр, драмалар, комедияләр, романнар

авторы ул.

* * *

Безнең урта мәктәпне бетерәсе ел иде. Имтихан көннәре якынлашкан мәхшәр иде бугай. Аяз Гыйләҗев чыгарылыш класс укучылары белән очрашырга килде. «Ялкын»да поэмам чыккан ел. Ике ел алдан гына «Җырчы чишмә» китабында шигырьләрем чыккан. Кемнәр белән диген. Әле ул чакта исемнәре беркемгә дә билгеле булмаган Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимовлар белән...

Зәгыйфьлек көчле булса да,

Күңелләр хисле иде.

Мин әле ул тиле хиснең шагыйрьлек дип аталганын белми идем. Ах, бәхетле чор булган!

Әнә шул сукыр бәхетем белән язучыга бер мәгънәсез сорау биреп ташладым:

— Аяз абый, бу караңгы якка сез нинди җим эзләп кайттыгыз?

— «Үги ана яфраклары» дигән хикәя яздым. Анда — икмәк, икмәкнең амбарга керүе, кешеләрнең үзара мөнәсәбәте. Хикәя инде беткән. Әмма вакыйганың үз җирлегенә кайтмыйча, туган-үскән җирне күрмичә, хикәяне кулдан җибәрә алмыйм, — диде язучы.

...Кулдан җибәрә алмыйм...

Үзең язган әсәргә җаваплылык мәсьәләсендә бу миңа беренче дәрес иде.

...Еллар үткәч, инде мин акны карадан аера башлагач, дөресен генә әйткәндә, башта ак белән кара буталып тонык төс барлыкка килгәч, бераз мәзәк итеп шушы вакыйганы язучы Хәсән Сарьянга сөйләгән идем.

— Син, энем, — диде ул, — язучы Аяз Гыйләҗевнең әдәбиятта яңа бер биеклеккә күтәрелгән чорында очрашкансың. «Үги ана яфраклары» белән ул иҗатында яңа бер киңлек ачты.

* * *

Печән өсте иде. Авылга кайттым. Әтиемнең абыйсы 72 яшьлек Акмалетдин карт белән печән чабабыз. Кул бизгән. Авыр. Мәтрүшкәле чәй эчеп, ял итәбез. Шул арада Баграж

урманының Чимәш карт өе аланында журналдагы әсәрнең соңгы битләрен укыйм.

Акмал карт һаман сораштыра. Миңа әсәрнең исемен әйтергә уңайсыз. Олы кешегә

— 72 яшьлек картка — ничек инде «Өч аршын җир» дисең?

Эчтәлеген сөйләдем. Язучысын әйттем. Акмал карт язучының әтисен дә яхшы бе-

лә булып чыкты. Әдипнең әтисе Мирсәет абзыйны хөрмәт белән телгә алалар безнең якта.

— Шулай, — диде дә Акмал карт, — булды хәлләр, Мирсәет малае дөрес сукалый.

Мирсәет малае дөрес сукаларга тиеш. Үзе дә җек күргән малай. Бошонсыдыр (бу

шунысыдыр) бит инде? Җек күргәнедер? Булыр. Алар урманнан чыккан.

Картның хәбәрдар булуына ис-акылларым киткән иде.

Мин хәзер Акмалетдин карт сүзләрен уйлыйм. Акылым яктыра бара. Чыннан да,

Аяз Гыйләҗев урманнан чыккан бит. Халыкның «Кара урман»ыннан чыккан. Илһам

Шакиров сузып җибәргән халык җырларыннан.

Заманалар авыр, еллар ябык,

Дус-иш кирәк гомер итәргә...

Ул әнә шул урманнан чыккан. Аны инде хәзер нинди генә ефәкләргә төрсәң дә, нинди

генә затлы бүрекләргә салсаң да, ул — үз халкының баласы... Сәламәт кенә булсын!

«Татарстан яшьләре»

24 гыйнвар, 1988



МАРАТ ӘМИРХАНОВ

Фатиха

Ходай талант дигән илаһи хәзинәне мыскаллап, бик сайланып кына бирә: кемгәдер ул мул, кемгәдер чеметем генә. Аяз Гыйләҗев бу яктан күкләргә дәгъва белдерә алмый инде. Киң колачлы чын талант иясе иде ул. Прозада да, драматургиядә дә үзен судагы балык шикелле хис итте. Прозасы драматургиягә хас көчле динамика белән сугарылса, драматургиясе прозача искиткеч тирән эчтәлекле булды.

Бу — һәммәбезгә дә мәгълүм хакыйкать. Тик Аяз Гыйләҗев «коеп куйган» язучы гына түгел иде шул. Иҗтимагый актив шәхес буларак, аның күзләре күпне күрде, колаклары күпне ишетте. Бигрәк тә татар әдәбиятының торышы, киләчәге, лаеклы алмаш мәсьәләләре борчый иде аны. Бик күп язучыларга фатиха биргән олы йөрәкле остаз да ул. Мәсәлән, Казакъстанда яшәп иҗат иткән Ибраһим Салаховның «Имәннәр тамыр җәйгәндә» әсәре аның әдәби яктан эшкәртүеннән соң дөнья күрде. Себердә яшәп иҗат иткән Якуб Зәнкиевнең «Иртеш таңнары» романы аның таләпчән кулыннан үтте. Үзем шаһит, алар аралашып, хатлар язышып, бик тату эшләделәр. Нәтиҗәдә роман Г.Тукай бүләгенә лаек табылды. Концлагерьларда җәфа чигеп кайтканнан соң, үзендә әдәби иҗатка рух дәрте табып, матур-матур әсәрләр тудырган Әнәс Галиевнең дә юл ба-

шында Аяз Гыйләҗев торганын беләм. Аның «Намус кушканча» повесте Аяз Гыйләҗев кулы аша узды. Аннан соң язылган әсәрләрен дә Әнәс ага гел Аяз белән киңәшеп, теләктәшлек табып, язып чыгарды. Өлкән буын язучыларыннан Нур Гайсин белән дә иҗади дуслыклары күркәм җимешләрен бирде.

Үзем дә әдәбиятка Аяз Гыйләҗев фатихасы белән кереп киттем. Мин — соң карлыгач, әсәрләрем илле яшьләрдә генә дөнья күрә башлады. Ә әдип белән якыннан танышуыбыз тагын да соңрак булды. Безне хәләл җефетләребез дуслаштырды. Шуның өчен мин Нәкыя белән Ләләгә бик рәхмәтлемен. Аяз гаҗәеп укымышлы, ифрат та хәтерле, бик күп өлкәләрдәге яңалыклардан тирән мәгълүматлы галим зат иде. Ул бервакытта да буш сүз сөйләмәс, һәр әйткәне — алтын бәясе. Белмим, минем белән әңгәмә корудан үзенә берәр файда алганы булды микән, әйтә алмыйм, әмма ул үзе гыйлем чишмәсе иде, фикерләү куәсе заманча, актуаль, катгый, тугры.

Туксанынчы елларда барган иҗтимагый вә җәмгыяви үзгәрешләр шаукымы мине дә үз дәрьясына тартып кертте. Күзәтүләремнең нәтиҗәсе буларак, «Дөя муены» дигән сатирик повестем туды. Билгеле инде, иң элек Аяз Гыйләҗевнең фикерен беләсем килде. Ул аны укып чыкты. Ләкин күзләрендә очкын кабынмады.

— Тәнкыйтеңне кабул итәрләрме икән? — диде сүрән генә.

Тагын бер кат сөреп чыктым. Аннан соң «Казан утлары» редакциясенә тапшырдым. Аны Марс Шабаевка биргәннәр. Аңа да әсәрем ошамаган. Янәсе, Татарстан җитәкчеләре мондый тәнкыйтькә лаек түгел. Шулай да аек акыл җиңде, 1996 елда әсәр журнал битләрендә урын алды.

Ул беренчеләрдән булып дустым өстәленә ятты. Ниһаять, күзләрендә очкын кабынды Аязның. «Син моны чын әдәби әсәр дәрәҗәсенә җиткергәнсең», — диде. Бераздан «Мәдәни җомга» атналыгында Аяз Гыйләҗевнең «Бәрәкалла, Әмирхан!» исемле аналитик мәкаләсе дөнья күрде. Бер генә өзек китерәм: «Автор үткен сүз белән җитәкче бюрократлар вертикален астын өскә кадәр бәяләп чыга. Теле — бритва авторның, турый гына. Күзе — прожектор, без күрмәгәннәрне күрә. Фикере, максаты

бер: ул халкыбызны, һәр җан иясен рухи коллыктан коткарырга ашкына... «Дөя муены»н бүгенге әдәбиятыбызның казанышы дип кабул итәбез».

Гыйләҗевләр берничә ел үзләренең туган яклары — Зәй төбәгендә яшәп алдылар. Яннарына кунак булып та баргаладык. Бу эчкерсез очрашулар хакында матбугатта да язып чыктым. Аяз минем иҗат белән якыннан торып кызыксына башлады. Күп тә үтми, Нәкыя аша Зәйгә чираттагы повестемны да юлладым. Түземсезлек белән остазымның бәһасен көтәм. Остазның да нинди бит әле! Уйлаганын күзеңә бәреп әйтә торганы. Дус дип тә, әшнә дип тә, туган дип тә котыла алмыйсың аның үткен теленнән.

Әсәрем кош теле чаклы гына бер язу белән әйләнеп кайтты. «Марат, зур уңышың белән котлыйм. Тик исемен үзгәртү мәслихәттер, мөгаен. Гөлнәзирә ятышлы булыр, минемчә. Уйлап кара». Шунда ук редколлегия әгъзасы сыйфатында «Казан утлары» журналына да юлламасы бар.

«Гөлнәзирә» 1998 елда укучыга барып иреште. Аяз 1998 елның 4 августында «Ватаным Татарстан» газетасындагы «Сирәгәеп калды урманлык...» язмасында әлеге ике әсәремә кабат әйләнеп кайтты. «Марат Әмирхан үзенең соңгы ике повесте белән чын тавышын ишеттерде. Талантлы әдип булуын, ниһаять, ачып салды», — дип язды.

«Тәкъдир» — минем беренче романым. Аяз Гыйләҗев бу хакта хәбәрдар иде, әлбәттә. Романда авыру, сырхау хәлләре тасвирланган вакыйгалар да бар. Шулар белән танышкач, ул миңа Эрнест Хемингуэйның «Елга аръягында, агачлар күләгәсендә» романын яңабаштан карап чыгарга, үлем якасыннан алган Америка хәрбие полковник Кантуэлл белән Италия чибәре графиня Ренатаның әңгәмәләренә игътибар итәргә киңәш биргән иде. Хемингуэй — диалоглар остасы. Чирнең үзе турында ләм-мим сүз әйтмичә, аның психологик асылын шулай тулы итеп фәкать ул гына тасвирлый алган. «Тәкъдир» романы Аяз Гыйләҗев фатихасы белән басылды. Роман соңыннан (2003) китап булып та чыкты.

Прозаик Аяз Гыйләҗевнең үз иҗаты да үрнәк иде миңа. Әйтик, «Үги ана яфракла-

ры» хикәясен мин үзем татар әдәбиятында мәхәббәт турында язылган иң самими, иң сәнгати әсәрләр рәтенә кертәм.

«Иң уңышлы әсәрләрегездән беренче итеп кайсын атар идегез?» — дип сорагач, ул, һич икеләнмичә: «Яра» повесте», — дигән иде.

«Яра» — дөнья укучысына тәкъдим итәрлек зур әсәр. Алексей Толстойның «Русский характер» новелласы белән аваздаш. Сюжетлары охшаш. Тик «Яра»ның нигезен мәхәббәткә мәдхия тәшкил итә. Кызганыч, Зәйтүнә белән Габдулланы милли өлге дәрәҗәсенә күтәрә алмадык. Моны мин әдәби тәнкыйтьнең йомшаклыгыннан күрәм.

Аязның вафатыннан соң «Казан утлары» журналы укучыларга минем «Тояк эзе» романын, «Мөкәррәмә», «И, кылган догам минем» повестьларын тәкъдим итте. Алар сайланма әсәрләремә дә (2004) кертелде. Боларга да шатланган булыр иде ул.

Мин әле дә остазым Аяз Гыйләҗев фатихасы белән яшим, иҗат итәм.

25 октябрь, 2005



МӘХМҮТ ӘХМӘТҖАНОВ

Студент Аяз Гыйләҗев әнә шундый иде

1945 елның октябрь уртасы. Казан дәүләт университетына укырга керергә дип хыялланып, татар халкының мәркәзенә килгән чагым. Соңга калуымның сәбәбе: комбайнчы булып эшләгәч, уңышны җыеп алмыйча паспорт бирмәделәр. Бу сәбәпне белгәч һәм «кызыл аттестатны» күргәч, ректор К.Г.Ситников «татар теле бүлегенә кабул ителә» дигән приказга кул куйды. Берничә көн мин «Колхозчы йорты» дигән кунакханәдә йоклап йөрдем. Аннан соң бүген КДУның геология факультеты урнашкан бинада тулай торакта яши башладым. Шушы бинаның иң зур бүлмәсе — лекцияләр укыла торган аудиториясендә яшәп ятучы студентлар янына мин кырык сигезенче җан иясе булып урнаштым. Бу аудитория-бүлмәдә группадашларымнан Аяз Гыйләҗев, Хәбибрахман (без аны Рахман дип йөрттек) Мөхәммәдиев, Мөҗәһит Хәйдәровлар да яшәде. Бүлмәдә заводтан «качып килгән» (ул чакта урта белемлеләрне иң беренче булып армиядән демобилизацияләделәр, шундый ук ташлама предприятиеләрдә эшләүчеләргә дә кагылды) студентларның кыланмышлары безнең ише яшь-җилбәзәкне куркуга сала иде... Андагы хикмәтләр турында яза башласам, олы бер «кыйсса» килеп чыгар. Еракка китәр дип уйларым... Ул хакта әйтми үтүем хәерлерәк булыр дип фараз кылам.

Мин булачак халык язучысы Аяз Гыйләҗев турында исемдә калган кайбер мизгелләр белән уртаклашам. Ә аңа кадәр ул елларның «идеологик-сәяси атмосферасы» хакында кыска гына белешмә бирү урынлы булыр.

Без әле ул елларда «Сталин империясе»ндә — СССРда уннарча миллион кешеләрнең бер гаепсез юк ителүен, ГУЛАГта даими рәвештә 13 миллион кешенең «хезмәт

белән тәрбияләнүен» белми идек. Хәзерге белемебез белән ул вакытка кайтып карарга мөмкинлегебез бар. Мәсәлән, элекке политбюро әгъзасы, сәяси тоткыннарның эшләрен тикшерү комиссиясе рәисе А.Н.Яковлев, күренекле галим-публицист Рой Медведев, профессор Г.Круглов китаплары әнә шулар хакында.

Ачлы-туклы яшәп, укып яткан студентларны нәкъ шул елларда шактый «чүпләделәр». Урыс группасында укучы якташым, фронтта каты яралар алган Мәҗит Рәфыйков шуларның берсе иде...

Инде Аязга килгәндә, без аның язучы булып китәсен шундук белдек диясем килә. Чөнки ул безгә әле генә иҗат иткән парчаларын, әсәрләрен укый иде. Тулай торакта түгел, университет аудиторияләрендә. Аеруча истә калган «Лира чыңлый» дигән зур булмаган хикәясе. Ул аны шакмаклы дәфтәрнең һәр юлына язган, мин янәшәсендә утырган булганга, хәтеремә сеңеп калган. Шул хикәясен ул аеруча хисләнеп укыды. Тыңлагач, миңа бик моңсу булып китте, чөнки язманың эчтәлеге шундый иде: берәү лирада уйный, шуның аркылы халыкка әйтәсе сүзен әйтә. Ләкин беравык лираның кылы өзелә, һәм музыкант югалып кала... Минемчә, Аяз бу әсәрен бер җыентыгына да кертмәгән бугай.

Аяз урта мәктәптә яхшы укыган. Университетта да ул исемле стипендия алып укыган булыр иде дип уйлыйм. Әмма ни өчендер — һәм мин әле дә моның сәбәбен өзеп кенә әйтә алмыйм, мөгаен, адым саен булган гаделсезлекләргә протест йөзеннәндер, аны үзе дә, бәлки, ныклап аңлап та бетермәгәндер, ул лекцияләргә йөрергә яратмады. Әйе, ашау-эчү ягы нык авыр булды, ләкин авырлык беркемне дә читләтеп үтмәде бит. Ә без шулай да лекцияләрне калдырмадык. Алай гына булса ярар иде, Аяз беренче



семестр имтиханнарына бармады. Закон нигезендә аны язга кадәр укудан чыгармадылар, имтиханнарны акрынлап тапшырыр дип уйладылар кебек. Кафедра мөдире Рәбига Афзаловна Хәкимова Аязның талантын, потенциясен белә һәм аны студент итеп сакларга тели иде. Гадәттәгечә, Аяз мәсьәләне үзенчә хәл итте.

Аяз һәрьяклап үзенчәлекле шәхес иде. Мәсәлән, бүлмәбездә яшәгән бик тә йомшак характерлы, эчкерсез Кузнецов белән дуслашты. Ул Мәскәү ягы егете икән. Бервакыт: «Казанда татарлар белән урыслар бәрелешкәнне үз күзем белән күрәсем килгәнгә, монда укырга кердем», — дигән иде. Алар Аяз белән уртак тел таптылар, дуслашып та алдылар. Ул да Аяз юлын сайлады: укырга йөрмәде. Кузнецовның да «Черек күлгә» эләгү ихтималы көчле иде, тик ректорат аны тиз генә «лекцияләргә йөрмәде, имтиханнарны тапшырмады» дигән формулировка белән университеттан чыгарды. Шул да хәтердә калган: Аяз белән Кузнецов «Пассаж» дип аталган бинадагы фотоательеда башларына чалма урап рәсемгә төштеләр...

Аяз янына театр училищесы студенты Мәүлә Солтан килеп йөри иде. Алар кайда, ничек танышканнардыр, без белмәдек, кызыксынмадык та, ләкин соңыннан шуны белдек: ул да «оппозиционер» булган икән.

Аяз Карлагтан (Караганда ГУЛАГ) кайткач, «Чаян»да эшләп алды. Шуны белеп аның янына кердем. Ул мине бик якын итеп каршы алды. «Мороженое» кафесына гына кереп сыйландык, сөйләштек. Кафеда гына тукталуыбызның сәбәбе дә бар: мин салырга әвәс булмадым.

Белмим, дөньяда язмыш дигән нәрсә бар микән — әгәр Аяз безнең белән укуын дәвам итсә, бәлки, ГУЛАГларны күрмәс иде. «Бәлки» генә шул. Чөнки 16 кешедән торган группабызда 2 сексот булган. (Алар моны соңыннан үзләре әйтте. Мәҗбүр иткәннәр.) «Космополитизм» дип күпме кешене харап иттеләр. Аяз ул хәлгә түзә алмас, «янар» иде.

Моннан 5 ел элек минем сценарий буенча Аяз Гыйләҗев турында тулы метражлы фильм эшләнде. Ул чакта мин аның фатирында булдым. Нәкыя ханым белән тату-

бәхетле яшәүләренә куанып киттем.

Бүтән сүз өстәп әйтә алмыйм. Аяз һәрчак күңелем түрендә. Ул миңа якын һәм кадерле кеше! Тормышымның бер мәгънәсе! Күкрәгемдә йөрәгем типкәндә һәрчак шулай булачак!

17 август, 2002

Нәкыя һәм Аяз

Гыйләҗевләр.

1998



РАБИТ БАТУЛЛА

Театрның өч субае

(Мәрсия)

Язгы ташуның дәһшәтле бозлары

күперне алып китмәсен өчен, адәмнәр,

яз кояшы җылыта башлауга ук, күпер

алдына өч урынга өчәр-өчәр итеп имән

баганалар — субай суга торганнар иде.

Нинди генә куркыныч ташу булса да,

нинди генә дәһшәт килсә дә, рәхим-

сез бозларны үз кәүсәләренә алып, ың-

гыраша-ыңгыраша, сыерылып, сыды-

рылып, кәкрәеп бетсәләр дә, субайлар

күперне бу гарасаттан саклап кала иде.

Соңгы 40 ел эчендә театр күперен

әнә шундый субай баганалары кебек

саклап килгән өч каһарман сәнгатькә-

ребез Празат Исәнбәт, Аяз Гыйләҗев

һәм Марсель Сәлимҗановлар бер-бер артлы дөнья куйды. Гүрләре нур булсын! Шу-

шы өч шәхеснең иҗатыннан башка татар театр сәнгатенең тормышын, торышын һич тә

күз алдына китереп булмас иде...

Зәй ягыннан чыккан мәшһүрләр байтак, әмма Зәй туфрагы Аяз Гыйләҗевне генә

биргән тәкъдирдә дә үзен аклаган булыр иде. Чыннан да, Аяз исеме 70 нче еллар

әдәбиятына ургылып килеп керде. Аның һәр әсәре (уңышка очраса да, уңышсыз булса

да) шау кузгатты, бәхәсләр куптара килде.

Аязның беренче пьесасы — «Җиз кыңгырау» — Камал театрында (1959) куе-

лып, зур уңышсызлыкка очраган иде. Хөрмәтле «Чаян» да авторның бу әсәрен

көлке угына тотып, карикатура ясап чыгарган иде. Аның «Җиргә тапшырылган серләр»е белән «Эңгер-меңгер» әсәрләре дә сәхнәдә әллә ни озак бара алмады. Миңа калса, аның бу әсәрләре шактый саллы, катлаулы драматик вакыйгаларга корылган иде, әллә режиссерлар әсәрләрне аңламады, әллә актерлар автор идеясенә каршы уйнады, һәрхәлдә, спектакльләрдә ярашканлык булмады. Автор — бер якка, уенчылар — икенче якка, режиссерлар өченче якка тарта торгач, әсәрләрне бармастай иттеләр кебек.

Аяз Гыйләҗевнең иң нык бәхәс кузгаткан гаугалы әсәре «Өч аршын җир»дер, мөгаен. Аның шул исемдәге пьесасы да катлаулы тормыш кичерде. Бу әсәр, «гаугалы» дигән дан алып, озак елларга сузылган кыйналу чорын узды.

Хөрмәтле Марсель Сәлимҗанов сөйләгән бер мәзәк хәл хәтердә сакланган. Аязның «Өч аршын җир»ен, Туфанның «Ат караклары»н репетицияләре башланырга торганда туктаттылар. Обком секретаре Мирзаһит Вәлиев чакыртып алды да ишектән килеп керүгә үк: «Нишләп син Миңнуллинның «Өч аршын җир»е белән Гыйләҗевнең «Ат караклары»н подпольно куеп ятасың анда?» — дип сүз башлады. Бер пьесаны да укып карамаган, Аяз белән Туфанны аерыр-аермастан әмер бирә, тыя. Килеп кемдер әләкләгән, бусы игътибар белән тыңламаган.

Ниһаять, ул әсәрләр, талантны тыеп торучы бөтен киртәләрне җимереп, дөньяга чыкты, сәхнәләрдә уйналды. Аяз Гыйләҗевкә кадәр колхозлашу чорындагы гаделсезлек һәм үз икмәгенә үзе керәчин сибеп качкан «кулак» турында болай кыю итеп язган кеше булмады шикелле.





Мал иясенә охшар дигәндәй, Аязның әсәрләре дә үзе кебек кытыршы холыклы

була килде. Ташкапчыкта утырып чыккач та Аяз шома гына яши алмады.

Ул: «Безнең күкрәкләр орденнар тагар өчен түгел, тукмалыр өчен киң яратылган!»

— дия торган иде.

Бу кыйналулар гына әдипнең рухын сындыра алмады. Ул үҗәт рәвештә яңадан-

яңа әсәрләр иҗат итә торды. «Көзге ачы җилләрдә» пьесасы аңа олы шөһрәт алып

килде.

Шулай да Аяз Гыйләҗевнең пьесаларын аңлап, аларга ачкыч табардай режиссерлар

булмады кебек. «Өч аршын җир» пьесасын режиссер Фаил Ибраһимов ничек итеп сәх-

нәләштерде! Телеңне йотарсың, валлаһи! Режиссерның табышлары, рәссамның җи-

һазлары, актерларның бирелеп уйнаулары камиллек хасил итә иде. Ул спектакль чын

мәгънәсендәге сәнгать әсәре иде.

Язучы буларак та, гаилә башлыгы буларак та Аяз ага бәхетле иде. Алар Нәкыя апа

белән өч гөрнәдир егет үстерделәр. Аларның берсе — галим Искәндәр Гыйләҗев,

икенчесе — драматург Мансур Гыйләҗев, өченчесе — малтабар Рәшат Гыйләҗев.

Өчесе дә саф татарча сөйләшә, татарча укый торган милләтебез угланнары.

«Милләтнең йөзен саклап калыр өчен иң беренче үз гаиләңдә татарча тәртип ур-

наштырырга кирәк!» — дия торган иде мәрхүм. Аның бу фикере сүздә генә калмады,

әдип моны үз гаиләсендә үрнәк рәвештә исбат итте.


«Мәдәни җомга»

12 июнь, 2002

Аяз Гыйләҗев

А.Гыйләҗевнең уллары (сулдан)

Рәшат, Мансур, Искәндәр



Сөйләкләр

Ай-һай-һай!

Аяз Гыйләҗевнең пьесалары бик еш уйнала башлагач, Нәкый Исәнбәт театрга килә. Ул көнне Аязның бер комедиясе уйналырга тиеш була. Спектакльне Исәнбәт һич көлмичә, елмаймыйча карап бетерә. Исәнбәтне озата чыкканда, Аяз: «Ничек соң, Нәкый ага? — дип сорый. — Спектакль сезгә ошадымы?» Исәнбәт бер сүз дә әйтми. «һе-һе-һе!» дип көлә дә кайтып китә. Аяз тагын яңа пьеса куйдыргач, тагын Нәкый Исәнбәтне театрга чакыра. Спектакль соңыннан ул тагын теге карттан сорый: «Ничек соң, Нәкый ага, бу пьеса ошадымы?» Нәкый Исәнбәт тагын: «һе-һе-һе!» — дип көлә дә таксига утырып кайтып китә.

Өченче тапкырында да шулай кабатлана, Аяз бу юлы түзми: «Нәкый ага, нәрсә соң ул «һе-һе-һе»? — дип сорый. Нәкый Исәнбәт байтак кына дәшми торганнан соң әйтеп куя: «һе-һе-һе — ул, Аяз, «ай-һай-һай!» дигән сүз».

Ризван Хәмид авызыннан

15 сентябрь, 1983

Исең киткән икән...

— Кәрами туган, Аяз Гыйләҗ сине яратып бетерми, диләр, дөресме?

— Дисәләр соң! Шекспир да Толстойны яратмаган!

«Тынгысыз каләм»

1984

Өч йөз илле пилмән

Уфадан дусты Нәҗип Әсәнбайның Казанга килүенә Аяз Гыйләҗев хатыны Нәкыя ханым белән әбисенә ике йөз пилмән ясап куярга куша.

— Кит әле, — ди Нәкыя ханым. — Ул ике йөз пилмәнне кем ашап бетерсен? Аннары мин бит пилмәнне олы итеп ясыйм, җитәр бер root сиксән пилмән.

— Әрәм булыр, кияү! — ди карчык кеше.

— Сез әйткәнне тыңлагыз! — ди Аяз. — Ике йөз аз булыр, өч йөз илле пилмән бөрегез.

Хатыннар пилмән бөрергә тотына. Аяз кунакны каршы алырга елга портына китә. Кайтуга пилмән әзер икән. Аяз кунакны сыйлый башлый. Шулай бик шәпләп пирәшләп, матур сөйләшеп, җан дуслар озак утыра. Утыра торгач, төн җитә, Нәҗип Әсәнбай өч йөз илле ике пилмәнне берүзе ашап бетерә дә йокларга ята. Икенче көнне Нәкыя ханым балаларны мәктәпкә озатырга йөргәндә сөйләнә икән: «Бу балаларга нәрсә генә ашатып җибәрим икән инде?» — ди. «Калган пилмәнне җылытып бир син аларга!» — ди әби. «Бик җылытыр идем дә, бикләр дә җылытыр идем дә, бер генә пилмән дә калмаган шул!» — ди хуҗабикә.

Бу хәлдән соң байтак вакытлар уза. Әби карчык чәй эчеп утырганда:

— Кияү, теге күп ашый торган дустың исәнме әле ул? — дип сорый.

— Ә-ә, Нәҗип Әсәнбайны әйтәсеңме, әби? — ди Аяз. — Исән әле, исән.

— Алай икән, — ди әби. — Вафат булса, миңа әйтә күр, авыр туфрагы җиңел

Р.Хәмид





булсын, урыны җәннәттә булсын дип дога кылырмын!

— Ул үзе әллә кемнәргә дога кылыр әле, әби! — ди Аяз.

Аяз Гыйләҗев авызыннан

25 декабрь, 1985

Үч алу

Драматург Аяз Гыйләҗев белән драматург Шәриф Хөсәенов бервакыт телгә килешкәннәр, ди. Икесе дә әче телле: болар байтак әрепләшкәннәр. Нәтиҗәдә Шәриф бәйнең сүзе аста калган. Вакытлар узгач, дуслашкач, Шәриф бәй Аяз бәйне өенә чакырган. Өй хуҗасы, кунакка урын күрсәтеп: «Утыр шунда! Мин теге вакыттагы бәхәснең үчен алырга чакырдым сине», — ди.

Аяз күрсәтелгән урынга утыра да, яман аваз илә кычкырып, аягына баса. Шәриф бәй Аяз утырасы урынга кактус гөле куйган булган икән.

Хатирәләр дәфтәреннән

1983

Нәкыя ханымның әнисе Нәүбаһар апа. 1969

Аяз Гыйләҗев, Шәриф Хөсәенов. 1960



Төпчек

Аяз Гыйләҗев төпчек улы Рәшатны бик иркәли икән.

— Алтыным, җанкисәгем, баллыкаем, зөбәрҗәткәем минем! — дип әйтә икән.

Беркөнне Аяз, төпчеген ияртеп, көймәдә йөрергә Иделгә чыга. Төпчеге ялгыш көймәне чайкалдырып җибәрә, алар чак кына суга егылып төшмиләр. Аяз, атасы-анасы белән сүгенеп, төпчеккә берне салып җибәрә дә:

— Юньләп йөре, дуңгыз баласы! — дип сүгенеп ташлый. Бераздан соң, бу вакыйга онытыла төшкәч, Аяз төпчеген сөя икән: «Алтыным бит ул минем, җанымның бер кисәге, татлыкаем минем, шикәрем син, балым син, ефәк баулы былбылым син...»

Рөстәм Мингалим авызыннан

Бер киштәдә ике китап

Аяз Гыйләҗевнең җәйге ял йортындагы китап киштәләре төрле китап-журналлар белән шыгрым тулы икән. Бары тик бер шүрлек кенә буш диярлек. Анда нибарысы ике китап тора. Урын җитмәү сәбәпле идәндә өелеп торучы китапларга карап, Батулла хуҗага дәшкән:

— Аяз абый, нигә бу бичара китапларны менә бу буш киштәгә урнаштырмыйсың?

— ди.

— Юк, парин! — ди Аяз. — Бу киштәгә мин татарның бөек язучыларын гына куям. Әнә анда Әмирхан Еники дә Равил Фәйзуллин. Яз, слушай, син дә шулар кебек, бу киштәдә өченче китап синеке булыр!

Ни сәбәпледер Аяз Гыйләҗев белән Равил Фәйзуллинның аралары бозылып китә.

Шул заманда Батулла тагын Аяз Гыйләҗевнең җәйге өенә кунакка бара. Китап киштәсенә бакса, ни күрсен, анда бер генә китап: Еники генә. Аны-моны уйлап тормастан, Батулла:

— Аяз абый, кая китте Фәйзулла? — дип сорый.

Сулдан — М.Мәһдиев, Ә.Еники, А.Гыйләҗев. Пицунда, 1986

Моңа каршы өй хуҗасы сүгенеп ала да болай ди:

— Кире уйладым әле мин, слушай, парин...

Байтак вакытлар үткәч, Аяз Гыйләҗев белән Әмирхан Еники арасыннан да кара мәче йөгереп уза. Батулла Аязның җәйге өенә килгәч, шуны күрә: буш киштә юк, аннан Еники китабы да алынган, ул киштәгә элек идәндә аунаган «Новый мир» журналы дыңгычлап тутырылган була.

Батулла, Аязга яңа чыккан китабын сузып:

— Ага кеше, менә син әйткән өченче китапны мин яздым! — ди.

Әмма хуҗа кырыс кына:

— Күрмисеңмени, сиңа урын юк! — ди.

Дөяләр кемгә төкерә?

Каракалпакстанда, Нөкәс шәһәрендә Татарстаннан килгән кунаклар шәрәфенә бай табын әзерләнә. Олы-бай мәҗлескә махсус төзелгән исемлектәге татар язучыларын гына чакыралар. Орденсыз, премиясез, исем алмаган язучыларны чакырмыйлар. Чакырылмый калганнар арасында Аяз Гыйләҗев тә була. Боларга кече табын, икенче сортлы мәҗлес оештырыла. Табын башында Каракалпакның яшьләр газетасы редакторы була. Бик шәпләп төшереп алгач, хуҗалар кунакларны шәһәр буйлап йөрергә алып чыгалар. Шулай йөргәндә, болар мондый күренешкә тап була: бер ишәк бауга тагылган бер дөяне тартып бара икән.

— Нәрсә бу, ыслушай? — дип сорый Аяз Гыйләҗев каракалпак егетеннән.

— Дөя күп итеп пахта ашый да күбенә, йөри алмас була. Шуннан соң аны ишәккә тагып тарттыралар. Әгәр ишәк туктаса, дөянең ачуы чыга, ул ишәккә төкерә башлый, дөя ишәкне үзенчә эт итеп сүгә! — дип аңлата егет.

Шулчак Аяз Гыйләҗев кычкырып елый башлый:

— Ыслушай, мин бит инде ул ишәк. Ә дөяләр олы банкетта утыра. Мин бит татар әдәбиятының ишәге, үзем иң авыр йөкне тартам, дөяләр миңа төкерә!

Мөдәррис Әгъләм авызыннан

1983

Янды... дигәндә

Аяз Гыйләҗевкә илле яшь тулган көннәр. Берничә язучы кечкенә генә мәҗлес корып утыралар икән. Төн урталары җиткәндә: «Әйдәгез безгә!» — дип, Мәхмүт Хәсәнов, колачын җәеп, урыныннан куба. Аның гадәттән тыш кунакчыллыгын белгәнгә күрә, берәү дә каршы килә алмый. Илдус Гыйләҗевнең машинасына утырып чыгып китәләр болар Казаннан Яшел үзәнгә. Юлда: «Иртәнгә студентларга лекция укыйсым бар», — дип, Мөхәммәт Мәһдиев кенә өе каршында төшеп кала.

Сәгать төнге бердә тупырдап килеп кергән ирләрне Мәхмүт Хәсәновның хатыны Мәрьям ханым елмаеп каршы ала. Шунда ук өстәлгә сый-нигъмәт тезә башлый.

— Их, Мөхәммәт Мәһди килә алмады бит, ә! «Бәхилләшү» дигән шәп роман язган. Әле берегез дә миннән кала аны укымаган. Талант, чукынчык, Ходай биргән талант! — ди Аяз Гыйләҗев, табын түрендә килешле утырып.

Тере классик сүзләреннән очынып киткән Марсель Галиев:

— Җәмәгать, рөхсәт итсәгез, бер сүз әйтер идем! — ди.

Классиклар аңа ым кагалар.

— Достоевский әйткән бит, әгәр чит планетадан бер зат килсә, Кешелек китабы итеп аңа бары бер әсәрне — Сервантесның «Дон Кихот»ын гына биреп булыр иде, дигән. Шуның кебек, әгәр чит планетадан килгән берәү безнең халык белән кызыксынса, аңа Мөхәммәт Мәһди китабын гына биреп булыр иде!.. — ди Марсель Галиев һәм чәкештерергә дип бокалын суза.

Әмма кулы өметсез бушлыкта асылынып кала. Аяз Гыйләҗевнең дә, Мәхмүт Хәсәновның да башлары иелгән, кашлары җыерылган, иреннәре салынып төшкән.



Бер мизгелгә пычак йөзе сыман үт-
кен тынлык урнаша. Мөлдерәп тул-
ган бокалларның күзенә ак төшә. Бер
кырыйда тынсыз калган Илдус Гый-
ләҗев:

— Янды җегет, хараплар гына бул-
ды... — дип офтанып куя.

Коточкыч авыр хәлгә калганлыгын
мизгелнең меңнән бер өлешендә аңлап
алган Марсель Галиев баш миендәге
барлы-юклы фикерләрен актара баш-
лый, кинәт... зиһене ачылып китә, соң-
гы фикере ничек буласын белмәгән
хәлдә, үлем исереклеге белән сөйли
башлый:

— ...Һәм ул...

— Кем? — ди Мәхмүт Хәсәнов.

— Ачыклап сөйлә! — ди Аяз Гый-
ләҗев.

— Теге чит планетадан килгән ке-
шене әйтәм, — ди Марсель Галиев.
(Әһә, фикернең азагы табылды, кыю-
рак бул!) — Чит планета кешесе Мәһ-
ди әсәрен укыгач, бу гаҗәеп татар хал-
кының тагын да бөегрәк язучылары бу-
лырга тиеш дип, Аяз Гыйләҗ һәм Мәх-
мүт Хәсән китапларын соратып алыр

иде!

— Шәп! Менә монысын әйбәт әйттең! — дип, Мәхмүт Хәсәнов тәрәзәне зеңгелдәтеп кычкырып җибәрә.

— Ыслушай, парин, моның өчен мин агу да эчәм! — ди Аяз Гыйләҗев, күзлек астыннан борынын югары чөеп.

Бокалларны чатнатып чәкештерәләр, аягүрә басалар. Чырайларына бәхет нуры йөгергән классикларга карап сөенгән Марсель Галиев маңгаена чыккан салкын тирне сыпырып куя.

«Шәһри Казан»

11 октябрь, 1991

Сүзсез дә аңлашыла

Бер яшь язучы Аяз Гыйләҗевкә үзенең кулъязма романын биргәндә:

— Зинһар, укып чыгып фикерләрегезне әйтсәгез иде! — дигән.

Аяз бәй романның беренче өлешен укыган да авторга кире кайтарып биргән.

— Икенче бүлеген укып чыкмадыгызмыни, Аяз абый? — дигән автор.

— Калган өлешен дә син язгансыңдыр бит, парин? — дигән Аяз бәй.

«Тынгысыз каләм»

1984

Социализм яулаган үрләр

Берничә язучыны Минзәлә педагогия училищесына очрашуга чакыралар. Аяз Гыйләҗев матур гына кереш сүз сөйли:

— ...Язучыларның элек үз бинасы, үз йорты юк иде, моңарчы без иске бинаның бер-ике бүлмәсендә кысанда яшәдек. Менә озакламый, без, ягъни Язучылар берлеге,

Мәхмүт Хәсәнов

элеккеге байлардан калган гаҗәеп матур бинага күчәчәкбез. Тукайның йөз еллыгына тагын бер яңалык: Тукай урамындагы элеккеге байлардан калган гүзәл йортта Тукай музее ачылачак. Менә сез дә искиткеч матур бинада элеккеге байлардан калган йортта укып белем аласыз. Саный китсәң, социализмның казанышлары байтак инде аның, бәхетле булыгыз, туганнар.

Минзәлә педагогия училищесы

26 июнь, 1985

Тукмар өчен туган җилкәләр

Г.Тукай исемендәге Дәүләт медален тагып куйгач, Аязга әйткәннәр:

— Аяз ага, сезнең күкрәк киң бит, аны бер медаль генә каплый алмас! — дигәннәр.

— Орден-медальләр тагар өчен безнең күкрәкләр киң булса да, штраф-тукмаклар алыр өчен җилкәләр дә бик киң! — дигән Аяз Гыйләҗев моңа каршы.

Минзәлә театрын озату мәҗлесендә әйтелгән сүз

30 июнь, 1983

Урысның бөеклеге

Мәскәүгә язучылар корылтаена баргач, Аяз Гыйләҗев урыс язучысы Беловка әйткән:

— Горький, Чернышевский, Короленко кебек олы урыс язучылары урыс булмаган халыкларның язмышы белән якыннан кызыксынган, ә сез нигә алар кебек киң күңелле түгел? Нигә яклауга мохтаҗ халыкларны яклап корылтайда сөйләмисез? Сез бит: бөек урыс халкы вак халыкларны үз канаты астына алды, дип мактанасыз. Канат астына алгач, яклагыз, саклагыз, ярдәм итегез, ниһаять! — дигән.

— Эх, Аяз, — дигән Белов, — без, урыс язучылары, үзебез сезнең яклауга мохтаҗ. Яһүд басты әдәбиятны, урыс язучылары бетеп бара.

Марсель Сәлимҗанов авызыннан

19 декабрь, 1985

Сай хәтер

Аяз Гыйләҗев Фәнзаман Батталга:

— Әгәр берәр вакыт синең янга килеп: «Карале, Фәнзаман Баттал кирәк иде, күрмәдегезме?» — дип сорасам, аптырап калма, ни өчен дигәндә, күз хәтере бик начар минем, — дип сөйләнеп барганда, шуларга каршы килүче берәү Аяз Гыйләҗевне туктаткан, сөйләшеп торганнар. Әлеге кеше китеп баргач, Фәнзаман Баттал:

— Кем булды ул, Аяз абый? — дип сораган.

— Егерме биш еллар элек бер хикәясен укыткан иде бу кеше. Кыяфәте истә калган калуын, ә менә исемен хәтерләмим, — дигән өлкән әдип. — Әйтәм ич, хәтер бик сай минем, парин.

Хатирәләрдән

1983

Японнар ни өчен алда?

Яшь галимнәр Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь төбәге Чимбәләй авылына килеп чыгалар. Бу — Хәйдәр Бигичевнең туган авылы икән. Профессор Миркасыйм ага Госманов колхоз рәисе, Социалистик Хезмәт Каһарманы Юсипов янына керә. Максатын аңлатыр өчен сүз башлый:

— Безгә бигрәк тә иске кулъязмалар кирәк, иптәш Юсипов, борынгы китаплар безне бик кызыксындыра! Зинһар, ярдәм итегез!



Колхоз хуҗасы ярдәмләшергә ризалык бирә. Бер-ике көннән соң Миркасыйм Госман кайтып китә. Галимнәрнең җитәкчесе булып Искәндәр Гыйләҗев кала. Халык белән сөйләшеп, бераз материаллар туплагач, кайтып китәр алдыннан гына Казан галимнәренең машинасы ватыла. Гыйләҗев янә колхоз җитәкчесе Юсипов янына китә. Машинага кирәк нәрсәне алыр өчен, Юсипов, Искәндәр Гыйләҗевне утыртып, үз машинасы белән «Сельхозтехника»га китә. Юлда барганда, коммунист Юсипов бик аптырап, гаҗәпсенеп әйтеп куя:

— Ит, сөт, икмәк кирәк дәүләткә! Нигә кирәк ул иске китаплар, аңламыйм! — ди.

Яшь егет Искәндәр Гыйләҗев авыр көрсенеп, болай ди:

— Сез, иптәш Юсипов, япон техникасына ничек карыйсыз?

— Һу-у, — ди Юсипов, — японнар Америкадан да алда.

— Ә беләсезме ни өчен японнарның техникасы алда, тормышы бай, матур?

— Кем белә инде аны! — ди коммунист Юсипов.

— Японнар иске китапларны хөрмәт итә, саклый, җыя, югалтмый! Шуңа күрә аларның экономикасы безнең ит, сөт, икмәк, бәрәңгедән йөз елга алда! — ди Искәндәр.

Искәндәр Гыйләҗев сөйләгәннәрдән

25 сентябрь, 1987

А.Гыйләҗев олы улы Искәндәр белән. 1983

ШӘРИФ БИККОЛ

Болай уксыңдыр дип белмәгән идем...*

«Күрәләтә безне рәнҗеткән», — дип,

Каргап булмый язмыш-шилманы.

Бер табында

бик еш утырырга

Ходай безгә насыйп кылмады.

Тик,

Мин,

«Биргәнеңә шөкер», — димен.

Бәндәләрдә төрле талым бар:

Җилләтеп тә бетәр иде, бәлкем,

Бик еш булса уртак табыннар...

Җитмәсә дә ярты дистәгә дә,

(Тылсым алар,

серле фал алар!)

Бергә күңел ачкан бу минутлар

Асылыңны ачып салдылар.

Икеләнеп тормый тарафыңа

Юнәлттем мин күңел җилкәнен:

Мин бит инде

Саф алтынны җиздән

Аерырлык яшькә җиткәнмен!

Шундый хакыйкать бар:

Юнь ир белән

Бер утырулары — бер гомер.

Хак сүз икән:

Йөрәк учагына

Син өстәдең тере бер күмер.

Бу заманда

Өмет өзгән мәлдә

Җанга ямь-юаныч табудан

Еш димәем,

Булсын әле алда

Бергә утырачак табыннар!

Моңарчы син

Серле китап идең,

Инде —

байтак бите укылган...

Болай уксың дип белмәгәйнем,

Шәп кешесең икән, чукынган!

Переделкино

7 ноябрь, 1992

* Аяз соңгы мәртәбә 1992 елда Переделкинога барды. Шунда алар башкорт язучысы Шәриф Биккол

белән өстәлдәш булганнар. Шәриф Биккол Аязны бик яратып, сокланып аралаша башлаган. Яллары тәмам-

ланганда, шушы шигырьне язып биргән. Бу шигырь Шәриф Бикколның җыентыкларына да кертелгән дип

беләм. (Нәкыя Гыйләҗева искәрмәсе.)



ДИАС ВАЛЕЕВ

Молот любви

К 75-летию со дня рождения народного писателя Татарстана Аяза Гилязова

В 1969 году меня вдруг начали таскать на «профилактические допросы» в КГБ. Оказывается, в своих рассказах и повестях, к тому времени еще нигде не опубликованных (тем не менее их стопка аккуратно возвышалась на столе у главного из четырех дознавателей), я злостно «очернял действительность». Через двадцать лет эта публика лубянского розлива беззастенчиво и со всеми потрохами сдаст стратегическому противнику великую страну, но тогда еще они играли роль патриотов. И я, молодой писатель, был для них почти «враг народа». Меня надо было хорошенько попугать и поучить уму-разуму. И вот после семи с половиной часов перекрестных допросов меня наконец выпустили. Гудела голова, тело налилось тяжелой усталостью, а я стоял на улице в раздумье. Надо было с кем-то посоветоваться. Назавтра я опять обязан был явиться к цензорам духа для продолжения «беседы». Но прежде нужно было поговорить с человеком, которому бы я всецело доверял.

Единственным таким человеком в Казани был для меня писатель Аяз Гилязов.

Шесть лет своей жизни — в самый разгар молодости — он провел в лагере где-то под Карагандой тоже за «очернение действительности», и всю эту гэбэшную публику, их приемы знал не понаслышке. И в тот день, не заходя домой, я поехал прямо к нему.

Аяз Гилязов жил тогда с семьей: жена Накия, сыновья Искандер, Мансур и Рашат,

мать жены Наубагар апа — в маленькой двухкомнатной «хрущевке» где-то на улице Воровского. Первым делом он накормил меня, ведь у меня за весь день крошки во рту не было, напоил крепким чаем. Тогда мы проговорили с ним около двух часов. Главное, я почувствовал, что не одинок.

Как писатель и как человек, Аяз Гилязов в те годы очень многое предопределил в моей жизни. Прежде всего это был настоящий писатель (среди членов Союза писателей их не так уж и много). Безмерно и разнообразно талантлив, щедр, строг, принципиален и одновременно отзывчив. Работяга, каких поискать, — он писал много, неуемно и с удовольствием. Никогда не знал в себе чувства зависти. Некоторых наших общих знакомых зависть и злоба съедали совершенно, но кому может завидовать творец от Бога? Всегда, в любые времена, в минуты славы и годы забвения, он — величина самодостаточная. Иными словами, Аяз Гилязов всегда являлся для меня примером, был учителем просто в силу своей внутренней природы.

Благодаря ему в то сложное для меня время я познакомился с Владленом Анчишкиным, автором «Арктического романа», заведующим редакцией художественной прозы издательства «Современник», где позже вышла первая книга моей прозы. Гилязов же свел меня близко еще с одним замечательным человеком и писателем — Гарифом Ахуновым, который перевел одну из моих первых пьес на татарский язык и убедил Марселя Салимжанова поставить эту драму на сцене Театра им. Г.Камала.

В конце 60-х и в 70-е годы мы общались много и часто. К этому времени Аяз Гилязов переехал в трехкомнатную квартиру на улице Восстания, а я жил сравнительно недалеко, на проспекте Ямашева. Сколько километров мы исходили по окрестным улицам и улочкам, проводя время в бесконечных разговорах — конечно же, о политике, разумеется, о женщинах, но прежде всего и в основном — о литературе. В летнюю пору часто встречались в Займище, были соседями по даче.

Он был из того поколения, что родилось на крутом повороте отечественной истории, — в стране ломался старый крестьянский уклад, создавались колхозы. Из того

поколения, чьи отцы и старшие братья, взяв в руки винтовку или автомат, ушли — у многих навсегда — на Великую Отечественную войну. Из тех, что выросли, как писал он сам, «под единственным уцелевшим крылом овдовевших матерей». Наконец, он был из того поколения, которое застало и непосредственно ощутило на себе все «прелести» ГУЛАГа. Не потому ли один из самых мощных корней гилязовской прозы и драматургии — это национальная идея, а второй — История?

Когда я близко познакомился с ним, Гилязов уже написал «Шамиля Усманова» и «Желтым цветом цветут подсолнухи», в которых нашла отзвук жестокая эпоха революции и гражданской войны. Трагические процессы, происходившие в татарской деревне в тридцатые годы, нашли отражение в знаменитой повести Гилязова «Три аршина земли». Вокруг нее было много слухов, домыслов: автора то возносили, то преследовали... Великая Отечественная война и сороковые годы отражены писателем в ряде произведений — «Сказание о Любви и Ненависти», «Люблю тебя, моя нежная...», «Вернись к истоку», «Весенние караваны». Наконец, современность в повестях «Посередине», «Лицом к лицу», «Тысячекилометровый путь», в романе «За городом — зеленые луга», в пьесах «Сумерки», «Один потерянный день».

Почему-то отчетливо запечатлелась в памяти премьера «Сумерек» в ТГАТ им. Г.Камала, состоявшаяся в апреле 1971 года. В пьесе и спектакле столкнулись два взгляда на жизнь — быть довольным собой, смириться со своей духовной леностью, жить для того, чтобы только жить, или искать какой-то более высокий смысл человеческого бытия на земле, пусть даже такого короткого?

Для манеры Гилязова-драматурга (а им написано сорок пьес!) характерны не столько насыщенные определенным цветом мазки живописи, сколько полутона, акварельная тонкость, работа с подтекстом. И потому, разумеется, играть «Сумерки» было нелегко. Нелегко, потому что не всегда словесный ряд выражался в прямом внешнем действии, но всегда тончайшие переходы, переливы в психологическом состоянии героев должны были быть выражены убедительно и понятно для зрителя. Спектакль,

поставленный Празатом Исанбетом, вылился в серьезное аналитическое исследование современной жизни, заставляющее людей всмотреться в самих себя.

И в целом Аяз Гилязов, на мой взгляд, художник ярко выраженного монологического стиля. Мир образов и идей, к которым, в часности, тяготеет его проза, как бы локализован вокруг личности самого рассказчика. Ход художественной мысли направлен обычно от конкретного быта к бытию. Сплав воспоминаний героя и лирических монологов автора художественно оправдывает появление в этом контексте философских размышлений о любви, о родине, о судьбах народа. Весьма показательна в этом плане, пожалуй, повесть «Сказание о любви и ненависти». Молотом любви, бьющим по наковальне ненависти, куется душа подростка военных лет. И благодаря этому она может выдержать любое испытание. Человек Гилязова не одинок. Он живет в своем мире, и путь его — это путь человека, постигающего красоту и боль своей земли. «Боль людей, боль времени, боль мира были и моей болью, я был живой частицей мира, заряженной не простой житейской необходимостью, а чем-то большим, доселе мной не испытанным», — говорит о себе герой повести «Посередине».

У каждого крупного писателя есть свой определенный круг мотивов, сюжетов, идей. Главный герой Аяза Гилязова — это человек, заполненный всегда чем-то большим, нежели эгоистическая жажда самоутверждения. Как и сам писатель, он мыслит более крупными категориями, что и придает произведению, несмотря на известную сюжетную локальность и национальный колорит, поистине философское звучание. Приведу по этому поводу мнение одного латиноамериканца — Хосе Карлоса Мариатеги, философа, основателя коммунистической партии Перу: «Мы не должны игнорировать национальную действительность. Перу — часть мира, который движется по общей траектории». Вот и для Аяза Гилязова татарская действительность не есть что-то обособленное, замкнутое на себе. Он воспринимал ее не в статике, а через это движение по общей траектории. Поэтому Гилязов и был настоящим писателем и уже при жизни классиком.

В конце 80-х и в 90-е годы он пишет романы-воспоминания «В чьих руках топор?», «Давайте помолимся», романы-хроники «До шестого августа...», «Другого пути нет» (последние два в соавторстве с А.Литвиным), снова возвращается и полностью переписывает свой ранний роман «За городом — зеленые луга», помогает завершить роман о сибирских татарах одному из своих коллег. Он пишет много. Пишет до тех пор, пока ему не отказывают глаза. Но и после этого он продолжает надиктовывать тексты жене. Примерно за неделю до смерти он еще диктовал...

Один год не дожил писатель до своего 75-летия. Но дело, конечно, не в дате. Она лишь повод для размышлений. Важно не то, сколько человеку исполнилось бы лет, а то, что он успел сделать за годы, дарованные ему судьбой.

А сделано Мастером много. Многое издано. Но немало из написанного находится еще в рукописях. А значит, путь Гилязова-творца еще не окончен.

На внешний, поверхностный взгляд вроде бы все хорошо. Аяз Гилязов — народный писатель Татарстана, лауреат Государственных премий, в его честь открыт даже дом-музей в деревне Баграж Заинского района, где он родился и куда вернулся и жил в течение двух последних лет...И все-таки я не назвал бы писательскую судьбу Аяза Гилязова счастливой. Тень гулагского прошлого много десятилетий довлела над художником.

Помню 1978 год. Гилязову — пятьдесят лет. Я готовил передачу о нем для татарского телевидения, но в последний момент был дан «красный свет», и передача не состоялась. Кто они, эти цензоры из телерадиокомитета? Никто теперь не помнит ни их имен, ни их фамилий. Но они и им подобные ставили шлагбаумы, тормозили выход книг, спектаклей...

Национальный характер и судьба народа, ход национальной истории — вот основные сюжеты мировой литературы. И когда я беру романы латиноамериканца Маркеса, египтянина Юсуфа Идриси, японца Ясунари Кавабаты, североамериканца Фолкнера, киргиза Чингиза Айтматова, татарина Аяза Гилязова, я слышу в них примерно одну песню...

«Республика Татарстан»

2003, 31 янв.

А.Гыйләҗев, Г . А х у н о в , М.Мәһдиевнең максатлары, сөенечләре уртак иде. 1993



РАЗИЛ ВӘЛИЕВ

# Г о м е р е м н е ң аяз көннәре...

Аяз ага белән ныклап танышып, якынаеп китүем һич көтмәгәндә-уйламаганда булды. Минем Мәскәүдә, Әдәбият институтында укып йөргән чагым. Казанның рухи кысанлыгыннан соң Мәскәүнең чагыштырмача хөр фикерле мохитенә килеп эләккәч, башта бераз аптырап та калган идем. Әмма бу халәткә тиз ияләштем, бер ел эчендә бераз Мәскәүчә уйларга, Мәскәүчә яшәргә дә өйрәнә башладым кебек. Кем әйтмешли, кесәләр буш булса да, күңелләр хуш, йөрәкләр куш чак... Ул заманда безнең кулдан килмәгән бер эш тә юк сыман иде. Мәскәүдә беренче очраган татар кызына гашыйк булып, берничә айдан аңа өйләнеп тә җибәрдем, озакламый Сөембикә исемле кызыбыз да дөньяга килде. Бала белән тулай торакта яшәргә ярамый дип куып чыгаргач, Мәскәү читендәге бер иске дачага барып сыендык. Гаилә асрарга кирәк булгач, төннәрен заводта тимерчелек цехында эшли башладым.

Менә шулай шау-гөр килеп, очын-очка ялгап яшәп ятканда, Казаннан мәшһүр язучыбыз Аяз Гыйләҗев килүе хакындагы хәбәр ишетелде. Җитмәсә әле ул безнең тулай торакның кунакханә бүлмәсенә урнашкан икән. Аяз ага — минем өчен гыйбрәтле язмышы белән дә, олы иҗаты белән дә буй җитмәслек илаһи шәхес. Казанда

дөнья күрә алмыйча Мәскәүдә басылып чыккан «Өч аршын җир» повестеның шаулаган еллары. «Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, институтта лекциядән чыгып барганда, ишегалдында Аяз аганы күреп алдым. Югары әдәби курсларда укучы шагыйрь Рәдиф Гаташ белән кызып-кызып әңгәмә коралар иде болар. Кул бирешеп исәнләшкәндә, Аяз ага үткен күзләре белән мине аяк очларымнан баш түбәмә кадәр сөзеп чыкты да: «Шушы буламыни инде «урыс капкаларын каерып ачучы егет?» — дип көлемсерәп куйды. Минем әле генә «Казан утлары» журналында чыккан шигырьләремнән хәбәрдар икәнен аңлагач, кинәт канатланып киткәндәй булдым, Аяз абый белән ике арадагы бушлык күз ачып йомганчы юкка чыкты. Тулай торакка кадәр таксида кайтканда да, Рәдиф бүлмәсендә озаклап чәй эчкәндә дә мин Аяз ага сүзләренең сихеренә бирелеп, телсез калгандай берни дәшмичә тыңлап тордым. Ул моңа кадәр мин ишетеп кенә белгән, әсәрләре «идән астыннан» гына таратылган Солженицын, Гумилев, Пастернак кебек тыелган язучылар, үзебезнең Исхакый кебек мөһаҗир затларыбыз хакында шулкадәр тәфсилләп һәм тәмләп сөйли ки, мин ирексездән әле генә дөньяга килгән сабый бала кыяфәтендә авыз ачып тыңлыйм да тыңлыйм. Мәҗлес ахырында ул Рәдиф белән миннән яңа шигырьләребезне дә укытты. Бераз мактап, салпы якка салам кыстырып та алды. «Язгыз, көнне, төнне белмичә языгыз, сезнең әле шашып яза торган чагыгыз! Сезнең яшьтә мин дә шигырь яза идем, парин. Өч чемодан шигырем әле дә дачада ята», — дип һаваланып куйды ул. Монысы безне котырту өчен генә булгандыр инде дип уйладык. Ул сүзен дәвам итте: «Әмма әйтәсе сүзне шигырьгә генә сыйдырып булмый. Әнә Пушкинны, Лермонтовны, Пастернакны алыгыз. Бөекләрнең пакусы киң була. Проза да язып карагыз сез... Рәдиф бөегебез коеп куйган шагыйрь инде ул, шуңа күрә проза белән вакланып, җиргә төшеп тормас, ә менә сиңа ныклап торып киңәш итәр идем...» Шулчак мин, хыялга бирелеп: «Минем язган повестем бар инде», — дип әйтеп ташлаганымны сизми дә калдым. Ә чынында бу — шагыйранә ялган, әлеге повесть кәгазьгә төшмәгән, ә бары тик минем күңел түрендә генә бөреләнгән иде. Аяз аганың: «Мин әле Мәскәүдә бер атна торам, эшлә-

рем беткәч, китәр алдыннан дачаңа кунакка килермен, повестыңны әзерләп куй, бергәләп укырбыз», — дигән сүзләрен ишеткәч, бөтен тәнем кызыша башлады.

Инде нишләргә? Бер атнадан Аяз ага минем повестьны укырга киләчәк, ә аның әле бер бите дә язылмаган. Минем гомеремдә бер тапкыр да мондый ахмак хәлдә калганым юк иде. «Бу һич тә алдашу түгел, чынлыкта повесть инде күңелемдә оешып җиткән, аны дөньяга китерәсе, кәгазьгә төшерәсе генә калган», — дип, үз-үземне юата-юата «Перловка» станциясендәге иске дачага кайттым да өстәл янына кадаклаunion утырдым. Ярый әле институтта каникул вакыты — укырга йөрисе юк. Мин көнне дә, төнне дә онытып яздым да яздым. Хатыным Алия куйган чәйне эчәргә генә бүленәм дә тагын кәгазь өстенә капланам. Тәүлегенә егерме-егерме бишәр бит яза торгач, Аяз ага киләсе көннең таңында мин «Эт кояшы» дигән повестемны тәмамладым. Атна эчендә җиңеләеп калган гәүдәмнең авырлыгын да тоймыйча, Аяз аганы алып киләчәк электричка янына очып, канатланып бардым... Гомумән, кешеләргә, бигрәк тә яшь-җилкенчәк язучыларга иҗат дәрте өстәү, канат кую — Аяз аганың иң асыл сыйфатларының берсе булгандыр. Дөрес, вакыты-вакыты белән ул бик кырыс, таләпчән, хәтта усал да була белә иде. Әмма нигәдер хәтеремдә боларның берсе дә алай тирән уелып калмаган, ә инде заманында күңелемә ул салган иҗат кузлары әле хәзер дә, вакыт-вакыт кызыша башлап, йокыларны качыра, кулга каләм алырга мәҗбүр итә. Ул безнең шактый таушалган кечкенә дача кисәген мактау өчен дә матур сүзләр тапты, ике каен арасына тартылган таганга утырып, көлә-көлә атынып та алды. Шушы «хан сарае» өчен аена күпме түләгәнебезне дә сорарга онытмады, өстәлемдә Рабит Батулладан калган вак шрифтлы борынгы язу машинкасын күргәч: «Нәшриятлар мондый стандартны кабул итми», — дип кисәтеп тә куйды. Ул һәрнәрсәне күрә, һәрнәрсәгә игътибар итә, аның һәрнәрсә хакында үз фикере, һәр кешегә, һәр вакыйгага үз мөнәсәбәте бар иде. Шулчак мин эчтән генә: «Чын язучы, чын прозаик шундый булырга тиештер инде», — дип уйлап куйдым. Алиянең аннан-моннан юнәтеп пешергән пылавын мактый-мактый ашаганнан соң, ул: «Әйдә, күрсәт инде шедеврыңны!» —

дип, йорт хуҗасыннан калган шыгырдавык диванга җайлап утырды. «Мин аны машинкада басарга өлгермәдем бит, кулъязма хәлендә генә ул», — дип ык-мык килә-килә аклана башлаган идем, моңа да исе китмәде. (Югыйсә аннан: «Ярый алайса, Казанга машинкада бастырып алып кайтырсың, шунда укырмын», — дип әйтүен көткән идем.) «Прозаны кулдан язып торма син, турыдан-туры машинкада басарга өйрән. Шулай җайлырак ул, язганың күзгә ачык күренеп тора. Әйдә, алайса син кычкырып укы, мин тыңлармын», — диде.

Моңа кадәр инде күп мәртәбәләр имтихан биргәнем булса да, монысы минем тормышымда иң авыр, иң җаваплы сынау булгандыр. Әгәр повестьны укып бетергәннән соң Аяз ага миңа «икеле» куйса, бәлки, киләчәктә бөтенләй иҗат эшенә кул селтәгән, һичьюгында, үз-үземә ышанычым бик нык кимегән булыр иде... Мин өч сәгать буена берөзлексез укыдым да укыдым. Аяз агайга күтәрелеп карарга да куркып укыдым. Әгәр шулчак ул туктатып берәр авыр сүз әйтсә, минем бөтен хыялларым, бөтен өметләрем, бөтен дөньям бер мизгелдә чәлпәрәмә килер кебек иде. Повестьның соңгы җөмләсен тәмамлагач, мин, ниһаять, Аяз агайга күтәрелеп карадым. Аның йөзеннән хәйләкәр елмаю дулкыннары йөгереп үткән кебек булды. Шулчак ул торып басты да: «Булган бу, парин, — диде. — Әмма күңелеңә авыр алма, повестеңны Казанда басулары икеле. Казан — бик тар күңелле, тынчу һавалы шәһәр ул. Маяковский әйтмешли, тәрәзәсен ачып җилләтәсе бар аның. Тик син язуыңнан туктама, бүген басмасалар, иртәгә басарлар, иртәгә басмасалар — берсекөнгә. Дөнья гел болай гына бара алмый ул, дустым».

Саубуллашканда, Аяз ага миңа язу машинкасы алырга акча биреп калдырды. «Пушкин урамында бик шәп «Эрика» машинкасы сата торган кибет бар. Немец машинкасы! Аны Мәскәү кешеләренә чиратка яздырып кына саталар. Икене алырсың, берсе үзеңә булыр. Югыйсә бу машинкаңда шедевр язсаң да, нәшриятлар кабул итмәячәк», — диде.

Аяз аганың юраганы юш килде. Минем «Эт кояшы» повесте хакында Татарстан

Язучылар берлеге идарәсендә фикер алышу оештырдылар. Бәхәс бик кызу булып, арада яхшы гына фикерләр әйтелсә дә, нәтиҗәне нәшриятның ул еллардагы баш мөхәррире ясады. «Мин бу әсәрнең уңай якларына туктап тормыйм, анысы хакында сөйләделәр инде. Без бүген сүз алып барган повесть совет чынбарлыгын бозып, караллтып күрсәтә. Шундый әсәрнең талантлы каләм белән язылуы аның зыянлы булуын икеләтә арттыра гына. Мин авторга тормышның якты якларына күбрәк игътибар итәргә, әдәбияттагы буржуаз агымнарга иярмәскә тәкъдим итәр идем». Баш мөхәррирнең тешләрен шыкылдата-шыкылдата сөйләвен тыңлаганда, миңа нигәдер кулымдагы зынҗыр чыңнары ишелгәндәй булды, күз алдыма ап-ачык булып Аяз аганың язмыш шәүләсе килеп басты... Егерме яшьлек студент тарафыннан язылган «Эт кояшы» повесте ил өстендәге куе болытлар бераз тарала төшкәч, егерме ике елдан соң (1990 елда) гына тулысынча басылып чыкты.

Ә язу машинкасын Аяз агайга барыбер алып кайттым мин. Һәм менә бу язмамны нәкъ менә шул Аяз ага белән бергә алган «Эрика» машинкасында басып утырам. Әмма ул машинкаларны алу җайлы гына булмады. Аяз аганың машинка алырга җыенуын ишетеп, Казаннан миңа тагын өстәмә заказлар килә башлады. Беркемгә дә баш тартып булмый, чөнки һәммәсе дә мин белгән, хөрмәт иткән мөхтәрәм шагыйрьләр. Тик Мәскәү кибетендә башкала пропискасы булган бер кешегә бер машинка гына

А.Гыйләҗев Разил Вәлиев кайтарткан язу машинкасы артында

саталар. Ә миңа бишне алырга кирәк. Каян табарга тагын дүрт москвичны? Җитмәсә моның өчен сәгать дүрттән барып Пушкин урамындагы кибет янында чиратка басарга, анда көне буе торып үз нәүбәтеңне көтәргә кирәк. Ниһаять, үзебез белән бер курста укыган бурят, монгол, калмык, балкар егетләрен ияртеп, чиратка язылдык. Атна саен барып, ел буена чиратыбызның кайсы тирәдә булуын белешеп тордык. Көне җитеп, биш машинканы кулга төшергәч, шул ук егетләр мине «Татарстан» поездына озатып та куйдылар. Вагонда ничек итеп мине «машинка сатучы спекулянт» дип атауларын, проводницага акча төртеп, көч-хәл белән бу бәладән котылуымны тәфсилләп сөйләп

тормыйм. Казан вокзалында мине каршы алучы булмады. Инде нишләргә? Таксига акча юк, ике кулга биш машинканы да күтәреп булмый. Ни чарадан бичара дигәндәй, ике кулга икешәр машинканы бергә бәйләп тоттым, бишенчесен тоткасыннан авызга каптым да трамвайга кадәр мүкәләп барып җиттем. Трамвайдан төшкәч, колхоз базарыннан Матбугат йортына да шул рәвештә кайтырга туры килде. Җитмәсә тирә-юньдәге халык бармак төртеп күрсәтә, арттан көлеп кала. Шулай көч-хәл белән Язучылар йортына кайтып егылдым. Юк, мин боларны һич кенә дә күргән михнәтләремне тасвирлап үземне кызгандыру өчен язмыйм. Боларны искә алуымның сәбәпчесе — әлеге дә баягы мөхтәрәм Аяз ага. Беренчедән, ул мине, әле яңа гына борын төртә башлаган әдәбият чебешен, якты дөньяга чыгару өчен куәт бирде, мә, эшлә, дип, кулыма корал тоттырды. Аяз абый аркасында мин шәп машинкалы булдым, ул машинка менә инде кырык елга якын минем иң мөкатдәс уйларымны кәгазьгә күчерә, хәзер дә ул мине һәр көнне ымсындырып үзе янына чакырып тора.

Мөхтәрәм шагыйрьләребез Илдар Юзеев, Нури Арслан һәм Әхсән Баянга Аяз ага фатихасы белән алып кайткан машинкаларның да әдәбиятыбыз өчен бәрәкәтле әсәрләр бүләк итүенә минем һич кенә дә шигем юк.

Язу машинкасы хакында шулай иркенләп сөйләвем юкка гына түгел. Иҗат кешесе өчен компьютер никадәр генә уңайлы булса да, минем әле һич кенә дә машинкадан аерыласым килми. Моның сәбәпләрен үзем дә аңлап бетермим бугай. Әмма бер сәбәбен беләм: ул — остазым Аяз ага ядкаре. Аяз ага машинкада гаҗәеп җитез һәм оста баса, Святослав Рихтер фортепьянода уйный диярсең. Вакыт-вакыт аның машинка тыкылдавы миңа йөгерек фикере артыннан калышмаска тырышып тупырдап чабучы ат тояклары тавышын да хәтерләтә. Ә кайчакта ул дошман явына каршы ялгыз калган пулеметчыга охшап ярсый-ярсый тыкылдата да тыкылдата кебек. Аның туктарга, бирешергә исәбе дә юк. Чөнки артта — аның газиз халкы, газиз ватаны...

Халкы өчен һәрчак утка керергә әзер кеше булса да, Аяз ага беркайчан да ил, ватан, милләт турында купшы сүзләр сөйләп йөрмәде. «Үзеңнең зурлыгыңны, халык-

ның бөеклеген бары тик эш белән, акыл белән, мәдәният-сәнгать әсәрләре белән генә күрсәтеп була», — дип кабатларга ярата иде ул. Һәм бу сүзләрне үзенең гаҗәеп мул иҗаты, бөтен тормыш юлы, кылган гамәлләре белән аклады.

Гыйнвар, 2006



МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

Дөньялыкта оҗмах

бакчалары хозуры

Ниһаять, миңа борынгы аргонавт-
лар йөзгән Урта диңгез дулкыннары-
на колач салу 1981 елның май аенда
насыйп булды. РСФСР Язучылар бер-
леге оештырган туристик сәяхәт өчен
хәләл акчамны түләгәч, уннарча кә-
газь-белешмәләр тутырып, хәтта әт-
кәң-әнкәң исән түгел икән, аларның
кабере кайда икәнлегенә хәтле күр-
сәткәч, Бауман райкомының иркен
кабинетында, биниһая озын өстәл ти-
рәли утырган корыч салкыны бөрке-
леп торган партия чиновниклары һәм
өлкәннәр советы әгъзалары каршы-
на бастырып сине рентген нурлары
аша үткәрәләр. Төрле сораулар би-
реп, капиталистик илләргә карата
бик үк мәрхәмәтле караштa торма-
вына тәмам инангач кына, хәерле юл теләп, сине чыгарып җибәрәләр.

Шулай итеп, Казаннан без өчәү — Аяз ага Гыйләҗев, хатыны Нәкыя апа һәм мин Испаниягә баручылар төркеменә эләктек. Калган язучы-галимнәр Мәскәү һәм Ленинградтан иде. Исеме таныш язучылардан тыш монда Бонч-Бруевичның оныгы, Ярослав Смеляковның хатыны, Максим Горькийның җиде яшенә кадәр Соррентода үскән оныгы Нина Пешкова да бар иде...

Искә төшсә, хәзер дә чирканып куям. Ширәмәт-2 аэропортында «чик»не узганда ян-яклары тоташ пыяладан торган бәләкәй генә камерага килеп керәсең. Борын астына мыек та чыкмаган яшь солдат документларыңны ала да, пыяла аша салкын күзләрен төбәп, гәүдәңне кадаклап куя. Бөтен күңелеңне актарып чыгарырлык итеп, керфек тә какмыйча үтәли тишеп карарга кайда өйрәткәннәр, нинди яшерен мәктәптә укыткан-нар бу империя солдафонын? Яшь кенә бит югыйсә, ә күзләре коточкыч җансыз, ник бер саплам нур әсәре булсын. Өмер генә бирелсен, әнкәсенә дә төбәп атачак бу! Өшеткеч караш вакыт-вакыт өскә төбәлә (чыгышлый күреп алдым, түшәм белән арткы стена тоташкан урынга кыеклап көзге куелган икән), арт чүмечемнән нәрсә эзли бу исту-кан?!

Әлеге кабинада алган тискәре нурланыштан мин самолетыбыз һавага күтәрелгәч кенә арынып, тынычлана алдым бугай...

Салон буйлап эреле-ваклы шешәләрдә затлы эчемлекләр, сигаретлар, шоколад-лар, тагын әллә нинди ялтыр каплар тезелгән нәни арбаларны этеп йөртәләр. Бар да долларга. Бу нигъмәт-байлыклар безгә төс түгел икән. Алыштырырга рөхсәт ителгән 35 әр тәңкә фәкыйрь акчаларыбыз җитәкче кулында, доллар хәлендә. Мадридта испан акчасы песетага алыштыргач кына ул аны безгә таратачак. Кесәдә акчаң булып, әйбер алалмау түбәнчелегенә инде күнегеп беткән идек, сыгылып торган байлыкка карап акчасыз тору да шундый ук мескенлек икән...

Аэрофлот компаниясенең затлы ризыкларын шәраб белән сипләп куйганнан соң озак та үтмәде, самолетыбыз Люксембург аэропортына төшеп утырды. Монда алай документлар тикшереп мәрәкә килмәделәр. Вокзалга кергәч, тар гына аралыктан үтә-сең, кырыйда полисмен карап-күзәтеп тора. Менә без, унлап кеше, тоткарлыксыз гына үтеп чыктык. Аяз ага килеп кергәч, полисмен кинәт калкынып килде дә, ике учына да ниндидер прибор кигән куллары белән Аяз аганың гәүдәсен баштанаяк сыпырып тө-шерде, аннары гына үткәреп җибәрде. Бераз каушап калган Аяз ага, аптыраулы елма-еп:

— Минем тюремщик икәнне монда да белделәр, слушай, парин, — дип куйды.

— Жан-Вольжан икәнеңне беләләр, Аяз ага.

— Шулайдыр. Тимер рәшәткә шәүләләре күзләрдә мәңгегә калалар. Күр инде, бүтән берәүне дә тикшерми бит... Киттек, әнә тегендә безнекеләр бушка гына капиталист сырасы эчәләр түгелме?

Озын стаканнарда сыра бирделәр. Ул дәвердә чит ил сырасын киноларда гына күрә идек. Менә хәзер эчәргә дә насыйп булды.

— Минем сырага ис китми. Йә, ничек, шәпме? — дип, Аяз ага гәрәбә кебек сыралы стаканны күзлегенә якын китереп карый.

— Артык юка боларның сырасы. Безнеке бит закускасы да үзендә була...

Иллюминаторга маңгаемны терәп, уйланып барам. Әх, Люксембург, Люксембург, аз гына көнчыгыштарак урнашкан булсаң, яшәтерләр иде сине аерым ил итеп, хәзергечә әйтсәк: «...в составе России...»

Еллар узгач, Аяз ага белән әдәбият турында сөйләшеп, күңелдәге фикерләребезне барларбыз.

— Киләчәктә Европа һәм Шәрык фәлсәфәсен, Ислам тарихын яшьтән өйрәнгән, Коръән, Тәүрат, Инҗилләрне яхшы белгән, фикри әзерлекле яшь талантлар әдәбиятка килерме? — дип сорау биргәч, Аяз ага:

— Әгәр якын елларда татар бетмәсә... Чын татарлар туу өчен тагын ике-өч буын үтү кирәк. Безнең бүген Исламиятнең бөеклеген аңлатып бирердәй галимнәребез юк. Диннең өстә яткан кануннарын аңлатудан башка тирәнгә керә алган шәхесләр күренми. Дин әһелләре чыгыш ясаганда да үз сүзләрен кемгә, нинди катлау кешеләренә юнәлдергәнен ачыклап бетермиләр. Дин — милләтнең, халыкның бөтенлеге сагында

Марсель Галиевнең Аяз Гыйләҗев белән әңгәмә вакыты. 1993

торган зур көч ул. Милләт өчен уртак дин алган халыклар гына дәүләтчеллеккә ирешкәннәр.

— Алда өмет күрәсезме?

— Тарих алга барсын өчен шәхесләрдән калыккан баганаларга гына күпер сугып

була. Безнең уртак милли батырларыбыз бармы бүген? Уйланырга кирәк...

— Сезне саткан, төрмәгә утырткан кешене беләсезме? Аны очраткач исәнләшәсезме?

Мадрид — Мәскәү самолеты болытларны аралап җиргә якыная. Гүя без еллар тавыннан төшеп киләбез. Аста — урман-күлләр, сусыл яшеллек. Төсе ят чит ил туфрагыннан соң җанга якын манзара.

Тәгәрмәчләр җиргә тигән мизгел бөтен вөҗүдең аша үтә, исән-имин кайтып җиттек бит дигән уй-шатлыгыннан күңел мөлдерәп тула. Ул арада салон, тыйнак кына «Ура!» кычкырып, дәррәү кул чаба башлады. Матур булса да Испаниясе, һәркемнең үз Исламиясе...

Әнкәң кебек үк, туган илне дә сайлап алып булмый, ничек бар, шулай яратырга хөкем ителгәнсең. Кыйнап һәм кыйналып яратырга.

Моннан унике ел элек булган сөйләшү

Кайнар йөрәкле шәхес иде ул. Күз алдында кабынып-дөрләп, ялкынын биетеп торган учак кебек иде. Безне, гадәттә, учакның ялкыны җәлеп итә, ә төптә ярсу күмерләр нинди хәлдә тетрәп-сыктап, көйрәп тере сулыш ала — анысын искәрми дә калабыз. Аның сүз күмерләре һәрдаим дөрләп китәргә әзер иде. Үткен телле, «югары көчәнештә» сөйләү рәвеше белән ул игътибарыңны урап ала, ваемсызларны да дер селкетеп, «йонын язып» ала торган иде. Кәефле чагында берәр яшь язучыга игътибар белән карап торыр да:

— Их, синең урында булсаң иде хәзер!.. Сандык төбендә яткан дүрт мең дә биш йөз шигырьне алышам яшьлегеңә! — дип, иңеннән яратып кагып куяр иде.

— Их, слушай, парин, минем яшькә җиткәч белерсең әле. Алтмыш яшь — илле түгел икән шул, — дигән иде Аяз ага. Тагын ун елдан соң ул:

— Җитмеш яшь алтмыш түгел икән шул... — дип, тагын элеккеге «егет чагын» сагынып куйды.

Хәтерлим әле, җитмеш яшьлеген «Тургай» дигән ресторанда бәйрәм иткән идек.

Аяз ага ут карашлы чибәр хатыны Нәкыя апа белән түрдә, уллары — Искәндәр (тарих фәннәре докторы), Мансур (драматург), кече уллары Рәшат (табиб, бизнесмен) — болар бергә — табынның икенче түрендәрәк. Аяз ага, тамада тарафыннан сүз бирелгәч, торып басып, уллары, киленнәре ягына яратып, горур бер караш ташлады да:

— Менә мин татар милләтенә өч ул үстереп калдырам. Киленнәрем дә чын татар, онықларым да, Аллаһы бирсә, татар булып үсәчәк! Кем, кайсыгыз минем кебек өч улы белән мактана ала?! — диде.

Гыйбрәтле тынлык, кисәтүле, күпләр өчен үкенүле өн салынган нәүмиз тынлык сыгылып иңгән иде шул мизгелдә. Олуг язучыбыз Аяз аганың бәгырь авазы, чаң суккандай, еллар аша һаман әле күңелдә кабатланып, сискәндереп куя.

Тавышы истә, күз карашы, йөреш-хәрәкәте, хикмәтле сүзләре хәтердә, нининдидер күзгә күренмәс өрфия пәрдәне генә аласы да...

Хәтерлим әле, Аяз ага белән редакция бүлмәсендә шактый озак сөйләшеп утырдык (һәр сүзен яздырып барган диктофонга рәхмәт!). Бу 1993 елның 20 сентябре иде. Аяз агага ул вакытта алтмыш алты яшь булган...

Йәгез, бер дога!

— Сезне, Аяз ага, Алласыз һәм тарихсыз проза вәкиле булып калу куркытмыймы?

— Менә мин «Йәгез, бер дога!» дигән әсәремне төгәлләдем. Анда сүз кырык ел элек булган вакыйгалар турында бара. Әсәрдә телгә алынган һәр кеше — чын, һәр вакыйга үз башымнан үткән! Үткәнемә һәм тарихка хилафлык кылмыйча, үзем кабул иткән дөреслекне сурәтләргә омтылдым. Чөнки кеше зурмы-кечкенәме, аның тарихка үз мөнәсәбәте, үз аршины бар. Миңа бу хатирәләрдән котылырга кирәк иде. Чөнки хәтеремнең иң якты еллары (22 яшьтән 28гә кадәр) Сталин зоналарында, төрмәләрдә үтте. Ул темага бик күп авторлар үзләренең ноктаи назарларыннан чыгып бәя бирделәр, һәртөрле жанрда язып чыктылар. Мин инде язмам дигән идем. Ләкин, уйлыйуйлый, шундый нәтиҗәгә килдем: мин булган лагерьлар турында әле беркемнең дә

язганы юк. Чөнки андый типтагылар 1948 елда гына төзелде. Без соңгы дулкынга эләктек. Шушы лагерьда үткәннәремне, кеше булырга ярдәм иткән, күземне ачкан бик күп олпат ирләрне әгәр мин язып ачыкламасам, бу дөнья турындагы фикерләремне укучыга чыгармасам, әсәрләремнең төбенә төшү кыен булыр иде. Бу роман минем киләчәгемне түгел, ә үткәннәремне билгели. Сент-Экзюпери әйтә: «Мине язганнарымнан эзләгез», — ди. Гади, һәркем башына килә торган фикер. Ләкин менә тарихи шәхес, философ, мәшһүр язучы әйткәч, ул ышанычлырак...

— Үзебездә туган фикерне авторитетлар җилкәсенә салырга тырышу гадәте безгә каян килә?

— Без бит үз фикерләребезне кемнәндер оялыбрак әйтәбез. Чөнки безнең беребезне дә татар халкының да, дөнья халкының да әле укытучы-остаз итеп, акыл иясе итеп таныганы юк. Безнең татар әдипләренең гомер юлларын әсәрләренә карап фикер йөртү кыен. Затлы кешеләребез хакында истәлекләр басылып чыга, ләкин алар искиткеч ярлы, фәкыйрь. Чорыбызның иң зур фаҗигале язмышын кичергән Салих Сәйдәшев турындагы истәлекләрне генә карыйк. Ул китап әллә кайчаннан бирле кибет киштәләрендә тузан җыеп ята. Әгәр без шушы бөек шәхесне ача торган нәни генә дәлилләр белән беркетеп, кеше җанына, аңына үтеп керерлек искәрмәләр белән чыгарган булсак, бу китап тормыш дәреслеге булып хезмәт итәргә тиеш иде бит. Чөнки XX гасырда Сәйдәш кебек талантлы, аның кебек бай рухлы һәм татар җанын аркылыга-буйга, түбәннән югарыга аңлаган шәхес тагын бармы? Ул — безнең милли каһарманыбыз. Бу югары сүзне без Тукайга карата гына әйткән идек. Халыкка маяк, күңел серләренә юлдаш булырлык, телне-моңны, бөтенлекне аңлаган ике милли каһарман бер гасырга җитә дип уйларга кирәк.

— Чор, төшенчәләр үзгәрә барган саен, бу шәхесләр әле яңа яктан ачылачаклар. Дөресен әйткәндә, әгәр тормыш элеккечә тигез генә барса, Тукайны революционер, коммунист итәргә дә күп калмаган иде бит...

— Тукай каршылыклы шәхес булмаган дип кем әйтә ала?! Әлегә без аны гел уңай-

га гына сыпырып тордык. Туры Тукай дибез. Аның хаталары булмаганмыни?! Үз замандашларына карата мөнәсәбәтләрдә «балаларча суллык авыруы» белән авырмаганмыни?! Тукай, миңа калса, үзенең каршылыклы булуы белән дә бөек. Аның ясаган хаталары, кылган гамәлләре — уңаймы алар, тискәреме — безнең өчен гыйбрәт, сабак. Ә Сәйдәш?.. Аны изеп таптаган, иҗатын буып торган кара ташлар аз булганмыни?!

— Күптән түгел теплоходта без Әстерханга төштек. Анда зур галимнәр, Әмирхан ага кебек аксакаллар катнашкан дискуссия вакытында Миргазиян Юныс: «Бездә революциядән соң, гомумән, әдәбият юк!» — диде. Мондый максимализм бездә студент чакта бар иде, ул чакта килешә иде. Моны бит яше алтмыштан узган әдип чын күңеленнән әйтте.

— Бер ул гына андый фикер йөртми. Радиодан чыгышларының берсендә, әле шушы елда, Мөхәммәт Мәһдиев тә, революциядән соң татар әдәбиятында бер генә күренекле әсәр дә юк, дип раслап чыкты. Бу нилектән туа? Талантлы язучылар булган кебек, халыкның талантлы укучылары да булырга тиеш... Телисеңме-теләмисеңме, әдәбиятның югарылыгын, аның базар бәясен, әгәр шулай әйтергә яраса, укучы үзе билгели. Дөрес... Татар әдәбиятының туксан биш проценты бүген авылга хезмәт итә. Татарның зыялы, әзерлекле укучысы аз. Әдәби телнең нечкәлекләрен белеп язган Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек язучыларның тел байлыгыннан күпме процент татар файдалана? Безнең әдәбиятның зур ялгышы — ул халыкка ярарга тырыша. Аның алдында тез чүгә, үрмәли, вагая. Ә бит язучылар төрле зурлыкта булган кебек, укучының да кабул итү дәрәҗәсе бердәй түгел. Миргазиян Юныс татар әдәбияты турында хөкем чыгарганда моннан мең ел элек башланган Европа әдәбиятлары белән чагыштырып карый. Ә бер уйлап карасаң, безнең проза бик яшь әле, аңа йөз ел гына тулып килә. Әдәбиятны караңгыга кысрыклап кертү җиңел ул. Дөнья әдәбияты классиклары, без хаклы рәвештә ярата торган шәхесләр белән чагыштырганда, әдәбиятыбыз түбәндә түгел... бары тик яшь булып кына кала. Бер генә

әдип тә, бер әдәбият та үз халкының дәрәҗәсеннән югары сикерә алмый...

— Киләчәктә Европа һәм Шәрык философиясен яшьтән өйрәнгән, Коръән, Тәүрат, Инҗилләрне яхшы белгән фикри әзерлекле яшь талантлар әдәбиятка килерме?

— Әгәр якын елларда татар бетмәсә... Чын татарлар туу өчен тагын ике-өч буын үтү кирәк. Безнең бүген исламиятнең бөеклеген аңлатып бирер галимнәребез юк. Диннең өстә яткан кануннарын аңлатудан башка тирәнгә керә алган шәхесләр күренми. Дин әһелләре, чыгыш ясаганда, үз сүзләренең кемгә, нинди катлау кешеләренә юнәлдерелгәнен ачыклап бетермиләр. Әлбәттә, динсез булмый. Дин — милләтнең, халыкның бөтенлеге сагындагы зур көч! Милләт өчен уртак дин алган халыклар гына дәүләтчеллеккә ирешкәннәр. Динле, дәүләтле булу тарихның бөтен юлларында бәхет саналган... Безнең милләтебезнең эчке ресурслары хәзер юкарган чак...

— Алда бер дә өмет күрмисезме?

— Без — җиде миллионлы халык, дибез. Кайберәүләр аны егерме миллионга җиткерә. Бу бит миф. Катнаш гаиләләр күбәя барган чорда нинди миллионнар булырга мөмкин! Алдырма син сан белән. Алдыр эш-хезмәт белән. Бер генә мисал: безнең Вил Мирзаянов дигән егетебез дөнья каршында үзенең көрәше, максатының ачыклыгы белән дан казанды. Бүгенге көнгә кадәр бу шәхеснең иманын, ул иманның ныклыгы нигезләрен ачып бирә алганыбыз бармы? Гомумән, без милләткә хезмәт итә торган шәхесләргә бәя биреп үтмибез, ныгытмыйбыз. Уртак каһарманнарыбызны күтәрә белмибез. Башкортларны гына алыйк. Салават Юлаев белән алар күпме еллар яшиләр. Шундый зур, якты шәхесләр милләтне җылытып торалар. Алар — милли тамырларга һәрвакыт көч биреп тора торган дым... Югыйсә бездә ул чорның Бәхтияр Канкаевлары, Батыршалары юкмы? Тарих алга барсын өчен, шәхесләрдән калыккан баганаларга гына күпер кагып була. Безнең уртак милли батырларыбыз бармы бүген?

— Муса Җәлил?

— Ул ачылып беткән шәхес түгел... Мин Җәлил һәм аның иптәшләре хакында шик-шөбһә уятырга теләмим. Яшьләрне тәрбияләүдә үз вакытында аларның роле югары булды. Ләкин... милли геройлармы алар? Татарның киләчәге өчен һәлак булдылармы? Уртак ватан өчен һәлак булулары белән тарихта калырлар, әлбәттә, әгәр килер заман яңа дәлилләр табып, аларның батырлыгын батырлык дип таныса...

— Сез, Аяз ага, юл йөрергә бик яратасыз. Соңгы вакыттагы тәэсирләрегез нинди?

— Авылларның рәвеше үзгәрә. Мәчетләр салына. Ләкин бу изге эшкә күп җирдә ашыгып, алдан уйлап бетермичә тотыну сизелә. Мәчетләрнең чын архитектура үрнәге булып гасырларга калачак, дип, төзелергә тиешлеген онытмасак иде.

— Моннан ун еллар элек без Сезнең белән Испаниягә барган идек. Ун чакрым биеклектән очкан самолет канатына тияр-тимәс калган Альп кыяларына карап шәраб эчкәндә, Сез: «Бу мизгелне бүтән кабатлап булмый», — дип әйткән идегез. Их, шуны тагын бер кабатлыйсы иде дигән үкенечле мизгелегез бармы дөньяда?

— Юк. Тәкъдир язган һәр мизгелдә үтәләсе үтәлгән, эшләнәсе эшләнгән. Әйтмим, һәрчак хак юлдан гына барганмындыр дип. Без бит бәхетсез заман җимешләре. Шулай булдык, тегеләй булдык, дип никадәр генә күкрәк какмыйк, гасырга хас хаталар бөтенебездә бар. Берәүләр бүген ашыгып-ашыгып үзгәрергә маташа, икенчеләр кабат ялган юлга баса... Без яшәгән ил шундый булды ул, ак киемнән, корымлы казан янында йөреп, тапсыз калу мөмкин түгел иде.

Кичергән мизгелләргә бәя дә үзгәрә икән шул. Менә ни, үткәннәргә кайтып, кабатланасы килми.

— Сталин чорында палачлык, доносчылык хөкем сөргәндә, кем нинди юл белән исән калганлыгы хакында хөкем йөртергә безнең буын кешеләренең мораль хокукы юк дип саныйм. Бүген шул мәхшәр кабатланса, совет чорында тәрбия алганнарның тагын да явызрак буласына, тагын да түбәнчелеккә төшә-

селәренә шикләнмим. Бу дәверне хәтерегездә кузгатканым өчен гафу үтенәм, әмма бер сорауны бирмичә кала алмыйм. Сезне саткан, төрмәгә утырткан кешене беләсезме? Аны очраткач исәнләшәсезме?

— Хәзерге мәгълүматларга таянганда, ул чорда һәр өч кешенең икесе теге яки бу күләмдә җәзалау органнары белән бәйләнештә торган. Катлаулы, авыр чор! Мине төрмә сукмакларына этәргән кешеләрне моннан ике ел элек кенә белдем. Бар — исәннәре, бар — күздән югалганы... Барчасы белән күрешеп-сөйләшеп йөрим. Аерым шәхесләргә караганда, чорны ныграк гаеплим. Беләм, ул гаеплеләр шушы елларда тәүбәгә килде. Тәүбәгә килеп күңелеңне сафландыру — үзе дә бер батырлык ич. Тәүбәгә килү (покаяние) һәртөрле дини өйрәтүләрдә күңел байлыгына ия булу түгелмени! «Казан утлары»ның 10 нчы санында басыла башлаган «Йөгез, бер дога!» дигән роман-хатирәмдә мин хәзерге заманның катгый сорауларына үткәндәге гыйбрәтләр белән җавап бирергә тырышам.

— Сезнең дә намус-вөҗданыгызга күләгә төшерергә тырышкан имеш-мимешләр, хәтта матбугатта язмалар да булды. Моңа каршы Сез ачыктан-ачык җавап бирмәдегез шикелле?..

— Кешеләргә гаеп ташлау, шик-шөбһә белдерү — көнчелек галәмәте. Әгәр мин әдәбиятта кайсыбер уңышларга ирешә алмаган булсам, ай-һай, мондый кара хәбәрләр шытып чыгар иде микән... Миңа таш атып, калкынырга тырышкан кемсәләрне эзәрлекләргә дә, үч алырга тырышырга да җыенмыйм. Югарыда телгә алынган романым әнә шул бәндәләргә җавабым да булыр. Язмышым турындагы хөкемемне йомгаклау сүзләрен мин замандашларыма шунда тапшырам.

— Җитмеш ел буена илдә-көндә барган вакыйгаларның асылына без соңгы елларда гына төшенә башладык. Хәзер күп нәрсә ачылды. Соңгы берничә ел эчендә артка, егерменче елларга кадәр кайтып, коточкыч күп мәгълүмат алдык. Әгәр ул мәгълүматлар табигый эзлеклелеге белән кереп барган булса... Сезнең «Балта кем кулында?» дигән романыгыз башкача, тыныч-сабыр күңел бе-

лән язылмас идеме? Сез, читлектән кинәт иреккә чыгарылган арыслан кебек, бөтен нәрсәне таптап, изеп, бәргәләнеп, барысын да тизрәк әйтеп калырга ашыккансыз сыман тоелды бу романыгызда.

— Ул романны мин моннан ун-унбиш еллар элек язарга уйлаган идем. Әлбәттә, сюжеты гадирәк иде, син әйткәнчә, тынычрак агышлы иде. Ләкин әсәр үзе өлгерде һәм мине өлгертте. «Балта кем кулында?» — минем иң җитди әсәрләремнең берсе дип уйлыйм. Монда минем чорга, халкыма мөнәсәбәтем чагыла. Балта кем кулында? Балта ленинизм, совет режимы кулында! Бу режим ике катлауны да имгәтте. Югары катлауны чамасыз-чиксез байлыгы белән, бернинди җаваплылык тотмый торган иркенлеге белән, бөтен бозыклыкка юл ачып, талауга, халыкны мыскыллауга йөз тотып имгәтте. Ярлы-ябагайларны исә ач тотып, салымнар белән сытып, кешелек хокукларын тартып алып имгәтте. Совет режимы аста да, өстә дә гарипләрне генә тудырды. Мин соңгы әсәрләремнең бөтенесендә дә шушы режимның татар халкын ничек изүе, талавы хакында фикер йөртәм. Милләтнең һәлакәте алда әле... Без гел инкыйраздан куркабыз. Ә бит инкыйраз булып узды. Тагын нинди инкыйраз көтәргә мөмкин! Татар кызларының кырык проценты чит милләт егетләренә кияүгә чыга. Татар егетләренең кырык проценттан артыгы чит милләт кызларын алып йөзләрен югалта. Бер Наҗар Нәҗми авылыннан гына да 26 татар кызы Үзбәкстанга кияүгә чыгып, соңгы берничә ел эчендә үзбәк халкын күпмегә баетты! Без алга карый белгән милләт түгел. Менә сиңа бер кыйсса: Ленинградның Товстоногов театры берничә ел элек Япониягә гастрольгә бара. Шуннан кайткач, күренекле актер Олег Басилашвили шундый бер хикмәтне сөйләде. Токиодан 75 чакрымда бер югары мәктәп бар икән. Анда Япониянең булачак галимнәре, эшмәкәрләре, министрлары, икътисад хуҗалары, кыскасы, сайлап алынган балалар укый икән. Шушы мәктәпнең ректоры Ленинград театрын расходланып чакырта, ике спектакль куйдырта. Шәкертләр бик матур каршы алалар. Басилашвили ректордан сорый: «Менә без сезгә ят булган урыс тормышыннан «Ат тарихы» һәм «Ваня агай» спектакльләрен күрсәттек. Сезнең укучыларга моның нинди файдасы

бар?» Ректор: «Әгәр шушында укыган мең җиде йөз укучының, дистә еллар үткәч тә, бу спектакль исенә төшеп, күңелендә мәрхәмәт очкыны кабынса, безнең бүгенге эше-безнең нәтиҗәсе булган», — ди. Менә япон ничек алга карый! Авылда калып дуңгыз, ат койрыгы борып кына алга китеп булмый. Шәһәр әлегә татар шәхесләрен бирми. Канында, җанында милли рух юк икән, андыйларны мин «ямаулы татарлар» дип атыйм. Ана карынынннан ук Сәйдәш моңнарын, «Ак бүре» әкиятләрен тыңлап үсмәгән татар беркайчан да чын татар була алмый. Халкына мәхәббәт рухында тәрбияләнмәгән ке-шедән ничек инде милли каһарман чыксын! Ләкин... Татарның коесы корыган, чишмә-се агышын туктаткан, дип әйтергә җыенмыйм. Хәзерге көндә милләтне ныгытырга мөмкинлекләр бар.

— Соңгы елларда мәйданнар шаулый. Ниндидер партияләр оеша, ниндидер көрәшчеләр сәхнәгә чыга. Сәяси эстрадага чыгучы көрәшчеләргә Сез ышана-сызмы?

— Юк! Берсенә дә! Үзләренә дә ышанмыйм! Сүзләренә дә ышанмыйм! Теләсә нәрсә әйтсеннәр. Башта мин Минтимер Шәймиевкә дә ышанмадым. Ул бит партияле кеше. Әле дә ул партия сафларыннан чыкмаган, әгъзалыгын туктатып кына тора... Бүтән җитәкчеләр дә шулай. Ләкин Минтимер Шәймиев бүгенге көндә милләтебез язмышы хакында уйлап эш итә. Ул моны хәл итеп бетерде, бөтен капкаларны ачты, дип әйтергә җыенмыйм. Әмма... кылган гамәлләренә караганда, ул дөрес кыйбла тота. Милли лидер булып йөрүче ниндидер маймылларга, Шәймиевне Җаһар Дудаевка алыш-тырыйк дип йөрүче бушбугазларга ничек инде ышанасың! Без бу милли нигилистлар-дан, бушкуык экстремистлардан арынсак, милләтебез, шөт иншалла, тарихта үз мис-сиясен үти башлар.

— Хәтерлим әле, Сибгат ага Хәким исән чак иде. Аның шигыренә язылган хикмәтле бер җыр бар иде бит әле:

Су буенда өянкеләр,

Минем дә җитте бугай бит

Картайдым дияр көннәр.

Шушы җыр яңгырый башлауга, Сезнең күзләрдә яшь күренә. Нинди каты бәгырьле дип уйлаган, җыелышларда тагын кемне сүгеп ташлар икән дип тетрәндереп торткан Аяз ага еласын әле. Мин моны беренче кат күргәндә бик гаҗәпләнгән идем. Аннары ничә тапкырлар шушы җыр җырланганда Сезнең күңел йомшауга шаһит булдым. Башка җырга алай ук чишелеп китмисез бит, сәбәбе нәрсәдә икән?

— Аны аңлатып булмый. Бу ниндидер сер, әлбәттә. Сибгат аганың 60 еллык юбилеенда Рөстәм Яхин мине чакырып алды да: «Аяз, син бит әле карт та түгел, нигә шулкадәр бу җырны бәгыреңә үткәреп кабул итәсең?» — дигән иде.

— Сезнең хакта күп нәрсәдән хәбәрдар, күп нәрсәне алдан белеп тора дигән легендалар йөри. Әйтик, Аксак Тимернең кайсы аягы аксак икәнне, Маргарет Тэтчерның иртәгә иртән иренә нәрсә пешерәсен... Аяз ага, әйтегез әле, якын араларда нинди кызыклы вакыйгалар булачак?

— Безнең бер чордашыбыз минем һәм берничә яшьтәшем турында олы бер шикаять язып җибәрәчәк. Исемен куеп тормас, «информатор» дип кенә тамга салыр. Коммерция оешмалары безнең Язучылар йортына бармакларын тыктылар. Якын араларда бу йортны алар тартып алып, язучы-әдипләрне урамда калдырачаклар.

— Боларның чынга ашмавы өчен, Аяз ага, йәгез, бер

дога!..

«Татарстан яшьләре»

19 ноябрь, 2005

Язучылар йорты. Мөштәри урамы, 14



ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН

Таза орлыклар

Кыйбла булып изге җилләр исәр,

Дөрес иман иңәр гомергә.

Уйчан күзле романтиклар үсәр,

Таза орлык чәчик бу җиргә.

Гамил Афзал

«Таза орлык чәчик бу җиргә». Намуслы һәр каләм әһеленең изге хыялы, олы бурычы әнә шул. Аллаһы Тәгалә әдиплек таланты белән бүләкләгән икән, син дөрес иман белән генә эш итәргә тиеш.

Аяз Гыйләҗев иҗатын тулы итеп күз алдына китергән кеше әйтер: автор иманын җилләр юнәлешенә карап алыштырып торган әдип түгел икән. Каләменнән чәчелеп калган таза орлыклар, алардан үсеп чыккан шытымнар әдип йөргән сукмакларның йөз кызартмаслык олы юлларга барып чыкканлыгын күрсәтә. Бу сукмаклар ахыр чиктә Аяз Гыйләҗевне хакыйкать биеклегенә алып килгәннәр.

Шул ук Г.Афзал бу язучыбызның иҗатындагы төп пафосны шактый дөрес тотып алды:

Син бик усал, ач арыслан кебек,

Усаллыгың җитәр йөз елга.

Юаш кына малай идең элек,

Усаллата икән бу дөнья.

Халык шагыйре Г.Афзал үз каләмдәшен «усал» дип кенә әйтеп калмый, бу сый-

фатның аңарда ни өчен барлыкка килүен дә аңлатып бирә: «усаллата икән бу дөнья». Шулай, иҗат ул шәхси үткәнеңнән, биографияңнән аерылгысыз. А.Гыйләҗевтә җәмгыятькә карата булган «усаллык» барлыкка килүнең сәбәпләрен без чын-чынлап бары тик аның «Йәгез, бер дога!» әсәре басылып чыккач кына аңладык. Ул Казан — Свердловск — Петропавел — Карабас — Актас — Волынка — Майкудук — Чиләбе — Казан маршрутын, тоткын буларак, рәшәткәле вагоннарда, кысан машиналарда, урыны-урыны белән җәяүләп тә узган икән. Ни өчен? Бары тик сталинчыл режимны, халыкны изүнең бу рәвешен мактамаганы, шуны ныгытуга өлеш кертмәгәне өчен. Егерме ике яшьлек егет, шул рәвешле яманаты чыккан 58 нче маддә буенча гаепләнеп, илнең каймагы булган меңнәрчә-меңнәрчә шәхесләр арасында, чыннан да, хакимиятнең тоткан юлына аңлы рәвештә каршы булган кешегә әверелә. Аның: «Акылны төрмә кебек баета торган мәктәп юк», — диюе шуңа ишарә. Бу «мәктәптән» А.Гыйләҗев менә нинди сабак алып чыга: «Октябрь — дөньяның иң хурлыклы, иң кара сәхифәсе ул. Нәрсә ул пролетариат диктатурасы? Тормыш кануннарын ерып-ертып алга үткән, өскә күтәрелгән берәүнең чикләнмәгән власте ул. Ил каршында да, Алла каршында да җавап бирмәячәк явыз шәхеснең өстенлеге».

Чыннан да, уйлап карыйк. Моңарчы Октябрь инкыйлабы, хезмәт ияләре бәхете өчен ясалды, дип аңлатылып киленде. Әмма бәхет кеше сөякләренә нигезләнә алмый. Халыкның иң хезмәт сөючән, эш рәтен белүче, иң акыллы, иң сәламәт өлешен юк итеп төзелгән җәмгыять ничек инде бәхетле дип атала алсын? Әйбәт әйберне бик тырышып мактауның кирәге булмый, ул үзе турында үзе сөйли. Ә җирнең алтыдан бер өлешендә ленинизм-сталинизм байрагы астында төзелгән, моңарчы тиңе булмаган төрмәне мактау өченниләр генә эшләмәделәр?! А.Гыйләҗев «Йәгез, бер дога!»да шуның шыксызлыгын ача. Әйе, Ленинның да, Сталинның да рухи атасы Карл Маркс иде. Бу алманлы яһүденең явызлыкта шигърият күрүе кемгә генә мәгълүм түгел. «Рәсәйнең татарларны яулап алуы үтә уңай күренеш», — дип язып чыккан ул кешенең шәкертләре аңа тугрылыклы булып калды. Чөнки явыз теория явыз гамәлләр нигезенә генә чәчәк

атарга мөмкин. А.Гыйләҗев бер урында Көнчыгышның бөек фәлсәфәчесе Конфуцийның мондый сүзләрен китерә: «Черек агачтан асыл сурәтләр юнып булмый». Шуның кебек, К.Маркснын талап алу сугышларын хуплавы беренче социализм иленең үз эчендә һәм аның тирәсендәге халыкларга күпме күз яше, җәбер китергәнлеген барыбыз да күреп тордык. Кешелекнең яшәү рәвеше, гамәле, фәлсәфәсе мәңгелек кыйммәт булган дингә дә нигезләнергә тиеш.

Аяз Гыйләҗев тә, мәхшәр газапларын үтеп, җирдәге тормышның бик күп якларын тирәнтен тәфтишләгәннән соң шушы карашка килгән икән, монда хикмәт бар. «Динсез диярлек гаиләдә үссәм дә, — ди ул, — Коръән укый башласалар, тәнемә каз тиресе чыга. Тел музыкасын, Коръән сүзләренең яңгырашын гипнозга тиңлиләр. Коръән аятләре адәм улларын йә кузгаталар, йә тынычландыралар. Берәү дә битараф кала алмый». Язучы хаклы, Коръән Кәрим — кеше өчен туры юлның, изгелекнең, саф күңеллелекнең ачкычы, фатиха бирүчесе, юл күрсәтүчесе.

Автор бу әсәрен «Йәгез, бер дога!» дип исемләгән. Үзе белән бергә җәбер-золымны, михнәт-хәсрәтләрне бүлешкән кешеләрне җентекләп искә төшергәннән соң, «күчкәннәр вә калганнар рухына», ягъни үлгәннәр һәм исәннәр намена дога кылырга өнди. Без, әсәр белән танышу барышында, әдипне искә төшерүче итеп кенә түгел, бәлки үзе яшәгән җиде дистәдән артык елга, андагы хәл-әхвәлләргә акыллы бәя бирүче буларак күрәбез. Аерым кеше язмышларын чор кичергән фаҗигаләр эчендә карау аңа әүлияларча киң күңелле булырга ярдәм итә. Ул үзен саткан, юк гаепләрен бар итеп кара яккан, кимсеткән кешеләрдән өстен булып кала, күңелендә аларга кинә сакламый. Үзенекедәй язмыш кичергән кешеләр — аның өчен изге, гөнаһсыз. Ун миллионнарча кешеләрне шундый «мәктәп» аша уздырган илнең киләчәге ничек хәерле булсын? Дөресендә, ленинчыл-сталинчыл хакимият үзен юк итүчеләрне әнә шулай төрмә «университетлары» ярдәмендә тәрбияләде. А.Гыйләҗевнең уйланулары шундый нәтиҗәләргә китереп чыгара. Үз заманын яхшы аңлап, аңа бүгенгедән торып бәя биргән, алай гына да түгел, киләчәктәге офыкларның кайбер төсмерләрен дә күрсәткән әдибе-

безне, фикер хәзинәләребезне баетканы өчен, тәкъдир итәргә генә кала.

Бу роман-хатирә аның иҗатын аңлауга тулаем ачкыч булып тора. Аны укымый һәм андагы һәрбер фикер турында тирән уйланмый торып, А.Гыйләҗевне һәм шәхес, һәм әдип буларак тулы аңлармын димә. Укучылар даирәсе боларны белми дә калыр иде — Аллага шөкер, сүз ирегe килде һәм хакыйкатьне ачып салу мөмкинлеге туды. А.Гыйләҗевкә килгәндә исә, ул дөреслекне икърар итүнең аз гына мөмкинлекләрен дә файдаланырга тырышты. Бу очракта М.Әмирнең сүзләре искә төшә. «Безнең авыл кешесе» әсәрендә ул Миргали турында болай ди: «Алдына алган теләгенә ирешү өчен, ул законнарның йә астыннан, йә өстеннән үтеп китәргә» кирәк була аңа. Шуның төсле, Аяз Гыйләҗев тә заманында цензорларның уяулыгын йоклатырлык мөмкинлекләрне бер дә кулдан ычкындырмаган.

Әйтик, «Үги ана яфраклары» хикәясе бер дә сәясәткә кагылмаган кебек. Унтугыз битлек әлеге хикәя мәхәббәт турында поэма булып яңгырый. Ул — язучының чын мәгънәсендә СҮЗ РӘССАМЫ булуын раслый торган әсәр. Аның төп каһарманы яшь егет Галимҗан өчен бу көн гадәти генә түгел — ул кичен сөйгәне Сөмәя белән мәхәббәттә аңлашырга тиеш. Шуңа күрә ул комбайннан ашлык ташу кебек тузанлы эшкә дә ап-ак күлмәк киеп чыккан. Менә ни өчен ул бүген һәр нәрсәдә шагыйранә матурлык күрә. Ашлык төягән машинасын басуда үсеп утырган матур үләннәр янында туктатып алырлык дәрәҗәдә күңеле нечкәргән аның. Әнә ул күзлут үләненә соклана. Бу чәчәккә шундый исем кушкан борынгы кешеләрнең күзәтүчәнлегенә шакката, вак зәңгәр чәчәкләрне кеше күзенә охшата.

Әсәрдә Галимҗанга капма-каршы итеп Хәнәфи образы куелган. Чөнки бу соңгысы — матурлыкны күрү, аңлау мәсьәләсендә саңгырау, колагына сыер баскан бер кеше. Әлеге үлән турында да ул: «Күзлутмы, чүзлутмы, сыер аны авызына бөтерә дә тыга», — дип, күренешне бөтенләй гадиләштереп аңлый. «Чәчәген белмим, әмма ачы бал исе килә! Берәр җамыякны түңкәйтеп җибәрергә диген син! Менә булыр иде эш!» — дип тә өсти. Ягъни чәчәкнең исе дә аңарда хәмер эчәсе килү теләген уята. Әнә сугыш-

ка кадәр үк төзелгән иске җил тегермәнен дә сүтеп алырга кызыга ул, күпме утын әрәмгә ята, ди. Әмма Галимҗан өчен җил тегермәненең мәгънәсе күпкә олырак. Ул аңа авылның сугыш кырыннан әйләнеп кайтмаган 75 кешесенә һәйкәл итеп, изгеләштереп карый.

Укучының болай уйларга да хакы бар: кыз белән егетнең иң кадерле көне сурәтләнгән бу әсәргә нигә соң әле автор шушы тискәре Хәнәфине китереп керткән? Ни хаҗәте бар аның? Халык җырыннан бер генә сүзне дә төшереп калдырып булмаган шикелле, сүз бара торган сәнгатьчә камил әсәрдә дә бер генә нәрсә дә артык түгел. Хәнәфи образы бигрәк тә. Дөрес, беренче карашка, ул гашыйк Галимҗан образының күңел матурлыгын тирәнрәк ачу өчен генә кертелгән кебек. Аның иң олы вазифасы, чыннан да, шуннан гыйбарәттер. Ләкин әдип аңа тагын да әһәмиятлерәк бүтән бурыч та йөкли. Бу тупас күңелле, хәмергә хирыслыктан тәм табучы кеше вакыт-вакыт йомры-йомры гына итеп дөрес һәм ул вакытлар өчен гаеп саналырдай сүзләр дә әйтеп ташлый. Галимҗанга ул, мәсәлән, болай ди:

— Синең урыныңда булсаммы мин?! Төкерер идем авылына. Тормышмыни бу, яшәүмени?! Шәйхулла типкесендә йөр инде.

Ә Шәйхулла (колхоз рәисе) кем типкесендә йөри? Әнә районнан ашлык тапшыру өчен биш удар көнлек игълан иткәннәр, ул шуны үтәү өчен җан-фәрман чаба. Димәк, ул да эшне үз дигәненчә генә, җай гына, кирәк булганча оештыра алмый. Шундый «удар» көннәр бөтен эшне чуалта, һәммәсен ритмнан чыгара, аннан соң шуның нәтиҗәсен ел буе төзәтергә туры килә. Ә өстәгеләрнең анда гаме юк. Аларга «штурмовщина» вакытында, тисә тиенгә, тимәсә куянга дигәндәй, тагын да өстәнрәк бирелгән күрсәтмәләрне үтәргә генә кирәк.

Ул елларда кешенең кемлеге эшли белү белән түгел, яши белү белән билгеләнә иде. «Яши белү» тегесенә дә, бусына да оста җайлашуны аңлата иде. Урыны-вакыты белән өстәге кешеләргә карап җайлаша, шәкелеңне үзгәртә алмыйсың икән, башлыкларыңа, ничә очрасалар да, җиргә иелеп баш имәсәң һәм синнән «түбәннәр» сиңа

шуны ук эшләмәсә — хакимлегеңне кулыңда озак тотмыйлар. Шул рәвешле түрә үзеннән кечерәкләргә хан да, хөкемдар да. Бу вазгыять «Балта кем кулында?» романында бик гыйбрәтле гәүдәләнгән.
Роман тукымасында заманыбызның асылын аңлау юнәлешендә геройларның тирән уйланулары табигый урын ала. Менә Фәридун Фазлыев исемле кешенең яшәү мәгънәсе турындагы уйланулары. Алар кешенең усал табигатьле булып үзгәрә баруына иҗтимагый аңның дөрес юнәлештә тәрбияләнмәве сәбәпче икәнен төшендерә. «Менә мин, — ди ул, — озак елларга кадәр кешенең яшәү рәвеше — көрәш дип ышанып яшәдем. Адәм балалары көрәшергә тиеш һәм вәссәлам! Шулай дип укыдык, дөнья маңгайга бәрә-бәрә һаман шуны тукыды. Бәхет дигән мөкатдәс сүз телдән төшеп кала язды, аңа бары тик өзлексез көрәш нәтиҗәсендә генә ирешеп була дип ышандык. Һәм бүтәннәрне дә шуңа ышандырырга тырыштык».
Уйлап карасаң, бу сүзләрдә хаклык ярылып ята бит. Социализм җиңә барган саен, илдә сыйнфый көрәш кискенләшә дигән ялган тәгълимат белән коралланган сталинчылар шулай өйрәттеләр, илнең бөтен тормышын шуңа кордылар. Мондый шартлардагы кеше, тамагы тук, өсте бөтен булса да, тулы бәхеткә ия дип санала аламы? Матди тәэмин ителгәнлек өстенә тулы сәяси һәм рухи иреклелек булганда гына камил бәхет урнаша ала. Автономиягә генә ия татар халкына да сан бар идемени ул елларда?!
«Торгынлык» дип аталган чор кешеләре... Алардан кемне генә әсәр үзәгенә куйсаң да, теләсә кайсы кеше мең төрле җепләр белән җәмгыятьнең бихисап катлауларына бәйләнгәнгә күрә, брежневчылар идарә иткән унъеллыкларның хикмәтләрен ачарга мөмкин булыр иде. А.Гыйләҗев, үз өстенә гаять җаваплылык алып, романда шуңа омтылыш ясый. Әсәрдә кемгә генә тукталма, үзе бер сюжет сызыгын алып китәрлек язмыш. Тик шулай да аларның барысын бер җепкә тезүче, ансыз роман оеша алмый торган бер образ бар, ул — Нәҗип Нургалиев. Югары техник белемле, утыз өч яшьтә. Нәҗип тормышта үз заманы кануннары белән каршылыкка керә. Алдындагы дивар

шулкадәр нык һәм биек ки, аны әйләнеп үтү яки берәр ярыгын табып чыгып китү мөмкин түгел. Җәмгыять алдындагы «зур гөнаһы», кара күләгә булып, һаман артыннан калмый. Чөнки ул бер җыелышта дөреслекне ярып салган: завод директорын милләтләргә бердәй карамауда гаепләгән, хуҗаның шундый эшләрен күреп тә дәшмәгән партком секретарен — «ваемсыз», профком рәисен «чүпрәк» дип атаган. Шуның өчен өметле инженерны эшеннән чыгарып ташлыйлар, тәүбәгә килмәгәч, төрлечә тинтерәтә башлыйлар. Аның сәламәтлеге кыл өстендә булуын белеп торуларына карамастан, Иван Илларионович, Наум Фогельсон кебек (муеннары җитәкчеләр ягына кәкрәеп каткан) врачлар Нәҗипне хәтта армиягә алырга яраклы дигән ялган нәтиҗә чыгаралар. Шулай да, Нәҗипнең хәле армиялек булмагач, аңа «психик авыру» дигән мөһер сугалар.

Рәсми оешмалар кушканнан аз гына тайпылып сөйләшкән яки эш иткән кешене юләр дип атау — аның белән көрәшүнең иң җиңел юлы. Янәсе, юләр ни сөйләмәс! Үзләренең табиблык намусларын атлап чыккан шифаханә чиновникларын Нәҗип тә «козгыннар оясы» дип атый. Әлбәттә, табибларның барысы да андый түгел. Бар аның халыкка тугры хезмәт иткәне өчен үзе үк төрмәдә утырып чыккан Фәридун Фазлыев һәм Фаина Марковна кебек, кешенең җанын дәвалардай осталары. Әмма шул ук Фәридун әйткәнчә, «җәмгыять җинаятьчеләрдән түгел, гаделләрдән арынырга, намуслылардан котылырга теләгән» илдә игелекле кешегә баш калкытырга ирек бирмиләр. Номенклатура — бары үз даирәсен генә кешегә санаучылар төркеме.

Әсәр герое Нәҗипкә килгәндә, ул шушы номенклатура эченә үтеп керергә тели. Шундагы кешеләр бәхетеннән үлеп көнләшә, яхшы фатир, дача, машина, мәҗлесләр, көньяк курортлары аның җанын бимазалый. Шуның өчен борчылып, аның сәламәтлеге какшый. Нәҗип — катлаулы холык иясе. Шул ук вакытта бу образ үзенең һәм намуслы кешеләрнең авыр хәленә карата булган протестын киң итеп күрсәтә алмый. Чөнки, күренгәнчә, Нәҗипнең бөтен хәрәкәтен барлыкка китерүче көч шактый зәгыйфь, ягъни ул, — нигездә, үзенең шәхси тормышын яхшыртырга булган омтылыш. Мондый

тар максатка ул кадәр зур көсәккә тотынмыйча да ирешергә мөмкиндер. Әсәр героена кайбер юлларны күрсәтүчеләр дә була. Ләкин Нәҗипнең ялгыз көрәштәге уңышсызлыгының төп сәбәбе — аның эш-хәрәкәтләрендә эзлеклелек, мантыйк булмауда. Шул ук вакытта холык-фигыль бөтенлеге җитенкерәмәү — аның бәхетсезлеге. Әлбәттә, бу очракта без авторга нигә образны тегеләй яки болай итеп сурәтләдең дип дәгъва белдерүдән ерак торабыз. Чөнки, башкача булганда, әлеге күп яктан гыйбрәтле сюжет барлыкка килә алмас иде. Кеше характеры ахыр чиктә язучыга үзен борчыган әһәмиятле фикерен әйтү чарасы икәнен хәтердән чыгармаска кирәк. А.Гыйләҗевнең каләме мондый нәтиҗә чыгара: «Власть ике төрле була ул, берсе аның күзгә күренә, икенчесе күренми».

Кечкенә генә промбаза директоры Фәтхулла абзыйлар, кибет башлыгы Вафа Сафичлар әнә ни рәвешле шәһәр башлыкларын бармак очларында биетәләр! Чын хакимият әнә шул матди байлыкларга ия кешеләр кулында. Боларында да, тегеләрендә дә оят дигән нәрсә бөтенләй юк. Без нәкъ шундый күренеш белән аннан алдарак кайбер башка әсәрләрдә дә очрашкан идек. Мондый «яши белүчеләр» өчен, дөрестән дә, Н.Хрущев әйткән «безнең буын кешеләре коммунизмда яшәр» дигән сүз тормышка ашкан...

Аның каравы, хакимият башында тотынып тору өчен, аларның күзләренә генә карап торучы тугрылыклы кешеләр бар. Бөтен гаделсезлекне алар шушылар кулы белән башкара. Шәрехли башласаң, явызлыклар өчен җавап бирүчене эзләп табу мөмкин булмый. Ник дигәндә, өстен катлау гөнаһсыз сабый булып кылана, ә балта белән эш итүчеләр исә — исемсез. Моннан бер генә нәтиҗә ясарга мөмкин: балтаны (хакимиятне) халык үз кулына алырга тиеш. Әнә шул вакытта әлеге корал бары тик чын намуслы кешеләр мәнфәгатьләренә генә хезмәт итәр. Тәнкыйтьче Ф.Миңнуллин да, дөнья белән саубуллашканда, «балтаның явызлар кулында булуына» борчылды бит.

Прозадагы кебек үк, драма әсәрләрендә дә А.Гыйләҗев кешене вакыт белән аерылгысыз тыгыз бәйләнештә карый. Вакыт исә һәрнәрсәгә үз билгеләрен сала. Кеше-

ләр аның алдында көчсез булып кала. Хәтта илленче елларда яшәгәннәр белән сиксәненче-туксанынчы дистәләрдә гомер итүчеләр арасында да аерма бихисап. А.Гыйләҗевнең пьесаларын бер-бер артлы укып чыккач та, иң әүвәл вакыт һәм кеше дигән, ягъни мәңгелек сорауларның берсе тирәсендә фикер йөртәсең. Прозасындагы кебек үк, аның драма әсәрләрендә дә конфликт ачык төсмерләнә, пьесаларының җегәрен дә фикер көрәше, аның тирән мәгънәлелеге тәэмин итә. Шул ук вакытта аларда фәлсәфә өстенлек ала. Бу үзенчәлек аның барлык әсәрләренә дә хас. Менә шуларның берсен — «Күтәреп искән җил» комедиясен карыйк.

Әсәрдә гәрчә көлкеле ситуация алынса да, аның төбендә җитди фикерләр ята. Комедиянең гаять күп сыйдырышлы жанр булуы биредә мең дә беренче тапкыр раслана. Җил — татар әдәбиятында Кол Галидән үк килә торган, олы мәгънәләр белдерергә хезмәт итүче деталь. А.Гыйләҗев тә аны әлеге комедиядә уңышлы куллана. Әсәрдә вакыйгалар сиксәненче еллар башында бара. Бу — ил белән җитәкчелек итүдә гаять җитди ялгышлар җибәрелгән чор. Аның иң зур афәте кешеләрне психологик һәм аң ягыннан гарипләндерү иде. Бик күпләр эшләмичә ашарга, җайлашырга, җилнең кайсы яктан искәнен чамаларга, борыннары белән кем ягыннан нинди җил килүен сизеп, үзенә файдалы кешеләр ягына авышырга өйрәнделәр. Боларның һәммәсе аерым кешеләрнең мөстәкыйль эшләргә омтылышын йөгәнләде, иң әшәке сыйфат — икейөзлелек тәрбияләнде. А.Гыйләҗевне дә шушы нәрсәләр борчый. Чорның тагын бер гарип күренеше — кайбер кешеләргә ясалма рәвештә абруй тагу, шуларны бүтәннәр өчен табынырга яраклы шәхес итеп күрсәтергә тырышу булды. Пьесада сурәтләнгән ферма мөдире Фәрхәнә — шундыйларның берсе. Ул җитәкләгән коллективны ничектер бер тапкыр районда алдынгы итеп күрсәткәннәр дә шуны әллә ничә еллар буена үрнәк итеп күрсәтеп баралар. Ә Фәрхәнәнең үзен исә «бөек хатын» дип атарга ук җөрьәт иткәннәр. Аны төрле җыелышларның түренә утырталар, сөйләр өчен нотыкларын язып ук бирәләр, ягъни үзең уйлап баш ватарга да кирәкми. Көннәрдән бер көнне, ачык һавада уздырылган митингта сөйләгән вакытта, аның кулындагы кәгазен җил очыртып

алып китә. Г.Афзал әйткән «кыйбла булып» искән җил аңа шулай итеп, үз сүзләрен сөйләү мөмкинлеген тудыра. Ләкин бу кешенең җәмгыять өчен файдалы эше булмаган кебек, башкаларга кирәкле сүзләре дә юк икән.

Кәгазьдән карап сөйләү — ул утызынчы елларда кереп киткән яман гадәт. Аңа кадәр кешеләр, шомамы-кытыршымы, укып түгел, уйлап сөйләгәннәр! Аларның нәрсәгә сәләтле булуын бер-ике сүз әйтүгә үк чамалаганнар. Утызынчы еллар урталарында исә, сүз сөйләү иң хәтәр эш булып әверелгәч, кешеләр ялгыш фикер әйтүдән куркып, әйтәсе сүзләрен төзәтеп-шомартып алдан ук язып куя торган булып киткәннәр. Тора-бара инде аларны бу мәшәкатьтән дә азат иткәннәр, нотыкларны әзер килеш кулларына тоттыра башлаганнар.

А.Гыйләҗев чаңны бик вакытлы суккан булып чыкты. Хәер, «Өч аршын җир», «Өтәч менгән читәнгә», «Җомга көн, кич белән...» әсәрләре белән ул мондый чаңны даими кага килде. Повестьта сурәтләнгәннәр нигезендә драматик фаҗига итеп эшләнгән «Өч аршын җир» әсәре иҗат ителүеннән соң дистә еллар үткәч кенә сәхнәгә күтәрелгән икән, димәк, бу пьеса ул еллардагы идеология куштаннарының бәгыренә үк булып кадалган дигән сүз. Адаш дип исемләнгән персонажның сүзләреннән моны шактый үтемле сизәргә була. «Бел, авыл халкы җәбер-җәфаны байтак кичерде. Шактый еллар безне кешегә дә санамадылар. Соңгы сыныгыбызны сыпырып алып чыктылар, налог, заемнар белән интектерделәр... Түздек... Без түзәргә өйрәнгән. Әле безнең көн дә килер дип түзәбез! Дөньяда гаделлек дигән нәрсә дә калгандыр лабаса. Бетмәгәндер ич ул?! Шул ышаныч барга түзәбез». Әнә шундый киләчәккә ышаныч хисләре белән тәмамлана әлеге трагедия.

Мирвәлине үз хуҗалыгына ут төртеп, авылдан чыгып китәргә мәҗбүр иткән сәбәп аңарда шәхси милекчелек хисенең көчле булуында гына түгел. Моны аның социаль хәле белән генә аңлату берьяклылыкка илтә. Ни өчен дигәндә, яшьлеген чын авыл хезмәте белән үткәргән Мирвәли күмәк хуҗалыкта да шулай ук тәм табып эшли алыр иде. Аның күңелен ахыр чиккәчә бер нәрсә кимсетә, ул да булса, атасыннан калган

мал-мөлкәтне нишләтү мәсьәләсен хәл иткәндә, авыл активистлары Мирвәлинең фикерен сорап та тормыйлар, аңа әзер карарны гына җиткерәләр: һәммәсен күмәк хуҗалыкка бирәсең, бетте-китте! Болай итүләре нык рәнҗетә, һәм Мирвәлидә моңа каршы тору уй-ниятләрен уята.

Инкыйлаб өстен катлауны хезмәт ияләре белән тигезләде. Дөресен әйткәндә, аларның бөтен хокукларын юкка чыгарды. Кешеләрне бәяләүдә төп күрсәткеч булып аларның җәмгыять мәнфәгатьләренә хезмәт итүе торды. Бу, беренче карашка, гадел җәмгыять булырга тиеш иде. Тик киресе килеп чыкты, совет хакимияте елларында кешеләр арасында яңа тигезсезлекләр барлыкка килде. «Бал кортлары белән янәшә» драмасындагы персонаж — хезмәтеннән ялга киткән офицер Ханзафар Вафичның хирург Зәки Әхиярович белән сөйләшүен тыңлау никадәр ямьсез тойгы калдыра. Ханзафар гади кешеләргә ярый торган табибларга шикләнеп карый. Таныш булмаган доктор үзен карый башлаганчы, Ханзафар аңа үзенең кем булуы, кайда эшләгәнлеге, орденнары турында арттыра-арттыра җиткерергә тели. Ягъни кем икәнен белсеннәр дә, аңа үзенең шәхесенә бәрабәр зур игътибар күрсәтсеннәр! Җиренә җиткереп дәваласыннар өчен ришвәт төртү дә аның күнегелгән гадәте. Шушы Ханзафарның — совет хакимияте шартларында үзен өстен катлау вәкиле дип санап килгән типның — күңелен ачып салуы җанны тетрәтеп җибәрерлек ачыш булып яңгырый. «Тигезлек харап итә! Тигезлек кирәкми, ярамый. Зарарлы ул! Тигезлек яраса, миңа йолдызлар такмаслар иде. Мин гади авыру гына түгел! Гыйбадларга моны тирәнтен төшендер».

Без хәзер җәмгыятьнең сыйнфый яктан катлы-катлы булып әверелә баруын ачыграк тоябыз. Ләкин бу катлаулану җитмешенче-сиксәненче елларда ук барлыкка килгән иде. Ул чакта өстен катлау булган номенклатура моны бик күзгә ташламыйча эшләде. Хәзер исә шул ук кешеләр, пәрдәләргә төренмичә генә, меңнәрнең күз алдында, халык өлешенә кереп, байлык туплыйлар. Аяз Гыйләҗев боларны шактый элегрәк күрде, тәфтишләде, әсәрләрендә шуларны халык хөкеменә чыгарды. Бу аның соңгы утыз елда җәмгыятьне тирәнтен өйрәнүен, аңлавын күрсәтә иде. Ул өйрәнү бездәге

социализмның күз буяу, алдау икәнлеген ачыклауга китерде. Иҗатта гадел булуы А.Гый ләҗев каләмен саташтыра алмады. Аның әдәбиятта гына түгел, җәмгыятьтә тоткан урыны да әнә шуның белән билгеләнә.

А.Гыйләҗев әсәрләре — совет хакимияте чорының сәнгатьчә тарихы, ахыр чиктә аның ни өчен җимерелеп төшүенең сәбәпләрен тирән итеп аңларга ярдәм итә торган әдәби елъязма. Килер буыннар бу әсәрләргә еш мөрәҗәгать итәрләр әле. Чөнки аларның кыйммәте бүгенге көн белән генә чикләнми. А.Гыйләҗев чәчкән таза орлыкларның яңа буыннар күңелендә бәрәкәтле үсентеләр бирәсенә безнең ышанычыбыз зур.





Дорогой
тов.
приглашаем вас на
нашу свадьбу
апреля
1957 г.

ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИН

Киләчәк кешесе

Аяз Гыйләҗев турында уйлаганда, әсәрләрен укыганда, ул бәгырьләрне тетрәндерерлек дәрәҗәдә якын булып күз алдына баса. Шул ук вакытта ул буй һәм хыял җитмәслек еракта, биеклектә торгандай. Ачык төнне күктәге йолдызлар шулай күренә, кулыңны суз да үзеңә ошаганын тотып ал. Булмый шул, адәм баласы күпме омтылса да, әкиятләрендә, җырларында, ягъни сәнгать әсәрләрендә, хыялый метафорада гына күк җисемнәренә барып җитә алган. Аяз ага да ерактагы якын йолдыз кебек. Мин бу хисне ике сүз белән — Рухи Камиллек дип атар идем. Ошбу каршылыклы тойгылар, күрәсең, аның тормышчан гадилегеннән, үз чорын тирәннән сөреп, аңлап, киләчәкне тоемлап, иҗатында шуның чаткыларын чагылдырып кала алу сәләтеннән килә торгандыр.

Уйлый, саный, искә төшерә китсәң, аның белән күп тапкырлар очрашылган, сөйләшелгән, мәҗлесләр уртаклашылган икән. Һәр күрешү тарихи ук булмаса да, күбесе турында озын-озак итеп сөйләп, китаплар язып булыр иде. Жанр таләбенә буйсынып, шуларның берничәсенә генә тукталып, иҗаты хакында кайбер күзәтүләремне укучы колагына сеңдереп үтәсем килә.

Аяз ага белән тәүге танышуыбыз узган гасырның илленче елларының икенче яртысында булды. Сәбәпчесе — сыйныфташыбыз Нәкыя туташ. Чем-кара озын толымнары, бит алмаларына иннек-кершәнсез дә алсулык йөгергән түгәрәк йөзе, килешле гәүдәсе белән малай-шалайны кызыктырып, чапкынлап йөрде дә беренче курсны тәмам-

ламас борын белдерү ясады:

— Җәмәгать, мин кияүгә чыгам.

— Кемгә? — дигән сорау берничә авыздан көзге яфрактай өзелеп төште.

— Безнең бүлектә, өченче курста укый. Аяз Гыйләҗев дигән егет.

Аяз белән Нәкыянең туйга чакыру кәгазьләре



Төркемнән Нәкыя нибары өч кешене — комсорг Шәүкәт Сәйфетдиневне, озак еллар татар радиосында диктор, баш мөхәррир булып эшләгән Рим Кәримовны һәм бу язмаларның авторын гына туена чакырды. Мәҗлес Аяз аганың яши торган фатирында булды. Истә калганы: без утырган бүлмә артык зурдан булмаса да, салкынча чоланы, ишек алды бар иде. Иркен, тыныч, аскы-өске катлардан «шауламагыз» дип кычкыручы, хәзерге кебек аракы сорап читтән бәреп керүче юк. Чакырылган кунаклар шактый булып, күбесе студент яшьләр, кияүнең сыйныфташлары, дуслары, туганнары иде. «Җизни» (без аңа шулай дип дәшкәндә үпкәләми иде) укыган группа егетләргә бай, арада армиядән кайтканнар, офицерлар, фирка хезмәткәрләре бар. Мидхәт Миншин, Фәрваз Миңнуллин, Мөкатдәс Юсупов, Кояш Тимбикова, Рәйсә Яхина кебек киләчәктә көчле мәдәният, әдәбият хезмәткәрләре, ягъни милләтнең асыл затлары чыгачак төркем. Мәҗлес тәэсирле булып истә калган: туйда бии тукмак та дигәндәй, биедек тә, җырладык та, бөтен шартларын китердек.

Мәҗлес барышында «җизни» күзәтү

үзәгендә торды, ул җитезлеге, һәркемгә

игътибарлы булуы, хәрәкәтчәнлеге белән

ошады, әмма артык кырыс, кемгәдер, нәрсәгәдер ачулы, үпкәле тоелды. Усал иргә тарыды бугай, дип, Нәкыяне кызганыбрак та куйганбыз, төркемнең чибәрен эләктерде, аңа ни кирәк тагын дип уйлаганбыздыр. Соңрак без Аяз аганың ул чорда кичергән рухи халәтен тирәнрәк аңладык. Аның башыннан узганнарны Ходай Тәгалә берәүгә дә күрсәтмәсен. Дарелфөнүндә белем эстәп, киләчәктә язучы булырга хыялланып, антик дөнья, гарәп, кытай фәлсәфәләренең серенә төшенеп, дөнья матурлыгына сокланып яшәгәндә, сине төнлә, җылы ятагыңнан тартып төшереп, тузга язмаган гаепләр тагып, судсыз-нисез, дөресрәге, ясалма мәхкамә белән салкын Караганда ягына озатсыннар әле. Холкың, фигылең, дөньяга карашың үзгәрер бу кычкырып торган гаделсезлектән. Усалланырсың!

Аяз агага үтәргә туры килгән тормыш баскычлары, күмер «приискалары» турында мәгълүмат безгә соңрак иреште. Ил, ыңгыраша-шыгырдый булса да, ике адым алга, берне артка атлап, сталинизм чорын узып бара, азмы-күпме фикерләү, сүз ирege килде, пәрдәнең бер чите күтәрелде. Әмма күптән түгел булып узган кыргый хәлләр хакында ачыктан-ачык, әйтик, «Йәгез, бер дога!» романындагы кебек бәян итү куркыныч. Күсәк башындагы тәмуг уты пыскып янган вакыт узмаган иде әле. Ә туй көннәрендә аның күңелендә әрнүле газап, тоз сипкән ярадай сызлап, башыннан узган хәлләрнең сынлы сурәте күз алдында торгандыр.

Студент туе өстәле бик әгъладан булмагандыр, мәгәр төрле-төрле аракыларның муллыгы һәм ниндидер тәмле, сәер эчемлекнең елгадай акканлыгы хәтердә. Оста кулыннан узган бу «куылган» сыекча бик ошады, әмма тамакны иркәләп төшеп, тәп башына утырта торган булып чыкты. Студентның боламыктай сыек гәүдәсенә, ярым ач корсагына күп кирәкме? Мәҗлес башында әтәчләнеп утырган гаярь егетләр берәмберәм бәдән ныклыгын югалта тордылар, хуҗа буларак үзен саклаган «җизни»нең бу

Туйда бии тукмак та...



хәлгә ачуы кабарды һәм тез аслары йомшарган агай-энене чоланга чыгарып, кайсын андагы диванга, кайсын авыл келәме җәелгән идәнгә әрдәнәләп өя торды. Гәүдәнең көчен алса да, исемсез эчемлек телләрне ачып җибәрде, күбесе, даһилыкка ук булмаса да, җәмгыятьтә мактаулы урынга, язучылыкка дәгъва итә башлады, мәҗлес кызган саен, Аяз ага кулы аша узган «чолан классиклары» арта барды. Берәү дә авылга гади укытучы булып барырга теләк белдермәде. Беренче курста гына укысак та, Нәкыянең йөзенә кызыллык китермәс өчен (бала-чага чакырган), эчү мәсьәләсендә өлкәннәрдән калышмаска тырыштык, ярый әле туй узган урыннан ерак яшәмибез икән, Киров урамына сызылып таң атканда, саба җилләре искәндә кайтып җиткәнбез. Аң төпкелендә ул чорда чая, чибәр, татар бүлеген утлы табада биеткән Диләрә Тумашеваның «Тел белеменә кереш» дигән лекциясенә барсаң шәп булыр иде дигән уй-ният яши, әмма башны калкытуга җиңел эчелгән сыекча уянып, иңнәрдән басып яткыра. Без дәрескә бармаганнан гына тел белеменә зур зыян килмәс дип, кичкә чаклы ятакларны бизәдек. Студент елларыбызда Аяз абыйга ихтирамыбыз арта, мөнәсәбәтебез гел яхшы якка үсә торды. Хөрмәтне сатып алып та, ялварып сорап та, дәгъвалап та булмый. Ул акча кебек, йә бар, йә юк. «Җизни» исә гамәли эшләре белән безнең күңелләргә якыная барды. Гаилә башлыгы буларак җаваплылык тоеп, «Чаян» журналында эшли башлады. Нәкыя ханым икенче курсны тәмамлаганда һәм бишенче курста укыганда малайлар алып кайта торды. «Җизни» Нәкыя ханым инде ике бала анасы булгач та, көндезге бүлектә укып, диплом алып чыгарга мөмкинлек бирде. Аяз аганың тылы нык булды, тормыш иптәше төпле, сабыр, җитди ханым булып чыкты, үзе белем эстәгән төркем белән дус яшәде, сез кем дә, мин кем дип, язучы хатыны булып кәпрәеп, эреләнеп йөрмәде, стипендия тота белми торган егетләргә әҗәткә акча биргәләде.

— Нәкыя ханым, татар милләтен ятим калдырасың килмәсә, биш сум акча биреп торчы?

— Нәкыя, группага мине җирләп, мәшәкать чыгарасың килмәсә, ун сумыңны кызганма? Күмү кыйммәткәрәк төшәргә мөмкин.

Нәкыя ханым «туйдым сез хәерчеләрдән» дип зарланып ала да сумкасына үрелә.

Укуын тәмамлагач та Аяз аганың җәмәгате җылы, тыныч урын эзләтеп маташмады, озак еллар дәвамында, язучының һәр җәһәттән ышанычлы ярдәмчесе, терәге булу өстенә, мәктәптә укытучы булып эшләде, татар телен гамәлгә ашыру өчен терсәкләрен каната-каната көрәште. Кыскасы, гаиләсе белән Аяз ага бик бәхетле булды. Мил-

Нәкыя ханым уллары белән. Артта — Искәндәр, уртада Рәшат һәм Мансур.

1969



Фалис Вәлиев, Аяз Гыйләҗев Зәйдә очрашу вакытында. 1997

ләткә эшчән, булдыклы, һәркайсы җәмгыятьтә үз урынын тапкан өч ир-егет бүләк иткән башка татар язучысы юк.

Туй мәҗлесендәге тәүге танышлык, бездән тормаган сәбәпләр аркасында, даими аралашуга күчеп китә алмады. Университетны тәмамлап, берничә ел Казанда яшәп-укып алганнан соң, миңа егерме ел тирәсе Алабугада дөнья көтәргә туры килде, ул чорда «җизни» белән еш күрешеп булмады. Һәркемнең көндәлек мәшәкатьләре, язу өстәле үзенә җиткән. Мин җитәкчелек иткән дәвердә Алабуга педагогия институтына язучылар, шагыйрьләр, җырчылар, көйчеләр гел килеп-китеп йөрсәләр дә, Аяз ага бу исемлекне бизәмәде. Вакытны бушка сарыф итү дип санаганмы, язучыларның Мәскәү янындагы иҗат йортларына еш йөрергә туры килеп, гаиләсеннән аерылып торырга теләмәгәнме, рәтле-юньле чакыруыбыз булмагандырмы, хәзер кистереп әйтүе кыен. Аннан килеп, Аяз Мирсәет улы теләсә кем белән изү чишеп, галахланып, кочаклашып, дуслашып йөри торган арзанлы кеше түгел иде. Ул рухына, интеллектына туры килгән, гамәли эше белән милләтенә хезмәт иткән кешеләрне генә таныды, шулар белән генә аралашты. Ул яраткан язучылар, театр әһелләре күбебезгә мәгълүм. Мине дә ул Алабуга techинституты ректоры булганым өчен түгел, ә татар шигърияте буенча дистәгә якын китап чыгаргач, проза хакында мәкаләләрем басылгач кына үз итте һәм туган ягы Зәй төбәге туфрагындагы якын дусты, өченче чакырылыш Дәүләт Советы депутаты, төрле җаваплы урыннар биләгән Фалис Вәлиев белән бер авылдан чыгып, бергә мәктәп юлларын таптаганны күңеленә алгач кына якын күрә башлады шикелле. Теләсә кем янында урам сүзләрен мул кулланырга яраткан, шуннан ләззәт тапкан, теләсә кайсы дәрәҗә әһеле белән үзен бәйсез тоткан Фалис Аяз абый белән очрашканда, саф әдәби телгә күчеп (анысын да яхшы белә, заманында КДУның татар теле бүлеген тәмамлаган), холкын уңай якка үзгәртә дә куя. Бу — язучыга хөрмәт, аның белән санашу, тирәлеккә ярашу дигән сүз иде. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, дияр идең, гадәттә «арба» — Фалисныкы, әмма дилбегә Аяз абый кулында була.

Аяз Мирсәет улы белән соңгы күрешүебез дә Фалис Әхәт улының фатирында, депутатлар яши торган йортта булды. Әшәке чир хәлен алып, кәефен кырса да, рәтләп ашый-эчә алмаса да, Аяз абый очрашуга килде, берни сиздермәскә тырышып, сүзгә катнашып, моңсу гына елмаеп утырды. Акыллы гына зарланып алганы хәтердә:

— Егетләр, күзләрем арыды, колакларым ишетүдән туйды, кан тамырларым кысылды. Әмма яшәүдән гайрәтем кайтмады.

Әлбәттә, бер әдәбият казанында кайнагач, А.Гыйләҗев белән «Казан утлары» журналы редколлегиясе, яшь язучыларны Берлеккә кабул итү коллегиясе (ул озак еллар аның рәисе булды, һәр дәгъвачыны җиз иләк аша үткәрде), Язучылар берлегенең идарә утырышларында, башка рәсми җыеннарда һәм «мальчишник»ларда утырырга насыйп булды.

Аяз ага һәрвакыт игътибар үзәгендә торыр, «алай түгел, болай ул, парин» дип, үз сүзен һәр җәһәттән өздереп әйтер, ышандыра белер: юморны, шаяртуны кабул итәр, кирәк булса, тәгаен җавабын табардай зат иде. Үз башыннан узган, ишеткән мәзәк хәлләрне сөйләп, урыны-вакыты белән күпкә арттырып, яшьрәк буынның, аерым алганда, Иделне йөзеп чыга алган Равил Фәйзуллинның киң маңгаеннан учы белән көнләшү тирләрен җыйдырган чаклары булгалады. А.Гыйләҗев үз бәясен белеп, төрле хәл-әхвәлләрдә вәкарьлеген саклый алды. Һичшиксез, ул Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким, Салих Баттал кебек өлкәннәрне хөрмәт итә, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов, Гамил Афзал кебек талант ияләренә, яшьтәшләренә хөрмәт белән дусларча карый, үртәшә, көлә, җитди итеп милли мәсьәләләр, әдәбиятның үсеш үзенчәлекләре хакында фикерләре белән уртаклаша, әңгәмәдәшен җиңел генә бәхәскә тартып кертә. Яшьләргә алмаш дип, җитди итеп, таләпчән карый һәм, аның уенча, өметле дип саналганнарына ярдәм кулын суза, талантлы дип тапканнарына фатихасын бирә, иң кирәкле вакытта тиешле фикерен әйтеп, кереш сүзен яза. Аның каләменнән төшкән башлам яисә соңгы сүздә фикерләү киңлеге, әдәбиятка хуҗаларча карап, аның көчләрен барлап, юнәлеш биреп, киләчәк үсеш юлларын тамгалап ба-

руы искитмәле. Ул, әлбәттә, теләсә нинди әрсезнең китабына кереш язмый, каләмле кешене генә хуплый, күтәреп ала. Мин аның уртакул язучы белән аралашып, дуслашып йөргәнен хәтерләмим. Язмышын дөрес билгеләмәгән, һөнәрен ялгыш сайлаган бәндәләрне ул үзенә якын китермәде, әдәбиятны алардан сакларга тырышты. Хәер, соңгылары үзләре дә аның таләпчән, кырыс холкын белеп, Аяз абыйның күзенә чалынмаска тырыштылар. Иҗади концепциясен, үз әсәрләренең фәлсәфи юнәлешен аңлап, бәяләп, тәфсилләп бирә алмаган өчен булса кирәк, ул тәнкыйтьчеләрне бик үк өнәп бетермәде. Үзе принципиаль, үтә таләпчән тәнкыйть мәкаләләре авторы буларак, күрәсең, бу өлкәгә югары критерийлар яссылыгыннан килгәндер, иҗатының асылын аңлаган тәнкыйть турында хыяллангандыр.

А.Гыйләҗев — әлегә чын-чынлап, тирәнтен өйрәнелмәгән, әзер кысаларга, кабул ителгән атамаларга сыешып бетми торган зур иҗат мирасы калдырган язучы. Аның проза, драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәләренә керткән яңалыгын бәяләү, аңлау һәм аңлату хәзерге әдәбият фәне алдында торган изге бурычларның берсе. Әлегә аның иҗаты турында Әхмәт Сәхаповның кандидатлык диссертациясе якланды, шуның нигезендә эшләнгән китабы чыкты. Аерым мәкаләләр генә язучының фәлсәфи концепциясен, фикерләү рәвешен, сурәтлелек байлыгын ачып җиткермиләр.

А.Гыйләҗевнең иҗат юлы шомартуга, бизәүгә мохтаҗ түгел. Ул көчен төрле өлкәләрдә сынап карады. Документаль нигезгә утыртылган әсәрләр дә язды, роман жанры үсешенә өлеш кертте, геройларын сәхнәгә күтәрде, хикәя, публицистика, мемуар кебек «вак-төяк» жанрлардан да йөз чөермәде. Эзләнә-уйлана торгач, үзе өчен күңеленә бер хакыйкатьне ныгытып куйды булса кирәк: аның динамик фикерләве, характерларны психологик нечкәлекләре белән тирәнтен, күңел борылышлары аша кинәт ачып куя алу сәләте, рухи дөньяга диалог һәм автор монологы аша үтеп керә белү сыйфаты һәм, гомумән, сурәтле фикерләве өчен иң кулае повесть икән. А.Гыйләҗевнең повестьсыз калган елы юк диярлек. Һәркайсы үзенчә кабатланмас. Классиклар иҗатын һәр чор үзенчә, замана вазгыятенә бәйле, рухи таләпләргә ятышлы укыган

төсле, А.Гыйләҗевнең иҗади каһарманлыгы туачак көннәрдә тулырак, тирәнрәк ачылыр, милләтен бәхетле итү, коллык, мескенлек психологиясеннән арындыра барып, камил инсан турындагы хыяллары тормышка аша барган саен, иҗатының тирәнлеге, сәнгати камиллеге, эшкәртелгән алмаздай, яңа сыйфатлары белән балкый барыр. Тормышның әшәке, кешене корт кебек кимерә, түбәнәйтә торган сыйфатларын әйләнеп үтмәсә дә (әйтик, «Өтәч менгән читәнгә» повесте), ул милләтенә үрнәк-өлге булырдай шәхесләрне күбрәк тудырды, илһамы якты чырайлы кешеләрне тасвирлаганда, каләме хакыйкый көмештәй ялтырап китте. Җөмләдән, татар хатын-кызларына хас күркәм сыйфатларны үзенә туплаган, сөттән ак, агым судан пакь, намуслылык, җаваплылык үрнәге — Бибинур карчыкны («Җомга көн, кич белән...») искә төшерик. Җайга салынып барган шәхси тормышыннан, йөргән егетеннән, үзгә уңайлыклардан баш тартып, аналарыннан ятим калган өч баланы кызганып, яшь кыз тол иргә кияүгә чыга. Аның белән дә яшәп кала алмый, атаны сугыш тегермәне үзенә тартып ала. Бибинур ятим балаларны интернатларга таратса да, берни әйтеп, аны кешелексезлектә гаепләп булмас иде. Үз газиз балаларын урамга чыгарып ташлаган ата-аналар Җир шарында җитәрлек. Тумыштан намуслы, итагатьле Бибинур бу юлга баса алмый, көннәр буе колхоз эшендә чиләнеп, төннәр дәвамында чит балаларны карый, кеше арасында ким-хур булып, рәнҗеп, ятимлекләрен сизеп, күңелләре кителмәсен дип, ул аларны үз балалары кебек тәрбияли, мәктәптә укытып кына калмый, һәммәсенә мәктәптән тыш белем бирә. Аңа дөньяви хисләр дә ят түгел. Җиһангирга булган олы, бөтен барлыгын биләгән мәхәббәте соңарып, кояш баер алдыннан килә; бөтен көчен, дәртен, яшьлеген кеше балаларына биргән Бибинур инде картайган, матурлыгын югалткан. Ә кешенең рухи дөньясы байлыгы тирәнлеген, самимилеген кем аңлаган, кемгә хаҗәт ул. Бөтен җегәрен алган, җелеген суырган, үзләре ятимлек газапларын күрмичә үскән балалар үз гаиләләрен корып, шәһәрдә урнашып калалар һәм үги аналарын бөтенләйгә оныталар. Нәкъ «ит яхшылык, көт явызлык» дигән татар халык мәкалендәгечә. Әллә үги аналары бар, әллә юк алар өчен.

Язучы Бибинур язмышын сурәтләп, миһербанлылык, рәхмәтлелек, гуманизм проблемаларын калкытып куя. Балаларның шундый мәрхәмәтсез булып чыгуында кем гаепле соң? Күрәсең, бу очракта нәсел орлыгы һәм шәһәр мохите тәэсире кешелеклелек төшенчәсеннән көчлерәк булып чыгалар. Иң гаҗәбе шунда: Бибинур карчык аларга үпкәләми, рәнҗеми, эшләре күптер, вакытлары юктыр, үзләре генә бәхетле булсыннар дип, тел-теш тидертми. Каян килә аңа мондый илаһи пәйгамбәрлек бөеклеге, киң күңеллелек. Тәрбиядән, ислам дине кануннарыннан, татар гаиләләрендә борын-борыннан килгән бала, киләчәк өчен яшәү фәлсәфәсеннән иңә торгандыр мондый аскетизм, дәрвишлек.

Бибинур өчен тамгалы көн — җомга. Чөнки бу көнне намазлар укыла, өйләрдә борыннарны кытыклап тәмле исле ризыклар пешә, утлар гадәттәгедән яктырак яна, халык шау-гөр килә, күрешә, сөйләшә, көлешә, чөнки һәр йортка каладан туганнары, балалары кайта, һич югында, хатлар, телеграммалар, күчтәнәчләр килә. Елдан-ел җиргә сеңеп, тузып, таушалып барган Бибинур карчык өендә генә мәет чыккандай тынлык, ул йортка беркем керми, чыкмый, хат ташучы да аяк басмый. Шул авыр тәүлекләрнең берсендә изге карчык фани дөньяны да ташлап китә. Язучының мәхәббәте кем ягында икәне бәхәс уятмый. Биредә симпатия дә, миһербансызлыкны кабул итмәү дә, Аяз Гыйләҗевчә, төгәл, ачык, ярым тоннарсыз, томанлы кинаясез бирелгән. Укучыда шундый сорау тууы табигый: бу образ җәмгыять өчен хасмы, типикмы? Чит-ят кеше бәхете, киләчәге өчен үзен корбан иткән, шул хәлне табигый дип санаган Бибинур кебек олы җанлы кешеләр күпме? Әлбәттә, мондый ялангач, үтә күренмәле фидакарьләр әдәбиятта да, Җир шарында да күп табылмас. Капиталистик мөнәсәбәтләр андый миһербанлылыкка юл калдырмас. Шулкадәрле ихласлылыктан бармак төртеп күрсәтеп көләрләр генә. Бу очракта бит тормыштан күтәрелебрәк, калкыбрак торган язучының хыялы олы мөнәсәбәтләргә, биеккә, яктыга омтылган идеалы бар. Идеал — караңгы, түбән тормышны алга әйдәп баручы изге көч. А.Гыйләҗев үткән, бик борынгы, мәҗүси чорларда яшәгән кешеләр арасындагы яшәеш кануннары һәм киләчәктә тууы мөмкин булган мөнәсәбәтләрне үзенең хыялы белән берләштереп, шуларның синтезы

итеп, татар прозасының иң уңай каһарманнарыннан берсен — Акәбине — Бибинурны иҗат иткән. Башка әсәр язмаса да, «Җомга көн, кич белән...» повесте белән генә дә А.Гыйләҗев татар әдәбияты тарихында калыр иде.

Әйтергә кирәк, язучының һәр әсәрендә диярлек каһарманнар ачык һәм калку, рельефлы тасвирлана, урталыкта буталып калган, камыры пешеп җитмәгән (аморф) затларны ул өнәми, сурәтләгәндә дә сатира боҗрасына ала. Геройларының фигыле, менәзе авторның үз холкыннан, дөньяны һәм рухи халәтне шәхси аңлавыннан юл ала торгандыр.

Заманында сыкранып кабул ителгән, мәгәр гасыр элпесе сынавын үтеп, татар әдәбиятының алтын фондына кергән, XX гасыр татар прозасының йөзек кашларының берсе булган «Өч аршын җир» повестен алыйк. Тарихка «Хрущев җепшеклеге» дип кереп калган алдаучан елларда язылган (1962), шул чорда олы бәхәсләр уяткан әсәрләрнең калкуы булгандыр. Авторны кулакны яклап, аңа ышаныч белдерүдә, үлем фәлсәфәсен (теләсә кемгә ахыр чиктә өч аршын җир җитә) алга сөрүдә, пессимизмда һәм башка «изм»нарда гаепләделәр. Яла ягуларның, сәяси кысуларның, ышанычсызлык белдерүләрнең бәясен тәгаен белгән автор бу фикерләрне авыр кичергәндер.

Вакыт, олы чүкеч сыман, барысын үз урынына утыртты, әсәрнең сәяси новаторлыгы, психологик анализ тирәнлеге, тел-стиль байлыгы елдан-ел тирәнрәк ачыла бара.

«Өч аршын җир»дә психологик сюжет яшәү мәгънәсенең серен, үзеңә җан өргән һәм кабул итәчәк туфракка якынлыкны физик һәм рухи сиземләргә мөмкинлек бирүе белән киң катлау укучының мәхәббәтен яулады. Әсәрнең үзәк герое Мирвәли — катлаулы, йөрәге күкрәгенә сыймаган шәхес. Көчләп күмәкләштерү белән килешмичә, дөресрәге, ата-бабасыннан мирас булып калган мал-мөлкәтне ярлы-ябага кулына бирергә теләмичә, бар байлыгын, мал-туарны юкка чыгарып, юлыннан кире әйләнеп кайтып, затлы йортына ут үрләтеп һәм кыргыйрак гамәлләре белән (бер очтан авылның шактый йорты яна) үзен һәм яратып, атасының каршы килүенә карамастан өйләнгән Шәмсегаянны да бәхетсез итеп иртә гүргә керткән Мирвәли бу ягы яхшы, уңай, әлеге сыйфаты начар дип кенә бәяләп котылырлык шәхес түгел. Ул иҗтимагый һәм шәхси

каршылыклар берәмлегеннән тора һәм социалистик реализмның герой турындагы кысасына сыймый. Аңарда теләсә кемнән таләп ителә торган төп сыйфат бар. Мирвәли — хезмәт кешесе, теләсә нинди эштән дә чирканып тормый. Тир түгеп табылган нәсел байлыгы аңа газиз һәм кадерле. Аның уйлавынча, шәхси милекне тартып алырга берәүнең, шул исәптән хакимиятне кулларына төшергән адәмнәрнең хакы юк. Иҗтимагый катаклизмнар килеп чыкмаса, Мирвәлинең бәхетле булырга бөтен мөмкинлекләре бар: йорт-җире яхшы, җире бар, яраткан хатыны янында һ.б. Менә шул изге төшенчәләрне яклап, аның бунтарьлыгы, гыйсъянчылыгы калкып чыга. Үз-үзен хуҗа итеп сизеп, бәйсез тотуы, дуамал холкы аны шул чор өчен хәтәр юлга бастыралар. Ул шәхси милекне талап, кешене сыта, изә торган тәртипсезлекләр урнаштырган иҗтимагый стройга каршы күтәрелә. Әлбәттә, аның бунты файдасыз, үзенә һәм гаиләсенә бәхетсезлектән башка нәрсә алып килми. Мәгәр Мирвәли, юаш ат кебек, теләсә кемгә баш иреп, йөгәнен киеп яши алмый, гаделсезлекләргә каршы чакыру ташлый. Сугыш ача. Көчләр тигез түгел, ул җиңелә һәм җиңүчеләрдән үзенә өч аршын җир сорап килергә мәҗбүр була.

Мирвәлине дуамалланып, авылдашларына китергән бәла-каза өчен гафу итеп булмаса да, хосусый милек яшәешен аклаган яңа чор аның хаклыгын раслады, язучының тарихи сиземләвенең дөреслеген исбатлады. Язучы Мирвәлинең барлык гамәлләрен хуп күрмәсә дә, симпатиясе кискен холыклы, көтелмәгән хәрәкәтләргә һәм хакыйкатьне раслауга үзен кызганмаган шәхес ягында икәнлеген тоемлау авыр түгел. Композицион борылышлар, тирән психологик анализ, табигать күренешләре авторның дөньяга һәм каһарманнарына мөнәсәбәтен аңларга ярдәм итә.

Әгәр без татар әдәбиятында, әле сәясәт социалистик реализмны үз кулында тотканда, аның кысаларына сыймаган, хәтта кайбер кагыйдәләрен кире каккан, дөреслекне, тормыш хакыйкатен алга сөргән яңа реализм туа килгән икән дисәк, аны А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»е кебек әсәрләрдән эзләргә кирәктер.

Үҗәт тәнкыйть А.Гыйләҗев повестеның соңында каһарманын тәүбәгә китерә, «тә-

зәтә», гафу үтендереп диярлек, колхоз идарәсе члены Мирвәлигә үтенеч белән алып килә (ул авылда Мирвәлинең адашы), димәк, социалистик реализмның тискәре герое хаталарын аңлап, дөрес юлга басарга тиеш дигән таләпләренә җавап бирә дияргә мөмкин. Мирвәлинең бу адымын татар халкының борынгыдан килгән гореф-гадәте, әдәп-әхлак кагыйдәләре белән аңлатып, аклап була. Туган җир тарта.

Авылдашлары алдында Мирвәли гаепле (шуны теләмәсә дә, өйләрен яндыра) һәм гадәти әхлак, дин кануннары буенча да, үз гөнаһларын танып, авылдашларыннан һәм Ходайдан гафу итүне сорарга тиеш. «Теге дөнья» мәшәкатьләре турында уйларга вакыт җитеп килә. Әсәрнең кайсы чорда язылганын онытмыйк. Язучы шундыйрак «реверанс» ясап, каһарманын «аз-маз» төзәтмәсә, повесть шул чорда дөнья күрмәс һәм иҗтимагый аң үсешенә тиешле тәэсирен иңдерә алмас иде.

А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»е һәм социалистик реализм «күлмәгенә» сыймый торган татар әдәбиятының үзгә уңышлы әсәрләре турында сүз алып барганда, совет әдәбияты үсешеннән бер моңсу мисал китерәсе килә. Әгәр Чыңгыз Айтматов союздаш республика вәкиле булмаса һәм «Җәмилә» повесте, француз язучысы Луи Арагонга тәкъдим ителеп, чит телгә тәрҗемә ителмәсә, тәрҗемәче әсәргә игътибарны юнәлтмәсә, бәлки, ул нәүбәттәге кыргыз язучысы булып калыр иде. Каләм иясен вакытында күреп алу аның үз-үзенә ышанычын арттыра, өстәмә көч, кыюлык бирә, каләмен чыныктыра. Татар язучыларын шулай күтәреп алучылар офыкта күренмәде, халыкка автомат рәвештә түбән сортлылык мөһере суккан автономия дип аталуның янә бер әшәкелеге иде бу. Үзәк «талантларны» күбрәк союздаш республикалардан эзләде һәм Луи Арагоннарга юнәлеш биреп торды.

Ике гасыр кул бирешкән елларда (XX һәм XXI) әдәбиятта реализмның тышындарак калган яисә аның мөмкинлекләрен киңрәк аңлаган эзләнүләргә игътибар үсү табигый. Модернизм, яңа модернизм, акмеизм, импрессионизм кебек хәзерге дөнья әдәбиятларына хас күренешләрнең тамырларын халыкның анимистик чордагы фикерләвеннән, мифологиядән эзләү кызыклы. Г.Гыйльмановның «Албастылар» исемле шул юнә-

лештәге әсәрен укыгач, А.Гыйләҗевнең әдәбиятка кыю, эзләнүчән, яңача фикерләүгә сәләтле яшьләр килә дип шатланганы хәтердә. Бу төр экспериментларга, әдәбиятның югары дәрәҗәсе хакында кайгыртып, аның барыр юллары, тормышның үзе кебек үк, бай һәм төрле булырга тиеш дип уйлаган әдипнең сүз сәнгатенең үсеш юлларын киңрәк күзаллаган әсәрләргә җылы карашы аңлашыла. Чөнки үзе «Яра» әсәрендә мәхәббәтнең кеше ышанмаслык батырлыклар кылуын үзәккә ала. Ул кыю гамәлләрнең әссасын-нигезен мифологик фикерләүдән, халык ышануларыннан эзләргә кирәклекне раслап, нигезләп чыга. Аның бу әсәре тар аңланган реализмнан ерак тора.

Аяз ага җаны, тәне белән милләтенә бирелгән, аның тарихи фаҗигасен, һаман да кыерсытыла килүен аңлаган, холкының гореф-гадәтләренең иң тирән катламнарын күзаллап әсәрләрендә чагылдырган, татарның бәхетле милләтләр сафына атлавын теләп, шуның өчен көрәш, аң, белем, мәгърифәт югарылыклары кирәклеген туктаусыз тәкрарлап торган әдипләрнең берсе иде. Азатлык, бәйсезлек проблемалары, кешелеклелек, милли идея, милли аң үсеше турында уйланулар белән уртаклашкан соңгы еллар публицистикасы хәзерге татар иҗтимагый фикерләвенең югары таләпләренә җавап бирәләр. Аларны җентекләп өйрәнәсе, гамәли тормышыбызга таяныч итеп аласы иде.

А.Гыйләҗевнең хакимият белән мөнәсәбәтләре гади һәм гадәти булмады. Бер яктан аны Зәй, Чаллы, Арча кебек төбәкләрнең хакимият хуҗалары якын иттеләр, сабан туйларына, башка милли бәйрәмнәргә чакырып тордылар. Икенче яктан, мөстәкыйль холкы, дөньяга бәйсез карашы нәтиҗәсендә, ул җөмһүрият хуҗаларының сөйкемле сөяге булмады, үзе дә түрәлеккә, мул тормышлы депутатлыкка омтылмады. Студент елларында Сталин иярченнәреннән күргән җәбер-золымны, нахакка рәнҗетүләрне ул барыбер ахыргача гафу итә алмагандыр. Күңел ярасы тән ярасыннан тирәнрәк була һәм озак төзәлә шул. Ул әдәбиятка килгән, шәхес буларак формалашкан елларда идарә башында битлеген генә алыштырган шул ук чиновниклар утырганын күреп белә. Беркадәр эченә бикләнә. Мәгәр, олы шәхес буларак, үз үпкәсен, рәнҗүен әсәрләренә кертмәскә, тараймаска тырыша. А.Гыйләҗев — үзе белән көрәшеп, үзен җиңгән

шәхес. Шуңа күрә мин аны, әсәрләрендә чагылган идеал, омтылыш, ният, рух олылыгын истә тотып, Киләчәк кешесе дип атар идем.

Сентябрь, 2002



МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

Аяз әкә сабаклары

Без, гадәттә, калдырган әсәрләреннән чы-

гып, язучының әдәби портретын сурәтләргә,

шәхси сыйфатларын билгеләргә яратабыз.

Минемчә, киресенчә эшләргә дә: шәхескә хас

үзенчәлекләрне барлап, шулар ярдәмендә

әсәрләрдә гәүдәләнгән сыйфатларның эчке

табигатен аңларга омтылып карарга мөмкин-

дер.

Әдәби фикеребездә хөрлек богауланган

чорны, шул замандагы каршылыкларны, эчке

көрәшне үзенчә чагылдыручы катлаулы мирас

калдырган, үзе дә озак еллар дәвамында эзәр-

лекләнгән, кимсетелгән, бары гомеренең соңгы

чорында гына Татарстанның халык язучысы

дигән исемгә лаек булган Аяз Мирсәет улы

Гыйләҗевнең кешелек сыйфатлары, фикерем-

чә, мондый алым кулланырга зур мөмкинлек-

ләр бирә. Ләкин мин бүген, болай зурдан куелган теманы махсус тарайтып, бер

истәлеккә генә мөрәҗәгать итәргә булдым. Аның кешелек сыйфатын чагылдыра

торган бу хатирәм, бәлкем, язучы иҗатының кайбер үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итәр.

Хәзергечә әйтсәк, тарихи ватанга кайтып Казан туфрагына аяк баскач, беренче

танышкан, ярдәм кулының җылысын тойдырган кеше Аяз Гыйләҗев булды.

Беренче танышу дигәч тә, аның сәбәпләре хакында да әйтеп китим.

50 нче елларның башында ук миңа «әдәбият җене» кагылган иде. Кулга төшкән,

телләрен аңлый алган нәрсәләрнең һәммәсен укый бару белән бергә үзем дә, кем

әйтмешли, «кәгазь пычраткалый» башладым. Тегене-моны язган булам, җыр-бәетләрнең текстларын күчерәм, мәкаль-әйтемнәрне җыеп терки барам. Үземчә мәш киләм. 1955 елда СССРга кайткач, Казакъстанга Казаннан почта аркылы алдырган «Татар поэзиясе антологиясе» һәм башка татарча яңа китаплар, журналлар күңелдә күптән борынлаган бер теләкне — ата-бабалар җиренә, Казанга кайту, Казан университетына кереп белем алу теләген тагын да көчәйтеп җибәрде. Төрле мөмкинлекләрдән файдаланып, студентлык елларына кирәкле кием-салым хәстәрли башладым. Тик күңелдә бер шөбһә дә баш күтәреп куйган иде: урта белеме урыс мәктәпләрендә алынган, сөйләм теле дә төрле төрки телләр мохитендә «канат чыгарган» кешегә татар әдәби телендә имтихан биреп, сынауларны узу мөмкин булыр микән? Әнә бит, күптән түгел генә Казакъстанга күченеп килгән Идел-Урал ягы кешеләре, җае килгән-килмәгән саен: «Телегез әллә ничек, дөрес сөйләшмисез», — дип төрттереп куялар. Әлбәттә, Казаннан алдырган «Галиәсгар Камал — ул татарның Островские», «Шәриф Камал — татар Горькие» ише шактый сәер дәлилләргә корылган әдәбият кулланмалары, «колхоз матур», «тормышыбыз хәзер бик матур» ише төче «тел үрнәкләре» белән шыплап тутырылган грамматика-синтаксис дәреслекләре буенча да әзерләндем. Үземне хәзерге татар әдәби телен яхшы белә торган Казан кешеләре тарафыннан сынатып карау фикере дә туды. Юлын да таптым шикелле. Шигырь рәвешендәрәк язган-сызганнарымнан сайлап, «Чаян» журналына бер әйбер юлладым. Хәтерем ялгышмаса, Тукайның «Авыл җырлары»на ияреп әвәләнгән, космос корабларының берсенә багышланган нәрсә иде бугай.



Дулкынланып көтә башладым. Нигезсез дә түгел. Күптән түгел Алматыда Ташкенттан килгән бер агай белән танышкан идем. Ул да шигырьләр язып җенләнә икән. Тик күңелен бик төшергәннәр үзенең. Казандагы Язучылар идарәсеннән, аныңча әйтсәк, «купал» (тупас) җавап килгән: «Сезгә татарча шигырь язардан элек телегезне яхшылап үтүкләргә кирәк булыр!» — дип кыздырган аны әдәбият буенча «консультант Камал исемле» кеше... Шуңа күрә Казаннан килгән конвертны мин әллә ничә мәртәбәләр әйләндереп, дулкынланып ачтым. Тик... җавапны тулысынча күчерәм: «Хөрмәтле иптәш Усманов! «Авангард»ка багышланган җырларыгызны алдык. Алар шактый кызыклы һәм оста язылганнар. Бу характердагы материалларның журналыбызда шактый күп басылган булуын игътибарга алып, җырларыгызны бастырып булмас. «Авангард» хакында күп кенә бастык шул инде. Башка материалларыгыз булса, җибәрегез. Сез азмы-күпме яза аласыз шикелле. Сәлам белән, «Чаян» журналының әдәби бүлек сотрудныгы Аяз Гыйләҗев. 23.XII. 1957 ел».

Җибәрдем, әлбәттә! Йөгерә-йөгерә дигәндәй, көлтәсе белән җибәрдем. Тик, 1958 елның 17 гыйнварында җаваптан күренгәнчә, болары да бастырырлык түгел икән. Шулай да «өчесенең иң әйбәте — Бюрократ Кабинетский «...кыскалыгы белән, фикере булу белән» ошаган А.Гыйләҗевкә. Калган ике шигырьгә төпле анализ ясагач, хат авторы «Бастыру өчен дип язмагыз сез, иптәш Усманов, мәгънә булсын дип языгыз. Шуннан аларның ничек басылуын үзегез дә сизми калырсыз (...)» дигән киңәш биргән. Күрәсең, беренче хаттагы «яза аласыз»дан яхшы ук канатланган булганга, мин бу икенче хатны алганчы ук тагын нәрсәләрдер җибәргәнмен. Һәрхәлдә, шул ук елның 29 гыйнварында язылган өченче җавап күпкә кырысрак иде инде. Кимчелекләр төгәлрәк күрсәтелеп, боларның да «кәрзингә» төшәчәгенә ачык ишарә ителгән.

Ләкин барыбер бу хатлар минем өчен сүзнең чын мәгънәсендәге күңелле, төп сорауларыма уңай җавап китергән сөенечле хәбәрчеләр иде. Аларда «тел белмисең», «дөрес язмыйсың» кебек бер сүз дә юк!

Димәк, икеләнмичә университет имтиханына керергә мөмкин икән.

Шулай дәртләнеп, бәлки, апрельдән үк аз түләнә торган эштән китәргәдер, берәр шабашкага тотынырга, ягъни юлга һәм Казанда ике-өч ай тыныч яшәрлек акча эшләргәдер дип уйланып йөргәндә, тагын бер хат килеп төште. Шул ук 1958 елның 25 мартында язылган тулы бер бит чамасы мәктүп. «Чаян» журналының әдәби бүлек мөдире Ш.Галиев имзасы куелган, димәк (антологиядән белүемчә), Шәүкәт Галиев дигән билгеле шагыйрь җибәргән хат! Ул болай башлана: «Аяз Гыйләҗев миңа сезнең шигырьләрне биргән иде. Мин аларны кызыксынып укыдым. Безгә килә торган күпсанлы әйберләр арасында, минемчә, сезнең әйберләрегез аерылып тора. Мин лирик шигырьлә-

Аяз Гыйләҗев. 1958



регез турында әйтәм». Шуннан соң автор кайбер мисалларга туктала. Мәсәлән, «Балалыгым калды еракларда, җитмәс инде аннан хат-хәбәр» яисә «Түгәрәк ай сөтле нурын сибеп» кебек «шигырьчә образлы әйтелгән» юлларны билгеләп, «Мин сезгә Казан белән даими элемтәдә булырга тәкъдим итәр идем», — дигән. Моннан соң, калган шигырьләрдәге уңышсызрак урыннар күрсәтелгәч, хат болай тәмамлана: «Үзегез турында киңрәк языгыз әле! Кыскасы, Сезгә язарга, язарга тәкъдим итәсе килә. Тагын да матуррак әйберләрегезне укырбыз дигән өмет белән...»

Икенче көнне үк казна эшеннән киттем. Андрей Ермоленко дигән үзем шикелле үк теләгенә җитеп бетмәгән бер әшнәм белән яңа йорт салырга җыенучы берәүгә яллашып, балчык изрәтеп саман кирпечләре суга башладык...

1958 елның 15 июлендә төнлә Казанга килеп төшкәч, вокзалның көтү залында йокы туйдырып алгач, иртәнге якта Бауман урамына барып чыктым. Менә 19нчы йорт. Минем «экзаменаторларым» утыра торган йорт! Тик мин кереп тормадым ул көнне: кунакханәгә урнашасы бар иде әле. Кыенлыклар белән булса да (прописка), минем өчен исеме символик кыйммәткә ия «Казан» кунакханәсенә урнаштым, ниһаять.

Иртәгесен, университетка документлар илтергә барышлый, тагын әлеге соры йорт алдына килеп чыктым. Сораша-сораша икенче каттагы бер бүлмәнең ишеген ачуга, күзләремә ышанмагандай, артка чигенә яздым: түрдәге бер өстәл артында «Чаян» журналы тышлыгында була торган символик рәсемгә охшаган күзлекле бер ябык кына егет утыра иде. Бүрек кадәрле чәчләре генә димәсәң... Аның уң ягындагы өстәл янында аграк чырайлы тагын бер күзлеклесе...»Әллә «Чаян»ның рәсемен болардан алып ясаганнармы?» дигән шаян уй килде башыма. Тәрәзә янында утыручы өченчесе генә күзлексез иде бугай... Бусаганы атлап, Аяз Гыйләҗевне эзләвемне, үземнең кемлегемне дә әйткәч, бүрек кадәрле чәчле, кечкенә буйлы егет җәһәт сикереп торды, бүлмәнең уртасына ук килеп күрешеп, башкалар белән дә мине таныштыра башлады. Икенче күзлеклесе Шәүкәт Галиев булып чыкты, күзлексезе исә Газиз Мөхәммәтшин дигән кеше икән...

Сәгать ярым чамасы сөйләшеп утырдык. Дөресрәге, аларның бихисап сорауларына җавап бирә бару булды минем эшем. Университетка укырга керү теләге белән килүемне белгәч, өчәүләшеп хупладылар бу ниятемне. «Татар бүлегенең башлыгы Хатип Госман минем якын дустым ул!» — дип куйды А.Гыйләҗев. (Соңрак, имтиханнар вакытында, кырыс чырайлы, олы яшьтәге вәкарьле Хатип Госманны да күргәч, алар арасындагы дуслыкның «сере» хакында да уйладым...)

Университетка документлар илтәсемне әйтеп кузгала башлагач, Аяз мине баскычка кадәр озата барды: «Тартынмыйча килгәләп тор, үзеңне ялгыз сизмә, киңәш-мазар да кирәк булуы бар», — дип озатып калды.

Аяз Гыйләҗев белән

Шәүкәт Галиев.

1958

Документларны тапшыргач, Гоголь урамындагы тулай торакка урнаштым. Имтиханнарга кадәрге бер айга якын вакытым Казан белән, аның музейлары, зиратлары белән танышуга китте. Һәр дүрт-биш көн саен диярлек «Чаян»дагы танышларым янына да кергәли идем. Сынаулар уңышлы тәмамланып, университетка кабул ителгәч, сөенче сорарга теләгән төсле, иң элек алар янына килдем. Кулны кыса-кыса котлагач, Аязның беренче сүзе: «Ата-анаңа хәбәр иттеңме?» — дигән сорау булды...

Әмма ләкин бер яхшыга бер яманы туры килә дигәндәй, укулар башланып, өч-дүрт көн узуга, миңа тулай торактан китәргә дигән фәрманны җиткерделәр. Тәмам аптырап калдым, хәтта коелып төштем: туган-тумачалардан, сыналган танышлардан беркем дә булмаган җирдә кая барырга?! Хәлемне курсташ егетләргә сөйләсәм, алар, уңайсызланып, күзләрен читкә бордылар, укытучылар да хәлемне аңлап баш изәүдән ары узмадылар. Кемнеңдер киңәше белән хуҗалык эшләре буенча проректор янына кердем. Татар кешесе, хәлеңне аңлар, дигәннәр иде. Ә ул, Закиров фамилияле иде бугай, сүзне бик кыска тотты: «У вас родители живы, у нас много сирот. Так что немедленно освобождайте место!» Эшләр идем, дворник булыр идем, дип әйтеп кара-

вымны тыңлап та тормады...

Шулай, аптыраган килеш, «Чаян» редакциясенә бара идем, урамда, «Татарстан» кинотеатры тирәсендә, Аяз үзе очрады. Кәефсез кыяфәтемне күрүгә ул:

— Нәрсә сөмсерең коелган, балтаң суга төштеме әллә? — дип сорады.

Сөйләп бирдем барысын да, юату сүзләре әйтер дип өметләндем. Ләкин ул:

— Бик әйбәт булган! — диде мине үчекләгән төсле көр тавыш белән һәм тагын да кабатлап куйды. — Бик әйбәт! Бу вариант синең файдага гына, парин. Барма син общежитиега. Төкер аңа!

Минем «кайда яшәргә соң?» дигән соравыма каршы ул тагын да көррәк тавыш белән:

— Кайда, кайда, — дип, мине үчекләп алды да, — тап берәр фатир! — диде әмер биргән кебек. — Ничек түләргәме? Аның кадәрле генә акча эшләрсең әле. Ничекме? Мин үзем табам сиңа эшне. Каләмең бар бит — язарсың. Ярар, юкка башыңны ватма, фатирга урнаш та кил минем янга. Тик кара аны, ялгыз хатын-кызларга, бигрәк тә яшьрәк марҗаларга керәсе булма! Берәр әби-карчыкны табарга тырыш. — Минем һаман икеләнеп торуымны күргәч, ул тагын тулай торак темасына кайтты: — Общежитие әйбәт нәрсә түгел ул, парин. Анда башкаларга ярашып яшәргә туры киләчәк. Берсе йоклар, икенчесе җырлар, өченчесе кәрт сугар. Чиратлашып бер-берегезне сыйларга, эчәргә туры киләчәк. Җүнләп уку да, рәтләп эшләү дә булмаячак ул общежитиеда! Әйбәт фатирга урнашсаң, үзеңә-үзең баш, үзең хуҗа булып яшәячәксең. Син бит инде унсигез яшьлек малай-шалай түгел хәзер!

Тулай торак һәм коммуналь фатир шартларына дан җырлаган кинофильмнарны шактый карап үскән кеше буларак... бу сүзләрнең дөреслегенә бик үк ышанып җитмәсәм дә, күңелгә бераз җылы йөгергән кебек булды. Рус-татар бүлегенә кергән Римнур Салихов (хәзер Алабуга педагогия институты профессоры) белән өч-дүрт көн эзләнә торгач, ниһаять, бер фатир кисәге таптык. Суконныйдагы Ново-Песочная дигән тыкрыкта. Хуҗалар арлы-бирле йөри торган коридор сыман кечкенә «бүлмә-

нең» ике ягына ике тар караватт китереп куйдык, араларыбыз адым ярым чамасы булыр. Дөрес, фатир эзләү процессында моннан да аламарак шартларны күрергә туры килгән иде.

Мәсьәлә шулай хәл ителгәч, Аяз янына кереп чыгарга булдым. Хуҗаның тимер юлда йөк бушатучы икәнлеген, өйдә утыручы карчыгының да еш кына борыны кызарып йөрүен белгәч, Аяз кырт кистереп әйтте:

— Тәкъдим иткән аракыларын эчәсе булма! Күршеңә дә әйт. Бер кат бурычлыга әйләнсәң... Хәзер сиңа беренче эшне бирәм...

«Эш» дигәне мин көткәннән «чак кына» башкарак булып чыкты. Бурычым «Чаян» редакциясенә хезмәт иярәреннән килгән шикаять-жалу ише хатларда күрсәтелгән адреслар буенча йөреп, хат авторының чынлыкта булу-булмавын, хатның кем өстеннән, ни өчен язылуын ачыклауга кайтып кала икән. Конфликтның сәбәбен белеп, берәр белешмә язу да кирә иде минем бурычка. Әгәр жалу хаты журналда бастырылырга лаек булса, аның телен, стилен сипләргә дә кирәк булачак икән.

Беренче сәфәрем, минемчә, уңышлы булып чыкты кебек иде. Мин барып җиткәнче үк күршеләр татулашып өлгергәннәр икән. Хатны кире бирүне яки ертып ташлауны сорадылар. Җәнҗалны үзем бетергән кебек канатланып кайттым. Тик Аяз ни өчендер сөер генә елмайды:

— Мондыена гонорар каралмаган шул. Ярар, бу хатны тикшереп кайт әле...

Икенче сәфәрем катлаулырак булып чыкты. «Чаян» кешесе килүдән коммуналь фатирда торучы ике күршенең үзара нәфрәтләре яңадан дөрләп кабынды. Конфликтның башын, сәбәпләрен мин генә түгел, үзләре дә онытканнар икән. Язган «белешмәм» дә буталганны бутау гына булып чыкты. Аны ике-өч мәртәбә күчереп язарга туры килде. Аяз аркылы-торкылы сызгалап чыккач, әлбәттә. Өченче, дүртенче хатлар белән дә шулай ук диярлек. Барып, очрашып, сөйләшеп кайтуларга караганда белешмә кисәген язу, хатларны шомарту күпкә кыенрак булып тоелды. Аларның кайберләрен игә китергәнче чиләнеп бетә идем. Ә Аяз сыза да ташлый, тырт-пырт килеп мы-

гырданырга тотына. «Каләмең бар, язарсың» дигән сүзләренә үкенмиме икән дип уйлап куям. Исемә Максим Горькийның проза язуга караганда шигырь язу җиңелрәк дигән бер фикерен дә төшердем. Ак тышлы бер калын китаптан укыган идем. Моны Аязга да әйттем. Ул да яхшы язылган прозаның чын поэзия икәнлеге, моңа исә бик озак өйрәнергә кирәклеге хакында дәртләнеп сөйләргә тотынды. Кыскасы, кешегә ияреп, халык җырларына охшатып шигъри нәрсәләр сызгалауга караганда, проза белән җүнлерәк әйбер язуның күпкә кыен икәнлеген аңлый башладым.

Бу нәтиҗә минем беренче курста укып йөргәндә ирешкән беренче казанышым, иң файдалы сабагым иде бугай...

Һәрхәлдә, хатлар «чакырган» адреслар буенча шактый гиздем Казан урамнарын. Җәнҗалларның күбесе ике-өч кенә гаилә торган коммуналь фатирларда, шундагы кешеләр арасында туа икән. Күп фатирлы, мәсәлән, ун-унбиш яки аннан да күбрәк хуҗалар яши торганнарында исә конфликт, гадәттә, шундагы коллектив белән ЖКО, ягъни коммуналь-хуҗалык торак идарәләре арасында чыга икән. Уртак кухнялы, бер бәдрәфле, өч-дүрт унитазлы, түшәмнәреннән, стеналарыннан комы коелып тора торган черек идәнле озын коридор, һәрберсе үзенчә «хуш искә» ия таш йортлар да, агач бараклар да шактый мул икән бу Казанда. Аларның ярлы, шыксыз эчке чынбарлыгы белән бәйрәм саен диярлек аннан-моннан акшарланып куела торган тышкы кыяфәтләре арасында никадәрле аерма! Күп нәрсәгә күз ачылды...

Монысы сабакның икенчесе һәм зуррагы иде.

Беркөнне бүлмәдә Аяз белән икәү генә калгач, җаен китереп, әлеге күңелсез күзәтүләрем, «социалистик ил өчен ят булган» күренешләрнең күп очравы хакында әйттем.

— Их, парин, — диде әңгәмәдәшем, тирән көрсенеп. — Әле күп нәрсәләрне беләсе, аңлыйсы бар икән сиңа! — Аннары тавышын баса төшеп, пышылдап кына дәвам итте: — Бездә бит, беләсең килсә, социализмның «с» хәрефе дә юк!.. Тик моның турында әйтергә генә ярамый... Монда бит стеналар да ишетә... — Үзе телефонга да ишарәләп, аны этебрәк куйды. — Аннары өч кешенең башы кушылган җирдә телеңне

тый. Бигрәк тә синең өчен шулай кирәгрәк... Мин сиңа хәзер бернәрсә дә әйтмәдем, аңладыңмы?..

Бусы сабакның өченчесе һәм мәгънәлесе, күп уйландырганы булды. (Нәкъ шундый ук сүзләрне бераз соңрак миңа университет укытучысы Үзбәк абый Байчура да әйткән иде.) Әлеге әңгәмә вакытында исә мин Аяз Гыйләҗевнең күптән түгел генә лагерьларда утырып кайткан, көч-хәлгә яңадан аякларына баса гына башлаган кеше икәнлеген белми идем...

Бераз шулай эшләштергәләп йөргәч, Аяз мине «Татарстан яшьләре»нең комсомол тормышы бүлеге мөдире Мирхәт Хөснимәрданов белән таныштырды. Ул да (Аяз киңәше беләндер, күрәсең) редакциягә килгән хатларны бирә башлады. Ул, Аяздан үзгә буларак, тырт-пырт сызгаламый, мин язганнарны елмайган килеш әкрен генә, «болай әйбәтрәктер» дип, үзе төзәтеп куя, киңәшләрен бирә.

Бермәлне, стипендия эреп бетеп, гонорар-фәләннең килеп җитмәгән чагында, Аяздан бурычка акча сорап торырга булдым. Ул элек: «Нәрсәң яна?» — дип, сәбәбен сорады. Гадәти акча беткәнлеген белгәч: «Гафу ит, күңелеңә авыр алма, мин бурычка акча бирмим. Үзем дә сорамыйм. Син дә өйрәнмә!» — диде.

Бусы да бер сабак булды. Өйдән акча соратмаска вәгъдәләр итеп киткәнгә (әти авыру, энеләр яшь булганга), кирәге әллә ни булмаган бер күн пәлтәм бар иде (студент өчен артык зур байлык!), шуны сатып кризистан чыктым. Үзем исә ул чакта Аязның да гаиләсе, яшь баласы белән фатир яллап торуын, айны-айга көч-хәлгә генә ялгап яшәвен белү түгел, уйлап та карамаган идем. Шулай да кулны тиен-мазар «җылыткан» саен, булуы ихтимал «кара көн» турында да алдан ук уйларга өйрәнә башладым.

Икенче курска күчкәндә фатирны алыштырырга туры килде. Тулай торакка эләгү бәхетенә ирешкән элекке күршем «урынын» шул елны укуын тәмамлап, университет китапханәсенә эшкә калдырылган яшь совет белгече Альберт Фәтхи алды. Икәү бергә Казан урамнарында шактый киләп саргач, бер әйбәт гаиләгә фатирга кердек. Үзебезгә бер аерым бүлмә! Уку залында интекмичә өйдә дә эшләргә, кирәк икән, төннәр буе

утырырга мөмкин. Чәй дә кайнатып, тегене-моны да җылытып ашарга рөхсәт. Кыскасы, Хәят апа белән Хатип абыйларда яшәгән ике ел дәвамында ял һәм бәйрәм көннәрендә дә рәхәтләнеп эшләргә шартлар бар иде.

Шул елны, Аяз Гыйләҗевнең үз катнашы булмаса да, аның исеме һәм үрнәге тәэсирендә, минем өчен тагын бер мөмкинлек барлыкка килде. Элек китапханәнең кульъязмалар бүлегендә эшләгән чакта беркадәр якыннан танышкан, Альберт килгәч, укыту эшләренә факультетка күчкән Мостафа ага Ногман беркөнне тормыш хәлләрем, матди мөмкинлекләрем хакында тәфсилләбрәк сораша башлады. Мәсьәләнең Аяз Гыйләҗев ярдәмендә шактый уңай хәл кылынуын, үземнең язу-сызу эшенә дә өйрәнә башлавымны әйткәч, ул бераз уйланып утырды: «Карале, Аяз әйбәт киңәш биргән бит», — диде. Аннары иртәгә фәлән вакытта Матбугат йортына килеп, икенче катта көтеп торырга кушты: «Мин дә берәү белән таныштырырмын. Аларга да, үзеңә дә файдалырак булыр».

Мостафа ага таныштырасы кеше китап нәшриятының яшьләр һәм балалар әдәбияты редакциясе мөдире Кыям абый Миңлебаев булып чыкты. Таныштырганнан соң, төрки телләрнең «берничәсен белүем» хакында да әйтелгәч, бүлек мөдире киштәдән бер зур папка алып бирде. Кыргызча әкиятләрнең татарчага тәрҗемәсе икән. Оригинал белән чагыштырып чыгарга кирәклеген әйтте. Шактый вак-төяк төгәлсезлекләрне таптым. Бигрәк тә кыргызча кеше исемнәренең, махсус сүзләрнең бирелешендә. Икенче юлы казакъ хикәяләренең тәрҗемәләрендә дә вак-төяк төгәлсезлекләр, хаталар таптым. Шуларның берсе, мәсәлән, казакъларда печәнне белдергән «чөп» сүзен татарча аңлап, абзарга печән ташыйсы урынга аннан чүп-чар чыгаруга кайтарып калдырудан, ягъни гамәлнең киресен әйтүдән гыйбарәт иде. Кыямның шаркылдап көлүен хәтерлим. Билгеле, китап нәшриятында гонорар ягы да әйбәтрәк, эшләре дә күңеллерәк иде. Шуңадыр, күрәсең, Аяз янына сирәгрәк йөри башлаганмын шикелле.

— Нәрсә, парин, — диде ул бер очракта, — акчаны үзең суга башладыңмы? Әллә берәр марҗага йортка кердеңме?

Мин укуларның авырая төшүе, «Шура» журналын өйрәнә башлавым һәм китап нәшриятыннан да эшләр алуымны әйтеп акланырга тотынган идем, ул көлеп җибәрде:
— Менә соңгысы бик әйбәт. Үз аякларыңа баса башлаган икәнсең. Ярар... Син «Яшь ленинчы»га да кергәлә әле, андагы егетләргә әйтеп куйдым инде.
Пионер газетасына фәнни-популяр темаларга вак-төяк парчалар язышкалау аспирантлык елларына кадәр дәвам итте. К.Миңлебаевтан эш алгалау да туктамады. Тәрҗемәләр белән «экспериментлардан» соң ул миңа башлап язучы яшь авторларның әйберләрен дә бирә башлады. Шулай итеп, үзем җүнләп яза белмәгән килеш, башкаларны тәнкыйтьләргә, «өйрәтергә» тотындым. Тора-бара кешене өйрәтү процессында үзем дә әкренләп өйрәнә баруымны тойдым. Бермәлне мөдир белән конфликт кисәге дә чыга язды. Рецензия язарга дип, А.Гыйләҗевнең «Дүртәү» исемле повестен тоттырды. Бер кичтә диярлек укып чыктым, кырыс реализмы, ихласлыгы белән бик ошады. Шулай яздым да. Редакция мөдире рецензиямне йөзләрен чыта-чыта укып чыкты да: «Бармый болай, бер кимчелек тә күрсәтмәгәнсең, алай ук шәп нәрсә түгел ул, гонорарны объектив рецензиягә генә язам», — дип, мин язганнарны өстәлгә ташлады. Ләкин үзе, араны өзәргә теләмәгәндәй, икенче папканы бирде: «Монысына теләсәң нәрсә яз. Барыбер басылачак».
Ул вакытта мин 1955 елның августына кадәр Казакъстанда «ташчы, бетон коючы, бригадир һәм десятник профессияләрен» үзләштереп кайткан А.Гыйләҗевнең моңарчы Казанда ике-өч ел эшкә урнаша алмый, язган-сызганнарының кат-кат «иләктән» уздырылып йөргәнлеген белми идем, билгеле. (Аның хакында Аязның үзенең дә нәрсә дә булса сөйләгәнен хәтерләмим.) Бары күп еллар узгач кына, Иделдә көймәдә балык тотып, дөресрәге, балык чиртми утырган бер чакта, мин аның «Дүртәү» өчен гонорар ала алмый калуымны көлеп искә төшердем.
— Шулаймы? — диде Аяз да көлеп. — Сиңа да эләккән икән! Ул «Дүртәү» генә түгел, «Берәү» өчен үзем дә шактый вакыт сохари кимердем...
Шулай итеп, җыеп әйткәндә, Аяз Гыйләҗев киңәше белән тәртипкә салган эшләү

һәм яшәү шартларым үземә елдан-ел күбрәк ошый башлады. Өченче курска күчкәндә, деканатка чакырып, сөенечле хәбәр әйтергә булдылар: тулай торакта буш урын бар, теләсәң, хәзер үк юллама алырга мөмкин.

Мин теләмәдем. Узган ике ел эчендә, әлеге мин аптырап калган чакта, Аяз Гыйләҗев әйткән сүзләрнең, ул биргән киңәшләрнең дөреслегенә тулысынча ышанып беткән идем инде хәзер.

Үземә үзем баш, үземә үзем хуҗа булып яшәүдән тыш, бу студентлык елларында мин рәхәтләнеп эшләргә, бертуктаусыз эшләргә өйрәндем. Башта кирәге булганга, матди ихтыяҗдан чыгып, әлбәттә, эшләргә тырыштым, тора-бара исә эшнең, эшләүнең тәмен, ләззәтен табып эшләдем. Ял көннәрендә дә, бәйрәмнәрдә дә эшли идем. Эшләү гадәтемә әверелгән иде. (Хәзер дә ял, бәйрәм көннәрендә эш башларга яратам. Фикер бүленми чөнки. Бу истәлекләрне дә беренче гыйнвар көнне иртәнге сигездә кәгазьгә төшерә башладым: узган елның беренче көнендә хәйриячеләребез хакындагы мәкаләмә тотынган идем; өченче елны исә, сырхауханәдә XXI гасырны каршылап яткан килеш, Гаспралы турында язарга туры килгән иде...)

Студентлык елларында ук бер-ике китапчыгымның нигезләре салынуы, мәкаләләремнең кайберләре Мәскәүдә үк басылып чыгуы да шулай нормаль эш шартларын булдыруның нәтиҗәсе дип исәплим. Киштәдә торган дистәгә якын китапларым белән йөзләгән мәкаләләрем барлыкка килүдә дә Аяз биргән киңәшләрнең әһәмиятен, өлешен тоям, күрәм.

Әйе, соңрак бер-беребезне хөрмәтләп «әкә» дип дәшә торган Аяз әкәнең үземә мәгънәви остаз булганлыгын танып, аның якты истәлеге алдында бүген башымны иям.

Без соңрак, 60 нчы елларның ахырларына таба, Аяз әкә белән ныграк якынлаштык. Утырдаш та булдык, кунакларга да йөрештек, бергә-бергә балык та каптыргаладык. Бер-ике ел дәвамында ул мине үзләре яныннан берәр дача йорты сатып алырга да димләп йөрде, бурычка акча биреп торырга әзерлеген дә әйткәли иде. Ләкин никтер

туры килмәде. Дөресен әйткәндә, бу дача дигәннәре дә миңа общежитиеләрне хәтерләтә төшә иде...

Аның шадра кәгазь (наждак кәгазе) кебегрәк кытыршы холкы, пычак шикелле үткен теле, минем исә тиз кабынып китә торган дуамал, кырыс характерым да бу якынлыкка, табигый урнашкан дуслыкка зарар итә алмады шикелле. Дөрес, моңа икебезнең дә үзара билгеле бер дистанция саклавыбыз да сәбәп булгандыр, ахрысы. Мин үзем исә аңлы рәвештә шулай эшләргә тырыштым — кайчандыр аның үземә олырак туганнарча күрсәткән кайгыртучанлыгын, ярдәмен бервакытта да истән чыгармадым.

Без инде бу елларда күп нәрсәләр хакында ачыктан-ачык сөйләшә идек. Бигрәк тә көймәдә утырган чакларда. Ләкин, ни хикмәттер, әлеге илленче еллар ахырындагы



хатлашулар, аларның сәбәпләре хакында бернәрсә дә сөйләшмәдек, хәтта аларны искә дә алмадык. (Бары Шәүкәт Галиев кенә ике-өч мәртәбә шигырь язу-язмавым хакында сорашып карады, аннары ул да кул селтәде...)

Аязның үземә — әллә кайлардагы чит-ят берәүгә игътибарлы булуының, Казанга — тарихи Ватанга кайткач, дөрес киңәшләр биреп, кадәри хәл гамәли ярдәм дә күрсәтүенең чын сәбәпләрен, серен соңрак кына аңладым мин. Әйтик, Ибраһим Салахов белән Якуб Зәнкиев әсәрләрен эшкәртүдә, дөньяга чыгаруда Аяз Гыйләҗев күрсәткән фидакарьләрчә эзлекле ярдәмнең мисалында ачылды ул сер. Аның илле сигезенче елда ук, узып барышлый гына төшереп калдырган фикер шикелле әйтеп куйган сүзләре исемә төшкәләп торды: «Беләсең килсә, Башкортстанда бездәгегә караганда татарлар күбрәк яши. Башка җирләрдә дә... Без шулай бүлгәләнгән, таратылган, көчсезләнгән халык инде...» Димәк, аның чит җирләрдәге татар кешеләренә һәрдаим ярдәм кулы сузуы ул вөҗданы кушкан, иманыннан килә торган гамәле булган икән!

Әйе, Аяз Гыйләҗев — ул бүгенге Татарстан кысаларын гел шулай мәңгелектән килгән хәл дип ышанып, «чын татар ул Казан артында яши» дип раслаган, наданлыкларына хөсетлек сыйфатларын да өстәп исәрләнгән, «киткән-беткән, нигә кайткан?» ише ахмаклык, ялган патриотлык чирләре белән агуланган бәндәләрдән аермалы буларак — күпкә киң карашлы, күпкә тирән уйлаучы, бик күпләрдән өстен торучы, шунысы белән берәүләргә ошаган, икенчеләренең ачуын кабарткан гаҗәеп катлаулы, каршылыклы зат иде. Шул ук вакытта үз халкының бүгенге язмышын, реаль мөмкинлекләрен дөрес аңлаган, аның серле, хәтта аңлаешсызрак киләчәге өчен дә чын-чынлап кайгырып, көенеп яшәгән, алда аны нинди реаль хәвеф-хәтәрләр көтәсен дә сизеп-тоеп борчылган моңлы шәхес тә иде ул.

Беренчеләрдән диярлек булып, үзгәртеп коруларга кадәр үк, Төркиягә сәяхәт ясап кайткач, мин аңардан «нәрсәләр күрдең, нинди нәтиҗәләр чыгардың?» дигән сымanрак итеп сорадым. Ул образлы гына итеп, кыскача җавап бирде:

— Төркиядәге кебек шартларның бездә, безнең гомердә булмаячагын белеп көен-

дем... Чыр-чу килешеп уйнап йөргән бала-чагаларга, ичмасам, сез үз телегезне оныт-
маячаксыз дип, башларыннан сыйпап сөендем. Хәтта елап та алдым...

Аяз әкәнең мине гаҗәпләндергән, уйландырган тагын бер сыйфаты, дөресрәге, гамәлләре бар иде. Ул кайчакларын тора-тора да, озын-озын хатлар яза башлый иде. Сизеп торам, үзенә дә күчермәләрен калдырып, җыеп бара ул. Бу гамәлне мин башта

Ибраһим Салахов (уңда) белән Аяз Гыйләҗевнең сөйләшер сүзләре бетәрлек түгел. Язмышлар уртаклыгында яшь аермасы да киртә түгел.

1987

телеграф, телефон чорында үлеп бара торган, хәтта бөтенләй диярлек үлеп бетә язган кызыклы язма жанрларның берсен — әдәби хатлар жанрын тергезергә омтылуның бер романтик галәмәтедер дип уйлаган идем. Ләкин минем хөкемем берьяклырак булган икән. Дус-иш арасында гел акча эшләргә ярата дип исәпләнә торган кешенең 5–6 шар битле, гонорар түгел, гап-гади рәхмәт тә китерми торган хатларны дистәләп-дистәләп язуының чын сәбәбен алай гына аңлату дөрес түгел икән. Чынлыкта, ул хосусый хатлар ярдәмендә кайбер әдәби жанрларга тиз генә кереп бетми торган, мәгәр үзенең күңелен гел тырнап газаплаган борчулы уй-хыялларын, хәсрәтле фикерләрен кемгәдер тизрәк әйтергә, ичмасам, кәгазьгә булса да теркәп калдырырга ашыгуның, фикри ашкынуның, дөресрәге, түзмичә тишеп чыккан «эчке чирнең» нәтиҗәсе икән! Димәк, ул хатларга карата да игътибарлы булырга кирәк икән безгә.

Ашыгу дигәч тә, бу хакта да безнең арада бер кызыклы сөйләшү, аннары аңлашу булган иде. Равил Фәйзуллинның күтәрелеп, танылып килгән чагы. Аның турында иң мактаулы сүзләрне Аяз әйтеп йөрде. Бер мәкалә язарга да җыенды ул. Салават күперенең бер башында — Тукай, икенче башында Фәйзулланы күрәм, диде. Күп тә узмый, «артык азынып киткән малайны» акылга утыртырга теләүчеләр дә табылды. Бер сүз белән әйткәндә, искедән-иске «өр-яңа» интрига иде. Аяз Гыйләҗевнең дә фикере үзгәргән. Әйбәтләп бер тәнкыйть итәргә җыенды. Интрига башында кемнәр торуын, аның сәбәбе нәрсәдә икәнлеген бераз шәйләгәнгә, бер очрашканда мин бу бәхәскә

кереп тормаска киңәш иттем. «Юк, — диде ул, кызып, — бу — принципиаль мәсьәлә, турыдан ярып әйтәчәкмен әле!» Әйтте дә бугай. Күп тә узмый, әлеге интриганы оештыручыларның берсе калын журналда Р.Фәйзуллин иҗаты хакында гел мактаудан торган бер мәкалә-әдәби портрет бастырып чыгарды. Аны укыган кешедә «Эзәрлекләнә башлаган зур талантның гадел яклаучысы да бар икән!» дигән фикер туачагы күренеп тора иде.

Беркөнне көймәдә кармак салып утырганда, тагын Равил хакында сүз чыкты.

— Уңышлы эшли парин, гел үсеп бара...

Форсаттан файдаланып, мин:

— Исеңдәме, теге вакытта бәхәскә кермәскә дип әйткән идем сиңа, — дидем. — Син тыңламадың. Ә ул, әнә, мәдхияле мәкаләсен бастырып, үзен тарих алдында аклап куйды. Ә син, урыс әйтмешли, на бобах...

— Кармагыңны кара, кармагыңны! — дип кычкырып җибәрде Аяз. — Чиртә бит! Тарт тизрәк... Ах, ычкындырдың!.. Җүнләп балык та каптыра белмәгән килеш утырасың шунда акыл сатып... Зур балык иде, парин, ай-һай, зур иде... Әрәм иттең каһәрне!..

Мин көлдем дә, елап та җибәрердәй булдым.

Тагын тынлык урнашты. Озак кына сүзсез утырдык. Мин аны үчекләмәс өчен читкә генә карап елмая идем. Ул еш кына үзен хәйләкәр итеп күрсәтергә тырышса да, аңарда чын хәйлә-мәкердән бернәрсә дә юк иде, минемчә. Бары тәҗрибә белән туры сүзлелек кенә бар иде. Шуңа күрә үзенә эләккәли дә иде. Шактый вакыттан соң ул үзе сүзгә килде:

— Шулай, татар акылы төштән соң, парин. Акыл җитеп бетми шул безгә...

— Юк, — дидем мин, аны бүлдереп, — сиңа күбрәк сабырлык, түзем җитеп бетми.

— Мондый хикмәткә кайдан өйрәндең соң? — диде ул, киная белән авызын ерып.

— Синең үзеңнән, — дидем. — Исеңдәме, талашкан күршеләрнең хатлары буенча йөргән чакта, син үзең талашучыларның берсенең дә тарафын алма, тыңлап кына утыр, булары тәмам чыгып беткәнче тыңла. Нәтиҗәне өйгә кайткач кына чыгар, дип, үзең

өйрәткән идең бит!.. Кармагыңа кара! Чиртә бит, — дип, бу юлы мин дә кычкырып җибәрдем...

Беренче балыкны кармактан ычкындыруга, аны чуп иттереп үбеп тә алды Аяз. Ул көнне ярыйсы гына тотылды балык. Күпчелеген ул тотты, әлбәттә.

Кайтыр юлга җыеныр алдыннан, балык тотудан канәгать булып, бераз тынычланган Аяз әкә, үзе белән үзе сөйләшкәндәй, адрессыз гына итеп әйтеп куйды:



— Гел үзеңне генә кайгыртырга ярамый бит... Башкаларга карата да юмарт була белергә кирәк! Сүз шуның хакында иде бит...

Юмартлык дигәч, шуны да өстәргә кирәк дип табам: Гыйләҗевләрнең бәйрәм-кунак өчен әзерләгән табыннарының мул, бай булуын аралашкан кешеләрнең һәммәсе дә хәтерлидер, шөт. Аязның кунак чакыруга формаль рәвештә карамаганлыгын күрсәтә торган фактлар шактый. Шуларның берсе үзенең алтмыш еллыгын билгеләгән чакта, Казанда азык-төлек мәсьәләсендә мәгълүм кытлык хөкем сөргән елларда, монда булганнары белән генә чикләнсәң дә, беркем гаеп итми торган заманда булды: ул ике-өч мәртәбә Мәскәүгә барып, төянеп кайткан иде.

Чакырылган кунакларының иркенләп, тәмләп, яратып ашауларын Аяз ихлас күңелдән тели иде. Мул итеп әзерләнгән затлы ризыкларын үзенчә мактый-мактый ашатырга тырыша иде. «Алыгыз, ал, бетә дип уйламагыз, тагын да бар!» — дип кыс-

тый. Шуны раслаган кебек, өлгер Нә-
кыя ханым да табакларга яңа өлеш-
ләр өсти тора. Бераз кызып та алган
хуҗа:

— Уылдыгын да алыгыз, тагын
ачылмаган ун банка бар әле!.. Каз-
дан, каздан башлагыз, майлы дип ку-
рыкмагыз, мае эреп беткән... Хөрмә-
се дә бик эсвижий, кичә генә ящигы
белән алган идек... Карбызы да быел бик уңган икән, чоланга быел егермене тәгәрәтеп
куйдык. Әйдәгез, алыгыз, — дип, шаярту, шыттыру элементларын да кертеп, илгәзәк-
ләнеп кунак сыйлый иде.

Кунак сыйлаудагы илгәзәклек, ихлас иркенлек ул, гомумән, күңел киңлегенең, чын
юмартлыкның табигый дәвамыдыр.

Моңа һәрдаим ирешеп булмаса да, моны һәрвакытта да икърар итәргә кирәк.

«Татарстан яшьләре»

16–18 гыйнвар, 2003

Ак каеннар кочагында



МАНСУР ГЫЙЛӘҖЕВ

Әтием

Биш яшемдә чагында миңа коточкыч төш кергән иде: имеш, минем әтием үлгән, һәм аны җирләргә алып китәләр. Берничә көн дәвамында шул җан өшеткеч төш тәэсирендә аңгыраеп йөрүемне хәтерлим. Ятимлек сагышы нәни йөрәгемне учлап тоткан иде... Утыз алты елдан соң әлеге төш өнгә әверелде...

Бала чагымда әти минем өчен дөньяда иң көчле, иң матур, иң акыллы һәм кодрәтле кеше булып тоела иде. Бүтән балаларның әтиләре минем өчен гадәти бер «абзыйлар» гына... Өстәвенә мин сабый чагымнан ук, әни белән әбидән ишетеп, әтиемнең бөек татар язучысы икәнен һәм бөек әсәрләр иҗат итүен белә идем. Шуңа да әти язу өстәле янына утыруга, безгә кычкырып көләргә дә, фатир буйлап чабып йөрергә дә ярамый иде. Ул вакытта без Воровский урамындагы «хрущевка»ның кечкенә генә ике бүлмәле фатирында яши идек. Минем өчен һәр иртә язу машинкасының тавышы белән башланып китә. Әти таңнан торып ук эшли башлый. Мин хәзер бүтәннәрнең машинкада басуына колак салам, ләкин әти бармаклары кагылып дөньяга килгән ритмны мин ишетә алмам инде. Ул тавышның язмасын тыңлап, шул чагында дөньяга килгән юлларны укып карасаң, хәзер кызыклы һәм гыйбрәтле булыр сыман... Мине иҗат дөньясына чакырган музыка шикелле яңгырый иде машинка тавышы. Чыннан да, әтинең язу машинкасына мөнәсәбәте музыка коралына карата кебек иде — ул аны бик кадерләп саклый, пөхтә тота, хәтта холкын белә һәм

аңардан беркайчан да аерылмый. Безнең гаиләдә соңрак язу машинкасына бәйле йола да пәйда булды. Искәндәр абыйга уналты яшь тулгач, әти аңа Югославиядә ясалган җыйнак кына машинка алып бирде. Шул ук яшьтә мин «Эрика» машинкасына тиендем. Рәшат энекәш тә, уналтысы тулгач, шундый ук бүләккә ия булды.

Минемчә, бу традиция әтинең яшьлегендәге яшерен хыялы белән бәйле иде: беренчедән, ул яза башлаган елларда машинкалы булу зур проблемалар тудырган, бик авырлык белән генә машинкалар сатып ала алган; икенчедән, улларының кайсысы булса да, бәлки, аның язучылык эшен дәвам итәр?..

Безне нәселебезнең борынгы гадәт-йолалары белән таныштыруга да әти зур игътибар бирә иде. Җәй саен без Зәй һәм Сарман районнарындагы авылларыбызга кайтып китәбез. Әти инде андагы якын туганнарга әйтеп куйган: балаларны җәлләп тормагыз, авыл эшләре кушыгыз, ипекәйнең тәмен белсеннәр! Әтинең зирәклегенә тора-бара шаккатам. Без авылда кыр эшләрендә дә катнаштык, яшелчә бакчасында да казындык, печән дә чаптык, утын да кистек, умарталар тирәсендә дә кайнаштык. Авылдагы әшнәләрдән берни белән дә аерылып тормый идек.

Безнең ыруда бала туу уңаеннан агач утырту гадәте дә бар. Аның мәгънәсен дә мин үсә төшкәч кенә аңладым — агач утырту белән син нindидер күренмәс җепләр белән шул җиргә баглы буласың, аны үзеңнеке итеп ярата башлыйсың. Чишмәләрне пакьләндереп тору да безнең нәсел өчен таныш йола. Әтиебез безне дә коеларны, кизләүләрне хөрмәт итәргә өйрәтте. Ә Сабан туе?! Безнең өчен бик тә үзенчәлекле бәйрәм иде ул. Бүтәннәргә Сабан туе күңел ачу, мәҗлес кору, бәйгеләрдә катнашу булса, без исә бәйрәмнәргә тозлы кыяр, помидор тулы агач мичкәләр, кыздырылган көнбагыш тулы капчыклар төялгән арбага утырып барабыз. Сабан туенда бу арба үзенә күрә бер сәүдә үзәгенә әверелә. Хәзер мин шул тозлы помидорларны кабымлык иткән ирләрдән көнләшеп куям. Безнең туганнар шулкадәр тәмле итеп тозлый белә иде аларны! Барысы да үз бакчабыздан... Җитмәсә безнең ише шәһәр малайларының да хезмәте кергән моңа. Янәшәдә генә кыз туганнарыбыз айбагыр сата. Безнең кебек ташбаш

малайларга исә тирә-юньдәге буш шешәләрне җыярга кушалар иде. Миңа бу турыда язу һич тә оят түгел бүген. Аракыдан, сыра яисә лимонадтан шешәләрнең бушавын көтеп кызмача төркемнәр тирәсендә буталу кызык бер маҗара төсле истә калган. Кире кайтканда безнең мичкәләр буш шешәләр белән тулы була... Эшмәкәрлек гадәте безгә, бәлки, шул рәвешле сеңдерелгәндер. Бу исә авыр елларда ничек тә исән калырга тырышуга, хезмәт сөючәнлеккә барып тоташа.

Ыруыбызның бүтәннәрдән үзенчәлекле аерылып торуын: сәләт, йолаларга сыгыну, хезмәт сөючәнлек, пөхтәлек, сүздә тору җәһәтеннән — гел үзебезчә булуын әтиебез һәрвакыт тәкрарлап тора иде. Ул моның белән горурланды, безне дә горурланырга өйрәтте. Бу горурлык хисе аның төп иманы иде.

Ул, кунакчыл кеше буларак, зур мәҗлесләр җыярга хирыс иде. Кунаклар бездә еш булды. Әни табынны бик мул кора, төрле ризыклардан өстәл сыгылып тора иде. Татар мәдәниятенең күренекле кешеләреннән бездә кем генә булмады икән?! Шәриф Хөсәенов, Шәүкәт Галиев, Марсель Сәлимҗанов, Илдар Юзеев, Гариф Ахуновларны мин бала чактан безнең өстәл тирәсендә утырган кыяфәттә хәтерлим. Әти безгә дә табын тирәсендәрәк утырырга куша — олылар сөйләшкән сүзләр колакларына керә торсын дигәндер инде. Чыннан да, мәҗлестә утыру өчен дә үзгә бер сәләт, үзгә бер әдәп кирәк бит. Сүз гадәттә әдәбият-сәнгать, тарих тирәсендә әйләнә иде төсле. Татар халкының үткәненә һәм киләчәгенә бәйле мәсьәләләр дә күтәрелә иде. Андый мәҗлесләр вакытында сеңдерелгән дәресләрне дөньяның бернинди университетларында да алып булмый. Әлбәттә, без биредә тын гына, дәшми генә утырырга тиеш идек. Бу шулай ук бик борынгы мөселман гадәте. Дөньяның мөхтәрәм кешеләре, аксакаллар сүз алганда, яшь-җилкенчәккә аларның һәр фикерен эләктереп калу лязем. Мин бу зарурияатне дә соңыннан аңладым, билгеле. Хәзер үземнең дә кайбер фикерләрне әйтү ихтыяҗы барлыкка килде дә... Тик андый кичәләр кабатланмый икән шул.

Әйе, безне бала чактан ук дәшмәскә һәм үз фикерләребезне сак кына әйтергә

өйрәттеләр. Моның төп сәбәбе без үскән елларга гына түгел, без туганчы булган чорларга барып тоташа. Ул заманнардагы фаҗигаләр турында хәзер укып беләбез. Безнең нәселгә исә аерата нык кагылган әлеге большевистик афәт. Әти ягыннан (әтиемнең бабасы) Сәхабетдин бабай — Сарманның җәмигъ мәчете имам-хатибы — утызынчы елларда Алабуга төрмәсендә атып үтерелгән. Әни ягыннан (әниемнең әтисе) Илһаметдин бабай исә Бөгелмә зинданында кырыгынчы елларда юкка чыга. Бөтен туган-тумачаның диярлек мөлкәте тартып алына. Үз фикерләрен курыкмыйча әйтергә җөрьәт иткән әти исә үзенең иң матур яшьлек елларын Сталин лагерьларында үткәрә. Күрәсең, әти дә, әни дә үз улларын гыйсъянчы итеп — коммунистик лагерьларның киләчәктәге тоткыннары итеп тәрбияләргә теләмәгәннәрдер... Бәхетебезгә күрә, андый заманнар үтте шикелле...

Без бала чактан ук татар театрларындагы бер генә премьераны да калдырмый идек. Жанрына, сыйфатына карамастан, әти безне һәр спектакльгә алып бара иде. Шулай да сиземләү кимәлендә без аларны аңлап карый идек сыман. Аннары бит театрны залдан гына түгел, эчтән дә — баш режиссерның кабинетыннан алып актерларның гримеркасына кадәр — күзәтү мөмкинлегенә дә. Ләкин иң гаҗәбе — әтинең премьералары. Чөнки аларның һәрберсе бәйрәм банкетлары белән төгәлләнә. Бу инде — үзенә күрә театр традициясе. Гадәттә, ул мәҗлесләр йә безнең өйдә, йә дачада үтә. Менә шунда инде спектакльне энәсеннән-җебенә кадәр тикшерү башлана. Безнең өчен кызык та, гыйбрәтле дә — яңа гына актерны сәхнәдә рольдә карадык, хәзер ул безнең өстәл янында гап-гади кеше кебек утыра, әни пешергән пәрәмәчне ашый!

Табигый, без театрны бик тә ярата идек, аның могҗизасы каршында хәзер дә баш иябез. Мең рәхмәт әтиебезгә!



Күп язучылар йөрәк сырхавыннан җәфаланалар. Әтине дә яшьтән үк йөрәге борчый иде. Шуңа да бер табибның киңәше белән ул балыкчы булырга карар кылды. Балыкчылык корты бер җаныңа керсә, бүтән чирләр бер якта торсын. Шуннан Идел буенда җыйнак кына матур дачабыз пәйда булды, әти моторлы көймә сатып алды. Әти балыкчылык шөгыленең фанатигына әверелде, без дә аңардан калышмый башладык. Малай-шалай өчен аннан да илаһи бәхет бармы соң! Иртә таңнан көймәдә Иделнең аулак култыкларына керәсең, якорь саласың да кармакны үзең генә белгән сихер сүзләре белән суга ыргытасың... Гаҗәп, шуннан соңгы елларда әти йөрәгеннән беркайчан да зарланмады.

Вакытның тиз узуына хәйран калырсың. Шагыйрь әйтмешли, менә без дә үсеп җиттек... Һәммәбезнең үз машинкасы бар, тик беребез дә әти юлыннан китмәде. Абыем Искәндәр тарих өлкәсен сайлады (хәзер университетта татар филологиясе һәм тарихы факультеты деканы, профессор), мин архитектура институтын тәмамладым, энебез Рәшат исә медицина институтын тәмамлады. Институттан соң мин Мәскәүдә проектлар институтында эшли башладым. Ләкин бу эш ни иҗади яктан, ни матди яктан күңелемә ятмады, канәгатьләндерми иде. Бәхетемә күрә, бу вакытта мин Мәскәүдә гел әти белән күрешеп тордым. Ул йә язучыларның Переделкинодагы иҗат йортында ике айлап торып китә, йә төрле пленумнарга, съездларга килеп чыга. Мин Мәскәүдә булганга да шулай ешламады микән? Биредә мин бөтенләй үзгә әтине күрдем. Мәскәү язучылары арасында аның дәрәҗәсе зур, түрә халкы да аны хөрмәтли. Сүзе үтә, горур, кайчакта кибарәнә* ... Монда ул татар әдәбиятының, татар милләтенең күренекле вәкиле иде. Шуңа күрә ул һәрвакытта башын югары тотарга тырышкандыр да... Шул чакта минем күңелдә ниндидер үзгәреш булды. Җанымның төпкелендә нәрсәдер ярылып алды сыман. Һәм мин яза башладым.

Мин ашыгып, чырышып, күп итеп яза башладым. Язып бетерү белән, беренче хикәямне әтигә җибәрдем. Берничә көннән соң аңардан җавап та килеп төште: «...повестең шактый уңышлы язылган. Беренче әсәр буларак бик әйбәт! Телең бар, сюжетны

* К и б а р ә н ә — горур.

Искәндәр (сулдан), Рәшат һәм Мансур Гыйләҗевләр Баграждагы йорт ындырында. 1995



сизәсең, матур чагыштырулаларың, образларың бар — тырышып эшләсәң, синнән чын, заманча язучы чыгачак! Бу иң мөһиме! Тик шуны онытма — язу эше бөтен көчне, игътибарны, гомерне таләп итә. Бу повесть синең күңел тавышың гынамы, әллә гомерлеккә атлап керүеңме? Әмма моны әйтү кыен. Минемчә, сиңа язарга кирәк. Бик нык эшләргә!»

Ләкин мине барыннан да элек театр тарта иде. Шуннан, тәвәккәлләп, мин пьесага тотындым. Пьеса язу миңа гаҗәеп ләззәт бирде, һәм мин әдәбиятның нәкъ менә шушы төре белән шөгыльләнергә карар кылдым. Драматургия — үзенчәлекле жанр, аның хикмәтле кануннары, кагыйдәләре бар. Әти минем беренче мөгаллимем иде. Сабаклары аның бик кыска, әмма төп-

ле, шуңа күрә аларны мин үл-
гәнче онытмам. Мәсәлән,
бервакыт диалоглар турында
сүз чыкты. Ике яшь кеше оч-
раша, берсе икенчесеннән со-
рый: «Исемең ничек?» Тege-
се: «Вахит!» — дип җавап би-
рә. Аның исеме чыннан да
шулай. Әмма бу сәхнә теле
түгел.

Ул йә сораучыны алдарга, йә сүгенергә, йә сорауга сорау белән җавап бирергә тиеш. Кыскасы, һәр фразаның төбендә конфликт ятуы зарур. Әлбәттә, әти тарафыннан мондый сабаклар күп булды. Аның тагын бер киңәше нык истә калган. «Чын драматург буласың килсә, сиңа бик тиз өйләнергә кирәк, — диде ул. — Гаилә корылуга ук котылгысыз конфликт та пәйда була, ә ул драматургка һава кебек кирәк».

Бу киңәшен тыңлаганда, мин аны, әлбәттә, бераз хәйләле дип уйладым. Һәрбер ата кебек, аның мине тизрәк өйләндерәсе, оныкларын сөясе килә иде. Оныклары күп булуын теләде ул. Әмма өйләнеп яши башлагач, драматургия өлкәсендә дә аның хаклы икәненә ышандым.

Шулай итеп мин акрын гына драматургия өлкәсенә үтеп кердем. Менә бервакыт әти миңа әйтте: «Син яшь, синең пьесаларың миңа бик үк аңлашылып бетми. Бар, син хәзер Ризван Хәмидтән өйрән».

Монысы инде мәктәпнең бүтән төрлесе иде.

Драматургия дигән катлаулы дөньяга мин шулай әтинең җиңел кулы белән кереп киттем.

Ул яһүдләргә бик хөрмәт белән карый, безне дә алардан гыйбрәт алырга чакыра иде. Яһүдләр арасында аның шактый ук дуслары һәм танышлары бар иде. Әти яһүд-

ләрнең табигый зирәклеген, хезмәт сөючәнлеген, аеклыгын, белемгә омтылуларын

Сурәттә калган якты мизгел. Гыйләҗевләр гаиләсе ял иткәндә. 1974



хөрмәт итте. Иң мөһиме, аларның бер-берсенә ярдәм итүенә, бердәмлегенә сокланды. Әлбәттә, моның төбендә үз халкының язмышы өчен әрнү хисе ята иде. Татарның бөтен фаҗигасе аның таркаулыгында булуын ул бик яхшы аңлады. Бердәмлек идеясен бөтен халыкка җиткерә алмавына әти бик газаплана иде.

Әти турында язам, ә күңелемне бер уй бимазалый: аны сөттән ак, судан пакь итеп күрсәтергә тырышмыйммы соң мин? Билгеле, әти һәр язучы кебек катлаулы, каршылыклы кеше булды. Һәркемнең үзенә генә табигый хас сыйфатлар аңарда да бар иде. Еш кына ул хискә дә бирелеп китә, тотнаксыз сүзләр дә ычкындыра... Ләкин аның барлык кимчелекләре милләтебезгә, гаиләсенә, һәм, гомумән, тормышка карата булган мәхәббәте каршында хәзер бик бәләкәй булып тоела.

Мәкерле чир — шикәр чире — әкрен генә аның саулыгын ашады. Тын гына сүнә баруын күзәтүе безгә коточкыч авыр булды. Ул безгә кинәттән әрнү китермәс өчен шулай махсус сүнде сыман... Дөньядан киткәндә, ул, әлбәттә, безнең турыда, нәселенең киләчәге хакында уйлагандыр...

Хәзер миңа бала чагымдагы коточкыч төш бүтән керми инде. Ләкин ул төшне мин йокыдагы улымның ятагы янында искә төшерәм. Кайчагында улым Муса төшендә куркып кычкыра, бимазалана, елап та җибәрә. Мин янәшәдә утырам һәм нинди куркыныч төш күрде икән соң бу нарасый, дип уйлыйм...

Ноябрь—декабрь, 2002

Әби белән бабай киленнәре Эльвира һәм оныклары Зифа, Муса хозурында. 2001



ЯКУБ ЗӘНКИЕВ

Танышу

Беренче тапкыр Аяз Гыйләҗев белән без 1965 елның декабрендә таныштык. Шулчак Татарстаннан килгән язучылар группасын, ягъни Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев, Фатих Хөсни агаларны безнең Хуҗайлан мәктәбенә Төмән обкомы хезмәткәре Изил Бәдретдинович Гарифуллин алып килде. Мәктәптә укытучылар, укучылар белән очрашу үтте. Шул кичәдән соң аларны мин үз йортыма алып кайттым. Рәшидәм Иртештән чыккан акбалыкны пешереп көтеп тора иде. Без чәй янында минем яза башлаган «Беренче орлыклар» дигән китап турында әңгәмә алып бардык. Алар минем бу идеяне барысы да хупладылар. «Безгә Себер якларыннан проза әсәрләрен чыгарырга туры килгәне юк әлегә кадәр», — диделәр. Кулъязма өстендә җентекләп эшләргә куштылар. 1966 елның август аенда Аяз Гыйләҗев, Себер яклары белән ныклап танышырга ниятләп, Хуҗайланга иҗади командировкага килеп чыкты.

Шул көннәрдә Аяз «Җиргә тапшырылган серләр» дигән пьесасын яза иде. Ул әсәр — укытучылар тормышыннан. Без бергәләп печән җыярга, аны кибәнгә салырга бардык. Бүрән исемле күлгә үрдәк ауларга чыктык. Мәктәп атын чәңгелчәк арбага җигеп күбәк чикләвегенә, Татар Вагайга Нурислам Таштимировларга барып, кунак булып кайттык. Иртән көн саен сәгать 6 да эш өстәле артына утыра, ике сәгать яза, аннан сәгать 8 дә Иртешкә төшеп су коена. Көндезләрен күршеләр, картлар — безнең авылдашлар белән очрашуга багышлый. Ул бездә ярты ай торгач, су юлы белән Салехардка сәяхәткә чыгып китте. Аның нәтиҗәсе буларак, соңыннан «Мең чакрым юл» дигән романын язды. Хуҗайланда йөргән бер риваятькә (ырымга) нигезләп, «Өтәч менгән читәнгә» повестен язды. Ул ырымның эчтәлеге болайрак: Аяз үз күзләре белән күреп киткән Хуҗайлан зираты Иртеш яры буена урнашканлыктан, зиратны язгы ташкыннар җимерә, ләхетләрне ача. Аннан кеше скелетлары (башлар, аяклар) айкалып чыга тора.

Якуб Зәнкиев белән Рәшидә ханым Казанда Аяз Гыйләҗевтә кунакта. 1978

Ә зиратны яңа урынга күчерергә шул ырым комачаулый. Имештер, беренче булып яңа

зиратка күмелгән кеше, үзе артыннан бөтен токымын алып китә, ди. Берчак нәселе булмаган Хафиз бабай Речапов, райисполком депутаты буларак, мине чакырып алып әйтте: «Якуб улым, миннән башлагыз яңа зиратны. Сөягемне суга саласым килми. Бу сиңа васыятем», — диде. Ләкин аны җирләгән көндә мин райсовет депутаты буларак сессиядә көнемне үткәрдем. Шуннан файдаланып, Хафиз бабайның ерак бер туган кисәге табылып, кабер казырга баручыларның юлларына аркылы төшеп, берәүне дә яңа зиратка таба уздырмаган. Әнә шундый бер күренешне лейтмотив итеп алып, әлеге «Әтәч менгән читәнгә» дигән повестен язды.

1976 елның 11–16 июнендә без Рәшидәм белән беренче тапкыр Казанда булдык.

Ул, ягъни Аяз Гыйләҗев, минем «Беренче орлыклар» кулъязмасына рецензия ясады. Ничек язарга, нәрсәгә игътибар итәргә кирәклеген өйрәтте. Аны мин үземнең укытучым дип әйтә алам. Казаннан кайткач, кулъязмамның икенче варианты өстендә эшләдем. Ике ел утырдым. Икенче тапкыр Казанда 1978 елның 10–19 маенда булдык. Илдар Юзеев миңа соавторлыкка (ул вакытта Язучылар берлегенең яшь язучыларга консультанты иде) Габделхәй Сабитовны тәкъдим итте. Нәшриятта Шәүкәт Галиев матур әдәбиятның проза бүлеге мөдире иде. Аның янында Сабитов белән без соавторлар буларак договор төзедек. Шул чагында Шәүкәт Галиев әсәрнең исемен яратмады. Әгәр кайчандыр русчага тәрҗемә итәргә туры килсә, сүз бодай һәм арыш турында бара икән дип уйлар кешеләр, диде. Габделхәй белән без «Иртеш буйларында күк томан» дигән исемне әйттек. Шәүкәт Галиев тагын «бу что-то туманно» дип кире какты. Әйдәгез, егетләр, хәзергә «Иртеш таңнары» дип атыйк. Әгәр тагын матуррагын тапсагыз, исемен үзгәртербез, диде. Бу исем, ягъни «Иртеш таңнары» барыбызга да ошады. Кыска да, Себер колоритын да эченә ала, һәм роман шул исем белән яшәп калды.

Габделхәй Сабитовның йөрәге авырта иде. Ул — инвалид. Яхшылап эшкә тотына алмады. Ул хәзер мәрхүм инде. Юкса бик талантлы һәм кешелекле, әйбәт язучы иде. Хәле авырая төшкәч, ул миңа әсәр өстендә эшли алмавын белдереп хат язды. Яңа соавтор эзләвемне үтенгән иде. Бу хәбәрне тагын Илдар Юзеевка ишеттереп хат яз-

дым. Ул, 1985 елда булса кирәк, Аяз Гыйләҗевне димләде. Аязның соавтор буласы килмәде, ә әдәби эшкәртүче булып алынды. Ул тотынгач, эш тиздән юлга да салынды һәм төрле сәбәпләр белән Казан китап нәшриятында 9 ел кулдан-кулга йөргәннән соң, ниһаять, Аяз Гыйләҗев ярдәмендә 1988 елда китап дөнья күрде. Безнең Төмән тирәсендә консультация алырлык кеше юк иде. Берчак Булат Сөләйманов белән сүз булып алды. Ул, мин зур проза китабына тотына алмыйм, бик әкрен эшлим, шигырьләр язам дип җавап бирде.

Башта «Иртеш таңнары» кыскартылып «Казан утлары» журналында басылып чыкты. Аяз бик талантлы язучы, тиз эшли, ул бик күп повестьлары, хикәяләре, романнары, дистәләрчә пьесалары белән популяр. Әсәргә таләпләр бик зур. Аяз «Иртеш таңнары»н да нәшриятта чыгарырлык хәлгә китерде. «Казан утлары» журналында эшләүче, романны басарга хәзерләгән язучы Рашат Низамиев әйткән икән: «Бу әсәрне халык кырылып укыячак», — дип. Чыннан да, бу яңа Себер материалына баетылган әсәр чыккач, бик күп хатлар яуды. Романны укучылар аны яратулары турында СССРның төрле почмакларыннан яздылар. Хатлар миңа да, Аязга да килгәннәр. Сочидан бер ханым Аязга: «Бу әсәр буенча кино чыгарырга кирәк», — дип язган булган. Миңа Ялутор районы Күлавыл укытучысы Наҗия ханым Мадъярова-Минназарова «Бу роман мотивы буенча пьеса язарга кирәк. Аннан да бигрәк кинофильм чыгарырга кирәк иде», — дип язды. Төменнән Сафиуллин Габдрахман һәм аның хатыны «Иртеш таңнары»ның сукырлар өчен Казанда язма пленкада ике китабы чыгуын да (тавышлы китап), үз өйләрендә тыңлауларын белдерделәр. Әлбәттә, тәнкыйть тә җитәрлек булды.

Аязның эчкерсез зур булышлыгы турында мин «Тормыш баскычлары» дигән китапта биографик язмамда белдергән идем инде. Аяз кульязмам өстендә эшләгәндә, мин өстәмә материаллар да җибәрә тордым. Ул алардан да файдаланды. Аяз белән безнең арада хатлашу 1965 елдан башлап хәзергәчә өзлексез дәвам итә. Ягъни 32 ел була инде. Ул хатлар үзләре бер мәктәп. Аяз Гыйләҗев болай караганда кырыс кебек күренсә дә, аның күңеле саф, мәрхәмәтле, фикерләре төпле. Ул вакыйгаларны, илдә

барган үзгәрешләрне алдан анализлап күрә белә, мәсьәләнең асылына төшә.

Аяз Гыйләҗевнең тормыш юлдашы Нәкыя ханым Гыйләҗева да бик уңган хуҗабикә, өч малайның анасы, тырыш, булдыклы, ана теле укытучысы. Ул хәзер пенсиядә. Соңгы елларда Аязның сәламәтлеге бик какшап китте. Шулай да әле кулыннан каләмен төшермәгән. Ул — «Казан утлары» журналының редколлегиясе әгъзасы. Нәкыя ханым иренә бик тә игътибарлы. Аңа хәленнән килгән барлык ярдәмен күрсәтә, дәвалый. Без Рәшидә белән аларда 1976 елның июнь аенда биш көн кунак булдык. Безне бик зурладылар, хөрмәтләделәр. Идел буена дачаларына да алып бардылар. Казан шәһәре белән таныштырдылар. Бер барганыбызда Галиәсгар Камал исемендәге академия театрында Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е бара иде. Безне анда Нәкыя ханым алып барды. «Болар — Себер кунакларыбыз», — дип, беренче рәткә утырттылар. Безнең яныбызда баш режиссер Марсель Сәлимҗанов, министрлар утыралар иде. Яшьләр театрында Т. Миңнуллинның «Алай түгел, болай ул» дигән комедиясен дә карадык. Анда автор үзе дә бар, бик күп язучылар җыелган иде. Казан Кремлендә булдык, Сөембикә манарасын да күрдек, Казан музеена да кердек. Бакый ага Урманче белән Флора ханымның өендә кунакта булдык. Озак кына әңгәмә алып бардык. Бакый ага остаханәсен күрсәтте, сынлы сәнгать шедеврларының ничек тууын күреп хәйран калып йөрдек. Якташыбыз, укытучы Ваһап абыйның кызы Флора Ахметованың тәмле ризыкларын авыз иттек.

Рәшидә белән без берничә тапкыр «Татар халык ашлары йорты»на кереп тә казанлыларның төрле-төрле блюдаларын ашадык. Һәм Рәшидәм гөбәдия, өчпочмак, чәкчәкләрнең рецептларын язып алды, шуннан бирле үзебездә дә пешерә. Аязларда Рәшидә Нәүбәһәр әби белән (ул — Нәкыя ханымның әнисе) Себер бавырсагын пешерделәр. Ул бигрәк тә Аязның кече улы Рәшатка ошады. Малай ул чагында әле детсадка йөри иде, хәзер үзе бала атасы. Олы улы Искәндәр университетта укыта, тарих фәннәре галиме, уртанчылары Мансур — драматург. Аның «Казан егетләре», «Бичура» һ.б. пьесалары Академия театрында озак барды. Үзе төп һөнәре буенча инженер-архитек-

тор. Кече уллары Рәшат медицина институтын тәмамлап предприниматель булып китте.

«Иртеш таңнары» кулъязмасын Аяз беренче кат укып чыккач ук: «Кызартма, нәкъ тормыштагыча яз!» — дигән сабакны бирде. Тыңлаулы укучы булырга тырыштым. «Иртеш таңнары»ның дөнья күрүендә иң зур рольне Аяз Гыйләҗев башкарды. Аңа мең рәхмәт!

Якуб Зәнкиевнең Аяз Гыйләҗевкә 1997 елның 22 октябрендә язган хатыннан өзек.

Ул аны Төмәндә чыга торган «Яңарыш» гәзите өчен язган булган.

Укытып, килештереп алу өчен А.Гыйләҗевкә дә юллаган. (Төзүче искәрмәсе.)



РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА

Аяз Гыйләҗевкә

Акрын гына карлар төшә өскә,

Офыккача тоташ япан кыр...

Учак шәүләләре сикерешә,

Бер кыз көлеп куя кайдадыр.

Ә аксакал карлар хозурында,

Алмаштырып булмый холыкны.

Азатлыкны тою мөмкинмени,

Татымасаң әгәр коллыкны?

Янәшәдә мәш киләләр ишләр,

Кем ул мылтык төзи киеккә?

Балта таушы...

Тигезлиләр тагын —

Үскән кемдер бер баш биеккә.

Татар имән сыман беркатлы ул:

Тамырларга балта тигәндә,

Горурланып аваз бирә көүсә:

Сабы безнеке, — дип, — имәннән!

Акрын гына карлар төшә өскә,

Офыккача тоташ япан кыр.

Монда Тукай ауган, монда — Гаяз

Буран ярып алга баргандыр.

Шагыйрьләрне

Болгар бабайлар ук

Хөрмәт иткән, кулга нан биргән.

«Аның урыны Тәңре янында», — дип,

Муенына элмәк кидергән.

Офыккача тоташ аклык бүген,

Ирексездән җаннарга йога.

Аксакалның эзләренә карыйм,

Һәм кабатлыйм: йөгез, бер дога!..

Тып-тын кала тирә-юнем шулчак,

Күздән тамган яшем ник ачы?

Иренемдә юкса ясин түгел,

Исән үтәсе юл догасы.

1997

Аяз ага хатлары

Без яшәдек инде, алда ни булыр?

Бармы татарга урын анда? Белмим...

А.Гыйләҗев хатыннан, 1990

Төрле төбәкләрдә әледән-әле әдәбият көннәре үткәрү гадәте бар. Кайберләрендә миңа да катнашырга туры килде. Балтач районындагысы аерата истә калган. Бу районны яратам мин. Ачык күңелле, эчкерсез кешеләр яши сыман тоела монда. Кунакчыл булулары шуннандыр. Татар рухы, милләтпәрвәрлек тә аларда бүтәннәрдән көчлерәк төсле. Әлбәттә, балтачларны күккә чөеп, башка төбәкләрне кимсетергә теләмим. Ләкин шунысы хак: кешеләрнең генә түгел, авылларның да үз холкы, үзенчәлеге була, авылдан авылга күчкәндә хәтта сөйләү рәвешенең дә күпмедер үзгәргәнен сизәсең.

Татар көндәлек матбугатын өйләренә алдыручыларның да шактый өлешен балтачлар тәшкил итә. Шушы хәл генә дә күп нәрсә турында сөйли, минемчә.

Шода авылында Мирхәйдәр Фәйзи музей-йорты бар. Әлбәттә, «Әдәбият көннәре»

дип зурлап үткәрелгән чарада (бигрәк яратмыйм әлеге мәгънәдә кулланырга шушы сүзне!) ничек инде аңа кагылмыйсың?!

Мирхәйдәр — бай нәсел баласы. Нәселе Чистай ягыннан. Шодада исә абыйсының утары булган. «Галиябану»ны язганда әлеге авылга кайтып йөрүләре бик ярдәм иткән, дип язалар театр белгечләре. Ярдәм иткәндер, итмичә... бик гүзәл авыл. Чишмәсе дә истә калган. Тик нигәдер монда туып, монда үскән бүтән бер кешегә шагыйрь булырга да, үз матурлыгына дан җырлатырга да ярдәм итә алмаган ул. Шагыйрьлекнең чыганагы, күрәсең, бөтенләй бүтән төштә... Борынгылар әйтмешли, сәмададыр... Табигатьтә яз иде! Күптән түгел генә салынган музей-йортында (искесе янып киткән) Мирхәйдәрнең рухын эзләп йөрибез. Берничә борынгы әйбер карыйбыз. Аларга Мирхәйдәрнең кул җылысы сеңгәненә ышанасыбыз килә!

Шул чагында тонык кына күкрәү ишетелде. Язгы күкрәү! Кайдандыр — тәрәзәме ачык? — әллә кайларда уйнаган яшеннәрнең исе өйгә кереп тулгандай булды. Ни күрәм?! — аксакалыбыз Аяз Гыйләҗев кинәт идәнгә ятты да ат сыман ауный башлады. Аңа Гариф Ахунов та иярде. «Өченче баһадир» Мөхәммәт Мәһдиев кенә — аларны нәкъ шул Балтачта, өч урыс каһарманын сурәтләгән мәгълүм картина астында, Марсель Галиев юмалап рәсемгә алдырган иде, — башын гадәттәгечә өскә чөя төшеп тәрәзәгә борылды. Совет чорындагы татар язучыларының һәммәсе кебек үк авылда туса да, сугыштан соңгы татар авылын сурәтләүдә тиңе булмаса да, Мөхәммәт абыйның «мажиклыгы» күзгә бәрелеп тормый, аңардан Еникидәй морзалык исе аңкый иде. Атаклы мулла баласы бит... Бәлки, каләмдәшләренең бу гамәлен ул кыланчыклык дип кенә кабул иткәндер...

Мин бәләкәй чакта беренче күкрәүне ишеткәч җиргә ятып аунау гадәте безнең авылда да бар иде. Бу, мөгаен, мәҗүси чордан ук киләдер. Авыл кешесе шулай язынкөзен яңгырның вакытында явып, иген уңышының мул булуын теләгән...

Аяз абый кебек олы язучыга моның ише кыланчыклык, ялган халыкчанлык ят иде, билгеле. Язгы күкрәүне ишетүгә, күңеле мәҗүсиләнеп алган икән, ни гаеп? Мәтәлчек

атса да беркем кырын сүз әйтмәс иде. Авыл җирендә бит. Мирхәйдәр Фәйзи йөргән нигездә...

Авыллык аның бөтен кыяфәтеннән бәреп тора иде. Югыйсә ул мажик баласы түгел, әтисе гомере буе мәктәптә укыткан, бабасы мулла булган. Әмма токымлы татар зыялысына хас тәкәллефлек, ыспайлык, кирәгендә шомартып җибәрү сыйфаты аңарда юк иде. Киемгә дә бик талымсыз иде ул. Яңа кәчтүм киеп чыкса да, бик фырт күренми иде. Галстукны да бик өнәп бетерми иде булса кирәк... Бумази күлмәген исә якасына кадәр үк төймәләп куя иде. Ә мондый гадәтне бик ачылып бетми торган йомыкый кешегә хас нәрсә дип әйтәләр. Бәлки, ул эчтән үзен гел тотрыклы кысада хис иткәндер, әмма тыштан болай һич уйламассың — күңеле шәрран ачык сыман, уйлаганын



агай-эненең йөзенә бәреп әйтә. Яраклашмый торган шәхес буларак, күпләрнең исендә сакланадыр әле ул...

Иҗат шундый нәрсә — күңелен ачып салмаса, үз җанына төшеп актарынмаса, язучының әсәре дә сай, ясалма килеп чыга. Чын язучы, телиме-теләмиме, күңелдәге иске яраларын бимазалый, кутырын ача. Аяз Гыйләҗев тә иҗатында үзен әйләндереп алган дөньяга гына түгел, үз-үзенә дә аяусыз иде. Әсәрләрдәге шомартуларны, сыйпауларны җене сөйми, кайчагында натуралистик алымнардан да тайчанмый иде.

Ул заманның әдәбият белемендә «социалистик реализм методы» дигән бер нәмәрсәкәй бар иде. Совет язучысы шул кысаларда язарга тиеш. Ягъни хезмәт кешесенең батырлыгына дан җырлау аның вазифасы. Иң әйбәт тормыш безнең илдә генә (империядә!), кимчелекләр бар икән, алар да бик вак-төяк... Кыскасы, ажгырып коммунизмга барабыз. Хәтта берара әдәбият белемендә «конфликтсызлык теориясе» дигән нәрсә уйлап таптылар. Әсәрләрдә уңай геройларны гына сурәтләүне таләп иттеләр...

Үзенең холкы, гомер юлы белән дә, олы таланты белән дә Аяз Гыйләҗев, билгеле,

мондый кысага сыя алмый иде.

«Тау сыртындагы корыган үлән чылгыйлары, корышкан абагалар арасында тынгы белмәс чикерткәләр скрипкәләрен уйныйлар. Тау итәге буйлап үзәннәрдән килгән җил, монда җитәрәк, капылт кына өскә менеп китә дә Мирвәлинең буй-буй яңа кулмәгенең ачык изүеннән үрелеп, аның йөрәген барлагандай шунда бутала... Шунда аның йөрәге, шунда! Әнә ничек тибә... Типсен әле ул! Мирвәлигә яшәргә кирәк! Яшәргә... Алда, тонык кына гөжләгән урман авызында, карылдашып дәү симез каргалар очалар...»

«Өч аршын җир» хикәясе шулай тәмамлана. Татар әдәбиятында бер вакыйга булган, күп бәхәсләр уяткан, совет идеологиясе сакчыларын сискәндереп җибәргән әлеге әсәр 1962 елда язылган икән. Мин туган елда... Гәрчә Аяз аганың моңарчы чыккан бүтән әсәрләре булса да, ул нәкъ менә «Өч аршын җир» белән татар әдәбиятында үзенең үзенчәлекле, мәртәбәле урынын ала. Сталин репрессияләренә кагылган, коммунистик сәясәтнең татар авылындагы үзенчәлекле яшәешне үзгәртеп җибәрүен җете буяулар белән тасвирлаган беренче әсәр иде ул безнең әдәбиятта. Утызынчы еллардагы коллективлаштыру зәхмәте аркасында читкә китеп олагырга мәҗбүр булган Мирвәли белән Шәмсегаян язмышы... Әлбәттә, бу заманда әле автор, соңгы еллардагы кебек, татар авылының фаҗигасен ачыктан-ачык, үзенә хас публицистик дәрт белән ачып сала алмады. Әмма моның кирәге дә юк. Әлеге фаҗига, нәфис әдәбиятның искиткеч кодрәте аркасында, юл астыннан тибә, укучының тамырларына күчеп сулкылдый башлый. Борынгылар «туфрак тарта» дип әйтергә яратканнар. Туган туфракның шушы тарту көче сагыштан сырхаулаган Шәмсегаянны да (туган туфрак ләхетенә башны куяр өчен), Мирвәлине дә кире суырып кайтара. Шушы туфрак көче, кая барсаң да аны җирсү хисе безне халык буларак саклаган да бит!

Кырыс буяулар әсәр тукымасында... Ләкин нинди гаҗәеп лирик җылылык та кушылган аларга... Күз яше белән... җан сагышы белән...

Билгеле, ул замандагы тешсез, купшы, янәмәсе партиячел язмалар (әсәрләр дияр-

гә тел бармый) арасында бу әсәр үзенең хакыйкый чынлыгы, әдәби эшләнеше җәһәтеннән әллә ничә башка өстен тора иде. Ләкин бездә андый өстенлекне яратмыйлар! — Кем булган ул кадәр? Нигә бүтәннәрдән калкып тора? Кыркырга! «Совет чынбарлыгын каралтып күрсәтүдә» гаепләр Аяз ага башына да әледән-әле ява тора. Юньле әсәр яза алмаучы донос язарга маһир була бит ул...

Әмма яхшы әдәбият кына милләтне милләт итә.

Аяз ага татарның бөек булуын, исеменең җисеменә тәңгәл килүен теләп яшәде...

Үзенең күңелендәге милләт сурәтенең чынбарлыкка туры килеп бетмәвен күрү аның өчен фаҗига иде, шуңа да ул, җисемебезне сыегайткан сыйфатларга ябырылганда, кайчак чик-чаманы да онытып җибәрде. Тик алда безне көткән упкынны искәрткәндә матур сүзләр эзләп торып булмый шул... Кычкырырга, сөрән салырга, бәлки, акырырга да кирәктер... Бу җәһәттән Чаадаев сүзләрен ничек хәтерләмисең: «Я предпочитаю бичевать свою родину, ...огорчать ее, ...лишь бы ее не обманывать».

Ләкин синең ләгънәт сүзеңне, җан авазын ишетүче бармы соң? Үлем түшәгендә яткан сырхауга «Тор! Ни йөзең белән көн уртасында болай ятасың? Эшкә тотын!» дип нәгърә орудан ни мәгънә? Милләт инде, аңын җуеп, саташулы төштә хур кызларын коча түгелме? Шундый шикләр, хафалар язучының яшәешен агуламый калмагандыр.

Соңгы елларда язучының бу әрнүе, киләсе бөек инкыйразны сизенеп газаплануы, кычкырудан бигрәк, үз эченә савылып сыктауга әверелде. Шуңа да күз уңында аның гел яшьрәк язучылар булды. Аңардан соң татар әдәбияты яшәрме? Яшәешен саклый алса, нindирәк кыяфәттә булыр ул?

Хәер, эчендә иманы булган һәркемне дә мондый сораулар борчыйдыр. Яңа гасыр татар әдәбиятының күңелләрдә үзе биләгән урынында калу-калмау мәсьәләсе Аяз аганың да гел җанын бимазалап торды. Татарча яшәеш мәйданының гел кысыла баруы гына түгел, якын елларда без бөтенләй көтмәгән яңа технологияләр килеп чыгуы әдәбиятны, кешелек өчен кирәкмәгән шөгыль буларак, тарих чүплегенә ыргытмасмы?

Әлбәттә, кешеләрне роботлар алмаштырмаса, Күңел, Җан, Рух дигән төшенчәләр

юкка чыкмас. Чын әдәбият исә шулар карамагында...

XXI гасырда татар әдәбияты ниндирәк юнәлештә үсәр? Уйлап баксаң, безнең әдәбият, хосусән аның прозасы, ниндидер без әле аныкламаган борылыш, әверелеш алдында тора бит. Соңгы ун ел эчендә генә Мөхәммәт Мәһдиев, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев кебек олуг язучыларыбыз фанилыктан бакыйлыкка күчте. Кемнәр килде?

Буыннар алмашынуы табигый, дип әйтүчеләр дә булыр, аңа бик борчыласы түгел, Гомәр Бәширләр китә, Госман Гомәрләр килә...

Бер очрашу вакытында Аяз ага көрсенеп әйтеп куйды:

— Бездән соң татарча язучы булмас инде...

— Урысча гына язарлар дисезме?

— Бәлки, ул татарча да булыр, тик безнеңчә түгел...

Аксакалның борчылуын аңларга мөмкин иде. Сер түгел бит, хәзер дөньяга чыккан кайбер әсәрләрне укыганда, чәчләр үрә тора. Бүгенге кайбер каләм әһелләренең теле белән Әмирхан Еники теле арасында җир белән күк аермасы! Югыйсә Еники безнең замандашыбыз, вафатына берничә ел гына... Әмма ул Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Ш.Камаллар замандашы да... Безне яңа — әллә искеме?! — әдәби телебезгә нигез салучылар белән тоташтырган күпер шулай юкка чыкты микәнни? Әлбәттә, тел һәрвакыт хәрәкәттә, мәсәлән, җилпуч, бакрач, табагач кебек сүзләр, шул исемдәге әйберләр белән гамәлдән төшеп калды, аларның мәгънәсен хәзер тел белгечләре дә аңламый торгандыр. Хикмәт бүтәндә... Бүген язучыларыбыз, үзләре төзек кенә урыс телендә сөйләшә белмәгән хәлдә, урысча уйлап татарча язалар. Җөмлә төзелеше урысча... Калька әдәби телебезнең җелегенә үтеп кергән. Шаккатмалы!

XX гасырның икенче яртысында татар хәяты зур үзгәрешләр кичерде. Тарихтагы тектоник хәрәкәтләр нәтиҗәсендә аның нигезе чатнады, язмышлар төшеп сытылырлык ярыклар барлыкка килде.

Җыеп әйткәндә, әсәрләрендә Аяз ага менә шул фаҗигане сурәтләде, «без нигә

мондый соң?» дигән аяныччлы сорауга һәмишә җавап эзләде.

А.Гыйләҗевтәге кебек зур, киң колачлы иҗат белән татар язучылары арасында бик сирәкләр генә мактана аладыр. Үз вакытында аның барлык әдәби әсәрләре дә диярлек дөньяга чыгып калды, шөкер. Ләкин Аяз Гыйләҗев дигән язучының бай әдәби дөньясы белән бүгенге укучы тулаем танышмы соң? Күпсанлы хикәяләр, роман-повестьлар, пьесалардан башка аның бит заманга, әдәбият тарихына кагылышлы күп мәкаләләре бар. Ә үзе өчен язып куйган көндәлек язмалар, төрле-төрле кешеләргә юлланган бихисап хатлар? Егерменче гасырның икенче яртысындагы әдәби хәрәкәтне аларсыз ничек күз алдына китерәсең?

Аяз ага миңа да хатлар язгалады. Яшьләр рәтеннән мине генә сайлап алгандыр димим... Әйткәнемчә, аның адресатлары арасында кемнәр генә юк. Шулай да әдипнең хатларын күздән кичерү миндә горурлык хисе уята. Әлбәттә, хатлар Аяз агача кискен язылган, бәхәсле урыннар да бардыр. Ләкин фикерләр искермәгән. Нигә бездә публи-



цистик фикер беркайчан да искерми? Тукайны, Әмирханны укыйсың — бүген язган кебек тоела. Татарның хәле һаман шул!

Һәм үзем дә, әлеге хатларны укыгач, башны учлап уйланып утырам. Гомерем ахырларында миңа да шундый ачы нәтиҗәләр ясарга туры килмәсме соң? Дөрес, мин хатлар язарга яратмыйм, ләкин язучының һәр язган нәрсәсе шул киләчәккә юлланган хат бит ул... Хәер, бер өмет бар икән әле, ул чакта сүземне тыңлар, язганымны укырдай кеше булса, мин дә Аяз агадай яшьләргә борылырмын һәм аның васыятен кабатлармын: «Бер төркем яшьләребезнең бүгеннән иманнарын ныгытуы миндә өмет уята, яшьли хак юлга чыкканнарның күпчелеге шул юлда ныгып калыр дип өметләнәм. Сез бәхетле чорга туры килдегез димим, ләкин сез кызыклы вакытка тап булдыгыз. Моның кадерен белергә кирәк! (2.XI.1990)».

Һәм мин дә хаклы булырмын. Чөнки телем исән икән, вакыт миңа һәрчак кызыклы...

«Идел»

2006, июль

Укучылар белән очрашу



ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА

Энекәш

Аяз Гыйләҗев татар әдәбиятында иң күренекле урын алган, халкыбыз күңелендә тирән мәхәббәт казанган зур язучы иде. Мин аның барлык әсәрләрен диярлек укып, сәхнәгә куелган барлык пьесаларын карап, күзәтеп бардым.

Аяз белән без яшьтәшләр идек. Ул миннән дүрт көн генә соң туган. Дүрт көнгә кече булса да, ул миңа энекәш булып чыга бит инде!..

Мин аңа шаярып, якын итеп: «Энекәш», — дип дәшә идем. Күңеле булып ул елмаеп куя иде. Кызганыч, яшьтәшләрем бу якты дөньядан берәм-берәм китеп бара торалар. Ямансу, бик ямансу булып куя. Аяз «энекәшем» дә китеп барды.

Мин Аязны бик якыннан беләм, без аның белән якын дуслар идек дип язарга җыенмыйм. Без 1945 елдан бирле таныш булсак та, бик аралашып, кунакка йөрешеп, еш очрашып яшәмәдек. 1945 елларда без икебез ике югары уку йортында: ул — Казан университетында, мин педагогия институтында укыдык. Ул елларда университетта да, пединститутта да әдәби түгәрәкләр бик яхшы эшли иде. Аязны шул әдәби түгәрәкләрдә күрә идем. Ул бу түгәрәкләрдә, төрле әдәби очрашуларда бик актив иде. Ничектер мин аны кара фрак кигән килеш сәхнәдә дә күреп калганымны хәтерлим. Мөгаен, бу фракны ул прокаттан алып торган булгандыр һәм аны киеп, концерт алып баргандыр. (Без, студентлар, концертлар куйганда, костюмнар алып торырга прокатка йөгерә идек.)

Аннары Аяз Гыйләҗев күренми башлады. Аны кулга алганнар, төрмәгә утыртканнар икән дигән хәбәр таралды...

Студент чактагы күреп калулардан күңелемдә аңар карата ниндидер җылы хис, хөрмәт сакланса да, 60–70 нче елларда мин әле аңардан бераз шүрләп тә йөрдем. Ул елларда күп кенә язучылар, тәнкыйтьчеләр матбугатта, язучыларның төрле җыелышларында минем иҗатымны бик каты тәнкыйтьлиләр, хагын да нахагын да әйтеп, минем шигырьләремне, җырларымны юкка чыгарып ташлыйлар иде. Кыю фикерле, сүзен күзгә карап, туп-туры әйтә торган Аяз башкаларга кушылып китеп, миңа бер-бер авыр сүз әйтер, болай да яралы йөрәгемне җәрәхәтләр дип уйлый идем һәм аңардан читтәрәк булырга тырыша идем. Хәер, аның үзен дә бу елларда «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар» кебек әсәрләре өчен шактый «кыйныйлар» иде. Аны да, мине дә «кыйнаган» шау-шулы бер җыелыштан соң Бауман урамы буйлап эчтән янып барам, артымнан Аяз куып җитте дә: «Слушай, мин «тегендә» булып кайткан кеше, мине «кыйнаулары» аңлашыла, син бит утырып та кайтмадың шикелле?» — диде. Үз биографиямне, үземнең «халык дошманы баласы» булуымны кешегә сөйләп йөрми идем, ярамый иде. Мине «кыйнаулар», бәлки, сәяси нигездә дә булмагандыр. Ә кем белә?.. Бәлки, биографиям дә роль уйнагандыр?.. Бер сүз дә әйтмичә, башымны иеп барам... «Слушай, нәрсә бик башыңны иеп, кайгыга батып барасың? Төкер, слушай, барысына да! Алар барысы да аренадан төшеп калачаклар! Син, мин аренадан төшмәячәкбез!» — диде. Мин бу сүзләргә бик шатланып, очынып китмәдем. Чын күңеленнән әйтәме, болай гына сөйләнәме дип, ул чакта Аязга да ышанып җитми идем. Шулай да бу сүзләр мине юатты, күңелемдә өмет уятты. Ул бер вакытта да башкаларга ияреп мине сукмәде, рәнҗетмәде.

Хатын-кыз язучыга ир-ат язучылар белән бер сафта торып иҗат итү җиңел түгел.

Ул турыда бик кызыклы итеп язып та булыр иде. Бу турыда сүзне озайтасым килми.

Кайбер очракта хатын-кыз язучыга ир-егетләр нәкъ менә хатын-кыз итеп кенә карыйлар, шул сәбәпле төрле имеш-мимешләр, күңелсез четерекле хәлләр дә туа. Шөкер,

минем үземә алай хатын-кыз итеп кенә карап, иҗатыма тегеләй-болай бәя бирүчеләр, урынсыз мактап азындыручылар булмады. Аяз да миңа хатын-кыз итеп карамый иде, мине үзе белән тиң иҗат кешесе итеп саный иде.

Аяз иҗатта бик ярдәмчел кеше иде. Күп кенә язучыларның әсәрләрен укып, кирәк булса үзе каләм тотып, эшкәртеп, дөньяга чыгаруда булыша торган иде. Уйламаганда-көтмәгәндә аның миңа да бер ярдәме тиде. 70 нче елларда Минзәлә театры минем «Комиссия килгәч» дип аталган комедиямне сәхнәгә куйды. Комедиямне тамашачылар бик җылы кабул итте. Театр шул спектакль белән гастрольләргә йөргәндә, «Социалистик Татарстан» газетасында Рамазан Байтимеровның бу спектакльне тетеп ташлаган, бик яман хурлаган мәкаләсе басылып чыкты. Аның мәкаләсендә «бер фельетон сыманрак кына пьеса» дигән фикер бар иде. Ул, Байтимеров, миңа күсәк белән китереп суккан шикелле итеп, матбугатта, язучылар җыелышларында берничә тапкыр шундый чыгыш ясады. Бу комедиядә Татарстанның атказанган артисты Анатолий Богатырев төп рольне башкара иде. (Анатолий да вафат инде. Бик талантлы актер, бик эшлекле, чибәр егет иде, мәрхүмкәй. Урыны җәннәттә булсын!) Анатолий: «Байтимеров мәкаләсе уңае белән, «Комиссия килгәч»не сәхнәдән алып ташларга җыеналар. Министрлыктан вәкил килеп караячак. Шул көнне син дә, Гөлшат апа, безнең янга — авылга (авылның исеме хәтердә калмаган) килеп чыксаң иде», — дип шалтырата. Спектакльнең язмышы өчен бик борчылып авылга килеп төшсәм, мине Анатолий белән Аяз Гыйләҗев каршы алды, министрлыктан вәкил итеп Аяз Гыйләҗевне җибәргәннәр икән. Әлбәттә, Аяз комедияне ошатмас инде, туп-туры күземә карап әйтер, дип уйладым. Спектакльне карадык. Аязга күз төшереп алгалыйм. Елмаеп-елмаеп куя, кайбер күренешләрне көлә-көлә карый. Спектакльдән соң: «Нәрсә, Байтимер күсәк күтәреп яза, хәер, аның амплуасы шундый инде. Фельетон кебегрәк диюенә шаккатырга кирәкми, комедиянең нигезендә фельетон шикелле эчтәлек ятарга тиеш. Сез, Анатолий, гастрольне туктатып кайтып китә күрмәгез! Спектакль туган, бар!» — диде. Шулай итеп «Комиссия килгәч» дигән комедияне репертуарда саклап калды. Бу минем өчен Аяз

тарафыннан эшләнгән зур яхшылык, ярдәм булды.

Соңгы елларда артык аралашмасак та, очрашканда гел дусларча сөйләшә идек. Бәйрәмнәрдә мине котлап шалтырату гадәте бар иде аның. Соңгы сөйләшүебез телефон аша 2002 елның 8 март көнендә булды. Ул бик җылы, матур итеп мине Хатын-кызлар көне белән котлады: «Син, парин, егет-хатын! Шулай да сине бу бәйрәм белән котлап, чын хатын-кыз бәхетләре телим!» — диде.

13 март көнендә вафат булу хәбәрен ишетеп бик моңаеп калдым!

Киң колачлы иҗаты белән татар әдәбиятына зур мирас калдырган Аяз бераз кырысрак кебек күренгән холык-фигыле, ләкин күзлеген төзәтә-төзәтә елмаеп карап сөйләшә торган ачык йөзле, кеше хәленә керә белгән киң күңелле кеше иде. Минем күңелемдә аңа карата җылы хатирәләр генә сакланыр.

Август, 2002

ВЛАДИМИР ИВАНОВ

Гаҗәпкә калдырган хәл

Аяз Гыйләҗев күренекле язучы, кабатланмас шәхес иде.

70 нче еллар башында аның белән бер очрашуны һич онытмыйм, һәм онытырлык та түгел.

Мин ул вакытта партия өлкә комитетының фән бүлеге мөдире булып эшли идем. Республика активы җыелышыннан соң минем бүлмәмә Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Рәис Беляев килеп керде. Гадәттә, без аның белән, ул Чаллыга шул ук кичне кайтып китмәсә, театрларга йөри идек. Бу юлы да ул: «Бүген кайсы театрга, нинди спектакльгә барабыз?» — дип сорады.

«Бүген Академия театрында Аяз Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә» спектакле. Әйдә карыйк», — дидем мин. Рәис Кыямович ризалашты. Театр директоры Әзһәр Хөсәеновка шалтыраттым: «Билет табып буламы?» — дип сорадым. «Аншлаг, — диде ул, — ләкин алтынчы рәттә урыннар булыр».

Безне Әзһәр Миншәехович әфәнде каршы алды һәм кунак бүлмәсенә алып керде.
Менә шул вакыттагы очрашу үзе бер театр күренешен хәтерләтте дә инде.
Без килгәндә, бүлмәдә баш режиссер Марсель Сәлимҗанов пьеса авторы белән сөйләшеп утыра иде. Марсель ага безне урыныннан торып, ишеккә якын килеп сәламләде. Аяз исә кузгалмады, без янына килгәч кенә басып, гомуми рәвештә исәнләште.
Ләкин Рәис Беляев шунда ук моның белән генә канәгатьләнмәде:
— Аяз, сез — татар халкының атаклы язучысы, драматургы, сезнең белән горурланабыз. Сезне кочаклыйсым килә», — дип, кулларын алга сузды.
Ләкин язучы аны русчалатып бик еракка җибәрде:
— Рәис Кыямович, әдәпле генә булыгыз, кочаклашу кирәкми, сез принципиаль түгел, төрлечә сөйли торган кеше. Кайчаннан алып мине атаклы драматургка чыгардыгыз? Әле бит ничә ел элек кенә комсомолның республика активында мине тискәре сүзләр белән хурладыгыз.
— Булды бу хәл, ялгышлык! Докладны мин язмаган идем, пропаганда бүлегендә кызлар язганнар. Мин язганны гына укыдым. Гафу итегез!
— Мин элеккеге сүзләрегезне гафу итә алмыйм, ләкин сезне шәхес буларак гафу итәм.
Ике зур шәхес, уртак тел тапмыйча, әнә шулай сөйләштеләр.
Минемчә, бу хәл күп нәрсәне аңлата. Аның тирән мәгънәсенә төшенү өчен шуны да истә тотарга кирәк: ул елларда Рәис Кыям улы өлкә комитеты җитәкчеләренең берсе, бюро әгъзалыгына кандидат иде. Халык арасында аны «Ф.Табеевны алыштырачак, ике елда ике орден алган кеше»,— дип сөйләделәр, ягъни аның бик дәрәҗәле чагы иде. Берәр конформист булса: «Рәис Кыямович, рәхмәт яхшы сүзләрегез өчен», — дип кенә әйтер иде. Ләкин Аяз әфәнде чын мәгънәсендә принципиаль, вөҗданлы һәм горур шәхес иде. Мин аны шундый итеп хәтерлим. Ул елларда ук аның гаиләсе турында да бик җылы тәэсир калды. Нәкыя ханым Гыйләҗеваны күпертмичә, объектив рәвештә әйтсәк, республикабызның татар теле буенча белгеч-педагогы иде, уллары да

иҗат кешеләре булып үстеләр: фәндә һәм сәнгатьтә күпләргә үрнәк.

«Шәһри Казан»

6 декабрь, 2002



РОЗА КАМАЛЕТДИНОВА

Кодрәтле сүз иясе

— Тормыш юлларында күңелгә мәңге сеңеп кала торган мәхәббәт тә сирәк очрый. Булачак кәләшегез Нәкыя туташны, ялгышмасам, Сез хат аша тапкансыз. Адәм ышанмаслык хәл, төрмәдә утыручы (нахакка икәнен кемгә аңлатып торасың!) егет белән саф, сылу-гүзәл кыз арасында башланган хатлашу өйләнешүгә, гомер бакый сүнми торган олы мәхәббәткә илтә. Сөйләгез әле шул хакта.

Аяз абый: «И-и, монысы бит инде үзе бер тарих, бүтән роман», — дисә дә, минем чынлап кызыксынуымны хуплап, сүз башлый:

— Багражда унынчы классны 1944 елның сентябренә яптылар. Укырга Сарман мәктәбенә киттем. Мин Югары Әхмәттә әби-бабамда яшәп, Сарманда укыдым. (Югары Әхмәт белән Сарман тоташкан кебек инде ул.) Нәкыя анда беренче класска кергән кызчык иде. Матур, ап-ак бөрмәле ыштан балагының күлмәк итәгеннән күренеп торган чагы. Кода, кодача булып чыктык без аның белән. Нәкыянең апасы безнең төп йортта кияүдә, безгә җиңгәчәй була. Туганнарда гел шул кызчык та кайнашып ята. Чыркылдап, юри минем тирәдә әйләнә дисәм... Шул җилфердәгән ак ыштан балагыннан тарттым да: «Син минем тирәдә болай уралма, киләчәктә әйләнеп кайтырмын да мин сиңа өйләнермен», — дип ычкындырдым бит берзаман. Бу — 1944 ел.

...«Эш»ен яңадан тикшерү өчен 1954 елда Казанга кайтарылгач, Нәкыя турында энесе Алмаздан белешмә ала. Аязның күңеле кузгала. Аяз тота да кызга хат юллый.

Нәкыя ханым ул хатны кадерләп әле дә булса саклый. Егетнең ышанычына, акыл куәсенә, җитдилегенә сокланмый мөмкин түгел.

Аяз илле бишенче елның көзендә илгә кайта. Авылына кереп, әти-әнисе белән күрешә, бер чынаяк чәй эчә дә җәяүләп утыз чакрым ераклыктагы Әхмәт авылына юл тота.

— Безнең умарталар күп иде. Бал аертып ятам, килеп керде егетем, — ди Нәкыя апа. — Эштән бүленеп булмый, рамнарны киредән умарталарга тапшырырга кирәк. Кул белән центрифуганы әйләндерәм. «Кая, мин әйләндерим әле!» — ди Аяз. «Юк! Син булдыра алмыйсың аны!» — дидем. «Кытай алфавиты түгелдер әле ул кадәр», — дигәне хәтергә язылып калган. Барыбер үзем эшләдем. Бер-ике сәгать көтеп утыргандыр. Аннан Бузат чишмәсе буена киттек. Тау башында бик матур чишмәбез бар, шул Бузат чишмәсе дип атала. Аяз карап-карап торды да: «Өйләнешкәч, тау астына мәхәббәтебез символы итеп агач утыртырбыз, яме», — диде. Өйләнештек, бер-бер артлы балалар — улларыбыз Искәндәр, Мансур, Рәшатларыбыз туды. Искәндәр туган елда (1958 дә) агач утыртырга кыбырсый башладым. Аяз онытыбрак җибәрде. Агач утырту вакытында һич кайту әмәлен таба алмыйбыз, аптырадык. Нәтиҗәдә, авылдагы туганнарга 150 сум акча җибәреп, (ул вакытта зур акча иде ул) безнең исемнән агач утыртуларын үтендек. Алар сөенә-сөенә ул эшне башкардылар.

Нәкыя апа урыс мәктәбендә татар теле өчен көрәшә, татар балаларына туган телне өйрәтә. Үз улларын да онытмый. Өч улын да сәнгать мәктәбенә йөртә. Искәндәр белән Мансурны, тәпи йөри башлагач ук өйләренә укытучы йөртеп, музыка серләренә төшендерергә телиләр. Төпчекләре Рәшат тугач, малайлар: «Рәшатны без үзебезчә тәрбиялибез, музыка кирәк түгел икән, егет кешегә спорт мөһимрәк!» — дип, инициативаны үз кулларына алалар. Әмма немец, инглиз телләрен өйрәнүләреннән зарлан-



мыйлар. Чит тел укытучылары аларны кечкенәдән үк бик ярата, янәшәдә генә яшәгәнгә, өйләренә чакыра. Алар анда ашап-сыйланып та кайткалый торган булалар. Ленинград блокадасыннан соң монда яшәп калган тәрбияле гаилә кешеләре булалар алар. Балалар анда йөрергә атлыгып торганнар. Искәндәр университетта тарих укыта, өчдүрт тел белә, еш кына Германиядә зур галимнәр белән сәяхәттә, симпозиум киңәшмәләрдә була. Бүген Казан университетында татар филологиясе факультетын җитәкли. Мансур, КИСИның архитектура бүлеген тәмамлап, берникадәр эшләгәннән соң, драматург булып китте, ә Рәшат исә медицина институтын тәмамлагач эшмәкәр булып китте.

...Олы җанлы Нәкыя апа гомере буе Аяз абый иҗатының ялкынында янып, аңа булышып, аның өчен ут йотып, кайгырып һәм сөенеп яшәде.

Тәнкыйтьчеләр Аяз Гыйләҗев башына гына түгел, үзләре дә күтәрә алмаслык күсәкләре белән әүлиядай хатын йөрәгенә дә сугып торганнар икән.

— Аяз ел йомгакларына йөрмәскә тырыша иде. Бик кыйнадылар бит аны. Кирәксә дә, кирәкмәсә дә гел төртеп тордылар. Әле күптән түгел бер хөрмәтле тәнкыйтьчебез ярым шаяртып, ярым уйнаган булып әйтеп торды: «Без барыбыз да Аяз Гыйләҗевне сүгеп тәнкыйтьче булдык. Аяз Гыйләҗевкә күсәк күтәрә алмаган тәнкыйтьче ул әле тәнкыйтьче булып исәпләнми иде!» — ди. «Өткәй җырлый да, җылый да» пьесасы куелды. Дамирә Кузаева, Камил Вәлиевлар шәп уйнадылар. Спектакльдә халык белән бергә обкомның идеология бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин да елап утырды. Соңыннан сәхнә артында да Аязның кулын кысып мактады. Әдәби ел йомгакларында Ризван Хәмид драматургия буенча докладында әсәрне мактады. Соңгы сүзне Мусин үзе әйтте: «Оялмыйча, төрмәдән кайткан адәмнәр хакындагы пьесаны мактыйсыз. Моны мин «медвежья услуга» дип атар идем», — дип сүгеп йомгак ясады. Мин Тукай клубында үксепүксеп елап утырдым. Җылы сүз ишеткәне булмады инде гомере буе. Еш кына ул булмаганда җыелышларга йөрдем. Гел тыела алмыйча елап кайта торган идем.

Идеология буенча җаваплы секретарь Мирзаһит Вәлиев тә үзен: «Каян табасың син

безнең тормыштагы кыек якларны? Тукта инде!» — дип, өстәл сугып сүкте. Бусы Качалов театрында «Один потерянный день» куелгач булды. Үзгәрә торган түгел инде ул, ник шуны аңламыйлар икән?!

Татарның акылы, күзе, намусы булырга туган кешене үзгәртү мөмкинмени?!

«Сөембикә»

№ 1, 1998

Роза Камалетдинова

Аяз Гыйләҗевтән ин-

тервью алырга килгәч.

1998



ФАТИХ КУТЛУ

Аяз абый — остазым

(Хәтер-хатирә)

Ике меңенче елның башлары иде. Аяз абыйның «Заман» газетасында басылып барган «Төркиянең түренә үк үттек» исемле хатирәләре мине үзенә җәлеп итте. Көннәрнең берсендә китап киштәләрендә «Йөгез, бер дога!» дигән романга күзем төште. Әсәр авторының хатирәләрен укыганлыктан, шикләнмичә сатып алдым.

Бу әсәр миндә көчле тәэсир калдырды. Аяз абыема тирән ихтирам һәм ярату хисләре уянды. Хәтта төшләремә үк керде. Мин Аяз абыйга ачык хат яздым. Ул «Заман» газетасында басылып чыкты.

Ләкин моның белән генә канәгатьләнмәдем. Күңелемне яулап алган әдип белән ничек булса да танышырга, хыялларымны чынга ашырырга кирәк иде.

Мин шундый дәрт белән 2000 елның апрель аенда Чаллыдан — ул вакытта шунда яши идем — Казанга «Заман» газетасына килдем һәм Аяз абый белән танышырга булган теләгемне белдердем.

Рәхмәт яусын, шунда Аяз абыйга шалтыратып: «Сезгә ачык хат язган төрек егете килгән. Аның Сезнең белән танышасы килә», — диделәр. «Кичке сәгать алтыда рәхим итсен», — дигән җавап алынды.

Шундый истәлекле булды бу танышу. Аяз абый нәкъ минем хыялымдагыча булды. Мин үзем белән теге вакытта укып чыккан «Йөгез, бер дога!» китабын автограф алырга дип алып килгән идем. «Фатих бәй, сез минем йортыма кояшның бер кисәген алып кердегез!» дип язып куйды. Ул китапка шундый җылы сүзләр язгач, мин бөтенләй оялдым.

Нәкыя апа тәмле ашлар пешергән иде.

Икенче көнне үзе кабат чакырды. Уллары Искәндәр, Мансур, Рәшат абыйлар белән таныштырды. Һәм шунда дүрт томлык әсәрләрен үз кулы белән бүләк итте. Ул бүләк иткәндә: «Фатих бәй, шушы китапларымны сезгә бүләк итәм, кабул итәсезме?»

— дип сорады. «Күктән ни яуган да, җир кабул итмәгән?» — дидем мин.

Ул көннән соң мин бу китапларны укып чыгарга ниятләдем. Укый да башладым, ләкин күңелем әллә ни тартмады — миңа авыр булды. Шулай да тырышып-тырышып укырга омтылдым, ләкин барып чыкмады.

А.Гыйләҗев Истанбулда. 1999



Һәм шушы китаплар 5 ел инде китап киштәмдә торалар иде.

Соңгы айларда мин үзем дә аңлап бетермәгән бер хәл булды. Мәрхүмнең үзеннән теге вакытта ук сорап калган идем: «Кайсы әсәрегезнең төрек теленә тәрҗемә ителүен теләр идегез?» — дип. «Өч аршын җир»не, — дип әйткән иде.

Бу әсәрне тәрҗемә итү минем бурычым дип карый идем. Һәм күптән түгел бу әсәрне тәрҗемә итәргә җөрьәт иттем. Менә шуннан кабынып китте дә эчемдәге учак. Аның андагы уй-фикер рәвеше, фразеология, тел хәзинәсе мине тәмам хәйран калдырды. «Булса була икән шундый язучы!» — дидем дә бу әсәрен төшенә-төшенә дүрт мәртәбә укып чыктым. Укыган саен ачылып китә, тирәнәйгәннән-тирәнәя бара. Гел укыйсы гына килә, теле шуның хәтле зәвыклы. Асларына сызып-сызып чыктым. Һәм көндәлек телдә сөйләшер өчен үз телемә аның телен сеңдерергә дип кассетага искиткеч җирләрен яздырдым, шуларны тыңлый-тыңлый телемне баетырга булдым. Үз-үземә шулай дип әйттем: «Бу әсәрләр синең дәреслегең — шундый ният белән анализлап кат-кат, җентекләп укып чыгарга тиешсең!» Шулай итеп, мин әлегә «Яра» һәм «Дүртәү» повестьларын укып чыгарга өлгердем. Ничек укыганымны күрсәгез иде! Әсәрдән аерылып булмый, билләһи, ашаганда, тукталышта, автобуста гел әлеге әсәрләрне укып йөрим дә шушы хәлгә шаккатам.


Моңарчы 5 ел буена тик яткан китапларны кинәт укып китүемнең сәбәбен эзләп баш ваткач, шундый нәтиҗәгә килдем. Аяз абыем: «Зур өметләр баглап бүләк итәм шушы китапларымны», — дигән иде бит. Ул минем хакта чын күңеленнән: «Шул әсәрләрем күңелеңдә мәхәббәт уяндырсын», — дип дога кылган, ахрысы.

Әйе, мин үз фикеремне, хисләремне көн дә төрекчә теркәп барам. Димәк, миңа татарча да каләм тибрәтергә вакыт җиткәндер. Моңа кадәр мин шуңа бар яктан да әзер түгел идем. Димәк, вакыты җиткән. Мин кыйбламны таптым, минем теләкләр, уй-фикерләрем Аяз абый әсәрләре аша камилләшәчәк. Мин татар теленең искиткеч байлыгын Аяз абый әсәрләре аша тойдым.

«Ватаным Татарстан»

19 август, 2005

Истанбулда диңгез сәяхәте вакытында. 1999



РУСТЕМ КУТУЙ

Что за зеркалом?

Только общение дает чувство подлинной жизни. Друг с другом, с травой, деревьями, дождем, снегом. И конечно, с книгой. Человек, в сущности, никогда не пребывает в одиночестве. Навстречу ему спешит и путник, и ветерок, и облако. И душа его собеседует с целым миром. Календарь каждодневно худеет, часы поторапливают безостановочным движением. Но человек обладает еще одной привилегией — жить не только в пространстве, но и во времени, перемещаться в нем. В этом смысле он своеволен, способен к перевоплощению, «легок на подъем», ненасытим в желаниях. Он может отлететь на десятки лет назад или предвосхитить грядущее с поразительной быстротой мысли и обескураживающим провиденьем чувства. Уединяясь, мы собеседуем: мысленно произносим монологи, озаряемся непредвиденными встречами.

Костерки памяти вспыхивают то там, то здесь, и время озвучивается речью. Мы как бы пытаемся подсмотреть: а что сокрыто за зеркалом? Не отражение на чистой плоскости нас интересует, ибо оно слишком очевидно, а глубина. То есть судьба, как мы ее называем, глубинная суть обыденного. Проникновение в ее кладовые дарует нам счастливые мгновения.

В последнее время обнаружилось некоторое сетование на якобы замедленный процесс обновления литературы. Жизнь, дескать, ее опережает выявлением нового качества. Это, ясное дело, недоразумение. Приходят на ум слова поэта: «Погоди, небесное, дай понять

земное...» За какие-то полвека громадно изменился не только облик земли и сам человек, но и встал на ребро вопрос существования вообще. А что делать с опытом времени — силовым полем обитания поколения, множеством исторических переломов — извержений вулканов минувшего? Минувшего, но незажившего. Опытом войн, революций, и снова войн, опытом возрождения из пепла? Это же надо осмыслить и воплотить, закрепить в памяти, потому что память не угнетает, а возвышает. И взгляд писателя поднимается от подножия к вершине. Корневое начало — его отправная точка.

Как менялась психология человека, какие она претерпевала бедствия, лишения, радости воспарения духа, победы, взрывы, смятения, — все это, без сомнения, и занимает творческую личность писателя в первую очередь, и потому его труд — нравственный поиск, а не словесные игры в сиюминутное отражение насущного дня. Литература, мне кажется, не столько предвосхищает, сколько освещает жизнь изнутри, а для этого необходимо неистощимое, стойкое горение. Бескорыстное служение правде.

Так я размышлял после прочтения повестей писателя Аяза Гилязова, сложившихся в весомую книгу. Книгу очень важную, очень искреннюю, предельно достоверную.

Она, эта книга, сколок его судьбы, сплетенной корнями с судьбой народа, выношенное суждение, как раз то, что сокрыто от беглого взгляда за гладью зеркала. В ней присутствует национальный характер, психологический портрет национального достоинства.

Если развернуть это определение, получится обширная статья о самом значительном, чем может гордиться писатель, статья о непреходящей сути — жемчужине в раковине: нет большей удачи для писателя, чем выявить и богато раскрыть в образах психологию своей нации. Подобное, увы, удается немногим.

Когда я восхитился образом Бибинур из повести «В пятницу вечером», автор сказал: «Я, может быть, двадцать лет носил ее в сердце...» Да, разумеется, среди обыкновенных слов в редкие часы прозрения нас посещают и вещие сны.

Старушка Бибинур — прекрасная героиня, по-другому я и не мыслю. Прекрасная!

Она само душевное расположение ко всему живому, бегущему и ползущему, чем за-

полнен мир. Она — праведница с открытым лицом и в самую тяжелую минуту, в любое время жизни. Женщина со своей тайной любви, со своей тайной не только в сокровенном чувстве, но в широком смысле доброго желания. Ее добро постоянно, не избирательно, она и явилась на свет, чтобы отдавать, ничего не прося взамен. Да, дорогой читатель, и такое есть счастье — безвозмездно отдавать. Очень сильный образ старушки Бибинур! Не могу я вспомнить похожего в других литературах по наполненности, свежести, обособленности, цельности. Ничего заемного даже на маковую росинку. Она естественно вышла в мир из сердечной тоски писателя по прекрасному, слишком живая, чтобы оставаться жить в пределах книги. Бибинур трогательна непрерывностью своих душевных подвигов, она истинна повсюду, где кладет маленькие следы. И поздняя любовь ее, очищенная от плотского побуждения, возвеличивает ее «тайну». Вот до каких высот может подниматься дух страждущего человека, как бы произносит автор. Вот как просветляется сердце! Праведник всегда несет на себе печать трагедии, мученический ореол. Для других, для окружающих его людей. Как бы ни был он, праведник, заземлен, дух его воспаряет. Обычной меркой тут не обойдешься, а посему в его присутствии сникает зависть, дикость своенравия, духовное невежество и слепота, мелочность бытовых неурядиц бескрыло отходит в тень. На то он и праведник, не ходульная знаменитость, что отрицает своим существованием всякую безликость, призывает к очищению, останавливает сдержанностью крик, бескорыстием — алчность. Отсюда и печать трагичности. И каждый, сопутствующий старушке Бибинур, оценен ее взглядом, зоркостью ее души — и Джихангир, и Галикай, и Габдуллазян, и Вэли, и Зухрабану-близняшка.

Я бы мог много размышлять о повести — она вся на слуху, освоена, принята чувством: теперь мне никуда от Бибинур «не деться», — но я пишу не критическую статью, а как читатель собеседую с заинтересованным читателем, причастный к писательскому труду, сопереживаю вместе с автором. Ибо знаю, как «боязно»писателю расставаться с сокровенным, препоручать его в чужие руки, — все равно, что дитя родное отпус-

тить на временный постой. Ведь у каждого свое «зеркало», и, как знать, не удовольствуется ли кто-то самонадеянным скольжением по поверхности, не прозревая при этом «зазеркальные» глубины...

Неискушенному читателю писатель представляется странной фигурой, наполовину вымышленной. Портретные черточки собраны с творческих личностей, давно заслуживших общее признание, из дневников, писем, воспоминаний. Все это — фантазия, легенда, домысел, над которыми витает нимб исключительности. И подчас поступки героев произведений, их действия полностью соединяются с жизнью автора. Находясь под пристальным вниманием, обрастают инородным материалом аналогий. Очень просто «увидеть» заносчивость, позерство, болезненность, тщеславие и т.д. С этой точки зрения Аяз Гилязов, мне думается, человек самоуглубленный, смеющийся скорее невпопад, будто на всякий случай, не способный обидеть другого для самоутверждения. Это мое предположение. Но что несомненно, он — человек счастливый, хотя бы потому, что пришел в литературу не по самолюбивой случайности, не по ковровой дорожке, а по требованию чувства. Мы сидели на одной студенческой скамье университета, но он был намного старше меня и, естественно, иронично воспринимал мои поспешные суждения. У него было на это право возраста, право знания жизни. Я бы не удивился, скажем так, произнесенной вдруг фразе: «У тебя еще молоко просыхает на губах, не кровь...» Жестко говорить учит жизнь. Она же учит быть и разборчивым. Я был свидетелем его воодушевления чужой рукописью. Так или иначе, на сегодняшний день писатель Аяз Гилязов — человек счастливый: его герои, сойдя со страниц книг, ушли, как свои люди, в народ. Он сумел показать то, что таится за «зеркалом» жизни, не погрешив перед правдой.

Повесть «Три аршина земли» в свое время была отмечена премией журнала «Дружба народов» лет пятнадцать назад. Я помню ощущение первого прочтения. Но в том-то и дело: время, как вершитель и судья, либо укрупняет подлинник, либо низводит его до положения всего лишь чертежа, замаха (протащилась туча, да не пролилась благодать-

ю). Ныне «Три аршина земли» так же уместны и не утратили ни одного оттенка свежей вести. Талантливый писатель потому и долгожитель, что образы, им созданные, протяженны во времени, хотя и невечна плоть земная, давшая им жизнь. Есть что-то превыше, сверхзадача искусства, возвышающая обыкновенность до величия. Вспомним пушкинское: «Прекрасное должно быть величавым». Я бы назвал это оптимизмом корневого начала, пульсом родника.

Проза Аяза Гилязова оптимистична, ее трагизм величествен. Дух преоборения возносит человека: не муть поднимает с души, а силы великие. Два героя Мирвали и Шамсегаян — словно два полюса магнита. Они противоборствуют в любви молчанием. Только смерть окончательно породнит их. Час прозрения, час ответа наступает по своим законам: на трех аршинах уместятся лишь бренные останки, а бьющемуся сердцу необходим воздух родины, безоглядность простора, постижение единства и братства на земле. Добро не умозрительно, а конкретно, его не размажешь кашей на тарелке. Им ценится жизнь, произрастая, бесконечно самовозрождаясь. И неиссякаемы источники добра.

Высокое художество философично, оно бежит суетности. Говоря образно, оно обязательно задается вопросом: а что за зеркалом? Оно изучает не только предмет, но и его тени при разном освещении.

Проза Аяза Гилязова высоконравственна, избегает прописной морали.

Повести о военном детстве, юности «Любовь и ненависть» и «Весенние караваны» донесут до читателя правду и слезы первого чувства, благотворное причастие к судьбе народной, в которой все повязаны одной веревочкой весенних караванов. Как бы эхом откликается Сибгат Хаким беспощадно, с обнаженным мужеством и откровением на нарисованные сцены Аяза Гилязова:

Как узелки одной веревки длинной,
навстречу женщины усталые бредут,
и тяжко сгорбленные спины —
за валом вал — качает, как в бреду.

Весенний караван в пустынном поле,
поклон тебе и тихое «Прости»...
Ломоть земли посыпан горькой солью
из женской нескудеющей горсти...

Пять повестей, сведенных вместе, говорят о многом. Каждая по отдельности — только об удаче писателя. Тема родного очага, корней, отечества требует именно разных ракурсов, временных моментов. Требует взятия глубинных проб, сердечного напряжения. Простое повествование лишь событийно, и герои его случайны, настоящая же литература имеет дело с пластами жизни, с родниками, а не ручейками, с мощным оглядом вширь и вглубь, а не за ограду соседа. Имеет дело даже не с героями, но всегда с типами. Она словно перерождает жизнь силой искусства, непременно возвышая ее, но никогда не унижая. Вот исходя из этого можно утверждать, что проза Аяза Гилязова патриотична без ложной патетики. Естественна и необходима, как хлеб, вода. Самоотверженна по сути характеров, по пламенности порывов, уважению к истоку. Она философична не по формальному изъявлению, а по самому образу мышления, природному виденью.

В татарской литературе работает, полон энергии большой мастер, перед которым открыты дали непредвиденного размаха. Ему еще предстоит сказать свое главное слово, хотя «высокий храм» выстроен, акустика налажена, свод сияет. Аязу Гилязову, я убежден, предстоит занять место в общенациональном масштабе, он способен поднять и нести достойно не какой-то пресловутый груз художника, а очищающую правду жизни.

1985



ФЛҮС ЛАТЫЙФИ

Юксыну

Кайчан да булса Аяз Гыйләҗев турында язарга туры килер дип башыма да китереп карaганым юк иде. Аяз Гыйләҗев безнең өчен — зур әдәбиятка чагыштырмача соңрак килгән буын өчен — кул җитмәс биеклек, әдәбият Олимпында борынгы грек аллаларыныкы шикелле үз урыны, үз сүзе булган изге бер зат кебек тоела иде. Әйе, ул елларда әле үзе исән чагында ук әдәбиятыбызның алтын баганаларына — классикларга әверелгән әдипләребез, сәнгатькәрләребез байтак иде. Без аларның фидаилегенә, фидакарьлегенә, гыйлем вә тормыш дөньясында киң колачлылыкларына, хәтер сандыкларының байлык-муллыгына сокланып, эшчәнлекләренең күпкырлылыгына сокланып карый идек. Соңгы ун-унбиш ел эчендә Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Бакый Урманче, Гариф Ахунов кебек бөекләребез фани дөньяны калдырып бакыйга күчкәч, әдәбият-сәнгатьнең тәхет залы бушап калды. Укучыларын бик еш таң калдырырга, көтмәгәндә-уйламаганда яңа әсәре белән шаккатырырга яраткан Аяз Гыйләҗев әнә шул мөбарәк тәсбихның соңгы мәрҗәне булды бугай. Изге урын буш тормас, ди. Әмма алар дәрәҗәсендәге бөеклекләргә ирешер өчен әдәбият түрәсе булу да, хакимият кәнәфиләрендә утыру да җитми. Моңа

ирешү өчен аларча фидакарьлек, каһарманлыкка тиң әдәби батырлык һәм еллар буе энә белән кое казып тупланган тәҗрибә дә, гыйлемлек тә кирәк шул. Еллар үтәр, әмма егерменче гасыр дәвамында әдәбиятыбызның төп йөген җигелеп тарткан, аның егәр-куәтен билгеләгән олуг әдипләребезнең бай мирасы тоныкланмас, асыл кыйммәте вә бәясе арзанаймас.

Ни кызганыч тоелмасын, азрак яшәде Аяз абый. 2003 елның гыйнвар аенда аңа әле нибары 75 яшь тулган булыр иде. Сиксәнне куып барганда яисә туксанга килеп җиткәндә дә ныклы кул белән, тыгыз фикергә, җете сурәтләүләргә һәм мәгънәле тасвирга бай әсәрләр язып, әдәбият яратучыларны сөендереп яшәгән аксакал әдипләребезне искә төшерсәң азрак тоела икән шул. Аяз абыйның язасы әсәрләре, газиз халкына әйтеп калдырасы байтак фикерләре, шиксез, булгандыр. Шушылай дип язып куйдым да уйга калдым: язучының гомер озынлыгы, бәлки, яшәгән елларының күплеге-саны белән билгеләнми дә торгандыр әле. Бәлки, әдипнең тынгысыз иҗатта янып үткән бер елы да үзенең рухи тыгызлыгы, яшәү мәгънәсенең тирәнлеге белән кайбер кемсәләрнең дистә елларына торадыр. Тукайны мин, мәсәлән, бүген аксакаллы карт итеп, акыл иясе итеп күз алдына китерәм. Якты дөньядан нибары егерме җиденче яшендә китеп барган шагыйрь калдырган бай иҗат әле тагын әллә ничә гасырлар буена милләтебезгә рухи байлык бирергә җитәрлек.

Затлы прозаик, ялкынлы публицист һәм нечкә драматург Аяз Гыйләҗев калдырган рухи мирас та үзенең колачы, фәлсәфи һәм психологик тирәнлеге белән күпләрне таң калдырырлык. Йөзләрчә хикәяләр, дистәләрчә повесть-романнар, утыз дистәгә якын драма әсәре, санап бетергесез тәнкыйть мәкаләләре, ялкынлы публицистика... Ә инде әдипнең көндәлек язмаларын, хатларын да искә алсаң, әдәбият тарихын өйрәнүчеләргә байтак елларга җитәр әле ул. Ләкин хикмәт аларның күплегендә генә түгел. Монда сүз бөек тел остасы, олы художник, адәм баласының катлаулы психологиясен тирән аңлаган философ, чын мәгънәсендә әдип булып өлгергән кешенең мирасы турында бара. Аларны җентекләп өйрәнү, матбугатта бастырып чыгару өчен дә шактый еллар

үтү кирәк булырдыр әле. Чөнки Аяз абый бер генә гаделсезлекне дә күңел күзеннән җиңел үткәреп җибәрми, теле белән әйтмәсә, аларны кайда да булса теркәп калдыру җаен карый иде. Үзе өчен генә яисә варислары өчен генә язган ул көндәлекләрдә һәм хатларда ниләр генә булмас, «очсыз-кырыйсыз күк бит ул» дигәндәй, илле елдан артык тупланган хатирә-мирас, чарасызлыктан гаҗиз булып, тешләрне кысып, кулларыңны йодрыклап йөрәгең бәргәләнеп язган хис-тойгылар концентрациясе бит ул! Чоры шундый иде!

Әйе, чоры шундый иде... Ләкин яшьлек чорында Аяз атлы егетебезнең дә түзә алмаган чаклары булган, күңелендә бикләнеп калырга тиешле сүзләре үз ихтыярыннан башка ташып чыккан, күрәсең. 1986 елда басылган «Совет Татарстаны язучылары» дигән калын зур хезмәтне — библиографик белешмәне карап утырам. «Прозаик һәм драматург Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстан АССР-ның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз классын һәм Сарман урта мәктәбенең унынчы классын тәмамлаганнан соң (1945), берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын ВЛКСМның Зәй районы комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була. 1948–1950 елларда ул — В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенты, ә 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казакъстанда яши һәм төзелештә ташчы, бетон коючы, бригадир һәм десятник профессияләрен үзләштерә. Аннары, яңадан Казанга кайтып, университетта укуын дәвам иттерә».

Чоры шундый иде.

Курсив белән аерып җыелган юлларга кабаттан күз төшерик әле, кадерле укучым! Нинди гади, битараф, садә юллар. Әйтерсең хыялый студент егет, яшьлек романтикасына бирелеп, университетта баш катырып мәшәкатьләнмәскә карар иткән дә, чемоданын тотып, Казакъстан далаларына чыгып киткән. Барысы да бик җиңел һәм рәхәт икән! Әмма эзләнүчән, зиһенле һәм зирәк укучы ул чорларда юл арасында яшерелгән

мәгънәне дә бик тиз тотып ала белә, юл арасында калганнарны укырга аеруча маһирланып беткән иде инде. Белешмәлекне төзүчеләр әнә шул маһирлыкны истә тотып, цензорларны үзләренчә бик оста «алдаганнар» да инде. Менә шушы бер җөмләгә егерме ике яшьлек студент егетнең тоталитаризм чорындагы «Җинаятьләр кодексы»ның дәһшәтле 58 нче маддәсе буенча хөкем ителүе дә, алты елга диярлек сузылган каһәрле каторга газаплары да, җәһәннәмнең җиде катын узуга тиң кара көннәр дә сыйган.
Аяз ага серле кеше иде. Еш кына бер сәбәпсез сүзсез калып, уйларына чумып онытылыр иде. Әйтерсең янында иптәшләре дә, аның бер кәлимә мәгънәле сүзен көтеп колакларын шомрайткан яшь-җилкенчәкләр дә юк. Әйтерсең ул далада япа-ялгызы калган. Менә бераздан ул башын чайкап куяр һәм бераз гына кылтайган, мактанган сыманрак иттереп: «Мин каторжан бит, парин!» — дип куяр. Әмма бу тышкы кыяфәт, «егетләнергә тырышу» артында ни-нәрсәләр ятканын күпләр аңлап та җиткермәгәндер. Каян белеп бетермәк кирәк! Аны без әле соңгы елларда гына бераз төшенә башладык та бугай. Хәер, андый чакларда Аяз абыйның һәрнәрсәгә сынап, җентекләп карый торган уйчан күзләрен моңсулык, әйтеп, аңлатып булмый торган, аны башкалардан аерып куючы ниндидер элпә каплагандай була торган иде. Еллар үтеп, «Йәгез, бер дога!» романын уку бәхетенә ирешкәч кенә, ул «егетлек»нең асыл бәясен чынлап аңладык та шикелле.
Шөкер, татар әдәбияты олпат шәхесләргә, телебезнең нечкәлекләрен үтә сизгер тоемлаучы, һәр кәлимәне асыл мәгънәсен белеп, алтын кысага утыртылган бриллиант кимәленә җиткерә белүче сүз осталарына бай булды. Һәм аларның берсе дип, мин, һич икеләнүсез, Аяз ага Гыйләҗевне күрсәтер идем. Редакциядә шактый озак эшләгән кеше буларак әйтәм: бер биткә сыеп бетмәгәнлектән, еш кына әсәрләрне кыскартырга, бер яки берничә сүзне алып ташларга кирәк була. Корректор яисә техник мөхәррир хәл итә торган гап-гади мәсьәлә бу. Кайбер авторлардан хәтта тулы абзацларны, тулаем-тулаем битләрне алып атсаң да әсәрнең эчтәлегенә зыян килми. Киресенчә, җыйнакланып кына кала әле. Ә менә син тиеп кара Әмирхан Еникигә! Тиеп кара Гомәр

Бәшировка! Кая ул бер бит яки абзац! Аларда бер сүзне дә кыскарта алмыйсың. Чөнки һәр сүз нәкъ үз урынында, һәр сүз янәшәсендәге иптәше белән мәгънәви яктан шулкадәр тыгыз тоташкан, бәйләнгән ки, аны алсаң яисә кыскарак язылышлы башка берәрсе белән алыштырсаң, бөтен җөмләнең, хәтта кайчагында бөтен әсәрнең ямен, бизәген җимерәсең. Менә ул сүз тәмен тою! Менә ул сүзләрнең чын һәм асыл бәһасен белеп куллану! Бу инде гадәти язу түгел, бу — сүзләр дөньясында яшәү, сулау. Аяз Гыйләҗев тә әнә шундый осталардан иде. Техник кыскартулар кирәк булганда корректорларыбыз аз «чиләнмәде» Аяз абый әсәрләре белән. Әмма ул рәхәт «чиләнү», сүз чишмәсенең челтерәп аккан саф агымын тоюдан татлы ләззәт кичерүгә тиң иде. Дөресен әйтим, мин үземне Аяз ага белән күп аралашкан, иҗат йортларында бергәләп сәйран кичергән, фикердәш, әңгәмәдәш вә табындаш булган кешеләрдән дип әйтә алмыйм. Әмма 1986 елдан бирле «Казан утлары» журналында эшләү дәверендә редколлегия утырышларында, теге яки бу әсәр хакында фикер алышканда шактый еш очраша идек. Хәтта бер-ике тапкыр өендә дә булырга туры килде әле. Хәтергә шунысы уелып калган: тикшерелгән һәр мәсьәләгә, һәр әсәргә карата аның анык һәм оешып җиткән үз фикере була. Булсын әдәбият мәйданын тетрәтеп торучы каләм иясе, булсын журналда әле беренче әсәре белән баш төртүче яшь егет — Аяз абый «авторитет»ларга, дәрәҗәләргә карап тормыйча турысын ярып салыр иде.

Соңгы очрашуыбыз, ялгышмасам, 2002 елның февраль ахырында булды. Журналның баш редакторы Равил Фәйзуллин белән аның өенә барган идек без. Аяз абыйның инде байтактан урын өстендә икәнен беләбез, хәлен белеп чыкмакчы идек. Ләкин без килеп кергәч тә ул, әйтерсең эшләп арыган һәм бераз хәл алырга гына яткан кеше шикелле торып утырды, егетләрчә күрешергә кулларын сузды. Ябыккан, нык бетәшкән иде. Әмма керфекләре арасында авыру кеше күзләре түгел, ә бар нәрсәне белергә, аңларга, күрергә омтылучы акыллы күзләр елтырый иде. Үзе хакында ләм-мим. Сорашканы-белешкәне — редакция хәлләре, язучыларның нинди әсәрләр китерүе, кемнең нindiрәк әйбер язып ятуы, әдәбият язмышы, Татарстанның суверенлыгы, халык-

ның киләчәге.

Моңсу һәм хәзер күңел төбендә аерым мәгънәгә ия була барган бу соңгы очрашу мизгелләрен тәфсилләп сурәтләп Аяз абыйның бердәнбере һәм гомер буе тугры юлдашы булган Нәкыя апаның, балаларының күңелен кузгатасым килми. Ләкин шуны аерып әйтәсем килә: гомеренең соңгы сулышына кадәр Аяз абый әдәбият дип, халык дип яшәде. Бер генә көне дә әдәбияттан аерым булмады. «Казан утлары» журналының 2001 елгы декабрь санында аның «Өметләр уята торган әсәр» дип исемләнгән соңгы мәкаләсе басылып чыкты. Язмыштыр инде, ул без фәкыйрегезнең «Бәйсез этләрне атарга» дигән роман-нәсере хакында иде. Үләренә берничә генә ай калганда да аның язганнарында «өмет» сүзенең сүрелмәве үзе генә дә бик күп нәрсә турында сөйли сыман тоела миңа.

Кыска гына мәкаләдә Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Русиянең М.Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, олы һәм катлаулы язмыш иясе, талантлы әдип Аяз ага турында барысын да язып та, иҗатына анализ ясап та булмый. Хәер, минем максатым да ул түгел. Бу язмалар үткен сүзле гаярь әдипнең тууына 75 ел тулыр көннәр алдыннан аны искә алып юксыну, ялгыз калып уйлану гынадыр. Ләкин мин бер нәрсәне анык тоемлыйм: сагынабыз сине, Аяз абый, тирән фәлсәфи әсәрләреңне сагынабыз, редакциягә килеп йөргән көннәреңне юксынабыз.

Әдәбиятка һәм безгә Син кирәк, бик-бик тә нык кирәк идең шул!

«Казан утлары»

№ 2, 2003





ТУФАН МИҢНУЛЛИН

Катлаулы, каршылыклы

талант

Аяз Гыйләҗевнең иҗади мирасын күз карасыдай саклаучы, ул иҗатны нык үҗәтлек белән пропагандалаучы, язучының хәләл җефете Нәкыя Гыйләҗева мәрхүм ире турында истәлекләр китабы әзерли дигәнен ишеткәч, аның миңа да мөрәҗәгать итәсен көтеп йөрдем. Һәм, чыннан да, көннәрдән бер көнне Нәкыя телефоннан шалтыратып:

— Аяз турында язасыңдыр бит инде? — диде. Мин дәшмичәрәк торгач: — Син дә язмагач ни була инде? Сез бит якын кешеләр идегез, гомер буе аралашып яшәдегез, ул сине хөрмәт итә иде, язганнарыңны югары бәяләде, — диде.

Минем боргалап сөйләшүемнән нәтиҗә ясады Нәкыя:

— Әллә язасың килмиме?

— Килми дип әйтә алмыйм. Без замандашларыбыз турында фикерләребезне әйтеп калдырырга тиешбез. Ләкин мин истәлекләр язганда мөмкин кадәр ихлас булырга тырышам. Әмма ихласлыгым бу очракта татарның зур язучысы Аяз Гыйләҗевкә күләгә төшерүе ихтимал. Бу аны да, мине дә бизәмәячәк, — дидем дә күңелемдә йөрткән уйларны Нәкыягә сөйләп бир-

дем. Нәкыя сабыр гына тыңлады,

рәхмәт аңарга. Һәм мине аңлады да

шикелле. Шулай да:

— Уйла әле, — диде.

Ныклап уйладым һәм язарга ки-

рәк дигән фикергә килдем. Ләкин

бик тирәнгә керергә җыенмыйм.

Шәхси мөнәсәбәтләргә дә кагылыр-

га кирәк булмас. Чөнки Аяз Гый-

ләҗев — гаҗәеп талантлы, әмма

катлаулы, каршылыклы шәхес. Мин

үзем дә әүлия түгел. Бик кискен бер

сөйләшүдә үземнән өлкән кешегә:

— Сак бул, Аяз Гыйләҗев, син

усал булсаң, мин дә юаш түгел, мин

— Мәрәтхуҗа малае, — дигән идем.

Миңа, әлбәттә, сабыррак булырга

кирәк иде. Нишләтәсең, кызып кит-

кәндә Аяз үзе дә сүзнең матурын

сайлап тормый иде. Кемгәдер бәя

Нәкыя һәм Аяз Гыйләҗевләр Зәйдәге йортларында. 1997

биргәндә чиктән чиккә ташлану да аның холкында иде. Бервакыт ул шагыйрь Равил Фәйзуллинны күккә чөеп мактады. Тукайдан кала татарның иң бөек шагыйре дигән сүзләр ычкындырды. Күп тә үтмәде, Равилне эт итеп сүгеп, җиргә салып таптады. Без аның бу сәер гадәтен бүген дә искә төшереп, көлебрәк сөйләшәбез. Ул озын итеп язучыларга хатлар язарга ярата иде. Бүген ул хатларның кайберләре матбугатта басы-ла. Аларда да каләмдәшләренә биргән бәясе урыны-урыны белән үтә кискен, аяусыз.

Аяз Гыйләҗев миннән җиде яшькә өлкән булса да, аңа абый дип эндәшмәдем. Үзе шулай кушкан иде. Якыннар идек бит. Әдәбиятка аяк баскан көннәремдә ул Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Альберт Яхин белән бергә янымда булды. Табынынннан калдырмады. Марсель Сәлимҗанов белән дустанә мөнәсәбәттә иде ул. Мин дә алар янына өченче кеше булып кушылдым. Мин әдәбиятта, театрда ныклап торып аякка баскач, премияләр ала башлагач, Язучылар берлегенең рәисе булып та сайлангач, Аяз үзгәрде. Кем белә, бәлки, үзем дә үзгәргәнмендер. Олыларга тагылып йөрүче малайлыктан чыгып, егет буласым килгәндер. Хәерле булсын. Әмма шунысы хак — Аяз Гыйләҗев һәрвакыт минем өчен зур язучы булды. Һәм ул фикерем бүген дә үзгәрмәде. Ул үзгәрә дә алмый. Татар әдәбиятында аның урыны билгеләнгән. Шуңа күрә мин аның иҗатына кагылышлы сүз әйтүне артык дип саныйм.

Әйтәсе сүзем — Аязның гаилә башлыгы буларак та талантлы әти булуы турында. Мин гомер буе аның бу сыйфатына сокландым. Ул — өч ир баланың атасы. Шуны әйтүгә үк, һәрвакыт акчага мохтаҗ татар язучысының хәле һәрберебезгә аңлашыла. Аяз каләм көче белән эшләп тапкан хәләл акчага аларны үстерде. Чын татар балалары итеп тәрбияләде. Әлбәттә, аның янында Нәкыясе һәм Нәкыянең үтә дә сизгер әнисе бар иде. Ләкин Аяз, чын ир кеше булып, гаилә иминлегенең сагында торды.

— Минем малайлар бик күп татарлар кебек мокыт булмаска тиешләр, үз кадерләрен белергә тиешләр, — дия иде ул.

Балаларын — Искәндәр белән Мансурны — театрга ияләштерде. Соңрак төпчек улы Рәшатны ияртте. Алар татар теленең тәмен белеп үстеләр. Ялгышмасам, алар өчесе дә театрның кайбер спектакльләрен яттан беләләр иде. Өйләрендә мәҗлес-фәлән булса, малайларын табын янына чакырып ала иде дә балаларына:

— Менә күрегез, болар — татарның затлы кешеләре, ныклап карагыз, аларны таныгыз, аларны олыларга өйрәнегез, — дип безне мактый иде.

Ә бит шактый татар язучыларының балалары татарча рәтле-җүнле җөмлә дә төзи белмиләр. Шул язучылар әле җитмәсә татар, татар дип сөйләргә яраталар иде. Иде

дим, чөнки бүгенге яшьрәк язучыларның балаларын белмим, бәлки, алар татарча бик шәп сөйләшәләрдер.

Малайлары белән горурланды Аяз. Очар кошлар үз балаларын очарга өйрәткән шикелле, тормышта югалып калмаска, кешеләр арасында кеше булырга өйрәтте ул. Өчесенең холкы өч төрле булса да, өчесендә дә аларның әтиләре сыйфаты — өчесе дә үҗәтләр. Искәндәр карап торырга юаш булып күренә. Ләкин ул юашлык түгел, сабырлык. Төптән уйлап бетермичә сүзен әйтмәс. (Аязга шул сыйфат җитешеп бетми иде.) Белеме — төпле. Бик яшь килеш галим булды, бүген ул фәннәр докторы, Казан дәүләт университетының факультет җитәкчесе. Мин аны аеруча хөрмәт итәм. Чын татар галиме дип саныйм. Искәндәр — Аязның иң затлы дәвамчысы.

Мансур — Аязның уртанчы улы. Ул, әтисе юлыннан китеп, әдәбият дөньясында яши. Шактый драма әсәрләре язып, алар күп театрларда уңыш белән баралар. Итагатьле егет. Мин аңа чын күңелемнән уңышлар телим.

Аязның төпчеге — бәләкәче — Рәшат, бизнес белән шөгыльләнә. Бу бер дә очраклы түгел, Аяз үзе дә хуҗалыклы кеше иде — акчаны таба белде, тапканын саный белде. Кайбер ирләр кебек мескенләнеп балаларына фатир сорап түрәләр алдына ялынып бармады. Өч малаен да үз акчасына фатирлы итеп фани дөнья белән хушлашты. Мин үзем татар шундый булырга тиеш дип саныйм. Һәм Аяз Гыйләҗев турында уйланганда, аның иҗади мирасына тиң итеп ул тәрбияләп калдырган балаларын искә алам.



* * *

Ә инде Аяз белән булган кызыклы манзараларга килгәндә, алар шактый булды. Шуларның берсен аның турындагы китапка теркәп калдырырга кирәктер.

«Руза» дип аталган иҗат йортында үткәрелгән драматургларның Бөтенсоюз семинарында Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»е һәм минем «Ат карагы»м макталды. РСФСР Мәдәният министрлыгы (СССРныкы бугай әле) вәкилләре, безнең белән килешү төзеп, безнең пьесаларны сатып алырга һәм урысчага тәрҗемә итәргә вәгъдә бирделәр.

Семинарга нәтиҗә ясаган җыелышта без түшләребезне киереп утырдык. Ул хәтле мактауга ничек тыйнак булып утырасың инде?!

Семинар бетеп, Мәскәүгә кайткач та, үз бәябезне белеп кенә, «Украина» кунакханәсенең уналтынчы катындагы ындыр табагы хәтле бер номерына урнаштык. Тәрәзәне ачып, уналтынчы каттан Мәскәү өстенә карадык. Аяз ике кулын кесәсенә тыгып, башын чөеп торды да:

— Мәскәү безнеке! — диде.

— Безнеке, — дип кабатладым мин.

— Моны юарга кирәк, — диде Аяз.

— Кирәк, — дидем мин.

Киттек ВААПка. ВААП ул — авторларның хокукын һәм драматургларның театрдан килгән акчаларын саклау урыны.

Бәхеткә күрә, ВААПта безнең счетларда акча шактый иде. Кесә тутырып акча алдык.

— Киттек ЦДЛга! — диде Аяз.

— Киттек, — дидем.

ЦДЛ дигәне — Язучылар йорты. Аның бик кәттә рестораны бар. Без нәкъ менә шунда типтерергә үзебезне лаеклы дип санадык.

Сулдан — Мансур, Рәшат, Искәндәр. 1970

Бик шәплəп сыйландык. Аяз рестораndагы аракы белән генә юанучы язучы-голәмгә җирәнеп кенә карады. Чөнки без иң кыйммәтле әрмән коньягын гына авыз итеп утырдык.

— Шулай ул татар малайлары! — диде Аяз.

— Шулай, — дидем мин.

Як-якка мыскыллы караш ташлап, рестораннан чыктык. Каршыга без белгән бер Мәскәү драматургы очрады. Мәскәү гадәте буенча, безне бераз гына талап калмакчы була бу. Безне күккә чөеп мактый. Без язганнарны тәрҗемә итеп, Мәскәү театрларында куйдырмакчы. Без икебез дә мыек астыннан гына елмаеп тыңлыйбыз. Чөнки икебез дә беләбез — тәрҗемәләрен түгел, үзе язганнарын да Мәскәүдә куймыйлар, провинциаль театрларда гына куела.

— Бездән эчәргә чамалый, — диде Аяз, татарчалап, — әйдә, күңеле булсын урысның, исерткәнче сыйлыйк әле үзен. Безне мокытларга саный, күрсәтик әле мокытлыкны.

Буфетка алып кереп эчерттек без моны. Күп эчте. Исерми. Мәскәүне эчереп исертеп буламы инде? Исермәсә дә, күп сөйләнә башлады. Мәгънәсез сүзләре белән туйдырды.

Бу юлы «киттек»не мин әйттем.

Тегенең бездән аерылырга исәбе юк. Бушка бездән башка Мәскәүдә кем эчерә аны! Теләнә торгач, безнең кайда урнашканыбызны белде.

— Бәлки әле кызлар белән дә килермен, — дип калды.

Бик озак буталып йөрдек Мәскәүдә. «Наполеон» дип аталган коньяклар сатып алдык. Куна тактасы зурлыгындагы «Бабаевский» дигән шоколадлар төяп, «Украина»га кайттык. «Өч аршын җир» һәм «Ат карагы»н язган драматурглар иң затлы нәрсә эчеп, иң затлы нәрсәләр белән генә закусить итәргә тиеш ләбаса.

Кунакханә номерында «Наполеон» капкалап рәхәтләндек кенә мактанып. Дөресен

әйтергә кирәк, үзебезне генә мактамадык. Татарны мактадык! Татар малайлары төшеп калган түгел алар, дип, тагын бер тапкыр Мәскәү өстенә карап әтәчләндек. Җырлап алдык, биеп тә җибәрдек. Шул арада өстәл өстендә җәелеп яткан шоколадтан кисәкләр сындырып алып кына кабабыз.

Мин үзем хәтерләмим, Аязның әйтүе буенча, мин әле өч тәңкәлекләрдән карга ясап форточкадан Мәскәү өстенә дә очырткан мын. (Хәерче баеса, шулай була бит ул.)

Караңгы капкач, үтә дә чибәр бер ханымны ияртеп, теге драматург килеп керде. Икебез дә ханымны күреп, әсәрләнеп, гипнозланып калдык. Драматургның барлыгын да онытып, икәүләп ханым тирәсендә бөтерелдек. Ханым, үз кадерен үзе белеп кенә, нәзакәтле елмаеп, өстәл янына утырды.

Теге драматург өстәл өстендәге байлыкның ияләре үзенең дуслары икәнлеген ханымга аңлатты. Портфеленнән кәкрәеп беткән ике тозлы кыяр чыгарып өстәл өстенә куйды — бусы аның зур ялгышлыгы иде.

— Бик шәп закуска, — диде.

Шуннан китте кураж. Миннән бик күпкә тәҗрибәлерәк Аяз сүзләрнең әллә ниндиләрен сайлап сайрады. Ханымны оста итеп мактады. Бу, әлбәттә, теге драматургка ошады. Ханымның иңбашына кулын салып:

— Ну, как моя Нинуленька? — диде.

Әйтүенә карап, Нинуленьканың драматургка хатын түгеллеген төшендек.

— Әйдә моның марҗасын тартып алабыз, — диде Аяз. Һәм тотындык эшкә.

Безнең кемнәр булуыбызны белергә чамалап утырган ханым бераз коньяк кабып алгач сөйләшә башлады, әмма вульгарлыкның эзе дә юк. Үз дәрәҗәсен белә. Без дә сынатмаска тырышабыз.

«Наполеон»ны чөмереп калырга тырышкан мәскәүский драматург утыра-утыра җеби башлады. Без ипле утырабыз. Ханым моны сизенә. Уңайсызланып, теге драматургның мәгънәсез сүзе саен кызарып та куя шикелле. Очына-очына Аяз иң югары дәрәҗәгә

менеп җитте, экстазга бирелеп, теге ханымга күрсәтебрәк ике тозлы кыярның берсен



чеметеп кенә тотып, чүп савы-
тына ыргытты. Икенче кыярны
чүп савытына мин озаттым.
Ханым кем белән кемнәр
янына эләккәнен тәмам аңла-
ды. Мәскәүский драматургтан
читкәрәк китеп, безгә якынрак
елышып утырды. Без салган
коньякны эчми башлады.
Мәскәүский драматург
урыныннан торып, алпан-тил-
пән килеп номер буйлап йөр-
де.
— Каковы мои друзья! —
дип мактанды.
Нинуленькасын кочакларга
теләп ханым өстенә иелгән иде,
ханым чалт моның яңагына.
Торып басты да уңлап-суллап
яңаклады тегене. Аннан:
— Идиот! — диде дә тиз-
тиз генә киенеп чыгып китте.
Без сүз әйтергә дә өлгерә ал-
мадык.
Мәскәүский драматургны
үзебез куып чыгардык. Куыл-
ганын аңламады ул, әлбәттә.

Аннары караватларга аудык та
аякларны селкеп-селкеп, буы-
ла-буыла көлдек.

— Шулай ул татар малай-
лары! — дип кычкырды Аяз.

— Безнең кулга эләксәң,
шулай була ул, — дип мин үкердем.

Иртәгесен хәлләр хәл иде инде. Анысы һәркемгә мәгълүм.

Ә безнең шатлыкның сәбәпчеләре булган пьесаларның язмышы махмырдан да кыз-
ганычрак булды. Аларны куйдырмадылар: Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»ен —
кулакны мактаганы өчен, минем «Ат карагы»н — ат карагына мәхәббәтле карашым
өчен. Казан обкомының сүзенә Мәскәү министрлыгы каршы килмәде, этлек эшләгән-
дә Казанның сүзенә дә колак сала иде Мәскәү.

Ярый инде, хәерле булсын. Аның каравы бер типтереп калдык. Хәзер менә сагы-
нып искә алып утырам.

Гыйнвар, 2006

Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллин. 1980



МӨХӘММӘТ МИРЗА

## Аяз Гыйләҗев — үз-үзен аямаган язучы

Иң яраткан язучың кем? дип сорасалар, кайчакта җавапсыз да каласың... Ничек итеп инде бер генә язучының исемен атамак кирәк? Шөкер, безнең буын китаплы чорга туры килде... Үзебезнең язучы-шагыйрьләребезнең китапларын да, урыс теленнән һәм башка телләрдән тәрҗемә ителгән китапларны да сабакташларыбыз белән ярыша-ярыша, чиратлап укып үскән буын инде без. Тоташтан һәр әсәрне укып та бармаганбыздыр, ләкин кайсы язучының әсәрләренә һәрвакыт игътибарлырак булырга, аның әсәрләрендәге мәгънәви киңлеккә тартылу халәте сеңгән иде безгә. Язучының әсәрен укыйсың, ошатасың, китап киштәндәге тиңдәшләре янәшәсенә урнаштырасың да янәдән кайтып укырга алынмыйсың. Китапны кабат-кабат укыйсы килү дигән нәрсә бар бит әле.
Чыннан да, аеруча кемне яратып укыдык икән? Андый язучылар берничә генә... Берсен әйтсәм, берсе кала, шуңа күрә бу очракта мин Аяз абый Гыйләҗевкә генә тукталып узасым килә.
Аяз абый Гыйләҗев! Менә кемнең барлык басылган китапларын укып барганмын да һәм кайберләрен, кабат кулыма алып, өр-яңадан укып чыкканмын икән... Аяз Гыйләҗев иҗаты турында күп язылды. Әмма, еллар үткән саен, аның иҗатының әһәмияте арткannan-арта гына барыр. Чыннан да, аның әсәрләре — тормышның үзе кебек үк бик

тә катлаулы, гыйбрәтле. Аяз абый әсәрләрендәге каһарманнарның язмышы һичкемне дә битараф калдырмый. Чөнки аның каһарманнары да, безнең белән янәшә йөрүче, тормышның төрле өлкәләрендәге үзгәрешләрнең, борылышларның сәбәпчеләре булып укучыны үзенә җәлеп итеп мавыктыралар. Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар», «Әтәч менгән читәнгә», «Йәгез, бер дога!», «Балта кем кулында?», «Яра», «Мостафа» кебек роман-повестьларын укып кемнәр генә тетрәнмәгәндер. Никадәр күңелләрне гыйбрәтле язмышлар үрнәге аша тәрбияләнергә мәҗбүр иткән язучы ич ул — Аяз Гыйләҗев.

Аяз Гыйләҗевне тормыш үзе аямаган кебек (ГУЛАГ тормышын үткән булганга шулай уйлавым), ул үзе дә каһарманнарын үзләре яшәгән тормышның барлык михнәтләре һәм рәхәтлекләрендә сыный, чыныктыра. Аяз Гыйләҗевнең каһарманнары уңай һәм тискәрегә, ак белән карага гына бүленми. Алар үзләре яшәгән җәмгыятьнең язылган һәм язылмаган кануннары, әхлак шартларында яшәү, тормыш итү өчен көрәшәләр. Аяз Гыйләҗевнең «Мостафа» повестен укыгач, мин тетрәндем. Шигырь үзеннән-үзе минем күңелемдә туды.

Һәр төбәкнең Муллины
утызынчы елларда
ярлы-гидай һәр мужик:
— Мин җирле, — дип торганда,
өмет сабын сындырып,
кылыч бирде кулларга:
— Туганыңны чак, — диде,
— Туганыңны чап, — диде...
Төгәл-кырыс кулланма...



һәр төбәкнең Мостафасы
утызынчы елларда
халыкның каш-күз арасын
ядрә белән ерганда,
юылды уелган җаннар,
чи ит белән буталып,
сузылды утлы еландай
оешкан кан тутыгы,
Черек күлне тутырып...
Мостафаның, Муллинның
оныклары туганда,
бабалары кулланмасын
өлге итеп куйганда,
оешкан кан тутыгына
күбәләкләр кунганда,
Черек күлнең аръягында
кызарып Ай тулганда,
сискәнеп тартылды ХӘТЕР...


Аяз Гыйләҗевнең әсәрләре, чыннан да, кискен драматик мохит шартларына корылган. Аның әсәрләрендә геройларының эчке хис-кичерешләре дә, үзара мөнәсәбәтләре дә, һәм шәхеснең үзе яшәгән җәмгыять белән мөнәсәбәтләре шулкадәр тормышның үзеннән алынганнар ки, һәр китап укучы ул әсәрләрдә үз җирлегенә таныш мохитне, үз җирлегенең таныш кешеләрен һәм үзенә таныш хис-кичерешләрне тоя. Автор аларның тормышы белән яши, елый, җырлый, көлә, сөенә, сүгә. Мондый кискен хис борылышларына үзен-үзе аямаган фидакарьләр генә түзә аладыр. Шул ук вакытта әдип үзенең геройларына-каһарманнарына ярдәм итәргә, аларның язмышына теләктәшлек күрсәтеп, булышырга тырыша. Аяз Гыйләҗевнең бу омтылышы китап

укучыларга да күчми калмый. Шуңадыр, бәлки, аның әсәрләрен кат-кат кулга алып укыйсы киләдер...

Инде ул яшәп иҗат иткән дәһшәтле, шаукымлы, вәхшәтле һәм шанлы дәвер — XX гасыр тарихка күчте. Шул гасыр эчендә кешелек тарихындагы коточкыч вакыйгаларның шаһиты һәм елъязмачысы, кабатланмас талант иясе, олуг язучыбыз Аяз ага Гыйләҗев шәхесе үзе үк тирәнтен өйрәнелергә һәм фәнни, документаль һәм нәфис әдәбиятыбызның имән баганасы булырга лаек...

20 октябрь, 2005

Аяз Гыйләҗевкә 70 яшь тулган көннәр. 1998



РАФАЭЛЬ МОСТАФИН

Сүзләр әйтелми калды

...Күптәннән авырып ятканын, урынга калганын белсәк тә, үлем хәбәре барыбер аяз көнне яшен суккан сыман булды. Үзе исән чакта әйтелергә тиешле сүзләр әйтелми калды. Соң булса да, әйтми калып булмый...

1995 елның гыйнварында Аяз Гыйләҗев миңа үзенең яңа гына нәшрият тарафыннан чыгарылган дүрт томлык әсәрләрен бүләк итте. Беренче китапның чиста битенә ул мондый автограф язып калдырды:

«Рафаэль!

Менә — утыз биш еллык тоташ хезмәтемнең бер өлеше. Газаплы, татлы йокыларны калдырган, мине берөзлексез тәртә арасында тоткан хезмәтемнең җимешләре... Тәнкыйтьчеләр — сәер халык, арадан бик сирәкләре генә яшел җимешләр яралганын күреп, җимешләр пешеп өлгергәч нинди булачагын юрый ала. Минем кем икәнлегемне, иҗат биеклегемне, үз юлымнан тайпылмавымны шәйләгәнсеңдерме, юкмы, белмим. Ә үзең анык кына бер чакта да әйтмәдең. Болай сиңа хөрмәтем чиксез зур. Кеше син! 31 гыйнвар, 95 нче ел. АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ. Казан».

Минем Аяз Гыйләҗев белән беренче күрешүем 1949 елны Казан дәүләт университетына укырга килгәч булды. Мин — беренче, Аяз икенче курста укый идек. Тәбәнәгрәк буйлы, базык гәүдәле, имән төбе кебек нык егет бер күрүдә үк үзенең түгәрәк күзлек пыялалары артындагы акыллы, үткер күз карашы белән җәлеп итте. Үз-үзенә бик нык ышанган, зур максатларга омтылучы, сәләтле кеше иде ул. Башка укучылар лекция белән генә канәгатьләнсәләр, ул исә профессорлар биргән белем белән чик-

ләнмичә, кич саен диярлек китапханәләрдә казына иде. Тыелган, ул вакытта «халык дошманнары» дип исәпләнгән язучылар — Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан әсәрләрен әллә каян табып, аларны җентекләп өйрәнеп, алар турында үз фикерләрен туплый иде.

Әлбәттә, мондый «башбаштаклык» ул чорда җәзасыз калмый. Кемдер «чаккан», күрәсең. 1950 елның мартында Аязның ятагы көтмәгәндә-уйламаганда бушап кала. Аның белән бер чорда Мәҗит Рафиковны, Гурий Тавлинны, тагы берничә кешене кулга алалар. Бу — ул чорның иң өметле, иң сәләтле, башкалардан бер башка өстен яшь талант әһелләре иде...

Казанга Аяз биш елдан соң гына — шактый олыгаеп, җитдиләнеп, ләкин мин-минлеген һәм үз-үзенә ышануын һичбер югалтмыйча кайтты. Университетта укуын дәвам итте һәм җаны-тәне белән иҗат эшенә бирелде, язучылык ләззәтенә чумды. Юк, лагерьда үткән вакытын каһәрләмәде, беркемгә дә үч сакламады. Хәтта хәятының соңгы көннәрендә дә: «Мин гомеремнең иң авыр елларын да сагынам», — дип язды. (Аның белән үткәргән әңгәмәне кара: «Татарстан», 2001, 9 нчы сан.)

Әле аннан соң да Аязга шактый катлаулы тормыш һәм иҗат сынаулары үтәргә туры килде. Шулай да ул иң авыр, иң кыен чакларда да төшенкелеккә бирелмәде, сынауларны бөгелмичә-сыгылмыйча узды, усал тәнкыйтьчеләргә дә, обком «күкеләренә» дә бил бирмәде.

Нәрсә соң аңа шундый көч бирде? Аның кыйбласын ачыкларга теләп, «Йөгез, бер дога!» исемле әсәрен ачып карыйк.

«Әдәбият нигезендә миллилек ята. Милли булмаган әдәбият — фальсификация ул. Әгәр язучы татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән — ул инде татар әдибе түгел».

Бу сүзләрдә, минемчә, Аяз Гыйләҗев иҗатының төп мәгънәсе, рухи көченең сере.

Әйе, ул чын мәгънәсендә татар әдибе, татар халкын тирәнтен аңлаган, аның турында чын күңеленнән кайгырган, янган-көйгән язучы. Миллилек ягыннан аны үзе чиксез

ихтирам иткән Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев белән янәшә куеп була.
Юк, ул халыкны мактап, аның алдында тезләнеп эш итми. Алай гына да түгел, кискен тәнкыйть итә: «Татар халкы соңгы вакытта аракы белән телевизорга сатылды», — дип яза.
«Мин бераз төшенкерәк күңелле кеше», — дип әйткән иде ул үзе турында. Әсәрләрендә дә ул күбрәк кайгы-хәсрәт, татар халкына тарих китергән бәла-казалар турында язды. Төрмә дә аның өчен үзенә күрә бер мәктәп булды. «Ул минем күземне ачты, тормышның ни икәнен аңлатты», — дигән иде ул югарыда телгә алынган интервьюсында.
«Йөгез, бер дога!» әсәреннән тагын бер өзек китерәсе килә. «Милләтнең иң зур байлыгы — хәтер. Уртак хәтерсез милләтләр, милләт булудан туктап, гавам, халык төркеменә әйләнәләр... Милли хәтер бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала һәм буыннар дисбесенең бөтенлеген, тулылыгын саклый...»
Хәтерне исә кем саклый? Матур әдәбиятның әһәмияте бу яктан искиткеч зур. Әдәби әсәр тарихи хәтерне образлы, тәэсирле рәвештә гәүдәләндерә, күңелләрдә тирән эз калдырырлык итеп тасвирлый.
Кайвакыт Аяз Гыйләҗевне уңай геройларның булмавында гаепләделәр. Янәсе, ул тормышның гел кире якларын гына тасвирлый, кара буяулар белән генә мавыга. Әйе, язучы тормышның авыр, хәтта куркыныч якларын бик ачык һәм тәэсирле итеп күрсәтте. Үз мәнфәгатен генә кайгыртучыларны, халык байлыгын туздыручыларны, кулга балта тотып башкаларга көн күрсәтмәүчеләрне нәфрәт белән тасвирлады. Карьера артыннан куучыларны, җыен торгашларны, җинаятьчеләрне җене сөйми иде.
Әмма шул ук вакытта аның әсәрләрендә төп урынны гади хезмәт кешеләре алып тора. Исхак белән Тәнзилә, Мирвәли белән Шәмсегаян, Җәүдәт белән Мөзәкир, Нәҗип белән Наилә, Арзу белән Хәбибрахман карт — болар барысы да саф күңелле, туры сүзле, тыйнак кешеләр. Алар чын мәгънәсендә уңай геройлар. Шул ук вакытта алар ниндидер дәрәҗәдә социалистик системаның корбаннары да.

Аяз Гыйләҗевнең колачы шактый киң булды. Без аны беренче чиратта күренекле прозаик буларак ихтирам итәбез. Ләкин шул ук вакытта ул үзенчәлекле драматург та (кырыклап пьеса авторы), үткен каләмле публицист һәм журналист, таләпчән, ә кай-вакыт усал телле тәнкыйтьче дә. Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин аның күпкырлы иҗа-тын җирдән бәреп чыккан кайнар чишмә белән чагыштырган иде.

Шулай да аның иҗатында иң зур һәм күренекле урынны повестьлар алып тора.

Тема, проблема ягыннан алар төрле-төрле булса да, барысы өчен дә уртак булган сый-фаты шул: алар әзер штамплардан, соцреализм кысаларыннан азат. Моны «Өч аршын җир», «Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн, кич белән...», «Язгы кәрваннар», «Яра» һ.б. әсәрләрендә дә күрергә була.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: А.Гыйләҗев повесть-романнарының лирик агымы бик көчле. Язучы шактый нечкә психологик детальләр, бай, җор, халыкчан тел, үзен-чәлекле сурәтләү алымнары белән эш итә. Әсәрләренең күпчелеге авыл тормышына ба-гышланган. Аларда әхлак, тәрбия мәсьәләләре, мәхәббәт-гаилә, намус-вөҗдан каршын-да җаваплылык, яшәүнең мәгънәсе һәм максаты, яхшы белән яманның көрәше кискен драматик вакыйгалар, тирән психологик конфликтлар, бәрелешләр аша яктыртыла. Тоталитар режимның иң авыр, цензураның рәхимсез котырынган елларында да ул халыкка туры сүз, хакыйкать сүзен алып килде, дөреслекне яклады. Шуңа да аның әсәрләре әле бик озак яшәр, автор үзе дә әдәбиятыбызда якты эз калдырган әдип буларак хөрмәт ителер.

Март, 2002



ИБРАҺИМ НУРУЛЛИН

Шулай, брат...*

Аяз!

Синең хатны алганның икенче көнендә сиңа
хат язарга утырдым. Хатың, әгәр ул чын йөрәк-
тән чыккан булса, бик әйбәт хат. Синдә вакыт-
вакыт несерьезностьлар булгалауга карамастан,
минем бу хатның эчкерсезлегенә ышанасым ки-
лә. Мин хәзер синең белән Лобачевский бакча-
сы чатында сөйләшеп торган минутларны хәте-
ремә китерәм. Анда син чын йөрәктән сөйләш-
кән идең.

Әйе, мин синең «искиткеч начар кеше» икән-
легеңне сизә идем, инде тәмам аңладым. Шулай
булса да сиңа яхшылык итәсе килә, ярдәмләшә-
се килә.

Как тебе быть? Минемчә, сиңа коллективка
керергә кирәк. Мин бу җөмләне механический
гына аңламыйм. Кеше кешеләр белән панибратс-
кий булырга мөмкин, ләкин коллективта бул-
маска мөмкин. Минемчә, иң бәхетле кеше аңы
белән генә түгел, ә бөтен йөрәге белән, җаны-тәне белән коллектив интересларын
шәхси интересыннан өстен куя ала торган кешеләр. «Куя ала торган кешеләр» дип
әйтү дөрес булмас. Мондый кешеләргә карата болай әйтү артык, чөнки алар өчен шәх-
си һәм коллектив интересларына бүленеш юк. Бу кеше иптәшләрен, коллективны,
илне, халыкны сөя икән, ул алар өчен хезмәт итәргә омтыла. Әгәр хәленнән килгәнне
эшли алса, ул сөенәчәк, әгәр эшли алмаса, ул борчыла. Димәк, бәхетле булу өчен

икенче нәрсә — ул эш сөю.

Шулай итеп сиңа юл: коллективка керү, коллектив интереслары белән яшәргә өй-

рәнү, гомумән, эш өчен яну — тәрбияләнү. Ләкин болай яну өчен нәрсәне булса да

чын күңелдән яратырга кирәк, ниндидер маягың «идеал уты»ң булырга кирәк. Ул «и-

деал уты» — халыклар бәхете, халыкны, кешеләрне чын күңелдән яратырга кирәк.

«Идеал уты»ң шушы халыкларның бәхете — коммунизм булырга тиеш. Шушы сый-

фатлар тәрбияләнә алса, кеше бәхетле була ала.

Нинди юл белән моны эшләргә мөмкин соң? Монда рецепт биреп булмый. Нинди

теләкләрең бар, күңелең кайсы якка таба карый? Минемчә, укырга кирәк. Гомумән,

укырга һәм мәктәпкә кереп укырга. Марксизм-ленинизм тәгълиматын гомумән йөрә-

гең белән аңламый торып югарыдагы сыйфатлар сиңа килмәсләр.

Хәзерләнергә кирәк. Киләсе елга университетка керергә кирәк (рус бүлегенәме,

татар бүлегенәме — барыбер). Безнең коллектив белән аралашырга кирәк, җәмәгать

эше алып бик добросовестно эшләргә кирәк һ.б.

Ә бит син безнең коллектив кебек коллективны кулыңа шәм тотып эзләсәң дә таба

алмыйсың. Фасеев, Гайнанов, Мәҗитов, Тимергалин һ.б. кебек кешеләр, алар алтын

* Аяз 1945 елда, Сарман урта мәктәбен тәмамлаганлыкка документ алганнан соң, университетка

укырга килгән. Андагы уку шартларының гаҗәп тә авыр булуын күтәрә алмыйча (ачлык, кием-салым на-

чар), ул ташлап кайтып киткән дип беләм. Зәйгә кайтып комсомол эшендә эшләгән. Анда кайткач, монда

калган студент дуслары белән хат алышып та торган. Шуларның берсе — Ибраһим Нуруллиннан алынган

хат. (Нәкыя Гыйләҗева искәрмәсе.)



кешеләр бит. Аларның күңелләрендә бер-берсенә карата аз гына булса да кер юк бит. Алар туктаусыз укыйлар, өйрәнәләр. Укымый, өйрәнми, туктаусыз алга бармый, минемчә, тормыш юк. Гайнановның шигыре «Совет әдәбияты»нда басылачак. Гомумән, ул бик нык үсте. Мәҗитов шигырьләре дә басылу тирәсендә. Фасеев, гаҗәп көчле эш язып, конкурста өченче премияне алды (200 сум). Галимҗанова ито диалектологик словарь төзүдә катнаша.

Син хәзер безнең иптәшләрнең әдәбият турында фикер йөртүләрен күрсәң иде.

Менә, Аяз, шундый хәлләр.

Ә синең әдәбиятка «кул селтәвеңә» мин болай карыйм. Беренчедән, мин синең язмавыңа ышанасым килми. Икенчедән, син язарга тиешсең. Шигырь, хикәя язучылар күп, ләкин бик азы гына язучы булып китәләр. Бары тырышлары, ихтыяр көченә ия булганнары гына язучы булып китәләр. Бит язучылык эше «каторжный труд». Язучы булыр өчен 1) белем, 2) ниндидер бер художественный вкус, 3) фантазия, 4) күзәтүчәнлек, 5) телне бик, бик яхшы белү кирәк. Синдә (4), (5), (3), (2) бар. (2) бар, чөнки син күп укыгансың, мондый вкус классикларны уку белән генә туа ала. Тел синдә бай, ләкин шушы тел байлыгын кирәкле урында куллана белергә генә кирәк. Күзәтүчәнлек турында әйтмим дә инде. Нәрсә җитми соң? Системалы белем җитми.


Бәлки, син, именно шушы юлларның язылуын көткәнсеңдер. Теләсә ни булсын, мин үз фикеремне әйтәм.

Шулай, брат, әйдә кил, укы. Бергә эшләрбез.

Бик бутап яздым. Чөнки уйлап торырга вакыт юк. Урак өсте. Хат көтәм. Ибраһим.

18.12.47.

Язучылар берлеге бакчасында Аяз Гыйләҗев белән Мөхәммәт Мәһдиев (сулда). 1993





ГӘРӘЙ РӘХИМ

«Урамнар артында яшел болын»

Урамнар артында яшел болын,
Аранны кимерә яшь колын.
Аранда тилмерә яшь колын:
«Урамнар артында яшел болын...
Урамнар артында яшел болын...»
Авылда көнозын бер аваз:
Тук та тук гел чалгы чүкиләр.
Абзыйлар, колынны онытып,
Көнкүреш бурычын үтиләр.
Яшь кызлар июньдәй көләчләр,
Урамнан узалар фырт кына.
Кызларга июньнән дәрт кирәк,
Колының кирәкме чуртыма!
Чирәмдә чал чәчле бер бабай,
Колынын, болынын онытып,
Тагын бер өч елга җитсен дип,
Нур җыя кояшка йөз тотып.
Авылда көләч бер көй —
Кешеләр җырлыйлар җәй җырын:
«Урамнар ар-тын-да я-шел бо-о-о-лын...»
Җыр тынган арада каяндыр
Дөп тә дөп бер аваз ишетелә.
Бу шулай аранда яшь колын
Аягын канатып тибенә.
Тибенә, әйтергә теле юк.

Аранны кимерә яшь колын.

Нишләсен, әйтергә теле юк:

«Урамнар артында яшел болын,

Урамнар артында яшел болын...»

1974



ХӘСӘН САРЬЯН

Тормышны раслау

Аяз Гыйләҗевнең беренче китабы 1960 елда чыкты. «Яшьлек юлларында» дип аталган юка гына бер китап иде ул. Әмма ләкин, беренче китапка хас кимчелекләре булуга карамастан, анда барыбер бүгенге җитлеккән язучы — художник Аяз Гыйләҗевнең инде сизелеп торган чалымнары бар иде. Тәкъдирдә шулай язылгандыр, ул китабы «яшьлек юлларында» калды, ләкин эзсез югалмады: ул татар әдәбиятына Аяз Гыйләҗев дигән бер язучы килгәнлеген хәбәр итте.

Шулай да, миңа калса, Аяз Гыйләҗевне ЯЗУЧЫ итеп таныткан беренче әсәре «Үги ана яфраклары» дигән егерме генә битлек хикәясе булды. Бу хикәядә бернинди ялган юк, уйдырма юк; авторның һәр сүзе самими, шул сүзләрдән ул, чын тормыш дөреслегенә һич тә хилаф китермәстән, икенче бер тормыш төзеп куйган. Анда нибары алты кеше яши: каравылчы Мифтахетдин, йөкче Хәнәфи, председатель Шәйхулла, шофер Ибраһим, шофер Галимҗан һәм сөйгәне Сөмәя. Бу алтауның хикәя мәйданында билгән җирләре — төрлесенең төрлечә: бер генә биттә күренеп киткәннәре дә бар, ләкин һәркайсысы күз алдына килә дә баса.

Хикәянең баш герое Галимҗан соңгы рейстан соң сөеп йөргән кызы Сөмәягә кыр чәчәкләре алып кайтырга, шул кичне беренче кабат мәхәббәтен дә әйтергә ниятләп куйган була. Ләкин шул көнне аны колхоз председателе төнгә каршы мөһим рейска җибәрә. Кузгалып кына киткәч, уйламаган җирдән машина каршысына ап-ак күлмәкләрен кигән Сөмәя килеп чыга һәм: «Мине дә Зәйгә утыртып бар әле, Галимҗан

абый», — дип, кабинага кереп утыра.

Юлда алар коеп яуган яңгыр астында калалар. «Тирән чокыр» дигән җирдә батып, пычранып бетеп, машиналарын көчкә чыгарганнан соң, чишмә буена төшәләр. Юынганда Сөмәянең кулы чокыр төбен каплап алган үги ана яфракларына тиеп китә. «Нинди салкын, юеш яфраклар!» — ди ул. Шунда алар икесе берьюлы «ниндидер серле мәгънә алган салкын яфракларны җыя башладылар. Яфраклардан ниндидер төче саз исе, ләм исе аңкый иде. Галимҗан үз кулындагы яфракларны кызга сонды».

Бер кочак кыр чәчәге урынына — бер кочак үги ана яфрагы!

Инде яңгырга чыланган Сөмәя Зәйгә барып тормый, Зәйдән кайтып килүче икенче шофер — Ибраһим машинасы белән кире кайтып китә. «Кабинага кереп утыргач кына, Ибраһим кызның өс-башы шактый юеш, пычрак икәнлеген абайлады һәм кулындагы яшел яфракларга күрсәтеп:

— Шушы себерке өчен килдеңме әллә? Әйт әле, нинди ырымы бар аның? Үзебезнең Чүке буенда да күп ич алар, — дип тезеп китте.

Кыз эндәшмәде, яфракларны күкрәгенә кысты».

Шушы тал бөреседәй бер эпизодка тал-тирәкнең үзе кадәр мәгънә йөкләнгән! Буесыны да, төсе-бите дә язылмаган Ибраһимның бик тә аптырау хәлдә әйткән бу сүзләре, фара кебек, аның бөтен кыяфәтен яктыртып җибәрә. Алай гына да түгел, Галимҗан белән Сөмәя эчендәге әйтелмәгән мәхәббәтнең әле үзләре дә белеп бетермәгән көчен күрсәтә.

Ни өчен әле мин бу хикәягә бу кадәр тукталып тордым?

Чөнки Мәхәббәт хисе нәкъ менә шушы садә вә самими хикәядә ихлас вә тормышчан тасвир ителә. Юк, бу — егет белән кызның икесеннән ары китмәгән мәхәббәт кенә түгел, бу — Җир белән Күккә, ягъни Табигатькә, барлык җан ияләренә булган бөек Мәхәббәттер. Әнә, казларның очканын күргән Галимҗан, машинасын туктатып, күзен дә ала алмыйча карап тора. «Тавышларын тыңлыйм... Очканда гына шулай кычкыралар бит алар. Кыр казлары кебек...» — ди ул, сокланып. Кешене кеше иткән хез-

мәт тә, ил алдындагы бурыч тойгысы да бу хикәядә шушы Мәхәббәткә өртелеп, романтик биеклеккә күтәрелгән. Аяз Гыйләҗев «хезмәт — яшәүнең нигезе» дигән баналь җөмләгә мисал язмаган, ә хезмәтне ул Мәхәббәттән һич аерылгысыз рухи ихтыяҗ итеп сурәтли алган.

«Үги ана яфраклары» хикәясеннән башланып киткән бу Мәхәббәт Аяз Гыйләҗевнең инде моннан соң язылган барлык әсәрләре өчен дә музыкаль ачкыч булып хезмәт итә. Шунсыз без аның иҗади йөрәген, идеалын аңлый алмас идек. Чөнки Аяз Гыйләҗевнең нинди генә әсәрен кулга алмыйк, һәркайсысы шушы сүнмәс тә, сүрелмәс тә Мәхәббәт утында чыныктырылган. Хәтта ки укыганда җелекләр кымырҗып торган «Өч аршын җир» әсәрендәге Мирвәли фаҗигасе дә башта төкереп чыгып киткән туган җиренә җирсеп кайтуы белән төгәлләнә. (Бу повесте өчен Аяз Гыйләҗев «Дружба народов» журналының 1964 елгы II дәрәҗә бүләген алды.)

Әсәрдән әсәргә бу мәхәббәт үсә, һәм инде ул язучының үзен әйдәп, җитәкләп барган, ансыз инде кояш та чыкмый торган иҗади юлдашына әйләнә. Чыннан да, карагыз: «Берәү» повестенда — малай килеш кенә бер кызны яраткан, ул кыз һәлак булгач та әле, ничә еллар оныта алмаган, инде бөтен мәхәббәтен кызның бәхетсез әти-әнисенә биргән Исхак; «Дүртәү» повестенда — арык атлар җигеп, авыр юлга чыккан дүрт үсмер малайны казадан коткарган, көчсез беләкләренә көч салган скрипкачы Хафиз карт; «Язгы кәрваннар»да — иң кыен сугыш елларында ачлыкка да, ялангачлыкка да бил бирмәгән, аркага арка, иңсәгә иңсә куеп, егыла-тора булса да Җиңүне якынайткан апалар, сеңелләр, япь-яшь малайлар...

«Өйдән чыккан ризыкларны уртак табынга куярга кирәк иде.

Иң кыен вакыт иде бу. Берәүләр кыенсынып, тынып калды, күзләр җиргә тәгәрәделәр... Кысыр сыер җилеме тиклем генә ризык капчыкларыннан нәрсә-кара чыга башлады. Алабута кушып пешерелгән, кайрактай кара катламалар, бәрәңге кырып, шуңа сыңар уч кына әремле арыш оны кушып пешерелгән ләчтә ипиләр, тәгәрәткән бәрәңгеләр... Таза ипиләр дә, солы, ясмык, борчак оны кушып пешергәнгә, вакланып, уа-

лып торалар.

Болар барысы да уртага чыгып тезелделәр. Уртадагы чана өстендә чиста ашъяулыкта урын калмады диярлек. Каян башына килгән диген, ашъяулыкны Әдилә тыккан икән!

Куллар табынга үрелде...

Юлда, ындырда, җилдә киселеп-яргаланып беткән бирчәйгән бармаклы, эре калын тырнаклы куллар... Тупырдатып бала сөясе урында җыерчыклы күз тирәләреннән күз яше сөртеп өйрәнгән куллар...»

Март аенда бәләкәй чана тартып, кышкы тар юлдан кыр казлары кебек тезелешеп симәнәгә баручы бу язгы кәрваннарны укыганда, күңел дигән касә тулып түгелә башлый. Сугыш чорының бөек рухлы кешеләренең бу тату мәхәббәтләреннән — йөрәк урынында таш булса, ул да эрер иде!..

Ләкин Аяз Гыйләҗев иҗатында Мәхәббәт белән янәшә, гүяки аңа куәт өстәр өчен, икенче бер тойгы — Нәфрәт тә уянып баш калкыта. Мәхәббәт кеше йөрәгенең бар яхшылыкка — гүзәллек йә тугрылыкка, дөреслек йә гаделлеккә иткән реакциясе булса, Нәфрәт — шуның нәкъ киресе. Сабый күңелендә үк әле, бу бик гади күренгән катлаулы дөньяга йөзгә-йөз килеп бәрелү белән, Ярату хисенә капма-каршы якта Яратмау хисе дә оя кора. Ул ямьсезлекне, хаксыз рәнҗетүне — гомумән, бөтен этлек, начарлыкны кире кагудан башлана. Менә «Дүртәү» повестеннан бер мисал: (1944 елның көзе) «Көнбатышта каты сугышлар бара. Дошманны тәмам кыйнап бетерү өчен, фронт һәм дәүләт бездән икмәк таләп итә. Ә монда атлар кырылган, кешеләр җитми, шуның өстәвенә елак көз иген-таруны бердәм генә җыеп алырга ирек бирми. Көн дә эштә кешеләр, төн дә...»

Шундый өзлексез тыпырдап, биеп торган яңгырлы бер төнне унбиш-уналты яшьлек дүрт малай — эшләренә караганда инде ирләр — ашлык төяп алтмыш чакрымлы юлга чыгалар. Моңа тиклем араларында гел бердәмлек, иптәшлек тойгысы булса, бу юлы исә, ничә тапкыр үтелгән бу юлда нидер була: иптәшлек-аркадашлык тойгысы-

ның бер чите чатнап китә. Дүрт малайның иң буйлысы, иң көчлесе саналган Вакыйф — аты сазлыкка баткан иптәшенә — Ибраһимга ярдәм итүдән баш тарта. Хәтта ки, «Ә мин китәм. Минем күләгәгә генә ышыкланып йөрмәсеннәр әле» дип, иптәшләрен авыр хәлдә ташлап китәргә дә җыена. Үсмер егет Ибраһимның шушы күрәләтә гаделсезлеккә булган Нәфрәте шушында ярала.

«Берәү» повестенда исә бу тойгы тагын да үстерелеп, герой характерына мөһим юнәлеш сызган бер көчкә әйләнә. Афәтле, мәкерле сугыш башлангач, өй саен атлар, уллар сугышка китә. Алар киткәндә, «Юл буйларында тапталып, изелеп өлгергән арышлар егылып кала.

Юл буенда яңа чабаталарның, кыршылган күн итекләрнең табаннары астында, сынып-сынып, чыклы күзле чәчәкләр кала...

Сынган күңелләр, өзелгән өметләр, киселгән бәхетләр кала...»

Болары — изге, мөкатдәс нәрсәләр. Ләкин болардан тыш әле тылда бик тирән поскан агулы елан Гыйльми Салихлары кала. Ул әле сугыштан соң да хезмәт һәм сугыш ветераны, кулы-аягы сынса да рухы сынмаган Нуруллананы чага; сугыштан таптаза кайткан Хөсәенне, тылда ир-егет булып җитлеккән Исхакны чага. Бу — зур гаделсезлек. Сугышта фашизмны җиңгән батыр егетләр үз өйләрендә бу гаделсезлекне әле җиңә алмыйлар. Менә шунда ныгый инде бөек тә, изге дә Нәфрәт хисе!

Еллар үтү-үзгәрү белән, Нәфрәтнең дә нишаны — төбәлү ноктасы үзгәрә. «Урамнар артында яшел болын» дигән романда төп геройның берсе, журналист Әхәт, дусты Идрискә болай сөйли:

«Хәзерге заманда әдәбиятта, сәнгатьттә классик хыянәтче Иуданың популярлыгы узды... Турыдан-туры аяк чалучы, хыянәтче образы яңалык түгел хәзер. Заманыбызның иң куркынычлы шәхесе итеп Понтий Пилат алына... Әнә шул белмәмешләр, күрмәмешләр, кешенеке кештәктә, үземнеке үзәктә дип читтән-чоттан кул уып йөрүчеләр куркыныч», — ди.

Һәм, ниһаять, Аяз Гыйләҗев, барлык әсәрләрендәге Мәхәббәт һәм Нәфрәт хис-

ләренә йомгак ясагандай, «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят»дигән гаҗәеп бер повесть язды. Ул безне яңадан да сугыш елларына алып кайта. Ләкин бу әсәрендә ул сугыш чоры кыенлыкларын беренче урынга куймый, аның бөтен дикъкате, инде уйлы-акыллы художник буларак, кешенең холкын, әхлагын хәрәкәт иттерә торган сәбәп вә нәтиҗәләренә юнәлгән. «Ил өстенә төшкән, үлемгә тиң сынаулар вакытында кемнәр кем булып кала?» дигән сорауга җавап бирә Аяз Гыйләҗев. Монда инде әрнүле, ачы Нәфрәт.

Ни өчен? Югыйсә повестьтагы әле егет тә булып җитмәгән Искәндәр бу Нәфрәтне бу тиклем дә әрнеп тояргa тиеш түгел иде бит! Шулай шул. Ләкин, ни кызганыч, сугыш чоры малайларының балачагы булмады — алар Мәхәббәткә хәтле Нәфрәт хисе татыдылар. Аларның нәфрәте иң әүвәл дөньядагы гаделсезлекнең дә иң гаделсезе, ерткычлыгы булган фашизмга төбәлеп туды.

Әйтергә кирәк, Аяз Гыйләҗев геройларының Нәфрәте кайберебезнең теле генә сөйли торган, сабын куыгыдай буш, ниндидер абстракт төшенчә түгел, ул — көйдергеч Нәфрәт. Андый Нәфрәт гаделсезлеккә читтән карап күзәтүдән генә тумый, аны кешенең үз йөрәге, бәгыре кичерергә тиеш. Гаделсезлек — Аяз Гыйләҗевнең шәхси дошманы. Чөнки ул аны берничә ел бәрабәренә үз җилкәсендә татыган. Шуңа күрә аның Нәфрәте дә куәтле. Андый Нәфрәт Аяз кебек көчле характерлар өлешедер.

Мин әле гел Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында сөйләдем. Ләкин моңа карап Аяз Гыйләҗев иҗатының төп темасы шул гына икән дип уйларга ярамый. Бу ике хис — язучының бөек идеалларга бару юлында дөньяны раслау йә инкарь итү өчен хезмәт иткән һич бозылмас бер компас ул. Ә инде Аяз Гыйләҗевнең бөтен әсәрләрен үзәк бер җепкә тезгән, фәкать аның үзенеке генә булган темасы бар: ул да булса — буыннар язмышы.



Әлбәттә, иң зур кыенлыкларны да җиңеп чыккан бер буын вәкиле буларак, Аяз Гыйләҗев күпчелектә үз буыны атлап үткән этапларны яза. Менә сугыш чоры. Язучы

аңа үзенең дүрт повестен багышлый. Ә сугыш чорында тыл үзе бер фронт булды. Аязлар буыны шул фронтта җиңеп чыкты. Бу буын, әйтергә кирәк, ун-унике яшьтән буыннарга төшкән авырлыкның үзәгенә җигелеп тарткан бердәнбер буын. Сугыш беткәч тә алар тугарылмады, дөньясына бер җигелгән килеш тартуларын белделәр. «Зәй энҗеләре» повестенда да, «Урамнар артында яшел болын» романында да, «Урталыкта» да Аяз Гыйләҗев үз буынын яза.

Ләкин бер буын да үзенә генә аерым барлыкка килмәгән — гасырлар буе, мең еллар буе берсе икенчесенә боҗрадай ялганып килгән. Аязлардан алдагы ике-өч буынның егерме миллионы сугышта юкка чыкты. Калганнары бик сирәгәйгән. Алар — «Берәү»дәге Нурулла белән Хөсәеннәр, «Урамнар артында яшел болын»дагы Хәлил белән Һашимнар. «Урталык»тагы Баязит агайлар, «Күзгә-күз»дәге Гафур Кәрамовлар...

Ә сугыштан соңгы буыннар кемнәр соң? Кырык сигезенче елда туган Рузалияләр буыны нинди («Урталыкта»)? Леналар, Рушаниялар кем («Кызлар хатлары»)? Ә Наза, Җәүдәт, Нәгыймәләр буыны («Күзгә-күз»)? Алай гына да түгел, ике эгоист әтисе-әнисе янында яшәп тә, ата-ана җылысын күрми үсә башлаган алты яшьлек Айдар нишләр («Урамнар артында яшел болын»)?..

Аяз Гыйләҗевнең һәркайсында эше бар. Буыннар бәйләнеше турында ул үзе менә болай яза:

«Гомер, тереклек, хезмәт тоташ чылбыр булып сузылганда гына, бәрәкәтле, өметле һәм нигезле була, кем дә булса аның бер боҗрасын өзә икән, бу — Җир шарын һәлакәткә китерәчәк.

Сугышлар, диктаторлар, фашизм — тереклекнең үсеш юлындагы күпме асыл боҗраларны өзеп ташладылар... Димәк, диктаторлар, сугышлар үсеш тарихының йомшак буынлы боҗраларын эзләп таба алганнар, чылбыр нык, таза боҗралардан гына тормаган» дип, фәлсәфәсе бик тирәнгә киткән масштаблы фикер йөртә.

Аяз — психолог. Дөрес, элегрәк язылган «Берәү» повестенда әле психологик ана-

лизны күп сүз белән бирергә тырышу, ягъни кичерешләрне никадәр күбрәк сөйләсәң, психологизм да шулкадәр тирәнрәк була дип язганлык сизелә иде. Ләкин бу инде үтелгән. Аннан соң Аяз Гыйләҗев безгә тирән психологик анализны «Өч аршын җир», «Урталыкта», «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят»тә күрсәтте. Бу җәһәттән мин аны үзебезнең Әмирхан Еникигә тиңли алам. Бу әсәрләрендә инде аның өрфиядәй назик хис, тотып кына әйтеп булмый торган нәфис, таләпчән сизгерлек белән тасвир ителгән психологик анализы персонажларның эш вә хәрәкәтенә, уйларының, сөйләгән сүзләренең табигый агышына төреп бирелгән булыр.

Ләкин Аяз Гыйләҗев, миңа калса, психолог булудан бигрәк, философ. Аның әсәрләрен мин, бигрәк тә «Урталыкта» дигән повестен, философик категория дип карар идем. Аяз Гыйләҗевнең философиясе, нәкъ психологиясе шикелле үк, әсәрнең тукымасыннан һич аерылмый — эчтәлекнең табигый сөземтәсе булып чыга. Дөресен әйткәндә, әдәби әсәрдә философ булу — һәр язучыга тигез тигән өлеш түгел. Шуңа күрә байтак кына әсәрләребездә бүгенге чынбарлыкның фәлсәфи нигезләрен ачып бирү җитешми, сәбәп һәм нәтиҗәләр фәлсәфи яктан аңлатылмый кала; күпчелектә без ихласлык белән, йә мавыктырып, йә ялкыткыч итеп, вакыйгаларны гына сөйлибез. Ә бүгенге чын проза, гомумән, әдәбият философиядән башка, ягъни кешелек туплаган асыл фикерләр яктылыгыннан башка яши алмый. Яшәсә дә озын фикерле була алмый, чөнки фәлсәфәсез әсәр — кайчандыр очып та, инде кулга ияләшкән өй кошлары кебек очарга итенеп карасалар да, җир тартып төшерә...

Аяз Гыйләҗев үзенең барлык әсәрләрендә дә чынбарлыктагы сәбәп бәйләнешләрен нәкъ менә әле әйтеп үткән фәлсәфи уйлар яктысына тотып тикшерә; аның фикерләре кыю, ул аларны алга-артка карап әйтми. Аның әсәрләре һәрвакыт тенденциоз булыр, ләкин бу тенденциозлык аның дөньяга марксистик-ленинчыл карашына, ягъни безнең бүгенге һәм киләчәк иманыбызга нигезләнгән.

Инде килеп, язучының әдәби осталыгы турында берничә сүз. Алда сөйләгән олы хисләр, масштаблы фикерләр әдәби әсәргә ничек әверелә соң? Гомумән, ни-нәрсә ул

әдәби осталык? Тормыштагы хәлләрне дөрес итеп, эзлекле итеп кенә сөйләп чыгумы?.. Әлбәттә — түгел. Заманының бөек идеаллары югарылыгына менгән чын язучы хезмәте, чынбарлыкны сүз белән — бары тик сүз белән — өр-яңадан төзеп, укучыга күрсәтүдән гыйбарәт ул. Әгәр сәнгатьнең бүтән төрләрен тоташ көе күз күреп йә колак ишетеп торса, язучы төзегән өр-яңа дөнья фәкать аерым-аерым сүзләрне, җөмләләрне бер-берсенә бәйләп укыганда гына хасил була. Язучы — үзе архитектор, үзе ташчы да ул. Аның карамагында йөзләрчә, дистә меңнәрчә сүз — төзү материалы. Әгәр язучы яхшы архитектор булып та, начар төзүче булса, ул салган бина ямьсез дә, шөкәтсез дә чыгачак.

Аяз Гыйләҗев әдәбият мәйданына бай тел белән килеп керде. Ләкин әле ул үзенең беренче әсәрләрендә төзүче булудан бигрәк — архитектор, художник булудан бигрәк, гадәти бер язучы гына иде. Ул әле иң гади күренгән сүзләрдән дә, оста каләмле язучыбыз Әмирхан Еники сыман итеп, садә дә, гүзәл дә сәнгать әсәре иҗат итә алмый, шуңадыр, тыелгысыз илһамга бирелеп китеп, сүз байлыгын кая куярга да белми, күбесен әле сызып ташларга курка, сүзләрнең дә куәтләләре белән эш итәргә ярата иде. Шунлыктан теле катлаулы һәм киеренке чыга иде.

Ләкин бу үтте.

«Урамнар артында яшел болын» романыннан соң Аяз Гыйләҗев кечерәк күләмле, гаҗәеп талантлы, гаҗәеп самими өч әсәр — «Урталыкта», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят» дигән повестьларын язды. Бу әсәрләрендә инде ул шәп архитектор да, оста куллы төзүче дә. Ул тормышның үзен, ләкин тагы да гүзәлрәген иҗат иткән. Иң әүвәл г а д и л е к к ә ирешкән. Ләкин бу гадилек коры сөяккә калган гадилек түгел. Ул — катлаулы гадилек. Ул — бөтен артык сүз вә детальләрне атып бәреп, иң кирәкле һәм төгәлләрен генә калдыру бәрабәренә интегүле һәм йончыткыч эш нәтиҗәседер!

Шулай ярала чын сәнгать әсәрләре.

Бу әсәрләре белән Аяз Гыйләҗев үзенең х у д о ж н и к икәнлеген исбат итте. Ул

хәзер вакыйгаларны, геройларны сындай итеп коеп кына куя! Менә бер мисал:
«Рәхимҗан бабайлар капкасын киң итеп ачтым да нык ук кычкырып сәлам бирдем:
— Алла куәт бирсен, Рәхимҗан бабай, исәнлекме? — дидем.
Ул баш чайкап кына сәламемне алды, тынын тигезли алмыйча, мышный-мышный озак кына миңа карап торды; терсәкләре ямаулы зәңгәр күлмәге манма су, ачык изүеннән гадәттән тыш аксыл тәне, очлы сөякләре күренеп тора. Кимерчәктән генә торган борын очында төссез тир тамчылары асылынган. Менә ул күлмәк итәген кайтарып борынын сеңгерде дә, кулын селтәп, бүкәнгә барып утырды, тонык картлык пәрдәсе өрткән күзләрен миңа текәде...
— Маташма интегеп, Рәхимҗан бабай! Берара үзем кереп ваклап чыгармын!
Шулай дисәм дә, карт башын чайкады, торып басты, бияләен салып ташлап, учларына төкерде, төкереге чыкмады, авызы корыган икән; коры учларын бер-берсенә ышкыды да, бер дә ычкындырмас төсле, балта сабына тотынды».
Менә сезгә теп-тере, җанлы сурәт! Ир-егетләре сугышка киткән дөньяда йөз яшьлек картның интегеп утын яруы да, кимерчәктән генә торган борыны да, төсе-кыяфәте дә, кулларын төкерекләгән булып балта сабына тотынуы да — сүзләргә художник кулы тигәч — күз алдына килде дә басты! Гүяки шул карт, бүкәнгә утырып бераз хәл алгач, минем күз алдында бияләйләрен салып ташлап, утын ярырга керешкәндәй булды...
Аяз Гыйләҗев инде кешене аяктан егарлык зәһәр, куәтле сүзләр белән эш итми, — ул хәзер телебездәге юк кына күренгән сүзләрнең дә, урынын белеп куйсаң, алмаздай ялтырап, куәтләнеп китә алучылык серенә төшенгән, — ул хәзер әдәби әсәрдә, гомумән, сәнгатьтә, фикерләү чарасы буларак иң кирәкле, иң кыйммәтле саналган детальләр белән эш итә.
Тагын бер мисал. «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят»тәге, авылда иң ялкау, иң юньсез хатын — Мәүлиханың кемлеген белү өчен ике җөмлә җиткән. Шул Мәүлиха — әтисе сугышта кан коеп йөргән Искәндәрдән сорый: «Атаңның хаты киләме? Акча салам димәгәнме?» — ди. Уйнап түгел, чынлап сорый ул моны!

Яки менә бу детальләрне укыйк: «Ул күгәреп тешләре коелган түгәрәк пычкылар, ул тары көшеле сыман кояшта ялтырап яткан пычкы чүбе таулары, ул юан нык сабаклы алабуталар, сажин-сажин кычытканнар, ул саргайган бармаклары арасына юан-юан тәмәке кыстырган ирләр, шул тәмәкеләрнең кысылган иреннәрдә чытыр-чытыр януы!..»

Ә менә бу җөмләдәге детальләр нинди:

«Арыш арасындагы бодай кебек, бер-ике ир-ат та бар. Болары кичәге фронтовиклар. Алар җитди, кырыс... Куллар шинель кесәсендә. Һәр шинельдә кесә бар — һәр кесәдә кул гына юк...»

Һәр сүзе образлы! Ә бит болар гап-гади сүзләр! Ләкин һәркайсысы, белеп борып куйгач, балкып кабынып киткән. Әнә шундый детальләр аша мәгънәнең хәтердә калу көче, димәк, тәэсир көче ныграк була.

Аяз Гыйләҗев соңгы әсәрләрендә аз сүз белән күп мәгънә аңлатуга ирешә. Мондый язучыны без «сүзгә саран» дибез. Ләкин бу саранлык — кирәк сүзне дә интегеп кенә тартып ала торган саранлык түгел. Әгәр Аяз Гыйләҗев шушы рәвешчә аз гына сүз белән дә күз алдыбызга кеше йә күренешне, хәрәкәт йә халәтне башы-аягы белән бастырып куя ала икән, димәк, ул үзе тасвир иткән нәрсәләрнең иң юмарт бер сыйфатын тотып алган булып чыга.

Аннары «сүзгә саран» дигән төшенчә ул әле һәр очракта да, штрихлар гына ясап, аннан бер, моннан бер тамызып язу дигән сүз түгел. Аяз Гыйләҗев, мәсәлән, кеше тойгыларына, уйларына керешеп китсә, штрих белән генә чикләнми — бер үк тойгының төрле ягын кайта-кайта, оныттырмаслык иткәнче яза. Димәк, саранлык ул аз сүз белән генә язу түгел, ул — язучы сүзне күбрәк исраф итәме, азракмы, тик артыгы булмасын дигән сүз икән! Ә иң мөһиме: язган һәрнәрсә «менә мин!» дип каршыга килеп бассын. Алай гына да калмасын — җиде кат күңелгә үтеп кереп, йөрәгебезне тоярга, миебезне уйларга мәҗбүр итсен. Аяз Гыйләҗевнең соңгы әсәрләре нәкъ шундый. Без, аларны укыганда, гүяки әсәр укымыйбыз, ә шундагы тормышның эчендә яшибез икән тәэсире калдыра, ягъни әсәр үзе югалып, җирендә тормыш кына торып

кала.

Тагы бер фикерем бар. Моннан берничә ел элек Аяз Гыйләҗев миңа: «Кичә дигән төшенчәне кулланмыйча, берәр әсәр язасым килә», — дип әйткән иде. Ни дигән сүз бу? Аның мәгънәсе болай: без, гадәттә, бигрәк тә зуррак күләмле әсәр яза башласак, вакыйгаларның бүгенгесеннән бигрәк, кичәгесен, ягъни үткәнен сөйли башлыйбыз — бүгенгесе бер бит булса, кичәгесе ун биткә дә сыймый. Хәлбуки зур әсәрдә вакыйгаларның фәкать бүгенгесен сөйләү, бүгенгесе беткәч, фәкать иртәгесен генә сөйләү — язучы өчен гаять авыр сәнгать. Бу — герой белән бергә атлап бару дигән сүз, бу, ниһаять, — һич артка чигенмәстән, гел алга бару, һөҗүм итү дигән сүз. Бу җәһәттән Аяз Гыйләҗев үз теләгенә ирешкән: «Дүртәү» повестенда да, «Язгы кәрваннар»да да, «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят»ендә дә кичә сүзе юк. Һәркайсысында вакыйгалар фәкать б ү г е н н ә н башланып китә дә гел алга гына бара.

Хөрмәтле укучылар! Кулыгызга алган бу китапка Аяз Гыйләҗевнең төрле елларда язылган проза әсәрләре тупланган. Шуңа күрә без бу мәкаләдә аны әдәбиятыбызда таланты балкып торган прозаик буларак сөйләдек. Хәлбуки Аяз Гыйләҗев — күренекле драматург та. Аның ике дистәдән артык драма әсәрләре татар театрларында гына түгел, илебезнең башка театрларында да куелган һәм куелып тора. Ә бу турыда үзенә башка зур бер мәкалә язарга кирәк булыр иде.

Менә шушы язучыбызга быел илле яшь тулды. Әгәр мин шушы мәкаләм аша Аяз Гыйләҗевкә киләчәктә дә иҗади бөеклек теләсәм, укучым, син дә күңелең белән кушылырсың дип уйлыйм.

«Социалистик Татарстан»

15 гыйнвар, 1978



МИҢНӘХМӘТ СӘХАПОВ

Кырыс чынбарлык

Әдәбиятыбызга катлаулы һәм каршылыклы тормыш сикәлтәләре аша, Сталин төрмәләре һәм концлагерьларының «баландасын чөмереп» килгән Аяз Гыйләҗев менә кырык елга якын инде иҗат мәйданындагы бәйгедә каләмдәшләренә бирешмәде.

Татар әдәбиятындагы урыны һәм әдәби хәрәкәткә йогынтысы мәсьәләсенә килгәндә исә шуны расларга була: Аяз Гыйләҗев — әдәбиятыбызда Фатих Әмирхан традициясен уңышлы дәвам итүче һәм аны үстерүче әдипләребезнең берсе. Аяз Гыйләҗев иҗатында әдәбиятыбызның икенче сулышын ачып җибәргә булышкан шушы юнәлеш бөтен куәте белән чагылды һәм аның әдип буларак талантын ачуга да зур өлеш кертте. Иҗатының башлангыч чорыннан алып бүгенге көнгә кадәр, кайбер әсәрләрен исәпләмәгәндә, Аяз Гыйләҗев тәнкыйди реализм методына турылыклы булды. Аның иҗатының шактый зур өлеше социалистик реализм догмаларына карата оппозициядә тордылар, һәм әдип тә бу принцибын артык тирәнгә яшереп торуны кирәк дип тапмады. Ул иҗат иткән әдәби әсәрләрнең күпчелеге шул чорда хакимлек иткән тоталитар системаның чын йөзен ачу, аның шәхес азатлыгын һәм иреген чикләвен күрсәтү һәм безгә тәкъдим ителгән идеалларның дөреслеген шик астына алу рухы белән сугарылганнар. Әйтик, аның «Качак», «Берәү», «Өч аршын җир» повестьларында шул дәвер-

нең каршылыклы, кеше күзеннән читтәрәк торган ямьсез һәм кимчелекле күренешләре шактый җитди тәнкыйтьләнсә һәм аның сәбәпләре шул система тарафыннан тудырылган дип расланса, «Урамнар артында яшел болын» романында, «Язгы кәрваннар», «Күзгә-күз», «Дүртәү», «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят», «Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн, кич белән...», «Яра» повестьларында бу пафос тагын да тирәнәеп, кырысланып китте. Ә әдипнең «Балта кем кулында?» романы белән «Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсе иҗат ителгәч, төрле характердагы җинаятьләр өчен уңайлы шартлар һәм яхшы җирлек тудырган тоталитар системаның ерт-лач йөзендәге матур битлек тә салдырып ташланды. Алай гынамы соң әле: Аяз Гыйләҗев гыйбрәтле геройларының катлаулы һәм каршылыклы, кай очракта фаҗигале һәм әрнүле язмышлары аша коммунистик системаның череп таркалган нигезен дә фаш итте. Бу нисбәттән, аның «Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсе татар әдәбиятында үзенчәлекле урын алып тора. Аның үзенчәлеге татар милли әдәбияты өчен өр-яңа булган «лагерь темасы»н уңышлы үзләштерүендә генә дә түгел әле. Аяз Гыйләҗев роман-хатирәдә, лагерь тормышын һәм төрмә дәһшәтләрен, уе һәм истәлекләре белән бер-ялгызы гына калган сәяси мәхбүснең күңел кичерешләрен һәм газаплы көннәрен тасвирлау белән бергә, бөтен илне һәм җәмгыятьне «лагерь» системасына китергән сәбәпләрне дә эзли, тикшерә, таба, анализлый. Әйтергә кирәк, ул бу очракта гади беллетрист буларак кына чыгыш ясамый, бәлки тарихи процессларны җентекләп анализлаган тарихчы, социаль күренешләрнең асылын тикшергән социолог, концлагерьның үзенчәлекле гореф-гадәтләрен, йолаларын, көнкүрешен, куллану әйберләрен тасвирлаган этнограф һәм шул чорның иҗтимагый фикерен өйрәнгән философ буларак чыгыш ясый һәм үзенең күзәтүләре, ачышлары белән бик теләп уртаклаша. Әдип фикеренчә, тоталитар хакимият системасы һәм ул тудырган концлагерьлар чел-тәре бер большевиклар уйлап тапкан «ачыш» кына түгел. Большевиклар дәүләт белән идарә итүдә булсын яки иҗтимагый фикер белән идарә итүдә булсын, бернәрсәне дә үзләре уйлап тапмаганнар, бары хакимияттә үзләреннән алдарак булган һәм башка

иҗтимагый-икътисади формация вәкилләренең эш стильләрен һәм дәүләт белән идарә итү ысулларын гына үзләштергәннәр. Тоталитар хакимияткә ихтыяҗ, Киев Русе чорында ук туып, Мәдһиш Иван һәм Петр Беренче хакимлек иткән заманнарда дәүләт идеологиясенә әйләнгән. Ягъни башка дәүләтләрне корал көче белән буйсындырып, аларның җир-суларын тартып алып, халкын коллыкка төшерүне төп кәсеп, даими шөгыль иткән дәүләтнең илбасарлык сәясәтен уңышлы рәвештә алып бару өчен тоталитар хакимият менә дигән терәк була. Гел талау сугышларында катнашкан халыкның рухи дөньясы буш, рухи тормышы бик фәкыйрь була, билгеле. Шул сәбәпле халыкның рухи дөньясында хасил булган «рухи вакуум»ны тоталитар хакимият системасының бер формасы — бөек мәмләкәтчел шовинизмы тутыра һәм гасырлар буе башка халыкларны коллыкка төшергән, «лагерь режимы»нда яшәткән күпсанлы урыс милләте дә беркөнне, башка аз санлы халыклар белән бергә, «лагерь социализмы»на килеп каба. Аяз Гыйләҗев тоталитар система көченең большевиклар хакимияте тудырган җәза органнарында гына булмыйча, аның, куәт биргән чыганакның, әле адәм балаларының аңнарында, зиһеннәрендә, коллык психологиясендә дә яшәвен искәртә. Ул әнә шулай, кешелек тарихы буенча аның борынгы чорына таба фикри сәяхәткә чыгып, әдәбиятыбыз өчен генә түгел, бәлки иҗтимагый фикер тарихыбыз һәм сәясәт белемебез өчен дә әһәмияте булырлык ачыш-табышларга юлыга. Үзе яшәгән чорның каршылыкларын, кимчелекләрен ачу, хакимлек иткән тоталитар система тәгълиматына бертуктаусыз тәнкыйть уты яудыру белән бергә, Аяз Гыйләҗев галәм могҗизасы булган аерым бер кешенең язмышын төрле аспектта карарга һәм тикшерергә омтыла. Аның геройлары һәрвакыт үзенчәлекле һәм рухи яктан таза-камил кешеләр, хәлиткеч мизгелдә гадәти затларның кулыннан килмәгән гадәттән тыш гамәлләр ясыйлар һәм тәвәккәл адымнарга баралар. Әнә «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят» повестендагы Арзу, үз өстенә нахак бәла алып, олы кешене төрмәдән коткарып кала. «Җомга көн, кич белән...» повестенда Бибинур, яшьлеген корбан итеп, өч балалы гаиләгә әни булып килә. «Өч аршын җир» повестенда Мирвәли исә туган җире хакына үзенә кара-

та эшләнгән җәбер-золымны да кичерә. Әйтергә кирәк, Аяз Гыйләҗевнең мондый мөлаем һәм гыйбрәтле геройлары аның иҗтимагый-эстетик идеалын чагылдырып кына калмыйлар, бәлки әдип төзегән һәм тамыры намуслы гамәлләргә һәм халкыбызның милли әхлагына барып тоташкан үзенчәлекле яшәеш формуласының тоталитар система чынбарлыгына караганда Гыйләҗев тәнкыйди реализм методы белән иҗат итә һәм аның кайбер әсәрләрендә «яшәү фәлсәфәсе»нең, ягъни экзистенциализмның кайбер билгеләрен дә табып була. Бу фәлсәфәнең кайбер постулатлары аның «Балта кем кулында?» романында һәм «Йөгез, бер дога!» роман-хатирәсендә төп геройларның тоталитар режим белән кискен бәрелеше вакытында чагылгалап алалар һәм гомеренең биш елын концлагерьда уздырган әдипнең шәхси тормыш тәҗрибәсенең бер факты буларак сизелеп куялар. Һәрхәлдә, Аяз Гыйләҗев, үзенең геройларын экстремаль хәлләргә куеп, «чик буе зонасына» китереп җиткереп, тормышның яшәү белән үлем һәм намус белән намуссызлык кебек дәһшәтле төшенчәләре арасында сынарга, тикшерергә һәм анализларга ярата. Аның күпчелек әсәрләрендәге геройлар да шулай гел авыр мәлләрдә сыналалар һәм кискен хәлләрдә ачылып китәләр. Иҗатында әдип һәм фикер иясе буларак эш иткән Аяз Гыйләҗев безнең әдәбият өчен яңа булган әдәби күренеш — тормышка тәнкыйть белән караучы һәм шәхеснең азатлыгы, рухи камиллеккә ирешү өчен утка да, суга да керергә әзер торган гыйбрәтле герой концепциясен тудырды. Уңай герой да түгел, үрнәк герой да түгел, чынбарлыкның фотокүчермәсе кебек алынган табигый герой да түгел, бәлки бары Аяз Гыйләҗев иҗат иткән чынбарлыкта яши алган һәм җәмгыятькә гыйбрәтле тормыш мисаллары белән үзенчәлекле рухи тәҗрибә тәкъдим итә алган, регламентлы бәхет идеологиясен танымаган гыйбрәтле герой, катлаулы һәм каршылыклы, үзенчәлекле герой! Шуңа аның әсәрләре, әзер штамплардан һәм норматив кагыйдәләрдән азат булганга күрә, укучыларны да гел үзләренә тартып торалар. Шул ук вакытта, рәсми булмаган кырыс чынбарлыкны тасвирлап һәм аның рухи-әхлакый кыйммәтләр системасын укучыга тәкъдим итеп, Аяз Гыйләҗев шәхес һәм яшәешнең тоталитар системага карата оппозициядә торган аль-

тернатив концепциясен дә иҗат итә. Кайчан да булса бер татар философлары әдипнең иҗатында чагылган иҗтимагый фикерне һәм аның үзенчәлекле «яшәү фәлсәфәсе»н тикшererләр, бәяләрләр һәм аларны милли фәлсәфә фәне әйләнешенә кертеп җибәрерләр әле. Әлегә без әдип һәм фикер иясенең яшәеш һәм шәхес турындагы фәлсәфи фикерләрен һәм уйларын атап китү белән генә чикләнәбез.

Аяз Гыйләҗевнең әдип һәм фикер иясе буларак янә бер үзенчәлеге шунда: ул беркайчан да конъюнктура артыннан кумады һәм иҗатында һәрвакыт гомумкешелек проблемаларына мөрәҗәгать итәргә тырышты, аерым бер шәхеснең язмышы аша адәм балаларының күңелләрен дулкынландырган һәм борчыган җитди мәсьәләләргә мөрәҗәгать итте. Шулай ук ул аерым бер кешенең эчке дөньясын, рухи тормышын тасвирлап, аның күңел дөньясына тирән яшерелгән серләрен дә эзләде, социаль вакыйгаларның шәхеснең әхлагына һәм кыйбласына тәэсир итү үзенчәлекләрен ачыкларга тырышты.

Аяз Гыйләҗевнең әсәрләре үткен проблемалары, «ике агымлы композициясе», кырыс һәм кайчакта шактый саран, әмма төгәл сурәтләү чаралары, үзенчәлекле әдәби һәм фәлсәфи-психологик детальләре белән генә түгел, бәлки теленең музыкальлеге, аһәңе, эчке гүзәллеге, төгәллеге һәм җыйнаклыгы белән дә укучыларны җәлеп итәләр. Кагыйдә буларак, аның стиле бик пөхтә, теле гаҗәп сыгылмалы, тыгыз һәм кырыс. Героен тасвирлыймы ул яки вакыйга белән берәр эпизодны сурәтлиме, бер генә артык сүз, тәгъбир яки төшенчә очратмассың. Барысы да үз урынында, барысының да төгәл функциясе бар. АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ ТЕЛЕ МӘРМӘРДӘН КОЕЛГАН ТАЛАНТЛЫ СӘНГАТЬ ӘСӘРЕН ХӘТЕРЛӘТӘ. Эмоциональ төсмер белән экспрессив хасият сүзләрнең эченә шулкадәр дәрәҗәдә оста яшерелгән ки, беренче мәлне аларны сизми дә каласың. Бары җөмлә бетеп, фикер тәмамлангач, һәм күз алдында сүз белән ясалган җанлы сурәт пәйда булгач кына аның тылсымлы һәм сихри кодрәте алдында таң каласың. Аяз Гыйләҗевнең теле тылсым һәм ырымнардан тора. Сихри табигате һәм эчкә яшерелгән тирән мәгънәсе белән әнә шулай оста эш итә, аны фикер һәм хис

дөньясында җаны теләгәнчә уйната. Лирик-эмоциональ бизәкләрне урыннарын белеп кенә куллану, психологик һәм фәлсәфи параллельләрне мул файдалану, текст астына яңа функцияләр йөкләү, вакыйгалар-күренешләр тәртибен үзгәртеп, аралаштырып бару, психологик ассоциацияләргә мөрәҗәгать итү, тарихи фактларны, чорга караган документларны әсәрнең сюжет тукымасына ипле кертеп җибәрү дә әдип иҗатында еш очрый.

Иҗатының менә шундый үзенчәлекле һәм үзенә генә хас нәфис хасиятләренә күрә, Аяз Гыйләҗевнең бай мирасы татар милли әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил итә. Аяз Гыйләҗев талантлы әсәрләре белән әдәбиятыбызда Фатих Әмирхан традицияләрен ныгытып һәм аны үстереп кенә калмады, бәлки әле социалистик реализм аяусыз рәвештә хакимлек иткән дәвердә үк тәнкыйди реализмның бай мөмкинлекләреннән оста файдаланып, башка методка таянып иҗат иткәндә дә талантлы әсәрләр тудырып булуын әнә шулай дәлилләде. Фикердә, уйда, гамәлдә кыюлыгы һәм иҗатта бәйсезлеге аңа дөнья әдәбиятларын борчыган, дулкынландырган катлаулы темаларны, кискен проблемаларны үзенең әсәрләрендә чагылдырырга һәм аларны хәл итүнең үзенчәлекле юлларын тәкъдим итәргә мөмкинлек бирде.

«Мирас»

№ 1, 2003



РИФАТ СВЕРИГИН

Замандашлар бәхетен кайгыртып...

Тормышның хәрәкәтен һәм закончалыкларын сәнгатьчә ача, актырта белүче, эзләнүчән һәм тынгысыз каләм ияләренә әдәбият һәрвакыт мохтаҗ була. Ә инде рухи һәм иҗтимагый тормышның үзгәрүе, баю этапларында әдәбиятны яңа сыйфат үрләренә күтәрүче сүз осталарының булуы аеруча кирәк.

Илленче еллар ахыры, алтмышынчы еллар башында яшь язучыларның бер төркеме: Рафаил Төхфәтуллин, Гариф Ахунов, Әхсән Баянов, Аяз Гыйләҗев һ.б. яңа эстетик кыйммәтләрне үзләренчә — җанлы тормыш рухында, сугыш елларында үскән яшьләр күзәтүе һәм кичерешләре рәвешендә әдәби образларда гәүдәләндерү теләге белән прозага килделәр. Алар арасында иҗади-эстетик карашларының шактый ук тенденциозлыгы, фикерләренең үткенлеге һәм сугышчанлыгы, искергән, инде таушалып, тормыш һәм сәнгать үсешенә комачаулый башлаган күренешләргә килешмәүчән мөнәсәбәте белән Аяз Гыйләҗев аерылыбрак торды. Аның иҗат тынгысызлыгы әдәбиятны уй-фикер торгынлыгы, образлы чараларның бертөрлелегеннән арындыруга, тормыш хәрәкәтләрендәге котылгысыз үзгәрешләрнең асылын аңларга, шушы яңа рухны сәнгатьчә ачарга, үзләштерергә ярдәм итәрдәй чараларны эзләү җирлегендә туган иде. Бәлки, ул чакта күпләргә бу борчу-эзләнүләр яшьлек кайнарлыгы булып кына тоелгандыр. Әмма 30–35 ел үткәч тә тормышка актив мөнәсәбәте, гражданлык пафосының, кешелек җәмгыятен гүзәлрәк итәргә теләү омтылышына кушылып, яңадан-яңа әдәби образларда гәүдәлә-

нә торуы инде танылган әдипнең иҗат позицияләре очраклы сайланмавы, эзлекле әзерләнүе, какшамаслыгы хакында сөйли.

Прозасының нигезен тәшкил иткән «Урамнар артында яшел болын» романы, «Өч аршын җир», «Берәү», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят», «Мең чакрым юл», «Җомга көн, кич белән...», «Әтәч менгән читәнгә», «Кызлар хатлары», «Күзгә-күз» повестьлары, күпсанлы хикәяләре әдипнең иҗат колачын, идея-тема диапазонын, стиль үзенчәлекләре һәм төсмерләрен билгеләргә һәм ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Авторның драматургия өлкәсендәге актив эшчәнлегендә дә идея-эстетик позицияләренең бердәмлеге, максатлы юнәлеше ачык гәүдәләнә.

Аяз Гыйләҗевнең әдәби эзләнүләре, беренчедән, тормышыбызны, әйләнә-тирәбезне сафрак, матуррак, кешеләрне олы җанлырак итеп күрергә теләү хисенә буйсындырылган булса, икенчедән, шул кешеләр — замандашларының рухи яңарышына ирешү өчен әдәбият-сәнгать чараларының үтемлерәк, тәэсирлерәк ысулларына яшәү хокукы бирү, укучылар аудиториясен шул яңалыкларны эстетик планда әзерләүгә кайтып кала. «Өч аршын җир»дә (1962) кеше һәм аның туган җире, коллективы, әйләнә-тирәсе, урыны кебек җитди мәсьәләләр күтәрелә. Татар прозасы өчен болар берсе дә яңа түгел. Әмма мәсьәләләрнең куелышы һәм әдәби чишелеше үтә кызыклы, үзенчәлекле. Кешеләрдән читләшкән, барлык психик һәм физик көчләрен индивидуальлек фәлсәфәсенә буйсындырган Мирвәлине төп герой рәвешендә тәкъдим итү шактый ук сәер иде. Әлбәттә, андыйлар моңа кадәр безнең прозада булмады түгел, тик алар барьерның теге ягында булгангамы, һәрвакыт диярлек эчке дөньяларыннан мәхрүм персонажлар



рәвешендә бирелә иделәр. Әдәбият үзе һәм әдәбият фәне озак еллар дәвамында уңай герой психологиясен өйрәнү белән шөгыльләнде. Ә биредә исә психологик анализ чит элементка — җәмгыятьтән аерылган, аннан читләшкән типка карый. Повестьта Мирвәлигә каршы социалистик җәмгыять нормалары рухында яшәүчеләрнең таза тирәле-

ге куелган.

Әсәрдә Мирвәлине яклаучы, хәтта аңа битарафлык саклаучы бер зат та юк. Берәү дә аның белән килешми. Әлбәттә, бу мохиттә башкаларны санламау, мин-минлек, җәмгыятькә, тарих агышына үзеңне капма-каршы кую фәлсәфәсе үсә дә, тамырлана да алмаячак. Кайчандыр үч итеп, йорт-җирләрен яндырып, күмәк хуҗалык амбарларындагы икмәкне яраксыз хәлгә китергән Мирвәлине авылдашлары шулай да ахыр чиктә үз яннарына сыйдыралар — картайган кешенең хәленә керәләр. Әмма әхлакый планда гафу итү түгел. Инде ничәмә-ничә еллар авылда беркемнең дә балаларына Мирвәли исемен кушмавы — җитди хөкем. Менә шушы факт дөньяда карашлар мәсьәләсендә бернинди дә ташлама, килешү булмаячак дигәнне аңлата. Мирвәлине авылга сыендыру исә — аның үчлеккә, әшәкелеккә нигезләнгән фәлсәфәсенең соңгы дәлилләрен юк итә — аңа кешеләр арасында яшәргә, җәмгыятькә хезмәт итәргә генә кала. Бу — халыкка каршы баручыларның әхлакый һәлакәте дигән сүз. «Кешеләр янындагы өч аршын җиреңә дә лаеклы бул», — шушы рәвешчә индивидуаль шәхеснең җәмгыятьтәге җаваплылыгы идеясе көчәйтелә. Нәкъ шушы тәмамланышка укучыны эзлекле, дәлилле алып килүе Аяз Гыйләҗевнең бу повестьтагы кыйммәтле иҗат табышы булды.

Аяз Гыйләҗев прозасының бер үзенчәлеге — ул контрастлык. Повестьларының берсе «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят» (1973) дип аталуы да тикмәгә түгел. Яхшылык һәм явызлык, матурлык һәм ямьсезлек, мәхәббәт һәм нәфрәт, саф әхлак һәм мещанлык — әнә шулар әсәрләрнең сюжет контрастлылыгын билгелиләр. Бер очракта дөньяга капма-каршы карашлар маңгайга-маңгай бәрелеш («Өч аршын җир»), икенчесендә төрле мөнәсәбәтләрнең каршылыгыннан бигрәк, аермасын гына күрәсең («Берәү»), өченче очракта укучы геройның дөньяга карашында кискен үзгәрешләр шаһитына әверелә («Урталыкта»). Укучының мәхәббәтенә лаеклы һәм нәфрәтенә дучар ителерлек персонажларны автор ерак тарихтан яисә чит җирләрдән эзләми, алар үзебезнең тормыш чынбарлыгыннан әсәрләргә килеп керә. Гомумән, Аяз Гый-

ләҗев — заман язучысы, үз заманының художнигы. Материалы — үзе күргән-белгән, кичергән тормыш вакыйгалары. Әледән-әле укучы күз алдына Бөек Ватан сугышы чорындагы авыл кешеләре, бигрәк тә шул вакытта зур тормыш юлына аяк атлаган намуслы, саф күңелле, тыйнак авыл яшьләре килеп баса. Автор дөньяга яшь кеше күзләре белән карый, ул күп хикәя һәм повестьларда авыр тормыш сынауларын үтә-үтә чыныгып килүче яшь герой рәвешендә кабатлана, әмма моны бертөрлелек дип түгел, ә күркәм, югары әхлак сыйфатларына ия образның тулылана баруы дип кабул итәсең. Аңа әнә шундый зур урын бирелүе дә акланган — аның зур идея функциясе бар — автор иң алгы планга яшьләрдә югары әхлак, коммунистик сыйфатлар тәрбияләү максатын куя.

Гомумән, Аяз Гыйләҗев әсәрләренең конкрет адресы бар: аларның иң зур күпчелеге яшьләргә юнәлдерелгән.

«Дүртәү» (1958) һәм «Язгы кәрваннар»да (1972) яшүсмерләр Ибраһим, Дамир, Әдилә, «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят»тә унынчы класс укучылары Искәндәр һәм Рифгать, бер генә яшькә олырак булса да, аларны укытучы Арзу, «Качак» (1959) хикәясендәге сыер савучы Тәнзилә, «Берәү» (1959) повестендагы Исхак һ.б. образлар аркылы сугыш һәм сугыштан соңгы елларда үскән татар авылы яшьләренең тулы бер буыны, сөйкемле, уңай типик герой үткән тормыш юлының аерым кисәкләре, этаплары гәүдәләнә. Ә дөньяны аңлау, аңа мөнәсәбәткә килгәндә, бу персонажлар арасында әллә ни аерма юк, аларның һәммәсен янәшә куеп, билгеле бер чор яшьләр буынының типик сыйфатларын берләштергән характер дип бәяләргә мөмкин. Димәк, Аяз Гыйләҗев әнә шундый җыелма характерның гаять тормышчан, дөрес образын иҗат итә алган.

А.Гыйләҗев әсәрләрендә заман һәм тормыш җәмгыять алдына әледән-әле китереп куйган һәм чишелешен көтә торган проблемалар күтәрелә. Алар арасында уйландыра, борчый, тизрәк хәл итүне сорый торганнары да бар. Җәмгыять милкенә дөрес булмаган мөнәсәбәт, яшьләрне тәрбияләү эшендәге ялгышлар, авылда эшче көчләр

белән бәйле күренешләргә дә язучы үз мөнәсәбәтен белдерергә тырыша. Мәсәлән, авылдан яшьләрнең китүе, эшче көчләрнең кимүе процессының А.Гыйләҗев мораль ягына игътибар итә.

«Берәү» повестының драматизмы — Исхакның туган җиреннән читләшә, аерыла башлавында. Якташлары, туганнарының, дөнья күргән олы кешеләрнең үзенә карата мөнәсәбәтләре салкыная башлавын тою — егеткә иң кырыс һәм катгый хөкем. Исхак үз ялгышын аңлый башлый.

Мөгаен, мондый әсәрләрнең тууына яшьләрнең авылдан шәһәргә агылуы, авылның эшче кулларга ярлылануы кебек экономик-социаль процесслар сәбәп булгандыр. Тора-бара Аяз Гыйләҗев мондый борчылуларның үзеннән-үзе барлыкка килмәвен һәм алардан алай җиңел генә котылып булмавы хакында тирәнрәк уйлый башлаячак («Җомга көн, кич белән...», «Өтәч менгән читәнгә»), тормышның катлаулы һәм җитди проблемаларын чишкәндә кешегә күп очракта үз намусы, вөҗданы каршында бергә-бер калырга туры киләчәген, һәрвакытта да янындагы изге, ярдәмчел кешеләргә исәп тотып булмавын аңлаячак («Урамнар артында яшел болын», «Урталыкта»). Ә хәзергә, алтмышынчы еллар башларында исә, автор игътибарын тормыш проблемаларының үзара катлаулы бәйләнеше, комплекслылыгыннан бигрәк, аерым эмоциональ яклары — якты һәм караңгы бизәкләре, буяулары, күренешләре җәлеп итә.

Авторның конкрет сурәтләр белән эш итү осталыгы үсә бара. Әсәрдән әсәргә юл сурәте, образ күчеп йөри. Тормыш юллары, шул юллардагы киртәләрне үткәндә кыенлыклар һәм сөенечләр... Кешеләрнең ихтирамын казану юллары... «Язгы кәрваннар» һәм «Дүртәү» әсәрләрендә сурәтләнгән көзге һәм язгы авыл, урман юллары күренешләре күз алдына рәссам сурәте рәвешендә генә килеп басмый, гүя үзеңне шул авыр юлларны үтүче хәлендә тоясың.

«Дүртәү» хикәясендә табигать үзе һәм кешенең физик халәте бергә тасвирлана. Хикәянең төп пафосы — караңгыдан яктыга таба бару. Вакыйгалар бер тәүлек эчендә сурәтләнә. Ә шулай да бу тәүлек, бигрәк тә төн, арбага икмәк төяп юлга чыккан дүрт

яшүсмергә генә түгел, укучыга да мавыктыргыч, очсыз-кырыйсыз булып тоела. Ниһаять, кыенлыклар артта кала, басынкы, төшенке, күңелсез күренешләр әсәр ахырында очраган картның мәгънәле әкияте белән алмашына. Хикәя геройлары — яшүсмерләр күңелендә дә зур үзгәреш була, аларның рухи яктыруы әнә шул сюжет тәмамланышы белән тәңгәл килә.

Әлеге ситуациянең тагын бер вариантын «Язгы кәрваннар» повестында очратабыз. Вакыйгаларны бәйләүче композицион алым бер төрле: юл сынаулары һәм ашлык ташу булса да, бу әсәр бөтенләй башкача якты, оптимистик сурәтләр, буяулар ярдәмендә эшләнгән. Ачлы-туклы яшәп кыш чыккан кешеләрнең бик авыр, җаваплы, газаплы һәм шатлыклы юлы бу.

Кыен минутларда юлчылар бер-берсенә ярдәмгә ашыгалар, авыррак йөкләрне үз чаналарына салып тартырга тырышалар, соңгы икмәк, бәрәңгеләрен бергә бүлешеп ашыйлар. Дуслык, татулык, бердәмлек мисалларын повестьтан бик күпләп китерергә мөмкин. Юл кешеләрнең мөнәсәбәтләрен, бу очракта ярдәмчеллекләрен күрсәтергә мөмкинлек бирә. Димәк, ярдәм сүздә түгел, эштә, гамәлдә күренә. Укучыны уңай мисаллар аша тәрбияләү омтылышы ачык. Авылдашларының үзара җылы мөнәсәбәтләре үтә табигый, самими, ышандыра — менә шушы үзара кайгыртучанлык, яхшылык тантанасы бигрәк тә ачык булып Ибраһим һәм Әлбинә мөнәсәбәтләрендә гәүдәләнә.

«Язгы кәрваннар»да җитди, моңсу лирик стиль өстенлек итә. Лирик штрихлар бик чамасын белеп кенә кулланыла, нәкъ әнә шул эчке күңел җылылыгы белән сурәтләнгән лирик хисси күренешләр әсәрнең гомуми лирик фонын билгели (язгы авыл пейзажы, еракта ишетелгән моңлы җыр, герой уйларының салмак, эзлекле агышы һ.б.).

Язучы бу повестьта халкыбызның кунакчыл, күмәк эштә бер-береңне кайгырту, бер-береңә булышу кебек күркәм милли сыйфатлар ачык гәүдәләнгән кайбер әсәрләргә — Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов иҗатларына таяна, шул традицияләрне дәвам итәргә чакыра.

Әсәрдә реалистик детальләр төгәллеге белән яшьлеккә хас югары романтик хисләр пафосы искиткеч матур үрелә.

«Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм Нәфрәт турында хикәят», «Берәү» повестьларының геройлары — сугыш чорында үскән авыл яшьләре — барысы да элек-электән бөртекләп җыелган, тупланган халык тәҗрибәсен, күркәм гадәт-карашларын хөрмәт итүче сабыр, акыллы, тыйнак хезмәт кешеләренең шифалы йогынтысында тәрбияләнәләр. Әнә шул аларга дәһшәтле чор сынауларын намус белән үтәргә көч, мөмкинлек бирә.

Характерны формалаштыручы әлеге мохитне туган авыл, якын тирәлек рәвешендә генә сурәтләү берьяклы һәм кирәксез идиллиягә дә әверелеп китәргә дә мөмкин иде. Бәхеткә каршы, әдип иҗтимагый һәм көнкүреш мөнәсәбәтләренең чынбарлыкта шактый ук катлаулы, каршылыклы икәнлеген, әлегә без күрергә теләгән килешү — үзара аңлашу, гармония дәрәҗәсеннән түбәнрәк һәм ераграк торуын вакытында сизеп алды.

«Җомга көн, кич белән...» (1979) повестенда без кешеләр арасында эчкерсез, саф, дусларча, туганнарча мөнәсәбәтләр тарафдарын — Бибинур карчыкны очратабыз. Биредә А.Гыйләҗев повестьларын аз-азлап урата башлаган идиллиянең эзе дә калмаган. Укучыны менә нәрсә уйландыра: бөтен гомерләрен башкаларга багышлаган, кешеләр бәхете өчен яшәүчеләр үз ихтыяҗларына килгәндә артык тыйнаклар, үзләрен якларга алар күнекмәгәннәр һәм намуссызлык, битарафлык, әрсезлек каршында көчсезләр, башкаларга ярдәмчелләр кыен вакытта үзләре ярдәмсез калалар... Нинди зур гаделсезлек!

Рәхимсез, күпләргә шәфкатьсез булып тоелган финал — Бибинурның ялгызы, урман чокырында кыргыйлашкан этләр өере уртасында калуы — повестьның әнә шул уйланылышына гаҗәп төгәл туры килә, төп идея шул рәвешчә ассызыклана. Авылдашларының битарафлыгы, якыннарының онытуы, туганнарының хыянәте шушы эпизодта яңача ассоциацияләнә һәм әсәрнең логик эзлекле, драматик тәмамланышы рәве-

шендә әсәрнең эмоциональ пафосын көчәйтә. Бибинур язмышы үзара ярдәмләшү, туганлык тойгыларын кадерләү, табигый кешелекле бәйләнешләр, кеше ихтыяҗына игътибарлылык кебек гадәти, гади һәм аңлаешлы хакыйкатьләр турында бик җитди уйландыра. Шушы гади хакыйкатьләр онытылып, әхлак кагыйдәләрен бозуга юл куелса, олы фаҗигагә юл ачык дия сыман язучы.

Күренешләрнең асылы, эчке мәгънәсе, сәбәпләренә тирәнрәк төшә, якыная бару белән сораулар кимеми, киресенчә, арта бара. Бибинур һәм Зөһрәбану, игезәкләр була торып та, ничек итеп аларның берсе мәхәббәт тарафдарына, ә икенчесе кешеләр нәфрәтләнерлек фигурага әйләнгән? Ни өчен үз канаты астына алып үстергән балалар Бибинурны онытканнар, ташлаганнар?

Аяз Гыйләҗев әнә шулай кешеләрнең үз-үзенә таләпчәнлеге кимегәндә котылгысыз әхлаксызлык, мещанлык, паразитлык дөньясына күчү процессын күзәтә, шул үзгәрешнең сәбәпләрен рухи ярлылык, рухи сукырлыкта күрә.

Әсәрдә Бибинур образының әдәби эшләнешенә, гаять үзенчәлекле булуына игътибар итми мөмкин түгел. Тәнкыйть героиня язмышы аша үтә җитди һәм актуаль проблемалар күтәрелүен бердәм билгеләп үтте, мөлаем характерга сокланып, бу биографияне күздән кичерде, образның социаль-мәгънәви функциясенә анализ ясады.

Шуның белән бергә «Җомга көн, кич белән...» повесте төзелеше, әдәби стиль, сурәтләү чаралары сайланышы белән дә үтә үзенчәлекле әсәр — әгәр бу игътибардан читтә калса, анализ һәм бәя тулы булмаячак.

Бибинур образы повестьның буеннан-буена үтә. Фәкать берничә бүлек кенә башка персонаж турында. Биредә сүз Бибинур тормышында хәлиткеч роль уйнаган кеше — колхоз председателе Җиһангир Сәфәргалин турында бара. Беренче бүлектә үк аның



үлеме тасвирлана — кешеләр бәхетенә гомерен багышлаган коммунист Җиһангир алар тормышында якты эз, ә Бибинур күңелендә матур мәхәббәт хисе кабызып, дөньядан иртә китеп бара. Бибинур күңелендә аның турында хатирәләр кат-кат уяначак әле — истәлекләр, уйланулар аша Бибинурның тормыш сәхифәләре яктыртыла, характерның төрле яклары ачыла бара.

Образның үтә җентекләп эшләнүенә, ышандыру көченә күптөрле юллар белән ирешелә: Бибинурның кешеләр белән бәйләнеш җепләре бөтен нечкәлекләре, бөтен ваклыкларында тасвирлана. Сүз уңаенда героиняның үз эченә бикләнгәнрәк икәнлеген дә искәртик. Шулай булгач, Бибинур — Җиһангир, Бибинур — Зөһрәбану, Бибинур — авылдашлары һәм Бибинур белән ул үстергән балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне шактый ук детальләп сурәтләргә кирәк булган. Бу мөнәсәбәтләр максималь тулылыгында бирелә, биредә кабатлаулар да урынлы, мөнәсәбәтләрнең үзләре урынына шул кешеләр турындагы уйлар, фикер йөртүләр дә күп очрый.

Аяз Гыйләҗев тормыш-көнкүреш штрихларының дөреслеге, төгәллегенә һәрвакыт туры булды, бу — аның әһәмиятле кредосы. «Җомга көн, кич белән...» повестенда мондый төгәллек бик зур роль уйный — героиняның ышандыру һәм тәэсир көчен арттыра.

Икенче бер принцип — ул язу манерасының мавыктыргыч, гади, аңлаешлы һәм кызыклы булуына ирешү.

Характер сайланышы һәм яктыртылышына тукталыйк. Гомумән, яшьләр турында язарга яратучы Аяз Гыйләҗев бу повесть үзәгенә олы кеше — тәҗрибәле, тормышның ачысын-төчесен татыган, гомер юлының ахырына якынлашып килүче кеше образын куя. Бу өлкәдә татар прозасы туплаган тәҗрибә шактый зур. Шундый образ — характер аша җитди, актуаль проблемалар кую мисалын Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә очраткан идек.

Бибинур образының драматизмы капма-каршы куюга нигезләнгән. Ул гомерен башкаларга багышлаган, тик кешеләргә булган олы мәхәббәте җавапсыз калган. Тәрбия-

ләп үстергән балалары аны онытканнар. Фаҗигале үлеме — коточкыч гаделсезлек, әшәкелек тантанасы булып аңлашыла. Мондый гаделсезлек, мондый хәлләргә юл куярга ярамый, күңел сукырлыгыннан котылырга кирәк — әнә шулай укучыда тискәре күренешләргә карата актив мөнәсәбәт, мондый күренешләрне кабул итә алмау, кире кагу мөнәсәбәте тәрбияләнә.


Повестьның катлаулы композицион структурасында поэтик детальләр бик зур роль уйный. Мәсәлән, пофрен — авыл читендәге буаның шаулаган тавышы — гомер агышының символы һәм героиняның уйлары истәлекләр дөньясына юнәлүен ишарәләүче бер билге ул. Гади көнкүреш вакыйгалары һәм баш геройның соң чиккә җиткән күңел сыкравы янәшә куелганда, бу детальнең тәэсир көче аеруча көчәя: «Бибинур карчык та көтте. Бер кайтырга тиеш бит инде алар! Җаннары булса, аналары янына Сабан туена бер кайтырга тиешләр!

Почта кызлары гөр-гөр килеп сөйләшәләр, алар Бибинур карчыкны юри күрмәмешкә салышалар. Алар карчыкның ни көткәнен бик яхшы аңлыйлар.

Ә буа шаулый. Шаулый! Җиһангир Сәфәргалинны озаткандагы кебек, ул моңсу шаулый...

Буа. Почта. Ялгыз һәйкәл...

Аяз Гыйләҗев. 1955



Буа тавышы бер акрыная, бер көчәя. Бибинурга гына шулай тоеладыр ул, чөнки аның зиһене кинәт кенә томаланып куя, аннан тагын ачыла... Ул егылып китмәс өчен чытырдатып күзләрен йома... Егылмый, турая, күзен ачканда, буа тагын да ныграк шаулый башлый. Әллә кайларга чакырып шаулый буа!»

Аяз Гыйләҗев җитди проблемаларны укучыга җиткерүнең яңа юлларын эзли. Беренче карашка җиңел һәм мавыктыргыч булып тоелган вакыйгалар, сюжет конструкцияләре, җитди фикерләр алып киләләр, укучы аңына катлаулы сораулар куялар, уйландыралар. Моның иң уңышлы мисалы — «Җомга көн, кич белән...» повесте. Мондый эзләнүләр «Әтәч менгән читәнгә» повестенда (1980) да дәвам иттерелде. Бу — ыгы-зыгылы, шаян, күп бизәкле, бөтерелмә, үтә уйнак бер тонда язылган әсәр. Әдип әхлак, яшьләр тәрбиясе, олыны — олы, кечене кече итә белү кебек җитди әйберләр хакында да сүз кузгата. Язучыны кеше тормышының көнкүрештәге гадәтилегеннән бигрәк, кискен

рухи үзгәрешләре кызыксындыра. «Ур-
талыкта» (1971) повестенең үзәгендә
иҗат кешесе образы тора. Сәгыйть әк-
рен-әкрен олы идеалларын оныткан,
аның интерес-ихтыяҗлары күбрәк да-
ча, йорт-җир кирәк-яраклары, кәеф-сафа яратучы дусларының күңелен күрүдән читкә
китми башлаган. Иҗатында да торгынлык — ул чын иҗатчы булудан бигрәк гап-гади
һөнәрчегә әверелеп бара. Үзенә карата тугры сүзне күзгә карап әйтүчеләр белән ачу-
ланышкан, сүзгә кергән. Әнә шундыйларның берсе — гадел, намуслы Баязит Гари-
фуллинның төзәлмәслек чир белән авырып китү хәбәре Сәгыйть күңелен тетрәтеп,
үзгәртеп җибәрә. Остазы белән очрашып, сөйләшеп, аның бәхилләшү сүзләрен алу
герой өчен үтә җитди бернәрсәгә әверелә. Бу очрашу, сөйләшү булачакмы, юкмы —
әсәр сюжетының төп сызыгы да шуннан уза. Чөнки ул Сәгыйтьнең алга таба бөтен
тормышының мәгънәсен билгеләячәк.

Повесть авторның «мин»е исеменнән алып барыла. Ләкин геройның иҗат кешесе
булу факты шулай да бу әсәрне автобиографик әсәр дип атарга мөмкинлек бирми әле.
Аяз Гыйләҗев әсәрне биография мотивларына максималь якынайтып, фәкать бер бу-
рычны күздә тоткан: ул укучыга күңел тупаслануы, әхлак позицияләрен югалту, ме-
щанлык чире һәркайсыбызга яный, һәрвакыт чын кеше булып кала белегез, дип искәр-
тә.

Әдип иҗатында шул рәвешчә тагын бер тематик юнәлеш — «шәһәр» линиясе,
шәһәр яшьләре, интеллигенция темасы нык үсеп килә. Алтмышынчы-җитмешенче ел-
ларда язучы иҗатында бу тема зур урын алып тора. Шулай да йөрәктән кичереп языл-
ган әсәрләр күбрәк авыл материалына карый кебек. Шәһәр повестьларының кайбер-
ләре уртача беллетристик әсәрләр дәрәҗәсеннән югары күтәрелмәделәр (мәсәлән,
«Күзгә-күз», «Мең чакрым юл» повестьлары). Бу урында Аяз Гыйләҗев иҗатының
сыйфат ягыннан бик үк тигез булмавы хакында да әйтергә туры килә.

Аяз Гыйләҗев. 1988

Ләкин «шәһәр» әсәрләрен дә әдипнең төп иҗат магистраленнән читкә куеп карамаска кирәк. Биредә сүз идея, максатлар аермасыннан бигрәк, тормыш материалы арасындагы аерма турында гына була ала.

«Зәй энҗеләре» (1963) повестенда А.Гыйләҗев заман героен иҗат итү юлында шактый уңышлы адым ясады. Әсәрдә төзелеш мастеры Гәрәй Шаминның чын тормыш борчулары, эш мәшәкатьләре, шатлыклары, үзе инанган максатка бару юлындагы киртәләрне җимерү, вакытлы җиңелүләрнең ачысы — барысы да вакыйгалар тезмәсе рәвешендә генә түгел, ә күңел хәрәкәте аша җанландырып сурәтләнә. Яшь белгечнең осталыгы арту үзеннән-үзе аңлашыла, әмма безне, барыннан да бигрәк, Гәрәй күңелендәге үзгәрешләр кызыксындыра. Повестьны чын-чынлап Гыйләҗевнеке иткән бер сюжет сызыгы барлыкка килә: күмәк эшне оештыру барышында Гәрәйнең үз күңеле тупаслана, ярлылана бара. Мастерның дорфалыгыннан намуслы, яхшы эшчеләр дә интегә башлыйлар.

Әсәр ахырында Гәрәй-Гәүһәр мәхәббәте белән бәйләнгән сюжет сызыгы геройны рухи савыктыру функциясенә буйсындырыла. Кызганычка каршы, нәкъ шушы урында автор кинәт кенә вакыйгаларны җентекләп дәлилләү принцибыннан читләшә, һәм, әйтергә кирәк, мондый игътибарсызлык яисә ашыгу сәбәпле, әсәрнең бик матур, җитди уйланылган идеясе — кеше рухын олылау, бер-береңне аңлау, аңларга омтылу кирәклеге идеясе тоныкланыбрак кала.

«Урамнар артында яшел болын» дип аталган роман да (1969) заманыбыз кешеләрен борчучы проблемаларның муллыгы һәм үзенчәлекле төзелеше белән игътибарны җәлеп итә. Иң алгы планга кешенең җәмгыять, халык, ил алдында җаваплылыгы, бурычы мәсьәләсе куела. Бу сорау романның баш геройлары — яшь журналистлар Идрис һәм Әхәт алдында да тора. Характерлары, табигатьләре белән бер-берсеннән нык аерылсалар да, бу ике егетне үзара якынайта торган яклар да бар — икесе дә намуслы, әйбәт булсын дип эшләүче, профессиональ яктан югары әзерлекле, культу-

ралы, мәгълүматлы кешеләр алар. Идрисне дә, Әхәтне дә Җир шарындагы хәлләр, кешелек язмышына кагылышлы хәбәрләр уйландыра һәм борчый. Сүз, әңгәмә уңаенда аларның әдәбият, сәнгать, культура өлкәсендә дә хәбәрдар, яхшы хәзерлекле булулары аңлашыла. Биредә сюжет агышына турыдан-туры бәйләнмәгән, очраклы рәвештә, сүз уңаенда гына әйтелгән реплика-штрихларга да укучы игътибарлы, сизгер булырга тиеш. Алтмышынчы еллар татар прозасы өчен бу да яңалык, сәеррәк күренеш иде. Биредә Аяз Гыйләҗев түбәндәге хакыйкатьне истә тота: һәр яңа әсәрдән алдынгы фикерләр, тирән эчтәлек, тәрбияви эффект таләп ителә икән, бу, үз чиратында, яңа әдәби формалар, алымнар, күңел дөньясын сурәтләүнең дә башка чараларын сорый.

«Урамнар артында яшел болын» — нигезенә әйбәт, якты фикер салынган, чын дуслык, тугрылык, совет җәмгыятендә кешенең кешегә булган мөнәсәбәтләренең матурлыгы идеяләрен яклаучы әсәр дип бәяләнде. Шуның белән бергә әдәби җәмәгатьчелек бу әсәрнең композицион яктан таркаурак булуына да игътибар итте. Мәсәлән, Ә.Еники фикеренчә, роман «бер мәсьәлә белән төенләнгән, бер фикер һәм хис белән сугарылган булырга тиеш. Әмма әсәргә бөтенлек җитеп бетми. Анда өч төрле сюжет бар, өч төрле проблема күтәрелә. Әсәрдә баланың тирә-юньгә мөнәсәбәте шактый киң бирелгән. Ә автор романда шундый зур проблеманы ташлап, икенче бер мәсьәләгә күчә, укучыны ярты юлда туктатып калдыра». («Социалистик Татарстан», 1970, 19 июль.)

Планета язмышы, киләчәге өчен борчылучы журналист егетләр («Урамнар артында яшел болын»), кешеләр бәхетенә бар булган гомерен багышлаган колхоз председателе Җиһангир («Җомга көн, кич белән...»), үз эшенә, туган ягына сокланып яшәүче Галимҗан («Үги ана яфраклары») һәм башка бик күп шундый геройлар әдипнең иҗат йөзен, оптимизмын билгелиләр. Менә шуларның берсенә тукталып үтик. Колхоз шоферы Галимҗан («Үги ана яфраклары») өчен бу гадәти эш көне түгел. Бу — аның күңел хисләре ташыган, нечкәргән вакыты. Бүген ул сөйгән кызы Сөмәясе белән аң-

лашачак, көне буе күңеленнән шуңа хәзерләнеп, уйланып йөри. Көзге кыр эшләренең кызулыгы, бертөрлелеге фонында геройның күңел очышы, омтылышы аеруча матур сурәтләнә.

Кинәт кенә алдан исәпләнгән план-хыяллар юкка чыга — кичен икмәк төяп станциягә — өстәмә рейс белән юлга чыгарга кушалар. Бурыч һәм бәхет арасындагы дилемма — хикәянең характерын да, төп идеясен дә ачардай үзәк нәкъ шушы урында. Шәхси бәхет һәм иҗтимагый бурыч шушы нигездә үзара бәрелешәләр. Бирелә эчке көрәшнең булмавы мөмкин түгел — егет үзенең хис-теләкләрен йөгәнләргә мәҗбүр. Шулай да Галимҗанның үз-үзен тотышында да, эчке уйларында да, инстинктив рәвештә генә булса да, канәгатьсезлек сизелми. «Аның күңел капкасы башкалар өчен ябык, бикле иде».

Шулай да әйләнә-тирәдәге җансыз әйберләр аша рухи халәт ачыла: «Мотор теләр-теләмәс кенә кабынды». «Көне буе ак күлмәк якасының аклыгын саклап йөргән иде, хәзер күлмәге дә каралды». «Әй, хәзер барыбер инде».

Теләр-теләмәс кабынган мотор да, ниһаять, аклыгын җуйган күлмәк тә — тышкы атрибутлар — әмма алар язучының чын иҗат табышлары. Рухи хәрәкәтне бу күренештә шулар аша гына белеп була.

Автор характерлар контрастлылыгын да ныклап эшкә җигә. Бирелә начар белән яхшының пычакка-пычак килеп бугазлашуы юк. Сүз дөньяга, тормышка карашларның төрлелеге турында бара. Грузчик Хәнәфинең килеш-килбәте, үз-үзен тотышы, тупас теле — берсе дә Галимҗандагыча түгел. Хәнәфинең дөньяга сокланучан Галимҗанга төбәп «Гомер үтте күләгә булып, шәүлә булып» дип әйтелгән сүзләрендә әлеге аермага бигрәк тә басым ясала. Ә инде Хәнәфи өстәмә рейстан баш тартып, машинадан ук төшеп калгач, аерманың сүздә генә түгел икәнлегенә төшенәсең.

Галимҗанга да шушы юлдан китәргә була иде бит, ләкин характер үсешенең логикасы моңа туры килми шул — әсәрдәге янәшә һәм капма-каршы куелган детальләр тезмәсе ачык идея бурычына буйсындырылган, әдипнең симпатиясе Галимҗан ягында.

Геройның матурлыгына укучыны да сокландыру максатында автор байтак сурәтләү чаралары куллана: үзенчәлекле диалог, табигать паралелльләре, образлар контрастлылыгы һ.б.

«Үги ана яфраклары» әдипнең әдәби техника, форма өлкәсендә ачылмаган мөмкинлекләре гаять зур булуын раслаучы иң яхшы хикәяләреннән иде. Аның иҗатында иң төп казанышлар да хикәя һәм лирик повесть жанрларында ирешелде. Роман, озын повесть юнәлешендәге эзләнүләр аңа әлегә тиешле, көткән нәтиҗәләрне биреп җиткермиләр. Аерым уңышсызлыклар, кагыйдә буларак, композиция пропорцияләренә игътибар җитмәгәндә күзәтелә. (Мәсәлән, «Мең чакрым юл».) Татар лирик прозасының иң яхшы традицияләреннән берсе — кешене табигатьнең иң гүзәл, иң камил заты итеп карау, уңай характерларның олылыгын табигать матурлыгы гармониясенә тәңгәл кую — Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә уңышлы дәвам иттерелә.

Хәзерге проза стильләренең бай һәм шактый чуар фонында Аяз Гыйләҗевнең эзләнүләре аеруча игътибарга лаек. Менә шушы яңалыкны сизү, раслау тойгысы әдипнең бөтен иҗат юлы дәвамында шактый эзлекле үткәрелеп килә — ул һәрвакыт яңалык, ачыш эзли, тормыш күренешләрен башкачарак, үзенчәрәк күрә һәм аңлата. Ә болар реализм әдәбиятының башка бик әһәмиятле таләпләре: югары принципиальлек, сәнгатьчә осталык, заманчалык, тормышчанлык, халыкчанлык, партиялелек онытылмаган очракта уңай нәтиҗәләр бирми калмый.

«Казан утлары»

1986, № 7, 148–153 б.



НӘКЫЯ ГЫЙЛӘҖЕВА

Бара юлдан язгы кәрванннар...

«Язгы кәрваннар» повесте «Казан утлары» журналында басылгач, Сибгат ага Хәким: «Аяз, мин синең ул повестеңны җылый-җылый укыдым. Син анда, үзең кичергән яшьлек еллары рухын саклаган хәлдә, каләм көчеңнең олпатлыгын раслагансың. Түзмәдем, шул исемдә шигырь яздым», — дигән иде. Ул шигырен Сибгат ага 1978 елның 10 гыйнварында язган икән. Ә Аязга 1976 елда чыккан «Шигырьләр» китабын бүләк иткәндә, ул түбәндәге автографны язган: «Аяз туган! Әдәбиятта членнар күп, чын язучылар, художниклар аз. Син — шул азларның берсе. Галимҗаннар, Әмирханнар токымына хөрмәтем зур! Сибгат Хәким. 9.02.77.»

Сибгат ага Хәким озак еллар дәвамында СССР Язучылары союзына Татарстан бүлегенең кабул итү комиссиясе рәисе булып торды. Аяз аның урынбасары булып, алар бергә уртак тел табып эшләделәр. Корылтайларның берсеннән соң идарә утырышында сүз булып: «Аяз күп кенә язучыларның әгъзалыкка үтүен тоткарлый, аны кабул итү комиссиясендә калдырмаска», — диләр. Шулай аларны бермәлне аерып куйдылар.

Сибгат ага йомшак холыклы, итагатьле буларак, әгъзалыкка дәгъва кылучыларга туры сүзен әйтергә булдыра алмагандыр дип уйлыйм хәзер. Ул: «Аязны кире урынбасар итеп куймасагыз, мин бу эштән баш тартам», — дип, Язучылар идарәсендә сүз кузгаткан. Яңадан Аязны аның урынбасары итеп сайладылар. Аяз соңга таба үзе дә рәис булып эшләп алды. (Ул вакытта андый эшләр бушлай гына, иҗтимагый итеп кенә эшләнәләр иде.) Элгәрге елларда аның рәис итеп сайлану хокукы булмады кебек исемдә калган. «Ник?» дигәндә, ул беспартийный язучы иде ич.

Еллар узды. Сибгат ага Хәким «Минем таныш өянкеләр» шигырен язды. Аңа Рөстәм Яхин аваздаш яңгырашлы шәп көй дә иҗат итте. Сәхнәләрдән ул җырны Рафаэль Сәхәбиев һәм Вафирә Гыйззәтуллиналар тамашачыга тәкъдим итә башладылар. Шул җырның музыкасы әз генә кузгала башлауга ук, Аязым үзенә-үзе урын таба алмыйча елый иде.

15 ноябрь, 2005

Аяз һәм Нәкыя

Гыйләҗевләр.

1988



СИБГАТ ХӘКИМ

Язгы кәрваннар

Хатын-кызлар килә иде тезелеп,

Кычкырдылар: ал, дип, атыңны...

Юк, сукмады абый, әйтерсең ат

Оятыннан читкә атылды.

Оятымнан мин чанадан төштем,

Йөрәгемне арыш тырнады;

Алар тартып кайткан чаналарда

Йоклый иде арыш кырлары.

Йоклый иде бодай басулары,

Йоклый иде яшел дулкыннар...

Чәчми калсаң әгәр, шушы кырлар

Гомер буе, беләм, сулкылдар.

Атны абый өйгә таба борды,

Атка җиңел хәзер, ат чаба.

Үземә дә җиңел иде минем,

Мин җәяүләп киттем Арчага.

Горур йөзләр, күзләр, ул карашлар

Күңелемдә язылып калганнар.

Зәңгәр күккә горур башны чөеп,

Бара юлдан язгы кәрваннар.

10 гыйнвар, 1978

Сугыштан соң икенче яз, моңсу

Язы иде кырык алтының.

Без чанада икәү, бездән башка

Эзе дә юк кырда атлының.

Абый белән икәү, озата мине,

Аты ябык, арык ат иде,

Минем күңелем кебек әкрен-әкрен

Эреп барган йомшак март иде.

Сугыштан соң күренеп китү өчен

Кайткан идем, юлым Арчага.

Тик без генә атлы, сугыштан соң

Калган бары бер ат, бер чана.

Безнең атның курка-өркәсе юк,

Дилбегәне абый буш тоткан.

Икенче бер, бүтән бер дөньядан,


Ак кар дөньясыннан, бушлыктан,

Кинәт кенә пәйда булды алар:

Ни икәнен сөеп назлауның

Онытып күптән, авыр чана тартып,

Төркеме күк киек казларның,



ӘНӘС ХӘСӘНОВ

Аяз Гыйләҗев чын әдип иде

Аяз ага белән беренче очрашуым әле дә хәтеремдә бик яхшы саклана. 1973 елда Ленинградтан каникулга кайткач, Казан телевидениесе өчен бер тапшыру оештырырга уйладым. Теләгем зурдан һәм матурдан иде. Казан мех комбинатының гөрләп эшләп торган чагы. Анда тегелгән матур, сыйфатлы туннарның даны ераkларга тарала. Комбинатның даны нәрсәдән тора соң? Анда эшләүче «алтын куллар» кемнәр алар? Әгәр дә шул осталар янына күренекле әдип Аяз Гыйләҗевне алып барсам, осталык серләрен ул да сорашса, бу әдип иҗаты өчен дә кызык булыр иде, телевидение дә гадәти булмаган тапшыру күрсәтер иде дигән теләк туды. Аяз ага берсүзсез риза булды, кызыксынып китте. Билгеләнгән көнне комбинатка үз вакытында бик төгәл килеп тә җитте.

Моңа кадәр минем аны якыннан күргәнем юк иде. Калын пыялалы күзлекле. Агара башлаган куе чәчле, үткен карашлы әдип әллә кайчан таныш кебек каты итеп кулымны кысты, танышып, сөйләшеп киттек. Аның җор тел байлыгына, фикер тирәнлегенә шатланып, мин, тапшыруыбызның яхшы чыгачагына өметләнеп, хәзерлек эшләре белән мәшгуль булдым. Ләкин тапшыруыбыз булмый калды. Телевидениедә нәрсә килеп чыккандыр, әллә машиналары ватылган, әллә кинооператор эшкә килмәгән, сәбәбен дә белеп булмады... Кыскасы, телевидение бригадасы килмәде. Мин Аяз агадан гафу үтендем. Аның кәефе китте, ләкин һич тә күтәрелеп бәрелмәде. Нишлисең, була

торган хәл инде, парин, дип, үзе мине тынычландырырга тырышты. Мин аңа ул чакта бик рәхмәтле булдым, иҗат эшемнән аерып йөрисең шунда, дип ачуланса да урынлы булыр иде бит.

...Икенче мәртәбә якыннан очрашу Газиз Мөхәммәтшинның хатыны Ләлә ханым оештырган мәҗлестә булды. Ул кичәдә Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин, Илдар Юзеев, Шамил Рәкыйпов, аларның хәләл җефетләре дә катнашты. Җырлы, биюле бу кичәдә Аяз аганың халкыбыз милли җырларын аз белүебезгә ачынып, әрнеп сөйләве хәтеремә уелып калды. Надан тәгълимат хуҗаларының бармактан суырып алган «яңа тарихи бердәмлек — совет халкы» дигән теориясенә таянып, бер милләтне өстен куеп, «аз санлы» милләтләрнең мәдәниятен кыскан заман иде шул. Аяз аганың: «Ничек кенә безне кысмасыннар, җырларыгызны белмәгез, өйрәнмәгез, дип әйтүче юк бит, җәмәгать», — дигән сүзләре минем колагымда әле дә яңгырап тора кебек.

...Әдип белән соңгы очрашуым Президент сараенда булды. Аны Аппарат егетләре култыклап баскычтан М.Шәймиев белән очрашырга алып менеп килгәндә, бер-беребезне сәламләдек тә туктап калдык. Аяз ага сулышын бүлә-бүлә миңа:

— Шигырьләреңне укып барам. Яз-яз, — дип, үзенчә фатиха биреп, авыр атлап менеп китте.

Шуннан соң инде ул озак яши алмады, бакый дөньяга — Ходай Тәгалә карамагына китеп барды. Урыны оҗмахта булсын! Ул чын мәгънәсендә олы әдип иде.

Декабрь, 2005



МӘГЪСҮМ ХУҖИН

Әдипнең иркле дөньясы

Һади уйнарга ярата. Әмма әллә ничәмә гаи-

лә яши торган сузма коридорлы йорттагы бер

бүлмәле фатирда ул инде иркенләп уйный ал-

мый, малайга инде киңлек кирәк. Ишегалды да

кысрык — тупка тибәсең, һәм кысыла-шәлпе-

рәя башлаган тубың берәрсенең тәрәзәсенә оча

да куна һәм чылтырт! Моңарчы ватылмаган өл-

гене сайлап эзләп табадыр, әй, шул шоп-шома

пыялага ябышып-сыланып ял итмәкче бугай. Әл-

лә Һади типмәсен өчен юри йомшаганмы туп?

Һе, көт, типмәс ди Һади, чатыр чабып килеп ти-

бәчәк тә җәһәннәм түренә очыртачак әле ул сине!..

Сүз әдип сурәтләвен дә теркәштереп, Аяз

Гыйләҗевнең «Тәрәзәләр» (1960) исемле хикә-

ясе һәм аның герое Һади турында бара. Бигрәк

тар шул Һадиларның уйнар урыннары. Ишегалды арысланнар япкан читлеккә охшаган. И-их, ишегалдыннан читкә, еракка китәсе,

теләгәнчә уйныйсы, чабасы-йөгерәсе иде. Тибикче әле тупка тагын бер тапкыр, күк

түбәсенә бәрелсен дә сихри сәяхәтеннән Һадиның аягына ук кире төшеп кунсын ул!

Тик... тагын чылтырт!..

Димәк, Һадиның әнисе Маһирә пыялачы Фәхриев абыйны тагын чакырырга мәҗ-

бүр. Үзгә холыклы кеше ул Фәхриев абый. Аның сүзләренең мәгънәсенә кайчакта тиз

генә төшенә дә алмыйсың. «Кешене тышкы дөнья белән бәйли тәрәзә», — диде пыя-

лачы абый соңгы килүендә. Әй-лә, ничек инде кеп-кечкенә тәрәзә кешегә дөньяны —

зур лабаса дөнья дигәннәре! — бөтенләе белән күрсәтә алсын?! Алай... Әллә соң тәрәзәләр чыннан да фани һәм әкияти дөньяларны ачучы бәхет капкаларымы икән?! Һәм

Һади таяктан тәрәзә рамы ясый башлый...

Әйе, сыймый тарлыкка малай, аның күңеле иркенлеккә, иреккә омтыла. Шулай булмый ни, тимер читлеккә ябылган арыслан хәленә калмассың ич инде.

«Җомга көн, кич белән...» повестендагы (1979) Бибинурга да үз даирәсе кысан. Тик аңа түземлек, сабырлык хас, ихтыяры көчле. Ашкын мәхәббәтенә йөрәгеннән бәреп чыгарга юл бирми ул. Моның сәбәбе нәрсәдә икән соң? Аның холкына хас сыйфатларында гынамы? Юктыр. Бибинур мәхәббәте фани дөньяга сыймастыр, шуңа күрә гап-гади апабыз олы мәхәббәтен үзенең иксез-чиксез күңеле дөньясында саклыйдыр. Бу мәхәббәткә нәкъ аның күңел дөньясында иркенрәк, бу мәхәббәт үзен бары тик шушында иркен тоя.

Әйе, Аяз Гыйләҗевнең әлеге әсәрендә дә җан иясенә хас иркенлек-ирек хаҗәте үзәктә тора.

«И-и, төрмәнең сөенечле мизгелләре!» Тетрәндергеч бу җөмлә әдипнең «Йәгез, бер дога!» романында (1990) яңгырый, нәкъ менә тетрәндереп яңгырый. Моны әйтү өчен төрмәдән иркенлеккә омтылышның сулыкмас, хокуксызлыктан ирекккә канатларыңны сындырмыйча оча алуыңа ышанычың какшамас булырга тиеш. Тоткын-мәхбүс моңа ничек ирешә алыр, гомумән, ирешә алырмы соң? Әмма бар икән ич хәл ителмәстәй тоелган мәсьәләнең чишелеше!

Һәм егет белән кыз яшертен рәвештә хатлар алышалар. Аларның бер-берсен моңарчы, бәлки, күргәннәре дә юктыр, әлегә алар бер-берсенең төсен-йөзен дә белмиләр. Алар — ябылуда, алар — тоткыннар. Алар җәберләнүдән котылу әмәлен бергәләп таптылар, рухи дөньяның мәхәббәт кочагында ирекле гизәләр.

Без Аяз Гыйләҗевнең хикәясенә, повестена, романына күз йөгертеп алдык, ягъни читлектән-кысанлыктан хөрриятккә-ирекккә ирешү көрәшен үстерештә — хикәядән романгача барышта күрдек. Иҗаты буенча әдип шушы лейтмотивка тугры булды һәм моны үзәктә тота алды. Шушы сыйфат Аязның тормыш итүендә дә чагыла иде.

Аяз белән без соңгырак елларда (без 50 елдан артык аралашып яшәдек) ешрак очракта телефоннан гына хәл белешә идек. Сирәк кенә (бик сирәк) ул мине шәһәр урамнарында йөреп керергә чакыра иде. Тик без урамнарны буйламый идек, очрашкач ук Аяз шәһәр читенә — иркенлеккә таба күрсәтә иде. Сүз, әлбәттә, әдәбият турында иде, гаилә хәлләренә «шөкер» һәм «әйбәт» дигәннәре җитә иде. Монысы — табигать кочагындагы хөрлектә хозурлык.

Әмма кайчакта чынлыктагы кысанлыкны киңәйтергә көче-сәләте җитә иде Аязның. Яшьрәк чакта мин аларның фатирында һәм дача йортында еш булгаладым. Ике бүлмәле кечкенә фатирда алтау яшәделәр алар: үзләре, игелекле әби, кечкенәдән эшчән һәм уйлы өч уллары. Дача йорты иркенрәк булса да, Аяз чарлактагы иелеп йөрешле куышына (эш бүлмәсенә) сыйдыра, кунакка сыйны шунда төрләндереп һәм мулдан куярга ярата иде. Моңа, әлбәттә, хәләле Нәкыя ханымның Аязы янына дус-ише килүгә сөенүе дә сәбәпче булгандыр. Әйе, бу очракта алар әлеге куышны җитәкләшеп киңәйтәләр иде!

Хезмәте дә колачлы иде Аязның. Атап кына узыйк: хикәяләре, повестьлары, романнары, пьесалары, төрле темаларга мәкаләләре... Дүрт томлыгы чыкты, көндәлек матбугатта яки китап булып басылып та, яки сәхнәдә уйналып та томлыгына кермәгән әсәрләре шулай ук күп, бик күп. Ул укучылары белән еш очрашты, аларга яңалык әйтү өчен алдан әзерләнә иде, укучысы алдына беркайчан да «буш кул» белән басмады. Татар язучылары арасында каләмдәшләренең һәм яшь авторларның кульязмаларын аның кебек күп укып киңәш бирүчеләр сирәктер. Соңгы әңгәмәләренең берсендә Аяз, кульязма хәлендә мирасыгыз күпмегә җыела, дигән сорауга:

— Утыз папка, — дигән иде. — Аларны Нәкыя карамагына калдырам, — дигән иде...

Менә ул — иркен иҗат мисалы!

Аяз Гыйләҗев күп кешеләр белән хатлар алышты, аның бу мирасы да бай. Хатларында ул холкынча турыдан бәрә иде. Миндә ачуланып язган бер хаты бар аның. Аязның ачулануына (бу очракта да әйтәсен иркенләп әйтеп бетергән) һич тә

үпкәләмәдем мин. Ул хаклы иде: акрын «кыймылдыйсың», «шуны да белмәскә» кебек ачы сүзләрдән башлаган да, иркенәеп китеп, әллә кайларга барып җиткән.

Мин дә аның әсәрләрендәге сөртендерүче кытыршы түмгәкләр турында әйткәли идем. Еш кына ул:

— Беләм инде, парин, үзем дә беләм... — дияр иде. — Ашыгылганмы, әллә бүтән сәбәпме шунда. Иркенәеп, тыныч кына шомартам әле мин ул кытыршыны...

Кайчакта кызышып ук бәхәсләшә идек, ләкин ачуланышмый идек. Шулай да бера-ра ике арадагы мөнәсәбәт киеренкеләнде. Гаеп кемдә булгандыр, икебез дә абайла-мыйчарак калдык. Анысы минем холыкның да алама төшләре бар инде, бәлки, арала-шуның сүлпәнәюенә минем уйланып җитмәгән бер-бер гамәлем сәбәптер. Без, оч-рашканда, хәл-әхвәл бүлешүдән узмый башладык, тик болар ясалма чыга иде.

Һәм бер очрашуда Аяз йөзен балкытып эндәште:

— Парин, сагындым сине!

— Сигез ел рәтле-башлы сөйләшмәгән идек, — дип елмайдым мин, ел исәбе тел очыннан үзе очып чыкты.

— Сигез елмы, парин?

— Сигез ел!

Әлбәттә, мөнәсәбәтләр киеренкеләнүе сигез елга түгел, сигез атнага да сузылма-гандыр, әмма Аязга болай күпертү ошады. Соң, шулай булмый ни, минем арттыруда ук җиңү иркенлеге бар лабаса — «сигез» ел дәвам иткән аксак-туксаклыкны бер җөм-ләсе белән бетерде ләбаса Аяз. Монысы да аның күңеле киңлеге ич.

Беркөнне мин аңа радиодан хикәямне укыячаклары турында әйттем. Тапшыру бе-түгә шалтыратты Аяз.

— Парин, ә, парин, үзенә әйтеп куйган идеңме? Тыңлады микән? И-их, парин...

Хикәя үсмер малай белән кызның бер-берсен ошатулары, ягъни беренче мәхәббәт турында иде. Вакыйга беренче заттан сөйләнә, анда, вакытлар узгач-узгач, лирик ге-ройның яраткан кызына — инде әби кешегә — бала чакларын яңартып һәм хәтта ачыр-

галанып-өзгәләнеп эндәшүе дә бар.

— Тыңлаган булыр. Әйткән идем...

Аяз шушы беркатлы (әдәби иҗат серләрен миннән яхшырак белә ич ул) һәм рия-

сыз (гадәттә үзен җитди тоту хас иде аңа) соравы белән мине бала чагыма кабат кай-

тарды, бүгенге кичерешләрем дәрьясын киңәйтеп-иркенәйтеп җибәрде. Һәм мин хи-

кәядәге кызчык — әбекәй Озынчәч В.нең (әсәрдә аның исеме шулай гына бирелә)

телефоннан шалтыратуын хәзергәчә көтәм. И-их, хыял дөньясының иксез-чиксезлеге!..

Безнең язучыларның кайбер әсәрләрен башка халыклар язучылары әсәрләре белән

чагыштыргалыйлар. Янәсе, без кабатлыйбыз. Әйе, гел дә яңаны уйлап чыгару мөмкин

түгел, борынгыдан килгән тема, эчтәлек, жанр кабатлана тора һәм кабатланачак, бо-

ларның (тупасрак әйткәндә, калыпларның) ничә төрле булуы әдәбият гыйлемендә хәтта
саналган. Бөтен хикмәт — үзенчә язуда.

Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәрен Чыңгыз Айтматовның «Ранние журав-

ли» повестена охшатучылар булды. Төпченә төшсәң, үзара охшашлыкны табарга да

мөмкиндер. Әмма миңа Аяз әсәре ошыйрак. Һәрьяктан. Аязның иҗатын РСФСР Язу-

чылар берлеге тикшергәндә, бер язучы, күренекле әдип Майя Ганина булса кирәк (ул

Аязның берничә әсәрен русчага тәрҗемә иткән), Аяз Гыйләҗев иҗатын Бөтенсоюзга

элегрәк киң рәвештә белдерү кирәк булуын әйтә. Безнең әдипләр, хәзер дә соң түгел

ич, диләр. Җавап кыска:

— Соң инде...

Аязның әсәре 1972 елда языла. Чыңгыз Айтматов әлеге повестен өч елдан соң,

дөрес, Аяз әсәренең русчага тәрҗемәсе юк чакта иҗат итә. Бу очракта да яңалыкка-

иркенлеккә Аяз алданрак барган ич.

Әйе, Аязның иҗатта да, тормыш итүдә дә үзе тудырган иркен-ирекле дөньясы

бар.

...Дачасына бардым. Бик уйчан иде, шулай да бик дустанә каршылады.

— Кибеткә барып кайтасым бар, — диде Аяз.

— Мин дә...

— Юк, син бармыйсың! Монда үзеңә берәр шөгыль тап.

Янәшәдәге авыл кибетендә аңа нәрсә кирәк булгандыр, моны белмәдем. Тиз борылды, җәһәт йөри иде ул. Бәлки, кибет юлына төшмәгәндер, каршындагы урманлы үр итәгенә генә җиткәндер. Күзләре ут уйный, йөзе балкый, хәтта күзлеге дә нур чәчә иде кебек.

— Таптым!

Һәм чардагы куышына ашыгып, мине алмагач төбендә ялгызымны калдырып менеп китте. Соңыннан әйтте, яза торган әсәрендәге вакыйганың үстерелешенә бер кечкенә деталь-күренеш җитмәгән икән, кибеткә дип барышлый шуны тапкан да юлыннан кире борылган икән ул...

Бер хәлне әйтмичә кала алмыйм икән. Аязның минем кулдан балта алуы турында.

Мине дачасына чакырды ул.

Аның зур агач көймәсе булуын яздылар инде. Иделдә балык тоту өчен көйләнгән иде пароход хәтле бу көймә.

— Кил әле, — диде. — Бәлки, балыкка чыкмабыз. Көймәнең рәте китә. Ике яктан да өске такталары кыршылып-кимерелеп бара. Шуларны җайлап алыштырырсың. Үз эш коралларыңны алып кил.



Минем күпмедер дәрәҗәдәге «балта чабу»га әвәслегемне белә иде Аяз. Шуңа күрә, ягъни кайсыбызның остарак чапкалавын ачыкларга теләгәнгә күрә чакыргандыр дип уйлыйм.

Эш коралларыңны алып кил дип кабат-кабат кисәтте ул.

Бардым. Эшкә башладым. Ашыкмыйм. Үз көемә ягъни. Балта белән юну эзен калдырмаска тырышам, ышкыдан соңгы кебек булсын ягъни. Осталыкны күрсәтергә кирәк ләбаса! Аннары безнең Саба ягы һөнәрчеләре эш кушучыларга беркайчан да начар әйберләр ясамаганнар. Дәрәҗәне сакларга кирәк икәнлегенә нык игътибар иткәннәр. (И-и мактанчык, син түгел бит, ә ҺӨНӘРЧЕЛӘР!)


— Нигә шундый салмак кеше син?! — диде ул. — Балта тота белгәнеңне беләм ләбаса. Әмма шул акрынлыгың белән нервларны кузгаттың, әй! Мин бу ике тактаны үзем генә дә куя ала идем ич. Синең корал тота белү дәрәҗәсен тикшерәсем килде минем, парин! Синдә генәдер мондыен да балта! — Аяз мине көйләүгә күчә башлады, мондый хәлгә сирәк, бик сирәк бара иде ул, гадәттә, күпләргә турыдан бәрүдән соң кирегә борылмады. — Тәки дә бүген бетерә алмый идең син бу эшне. Таңнан ук балыкка чыгасы бар бит. Әйе, чыгабыз, кармакларыңны ала килгәнсең ич. — Һәм: Азмаз гына язсаң да, эш коралларың шәп! — дип төрттереп тә алды. — Күбрәк яз, дим мин сиңа, парин...

Иҗат дигәнең тукталу белми шул, бара да бара, һаман иркенәя-киңәя. Олы әдибебез Мирсәет улы Аяз Гыйләҗевнең бай мирасы — әнә шулай колач җәеп, көчне кызганмыйча халыкка тугры хезмәт итү җимеше. Без дә бирелеп-иплəп җыйыйк аның үзе тудырган ирекле иҗатында һәм иҗади иркенлектә үскән шул җимешләрне. Һәм саклыйк.

«Мәдәни җомга»

24 гыйнвар, 2003

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтовның тел остасы булуына А.Гыйләҗев белән М.Мәһдиев тә соклана иде. 1993



ГАРӘФ ШӘРӘФЕТДИНОВ

Идел дулкын кага

1

Менә, җаннарга җылы өреп, тагын яз-

лар килде. Белмим, быелгысы ничәнчесе-

дер инде, без Займищеда бакчада һәр яз са-

ен бер сандугач сайравына мөкиббән китеп

яшибез. Шунысына гаҗәпләнәбез без аның:

ул чит-ят җирләргә китеп кышласа да, бәл-

кем, әткә-әнкәләрен югалткан бала санду-

гач кына булса да, туп-туры безнең бакчага

кайта һәм ел да гел бер төшкә, гел бер ку-

ак тирәсенә оя ясый.

Агачларны яшәртеп май урталары җит-

теме, җылы бер тымызык кичтә сандуга-

чыбыз ызандаш күршеләр Әхсән Баян, Ил-

дар Юзеев, Шәүкәт Галиевләр коймасы ар-

тындагы куе куаклык арасыннан нәзек та-

вышы белән сузып кына беренче авазын са-

ла. Кышлаган якларыннан исән-имин кай-

тып җитүен хәбәр итүеме бу? Әллә туган иленең назлы һавасы тергезгән аһәңен тик-

шереп, сынап каравымы? Ләкин, нишлисең бит, тәүге аваз әле өне җитеп бетмәгән

кебек тоныграк, кыюсызрак булып чыга. Моңа ул үзе дә бик үк канәгатьләнеп бетми,

ахры. Кунган ботагында берара тынсыз шомланып утыра да, тавышына дәртле бер

яңгыраш өстәп, янә сызгырып җибәрә. Ә-ә, бу юлы инде ярыйсы, монысының тыны

иркен, яңгырашы көчле, үткер булып ишетелә. Һәм шуннан соң бүгенгә җитеп торсын

дигәндәй шым була... Тирә-як тынлык мохитенә чума.

Аның каравы икенче көнне иртән, кояш күтәрелә башлауга, табигатьтә чын тамаша куба. Аллы-гөлле чәчәкләр сарган бөтен үзәнлек бакчалары сокландыргыч сандугач моңына күмелә. Бу тирәлеккә ияләнеп беткән бүтән кошлар нинди генә авазлар чыгарып чутылдап, үзләренчә сайрап карамасыннар, безнең ми күзәнәге аларның берсен дә кабул итми, ишетми. Күңелнең бөтен барлыгын бары тик сандугачның сихри моңы гына били. Һай, тавышы ла тавышы шул! Зиһенне иркәли торган нинди генә бизәкләре, борылмалы-сыгылмалы күчешләре, тынышлары юк аның. Ярсып-ярсып, дәртләнеп-дәртләнеп тезә көен, өздерә, күңелне тәмам әсир итә. Илаһи көч бар үзендә! Бер таңнан икенче таңга кадәр һич тукталмый, өзлексез диярлек бит. Күз шәйли алмаслык дөм караңгы төн уртасында да якында гына сыман «чут-чут!» итә дә шуңа ялгап китә тезеп, китә тезеп үзәккә үткеч моңлы җырларын. Җиһанга йокы кунмый. Сихри, дәртле җыр белән җәйнең иң матур таңы ата.

Эчендә җаны булган кеше әлеге манзарага битараф кала аламы?! Кая ул! Шуңа күрәдер дим, бу көннәрдә бакча кешеләренең табигатендә дә күзгә күренеп кайбер үзгәрешләр барлыкка килә, кыяфәт-хәрәкәтләренә ниндидер бер ип куна, сабырлык иңә. Бакчачылар бу көннәрдә басынкыланып, уйчанланып, салмакланып калган кебек булалар.

Әнә Шәүкәт белән Илдар һәр кичне табигать хозурлыгына ләззәтләнеп, бакчалар сукмагы буйлап, үзләренчә әйтсәм, урам әйләнеп, һава сулап кайтырга чыгып китә. Дусларның сөйләшер сүзләре күп. Кәефләре шәп. Шулай булмыйча соң! Ул бакчаларның матурлыгын күр инде. Күз алдында диярлек алма-чия агачларының чәчәк бөреләре, сыеша алмыйча, менә-менә ярылырга торалар. Ә шомырт, сирень, ирга чәчәкләреннән хуш ис бөркелә.

Сандугачлы кичләр дусларга да тәэсир итми калмый. Тик хәзер алар күбесенчә сүзсез кыяфәттә, салмак кына янәшә атлыйлар. Күз тимәсен үзләренә, Шәүкәтнең буй-сыны төп-төз, ә Илдар кулларын артка чалыштырган. Йөз чалымнары җитди. Аңлашу, фикерләшүләр күбрәк нурлы җылы караш, ым кагулар аша бара. Тик ара-тирә

генә шаянланып көлешеп алулары ишетелеп китә. Күренеп тора, дусларның рухи дөньясы белән сандугач тылсымы идарә итә.

Әхсәннәр бакчасында да хәрәкәт сүрәнәйгәнгә һич гаҗәпләнәсе түгел. Сәбәбе һаман да шул: табигать хозурлыгы җанны эретеп иркәли. Һәркем үзенчә хис дәрьясында йөзә, ләззәт кичерә.

Сандугач сайравын таң калып тыңлаган, аңа гаҗәеп бер могҗиза итеп караган Аяз турында аерым һәм киңрәк итеп язмый хәлем юк. Т а б и г а т ь к ә мөнәсәбәте һәм карашы белән искиткеч үзенчәлекле кеше иде шул Аяз! Аны искә төшереп, җанлы килеш күз алдына китерә башлагач, б ә г ы р е м телгәләнә, күңел үрсәләнә. Хисләр ташкынынннан мине көчкә-көчкә генә сабырлыгым тыеп тора. Менә икенче яз инде Аяз үз бакчасындагы гүзәллекне, яз тамашасын күрүдән мәхрүм.

Мәш килеп яшәп ята идек бит без. Аязлар белән безнең бакча арасындагы сукмакка беркайчан да тузан кунмады. Ни әйтим, безнең түтәлләрдәге яшелчәнең ничек үсүен Нәкыя күзәтчелек итте. Ә алар бакчасындагы җиләк-җимеш уңышы хакында иң хәбәрдар кеше минем Рәисә иде (искә төшергән саен, йөрәгемә кан сава: бүген Рәисә дә мәрхүмә. Аяздан соң ул да кинәт китеп барды).

Аязның бакчаны, Займищены яратуы үзенчә иде. Көзен, кышын иҗат дөньясыннан аерыла алмаса да, язга таба аның күңеле түрендә бер тынгысыз бөре баш төртә иде. Быел яз ничек килер икән? Иделне күрә алырбыз микән инде? Юк-юкта миңа шалтырата, ара-тирә сүз сыя торган башка дус-ишләре белән дә хәбәрләшә. Яз галәмәтен искәртеп, кояш югарырак күтәрелеп, яктырак караган саен, Аяз күңелендәге вәсвәсә дә көчәя бара. Ниһаять, менә сукмаклар ачылуны, Идел култыгындагы су күтәрелә башлавын ишеткәч, йөрәге түзми. Нәкыя белән парлашып, гадәттәгечә, иң иртә кузгала торган поездларның берсенә өлгереп, Займищега килеп төшә.

Өйләре каршында сары чәчәкләр күз ачкан. Тюльпан чәчәкләре төргәк башлы сабакларын югарыга таба сузганнар. Аязның шәхси үз шөгыле бар: ул ел саен көздән бөтен сукмак буйларына, өй түрендәге ачык урынга ачы какы, балтырган һәм хәтта

шома көпшә орлыкларын чәчеп тора. Һәм яз башыннан ук колакларыннан тартып үстергән кебек аларны карап-саклап үстерә. Кузгалак, кыяклы суган борын төртәләр. Аяз аларны чүпли, юа. Аннары:

— Зәңгелә кач, Идел кич: иске авызга яңа аш! — дип догасын укый да учмасы-учмасы белән кетердәтә, кимерә башлый. Шундый тәмле итеп чәйни, авыздан сулар килә.

Без аның белән су буена төшәбез. Аяз андагы аланлыкларга да ашамлык үләннәрен чәчкән. Аларның борын төрткәннәрен тикшереп чыга. Аннары Идел ярына басып уйчанланып кала. Табигатьнең зиһен сыйдырып бетерә алмый торган иң нык үзгәргән, яңадан туган чагы. Җире туң, яр буе кары яңа җепшеп килә, ә астыннан ямь-яшел яфраклы үлән калкып маташа. Идел култыгы суына чүпрә тутырганнар диярсең. Су күбекләнә-күбекләнә кайный, җил уңаена тирбәлә, бөтерелә. Вак бозларны өереп, ташу күз алдында яр өстенә таба күтәрелә, күперә.

Аяз күңелендә дә шушыңа охшаш дәрт ташкыны күпереп килә кебек. Аның кайчаннан бирле инде нәкъ шушы мәхшәрне күрәсе килгән иде бугай. Менә ичмасам күрде, булды, күңеле утырды, җилләнүе басыла төште сыман.

Ул хәзер озаклап юанып тормый. Нәкыясе белән бергә, ашыгып килгәндәге кебек, ашыгып кайтып та китә.

Аяз эшкә күмелгән. Берничә корректурасын укыйсы бар икән. Нәшрият ашыктыра, ди. Аның янына киңәш сорап казакъ даласыннан Ибраһим ага Салахов та килеп төшкән. Өстәлендәге язып бетерәсе әйберенә дә бүген-иртәгә генә нокта куя алмый



Язгы табигать хозурында. Займище, 1968



икән әле. Шул ук вакытта быел кыш буе А.Солженицын томнарын сөреп чыкмакчы булган. Аны да тәгәллисе бар икән.

— Чиратта Михаил Булгаков әйберләре көтеп ята. Мин хәзер алардан башка яңа әсәргә тотына алмам кебек, — дип фикер уртаклаша ул.

Шуннан соң Аяз бакчада тагын атна-ун көн күренми тора. Ә үзе һәр көн диярлек отчет сораган кебек, миңа телефоннан шалтыратып, бакча хәлләре турында төпченә. Әмма өстәле янына үзен бәйләп куярга күпме генә тартышмасын, бакчада сандугач моңы сирпелә башлауга, аның түземлеге төкәнә. Ул үзенең эш тәртибен бераз үзгәртергә мәҗбүр була. Алар еш кына иртә таңнан ук Займище якларын урап кайтырга ашкыналар.

Дөресен әйтим, Аязыбыз күзгә күренеп үзгәрә. Иң элек күзгә чалынганы — йөзен сарган гадәттәге кырыслыгы эреп юкка чыга. Яшерен-батырын түгел, элегрәк талканы корырак чакларда кайбер аваз-ымлыкларының ызанга сыймыйча күрше-күлән җиренә чыккалаган очракларын да ишетмәмешкә сабышкан чакларым була торган иде. Хәзер инде аның тәмле теле җанны эретә, Нәкыягә дә: «Әнкәсе!», «Нәкыя абыстай!» — дип назлы итеп дәшә. Студент улы Рәшатка да елмаю бөркелә, аңа эчке бер горурлыгын кушып: «Олан!» — дип теленнән төшерми.

Ирештек шундый көннәргә дә. Тора-бара Аяз бакчада инде кунарга кала. Иртәнге бакча ямен сурәтләп бетерүе кыен. Андагы гүзәллек, хозурлык, илаһилык кешегә канат үстерә. Мондый иртәләрдә йокы кача. Без Аяз белән, таңнан ук көймәгә утырып, Идел уртасына кереп китәбез. Нәкыя яр буена тиклем Аязның әйберләрен ташыша. Моторны кабызгач та әле ул безне яр буендагы агачлар ышыклыгын үткәнче озата бара.

Йа Хода! Идел өстендәге матурлыкка таң калырлык. Һушны ала. Урман артыннан

кызарып кояш күтәрелеп килә, ә күк гөмбәзенең көнбатыш ягында тонык ярымай офык артына кереп югалырга җыена. Су өсте пыяла кебек ялтырап тора. Шылт иткән җил

Улы Мансур белән көймәдә, балыкка сәфәр. 1968



хәрәкәт юк. Анда-санда безнең баш очы турысыннан озын канатлы акчарлаклар үтеп киткәне күренә. Алдагы утрау буенда кыр үрдәкләре йөзеп йөрүен шәйлибез. Аксыл-соры челән, озын муенын сузып, яр буена сакка чыгып баскан. Идел уртасына табан озын утрау эчендә тынлыкны ярып тартар кычкыруы ишетелә. Аңа якыннан бытбыл-дык җавап кайтара.

Утрау буендагы сандугачны әйтәм, кояш чыкканга куанган кебек, тагын да дәрт-ләнеп өзгәләнә-өздерә. Бөтен дөнья кояшның иркә, назлы нурларына коена.

— Илнең күп җирләрендә булдым. Әмма мондый да матурлыкны беркайда да күргәнем булмады. Исең китәр безнең Идел буйларына! — дип соклануын тыя ал-мый Аяз.

Без берничә утрауны әйләнеп үтәбез дә, Идел агымына якынрак киң алан кадәр ачыклыкка җиткәч, моторны сүндерәбез. Көймәне туктатып, якорьлар төшерәбез һәм бавын тарттырып көймә мөгезенә бәйләп куябыз. Тирәнлек ун метр чамасы. Нәкъ үзебез теләгәнчә. Димәк, рәхим ит, балыкларга дип әзерләнгән азык-ризыкларыңны челтәрле капчыгы белән төпкә төшер дә, әйдә, тотын эшкә.

Шуннан соң кармакларны рәтлибез. Алар ризык капчыгы өстенә төшеп яталар.

Ярты сәгать үтми, без бер-бер артлы эре табан балыкларын суырып чыгара да башлыйбыз.

Әй кызык та соң Аязның балык тотуын карап тору. Үзе бер кәмит, үзе бер тамаша.

Килә генә бит балык аңа. Берьюлы икешәр кармагына чиртә. Тартып чыгарырга өлгер генә!

— Әйдә, җаным, әйдә. — Эләккән балыгын югарыга тартып менгерә. — Кемгә килеп капканыңны беләсеңме соң? Рәхмәт төшкере, моңарчы кайда йөрдең син? — Кайсын чуп итеп үбеп тә ала. Үзе көйли, үзе бер кармактан икенчесенә йөгереп йөри.

Кояш югары күтәрелгәнче, без шактый балык тотып өлгерәбез. Озакламастан көн ныклап кыздыра башлый. Балык чиртү сүлпәнләнә. Безнең калын кием-салым-нарыбыз да акрынлап-акрынлап

юкара. Ник бер җил исеп алсын.

Менә берзаман дөнья бөтенләй

тынып кала. Өстән боерык бир-

гәннәрмени, бер тынышта ка-

мыш арасындагы бакалар ба-

кылдаудан туктый. Көтүләре-

көтүләре белән акчарлаклар яр

буендагы комлыкка төшеп сы-

рышып утыралар. Тик арадагы

бер юньсезе — килбәтсез һәм

озын канатлысы, муенын су-

зып-сузып, шомраеп, каһкаһә-

ләп, илереп-илереп кычкырыр-

га тотына. Күңелгә тия. Сайрау-

чы барча кошлар бер мизгелдә

шым булалар. Ник бер балык

баласы кармакны селкетеп ка-

расын. Йә, күр инде, суы ди-

сәң, суы тонык, чиста, агымы

тыныч — килмәгән шарты юк.

Ә бөтен җан иясе кинәт мәрт-

кә киткәнмени? Ни булды әле

бу дөньяга? Аяз моның сәбәбен

белә.

Нәкыя һәм Аяз Гыйләҗевләр Зәйдәге

йорт бакчасында. 1997

— Парин, безгә хәзер җил чыкканны көтәргә кирәк. Бөтен табигать ләззәткә ереп,

рәхәт кичереп ятканда, ник бердәнбер балык-мескен үзенә азык эзләп, михнәт чигеп йөрергә тиеш икән? Шулай булгач соң, ул да төпкә борынын терәп йокыга талмагандыр дип кем әйтер?

Сәгатьтән артык вакытны әрәм иттек. Сыңар яфрак та селкенмәде. Ә берзаман, һич искәрмәстән, су өстен шадраландырып, җил исеп җибәрмәсенме?! Яр буе кошларына да әллә ни булды диярсең. Бөтенесе дәррәү купты. Суда чүп-чар чәбәләнә башлаган иде — шалт! — Аязның бер тәлтәвече көймәне селкетерлек итеп дырылдарга кереште. Шуннан китте, китте, мин сиңа әйтим, безнең нәфеснең дә авызы тыгылды.

Яр буенда безне Нәкыя каршы алды. Әй мактады инде Аязны. Тыюлы елмаюын калын пыялалы күзлеге аша кысык күзләреннән күреп булмаса да, җилдә, кояшта бүртенгән аксыл иреннәре барыбер җыеп, яшереп бетерә алмый иде аны.

2

Балыкчы, бакчачы булу — ул безнең өчен бер мавыктыргыч һәвәскәрлек шөгыле генә иде. Әмма болардан тыш Аяз белән миңа байтак озак чын рәсми мөнәсәбәтләрдә аралашып та яшәргә туры килде. Аяз — күренекле язучы, актив автор, ә мин унбиш елга якын Татарстан китап нәшриятының директоры булып эшләдем.

Авыр һәм бик үзенчәлекле дәвер булды ул. Дөрес, китап бастырып чыгаруда кайчан да бер җиңел чак булды микән? Ай-һай, булмагандыр, дим.

Безнең чорда карап торган бердәнбер нәшрият иде ул. Милли китапка ихтыяҗны санап-сурәтләп бетерә торган түгел. Искә төшерсәң, ис китәрлек, йә инде шул көнгә кадәр борынгы тарихыбыз өйрәнелмәгән — кулга тотардай бер тарих китабы юк. Бу чор укучылары хәтта урта гасырларда нинди шагыйрьләр яшәгәнлеген,ниләр иҗат иткәнлекләрен белмиләр. СССРның 80 нән күбрәк өлкәсендә һәм республикасында татар мәктәпләрен дәреслекләр белән безнең шул нәшриятыбыз тәэмин итәргә тиеш. Болар өстенә күпме мәҗбүри партия-идеология әдәбияты. Шулардан соң еллык планда бүгенге авторларга һәм үзебезнең классик әдәбиятка ничә китаплык урын калды-

рып була?

Бер караганда, зур куаныч кебек, нәшриятка гаризалар агылып килә. Бу — иҗади активлык яши дигән сүз. Кулъязмаларга кытлык юк, хәтта тагын бер еллык планга җитәрлек запас бар. Аларның кайберләре әдәби эшләнешен, сыйфатын ачыклау өчен белгечләргә рецензияләүгә бирелгән яки кабат карап чыгу, ипләү-сипләү яисә төзәтмәләр кертү өчен авторларына кире кайтарылган. Монда Мәскәүдәге Росглавиздатның да катнашы бар. Ул да һич тынгы бирми, бер казандагы икенче тәкә башы кебек, гел тылкыша, үзенекен итмәкче була. Үзе кирәк дип санаганны контроль рецензия ясату нияте белән бездән соратып алдыра. Милли әдәбиятка җитәкчелек итә, янәсе. Мәскәү әйткәннәр, аның контроль таләпләре үтәлми карасын!

Шулай итеп, нәшрият конвейеры ел әйләнәсе тукталып тормый. Ел саен 300дән артык исемдә китап-брошюра сатуга җибәрелә, гомуми тиражы 5–6 миллион данәгә җитә, тик күбесе урыс телендә һәм урыс телендәге әдәбият өстенлекле санала. Сәяси максат шулай куша.

Әйтергә кирәк, нинди генә киеренкелекләр һәм каршылыклар барлыкка килмәсен, иҗат мәйданында милли көчләр кимемәде. Сугыш кырларында чыныгып кайткан өлкән буын язучылары белән бер сафка яңа буыннар үсеп өстәлеп торды. Нәшриятка мөрәҗәгать итүче авторлар саны хәтта арта башлады.

Безнең чорда эшләгән менә шул йөзләгән авторлар арасыннан бик күпләре хакында олы хөрмәт, җылы ихтирам белән телгә аласы килә. Һәм мин, шул ниятемне өлешчә генә булса да гамәлгә ашырып, үзебезнең чордаш, аерым бер дәрәҗәле һәм үзенә хас абруй иясе Аяз Гыйләҗев турында башлаган сүземне дәвам итәм.

70 нче еллар ахырына безнең нәшриятта әдипнең 10нан артык хикәяләр, повестьлар, пьесалар җыентыгы, «Урамнар атында яшел болын» романы басылып чыкты. Бу елларда без аның белән якыннан торып хәл белешеп, шактый тыгыз элемтәдә аралашып яшәдек.

Фикердәше академик Миркасыйм Госманов бер язмасында Аязның «шадра кәгазь

кебегрәк (наждак кәгазе) кытыршы холкы, пычак шикелле үткен теле» дип үз итеп әйткән сыйфатларын нәшрият тормышында шәхсән миңа күрергә туры килмәде. Күпьеллык эш тәҗрибәсеннән чыгып әйтәм, мин Аязны гаугалы авторлар рәтенә кертердәй очракларга тап була алмадым.

Ул Матбугат йортының дүртенче катына йомышы булса яки махсус чакырсалар гына күтәрелә. Аның, үзе әйтмешли, нәчәлникләр күзенә чалынып, эч пошырып йөрисе килми. Ул үз әсәрләрен Фәрваз Миңнуллин яки Таһир Нурмөхәммәтов редакцияләвен ярата төшә. Шуңа күрә, нәшриятка килсә, алар янында утырып, хәл-әхвәлләр сораштырып чыга. Редакция мөдирләре Шәүкәт Галиев белән Шамил Рәкыйпов аңардан кайбер катлаулырак кулъязмаларны укып чыгуын һәм үз фикерен язып бирүен сорыйлар. Моны ул, яшь язучыларга ярдәм итү төсендә эшләргә кирәк булганда, җиренә җиткереп үти. Әмма ләкин тәҗрибәле язучыларның редактор ярдәменә исәп тотыбрак эшләгән яки ноктасы куелып җитмәгән әйберләре аның кулына керсә, гомере буе онытылмаслык сабак бирә. Шуның нәтиҗәсе дип карарга кирәктер, берзаман безгә үз әйберен нәшрият планына ансатрак кертергә исәп тоткан бер авторның югары оешмаларда А.Гыйләҗев рецензияләрендә объективлык җитмәүгә дәгъва белдереп йөрүен хәбәр иттеләр. Өстәвенә нәкъ шул вакытларда көндәлек матбугатта да Аязның бер повестена карата «Күзгә-күз карап» дигән рецензия пәйда булган иде. Анда авторның «ялгыш юлдан» атлавы, идеология таләпләре белән исәпләшмәве тәнкыйтьләнгән иде. Бу хәл пыскып янган учакка кисәү өстәгән кебегрәк булып килеп чыкты. Ягъни аңа карата электән килгән киеренкелек яңадан үз хәленә кайта язды. «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар» повестьлары авторы тагын чыгымларга уйлыймы? Нәшрият ни карый? Димәк, А.Гыйләҗев кеше кулъязмаларына рецензия язу белән бик мавыкмаска, үз фикерләрен башкаларга көчләп такмаска тиеш. Янәсе, әнә үз әйберләренә игътибарын көчәйтсен. Бер рәттән, нәшрият җитәкчесе буларак, миңа да бераз үпкә сүзләре ишетергә, яңа басыла торган кайбер повестьларның корректураларына махсус күз йөртеп чыгарга туры килде.

Дөресен әйткәндә, тормышның әче мәктәпләрен үткән, «акыл утыртып кайткан»
Аяз беркайчан да нәшрият җитәкчеләре һәм редакторлары алдында даулашып, тәмсезләнешеп йөрмәде, сабырлыгын җыйды, чыгырдан чыкмады. Әмма ул үзенчә эшләде, үзе салган юлдан барыбер тайпылмады. Аның әсәрләре үз чиратында бер-бер артлы чыга торды. А.Гыйләҗев «Җомга көн, кич белән...» (1979) һәм «Әтәч менгән читәнгә» (1980) повестьлары өчен 1983 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.
Аяз тумышы белән кемне дә авызына каратырлык кызык әңгәмәдәш иде. Кешене тыңлый һәм тыйнак тотышы белән үзенекен тыңлата белә иде. Әгәренки урынсызга бәхәс-фәлән купсамы, дөнья бетә — ул кырыс теле белән уеп кына ала, кеше-бичара, үзенчәрәк әйткәндә, тәүбә догасын әйтеп өлгермәстән, тәһарәтен җуярга да мөмкин иде.
Ул ялгыз, үз-үзенә бикләнеп яшәргә яратмады. Якын дуслары булды. Иҗат йортларына киткәндә дә элемтәне өзми, үз фикерләрен хат итеп язарга ярата иде. Шушы уңайдан гыйбрәт өчен мин аның берничә хатын укучылар игътибарына да тәкъдим итәргә булдым.
23 март, 1983
Переделкино
Гарәф дус!
Киткәнгә менә ничә көн, синең «Вакытсыз чыгардың «Казан утлары»нда мәкаләңне, бик вакытсыз!» дигән сүзләрең, әр катнаштырып елмаеп карап торуларың әле дә күз алдымда... (Сүз «Казан утлары» журналының 1983 елгы, 2 нче санында басылган «Тынычлану зарарлы» дигән мәкалә турында бара. — Искәндәр Гыйләҗев.) Син гомергә... каты орынмадың... ашыгып кына хөкем чыгара торган җан түгел. Күзгә карап әйткәнсең икән инде, син бу турыда уйлагансың, мине — юньсезне кайгырткансың... Әле синең әдәпле булуың һаман өстенлек алды!.. — мине җәлләп Флүн Мусиннар адресына әйткән сүзләремне телеңә алып тормадың!.. Гәрчә анысы өчен дә сүгәргә

җаең бар иде.

Әйе, мәкалә басылып чыкты. Син «ошамады!» дигәч, мин бер мәлгә тагын бер кат уйланып калдым. Мәкаләне мин былтыр апрель айларында биргән идем шикелле. Уйламыйча гына язгандыр дип белмә тагын, анда әйтелгәннәр байтактан җанымны талап килә иде. Бәлки, ул мәкаләдән соң да берни үзгәрмәс, талантларның килеп чыга алмавы бик күп сәбәпләргә бәйләнгән. Әмма мин бу сүзләрне әйтергә тиеш идем! Тиеш!..

...Сәнгать, әдәбият шундый көч ки, ул милләтне тудыра, милли бөтенлекне саклап тора, милләтне яшәтә, аңа нур бирә, кешелек алдында милләт өчен җавап тота. Шул әдәбиятта кайчанга кадәр уртакуллар өстенлек итәргә тиеш? Аларның өстенлеге минем өчен генә булганда артык куркыныч та түгел, мин ничек тә яшәрмен, көрәшермен, начарлыкның өстенлеге яшьләр өчен куркыныч! Мине ул мәкаләне язарга мәҗбүр иткән төп сәбәп, юк, уйлама, Барласлар яки К...ләр генә түгел, ахыр чиктә әдәбият бервакытта да бөеклекләрдән генә тормаган, мине прозада яшьләрнең юклыгы мәҗбүр итте.

...Без ничә еллар үз яныбызга балласт җыябыз. Аларны тынычландырабыз, съездларда мактыйбыз. Болар барысы безнең алга барышыбызны акрынайта, киләчәк биеклекләрне ераклаштыра, халтурачыларга яшәргә һава бирә. Яшермик, әллә сез кайбер китапларны чыраегызны сытып чыгармыйсызмы?! Син — намуслы кеше, әдәбиятны аңлый белә торган җан... Син дә, мин дә «яңгырдан чыгып карга кермик тагын!» дигән курку томаны арасында яшәмибезмени? Без барыбыз да шушы зарарлы ялган атмосферасының корбаннары түгелме әллә? Корольнең шәрә икәнен кемдер җан ачысы белән кычкырырга тиештер ләбаса?!

...Тик мин талантым белән берчакта да сәүдә итмим, мөмкин кадәр, булдыра алган чаклы ил һәм халык алдында саф күңелле булып калырга тырышам. Һәм әгәр йөзем ак булмаса, ул мәкаләне язып чыга ала идемме? Йөрәгем җитә идеме минем аңа? Үз эшемнең көченә ышаныч миңа юлдаш булмаганмыни? Ниһаять, мин әдәбиятта бер

күнлек яки бер еллык узгынчы гына түгел. Берчакта да. Чөнки, асылда, алар халыкныкы, милли әсәрләр, мин аларны халыктан алган да бурычымны үтәү йөзеннән кире кайтарып биргән.

Димәк, әйдә, борынны төшермик әле.

...Переделкиноны яратам мин. Монда эшләнә! Менә хәзер дә көннәр чуар: әле ява, әле сытыла, әле томан, тик мин бер нәрсәгә баш бирмичә повесть язып утырам. Көлке повесть булачак ул! Рәхәтләнеп бер көләсем килә әле! Кемнәрдер минем авызны җимерергә маташканда, рәхәтләнеп, егыла-егыла көләсем килә! Шул ук вакытта үз-үземнән дә!..

Сиңа саулык-сәламәтлек, ихлас тынычлык теләп калам.

Аяз

Әйе, шулай, Аяз Гыйләҗев әрәмгә вакыт үткәрергә яратмады. Ул яңа әсәрне язып бетергәч тә, өстеннән авыр йөк төшергән шикелле җиңеләеп, иркенәеп киткәнен сиздерми, уй-фикерләрен нинди дә булса бер шөгыль белән тынычландыра. Йә җыелып яткан газета-журналларын актарырга керешә, йә булмаса, машинкасы янына килеп, кемгә дә булса хат язарга утыра.

Аерым язучыларның эш стиле, гадәте-шөгыле турында сүз чыкканда, миңа Аяз Гыйләҗевнең күп һәм озын-озын хатлар язу гадәтенә кайберәүләрнең сәерсенеп карауларын һәм бу кадәресен өнәп бетермәүләрен ишетергә туры килгәне бар. Мин моңа артык гаҗәпләнмим, һәм «Татарстан яшьләре» газетасының быелгы 5–6 саннарында Миркасыйм Госмановның «Аяз әкә сабаклары» дигән матур язмасында бу хакта әйткән фикерләре белән тулысынча килешәм...

Миркасыйм әфәнденең хаклыгын мин күп дәлилләр белән хуплыйм. Аяз, кемгәдер хат язганнан соң, гел әйтә торган иде: «Хат язгач, рәхәт булып китә. Бушанып калам, тыным киңәя, парин. Уйларым язасы әйбергә күчә».

Чыннан да, Аяз хатларында кешенең гадәттәге хәл-әхвәлләрен генә сораштырып язмый бит. Аны үзенең эчен пошырган мәсьәләләр — сәяси вазгыять, халык язмышы, әдәбият тормышы, иҗат үсешенә мөнәсәбәт, язучының бурычы кебек җаваплы һәм

бик урынлы мәсьәләләр борчый, уйландыра, җанына тия.

1988 ел башында Аязга 60 яшь тулды. Җәмәгатьчелек аны зурлап билгеләп үтте.

Аңа хәйран дулкынланырга туры килде. Шушы юбилеennан соң дөнья барышына мөнәсәбәте, үз-үзенә таләп мәсьәләсендә кайбер үзгәрешләр дә барлыкка килде кебек.

Моны аның кайбер хатларыннан да сиземләргә мөмкин, минемчә.

25 март, 1988

Переделкино

Гарәф дус!

...Килдем, кадалып эшләп яттым, баш калкытмадым. «Яра» исемле повестьны, яңадан карап, күчереп, журналга җибәрергә кирәк иде. Аны озаттым да яңа эшкә тотындым. Эшне туктатырга да ярамый, вакыт җитми, гомер аз калды. Гади кеше алтмышка җиткәч кинәнеп, «эштән котылдым!» дип иркен сулыш алса, язучының эш бүтәнчәрәк икән. Аны якынаеп килгән әҗәл сискәндереп, гомернең әз калуын аңлау күңеленнән китми икән. Эшлисе конкрет эшләр дә бар бит әле!..

Алтмыш яшьтә Мәскәүгә эз дә басмыйм, күзләрне кызганып китап укымыйм, хатлар язмыйм һ.б., һ.б.

Бер срок шулай үтте, икенче срокта югарыдагы кагыйдәдән кайбер чыгармалар ясаганны үзең күреп торасың, хат язам...

...Дөнья хәлләре уйлата. Үлеп барган күзәнәкләр уяна, кешеләр генә түгел, халыклар да үз сүзләрен әйтергә омтылалар. Хәзер моны туктата ала торган түгел!

Мин унынчы апрельдә кайтам да тиз үк Чаллы—Зәй якларына юнәләм, авылыбыз чишмәсенә ташны әзерләп бетереп, куярга кирәк. Аның мәшәкатьләре шактый булачак әле...

Малайлардан хатлар килгәләде, сөендем.

Рәисә абыстайга күптин-күп сәлам тапшыр.

Һәр икегезгә саулык теләп, тирән ихтирам белән Аяз

29 август, 1988

Переделкино

Гарәф дус!

Анд. Платоновның китабын алып килгән идем. Буш чакларда шуны укып ятам.

Үзәк матбугатта «В.М.Шукшин да, драматург А.В.Вампилов та Анд.Платонов әсәр-
ләре белән таныш иделәр» дигән хәбәр күзгә чалынган иде. Бу бик җитди хәбәр! Әгәр
социализмның асылын, аның максатын һәм чынбарлыгын аңлыйсың килә икән, әлбәт-
тә, Платоновны, Пастернакны да бик нык укырга, белергә, туктаусыз өйрәнергә кирәк
икән. Егерменче, утызынчы еллар рус әдәбияты Платонов янында гына ачылып китә
ала, аның «юкалыгы», ялганы, буш өметләргә корылган булуы, төче пафосы — һәм-
мәсе ап-ачык булып ярылып яталар. Дөньяны үзгәртергә керешкән бәндәләрнең хис
стандарты, буш хыялый булулары күзне ачып җибәрә.

Кемнәргә ышанып, кемнәргә өметләнеп, кая, бушлыкка, өметсезлеккә, чыгалмас-
лык сазлыкка омтылган икән социализм төзергә тотынган халыклар!.. Әгәр шуны бел-
мәсәләр, Шукшин да, Вампилов та ирешкән биеклекләренә менеп җитә алмаслар иде...

Уйлап йөрим: без дә, татар әдәбиятын укып үстек, дип сөйләшәбез инде! Ф.Әмирхан
юк, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, М.Галәү, Г.Ибраһимовлар да юк, Г.Тукайны да «буржу-
аз-демократ» дип тибеп кенә үтәбез...

Мин унынчы класста гына китапларны урысча укый башладым. Яшьлек, күңелнең
иң тере чагы, җирнең ачылып, һәр бөртекне кабул итеп, сеңдереп яткан чоры — буш-
куыклар артыннан чабып үтте. «Йосыф китабы» юк, тарих юк, тарихи романнар юк,
«татар татар булып бары тик 1917 елдан соң гына яши башлады», — дип, көн туса
тукыдылар безгә... Менә хәзер Гаяз Исхакый тирәсендә ямьсез тарткалаш бара. Бәл-
ки, Гаяз Исхакый татар әдәбиятының иң күренекле, иң калку бер буыныдыр?! Әмирхан
Еники аны үзенең остазы дип саный, мин — Әмирханны! Әгәр үз заманында, миңа
остазлар кирәк чакта, Гаяз Исхакыйны укып, белеп, сөеп яшәсәм, минем офыгым киң-
рәк булмас идемени?! Әле ярый татарча китаплар булган! Сәрвәр апа тәрҗемәсендә

М.Горькийның алты томлыгы, Пушкин, Лермонтов, Толстой (азмы-күпме)... Тик Достоевский барыбер юк! Достоевскийны мин җиткән егет булгач кына укыдым... «Преступление и наказание»не үзем укыйм, үзем үкереп җылыйм. Китапны әле тотып ыргытам, әле кочаклап алам... Нигә минем дөньяма Достоевский иртәрәк кермәде икән? Гомернең һәр бүленешендә кеше үзгәрә, бөтенләй яңа кешегә әверелә. 10 яшьтәге Тукай шул чор аңына сеңә.

Үскән саен, яшәгән саен яраткан язучыларга мөнәсәбәт катлаулана, арта бара, Достоевский, Тукай, Толстойлар һәр кешегә үз вакытында, нәкъ җан эзләгән чакта килеп керергә тиешләр. Бөек әдипләр күңелгә кереп урнашалар да синең белән бергә яшиләр, бергә гомер кичерәләр. Соңга калып килеп кергән әдип — аяныч. Илдус Ахунҗанов белән бер тапкыр очраклы гына күрештек, К.Нәҗми урамында, бер капка түбәсе астында яңгырдан ышыкланып торган идек. Шунда ул миңа Э.М.Ремарк исемен атады! Гомер юлына нәкъ менә аны көткән мизгелдә килеп керде. Рәхмәт Илдуска! Мәскәүдә укыганда Ал.Исбах мине, җитәкләп, Сент-Экзюпери давыллары арасына кертеп җибәрде. Нинди вакытлы булды ул бөек кунак миңа!..

Менә хәзер Анд.Платоновны укыйм да... бәргәләнәм: ник элегрәк укымадым икән мин бу сәер һәм бөек кешене?! Без кайдадыр юлдашлар буласы икәнбез ич, мин ул салкын сукмакларның каян киләсен дә, кая барасын да белеп торырга тиеш булганмын ич!.. Хәзер исә авыр, Платоновны акыл белән генә кабул итеп була. Хисләр уйгынлыгы һәм арадашлыгы юк дәрәҗәсендә... Без белми калган күпме бөек җаннар бардыр әле әдәбиятларда?! Үзебезнең Гаяз Исхакыйны кайтармый тору яшьләрдән кемнеңдер юлын кисмәс микән?.. Бәлки, менә Ркаил Зәйдуллинга, Газинур Моратовка, Нияз Акмаловка да нәкъ ул кирәктер. Татар тарихының мәгълүм бер чоры өчен җавап бирә алган язучылар юк икән, безнең тарихыбыз өзек-өзек, китек һәм гарип булып калмыймыни?!

Шуларны уйлап ятам әле, парин. Сау булып тор, чирләмә.

Ихтирам белән Аяз

15 октябрь, 1988

Пицунда

Гарәф дус!

...Мин 11 октябрьдән бирле монда. Пицунданы үз итәрмен дип һич уйламаган идем, дүртенче көземне монда үткәрәм. Быел соң килгәнмен, көннәр әйле-шәйле...

Без монда шактый ишле төркем: Әхсән бичәсе белән, Баян Гыйззәт хатыны белән, Мушинский хатыны, кызы белән, янә дә үзебезнең Равил Фәйзуллин...

Татарлар йөри! Переделкинога барсаң, алар тулып ята, монда килсәң, алар... Үзем дә нык йөрим бу араларда. Сөенәм: эшләнә! Литвин белән уртак романны шактый алга җибәрдем дә ашыгыч кына яңа повестька тотындым. Шуның беренче вариантын тәмамлап булмасмы дип социалистик ярышка чыккан көн. Иҗат йортының хуҗалары белә микән шуны, белмиләрдер, белсәләр, ашханәдә бераз ныграк сыйларлар иде. Переделкино белән чагыштырганда монда ул кәйрәк... Нәкыя абыстай пешергән ризыкларны сагына-сагына, килгән юлларыма карый-карый кайтып китәргә көннәрне саныйм... Озаккарак, ераккарак киткәнмен икән!..

...Эш тотканда әллә ни күп укып булмый, ара-тирә газеталар караштырсаң, шул җиткән, күзне дә җәллим, көчне дә. Эш барганда күзгә ак-кара күренми. Переделкинода кино сагындырып атнага ике генә мәртәбә була торган иде. Монда әле көн саен, керсәң — режим бозыла, кермәсәң — бик шәп картиналар күрсәтteләр... Кичә исә бик атаклы «Жертвоприношение»не карадык. Тәэсирле фильм, шайтан алгыры! Сүзен күңелгә үткәрә торган персонажлар, җете куе буяулар, дөньяның иң алда торган мазалары!..

Әхсән, Равил белән аралашабыз...

Да-а, моннан берничә ел элек кенә балыкчылар тимер күпер өстендә тезелешеп торалар иде, хәзер бушлык, беркем кармак салырга төшеп тә карамый. Бу да уйландыра, димәк, балыклар да социалистик елгалардан, диңгезләрдән череп таралган буржуаз илләргә таба йөзеп киткәннәр икән. Аларның балык базарларында утыз-кырык төрле яңа тотылган балык. «Буржуйлар балык ашарга ярата!» — дип яза безнең дөреслек

яклы булган газеталар... Хәерле булсын!

Нихәлләр? Хат язарга өлгерәсең әле, килеп җитәр микән, анысын белгән юк. Рәйсә абыстайга һәм үзеңә тагын бер кат сәлам!

Тирән ихтирам белән Аяз

Бу хатларга мин аңлатмалар, шәрехләмәләр бирүне кирәк тапмадым. Укучы үзе алардан язучы-әдип Аяз Гыйләҗевнең иҗат портретына өстәмә байтак мәгълүмат алырдип өметләнәм.

3

60 яшьлеген Аяз олы бәйрәм төсендә җиңел генә үткәреп җибәрә алмады. Ул тантана-шатлык хисләренә артык ирек бирмәде. Тантаналар үткәч, Аязның үз-үзен тотышы, кыяфәте электәгедән нык җитдиләнде. Ниндидер сагаюлы, уйчанлык төсе керде. Ә үзе кайчан карама гел囗 эштә, һаман яза, ни беләндер гел-гел мәшгуль булды. Аяз өчен чынлап торып вакытның кадере үсте.

Без аның белән Займище бакчасында сирәгрәк очраша башладык. Ул, бакчаны, Идел буйларын, кырыйдагы урманда гөмбә үсә торган аланнарны еш сагынуын әйтеп, күбрәк миннән сораштыра. Тик барыбер дә кай көннәрне, Нәкыя ханымны ашыктыра-ашыктыра, тиз генә Займищега килеп төшә. Юл уңай ул минем янга да кагыла, яңалыклар белән кызыксына, дус-иш балыкчыларның хәлләрен белешкәндә, үзенең дә дәрте канатлана, күзләре очкынлана.

Без инде яңадан Аяз белән бергә Иделгә балык тотарга чыга алмадык. Баштарак, менә майда, менә июньдә бер чыгып керәбез дип, үз-үзебезне тынычландыра идек. Аннары быел булмады, бернигә карамый яренгә эшләрбез дип кичектерә килдек. Аннары...

Аязның шикәр авыруы, кан басымының еш үзгәреп торуы сиздерә башлады. Ул иҗат йортларына йөрүләрен дә азайтырга сүз бирде. «Балта кем кулында?» әсәрен тәгәлләгәннән соң бөтенләй диярлек йомылып китте. Аның нияте репрессия елларында үзе тоткынлыкта яткан урыннарны йөреп, аларга бүгенге күзлектән карап, күреп кайту иде. Шул михнәтле дәвер упкыннары хакында нидер язу уе барлыгын ул байтак-

тан телгә алып килә иде. Аяз ашкынып юлга җыенды. Ләкин бу сәяхәт — аның авыр йөрәк ярасын кабат яңартуы, баштан кичергәннәрен барлап, күргән-өйрәнгәннәрен зиһене, йөрәге аша үткәреп, «теге дөнья» дип аталган шул үткән заманда яшәп кайтуы аның бәгырен телгәләп, җанын сызлатмый калгандырмы әллә?

Казакъстан якларыннан, бик ераклардан урап кайтканнан соң, Аяз, дус-иш алдына чыгып, сәяхәте белән таныштырып, кичерешләрен күрсәтеп тормады, йомылып эшкә чумды. Ниһаять, «Йәгез, бер дога!» дигән романын тәгәлләп дөньяга чыгарды.

Аязның уйчанлануы, тәүлек вакытының минутларын исәптә тотып тизрәк-тизрәк эшләп калырга омтылуы, ашкынуы, ашыктыруы юкка гына түгел иде бугай шул. Ул үзенең гомер чамасын күңеле, җаны белән тойды булса кирәк.

Ә үзе һаман Займищены, Иделне исеннән чыгармады. Телефоннан шалтырата, күңелен таба. Хәле аруланып китсә, Нәкыясенә таянып, йә Искәндәр, йә Мансур, йә Рәшат уллары машинасы белән бакчага килеп җитә. Савытларга чишмә суы тутыралар. Шул арада Аяз җир исен иснәсә, Идел ярын күрсә, күңеле бөтәшә.

2000 ел. Җәй уртасы. Матур көн. Вәгъдәләшкән сүзебез бар иде. Без, Аяз, Мансур һәм оныкы Муса, дүртенчесе — мин, моторлы көймә белән Иделгә чыгып, бераз йөреп кайтырга булдык. Мансур Аязны күтәргәндәй ярдәмләшеп, алдагы урындыкка кертеп утыртты. Һәркайсыбызда изүе дә төймәләнмәгән җиңел күлмәк, башта ак юка кепка.

Нәкъ чиллә вакыты. Кузгалдык. Идел кояшы күзне чагылдыра. Агач көймә суны ярып бара, безнең арттан кыйгачлап тезелешкән дулкыннар ияртә.

Белмим, бәләкәй Муса нинди куаныч кичергәндер — анысы миңа күренми. Ә менә Аяз берничә ел күрмәгән Идел манзарасына таң калган, соклануы йөзенә чыккан. Күзен су көзгесе чагылдырса да, ул карашы белән ерак утрауларны иңли, буйлый. Уң кулдагы ерак утрау буендагы комлык өстендә җемел-җемел килеп рәшә уйный, һава дулкыннары тирбәлә. Нәкъ арыш серкә очыргандагы кебек. Су өсте тыныч, үткән-сүткән көймә, пароход заты юк. Без, бер утрауны үтеп, Казан—Мәскәү юлы күпере-

нең югары ягына килеп чыгабыз һәм, Иделнең төп агым юлын үтеп, каршыдагы урманлы яман текә яр кырыена җитеп борын төртәбез. Җитез хәрәкәтле Мансур көймә борынын җәһәт кенә ташлар өстенә тартып куя, аннары Аязны күтәреп, ипләп кенә җиргә бастыра. Муса өлгер, үзе сикереп төшә.

Барыбыз да, аякларны суда чылатып, ап-ак ташлыкка урын җайлап утырышабыз.

Безнең каршыда Иделнең бөтен манзарасы ачыла. Васильево ягыннан килгән Идел, Зөя елгасы белән кушылган үзәнлектә борылма ясап, без утырган урманлы ярга таба тартылып, орынып ага. Шуңа күрә биредә агым да көчлерәк.

Аяз Идел дулкыннарының яр кагуын күзен дә алмыйча карап утыра. Бу безнең балык тота торган урыннар бит. Җәй саен шушында тиклем килеп кармак сала идек ич. 30 еллар булырдыр бирегә йөрүләребезгә.

Шушы дәвер эчендә Идел агымы, үзем турында әйтеп тә тормыйм, Аязда күпме матур хыяллар, уйлар, җылы өметләр уяткан, аның күпме моң-зарларын юып, күңелен юаткан, күпме шаянлыкларын, ихлас сөйләүләрен тыңлап бөтерелеп торган икән?! Ышанам, Идел Аязга нык ярдәм дә иткән. Идел ташкыны аңа яшәү өчен көч-кодрәт, хисдәрт өстәп торган, яңа хыял-уйларына канат иңдергән, илһамын үстергән. Әнә бүген татар әдәбиятында Аяз Гыйләҗевнең үз Иделе яр кага.

Ак таш өстендә утырган Аязны күзәтәм. Күренеп тора: дулкынлана, йөзен сагыш сарган, күзләре дымланган. Искәрәм, Мансур әтисенең хәле өчен борчыла. Ул кузгала башларга тәкъдим итә. Аязның бу хозурлыктан аерыласы да килми кебек, әмма аның күңеле булган. Калтыравыклы тавышы белән рәхмәт әйтә. Тагын нидер өстәп әйтәсе килә бугай да, тик дулкынлануы өнен баса, сүзсез генә минем беләкне кыса.

Без кайтыр юлга чыгабыз. Аяз тирә-якка күз салырга тырыша, артта калган урманлы ярга борылып-борылып карый. Иделдән һич аерыласы килмәгән кебек. Ул Идел белән саубуллаша.

Хуш, үзебезнең Иделкәй!

«Мәдәни җомга»

2 май, 2003






Сурәтләрдә калган мизгелләр



МИРГАЗИЯН ЮНЫС

Мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы

(А.Гыйләҗевнең иҗат портретыннан эскизлар)

Әдәбият ишеген шакып йөргән чагы булдымы икән Аяз Гыйләҗевнең? Аның өйрәнчек чагын, отышлы тема эзләп, отышлы жанр сайлап йөргән вакытларын да хәтерләмим мин. Ул татар әдәбиятына күк күкрәгән тавышлар чыгарып килеп керде.

Башта «Дружба народов» журналында басылган «Өч аршын җир», бераздан «Тәрәзәләр» китабына кергән әсәрләр һәм «Урамнар артында яшел болын» романы. Бәлки, арада аның башка әсәрләре дә булгандыр? Мин Аяз иҗатын үз күзем белән күзәтеп баруым турында сөйлим. Хәтердә аның шушы әсәрләре сакланып калган.

«Урамнар артында яшел болын», Эрнест Хемингуэйның иң көчле, иң тирән, иң нечкә хисләрен ачкан («Across the River and into the Trees») «Елга артында, агачлар күләгәсендә» әсәренә охшап, моңлы тантана авазлары чыгарып яңгырады. Әдәбиятка талантлы кеше килү эзсез калмый. Һәр яңа талант әдәбиятның офыкларын киңәйтә, әдәбиятны тою көчен яңарта һәм каләм осталарына яңа мөмкинлекләр алып килә. Һәр яңа талант әдәбиятта күп еллар эшләп килгән сәләтле әдипләрнең абруен күтәрә һәм моңа кадәр тыныч кына гонорар кимереп яткан графоманнарның бүрекләренә ут төртә. Чыннан да, Аяз Гыйләҗевнең әсәрләре матбугатта күренә башлау белән әдәби процесска җан кергәндәй булып китте, һәм тәнкыйть өлкәсендә дә уяну сизелде.

«Язгы кәрваннар» дөнья күргәндә, «Урамнар артында яшел болын» әле укучының күңелендә иде. Зур роман эчтәлеген эченә сыйдырган бу хикәя җитлеккән мастер ка-

ләме белән язылган иде. Гайрәтле, горур, халкыбызга хас кырыс оптимистик сулышта эшләнгән әсәр әдәбиятыбызны баету белән генә чикләнмәде, бу әсәр татар әдәбияты өчен этап булып калачак. Бер төркем хатын-кыз һәм яшүсмерләр, язгы юл өзелгән чакта, бәләкәй чаналарга җигелеп элеваторга симәнә алырга баралар. Дөрес, кәрванчылар әлегә ач, киемнәр юка, аякларга салкын кар суы үтә. Әмма бу өметсезлекне ачлык, озакка сузылачак ялангачлык түгел, яланнар ачылгач чәчеләчәк орлык рухы җылыта, баета. Шул орлыкны колхоз амбарына кайтарырга кирәк. Орлык кайтса, яланнар кысыр калмас. Алда зур, җылы өмет. Шушы өмет җиргә иңсә, үзебез дә, балаларыбыз да тернәкләнеп китәчәк... Кар суына батып, чана тартып барганда, ике яшь йөрәктә мәхәббәт уты кабынып китә һәм бу ут Ромео белән Джулеттоныкыннан бер дә ким түгел. «Язгы кәрваннар» — халыкның түземлелегенә, аның авырлыкларны горур оптимизм белән кичерә белүенә гимн булып яңгыраган хикәя. Гыйләҗевнең җор, якты таланты яшәүгә мәгънә биреп торучы ӨМЕТнең нинди зур, нинди көчле булуын укучыга җиткерә. Бу яктан «Язгы кәрваннар»ны Джек Лондонның «Яшәү мәхәббәте» һәм Эрнест Хемингуэйның «Карт һәм диңгез» хикәяләре рәтенә куярга мөмкин.

Ниһаять, мин Аяз Гыйләҗевнең үзе белән очраштым. Гомәр ага Бәширов Кисловодскида дәваланып Казанга кайтып бара иде. Мин аны каршы алырга Мәскәүнең Курск вокзалына чыктым. Вагон ишегеннән алар икәү килеп чыктылар. «Аяз Гыйләҗев хәзрәтләре, таныш булыгыз», — диде Гомәр ага, үзе белән бергә дәваланып кайткан юлдашына күрсәтеп.

Мин бер минутка югалып калдым. Каршымда аренага чыккан коррида үгезедәй аякларын җиргә ныклап беркетеп баскан бер кеше басып тора. Үзе минем Гомәр абый белән сөйләшүемне тыңлый, сизәм, хата сүз ычкындыруымны дәртләнеп, түземсезлек белән көтә. Хата сүз ычкынды булса кирәк. Аяз тәнкыйть чыбыркысы белән мине камчыларга тотынды. Тәнкыйть кемгә ошый? Ошамады миңа бу бәндә. Ошамады гына түгел, Гомәр абыйның шушы әтәч белән аралашып йөрүенә хәтерем калды.

Шушы кеше янында, чыннан да, Гомәр абый Бәширов башка планетадан иңгән зат булып күренә иде. Һәр сүзен кат-кат үлчәгәннән соң гына, ашыкмыйча, борынгыларча ләззәт һәм итагать белән генә сөйләшә. Өлкән әдиптәге вәкарь, чама саклау керәшеннәр җырындагы «әкрен кирәк, иплəп кирәк тыңларга сандугач сайрауларын» сүзләре мисалына тәңгәл килеп тора. Беренче күрүендә борынгы грек мифологиясе белән мавыгучы кызымның Гомәр ага турында: «Әти, бу Приам патшамы?» — дип соравы юкка гына булмаган, күрәсең. «Устами младенца глаголет истина» диләр руслар.

Минем әсәремә эчке рецензия язганда Аяз Гыйләҗевнең барлык тәнкыйтьләрен саный башласам, озакка китәр иде. Беренче очрашудан соң Казан поезды ике күренекле әдипне башкаладан алып китте. Перроннан төштем. Юл буе Аяз Гыйләҗевнең кемгәдер охшашлы булуы һәм шул прототипны исемә төшерә алмыйча баш ватып кайтам. Кемгә? Кайтып җиттем. Баскычтан менгән чакта келт итеп исемә төште: ул бит Джек Лондонның «Мексикалы» исемле хикәясенең герое Фелипе Риверага охшаган. Кырыслык. Максимализм. Ялганга, имитациягә һәм приблизительностьлыкка аяусызлык. Авызлык тешләп дулаган ат шикелле, дилбегә тыңламыйча дулап, үз кыйбласына чабу. Киртәлексез юлны өнәмәү, дошмансыз, конфликтсыз яши белмәү...

«Мексикалы» хикәясенең финалында ачыклана: Фелипе Ревераның кырыслыгы туган илен, халкын өзелеп яратуда, революция өчен соңгы сулышын бирергә әзер торудан икән. Фелипе дусларын да шундый кырыс, шундый компромиссыз бирелү белән ярата. Беренче урында революция ихтыяҗы. Революция аның иманы, өмете, киләчәге. Ул шуңа күрә дусларына карата аяусыз...

Аяз Гыйләҗев тә безнең әдәбиятыбыз ихтыяҗына компромиссыз бирелгән кеше.

Инде күпме еллар әдәбиятыбызның пакьлеге, аның халыкчанлыгы һәм хакыйкыйлыгы өчен көрәштә үзен туктаусыз кайнатып тора. Һәр графоман, һәр имитатор һәм һәр халтурщик аның яныннан тыныч кына узып китә алмый. Алар аның, дөрес, эченә типмиләр, чукмар белән баш түбәсенә дә кундырмыйлар. Бу сугышта, дөрес, тән кара көйми, борыннан да кан китми, кан бары тик йөрәктә генә ойый, йөрәккә кан сава.

Әдәбиятның төп ихтыяҗына, аның сафлыгына, пигамбәрлек вазифасына каршы көрәшүчеләр аяк чалу, итәк астыннан ут йөртү белән генә чикләнеп калмыйлар. Аларның төп кораллары шул: «Без — патриотлар, — дип, күкрәкләренә суга-суга үкерәләр алар. — Патриот булганга күрә, без чынбарлыкны мактыйбыз, бүгенге чынбарлыкка мәдхия җырлыйбыз». Һәм шушындый гонорар мародерлары, патриотизмны моноль рәвештә үзләренә тартып алып, башкаларны патриотлыктан мәхрүм итәргә тырышалар. Графоманнар тактикасы менә шундый.

Аяз Гыйләҗевнең әсәрләре, матбугатта күренү белән кискен бәхәс кузгатып, капма-каршы бәя ала килделәр. Аңа тәнкыйтьчеләр «мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы» дигән исемне дә тагып өлгерделәр. Шушы исем әдипкә озак сакланырлык булып ябышып та өлгерде шикелле. Гыйләҗевнең иҗатына карата «мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы» дигән ярлык туры килсә дә, бу иҗатны татар әдәбиятының кечкенә бер өлеше итеп караганда, тәнкыйтьчеләр фикерендә башка язучыларны мәсхәрәли торган киная барлыгы сизелә. Безнең әдәбиятта «мәхәббәт һәм нәфрәт» җырын бер Гыйләҗев кенә җырлыймыни? Башка язучылар укучы күңелендә мәхәббәт һәм нәфрәт тойгылары уята алмыйлар микәнни? Мәхәббәт һәм нәфрәт уята алмаган әсәрне әдәби әсәргә санарга хакыбыз бармы соң безнең? Аяз Гыйләҗевкә тәнкыйтьчеләр таккан шушы этикетка миндә һәм башка язучыларда да дип уйлыйм мин, ниндидер ризасызлык хисләре уяткан сораулар тудыра.

Әдәби әсәрнең бәясен сюжет, композиция төгәллеге, аның теле, эшләнеше, тема актуальлегенә карап билгеләү инде күптәннән нормага әйләнгән. Ә әдәби әсәрнең сыйфатын билгеләгәндә, кызганычка каршы, аның тормышны чагылдыру көченә, яшәешнең мәңгелек кануннары белән чор таләпләре арасындагы конфликтны күрсәтә алу сәләтенә без күп очракта күз йомып узарга тырышабыз. Яшәү катлаулы. Ни сәбәптер бу катлаулылыкны техника казанышлары да, экономика уңышлары да, хәтта муллык, бай тормыш шартлары да бетерә дә, киметә генә дә алмый. Киресенчә дип әйтергә дә буладыр, эчке конфликтлар яшәү шартлары төрлелегендә кискенләшә генә дә бара

әле. Адәм баласына җиңел машинага утырып йөрү, затлы ашлар белән тукланып кыйм-
мәтле киемнәргә генә төренеп йөрү җитми. «Не хлебом единым» диелгән Тәуратта.
Адәм баласының җанына да нәрсәдер кирәк. Әгәр шул җан азыгы булмаса, байлык та,
зур урын да, хәтта яраткан эш тә кешене тулысынча канәгатьләндерә алмый. Дөнья
яралганнан бирле мул яшәү белән изге яшәү арасында беркайчан да килешүгәирешә
алмаслык кискен көрәш бара. Шушы көрәш бүгенге көндә дә үзенең актуальлеген
югалтмаган. Тормыш аренасына чыккан һәр яңа буын ни сәбәптер яшәү гыйлемен өр-
яңадан өйрәнергә мәҗбүр. Безгә кадәр яшәп киткән буыннар тәҗрибәсен ни сәбәп-
тәндер көндәлек тормышта тулысынча кулланып булмый. Әдәбият, җәмгыятьнең кү-
заллау формасы, кешелек дөньясының вөҗданы буларак, тормыш аренасына чыгучы-
ларга кулланма ролен уйный. Ул нәкъ шул ягы белән алыштыргысыз кыйммәткә ия
дә.

Әшәкелек белән яхшылык, ялган белән хакыйкать арасындагы чикнең кай тараф-
тан узуын фән дә, фәлсәфә дә тормышта кулланырлык итеп күрсәтә алмый. Чорның
иманы, яшәешнең кыйбласы буларак караның — кара, акның — ак, ялганның — ялган,
хакыйкатьнең хакыйкать булуын укучының аңына һәм хисләренә ни сәбәптер әдәбият
һәм сәнгать кенә җиткерә ала. Җиткерү белән генә чикләнмичә, Шекспир, Толстой,
Тукай яулаган сыйфатларга ирешкән әдәби әсәр, ялганга, икейөзлелеккә даими нәф-
рәт уятып, укучының тойгыларын тәрбияли. Кулына каләм алган кешенең бу турыда
бер генә минутка да онытып торырга хакы юк. Кызганычка каршы, ниндидер каһәрле
сәбәп, безнең канга сеңгән коллык микроблары шушы иман шартына тиң канунны еш
кына онытырга мәҗбүр итә. Әдәби әсәргә бәя биргәндә, аның эчендәге нәфрәтнең
компромиссыз булуына, андагы мәхәббәтнең саф һәм риясызлыгына таянып кына эш
итәсе урынга, без еш кына теманың ялган вәгъдәсенә ышанып хөкем чыгарабыз. Хал-
тура, әдәбият имитациясе мавыктыргыч сюжет артына яшеренеп, ширбәт телгә төре-
неп килә. Халтура һөҗүме бөек Гомер, Кол Галиләр чорыннан бирле чын әдәбиятка
карата туктালып торганы юк. Аңа каршы көрәшү елдан-ел авырая һәм катлаулана ба-

ра. Йөгерек тел белән язылган маҗаралы сюжетлы әсәрне тәмле аштан соң кәефләнеп ял иткәндә дә теш арасына кергән итне чокый-чокый укырга кем яратмый? Без канәгать. Андый әсәрне укыганда гражданлык позициясе уянмыйча, мәхәббәт һәм нәфрәт хисләренең йоклап калуына әһәмият биреп тормыйбыз без. Нигә нервларны бозарга? Болай да тормышта мәшәкать күп. Мәхәббәт һәм нәфрәт хисе уятмаган әсәрне күңелдә өченче төрле тойгы — битарафлык тәрбияләвенә дә кул гына селтибез. Тормыш мәшәкатеннән афәт килгәндә башын комга тыгып яшеренгән кыяфәткә кергән тәвә кошы шикелле кыланабыз без детектив сюжетлы әсәр укыганда. Битарафлык — кешелек дөньясында безгә кадәр яшәгән һәм киләчәктә дә яшәячәк иң шапшак, иң куркыныч тойгы. Кешелек тарихындагы әшәкелекләр: колониаль система, коллык, фашизм, икейөзлелек — боларның барысы да шушы хис белән ашланып, битарафлыкның шифалы сулышында тамыр җәюе турында уйлап баш ватудан безне детектив сюжет коткара. Әкренләп җан бирчәю, рухсызлык, әхлаксызлык — шушы кешене кире хайванлыкка сөйрәүче сыйфатларның барысы да битарафлык куенында тәрбияләнә.

Язучы әсәре аша укучы күңелендә мәхәббәт һәм нәфрәт тойгысын тәрбияли алмаган очракта, әдәбият, җәмгыятьтәге төп вазифасын югалтып, күңел ачуга көйләнгән балаган программасына әйләнер иде.

Моннан өч ел элек Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» исемле китабы чыкты. Сюжет искиткеч гади. Әсәрнең төп герое Бибинур — сокланып туя алмаслык сылу, ябь-яшь кыз. Ул, матур егеттән баш тартып, өч балалы тол карт иргә — Габдуллаҗанга — үз иркеннән кияүгә чыга. Алар бергә яши дә алмый калалар, Габдуллаҗанны сугышка алып китәләр. Шул китүдән өч баланы ятим калдырып, сылу, матур кызга тол тамгасы салып, Габдуллаҗан югала. Бибинур үзенә чит-ят ятимнәрне авыр шартларда тәрбияләп үстерә. Үсеп аякларына баскач, балалар үги аналарын ташлап китәләр. Бибинур ялгызлыкта, шул балаларны бер күрергә тилмереп, картлык көнендә газап чигә.

Соңгы елларда гаилә кору, семьядагы ир белән хатын арасындагы тату, бердәм

яшәү, бала тәрбияләп үстерү проблемалары газета битләреннән төшми диярлек. «Җомга көн, кич белән...»гә шушы проблема куелган. Беренче карауга мәсьәлә чиктән тыш гади, хәтта примитив хәл ителгән шикелле. Инде кем иректә көннән сокланырлык матур егетне ташлап өч балалы карт тол иргә кияүгә чыксын?! Инде кем ирекле көннән ят балаларны карап үстерсен?! Әсәрне укымаган кеше һәр очракта шулай уйлавы мөмкин. Әсәрне укый башлау белән, син Лев Толстойны чиктән тыш дулкынландырган проблемага кереп китәсең. Бу дөньяда үз бәхетең өчен генә тырышканда бәхетле булып булмый. Бәхеткә ирешү өчен башка кешеләрне дә бәхетле итәргә тырышучы булырга кирәк. Шушы проблеманы Аяз Гыйләҗев искиткеч тирән итеп бүгенге көн тормышы аша ачып күрсәтә алган. Бу әсәр дә «Язгы кәрваннар» шикелле халыкчан һәм әдәбиятка тормыш чынбарлыгыннан кергән. Бала җанлылык, бала тәрбияләп үстерү аша бәхеткә ирешү халкыбызга хас күркәм бер сыйфат. Төрки хатыннарның бала җанлы булуын демография һәм социаль психология өлкәсендәге фәнни тикшеренүләр раслый. Бу турыда XI гасырның беренче яртысында Багдадта яшәгән галим Ибне Бутлан язып калдырган. Һәр даһи әсәр гади була. «Моны ничек мин үзем язмаганмын икән?» — дип аптырап йөрисең чын, озак яшәрлек әсәрне укыганнан соң. «Җомга көн, кич белән...» соңгы ун-унбиш ел эчендә татар әдәбиятының горурлыгы булган иң яхшы әсәрләрнең берседер дип ышанам мин.

Инде Аяз Гыйләҗевне ун елдан артык беләм. Аның белән озаклап сөйләшкәннәрем, серләшкәннәрем бар. Аның турында башка язучылар әйткән фикерләрне дә күңел салып тыңлап йөрим. Беренче очрашуда күзгә ташланган Аяз — ул язучы Аяз Гыйләҗевнең нәкъ ярты өлеше генә икән. Ә хәзер Аяз турында мин болай әйтер идем: әдәбият уңышларына сабыйларча шатлана, башка язучы иҗат иткән яхшы әсәрдән бәхетле була белә торган шәхес. Мөхәммәт Мәһдиев, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах әсәрләре матбугатта күренү белән, аларны иң беренче укучы Аяз Гыйләҗев булыр, һәм чын әсәрнең дөньяга килүе аңа зур куаныч, бәйрәм! Марсель Галиев, Фәүзия

Бәйрәмова, Азат Ганиевнең беренче адымын иң башлап Аяз Гыйләҗев күреп алды һәм ул аларга беренче булып ярдәм кулын да сузды.


«Тәрәзәләр» җыентыгы Аяз Гыйләҗевнең «Үзем турында» дигән кереш сүзе белән башланып китә. «Үги ана яфраклары» хикәясенең герое Галимҗан турында автор болай ди: «Галимҗан — авыл шоферы... Күккә һәм җиргә карап төрле уйлар уйлана белә торган, мәхәббәтнең изгелеген, олылыгын, кешенең мәхәббәтен кабатланмас горурлыкта булырга тиешлеген аңлаган тәрбияле, нечкә күңелле кеше... Ул матурлыкны кабул итә белә, үзе дә аны тудырырга омтыла, дөнья әдәбиятын — Экзюпериларны, Хемингуэйларны укый, төньякның гүзәл сихерчесе Григны бөек Сәйдәшне сөйгән кебек үк сөя, әмма барлыгы, бөтен яшәеше белән шушы җирдә, үзебезнең җирдә яшәүче бай рухлы егет. Җир дип атала торган планета кешесе...»

Бу юлларны Аяз Гыйләҗев үзе турында язган.

1984–1985



# Аяз Гыйләҗев



# Үзем турында үзем...





Балачак сукмаклары

1

Әйе, бүген дә, алтмыш яшьне үтеп, ашыга-ашыга җитмешкә тәгәрәгәндә дә, мин җәяүле сукмакларга тыныч кына карый алмыйм. Олы юлларны аркылы-торкылы кисеп үткән гап-гади сукмаклар миндә татлы хисләр, җылы тойгылар уяталар. Кая гына барсам да — поезддамы, автобустамы — мин ихтыярсыз тәрәзәгә ябырылам: уңга-сулга, урман ешлыкларына, әрәмәләрнең сихри кочагына кереп киткән сукмакларга карап, хыял дөньясына чумам. Шушы, меңнәрчә адымнар белән такырланган, инешкүл буйларын чәлмәп ураган, карурманнарның серле дөньясы аша үткәрүче, зарыктыручы, кавыштыручы уравыч тар юллардан дөньяның иң бәхетле адәмнәре йөридер дип фараз кылам. Әнә алар, кабаланмыйча, бер-берсен очлы терсәкләре белән борчымыйча, дөньяның кабатланмас гүзәллеген туя карап, зәп-зәңгәр күк, ямь-яшел җир белән аңлаша-аңлаша, болын, урман чәчәкләренең куе исенә кинәнеп бәхет диңгезендә йөзәләрдер төсле.

Бәләкәй чакта сукмаклар синеке! Ялантәпи тып-тып басып дөнья белән танышу әнә шул җәяүле сукмаклардан башлана. Кая карасаң да, сиңа ят ярлар, моңарчы син күрмәгән, күрә дә алмаган сер дөньясы.

Балачак хатирәләре — әкрен аккан, өзек-өзек ак болыт кебек истәлекләр — бер-беренә ялганмыйлар, әллә кайда, шул серле сукмакларда уралып, еракта, томанлы офыклар артында тынып калган вакыйгалар һичкайчан да бер-беренә чылбырдай тоташа алмыйлар. Алсу шәүлә дә кебек алар, таңда яңгыраган сак җыр да сымак, кайчан булып үткәннәрен өзеп әйтеп тә булмый. Балачак хәсрәтне белми, ә вакыт белән янәшә яшәү хәсрәт килгән көннән генә башлана...

Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән. Шулай уйлыйм, хәтергә нык сеңеп калган вакыйгалар шуны сөйли.

А.Гыйләҗевнең әнисе Мөгаттәрә, әтисе Мирсәет. 1935 еллар



Җәйләрнең берсендә әнием ындыр түрендәге кыяр түтәлләре ара-

сына барып кергән. Мин, терсәкләремә таянып, артымны туңкайтып,

борын очым белән җир сөреп, чәнти бармак кадәрле үскән кыяр ма-

лаен кимереп ятам икән... Әни, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп: «Улым, ни-

гә кыярны ятып ашыйсың?» — дип сораган. Мин, аллы-күкле янып: «Үзең өзмәскә куштың ич!» — дип җавап биргәнмен, имеш. Җавабымны

үзем хәтерләмим, әни сөйләвеннән исемдә калды, ул ышанып сөйләгәч, шул вакыйга бала чагымның иң кадерле хатирәсе булып күңелемдә саклана.

Минем әтием тумышы белән Сарман кешесе, үз-үземне белә

башлаганда без Югары Баграж дигән гүзәл керәшен авылында, нәкъ

чиркәү каршысындагы пуҗымда, Әндриян дәдәйләр өендә яши идек.

Таза ихата, йорт-җир байларча биек итеп салынган, җәен салкынча,

кышын зәмһәрир суыкларда да җылы була торган калын стеналы таш

амбарны мин аерата ярата идем.

Әндриян дәдәй — балта остасы, аны Федоттагы ятим балалар йортына

эшкә чакырып алганнар да, ул гаиләсе белән шунда яшәп ятканда, без алар өендә тордык. Минем татлы, кадерле балачак

истәлекләрем Җир шарының шушы нәни ноктасы белән бәйләнгән. Каршыда, бакча

эчендә чиркәү, уңда мәктәп биналары, мәктәп каршысындагы киң генә мәйдан ми-

ңа — шактый елгыр малайга — яшәү серләрен ачып биргән кадерле урыннар иде.

Әндриян дәдәйләр бакчасы кояшка таба авыш, ул сөзәкләнеп ындыр артыннан үт-

кән Метри елгасына төшә. Язын әз-мәз сулы, ташу кузгалганда ике-өч көн дулап

алып, җәйге чилләдә кибеп-корый торган Метри ярында әти яшелчә бакчасы ясады.

Яфракларыннан татлы ис таратып утыручы юаш карлыган куаклары да шунда тезелде.

Кыяр, кишер, чөгендер, помидор янәшәсендә Югары авыл өчен ятрак булган кавын-

карбызлар тәгәрәп үсте. Кунак-мазар килгәндә, әти аларны чәй эчкәнче үк бакчасына

алып төшә иде. Әти урта мәктәптә химия, биология укыта — иртә-кич бакчада казы-

нырга нык ярата иде.

Соңгы сигез гасыр эчендә дөньяда табигатьнең иң мәрхәмәтле еллары утызынчы

белән кырыгынчы еллар арасына туры килгән. Җир сирәк тетрәгән, зилзиләләр сирә-

гәйгән, янар таулар яман утларын сак түкергәннәр, җәйләр җылы, мәрхәмәтле, шәф-

катьле булган. Утызынчы-кырыгынчы — минем бәхетле бала чагымның еллары! Мин

хәзерге әле коры, әле яңгырга тоташ манчылган җәйләрне ул бәрәкәтле еллар белән

чагыштырып карыйм, һәм хәзерге заман балаларын уйлап күңелем сызлый... Җир мәрхәмәтле, сөйкемле еллары белән дә безне иркәләгән икән!

Агач чиркәү! Аның безнең тәрәзәләргә караган диварына, өскә үк «1840» саны

сугылган сары калай кадакланган. Без бәләкәй чакта Баграж чиркәве үзенең йөз еллы-

гын үткәргән икән. Мин чиркәүнең биек-биек, янындагы озын чыршылардан да биег-

рәк күтәрелгән хачларын, эчендәге алтын-көмешле бизәкләрен, диварларына эленгән

Мирсәет Гыйләҗев. 1938



тәреләрне, чигүле тәре алъяпкычларын яхшы хәтерлим. Утызынчы елларда авыл коммунистлары — Озын Микәйлә, тагын кемнәрдер — чиркәү хачларын кисеп, түбә калайларын изә-изә дөбердәтеп җиргә төшерделәр.

Чиркәүгә һәм Әндриян дәдәйләр өенә чапырышта, сул ягыбызда, мәшһүр каравыл өе. Шунда ук янгын сарае, ат абзарлары, күгәргән кул насослары, коргаксыган мичкәләре, лапас өрлекләрен терәгән шома сөян баганаларга ыргак, багур, корымлы пумалалар асылган, дәү-дәү имән чөйләргә бөятләре ашалган камытлар, буяулары купкан дугалар, сүсәргән аркалык-түшлекләр, таҗ баулары эленгән. Без — Урта һәм Аскы урам малайлары — бәхетле! Әниләрнең «замат арасында кайтасы бул, ыштубыты ишетсен колагың!» диюләренә карамастан, әбәдтән соң гел шунда уралабыз. Мич арасыннан, аулактан урын алып калырга кирәк. Менә каравыл өенә карт-коры җыела башлый, кичкырын, иплəп кенә ирләр дә шунда тартыла. Алар вәкарь белән, ашыкмыйча күрешәләр, озын итәкле чикмәннәрен, иске пинжәкләрен чишеп җибәрәләр, чилемнәрен кагып тәмәке тутыралар. Һәм китә сүз! Ишек шар ачык булса да, өй эче тиздән төтен белән тула, ләкин без кыймшанмыйбыз, киресенчә, мич арасыннан башта елтыр танаулар күренә башлый, аннары баш күренә, муеннар сузыла. Ашау, өй, әнинең кисәтүләре истән чыга, кумасыннар гына!..Кызык сүзләр, мәзәкләр, дәмәкләр шунда сөйләнә...Инде Багражның атаклы сунарчылары Аксак Ибан белән Сәвәләй Питеры да килеп керсә... бетте! Без төнгәчә аларның маҗараларын тыңларга әзер. Түтәл тәмәкесеннән төрелгән «кәҗә сыйраклары» чытыр-чытыр яна, йөз ел юылмаган тәрәзәләргә эңгер иңә, идән өстенә яңа керүчеләрнең алапай чабаталарыннан туфрак коелып, яңа катламнар ясала, ә безгә рәхәт. Керәшеннәр үтә сабыр, бер-берсенә итагатьле халык, ничә еллар яшәп, багражлыларның үзара сугышканын, талашканын күргәнем, ишеткәнем булмады. Багражда олылар — Олы, кечеләр — Кече...

Кем ничек кушкандыр, берзаман каравыл өе адәмнәре янына мин үз бакчабыздан бер кесә кыяр тутырып килдем. Бусын үзем дә ап-ачык хәтерлим!.. Дәү-дәү, көрәк сакаллы керәшен дәдәйләр мине кызык өчен генә кыяр урларга җибәргәннәрдер дип

уйлыйм, борчак кузагы дәүмәлеге кыярларны күреп: «Ник мондый вакларын өздең?» —

Мирсәет һәм Мөгаттәрә Гыйләҗевләр уллары (сулдан)

Аяз, Алмаз һәм Азат

белән. 1935



дип сораганга, «Олыракларын күтәреп булмый шул аның!» — дип җавап бирдем. Үзем оялып, пешеп-янып идәнгә текәлдем һәм нәп-нәни кыярларны идән ярыгыннан берәм-берәм базга шудыра башладым.

Оялуымны, чәнти-чәнти кыярларымны, ирләрнең көлеп җибәрүләрен бүгенгедәй хәтерлим. Авыл малаеның балачак хатирәләре кыяршалканнан башлана икән, моңа һич гаҗәпләнергә кирәкми. Авыл баласы үзенең эшчәнлеген, хезмәтен әнә шул бакча түтәлләреннән башлаган.

Әтиемнең Сарман тумасы икәнен әйткән идем инде, әнием Мөгаттәрә дә шул төбәк кызы, Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында туып үскән. Әти Минзәләдә педучилищеда укый башлаган, әнием шунда ук кызлар мәктәбендә белем алган. Минзәләдә танышканнар алар, шунда кавышканнар. Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни бер-бер артлы өч малай табып өйдә утыра. Әтине, яшь мөгаллим дип, район читендәге Югары Баграж авылына укытырга җибәрәләр, авыл Зәй районы карамагына күчкәч тә, безнең гаилә Багражда калган. Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда, юмарт күңелле, кунакчыл, гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтте. Олысы-кечесе безне хөрмәт итә иде. Көрәк сакаллы, абруйлы авыл агайлары әниемне яратып, гади укытучы хатынын зурлап «апа» дип эндәшәләр, әллә каян, ерактан, бөгелә-сыгыла сәламләп киләләр иде. Әнием оста җөйче иде, Баграж сылуларына чуклы-чачаклы түшле, бәбәйтәкле күлмәкләр тегеп кигертә

башлагач, аның абруе тагын да үсте. Ата-ананың абруе авыл арасында малайларны да үзсендереп җибәрә. Хәтеремдә, авыл уртасындагы мөгәҗи* амбарына айбагыр кайтарып тутырдылар. Кояшлы көннәрнең берсендә айбагырны амбар алдындагы чыбылдыкларга чыгарып тараттылар. Керәшен авылында айбагыр йорт буенча тулып ята, шулай да малайларның күзе амбар тирәсендә... Айбагырның үзе түгел, шуны чәлдерергә маташу дәмәк!.. Амбар артыннан шыпан-шыпан чыгып кесәләргә айбагыр тутыра башлаган гына идек, тап-таза Югары оч егете Миндәй Ибаны якадан эләктермәсенме?! Яра инде дип торганда, Ибан минем кем малае булуымны белгәч йомшады, кесәмә айбагырны шәпләп үзе тутырды...

Озын кышларны кая да чыгып йөрмибез, Багражда үткәрәбез, язгы-җәйге бәйрәмнәргә — җыенга, Сабантуйга — без Сарман, Әхмәт якларына кайта торган идек. Хуш исле йомшак печән түшәлгән тарантаска гаилә белән төялеп, мәктәп атын җай белән генә атлатып егерме чакрымны — Сарман — Баграж арасын үтүләр татлы төш булып истә калды... Завод үрен менгәч, юл урман эченнән үтә, ә анда каен җиләге кыпкызыл келәм булып, кызыктырып, җанландырып безне көтеп ала торган иде. Табигатьне олылау, аны изге санап баш ору безнең заман кешеләрендә үтә дә көчле иде! Без, малайлар да, җиләкне алан читеннән, таптамыйча, берәмтекләп җыя идек. Башта «кызыл сандык»ка — авызга шудырасың, аннан берәр савытка, күчтәнәчкә җыя башлыйсың. Җир-су чиста, болытлардан көмештәй яңгыр ява, җир хәзинәсе җиләк-җимешләр әле саулык кына китерә!

Гаҗәп, бәләкәй чакта мин Сарман урамнарына калай җәелгән, ә Нөркәй дигән авыл кешеләре очлы түбәле брезент юрталарда яшиләр дип белә идем. Малай кеше

* М ө г ә җ и — келәт (диал.).

Аяз (сулда) абыйсы Азат белән



аякка киеп торамыни? Күп кешеле Сарман урамнары нык тапталып, җәйге челләләрдә көйдерерлек кызгандыр шул! Мин шулай дип хәзер генә, шушы хатирәләрне язган чакта юрадым. Ә нөркәйлеләрне ник брезент юрталарга күчергәнмендер, аңламыйм, бәлки, әтиләр белән Нөркәй авылын узып та киткәнмендер?

Исемдә, тәбәнәк кенә, йомры гына ике малай, әтинең бертуган абзыйсы Мәхүб-рахман абыйның улы — яшьтәшем Максут белән алар капкасыннан ишегалдына кереп киләбез. Куллар артта, йөзләр җитди, авызлар йомык. Әниләр безгә карыйлар да баш-та... кычкырып көләләр! Ә аннан соң... кулларны кычыткангa үреләлә. Тикшереп карасак, икебезнең дә түшләр сап-сары икән... Ни хикмәттер, дүрт яшьләрдә чакта икебез дә чи күкәй эчәргә ярата торган идек. Гел-гел ояга менәргә әниләр рөхсәт итмәгәндер шул, ара-тирә күршеләрнең тавык ояларына да походка чыкканбыздыр... Шуны уйла-дым исә, мәшһүр шагыйребез Һади Такташның «Мокамай йомырка урлаган» дигән тәүге шигыренең юллары искә төшә. Һәр Мокамайның Әйшә тәтәе була, бәләкәй чакта татыган «кычыткан себерке»ләр ул чакта урлашмаска өйрәткән әче сабак була торган иде.

2

Дүрт яшемдә идемме, әллә якты кояш астында бишенче җәемне үткәрә идемме, безнең авылда балалар бакчасы ачтылар. Аны «Площадка» дип атадылар. Урак өсте иде шикелле. Минем әни белән Югары очның Феона апа Васюкованы тәрбияче итте-ләр. Үзләре ашчы, караучы, җыештыручы, кер юучы да иделәр. Шуның өстенә әни малай-кызларга пар җәйге киемнәр дә текте. Ул чактагы рәхәтлекләр! Су коеныргa йөрибез, авылга авып торган тау тезмәләре битләреннән җиләк җыябыз, олы малай-ларның ат коендырганын бергәләп карыйбыз. Мин атларга якын ук килергә куркам,

А.Гыйләҗев ireккә чыккач 1963 елда Урта Багражда салдырган йорт



читтән генә, сагаеп, яр буе таллары арасыннан карап торам. Ник дигәндә, берзаман әти белән мәктәпнең Аманат исемле атына утырып кайттык та, әти Аманатны тугарып җибәрде, мин сарай ишеген ачарга йөгердем. Аны-моны искәрмичә барам, башын чайкый-чайкый артымнан фырлап килгән Аманат кинәт җилкәмнән умырып алды да мине алагаемга чайкап җибәрде. Акырып еларга тотындым, аркам канады, Аманат тешләренең эзе шактый вакыткача җөйләнеп торды. «Аткамы, бүтән хайваннаргамы, телең белән тәмләп эндәшмичә, берчакта да алдына төшмә!» — дип өйрәтте әти. Мин гомерем буе аның киңәшен тоттым, тик, нихәл итәсең, йорт тирәсендәге мал-туарлар, кошкорт әтинең киңәшен белмәгәндер шул: үз гомеремдә мине өч тапкыр каз талады, дүрт-биш мәртәбә кәҗә тәкәсе сөзде, колхозның иң дәү ата дуңгызы төртеп екты, бер тапкыр Имәнле урамында ана күркә кычкыртып талады.
«Площадка»ның кайда, кем өендә урнашуы ныклап исемдә калмаган, мәгәр без Метри елгасы тирәсенә Каравыл почмагыннан Макар дәдәйләр, Ипис түтиләр ызаныннан төшеп йөри идек. Елга аръягында искиткеч матур, аллы-гөлле чәчәкләр каплаган бәләкәй генә болын бар иде. Иртә яздан кара көзгәчә чәчкәләр бер-бер артлы ачылалар да җәйнең һәр күләмендә болынның үзенә хас чәчкә исе була торган иде. Беркем кисәтмәсә дә, болынга аяк баскан кеше кинәт үзгәрә, чәчкәләрне өзмәскә, үләннәрне таптамаска тырыша. Кай яктан җилләр иссә дә, алар тыгыз һавалы бу үзәнгә төшеп җитә алмыйлар, көн туса, без шул оҗмахта күбәләк куабыз, гөрле-качышлы уйныйбыз, әз-мәз таптап китсәк тә, без болыннан чыгуга, үләннәр рәхәтләнеп турая торганнар иде. Еш кына болынга, эштән бушаганда, әти дә төшә, безне түгәрәкләп тирәягына утырта, гонҗә-үләннәрнең исемен атап, берәм-берәм күрсәтә башлый. «Безнең якларда ашарга яраган йөзләп үлән бар», — дия иде. Ниләр генә җыеп ашамый идек без Баграж болын-урманнарыннан! Җиләк-җимешне, гөмбәләрне әйтеп тә тормыйм, язга чыгып кар китүгә, кояшка караган ермак ярларына сап-сары булып бакыр тәңкәләр сибелә. Кимәшә башын бүксәң кап булганчы аша, зыяны юк. Кимәшә башына Мөгаттәрә һәм Мирсәет Гыйләҗевләр үзләре утырткан каен хозурында. 1970

ялганып урманда, күздән калган коры яфракларны аралап, күке башы калкына. Аланнарда кузгалак үсә, кыр какысы, урман какысы котырып уңа...Төрле якларда әнис, җир бәрәңгесе, карабаш, балтырган җыярга йөрибез. Олы су башында сарана!.. Кәҗә башы урамыннан ындыр артларына төшсәң, ни генә юк анда: песи борчагы, карга борыны, шепкән... Тыкрыкларда кычыткан кыяры үсә. Карга борынының тамарга торган җиләген ашыйбыз, шепкән уабыз. Шома көпшә, сасы көпшә, чуар көпшә. Җаның ни тели!

Эссе җәй! Яндыра! Быел коры җәй, ләкин без яраткан болынның дымы бетми, без, икешәрләп тотаклашып, Метри елгасына таба төшеп барабыз. Алдан юл күрсәтеп әни бара, ыбыр-чыбыр бәрәңге арасында адашып калмасын дип, арттан үткер күзле Феона апа атлый. Нәкъ каршыбызда, елга үзәненең аръягында, уңдарак, унбиш-егерме йортлы Имәнле урамы. Урам очында Чулак Кунуннар йорты. Үкличә киртәсе алар ихатасына тоташкан. Үзем күрдем, әнигә ияреп көтү каршыларга барганым бар. Кунуннарның Ладимыр исемле куштүбәле базык уллары да «Площадка»га йөри, без хәзер шуның белән җитәкләштек. Булса да булыр икән шук бала! Ладимыр берәүгә дә тынгы бирми, кызларның толымыннан тарта, толымы юкларның бармагын тешли, малайларны чалып ега, су коенганда кызларның күлмәгенә таш бәйләп буага ыргыта. Үзе көчле, үзе алагаем хәйләкәр. Бу терекөмеш мәктәпкә кергәч тә укытучыларның җыгын чыгарды. Дәрестә утыра алмый иде, мәктәп базына кереп чума, теленә нинди җыр килсә, шуны акырып ята... Имәнле урамы хәзер юк, бетте, таралды, Ладимыр яшьтәшем дә күптән инде гүр иясе булды. Үскәч акыллы, үтә сабыр, ипле кеше иде, шофер булып эшләде, көтү көтте... Сирәк кенә сагынышып очраша торган идек, урының җәннәттә булсын, яшьтәш!

Төшеп барабыз, әни, күз алдында булсынга, аны алгы парга куйган, шунда да ул мине чалып егарга маташа. Тезләре кутырлап беткән, иягендә җөй, иреннәре мыймылдый, колагы селкенә — һич тик бара алмый! Күзем Имәнле урамы өстенә эленгән печән кибәне дәүмәлеге болытка төште. Болытны чамалап, әни дә туктап калды. Зәп-

зәңгәр иде күк, каян яралды әле бу аклы-каралы иләмсез болыт?! Капылт кына әллә ни булды, зәңгәрсу кызыл сызык болыттан аерылды да түбәнгә, җиргә, Имәнле урамы өстенә атылды. Күк яман чатлап урталай ярылды, гайрәтле күк күкрәвеннән без җиргә егылдык. Әни, борылып: «Балалар!» — дип кенә әйтә алды. Аяк өстендә бер Ладимыр гына басып калган икән, Имәнле өйләре өстеннән ургылып чыккан төтенне әүвәл ул абайлады, яшелле-мөшелле тавыш белән: «Пужар! Пужар!» — дип акырырга тотынды. Озак та үтмәде, тирә-якка искәртеп, чиркәү чаңын кага башладылар. Әни белән Феона апа, тилгәннән качып кайсы кая таралган чебиләрне җыйган төсле, безне көчхәл белән җыйдылар. Бер кыз куркуыннан Метри елгасының төбенә үк тәгәрәп төшкән икән. Утыра шунда посып, үги ана яфраклары арасында! Без бәрәңге сабакларын таптый-таптый каравыл өенә менеп җиткәндә, анда мәхшәр башланган иде инде. Тик ятып үшәнләнгән каравыл атлары чаң тавышыннан куркып тәртә арасына керми интектерәләр, пужарниклар да каушаган, алар ат сыртына каеш камчы белән тамызалар. Атлар аның саен киреләнә, йөгәннәрен тартып хырылдыйлар. Күпердән әйләнергә ераксынган Урта урам адәмнәре, чиләк, көрәк, багурлар тотып, без менгән сукмактан гына Метри елгасын кичеп, янгын ягына элдерделәр. Башта аклы-каралы куе төтен бөркелгән иде, соңра ялкын телләре сузылды, бераздан Имәнле урамы тоташ учакка әйләнде. Әллә-лә! Яна Имәнле урамы, дөрли, ә яман гадәтле алама болыт, «Сау булыгыз!» дигән төсле, авыл күген бер әйләнде дә үтеп китте. Ут янына чабарга шүрләгән карт-коры каравыл өе янына җыйналды. Телләрдә бер сүз: «Вәт, Ходаның хикмәте, ишеп яуса соң! Нигә утын гына ташлап калдырды бу болыт, шоннык?!»

Унбер йорт нигезенә кадәр утырып янды.

Кага-кага чиркәү чаңын урталай ярганнар...

«Эзейдән дә килделәр, тирә-яктагы унбиш авылдан атлар килде», — дип сөйләде соңарган кичке чәй янында әни. Ул төнгә әни «Площадка»га ашыкты, ул төнне Имәнле урамы балаларын шунда кундырдылар. Әни шуларны карап, ашатып, «Площадка»ны саклап чыкты.

Мин бик озак йокыга китә алмадым, иләмсез болыттан аерылган дәһшәтле ут күз алдымнан китмәде. Йоклагандай булам да куркып, кычкырып уянам. Ичмасам, янымда әни дә юк!

Шул көннән мин болыттан, яшен утыннан, күк күкрәвеннән курка башладым. Офык читендә каралҗым болыт куера башладымы, өйнең берәр почмагына кереп качам. Тик яшен камчысының агы шулкадәр көчле — кермәгән тишеге, үтә алмаган почмагы юк. Чоланда дәү агач сандыгыбыз бар — артына кереп посам — яшен чартлый-чартлый мине эзләп таба. Толыпка уралып мич арасына кереп утырам — колагымны ярырдай күк күкри. Ахырда әмәлен уйлап таптым. Олылар йоклый торган карават башына әни мендәр-ястыкларны өеп куя иде. Чак кына болыт кабарды исә, шул мамык тавын ишеп төшерәм дә ястык-мендәр астына кереп йомылам. Яңгыр килгәндә, ишек-тәрәзә тыгызлап ябыла, мич төннекләре томалана, өебез бәләкәй, бөркү, эссе. Ястык арасында мунча ләүкәсеннән мең яман, тын җитми, шабыр тиргә батам, манма су булам, ләкин курку барысын да җиңә.

«Курку — иң явыз көчләрнең берсе», — дип аңлата әти, мине батыраерга чакыра.

Бу курку хисеннән мин озак арындым, хәзер яшенне бар дип тә белмим, хәтәр давыллы сәгатьләрдә, каралҗым караңгы күк явызланып ут чыбыркысын болгаганда, Идел уртасында балык тотып утырганым бар. Әллә нинди яшен сәнәкләре күз алдымда болытлардан аерылып биектә яман сызылып барды — каушамадым. Курку, хатирә булып кына калганда, әллә ни зыянлы түгел икән үзе!

3

«Улыбыз үсә!» — диләр, әти белән әни куаналар. Күрше-күлән, килгән-киткән кунаклар да мине алларына бастырып мактыйлар. «Үскән, егет булган ич улыгыз!» — дип, әниләрнең сөенечен арттыралар. Бала-чаганы мактаган саен, сыйның мулрак, тәмлерәк эләккәнен хәзер генә аңлыйм — үзем дә өч бала атасы...

Үсү шулдыр инде: хәзер үзем генә дә көтү каршыларга барам, үткен күзле, корыч томшыклы тилгәннәрдән бәбкәләрне дә энем Алмаз белән бергә саклыйбыз. Сыер

абзарын тазартырга, ишегалдын себерергә, малларга печән салырга әти белән чыгабыз. Эш арасында әти янында уралу иң рәхәт чаклар булган...

Үсте дисәләр дә, бәләкәй шул әле мин! Үземнән ике яшькә генә олы Азат еш кына мине тәпәләп ала. Менә ул үскән ичмасам! Шкафның иң өске киштәсенә үрелә дә прәннекне чәлдерә, мин сорасам, муен тамырыма кундыра. Азат үскән, ичмасам, ул мәктәпкә йөри, ул — укучы, аның белән чамалап сөйләшергә кирәк. Олы малай булarak ул әти белән утын кисәргә чыга, пычкының бер башын ул тарта. Мин әти ярган утынны ышыкка, лапас астына ташыйм, ә энекәшем Алмаз җиз таска түбәләмә итеп йомычка җыя. Баграж авылын өч яктан урманнар ураган булса да, безнең әти әрәмшәрәм иткәнне өнәми.

Үскәнмендер дә шул: хәзер мин бик күпне беләм. Безнең бабай Сарманның иң ярлы «Ак ыштаннар мәхәлләсе»нең имамы булган. Әтинең Нурлыхода, Мәһиәнвәр, Әсма атлы апалары бар, Сарманда элегрәк телгә алган Мәхүбрахман абый яшәп ята. Элеккеге Мөхәммәдия шәкерте, зур укымышлы, зыялы кеше, скрипкачы, һәр яктан талант иясе. Бакчачы, җиләк-җимеш үстерү остасы. Агач утырту, күпер юллары төзәтү, табигатьнең кадерен белү безнең нәселдәге һәр кешегә хас. Нурлыхода түтинең ире Ризван мулланы күргәнем юк, ахрысы, ә аларның бердәнбер уллары Хәмзә исемле искиткеч чибәр, бөдрә чәчле, көр тавышлы егет безгә еш-еш кунакка килеп йөри. Без дә аларга баргалыйбыз. Әсма апаның Лена, Илтөзәр, Раҗия исемле балалары да безгә килеп чыга, безнең яшьлек чорында туганнар еш аралаша иде, бер-береңә хөрмәт, хәл-әхвәл белешү көндәлек гадәткә кергән, канга сеңгән иде. Безнең йортка иң еш килеп йөргән кеше әтинең тол апасы Мәһиәнвәр булгандыр. Без аны кыска гына «Әнвәр түти» дип атап йөрттек. Әнвәр түти, еш килү өстенә, бездә бик озак, икешәр, өчәр ай торып китә иде. Көзгә кереп бакча эшләре тәмамлангач, сугымнар суелгач, каз өмәләре үткәч килеп төшә дә язга кадәр кунак була. Үз гаиләсе булыр-булмас, кияүгә чыгып тиз үк аерылып кайткан бу апабыз әз генә йокычан, әз генә юбалгы, мунчага барса, дүрт-биш сәгатьсез чыкмый торган тәмлетамак карчык

иде. Каратут йөзен, шактый күләмле борынын гына калдырып, башын яулык белән урап куя торган бу апа гомере буе кара-көрән, озын итәкле күлмәк яратты, яулыкның да агын бәйләми иде шикелле. Бу ятимә карчык, олылардан аерым хөрмәт күрмәсә дә, безгә килергә ярата иде. Дөрес, аның өс-башын карыйлар, тамагы сыйлы, урыны түрдә, мәгәр олы кунак-мазар килгәндә аны табынга алмыйлар, бәлки, ул үзе шулай теләгәндер, әмма кеше барында, кече якка чыгып Әнвәр түти ашап утырганда, мин аны үтә нык кызгана идем. Шунысы да бар: күпме яшәсә дә, ул мәңгелек кунак, өй эшләренә катышмый, сирәк-мирәк идән себергәли иде, мендәр-юрганны кагарга көнгә алып чыга. Яше олы булса да, намаз укымый, мин аның дога укып, амин тотканын да хәтерләмим. Ул шушы дөньяда тарсынып, нәрсәдәндер кыенсынып яшәгәндер, ахрысы. Хак, зарланганын ишеткәнем дә булмады, җылаганын күрмәдем, йомылып, үз уйларына батып яшәүче бу сәер апага мин аерата нык тартыла идем.

Үзара дус идек без.

Менә олылар кайсы кая тарала. Киндер букчасын асып Азат мәктәпкә китә, Алмаз уенда. Без түти белән өйдә икәү калабыз. Кайчагында гына Алмаз да өйдә була. Урамга чыгар идең, карлы яңгыр коя, тәрәзәләр парланып томаланган, җил ян бакчадагы шомырт агачларының соңгы яфракларын талап улый. Шундый аулак чакларда Әнвәр түти капылт үзгәрә, аның хәсрәтле җыерчыклар белән каймаланган кап-кара күз тирәләре җанлана, нурлана, ул яулыгын маңгаена күтәребрәк куя, каратут маңгаена чал сибелгән кара чәчләре сибелеп чыга. Аның җанлануын, күңелле үзгәрүен күреп мин куанам, түтине ныграк сөендерәсем килә, өстәлне, урындыкларны күчереп өйне киңәйтәм, идәннән — сәкегә, сәкедән идәнгә сикереп, мәзәк ясарга тотынам. Авызборынымны мыймылдатам, телемне чыгарам, күзгене үчеклим, ишек катында мыштым гына утырган дәү галушларны киеп, лыпыр-лыпыр биегәндәй итәм. Берзаман галушлар очып ике якка барып төшәләр... Әнвәр түти тагын да җанланып минем маймыллануымны күзәтеп тора, ачуланмый, сукми, көлә, тәне җиңеләеп китә. Аның да

иңбашлары бер күтәрелә, бер төшә, йөзенә кызыллык чыга: ул, учын учка бәреп, такмак әйтергә тотына. Аның такмагы кыска, ике-өч сүздән генә тора, алай да минем йон оек кигән аякларым үзеннән-үзе сикергәли башлый, мин идән уртасына чыгып тыпыр-тыпыр биеп китәм. Түти, җай гына, бер көйгә генә: «Сездә кем бар киндер суга, сездә кем бар киндер суга?» — дип, бертуктаусыз кабатлый. Аның сүзгә зарыккан иреннәреннән тавыш һаман көчлерәк чыга, ни озак такмакласа да, мин арымыйм, аның шушы гади такмагы мине котырта, дәртләндерә, шашындыра. Мин тәмам онытылганмын, түтинең колагы тышта икән, менә ул тынып кала, яулыгын төшереп бәйли, маңгаен яшерә һәм тынын тигезләргә мич арасына кереп китә. Андагы үзгәрешне күреп мин телсез калам. Түтинең: «Кайттылар!» — дип пышылдавы гына мине игә китерә.

Әнвәр түти белән без корган театрны Алмаздан бүтән кеше күрмәгәндер дә, ул да, мин дә серне чыгармадык. Әллә күреп тә дәшмәделәрме?

Авыл өе бик бәләкәй булса да, элек аңа әллә ниләр сыя иде! Сыер бозауласа, бозавын күтәреп өйгә кертәләр, кышкы суыктан саклыйлар. Без малай чакта суыклар чыннан да суык була торган иде. Көздән, ноябрь башларында төшкән кар, язга кадәр шылт та итмичә, эремичә ята иде. Бозау артыннан сыер да өйгә килеп керә. Бозавын ялый, иркәли, куе угыз сөте белән аңа үсәргә көч бирә... Угыз коймагын без барыбыз да бик яратабыз. Коймак пешкән көн — елына бер килә торган бәйрәм. Ул көннең тагын бер бөек шатлыгы бар: мин, зур колхоз табагына тутырып, күршеләргә угыз коймагы ташыйм! Күршебез Ипис түти, коймак керткәч, миңа бер уч чикләвек, бер уч айбагыр бирә, бозау турында озаклап, бөртекләп сораша. «Маңгаенда кашкасы бармы? Бәкәле ак түгелме? Ни төсле?..» Үзең керткән күчтәнәч коймак белән чөгендер чәе эчә-эчә бозау турында сөйләү нинди рәхәт!.. Балачак рәхәтләре алар үзгә, аерата кадерле, аерата газиз...

Сыер өйгә кергәндә, мин, аның очлы мөгезләреннән куркып, мич арасына кереп качам. Әнвәр түти мине арттан кочаклый, мин, аның җылы тәненә тиеп, дөньямны

онытып тынычланам...

Аулак калган мизгелләрдә без кәмит күрсәтеп кенә яшәмибез, кайчагында Әнвәр түти боз каткан тәрәзә алдына килеп баса, ике кулы белән ике тәрәзәнең ике яңагынаябыша һәм тонык кына бер көйгә җырлагандай итә. Тавышы юк аның, тавык кырлавыннан аерылмый, ләкин сабый булганмын, тутамның — ятим-ялпының, бичара толның — бертуктаусыз мөнәҗәт укуын белә алмаганмын. Сүзләрен аңлап бетермәсәм дә, мин аның тәрәзә аша йотылып үз балачагына кайтканын, кемнедер сагынып, юксынып мөнәҗәтләр укуын үтә дә ярата идем. Андый чакларда түти түгел, мин сагаям, капка әз генә шыгырдады исә, «Кайттылар!» дип пышылдыйм... Уртак серебезнең дөньяга фаш булуын теләмим...

Менә безнең «гаилә» ишәя, исәя башлаган, мөгезләре төртеп чыккан наян бозау янына берәм-берәм сарык бәрәннәре кереп кушыла. Бәрәннәр тиз үсә: атна дигәндә өйгә алар хуҗа була! Җитмәгән җирләре, аудармаган нәрсәләре калмый. Иләк, чиләк, ипи табаклары һәр көн күчеп, күченеп йөриләр. Өй тарая, бозауны муенчаклап аралыктагы тимер боҗрага бәйләп куялар. Бәйләп куймый кара, бәрәннәргә ияреп алдын-артын сикертеп чаба башласа! Беркөн ычкынган да ашлы сулар җыя торган лаканны аударган. Әй әләкте Әнвәр түти белән миңа!

Бозау, бәрәннәр белән аулак өйдә калырга ярата Әнвәр түти. Ул аларны кочаклый, муеннарын кашый, чәйнәп ипи йомшагы каптыра, дымлы борыннарын үбә. Бәрәннәр аның саен наянланалар, кушаяклап сикерәләр, ишекле-түрле ду килеп чабалар. Муенчагын өзәрдәй булып аралыкта бозау сикерә, Әнвәр түти идән уртасына чыгып баса да, учларын шапы-шопы китереп, үзенең мәңгелек такмагын кабатлый: «Сездә кем бар киндер суга!..Сездә кем бар киндер суга!» Бәрәннәрнең нәни тояклары дер селкеткәннән бүрәнә арасыннан мүк коела, кыстырган җиреннән уклау атылып чыгып идәндә бии, кисәү агачлары, җәмки, самовар торбалары, ухватлар дер-дер селкенәләр. Андый чакта тик торып буламыни? Мин дә өйдәге хәрәкәткә кушылып китәм һәм Әнвәр түтигә ялгап такмак әйтә башлыйм... Юк, аның сүзләрен кабатламыйм, минем

үземнеке, үзем чыгарган такмак бар...

Чыгарган беренче такмагым — шигъри юлларым хәтердә калмаган, соңгы бер юлы гына исемдә... Әлбәттә, ул шушы бөдрә йонлы, тере күзле шук бәрәннәргә багышланган иде... «Идәндә шомырт коя» иде аның соңгы юлы... Баштагы юллары «Яфрак ярата бәрәннәр... тамаклары тиз туя... Тамак туйгач сикергәләп, идәнгә шомырт коя» булды шикелле...Ни гаҗәп, Әнвәр түти минем такмакка игътибар итте, «киндер сугучыны» онытып, миңа ияреп, мин чыгарган такмакка кучте, без икәүләп идәндә сикергәләдек, керәшенчә әйтсәк, уармак килдек, дәмәк ясадык.

Иртәгесен без тагын аулакта калдык, бүтәннәрнең аяк эзе тынгач, бозау, өч бәрән, Әнвәр түти һәм мин пәри туен башладык... Һәм Әнвәр түти кичә мин чыгарган такмакны кабатлый башлады... Бу хәл миңа көч бирде, дәрт өстәде... Шул көнне мин яңа такмак чыгардым. Анысы аралыкта моңаеп торган бозауга багышланган иде сыман...

4

Кар китте, сукмаклар төште. Мин хәзер урамнан кайтып кермим дә. Аскы урамда Кирушлар турында атау, җир иң әүвәл шунда ачыла. Җыелышып тәтәйле уйныйбыз, кузналы, акча чөябез. Кичләрен мөгәҗи амбары тирәсенә яшьләр җыела. Кайчагында яшьләр уены безнең турга — Әндриян дәдәйләрнең амбары алдына күчә. Имәнле урамыннан, гармунын күтәреп, Чыжык Бәчелие килә. Уйныйлар, җырлыйлар. Әтинең иске пинжәген иңемә салып, төренеп мин дә бер читтә басып торам. Яшьләр җырына кушылып иреннәрем кыймылдый, ни гаҗәп, берзаман мин яшьләр җырлаганның сүзләренә үз такмакларымны кушып җибәрәм.

Яз — бәйрәмнәр чоры. Беләм, озакламый Олы көн килеп җитәчәк. Олы көн — урысларның Пасха бәйрәме. Ул көнне Баграж — керәшен авылы гөр килеп торачак. Караңгылы-яктылыда бала-чагалар күкәй җыялар. Өйгә кергәч, тиз-тиз «Иусус Кристус терелеп торган» диләр. Йорттан йортка йөреп, минем дә манган күкәй җыясым килә. Тик мине әни чыгармый: «Без — татар, мөселманнар», — ди ул. Мин аңлап бетермәсәм дә, татар икәнлегемне, керәшеннәрдән аермамны сизә башладым. Су коенырга буа алдына төшсәк, малайлар миңа карап җыр-җыр көләләр, усалраклар:

Татар, татар — тарама,

Кермә безнең арага.

Кысылырсың, үләрсең —

Биш тиен акча түләрсең... —

дип, җыр әйтәләр.

Усал малайларның авызын томаларлык такмак чыгарасым килә, барып кына чыкмый, җавап итеп кайдадыр отып алган җырны кабатлыйм:

Керәшен, керәшен — керкәле,

Баш түбәсе серкәле.

Бәйрәм якынайганын шуннан сизәм, көн туды исә, Багражның кынҗыр кызлары әни янына күлмәк тектерергә киләләр. Бәйрәм якынлашканын бер сылу кызлар гына сизенәме?!

Югары очта Җәмәй атлы бер бик фәкыйрь кеше бар иде. Кышын тәмәке төрергә гәҗит каян алгандыр, һәр язда исә ул безгә килеп керә торган иде. Килә, болдыр баскычына утыра, дәшми — теле юк. Телсез Җәмәй дә диләр, кушаматы — Пружин. Озын чандыр гәүдә сорау билгеседәй бөгелгән. Очлы ияген өч-дүрт бөртек сакал ябышкан. Өстендә алагаем дәү якалы, терсәкләре ямаулы чикмән. Кырык ямаулы чалбар тишекләреннән тез башлары күренеп тора. Аягында киндерәләре ялганган дәү-дәү мыеклы чабаталар. Пычрак аягы белән өйгә керми, кат-кат чакырсаң да, ияген як-якка чайкый. Тәмәкегә гәҗит сорап килгән Җәмәйне безнең әни берчакта да ашатмыйча, тамагын туйдырмыйча җибәрми торган иде. Өйдә нинди ризык пешсә, тәлинкәгә салып Җәмәй дәдәйгә чыгара. Мин аның ашаганын карап торырга яратам. Озын җәпле бармаклары катып, калҗаеп беткән; тырнаклары — җиту. Алдына ризык килгәч, ул кинәт үзгәрә, гәүдәсе тураеп киткәндәй була. Ул ризыкның бер бөртеген, бер тамчысын исраф итмичә, кадерләп, олылап ашый. Ипи, дурычмак өлешен йоткач, башын артка ташлый, бугаз алмасы бүлтәеп чыга, ул керфексез яшел күзләрен йома, күз урынында вак җыерчыклардан хасил елмаю гына балкып кала.

Тәлинкә чыгарасыңмы, табакмы, табамы — ризыгы беткәч, ул һәрберсен ипи катысы белән ышкый-ышкый сөртә, майга манчылган икмәк катысын кәнфит суыргандай суыра... Кулына гәҗит эләккәч, тәмәкесен шартаякның тубырлы башы юанлыгы итеп төрә. Безнең өй тирәсендә кабызмый, әнинең тәмәке исен яратмавын белә, «тартмыйм, тартмыйм!» дигәндәй, тәмәкесен күз югарылыгына күтәреп күрсәтә.

Әниләр кая киткән булгандыр, беркөнне әбәдтән соң Җәмәй дәдәй килеп керде.

Әнвәр түти ишегалдында, кояш күзенә мендәрләрне тараткан, мин, җиз тасны аударып, астына баулы таяк кыстырып, тас астына җим сибеп, күгәрчен тотарга маташам. Күгәрчен белән мавыгып, Җәмәй дәдәйне онытып җибәргәнмен, берзаман карыйм, утыра да утыра теге, ыңы-шыңы юк, тез тишекләрен чикмән итәген кайтарып яшергән. Әнвәр түти тегеңә берни чыгармый. Мин аның янына йөгереп килдем. «Бетмәс монда әрәмтамак, хәерчеләр!» — ди тутам. «Ипи кыерчыгы алып чыгам!» — дип, өйгә керә башлаган идем, түти мине эләктереп алды. «Йөрмә!» Мондый кирелеген белми идем тутабызның, аптырап киттем. Җәмәй дәдәй утырды-утырды да бөгелеп, бөкерәеп чыгып китте. «Саран бака син, Әнвәр түти!» — дип кычкырганымны сизми дә калдым.

Хәерчеләр дигәннән, без бәләкәй чакларда хәерчеләр авылдан авылга ел әйләнәсенә йөриләр иде. Ни бирсәң дә алалар, иске-москы кием-салымны да алалар, ипи кыерчыгына да бөгелә-сыгыла рәхмәт әйтәләр. Сәер, җәенке арбаларына утырып дөя җиккән кыргызлар килеп чыга иде. Алар дөяләрен урам уртасында туктаталар, үзләре өй борынча кереп йөриләр, чыбыркы сабы белән муеннарын кашып: «Яндык, казалы булдык», — дип, күзләреннән кысып кына тонык тамчылар чыгаралар.

Керәшеннәр — үтә ярдәмчел, мәрхәмәтле кабилә. Кыргызларга ышаналар, жәллиләр, «бала-чагаң күпме?» дип белешәләр. Яртышар капчык бәрәңге, подаука төбенә салып он чыгаралар, ашарга да дәшеп кертәләр. Ә без, аю мае сөрткәннәр мени, дөя яныннан китмибез. Якын барырга базмыйбыз, дөянең усаллыгын беләбез. Лач итеп төкерергә дә күп алмый ул!..

Авылда тагын бер сәер хәл булды: тазарак тормышлы йорт хуҗаларын өйләреннән куып мунчаларга, таш амбарларга чыгардылар. Бездән ике-өч өй аркылы гына яшәгән Үтәми дәдәйләрне дә мунчага кудылар. Ишле балалы Үтәми дәдәйнең өен мәктәп иттеләр. Тиздән, бик тиздән Үтәми дәдәйнең улы — яшьтәшем Бәчели белән алар өендә беренче класста укый башларбыз дип кем уйлаган...

5

Без яшәгән йорт хуҗалары Багражга кайттылармы-юкмы — хәтеремдә калмаган.

Әндриян дәдәй хатыны, ике малае белән Федот детдомында озак кына яшәде шикелле. Кайтмый калмаганнардыр, алар үзара да, күрше-каршы белән дә тату, дус яшәрлек сабыр, акыллы кешеләр иде. Кайтып, безнең тигез генә аккан тормышка бер-бер бимаза ясасалар, ихтимал, хәтеремдә дә калыр иде. Явызлыкның ташка язылып, яхшылыкның комга язылуын аңлый башлаган идем инде мин. Әндриян дәдәй тәбәнәк, базык кеше иде. Бер кулының дүрт бармагы юк, кыска, кисек буынлы бармаклары белән аркамнан сөеп куркытканы исемдә. Бөдрә йомшак чәчле иде без торган йортның хуҗасы. Багражда һәркемнең нәселдән күчеп килгән кушаматы бар. Әндриян дәдәйләрнең күршесе — Боярлар. Ата-бабасы тимерче бу крестьяннарга ник Бояр кушаматы тагылгандыр, белмим. Авылның Югары очтан Түбән очка кадәр өйдән өйгә сикереп күчә торган кушаматлар әлифбасы бар, әйтик: «Әндриян бөдрә, Бояр ыштанын салып йөгерә...» Нәсел-нәсәбеңнән берәү авылга яки авыл кешеләренә яманлык кыла икән, беттең, кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмас! Берәр адәм хәтерли микән Югары Багражның кушаматлар әлифбасын? Ялкауларга, аңкауларга, җыбыткыларга, канчыкларга, биләмчеләргә, каруннарга нык эләгә иде ул җор тезмәләрдә!

Нигә Бояр кушаматы алган нәселне ыштан салдырып йөгерткәннәр? Белмим. Ул нәселдән авылда байтак гаилә бар иде, һәммәсе һөнәрманнар, яхшы, тырыш кешеләр.

Бояр Ибаны, яшьтәшем, исәнме син? Кайларга китеп югалдың?..

Әндриян дәдәйләргә кунакка барып кайту вакыйгасы онытылмаслык булып хәтердә сеңеп калды. Сөенечле дә, фаҗигале дә булды ул хәл.

«Барып кайтыйк булмаса бер, ничә тапкыр чакырдылар инде!» — дип, өйдә сөйләшенгән сүзләргә игътибар иттем: кунакка бару балачакның бәйрәме иде бит! Кунак дигәндә мин бик җәһәт идем. Яңа юллар, ят авыллар, яңа җирләр... Һәммә тараф серле, кызыклы. Ә мин сергә тартыла торган тере малай идем. Ниһаять, сүз, күчә-күчә, төп мәсьәләгә дә барып җитте. «Өйдә кемне калдырырга? Мал-туарга, йорт-җиргә кем күз-колак булыр?» Әнвәр түтине ашыгыч кына чакырып алдылар. Чакырган җиргә килми каламы безнең тәмлетамак тутабыз? Нәни төенчеген тотып, иплэп атлап, кичкырын килеп тә җитте. Мин, авызымны ерып: «Ә без Әндриян дәдәйләргә кунакка барабыз!» — дип кычкырдым. Әнвәр түтигә сыер савуны тапшырып булмый, сыер малы аны санга сукмый. Күршебездә үтә уңган, ишле балалы Ипис түтиләр яши. Олы эшләрне аңа тапшырып, вак-төяген Әнвәр түтигә йөкләп, ниһаять, без ерак юлга чыктык.

Федотка бездән ике юл бара икән, берсе — район үзәге Зәй аша, икенчесе аулак, урау юллар аша — Ашыт, Әхмәт, Кадер авылларын үтеп барырга кирәк. Имәнле урамын узып Түбән авылга төшеп барганда, әти белән әни әз генә тарткалашып алдылар. Әти: «Зәй аша барыйк, анда юл ышанычлы», — дигән иде, әни каршы төште: «Әллә кайдан уратып йөргәнче, турыдан гына чыгыйк», — ди. Әти: «Әйләнечтән юл туры, урман юлларын белмисеңмени?» — дип, үз сүзен куәтләде. Ата-аналар тарткалашканда быткыч балалар тик тора аламы? Азат, дилбегә тотып, кукраеп кузлага утырган. Борыны чөенке олы малай әти ягын куәтләде: «Зәй аша барабыз, Зәй аша!» Ә мин, әни малае: «Урман аша барыйк, урман аша!» — дип тыкырдатам. Әни алдына җайлап яткан энекәшем Алмаз юлга чыгуга тәмле йокыга талды. Түбән авылга төшкәнче бәхәс дәвам итте, ахыр чиктә ике як та йомшап уртак фикергә килделәр: Ашыт-Әхмәт авыллары аша барабыз да Зәй аша кайтабыз! Азат, миңа борылып, телен чыгарып күрсәтте. Нигә очынган була инде, икебезнең дә сүзе үтте ләбаса!

Без Түбән авыл урамына барып кердек. Күрше авыл кешеләре, әти-әнине танып,

түбәнчелек белән сәламлиләр, кая баруыбыз белән кызыксыналар, белгәч, безгә хәерле юл телиләр. Авыл кибете янынnan үткәндә әти атны туктатты һәм, вак-төяк булмасмы дип, кибеткә кереп китте. Ары-бире каранып утырганда, күзем бер адәмгә төште. Бер йорттан чыкты кеше, селлин-селлин атлап икенче капкага кереп югалды. Әз генә вакыттан соң чыкты, тагын күздән китеп торды. Җәмәй дәдәй! Өй борынча нишләп йөри икән Түбән авылда? Мин күргәнне әни дә күрә икән, сораулы карашымны абайлап: «Җәмәй дәдәң өй борынча хәер сораша, тамагын шулай туйдыра», — дип аңлатып бирде. Җәмәй дәдәйне кызганудан җылап җибәрдем. Мин аның ничек яшәвен, ничек тамак туйдыруын, кемнәр белән торуын моңарчы бөтенләй белмәгәнмен икән! Әни нидер аңлатты,ниләр сөйләгәне хәтеремдә калмаган, мин: «Җәмәй дәдәйгә ашарына бирик!» — дип, әнине йолыккалый башладым. Әни күчтәнәчкә төрелгән ризыклар арасыннан үзе пешергән шадра печеньене учы белән тутырып алды да миңа сузды: «Бар, улым, Җәмәй дәдәңә бир!» Тыгыз коймалы урыс капкадан чыгып килүче бичара телсез каршысына йөгердем, ташка абынып егылдым, печеньеләрне күкрәгемә кыскан идем, алар чәчелмәде, кулым буш булмаганга, борыным белән җиргә бәрелдем, канады. Канаса да еламадым.

Җәмәй дәдәй биленә таккан капчыгына печеньеләрне шудырды да дәү кулы белән аркамнан какты. Сирәк сакалын селкетеп рәхмәт укыды. Аның керфексез яшькелт күзләреннән күз яше кысылып чыкты...

Әни ап-ак кулъяулыгы белән минем тузанга, канга буялган борын тирәләрен рәтләп торганда, әти кибеттән чыкты, без сәфәребезне дәвам иттек. Авылны чыккач кына әни, миңа карап: «И улым, дөнья йөзендә бәхетсезлекләр бик күп шул әле», — диде. Әти белән әни үзара сөйләшеп бардылар, иген уңмаган елларны, мин аңламаган налогларны, кысуларны телгә алдылар. Җәмәй дәдәй белән очрашу аларга шулай тәэсир иттеме, әллә мондый күңелсез әңгәмәнең бүтән бер сәбәбе бар идеме? Без урманны чыктык, авыл араларын үттек, авылларга кердек, туктап ат эчерттек, әни коега су алырга килгән ят апалар белән тиз-тиз нидер сөйләште, әмма ата-анамның

йөзеннән моңсулык Федотка барып җиткәнче китмәде. Бу юлы әти-әни сөйләшкән сүзләр берәм-берәм минем күңелемә кереп ояладылар. Әниемнең: «И улым, дөнья йөзендә бәхетсезләр бик күп шул әле», — дигән сүзен мин гомерем буе онытмадым.

Бу сүзнең хак икәнлегенә тагын бер мәртәбә шунда, Федотта ук ышанырга туры килде.

Хуҗалар безне искиткеч җылы каршыладылар. Олыларга гына түгел, безгә, бот буе малайларга да сый-хөрмәтнең иге-чиге булмады. Пилмән дә пешерделәр, тавык та куырдылар. (Дөрес, тавык боты олы малай Азат белән төпчек малай Алмазга эләкте, мин муен кимереп калдым.) Әндриян дәдәйнең уллары Никипар белән Ибан безгә элек алпавыт утары булган детдом биналарын, таллар арасында җәелеп яткан тирән буаны күрсәтеп йөрделәр. Тоташ чия агачлары белән капланган бик биек тау башына менгәч, мин телсез калдым. Мондый киңлекләрне, ерак офыкларны, матурлыкны минем берчакта да күргәнем юк иде. Баграж тавына менгәнем бар, ләкин безнең авыл өч яктан урманнар белән әйләндерелеп алынган да, тау башыннан ерак офыкларны күреп булмый торган иде. Ә монда исә... бер-берсен кисешкән басу юллары, елга буе әрәмәләрен чәлмәштергән сукмаклары мине тәмам хәйран калдырды. Минем дә әнә шул, кышкы


АЯЗ
ГЫЙЛӘЖЕВ

карда куян эзе сыман чәлмәшкән сукмаклардан тагын әллә кайларга барасым, әллә нинди ят дөньялар белән танышасым килде...

Ничә көн кунак булганбыздыр, исемдә калмаган, кичләрнең берсендә өстәл тирәсендә олылар белән тәмләп бәрәңге дурычмагы белән чәй эчеп утыра идек, кече яктан дурычмак өйгән тәлинкә күтәреп чыгып килүче апа лып итеп урындыкка утырды. Кызганычка каршы, Әндриян дәдәй хатынының исемен онытканмын... Урындыкка утырды, тәлинкәсе идәнгә шапылдап төште, майлы дурычмаклар идәнгә тәгәрәде. Олылар: «Ни булды? Ни булды?» — дип, апа тирәсендә кылбырдак килделәр. «Башыма кемдер күсәк белән китереп сукты!» — диде апа, әз-мәз хәлен җыеп. Олылар дару эзләргә тотынды, мин тәмам аптырашта калдым. Нинди күсәк? Кем сукты? Өйдә бездән башка беркем дә юк лабаса? Уллары Никипар белән Ибан да өйдә юк. Алар Зәйдән килгән кунак абыйны буа койрыгындагы камышлыкка үрдәк атарга алып киткәннәр. Кичке чәйгә алар да кайтып җитәргә тиеш. Апабыз елапмы-елый, бәргәләнә генә, чыдый алмый. Әндриян дәдәй чакыруы буенча бераздан өйгә фельдшер килеп керде. Биргән даруларны эчмәде Әндриян дәдәйнең җәмәгате, гел бер сүзне кабатлады: «Бәла килде безгә, хәсрәт килде. Башыбызга кайгы төште!»

Эңгер-меңгер иңгәндә, кабык арбага салып Әндриян дәдәйнең кече улы Ибанның җансыз гәүдәсен алып кайттылар. Эш болай булган икән. Зәйдән килгән сунарчы камышлар селкенгәнен абайлаган да шул төшкә төбәп атып та җибәргән... Ядрәләре туп-туры Ибанның күкрәгенә килеп төшкән икән, йөрәгенә үтеп кергән. Ибан аһылдап кычкырган да шунда ук җан биргән... Шул секундта әнкәсенең башына күсәк белән органдай булган. Ана сизгерлегенә тиңнәр юк!

Әндриян дәдәй сап-сары нарат такталардан улына табут ясый... Нарат ылыслары белән, чәчәкләр белән бизәлгән караватта Ибан ята. Аның баш очында кара яулыгын


бәйләгән әнисе утыра. Ишегалдында ике кулын аермаска йозаклап, һавада селки-селки, бичара сунарчы, Әндриян дәдәйнең кардәше йөри. Өй тирәсендә йөзләгән детдом балалары җыелган. Бүтән чакта шукланырга, тәрткәләшергә һәвәс малайлар да бүген тып-тын торалар...

Мин дә шулар тирәсендә йөрим. Мин бүген фаҗиганең ни икәнен, ата-ана хәсрәтен беренче тапкыр үз күзләрем белән күрдем. Хәзер буа өстендәге тип-тигез су да, биек-биеккә менеп киткән таулар да, буа өстенә ишелеп торган агачлар да, алпавыт утары, ул яшәгән йорт болдырының түгәрәк, сырлы-сырлы бизәкле баганалары да күземә күренми. Болытлымы көн, кояшлымы — барыбер караңгы...

Ибанны ничек, кая күмүләре исемдә калмаган. Кайсы юлдан кайтканыбызны да белмим. Хәер, моның әһәмияте бар идемени хәзер? Әче күз яшьләренә төрелгән бу көн, нарат ылыслары арасында сузылган Ибанның балавыздай йөзе, Җәмәй дәдәйнең йорттан йортка кереп теләнеп йөрүе шушы җәемнең иң авыр хатирәләре булды шикелле.

Ибан үлгәч, Әндриян дәдәйләр Федот детдомында озак тормадылар, Багражга кайттылар. Без гаиләбез белән Урта урамның буш өенә күчтек. Аның хуҗалары кая киткән булгандыр, хәтерләмим, мәгәр аларны да бер-бер нужа, бәхетсезлек күчереп йөрткәндер дип уйлыйм. Кешеләрне урыннан урынга күчәргә мәҗбүр иткән тынгысыз заманга кереп баруыбыз хакында әти-әниләрнең кеше югында шыпырт кына сөйләшүләре истә калган...

Июль — август, 1991



Эзләремне эзләдем...

Укучыма бер эндәш

«Вакыт ага» дибез, һәм без аны, канга сеңгән гадәт буенча, аккан су кебегрәк күз алдына китерәбез. Асылда бу — ялгыш караш. Вакыт белән дөнья йөзендәге бер төшенчәне дә, хыяллардагы бер мизгелне дә янәшә куеп, чагыштырып булмый. Чөнки вакытның башы һәм азагы юк. Алай да... Әйдәгез, Вакытның мәгънәсен күнеккәнчә гадиләштерик тә, уйда, телдә кабул ителгәнчә, «Вакыт ага» дип килешик. Фикеребезне ачыкларга тырышып, «Вакыт безне ияртеп ага» дип билгелик. Асылда бу да ялгыш караш. Вакыт мәгълүм бер сызыкка кадәр генә адәм балаларын ияртеп ага! Кеше гомеренең кап уртасында Вакыт бер мизгелгә туктала! Сизгән кеше аны сизә, сизмәгәннәр — юк. Мин бу дәһшәтле халәтне кырык яшемдә кичердем. Унҗиденче гыйнварда бер кеше булып йокларга ятсам, унсигезендә мин бөтенләй бүтән кеше булып уяндым. Шул сәер тойгыларыма таянып, заманында «Урталыкта» дигән әсәр дә язган идем. «Урталыкта»ны язган дәвердә мин тойгыларымның һәммәсен дә аңлап вә аңлатып бетерә алмаганмын: кырык яшем тулган секундтан Вакыт мине ияртеп кире ага башлаган икән! Аның бу серле хасиятен алтмышым тулгач кына аңлый алдым мин.

Яшь чагында, гомернең беренче яртысында, Вакытны үткәрә алмыйча изаланасың. Вакытның үз кануннары, үз җае, үз тәртибе бар, ә син аны ашыктырырга телисең: анда еракта, серле офыклар артында, сине бәхет вә сәгадәт, татлы җәннәт көтеп зарыгадыр кебек. Кичне җиткерә алмыйсың, таңнарны көтеп аласың. Зарыгып язга, җәйгә чыгасың; ашыга-кабалана көзгә, кышка керәсең. Безнең бабайларның һәр сүзендә, һәр ишарәсендә шигъри вә тирән мәгънә ята. «Яз»га, «җәй»гә чыкканнар алар; «көз»гә, «кыш»ка кергәннәр. Көз, кыш авыр вакытка керү булса, яз, җәй Вакытның гүзәл чагына чыгу, авырлыктан, мәшәкатьләрдән котылу булып саналган...

Әйе, әнә шул серле сызыкны атлап чыгуга, Вакыт курьер поезды сыман ашыга

башлый. Гомернең икенче яртысы ни өчен тиз үтә? Чөнки гомер елгасы кирегә ага: хәзерге тормышыңның яңалыклары, вакыйгалар хәтерне авырайта алмыйлар. Гомер-нең икенче яртысындагы тормыш вакыйгалары, яңалыклар тиз-тиз әһәмиятләрен, ка-дерләрен югалталар. Чөнки син Вакыт елгасына чумып кирегә агасың... Кирегә, бер

А.Гыйләҗев — тоткын.

1954

тапкыр үткән Вакытыңа таба барасың. Гомеребезнең икенче яртысында күргән-таныш-кан кешеләрне без тиз онытабыз, укыган китапларның, караган киноларның тәэсир көче дә элгәргедәй булмый. Теләсәк-теләмәсәк тә, без үткәндәге Вакыт кануннарына буйсынып, үткән гомер белән яши башлыйбыз. Хәтерлисезме халык җырын:

Олы юлдан атлар уза,

Безгә кала тузаны.

Алда гомер бардыр барын,

Сагындыра узганы.

Татар җырлары — безнең милли фәлсәфәбез. Татарга уйларга, укырга, югары үр-ләргә мөмкинлек калмаганда, ул барлыгын, яшәешен, өмет-өметсезлеген җырларга салган, хыялларының иң мөкатдәсен җырга күчергән. Әле безнең үз җырларыбызга чынлап торып игътибар иткәнебез юк.

Кабатлап әйтәм, килә берзаман хәтергә балачак, үсмерчак еллары. Дөньяны куй-ган һәм мәшәкатьләр арасында чак кына онытылып торган ата-аналар, әби-бабалар хәтергә әйләнеп кайта, төшләргә дә гомернең беренче яртысы ешрак керә, гомердә булмаганны төшләреңне сөйлисе килеп тел кычыта... Чөнки син Вакыт елгасына ияреп кирегә агасың, үткәннәргә.

Гомеремнең яртысы дип мин кырык яшемне билгеләдем. Ходай ни язгандыр, кы-рык, алтмыш яшьләрдә Тәңре белән турыдан-туры мөнәсәбәткә кереп булмый... Якын дусларымнан берәү, коммунист, шул явыз тәгълиматка колларча табынган Ярулла дус-

тым, җитмешне узгач кына дөньяга икенче күз белән карый башлады. Ул — намуслы кеше, соңарып булса да рухи яңарыш кичерә, Вакытның кирегә акканын тоя башлады. Үткәндәге ялгышлар, ихтыярсыз кылган гөнаһлар искә төшә... Телисеңме, теләмисеңме, безнең буынга хәзер бер нәрсә ап-ачык: адәм улларын язмыш йөртә! Теге яки бу гамәлебез белән без: «Үзебез башкардык! Үзебез эшләдек! Үзебез җиңдек!» — дип масаерга яратсак та, бөтен ихтыярыбызны Язмышка тапшырып, шуның кануннарына буйсынып кына яшибез. Вакыт алдында без бик кечкенә, кылган гамәлләребез дә тырнак очы хәтле генә...

Бу язмаларымда мин аңлы рәвештә үткәннәремә кайтып барам. Теләгән кеше, әйдә, минем чанага утырсын. Бара-бара, бәлки, бер җырны җырларбыз!..

* * *

Утырып уйлар уйладым...

Татар җыры

Ничә еллар дәвамында күңелне көйләп, әзерләнеп, әледән-әле шушы төбәккә ыргылып, һаман суйлакланып, икеләнеп, ерак юлдан өркеп-куркып, юк сәбәпләрне калкан итеп яшәдем дә, ниһаять, кырык эшемне кырык тарафка чәчеп ташлап, тәвәккәлләдем — Карагандага барырга чыктым. Плацкарт вагонны «Мәскәү — Караганда» поездына Казанда тактылар. Сөйләшүләрдән колакка чалына — вагонда күпчелеге казанлылар яки Татарстан кешеләре, хәзерендә Караганда тирәсендә яшәүчеләр икән. Ләкин минем беркем белән дә аралашасым, белешәсем килми. Болар — башка буын вәкилләре, аңнары бүтән, болар мин барасы Караганданы белмиләр дә булыр, болар үз ихтыярларыннан, үзләре теләп туган-үскән җирләрен язмыш иркенә ташлап киткән кешеләр. Качаклар!.. Качак балалары... Әллә нинди дәлилләр табып, мең төрле җитди сәбәпләрне мисалга китереп аклансалар да, мин Идел-Йортны ташлап киткән татарларны аңламыйм. Гаеплемен: яратып бетермим мин аларны. Әйе, татарны кысканнар, изгәннәр, таптаганнар, мыскыллаганнар, куркытканнар, илдәге язмышларын каргап, нәсел-нәсәпләре белән төйнәлеп, авылы-авылы белән күчеп киткәннәр алар. Шул юл

белән дә татар таралган... Ләкин кемдер калган! Милләт язмышының бөтен авырлыгын күтәреп, иң каһәрле елларда да илдә яшәгән. Кайда гына юк татар башы?! Без җәфа чиккән Актаста да бар икән алар! Быел кыш мин, тамагыма балык сөяге кадалып, шифаханәгә кергәч, башына кәләпүш чәпәсә дә, иманын күптән җуйган бер татар белән аралашкаладык. Кызы белән киявеннән егылып уңган: Актаста яшиләр икән, без казый башлаган шахтада эшли кияү, бер кулы белән күмер, икенчесе белән акча көри, барып җиткән оҗмахның түренә! Анда аракының нindиен телисең, шундыен алырга була икән... Эштән кайтышлый да яртыны кәгә икән шахтер кияү! Аракы муллыгы белән җәмгыятьнең социаль хәлен билгели торган заманда шахтер кияүгә әллә ни сүз әйтәсе дә килми, мәгәр аның татар икәнен уйлагач, күңел болгана. Урамда исереп бер урыс ята икән, күргән-белгәннәр: «Әнә Василий ята», — дип үтәләр. Габдрахман яки Бикмөхәммәт ауный икән: «Әнә т а т а р ята!» — дип төртеп күрсәтәләр...
Быел Актас якларына барасымны белә идем, кичектерергә һич ярамый иде, алай да оҗмахлы кияүнең адресын сорамадым. Тәмуг газапларында интектергән Актасны оҗмах санаган татар миңа нигә? Кәләпүшле агай да миңа рәнҗемәсен — татар булсак та, без инде төрле-төрле кыйтга кешеләре.
Теке-теке барабыз, вагонның төрле почмагында татарча сөйләшенгән сүзләр аратирә колакка эленә. Телләрдә җөмһүрият, ил язмышы түгел, һаман бер балык башын чәйниләр: кем машина алган да, кем кызын бай кияүгә — сәүдә кешесенә урнаштырган. Кемне каптырганнар да, кемнедер ришвәт биреп ансат кына коткарганнар! Аны мактыйлар, ул милли каһарман — бүтәннәргә үрнәк! Туган якларыннан китеп баралар лабаса, юк, беркем тәрәзәгә ябырылмый, берәүнең дә күзендә аерылу газабы шәйләнми. Юк, юк, мин бу татарлар Карагандасына бармыйм, анда минем үз шәһәрем, үз калам...
Очраклы юлдашларым — татарлардан тиз үк ераклашам, каршымда җәелеп утырган симез, юантык хатынның баядан бирле нидер мырлавын аермачык ишетә алмыйм...
Миңа эндәшә икән, тиктомалдан татарны сүгә! Хатын Морки районыннан булып чык-

ты, Марий Эльдан, мари марҗасы. Мөзәкир Хәкимовның райондашы! Мин ул бәхетсез татар баласының фаҗигале үлеменә багышлап «Урамнар артында яшел болын» дигән роман язган идем. Шул төбәктән ник бер хат килсен! Үз-үзенә кул салган ундүрт яшьлек үсмернең әтисе дә, күпсанлы туганнары да тел ящерделәр, дәшмәделәр. Әллә шушы явыз бәндәләр андагы татарларның авызын тегеп бетергәннәрме?!
Дәшмим, ә хатын тетә генә татарларны!
Имеш, алар ягында бер совхозда директор булып татар эшли икән. Череп баеган кысык күз татар! Волгоградта өчәр бүлмәле ике квартир тота, Кырымда, Кара диңгез ярында шәхси дача җиткергән, совхоздагы йорт-җирен әйтәсе дә юк, борылып чыгармын димә...
...имеш, дебил татарлар, мотальщиклар, белер-белмәс урысчалары белән Мәскәүгә таларга баралар икән дә: «Мое хочет хараша жить!» — дип, наганнарын чыгаралар икән.
...Бауман урамында урысларны атлы милиция саклый икән...
...шул татарлар үзенә республика сорап яткан була бит әле... Ни эшләргә телиләр диген!
...ул татарларның пычраклыгы! Шакшылыгы! Әле менә почмакта бер хатын пирожки сатып тора. Ун ел битен юмаган диярсең. Ей богу!
Нәкыя ерак юлга озата төшкән иде, безнең татарча сөйләшкәнне мари хатыны ишетеп торды, аның алдында да үз телебездә сөйләшү аңа ошамадымы? Зарланды, сүкте татарны юлдашым. Инде түзмәде, миңа карап: «Йә, менә сез... татарга дәүләт белән идарә итү хокукын бирергә кирәк дип саныйсызмы?» — дип сорады. Мин шакшы телле бу хатын белән бәхәскә кермәдем: әле юлда ике тәүлек чамасы барасы бар, хәзердән чәкәләшә башласаң, кая керер тишегеңне тапмассың! Беркатлы төс алып: «Мин ул тарафлардан ерак йөрим», — дигән булдым да телемне тешләдем. Һәм шушы җүләр юл буе, шар-шар килеп, татар халкын тоташ сүгеп, хәкарәтләп милли мәсьәләне хәл итеп барды. Бара-тора аңлашылды: мари хатыны урыста кияүдә икән, педа-

гог, Карагандадан ары Шахтинск шәһәрендә яшәп ята икән. Татар каршысында авызлыксыз котырынган педагог үз төбәгенә, үз ишләре, теләктәшләре арасына кайтып кергәч ни сөйләмәс? Татарның абруен әнә шулай югары күтәрә торган эмиссарлар бер ул гынамы? Меңнәр алар, ун меңнәр...

Тимер юлдагы яман хәлләрне, талау-үтерешләрне көндәлек матбугаттан укып-ишетеп торганга, ялгызым сәфәр чыгарга шүрләбрәк йөри идем, вагонга кергәч тә һәр күләгә өрәк, һәр күз карашы атылган ук булып күренде. Бара-бара тынычландым, тамбур ишеге ачылган саен бөркелеп кергән Рәсәй исенә күнектем сыман. Бәдрәфтә, гадәттәгечә, су юк, ис кенә мул... Барабыз. Туктыйбыз. Тагын шыгырдап кузгалабыз. Мари хатыны, татарларны онытып, өстәге сәкегә сузылган купшы кызы белән сүзләшә, аңа «тирән» акыл бирә. Караганда пединститутының икенче курсын бетергән булачак педагог та бу сәфәрдән татарларның кемлеген шәп итеп өйрәнеп кайта инде!..

1950 елның азагында шушы маршрут белән куганнар икән инде. Әгерҗе, Сарапул... Нократ, Чулман иделләре. Әле күңел уянмады, җаным җирсеми, кунакка баргандай битараф һәм ялкау хәлдә үзебез урталай ярып барган тирә-якны салкын гына күзәтәм. Тәрәзә пыяласы тонык: астан өскә мәңгегә юылмаслык тузан касмакланып каткан, көн явымлы, сүрән, болытлар, соры урманнарга тия-тия, бер-берсен изеп-таптап агалар...

Әле сәфәремнең максаты үзем өчен аермачык түгел. Җан тартканга буйсынып юлга чыккан мәлем, алданиләр булыр, ни булып бетәр, әле аларын уйламыйм да кебек, «башны салларга салып» үткәннәргә агып барам. Ургылып караңгы төште. Каралган борыннарын пычрак ояларыннан сузган лампочкалар яктылык китермәделәр; тирә-якка һәм тынычлыгын җуя барган күңелгә шомлы караңгылык кына өстәделәр... Теке-теке килгән тавыш аһәңендә боргалана торгач, мин дә йокымсырадым...

Иртән Уралны, Свердловскины үттек... Свердловск төрмәсенең биек-биек читлекләре хәтеремдә... Кайчан да исә бер бу хакта язасы булыр әле. Свердловск хатирәләре, очрашулар... Бу шәһәрне урыс журналистлары Екатеринбург дип атап йөртә баш-

ладылар. Алда ызгыш-талашлар булыр әле, булмый калмас, исемнәрнең чатнар көннәре алда әле. Канлы исемнәрне иңнәрендә күтәреп торган шәһәрләр берзаман уянырлар... Кая карама пычрак сыпкылы юллар, ташландык ихаталар, җимерек күперләр, хәрабәгә әйләнгән кирпеч биналар, тагын әллә ниләр, исраф булып, әллә кайларда ауный. Бер файдасызга җирнең татлы канын суырып утыручы кәкрешкә америка чаганнары күзгә чалынып үтә...
«Курганга җитәбез!» — дип, кемнәрдер кыбырсый башлады. Мин шушы як кияве Нур Әхмәдиевнең сөйләгәннәрен исемә төшердем. «Андамы? Анда үрдәкләр, «мине ат та мине ат!» дип, мылтык көпшәсе алдына чиратка басалар. Ә балыклар көймәгә үзләре сикерә. Көймәне батырмасалар ярар иде дип, эрерәкләрен кире суга тибеп төшерәсең. Кияү анда падишаһ белән бер! Иртәнге чәйгә кунакка дәшәләр — биш тавык, ун үрдәк суялар, көндезге ашауга бүлтерек тәкә чалалар, ә кичке бәлешкә тач май сарыкны багышлыйлар... Бай яклар! Таң туса, өйдән өйгә йөртәләр, җаның ни тели — шуны әзерлиләр. Анда барып төпләнгән татар Татарстанның кар-бураннарына, көзге-язгы пычракларына кире әйләнеп кайтмый инде», — дип таң калып сөйләгән иде. Салып утырган мәл булгандыр, табын уртасына шешә чыгарып бастыргач, татарның теле чишелә, мактанырга яратабыз. Аннары ун-егерме елга бер кайтып күренгән шагыйрь кияүне сыйлау чутмыни ул Курган татарларына?!
Томанлы кара тәрәзәләр аша көннең сытык чыраена карап, Нурның Мюнхгаузен булып шыттырган әкиятләрен уйлап, шикләнеп барам. Кемдер сөйләгән иде, Ташкенттан туганнары кайткан икән дә, шунда кардәш бер ханым хуҗаларның сөремле, пычрак, карлы-бозлы кысан балконнарына чыгып баскан да: «Юк инде... Аяк-кулга богау салсалар да, монда кайтасым юк», — дигән. И, дөнья киң, татарның ниндие, нинди киемгә төренгәне, нинди чит иманнарга баш биргәне юк хәзерге заманда?!
Күл буе каеннарыдай бер буйда үсеп утырган каен чаукалыгын үттек. Каеннар тапсыз, тоташ буйдан-буйга ап-ак. Сергей Бондарчук «Сугыш вә дөнья» кинофильмын төшергәндә, тээссорат көчлерәк булсын өчен, каен урманын акшарлап чыктык», —

дип язган иде. Әллә шул акшарлы каеннар калганмы монда? Бездә, Татарстанда, каеннар карала бара, озак та үтмәс без «кара каеннар» дип җырлый башларбыз. «Мә ал мине!» дигән сыман җәелеп, тәбәшәк ак ярлы юаш күлләр җәйрәп ята. Ярсыз күлләр күңелдә кызганыч тойгылар уята, дулкыннары чарпалышып йөрәккә кагылып тормагач, корысын күлләре! Акшарланган сәхнә каеннары бетте дигәндә чираттагы чаукалыкка барып кердек. Каеннар ап-ак килеш корыганнар, очлары, югары баш ботаклары шартлап сынган, шөкәтсез урман-хәрабәләр безне шактый озак озата барды. «Калыгыз инде, арыгансыздыр, җитәр!» — дип инәләм, юк, баралар да баралар. Конвой солдатлары кебек һич арттан калмыйлар! Күпме ил үттек, бихисап соры чакрымнар артта калды, чәчелгән җирләр, печәнле болыннар юк дәрәҗәсендә. Бер файдасызга буш ята торган бу иңкүлекләрне имгә китереп, ни булса да файдалы үсемлекләр үстереп булмый микәнни? Мәскәү белән Казан арасы искә төште. Урысның төп биләмәләренә барып кергәч, тәртә буе һәм юанлыгы гына калкына алган нәп-нәзек наратларны, кәкре, гарип каеннарны күргәч, күңел тарихка борылып кайта. Урыслар — искиткеч сугышчан халык. Сугыш осталыгына урысларны җирле шартлар, мөмкинлекләр ирештергән. Чәчкән игене урысның тамагын туйдырырга җитмәгән.

«В старину, когда на нашем континенте не было еще картофеля, русская деревня кормилась капустой и репой. Скороспелую, стойкую к холодам репу сеяли древние новгородцы. Вдоль городских стен тянулись репища, участки, на которых росла репа. В неурожайные годы, когда рожь вымерзала, выносливая репа заменяла Господину великому Новгороду хлеб».

«Среди старинных городов-огородников был и красавец Суздаль. Суздальцы копали грядки в речной долине. На иловатой земле вырастали огромные кусты хрена. Суздальский хрен был сочным и острым, как говорят, «злым». Да, хрен злой... но богат витаминами С, залечивает цингу. Его фитонциды, убивая бактерии, охраняют человека от болезней» («Неделя» атналык газетасыннан).

Урыс гаскәре шалкан һәм керән ашап кына гайрәт туплый алмаган, әлбәттә. Пеш-

кән шалканны бездә «усрак ашы» дип атап йөртәләр. Керән ашарга да теш арасына симез ит кыстырырга кирәк. Суздаль чиркәүләрен бизәр өчен шалкан-керән сатып кына алтын табылмаган, әлбәттә. Үз җирендә торфтан башка казылма байлыгы булмаган, нефть, ташкүмер чыкмаган сугышчан урыс милләте, дөньяның әле көнчыгышына, әле көнбатышына яу чабып, үзенең экономикасын рәтләгән, тамак туйдырырлык рәт тапкан... Менә мин утыз ел дәвамында тоташтан Мәскәү юлын таптыйм, күпме җирләрне чүпләгән шушы кәрлә урманнарга, файдасыз күксеп яткан сазлыкларга карап йөрәк әрни. Төзелешкә яраклы агач та үсми, утынга кисәрлеге дә юк, чалыш-чолыш кәкрәеп утыралар да тәртә буе калкынгач авып, дөнья сасытып яталар... Шанлы-шәүкәтле башкалабызның борын астында шундый хуҗасызлык яшәгәндә, бу якларга акыллы хуҗалар берәр заман килер микән?!
Уйдык-уйдык, тимерьюлчылар утырткан дөньядагы иң файдасыз агач — америка чаганнары чайкалып утыра. Илнең кайсы юлы белән барсаң да, тимерьюлчыларның яратканы шушы чаганнарга тап буласың. Валлаһи, дуңгыз күзе букка төшә — рас сүз! Орлыгын көз-кыш кына түгел, язын да мул тарата торган, күрер күзгә ямьсез, әрсез бу чүп-агачлар берзаман урманнар арасына да барып керер кебек. Дөньяда америка чаганы белән эт эчәгесеннән дә әрсезрәк үсемлек вә агач бармы икән?!
Күземне тәрәзәдән алып вагон эченә карагач, имәнеп киттем. Күптән түгел генә телевизордан Шри-Ланкадагы канлы бер вакыйганы күрсәткәннәр иде. «Тамил илама» сугыш чукмарлары намаз вакытында бер мәчеткә басып керәләр дә Аллаһы Тәгаләгә йөз тоткан гаепсез диндарларны кырып салалар. Шәһитләрнең акка төрелгән йөзләгән мәетләрен күргәч кан калтыраган иде. Эссе, тынчу, сасы вагонда ак җәймәләргә уралган юлдашларым шуларга охшап китте. Шөкер, ипләп-ипләп халкыбызга дин кайта. Дин, иман, тәртип, гореф-гадәтләр сакчысы булып, милләткә хезмәт итәчәк.
Дин — иң көчле коралларның берсе. Ләкин дин, җирдәге һәрбер корал кебек үк, явызлык ягына да борыла ала. Җирдәге явызлыклар бик күп очракта дин исеменнән эшләнә. Шундый бәла-казалардан Ходай үзе сакласын. Без христианнар, иудейлар белән

янәшә яшибез, алда, Европадагы кебек, чик баганалары кимегәч, буддистлар, индуслар арасына да җиңел барып йөрербез, татарда бүтән диннәргә тирән хөрмәт хисен бүгеннән тәрбияләргә кирәк. Дин аша ясалган яра — иң авыр яра, чөнки ул һәр очракта тәнгә генә түгел, йөрәккә дә барып тия.

Йокым өзә-тотә булса да, мин берөзлексез төш күрдем. Төш — аңның кирәге калмаган хатирәләрдән, ыбыр-чыбыр истәлекләрдән, җанны авырайткан тәэсирләрдән арынуы ул. Әгәр төш аша бушанмаса, адәм баласының мие тыгызлыкка чыдый алмас иде, һәркем билгеле бер чикне үткәч, мие түнеп дөнья куяр иде. Төш — Алланың адәм улларына биргән мәрхәмәте, шәфкате ул, без кирәге калмаган хәтер шлагыннан төш ярдәмендә арынабыз, алдагы яшәү хәрәкәте өчен баш миебездә сау күзәнәкләр әзерли торабыз. Лагерьдан кайткач, бик озак елларга кадәр төшләремә төрмә кереп интектерде. Әле дә, торымнан торымга үземне явыз конвой куган җәберләнгән кол хәлендә күреп, куркып уянам, аңга килә алмыйча озак вакытлар калтырап ятам. Нигә мин, юлда килгәндә, гел-гел тирә-ягыма йотылып, Нур Әхмәдиев, бүтәннәр сөйләгәннәрне хәтеремә алып, алда мине көткән җир турында өзмәс уйламадым икән? Юанырга теләдемме, онытылырга гына тырыштыммы?.. Белмим. Күңелем иләс-миләс булгандыр шикелле...

Таң атканда, без Караганда тирәсенә барып кердек. Сулдан, ниһаять, күңелләрне айкалдырып, нидер әйтергә җыенгандай, нәкъ минем күзгә карап кояш калыкты. Яңа иртә, яңа көн, кояш та яңа. Инде як-ягымда Караганда җирләре. Тигезлек, ми төбе сыман яссылыкларны үтеп, юаш кына сузылган калкулыклар арасыннан дөбердәп барабыз. Гел машинада яки усал конвой сагы астында җәяү йөреп, лагерьда чакта офык юк кебек иде. Алай да Актастан Волынкага этап булып җәяү барганда, эшкә йөргән мәлләрдә бу як даласының котсыз тигезлеген, бертөрлелеген, ярлылыгын чамалый идем.

Сизәм, кояш мине танып алды, чөнки бу мизгелдә күз чокырымда мең вә миллион тоткыннарның моңы куерган, ул бу каһәрләнгән изге җирне минем өчен махсус як-

тырта, теләктәш җил күзләремә күләгә төшмәсен өчен җиңел болытларны куып тарата. «Күр! Кара! Хәтереңне яңарт! Ела! Куан!» дигән сыман, көн ачылганнан-ачылды, мин соры касмак-корым сыланган, юл буе миңа дошманлык кылып, дөнья чынлыгын яшерергә маташкан тәрәзәгә сеңдем, йөрәк сикерә, атлыга, күз карашым вагон тәрәзәсе сыйдырган тар манзарадан әллә ниләр эзли. Җаным үксеп-үксеп еларга тотынды, күкрәк вагон-калтырчаны уздырып дөпелди. Мине бәхетле һәм бәхетсез иткән бу җирләр! Саумы, Актас! Саумы, таш базлары! Саумы, Федоровка, Михайловка! Гаҗәеп моңлы, айлы сихри төне белән мине язучы ясаган Майкудук, саумы! Салкын зыкы суыкларда, ярты төндә, баш очымда Җидегән йолдыз чиксез зур сорау билгесе булып янганда, усал этләр өрдереп мине йотып алган Карабас, саумы! Таныйсызмы мине?..

Гаҗәп нәрсә бит ул кешенең табигате! «Үзем җәфа чиккән лагерьларны эзләп табып, күреп кайтам бер!» дип, кайчаннан әзерләндем, көне килеп җитә дигәндә, күңелдә икеләнү: барыргамы? Җүләрлек түгелме бу? Ни эзлисең син аннан? Ни табармын дип өметләнәсең?.. Икеләнүнең сәбәбе шул булгандыр дип уйлыйм. Җәһәннәмнән бер котылып чыккач, анда кичергәннәрне тулаем берәүгә дә сөйләмисең, үзеңне көчләп-көчләп андагы җәфаларны онытырга тырышасың. Бу теләк шулкадәр көчле була ки, лагерьда шундый дус күргән иптәшләреңне дә күңел дәфтәреңнән сызып ташлыйсың. Ул хатирәләргә кайтасы да, хатирәләрне яңартырлык адәми затлар белән очрашасы да килми. Мин котылып чыккач, күпчелек иптәшләр әле анда, тәмуг базларында калды. Украин егете, иң якын дустым Иван Семенович Велягурский белән кыска гына ара язышкаладык та... Велягурский лагерьда чакта хатлар язды, котылып чыккач — тынды, югалды. Кырым татары Эскандер Даирскийның туган-тумачалары Казанның Киров районында яшиләр иде дип беләм. Эскандер Липецк шәһәреннән Казанга килеп тә киткән, шалтыраткан, без өйдә булмаганбыз... Ныклап күрешим дисә, җаен таба алмас идемени?.. Ике елдан артык бергә ашаган-эчкән Берлин егете Гейнц Бем белән илле бишнең җәендә аерылыштык. Соңгы ике хатын ул миңа Решеты шәһәре янында-

гы тайгадан, чит ил кешеләре өчен оештырылган лагерьдан язды. «Күп лагерьлардан чит ил кешеләрен монда җыйдылар. Француз, чех, болгар, поляк, фин һәм иранлыларны азат итеп илләренә озаттылар. Алар Мәскәүгә кадәр поезд белән үз ирекләрендә барачаклар. Без дә азатлык көтеп ятабыз!» — дип, миңа хатлар язган Гейнц та югалды. Германиядән хатлар язмады... Адреслар да алышкан идек югыйсә, мин дә эзләмәдем, алар да язмадылар. Таралыштык...

«Барам», — дигәч, язучылар арасыннан бер кеше генә өзеп сорау бирде: «Ни эзлисең син анда барып?» — диде Рафаэль Мостафин. Мин өч кешенең исемен атадым: «Япониядә яшәгән, шунда җиде классны татарча бетергән Абдулла Али-казының язмышын белеп булмасмы. Лагерьда күп яктан күземне ачкан урыс Мерзленков Александр Васильевичның, Мукачеводан төрмәгә эләккән Ростислав Иванович Илечконың формуляр-делоларын гына булса да бирмәсләрме... Чынлыкта кемнәр иде икән алар?» — дидем. Рафаэль күпне өйрәнгән егет, мондый киңәшен бирде: «Син, Караганда КГБсына барып кергәнче, мондагы иптәшләрдән, КГБ хезмәткәрләреннән үтен, алар шалтыратып куйсыннар, сиңа ярдәм итүне үтенсеннәр. Югыйсә урамнан килеп кергән кешегә алар лагерь документларын берчакта да күрсәтмәсләр!» — диде. Ахирәт дустым, каләмдәшем, фикердәшем Алексей Литвин инде байтак еллардан ЧК архивында эшләгән кеше — минем үтенечемне КГБ хезмәткәрләренә җиткергәч, алар, Карагандага шалтыратып, киләсемне хәбәр итеп куйдылар...

Вокзалдан шәһәр үзәгенә автобус белән бардым. Дәүләт куркынычсызлыгы идарәсенә кагылдым. 19 август, якшәмбе көн. Тар гына тәрәзәчектән кизү офицер чак кына эзләнде дә кайтыр билетымны тоттырды, кунакханәнең исемен атады һәм бер телефон бирде. «Кирәк булсак, шалтыратырсың», — диде. «Казакъстан» кунакханәсенә урнаштым, казакъча «Кунак өе» икән. Матур. Эшне бүлмәдәге чебеннәрне кырудан башладым. Казакъстан чебеннәренең җанын кыйдым бер! Ике төн тинтерәгән башны мендәргә салып озак кына ятсам да йокы алмады, әз-мәз тамак ялгагач, шәһәр белән танышырга чыгып киттем. Ары-бире каранып, ятсынып кына Ленин проспектын ура-

дым. Горняклар сарае түбәсенә менеп тезелгән таш сыннарга карап озак кына уйландым. Шәһәр казакъ җирендә утыра. Заманча төссез, иясез, милләтсез һәм шыксыз кала икән Караганда! Казакълык сизелми дә дияр идең, бик нык акшарланган, чамасыз бизәнгән, үз төсен җуярлык дәрәҗәдә ясанган казакъ хатын-кызлар еш очрый, арада егылып китәрлек чибәрләр дә бар. Күпчелек затлы киемнәрдән, кыяфәтләре — байларча тук, текә. Бара-бара тимер юл вокзалына төшеп җиткәнмен. Актас лагерыннан безнекеләр килеп салган иде бу вокзалны! Ишелеп, бүселеп төрле тарафтан килеп чыккан пассажирлар беләләр микән моны?.. Вокзал алды мәйданында уймак, кәрт ярдәмендә акча җыючы шарлатаннар мыж, аларны уннарча ачыгавыз тамаша итә. Хәерчеләр күп. Урам аша салынган җир асты улакларында да алар күпләп утыра. Берсе шакшы куллары белән сәләмәгә төрелгән баласын кочаклаган да казакъча җырлый. Акчаны мул сибәләр, көмеш ява гына, мин дә салдым: сәфәрем исән-аман тәмамлансын, өйдәгеләр сау торсын!

Кунакханәгә каршы диярлек, чапырышта, Ленинга кызыл гранит яркалардан һәйкәл бастырганнар. Якынрак баргач күрәм, юлбашчының такыр башына ике яклап күгәрчен кунган, эңгер-меңгердә Ленинга мөгез чыккан кебек. «Казакъ та өлешсез калмасын!» дигән сыман, Горняк сарае каршысына, урам аша, ике шахтерга аннан-моннан таслап дәү, иләмсез һәйкәл бастырып куйганнар. Шахтерлар кочаклашкан, милләтләр дуслыгын ныгытучы бу монументтагы икенче шахтерны теләсә кем дип уйла... Ленин да тупас, шыксыз. Бернард Шоу авызыннан, дип, газеталарның берсе мондый сүзне әйттергән иде: «Антикоммунизм — величайшая глупость XX века». Кайбер чыганаклар мондый «акыллы» сүзне Томас Манн әйткән дип баралар. Ай-һай, акыллы һәм тапкыр Бернард Шоу әйтте микән мондый ахмаклыкны? XX гасырдагы сәяси системаларның төбен-тамырын аңлаган, «Майор Барбара» пьесасында корал ясау короле Андершафт исеменнән дөньяның әче хакыйкатен әйтеп калдырган Шоу андый тупас хата җибәрер микән? Муаммар Кадафи, Фидель Кастро, Саддам Хөсәен кебек канечкеч диктаторлар Ленинның «Дәүләт һәм революция» китабын кулдан төшермиләр икән.

Әтәч диктатор Даниэль Ортега ишеләргә көчле корал калдырды Ленин. Ленинның теоретик кораллары җитмәгән очракта, Россия, үз гражданнарының авызыннан өзеп, дөньяның бөтен почмакларына корал озата тора. Бушлай, дусларча бүләк итеп озата. Бик күп афәтләр, канлы бәрелешләр Россия коралы ярдәмендә тормышка ашырыла. Ленин тәгълиматын без өзек-өзек кенә, үзебезгә кирәк кадәр генә ятлыйбыз. Берчакта да тирәнгә кереп, аның яман асылын аңларга тырышмыйбыз. Илдә әхлак бозылды, иман тапталды. Явызлык өскә чыкты. Караклык, әләк-чәләк, коррупция, ришвәт чәчәк аткан икән — болар һәммәсе дә Ленин тәгълиматының җимешләре! Ленинның «Яшьләр союзының бурычлары» дигән әсәрен илдә кем генә белми икән? «Укырга! Укырга! Укырга!» дигән чакыру шушы китаптан. Һәм бу сүзләр бөтен почмаклардан безгә чекерәеп карап торалар. Ә әсәрнең асылын тәшкил иткән «Мы отвергаем нравственность и мораль как понятия буржуазные, как инструмент, который был нужен ей для подавления рабочего класса!» дигән дәһшәтле чакыруга безнең зиһен җитми. Сталинны сүгәбез, каргыйбыз; ул исә үзенең укытучысының теоретик фикерләрен тормышка ашыручы гына булган.

...Соңгы чирек гасырда тоталитар режимның иң ышанычлы коллары укытучылар булды. Алар арасында якты кешеләр әз калды. Күпчелек надан, югарыдан ни әйтсәләр, шуны такылдаучы саесканнарга әйләнде. Әйе, Ленин белән Маяковский наданнар өчен цитаталар коесы алар, әз генә иеләсең дә чумырып кына чыгарасың! Берчакта да тормышка ашмаслык зарарлы цитаталар аларда тулып ята. Дөньяның һәр мизгеленә, фикернең һәр бозык адымына Ленин, Маяковскийдан таяныч таба аласың. Шулар ярдәмендә дөнья тарихы бозылды, адәм улларының табигый үсеш законнары актарылып ташланды. XX гасыр — гарип диктаторлар, шизофрениклар заманы, канечкеч власть сөючеләр заманы. А.И.Солженицын «Архипелаг ГУЛАГ» исемле атаклы әсәрендә, мәкаләләрендә бу хакыйкатькә мисалларны бик күп китерә. Антонов-Овсеенко «Тиран портреты» дигән мәшһүр китабында «Сталинга юлны Ленин ачты» дип язды. Урыс

рәссамы Илья Глазунов «Ленин — величайший злодей XX века» дигән фикерен халыкка җиткерде.

Мөгезле Ленин яныннан кырын-кырын карап, шыпырт кына үтеп киттем. Алла саклasын, җиргә яңа тиран килмәс дип кем әйтә ала? Алда киләчәк һәр тиран, һичшиксез, уң кулын Ленин китапларына куеп сөяләчәк. Фәрештәләр җиргә сирәк иңсә, тираннар ал байраклар тотып җәһәннәмнән, җир үзәгеннән чыга торалар. Шуңа күрә адәм улларының тереләре күккә карап хыялланырга, юанырга гадәтләнгәннәр. Адәмнәрнең Җиргә ерак берәр планетадан китерелүләренә хәзер һичкем шикләнмидер дип уйлыйм. Адәмнең беренчел формалары, әлбәттә, космос киңлекләрендә яралган. Шуңа күрә хыялланганда, без борыныбыз белән җиргә кадалмыйбыз, тезләнеп күккә багабыз, тирән сагыш белән адәм җанының чишмәсе типкән күккә баш орабыз. Ниһаять, безне Җиргә күчергән кодрәт ияләре бер әйләнеп кайтырга тиеш ләбаса? Җир улларыннан хак, гадел җәмгыять төзү барып чыкмады, адәмнәр кулыннан шәфкать, мәрхәмәт китте. Кешелектән аны Маркс-Ленин тәгълиматы тартып алды. Шушы тәгълиматка таянып Җирдә тираннар туа торды. Аларны авызлыклар көч бүгенге Җир кешеләрендә юк.

Без көчле рух иясе Рейганның безнең илне «явызлык империясе» дип атавына үпкәләгән булып кыланабыз, «ай-һай, яла яга!», имеш. Әгәр динле, иманлы, көчле рухлы Рейган, Тетчерлар булмаса, явыз Брежнев урынына алмашка нәкъ аның төсле үк бушкуык менеп утырачак иде бит! Рейган, Тетчерлар явызлыкның, тиранияләнең Мәскәү аша бөтен илләргә таралуыннан куркып, кешелекне махау чиреннән арындырырга теләп кенә, дөньяны ленинизмнан саклап калу бурычын үз өсләренә алдылар. (Үзенең коммунистик принциплардан чигенмәсен белдереп шөһрәт алган Ленинград химигы Нина Андреева да «үзгәртеп коруны оештыручылар» дип Рональд Рейган белән Маргарет Тетчерны исәпли икән. Ләкин без бу мәсьәләгә бөтенләй бүтән күзлектән, капма-каршы ноктадан карыйбыз. (А.Г. «Мегаполис-ЭКСПРЕСС», 1991, 21 март, 12 нче сан, 22 б. Влад. Масленников мәкаләсеннән.)

Шәһәр белән танышып йөргәндә, шушы авыр уйлар миннән калмадылар. Үзгә

географик пояс, вакыт аермасы өч сәгать — йокы, эш, ашау тәртипләре тәүлек эчендә бозылды. Унтугызыннан егермесенә каршы төндә йокладыммы-юкмы, белмим. Күңел Актаска омтыла! Мондагы вакытка буйсынып иртәнге сигездә әз-мәз капкаладым да тимер юл вокзалына төшеп киттем. Көн болытлы, салынкы. Озын вә мәгънәсез Совет проспекты буйлап барам. «Советский» исемен йөрткәнгә күңелгә тияме бу урам? Автовокзал да тимер юлныкы белән янәшә икән. Тавыш, ыгы-зыгы, чәбәләнү, күзе тонган сәфәрчеләр, талаш, кагылып, төртелеп китүләр, күзне тырный торган озын-озын чиратлар. Аяк асты юеш, пычрак. Кичәге кыска итәк кигән купшы казакъ кызлары бүген төренгәннәр, күз-кашлар гына Африка кабиләләренең битлекләрен хәтерләтә. Белешмәләр марҗасыннан юлны сорашам, нидер мыгырдый, колагым сак, ишетмим генә бит! Тук, кызгылт чыраена карап соравымны өченче кат әйтергә кыймадым: йә берәр нәрсә белән алып бәрер, усаллыгы йөзенә чыккан. Вокзал яны мәйданына чыктым, баш очында, багана очларында белешмә такталары эленгән икән. Актас та, Волынка да күренмәде. Диспетчер янына килдем. Мөлаем тавышлы яшь кенә ханым ачыклап бирде: «Актаска 41 нче автобус йөри»,— диде. Менә кайда икән ул, иң кырыйдагы бүлемтектә! Барып бастым. Кеше аз, ишле бала-чага. Койты киенгән, йончыган кыяфәтле адәмнәр дә бар. Хәрбиләр бик күп. Ничәмә-ничә юнәлешкә китәргә торган чиратларның һәммәсендә дә погоннар, кокардалар елтырый. Үгез җигәрлек таза-таза пәһлеваннар вәкарь белән генә, чын хуҗаларча басып торалар. Өтек кенә төсе уңган автобус мин терәп торган багана турына килеп туктады. Сараньга бара икән. Таныш исем! Актастан Сараньга, Сараньнан Актаска этаплар йөреп кенә тора иде. Белештем, шушы өтек арба Сараньга Актас аша бара икән. Үзем өчен әкияти тоелган сәфәр язмышына гади генә Актас, Сарань дигән сүзләр катышып, юлым ачыклангач, боегып киттем. Актаска бару минем өчен тиңдәшсез олы могҗиза булып тоела иде ич! Ә монда кер дә утыр, билет бәһәсе дә унбиш тиен генә! Керeп утырдык, дулкынлануымның чиге-чамасы юк. Хисләремне гади сүзләр белән генә берчакта да аңлата алмам, төш күрәм дә кебек, өн дә сыман. Хис-тойгылар минут саен алмашына. Сабырсызлана,

каядыр карурманга кереп адашканмын да кебек, бозы арчылып бетмәгән агымсуда коенам да сыман, күз карашым каушап тирә-якны капшый, тишә, үтәли күрә, күземә автобуска төялгән адәмнәр түгел, юл, юл читендәге котсыз агачлар гына күренә. Юл! Мин юлда! Кырык елга якын вакыт үткәннән соң мин Актаска барам! Алып бармыйлар, үзем барам. Актас бар икән, яши икән! Байтак төрмәләр, лагерьлар аша үтсәм дә, Актас, анда күргәннәр, кичергәннәр, андагы иптәшләр, вакыйгалар ныграк истә калган. Йөзләгән исемнәр, кешеләрнең йөз-кыяфәтләре әле дә истә!

Юл, юл, юл! Барабыз! Кемдер керә, кемдер чыга, арткы рәткә кереп утырган хәрбиләр кыймшанмыйлар. Кая баралар диген?.. Шахтерлар каласы да америка чаганына гашыйк икән, ике яктагы куе чаган урманы Хрущев бабайга һәйкәл булырлык биш катлы шөкәтсез йортларны шактый нык яшергән. Бәлки, мин дә төзешкән 19, 21 нче мәхәлләләрне телеп үтеп барабыздыр? «Актас якын гына ул!» диделәр миңа. Америка чаганнарын шәһәрләрдә күргән саен, күңелемдә бер уй калка. Христиан дине безнең Зәй якларында чиркәүне мул салдырган. Керәшен авылларындагы чиркәүләр агачтан, урыс авылларында нык итеп таштан салынган. Сәбәп нәрсәдә? Христиан дине татарларда вакытлыча гына, берара вакыт үтәр дә татарлар тагын исламга кайтыр дип уйлаганнармы? Чаган тезгән хуҗалар үзләрен бу җирдә вакытлыча гына дип чамалаганнар, ахрысы. Чаганнарны җир хуҗалары — казакълар утыртмаганы күренеп тора. Алары исә юкә, каен утыртырлар иде.

Юл, юл, юл! Янәшәмдәге кешеләрдән гел сорашып, белешеп барам, алар минем инәләр өстендә утыруымны, борчалы кием кигәнемне сизмиләр булыр, гади генә: «Әйтербез, әйтербез!» — дип тынычландыралар. Петлицаларына самолетлар ябыштырган гөрс-мәрс аю хәрбиләр төшеп калдылар. Сулда, асфальттан ерак та түгел, локатор әйләнә! Бу инде очып китәргә килмәгән! Ни генә юктыр бу дала тирәнлекләрендә! Вагонда шыпырт кына сөйләшенгән сүзләр колагыма эленгән иде: «Монда (шәһәрчек исемен ачык ишетә алмадым!) уран рудниклары янәшәсендә биологик корал заводы эшли. Ирләре тоташтан пеләш! Яше-картының башы ялтырап тора!» Сөйләшүчеләр

таз башларны мәзәк итеп сөйләштеләр. «Биологик корал» дигәнгә һич исләре китмәде. Анда да яртысы татар эшлидер әле! Читтән кайтучылар арасында пеләшләр күп күренә башлады. Рәсәйнең агулы, иң зәһәр эш урыннарына безнең агай-эне барып яллана, рудникларда чиләнә, төпсез шахталарга барып төшә. Гаҗәп халык! Үз җиренә сыймаса да сыймас икән! Бүтән милләтләр дә үз араларыннан «утлы табаннарны» аерып чыгаралар, мәсәлән, шәһри Казанда гөрҗи-әрмәннәр байтак кына, тик ник арадан берсе кара эштә чиләнсен! Татар бара да җәһәннәм базына дөмегә! Булса да булыр икән үз кадерен җибәреп йөрүче милләт!..

Күз вә күңел теге елларда ияләнгән даланы эзли. Элек без үткән юллар комлы-балчыклы була торган иде. Үлән-үсемлекләр сирәк. Анда-санда уйдык-уйдык кара әрем үсә дә, тәбәнәк, җирдән ерак китәргә базмаган караганник дигән куаклар була торган иде. Көндезге дүртләрдә җәен ком бураны даланы күтәреп киткәндәй булып дулый иде. Җилсез чакта кайларда посып яталардыр, җил дала ярыкларыннан бүре уты — дүңгәләкләрне эзләп таба, аларны куа, тәгәрәтә, чүмәлә кадәр итеп йомарлый. Җил ыжгыра, тузан-туфракны болытларга күтәрә, аяз көннәрне кояшны томалый. Кыямәт башлана! Ач тоткыннар күкрәкләрен җилгә куярга тырышып, битләрен җиңнәре белән капларга маташып сөрлегә-сөрлегә атлыйлар. Ә җил аяусыз, аның ыргымнары тарта, йолка... Җил иркенә бирелеп, сафтан кашык буе гына читкә чыгып кара. Читчиттән барган ерткыч этләр җилләрдә аерата усалланалар... Комнан сукырайган, җилдән көчсезләнгән дүрт-биш йөз кешелек ачлар колоннасы күз алдыма килеп китте...

Хәзер дала юк, бөтен тараф казылган, чокылган, тишелгән, актарылган, сыдырылган, эшерелгән, өелгән... Караганниклар да, дүңгәләкләр дә күренми. Офыктан офыкка даланы бөтен киңлегенә җир астыннан гигант сукыр тычканнар казып барган шикелле. Ниндидер предприятиеләр, уңга-сулга каерылган тар юллар, таш коймалар, шахталар, соры таш эскертләре, балчык таулары — терриконнар, аркылы-торкылы чыбык эленгән сансыз-исәпсез кыеш-мыеш баганалар. Утыз-кырык ел эчендә адәм баласы монда теләгәнчә усалланган, көче белән масаеп, җирнең йөзен, махау чире йоктырып,

аяусыз ермачлаган. Элек, без барында, монда кая карама лагерьлар, кат-кат тимерчыбык киртәләр белән кат-кат чолганган эш, хуҗалык урыннары тезелеп киткән иде, хәзер аларның берсе дә юк, алай да бер җирдә дә ямь, җылылык, аш калмаган. Монда табигатьнең патшасы Homo Sapiens түгел, иблис, убырлар, җиргә үчле җен-пәриләр хуҗалык иткән диярсең. Күзләрем комарланып як-якны ашый, әрәмгә үткән елларымны уйлап җаным сыкрый, дөньяның гаҗәп мәлләрен искә төшереп бөтен күзәнәкләрем елый.

Кыямәт көнне Сират күперен кичү өчен күпме вакыт кирәк булачак? Дини чыганаклар ул хакта мәгълүмат бирәме икән? Мин әнә шул, кылдан нәзек, кылычтан үткен мәшһүр Сират күперенә кергән адәм хәлендә. Бармы моның очы, азагы бармы?!

Уңда «Дачалар» дип язылган күрсәткеч-такта калды. Тәбәнәк агачлар арасында җилфердәгән керләрне, умарталардан чак кына зуррак такта йортларны күргәч, телсез калдым. Лагерьларны сүтеп дача салганнармы әллә? Агачлар да шул чактан калганмы? Әллә исемсез зиратларны яшерер өчен корганнармы ул такта дачаларны? Яңа буынның ваемсыз затлары кадерсез сөякләр, дога көтеп яткан бичара җаннар өстендә тормыш коруларын беләләрме?! Тәнем-җаным, нурым-күгем, бөтен барлыгым-иманым белән як-ягымда сузылып кала барган шушы җиргә сеңдем, тамырларымны әле бер киңәйтеп, бер тарайтып, кан урынына кайнар, җирле үлчәү берәмлекләренә сыймаган плазма акты. Кеше каны химик составы ягыннан диңгез суы белән бертөрле, хәзерге мәлдә минем тамырларга диңгез генә түгел, океаннар сыеп бетте. Ми тартмасына ут тулды! Ялкын! Көч! Тәрәзәгә йотылуымны белдермәскә тырышам, күземне берәүгә дә күрсәтмим, янәшәмдәге килмешәкләр берни сизми сизүен, җанымдагы уттан автобус ничек дөрләп, янып китми?

«Кирпеч заводын ничек табарга?» — дип сорашам, тавышым чыкмый, ирен арамнан иңрәү, сагыш коела. «Искесенәме? Яңасынамы?» — дип сорыйлар. «Искесенә, искесенә!» — дип ашыктырам мин. Сарань автобусына тап булуым хәерлегә дә булган әле, Актаска йөрүче автобус иске кирпеч заводына хәтле бармый да икән, ә Сарань

машинасы нәкъ шуның кырыеннан үтә, диләр. Поселоктан заводка кадәр шактый ара төшәргә кирәк икән әле. Ниһаять, урамнар, йортлар артта калды, сөзәк үр төшеп автобус нәкъ завод каршысына килеп туктады. Икәү төштек, юлдашым, урта яшьләрдәге хатыннан: «Кирпеч заводы шушымы?» — дип сорамыйча булдыра алмадым. «Шушы булмыйча», — диде хатын, исе китмичә генә, һәм каядыр кереп югалды. Ятсынып карап торам: җирне-күкне, тирә-ягымны, заводымны танымыйм. Җир күкрәге ертылып беткән, умырылган, тирән-тирән аклы-каралы пычрак чокырлар арасыннан борма юллар үтә. Вася Иванов эшләгән котельняның пыф-пыф итеп утырган торбасы юк. Яңарак булсалар да искереп өлгергән яңа корылмалар, шөкәтсез биналар, кыеш ишекләр, ватык тәрәзәләр, күгәреп, сынып-ярылып беткән шифер түбәләр — барысы да ят. Завод ихатасы тирәли корылган, кош та очып чыгалмаслык чәнечкеле койма да, мин ничәмә-ничә тапкыр үтеп-сүтеп чыккан тимер капка да юк. Кинәт завод ягыннан җил исте. Ис! Таныш ис борынга бәрелде. «Атла!» — дип акыручы юк, таныш искә борынымны турылап, әкрен генә алга атладым. Йомшак кына басам. Тыңланам, сагаям, нәрсәнедер югалтырмын, сизми калырмын, күрмәм, аңламам дип пошынам. Аяк табаннарым, сизәсезме? Минем эзләремне табасызмы? Табасызмы?..

Кинәт миңа төбәлеп, мәңгелекне эзләгән күзләремне кисеп, чуар-чабар киемнәрдән тере ташкын убылды... Алар! Юлдашларым минем, кадерлеләрем, төрмәдәшләрем! Сез бит бу, сез! Илле беренченең җәй уртасында, нәкъ шушы урыннан көпәкөндез якты кояш читенсенеп кенә далага карап торганда, кирпеч төяргә зонага кергән өр-яңа самосвалны яулап алып, дүрт тоткын качканнар иде. Кыска арада дуслашкан Мәскәү студенты Анатолий Кузовкин, авызыннан челемен төшермәгән сүзсез урыс Зонегин, кысык күз кабаклары арасына утлы күмер кыстырган киң күкрәкле, базык, гаять көчле казакъ егете К. (фамилиясе тел очымда тора, хәтерләмим, исеме дә онытылган), мин бөтенләй белмәгән диярлек, биек буйлы, ачык йөзле, затлы токымлы литвалы ир... Бу машинада якын дустым, әтисе черкес, әнисе татар Абдулла Али-казы качарга тиеш иде. Мин аларның качасын белә идем. Абдулла эшкә безнең заводка

түгел, төзелешкә йөри иде, бүген аның карточкасын безнең бригадага күчереп тыгарга тиешләр иде, план кайдадыр өзелгән, карточкасы булмаганга аны вахтада тоткарладылар. Аның тимер капкага эчтән тотынып карап калганы әле дә күз алдымда...

Казакъ — җирле егет, юлларны белә, литвалы — оста шофер, алар, машина хуҗасының касыгына пычак терәп, аны аска салып, өстенә менеп утыралар, Зонегин белән Толя әрҗәдә яталар. Җәй. Һәркайда кирпеч кирәк, машиналар туктаусыз агыла, төялгән машиналар вахта капкасын чыгалар да алдан-арттан шлагбаум уртасында калалар. Очлы лом тоткан солдатлар, әрҗәгә сикереп менеп, кирпечне аралап, йөкне каезлыйлар, җентекләп чокчыналар. Ләкин машиналар күп, тиргә баткан солдатлар кайчак шлагбаумны төшереп тә тормыйлар. Безнең качаклар шуңа исәп тоталар да, капканы чыгуга, туп-туры машинаны сакчы солдатлар өстенә юнәлтәләр... Кинәтлектән бер мәлгә югалып калган солдатлар читкә тайпыла, машина ул арада заводтан ерагаеп та өлгерә... Безнең бригада карьер янында кирпеч блоклар сала иде. Атыш тавышларын ишеткәч, йөрәгем шартлар дәрәҗәгә җитте... Кача алдылармы, юкмы тегеләр? Качкыннарның маршруты мәгълүм, алар, шәһәргә барып кереп, халык арасында эрергә җыеналар. Шәһәргә, шәһәргә! Әмма шәһәргә безнең юл торак зона яныннан гына үтә. Завод ягыннан ишетелгән атыш тавышлары каланчалардагы сакчыларны сагайта, җан-фәрманга шашынып чапкан машинаны алар абайлыйлар һәм ут яудыра башлыйлар. Толя каты яралана, машинаның радиаторы тишелеп, шәһәргә җитәм дигәндә, суы бетеп туктап кала. Исәннәр кайсы кая тая, хәлсез Кузовкинны әрҗәдә калдыралар. «Качыгыз тизрәк!» — дип ялвара ул. Моңарчы ике таза күт астында посып яткан, касыгына пычак терәлгән шофер, солдатлар килеп җиткәндә, яхшы атлы, батыр булып күренер өчен, яралыны әрҗәдән сөйрәп төшергәндә яңаклый башлый. Солдатлар: «Кемнәр качты? Кая киттеләр? Адресларын әйт!» — дип, Толяны кыйнап үтерәләр.

Атна эчендә качкыннарның бүтәннәрен дә тоттылар. Иң соңгысы итеп казакъ егетен тотып китерделәр. «Кол Изаура» фильмындагы кебек, куллары югарыга бәйләнгән, үкчәләре, аяк очлары җиргә тияр-тимәс кенә торган көчле, нурлы казакъ егетен

мәңге онытасым юк. Безгә гыйбрәт итеп асканнар иде аларны...

Кыска бөдрә сакаллы, сызылып кара мыек чыгып килгән ак йөзле, ирләрчә чибәр, яшьли атылган Анатолий Кузовкин, якын урыс дустым! Үзара шаяртып, син мине: «Разночинец», — дип атап йөртә идең! Кем искә ала икән сине бүген?! Догаларда телгә алып, сагынып синең җаныңны җылытыр кеше калдымы җир йөзендә? Исәнме син, кыю Зонегин? Батыр литвалы? Бәлки, син «Саюдис»та бүген мәйдан тотасыңдыр?..

Җан дусларым, лагерьда чирдән үлеп калган Теодор Августович Цеплитис! Син Робинзон булсаң, синең күләгәң булып йөргән, мине «туганым, чикерткә!» дип үртәргә яраткан Жанс Матисович Миезис! Мәңге күңелемнән китмәс, егермедән артык тел белгән профессор Ростислав Иванович Илечко! Мандельштам шигырьләрен укыган, мине Гумилев әсәрләре белән таныштырган Сергей Сергеевич Козлов-Куманский! Ярслау татары Мигдәт Динмөхәммәт улы Сәләхетдинов!..

Сез бүген, ирләрчә кочак җәеп, миңа таба ыргыласыз — уртак эзләргә сак кына баса-баса, мин бүген сезне эзләп киләм! Завод бар икән әле, бар, ул тәбәнәкләнмәгән, як-ягына балчык, лай өелеп, ул уртада моңаеп калган, аста. Уңда Гофман мичләренең беренче чираты. Авыш ишекләрдән кирпеч чыгарып өйгәннәр. Безнең дәвердә кирпечләр ап-ак, Гжель фарфоры сыман чыңлап тора иде, хәзер кирпечләр каралган, димәк, балчыкның сыйфаты үзгәргән, шихта (катнашма) элеккечә түгел... Аяк тавышы чыгармаска тырышып, мич ишекләре каршысыннан сузылган рельслар ягасыннан барам. Бу якның бригадиры озын, юка гәүдәле бандеровчы иде. Аның да исеме сакланмаган, онытылган. Аргы баш мичләренең бригадиры урыс кешесе Петр Скороходов иде. Гитарачы! Есенинның бөтен шигырьләрен көйгә салып җырлап күрсәткән очлы яңаклы Петр! Ялны синең белән беркөнне алырга тырышкан, бүлмәдә күләгә сыман шым гына йөргән Авдей карт! Кардинал иде синең кушаматың, Авдей дәдәй!.. Сез миңа күпме яхшылык, игелек күрсәттегез! Җылы җаннар! Бүген монда беркем юк, тып-тын, рельслар эргәсендә көл сыман ай тузаны яткан, мондый тузан бүтән бер жир-

дә дә юк, ул су булып ага, үтеп киткәндә, үкчәләрдән ясалган чокырчыклар тиз үк күмеләләр... Монда газап чиккәннәрнең эзе сакланмасын өчен Иблис кодрәте белән ясалганмы әллә мондый тузан? Элек тегермәннәрдә бүрәнә араларына ак тузан куна иде. Гариф Ахунов аны «онта» дип телебезгә кертеп тә җибәрде. Ә бу тузан үлек, котсыз... Җиргә тамган күз яшьләрен дә, кан тамчыларын да йота торган тузан. Беркем очрамавына сөенеп, аяк эзләремне йоттырып, үзем озаграк эшләгән пресс цехына таба атлыйм...

Әйдә, цех әзрәк көтеп торсын әле, яза-яза кулым арыды, чак кына ял итеп алыйк...

Бүген егерме беренче август, сәгать көндезге унбер. Унтугызында килеп төштем, кичә көне буе Актаста булдым... Кайткач та көндәлегемне язарга тотындым, бүген хисләремә буылып-буылып шуны дәвам иттем... Үткән төндә дә йокы эләкмәде, кытайлармы, ят халык төн ката бәйрәм иттеләр. Көндез урынга тәгәрәп карасам да, күзгә йокы эленмәде, йокы Казанда калган, баш иңкеп, аңгыраеп караваттан тордым. Булса да була икән тоташ шауга күмелгән кунакханә! Пәри күтеннән чыккан тавышлар яңгырый, билләһи! Тагын шундый тәмуг төне көтелә, коридорда иртәдән дөп-дөп йөриләр, ачык ишекләрдән бер-берсенә кычкыралар, карурманда адашканнармыни! Белештем, кытайлар икән, монда больница салалар, ди. Башта яман тавышлар белән адәм балаларына чир йоктырып, соңыннан дәваларлык булсын диләрме?..

Төнем гасабиланмыйча үтте диярлек, кытайлар эчтеләр-эчтеләр дә сеңделәр. Гаҗәп. Төнге бердә телефон шалтырады. Шук кызлар: «Такси чакырдыгызмы?» — дип сорадылар да шаркылдап көлештеләр. Монда, кунакханә тирәсендә, сәер кешеләр күп, ахрысы. Җирле халык, шәһәр егетләре киләләр дә эскәмияләрдә тезелешеп утыралар. Беркая бармыйлар, кузгалмыйлар, берәүне дә көтмиләр дә сыман. Мин кичке сигезләрдән дә калмыйм, куркам, кереп бикләнәм дә вәссәлам. Кичә алай да гаҗәбрәк бер хәлгә юлыктым, шуңа күрә кирпеч заводын онытып торып, хәзерге хәлләремне теркәп куясым килә.

Кичке ашны кунакханә ресторанында ашарга җыендым. Беренче мәртәбә керәм!

Алтыда ачыла дип килсәм, «Җидедә!» — дип кире бордылар. Сәгать тулганны көтеп, Үзәк универмаг тирәсен урадым. Якында ул, каршыда гына. Аяк киеменең җайсызын алганмын, үтерә генә! Йөрем күп шул, нишлисең. Борма баскычтан ресторанга менсәм, борын төбендәге өстәлдә япа-ялгызы бер адәм утыра. Казакъ. Утыз-утыз биш яшьләр булыр. Хәер, ялгышуым да ихтимал, чын казакъның яшен күз күнеккәч кенә тәгаен әйтеп була. Түшенә ике карбыз кыстырган, артына унар табалы штанга тыккан, нык таушалган, көйгән керфекле, өшәнгән марҗа каршыма ук килеп, үткер генә итеп бер карап алды да: «Мужчина, вы один?» — дип сорады һәм, җитәкләп дигәндәй, теге ир янына китереп утыртты. Утырабыз, көтәбез. Рәсәй бит, килеп караучы юк. Ярты сәгатьләр көткәч чыдамадым: «Шушы марҗа ашатамы безне?» — дип сорадым. Теге бәндә борын тишегеннән генә: «Советлар Союзында кайчан тәртип булганы бар соң?» — дип яман мыгырдап куйды. Дәшмәдем, арыган да идем, үз уйларым үземнән калмаган иде. Учыма иягемне терәп, кара бүкәй булып, сабыр гына утыра бирдем. Ниһаять, ризык килде, авызга тәм йөгерде, сүз нидән башлангандыр, казакъ, кинәт җанланып, тиз-тиз генә сораша башлады. Каян килдең, нигә, ни эш бетереп йөрисең һәм башкалар? «Йортлар идарәсендә бухгалтер булып эшләп пенсиягә чыктым, кайчандыр бу тирәдә лагерьда утырган идем, хәзер яшьлегемне сагынып, эзләремә басып йөрим шунда», — дидем. Казакъ бабасының татар булуын белдерде дә, сорамасам да, үзе белән таныштыра башлады. Алма-Атада тора икән, кунакханәсе дә бүтән, соңгы җир тетрәгәндә ата-анасы йорт-җирсез калганнар да, монда, Карагандага килеп, йорт җиткерергә кирәк-яракны юллап йөри, имеш. Ярый, хәбәрләр алыштык, таныштык, ул бу сүзне бүтәнгәрәк каерып тәпчинә, сораша башлады. Казанның яртысы урыслар, татарлар азчылык, ничек бу хәлгә чыдап торасыз сез? Иҗтимагый үзәк ни хәлдә?Ниләр планлаштыра? Татарлар киләчәктә нишләргә җыеналар?

Мин, сарык, ике колагымны әрекмән яфрагыдай шәңкәйтеп, һаман ресторанның идән мунчаласы тәме килгән үтмәс ризыгын күшим, канга сеңгән саклык инстинкты

гына телне әйләндерә. «Мин гади кеше, белемем аз, беләм: бездә, Казан татарларында, милләтчелек юк, урыслар белән тату яшәү безнең канга сеңгән шул. Иҗтимагый хәрәкәттән мин читтә йөрим, картайдым, колак ишетми, күз күрми...» — дип, башны чынлап эшләтергә иренеп, шара-бара тик сөйләп утырам!

Сагаюым шуннан башланды: «Кардәш!» дип кочаклап алган, үз исемен атап, якынаерга тырышкан, теләктәшлек күрсәтеп мине кызганып уфылдаган казакъ капылт үзгәрде, торды, кузгалгач борылып та карамады, саубуллашмады, минем барлыгымны онытты. Бүлмәмә кайтып барганда, ят адәмнең кыланмышларын өзелмәс бер җепкә тезә башлагач әсәренеп киттем. Ата-анасына булышырга йөрүе дә, бабасының татарлыгы да, үзенең «әфганлы» икәне дә (документын чыгарып салды!) мине йомшату, тел яздыру гына булган лабаса! Бүгенге «Индустриальная Караганда» газетасының беренче битендә (1990, 22 август, 193 нче сан) «Не вижу необходимости» дигән мәкаләдә шәһәрнең Ленин районы халык депутатларының район советы рәисе урынбасары К.Ташбулатов сайлаучылар исеменнән Караганда шәһәренә шул көннәрдә гаскәр кертү белән асла килешмәвен белдерә. Димәк, Карагандага шушы арада, мин килгән шәптә, гаскәр керткәннәр! Шәһәрдә бу актка каршы протест митинглары бара икән. Казаннан җирле КГБга ни дип шалтыраттылар икән? Мин «архивка керергә булышсыннар» дип әйттерергә теләгән идем. Килгәннең икенче көнендә кизү биргән телефон белән шалтыраттым, «архив документлары» дигәч, трубка шактый вакыт дәһшәтле тынып торды, җаваплы иптәш, минем кем булуым белән, ни юллап йөрүем, ни эзләүләрем белән кызыксынмады, сорашмады, белешмәде. «Эшебез күп, бик тыгыз вакыт, вакытым юк», — диде.

Алар шушы болганчык көннәрдә Казаннан казакъларны болгатырга килгән яшерен эмиссар дип кабул итмәделәрме мине? Эмиссар буласы иде дә... алай түгел шул, түгел! Иҗтимагый хәрәкәттән читтә яшим, олыгайдым, акыл салмакланды. Егәр барында, зиһен ачык чагында «программа минимум»ны башкарып чыгасы килә, язасы әйберләр күп булмаса да, бар... Язарга, язарга, язарга! Халкым язмышы хәл ителгән-

дә, миннән өлеш хак, гадел сүз булыр. ГАДЕЛ СҮЗ БУЛЫР!

«Туганым!» дип кочаклап каршылаган, төкереп киткән казакъ бәндәсе уйларымны көтелмәгән якка юнәлтте. Бәлки, бу бер курку гына булгандыр? Сагаюым гына булгандыр? Белмим.

Бүген, әйткәнемчә, егерме икенче август. Төн җылы, рәхәт булды. Кытайларның чираттагы бунты да колакка кермәде, иртән саф баш белән уянган идем. Сәгать сигездә үк автовокзалга төшеп, көч-хәл белән Волынка таш карьерын эзләп таптым. Әгәр килгән көнне үк, күңел үтә боек, төшенке чакта, карьерны эзли чыксам, һич табасы түгел икәнмен. Бүген мин бүтән, җаныма үзем хуҗа! Аякны кыра торган ботинка башларына учлап-учлап гәҗит кисәкләре тутырдым да кукраеп йөрим. Аяк адымнары кәефкә карап үзгәрә, текә йөримдер шул, таш базына алып барган такси шоферы: «Сез олы бер начальник булгансыздыр, ахры», — диде. Көлемсерәдем. Язучы начальник була диме? Начальник та берчакта да язучы була алмый. Берчакта да! Язучы — үз халкының рух сакчысы, намусы. Мин шулай була алдыммы? Белмим. БУ ДӨНЬЯДА ИҢ АВЫРЫ — ҮЗ-ҮЗЕҢӘ ХӨКЕМ ЧЫГАРУ...

Шартлап урталайга ярылырга әзер җанымны чак-чак тыеп, пресс цехына таба барам. Нигә эшләмиләр икән бүген? Беркайда бер кеше заты күренми. Гофман мичләре элекке нигезләрендә утырсалар да, беләм, шушы еллар эчендә аларны ничә сүтеп, ничә тапкыр җыйганнар иде. Үземнең дә кирпеч яндыру мичләрен сүтеп-җыйганым бар иде. Ишекләр, ишекләр... Берләренең ишекләре томаланган, эчтә чи кирпеч кибә. Арырак үтүгә, ишекләрдән эссе бәрә: монда дулый-дулый ялкын йөри, кирпеч яна. Берләре ачык: алардан яндырылган кирпечләрне бушаталар. Тар һәм тәбәнәк ишекләргә сыешлы автопогрузчиклар көйләгәннәр икән. Безнең заманда мичтән кирпеч чыгару гаять авыр хезмәтләрнең берсе иде! Мич эчендә әле 60–70 градус эсселек, уттай кирпечләрне яланкул тачкаларга төйисең һәм тимер тасмалардан тәгәрәтеп ишегалдына чыгарасың, анда штабельләргә шакмаклап өясең... Мичкә яланбаш керсәң, чәч көя торган иде! Һәрбер кирпеч дүрт кило! Тачкага 60–70 кирпеч төяргә кирәк. Ким-

рәк төясәң, норма үтәлми. Норма үтәлмәсә, үзеңнең генә түгел, бригаданың паегын кисәләр. Зың-зың итеп чыңлап торган алмаздай үткен кырлы Актас кирпечен вагоннарга күпме төядем икән мин? Учлар сыдырылып, канап, бармак башларының тиресе кубып, төннәр буе сыкранып, еламсырап ята торган идек... Бу заводта мин сынамаган хезмәт төре әз калгандыр...

Ниһаять, пресс цехы. Дүрт пресстан бүген берсе дә эшләми. Өч хатын, тузанлы агач рейкаларга утырып, бидоннан кружкаларга чумырып алып, суык чәй чөмерәләр. Алар эндәшми, мин дә тып-тын гына ары-бире йөргәлим... Эшне монда да чак-чак «җиңеләйткәннәр» икән: карыйм, кирпечне автоматлар кисә. Заманында бу чамасыз авыр эшне бригаданың таза, тыңлаучан егетләре — латыш Скуя, эстон Ансонслар башкара иде. Кирпеч заводында бер генә җиңел эш тә юк, җитмәсә, һәр бригадага җидесигез карт-коры кертелгән, аларның формулярларына «Использовать на особо тяжелых трудах» дип язылган. Безнең пресс бригадасында иң өлкән кеше мәскәүле Ной Борисович Окунь. Гомере буе наркоматларда эшләгән бу җитмеш биш яшьлек кешене кая куясың? Тамак туйдырыйм дисә, бригада аның нормасын да үтәргә тиеш. План үтәү ягын бригадир кайгырта, әгәр ул «вольняшкалар» — цех мастеры, начальнигы, нормировщиклар белән уртак тел таба алса, эш бераз көйләнә, юк икән — бөтенең өелеп ач утырасың...

Пресслар яныннан карьерга чыга торган ишеккә атлыйм. Өч-дүрт ир стенага арка терәп тәмәке пыскыталар, миңа теләр-теләмәс кенә күз ташлап алалар. Мин аларга да дәшмәдем. Күрер күзгә сөйкемле генә адәмнәр, арада зыялысы да бар түгелме?.. Балчык эше һәрчак авыр, төтен, тузан, газ... Безгә алмашка кемнәр килеп, кемнәр китте икән? Нинди затлар? Уртак язмыш йөртәме аларны, әллә һәркайсысы үз улагыннан агып төшкәнме? Беләсем килсә дә, әлегәчә мин беркемгә дә эндәшмим, минем хәтеремне мәңгегә биләгән йөзләрчә шәүләләр болыты мине озатып йөри, сорашмыйм да, алар кайчандыр монда коточкыч язмышка дучар ителгәннәрнең җәһәннәме икәнен бөтенләй белмиләр дә... Автобустан төшкәч, теге юантык хатыннан: «Заводны япон-

нар, немец әсирләре салганын, озак еллар монда тоткыннар эшләгәнен беләсезме?» — дип сорагач, ул миңа акылдан шашкан кешегә карагандай карады. Ә болар яшьләр, әле ни белсеннәр? Яшьләр тарихны яратмый.

Кире әйләнеп кереп, мичләрнең аргы баштагылары янәшәсеннән барам. Кара-көрән ишекле киптерү камералары. Исләр, төсләр, гомуми манзара таныш, искечә. Безнең цех начальнигы чулак Сергеев иде, мастерыбыз Григорьев дигән юаш кына төшенке иңле бәндә. Алар да мондадыр кебек, төтен-газ саркып торган камера ишегеннән безнең кәйлә-туфталарны тотарга куелган, авызыннан сасы махоркасы төшмәгән ат тешле ярты казакъ, ярты урыс Ундасынов килеп чыгар төсле. Аныңча итеп, «Эх, французлар!» дип пышылдыйм. Болар «вольняшкалар», шулай булса да бергә эшлибез, язмыш уртак. Завод директоры Белоусовны, Лидия Тимащук Кремль врачларының «битлеген салдыргач», врачларга үлем җәзасы таләп итеп чәчрәп чыккан ыспай киемле юка, какча кешене без бик сирәк күрәбез. Йодрык кадәрле, йомры гәүдәле... карлыгачтай кап-кара, һәйбәт кара тройка кигән баш инженерыбыз яһүд Ройман пресслар ремонтта чакта кереп-кагылып чыккаласа да, тоткыннар белән сөйләшми, мөгаен, үзе дә җәза татыган сөргендәге кешедер, үз ихтыярыннан Карагандага килеп тормас, ул, гаепле кешедәй, ике-өч минут аякларын алыштырып басып тора да югала. «Вольняшкалар» безнең белән ныклы аралашмыйлар, тоткыннар булганда үзара да сөйләшмиләр диярлек, йомышларны үтәмиләр, почта әрҗәләренә хат сал дисәң, алмыйлар. Хатларны кирпеч төяргә кергән машина шоферлары да сирәк ала, ә безнең хатлар саласы килә, гамәлдәге закон буенча безгә елына ике хат язарга гына рөхсәт, анда да урыс телендә. Җитмәсә, нибарысы ачык хат... Ялынып, ялварып тапшырган хатларның күпчелеген шоферлар почтага илтеп йөрми, алалар да юк итәләр. Бер-берсеннән курку җелекләргә төшкән. Без хатларны болай да шомартып, бизәп, таслап, ата-ана, туганнар өстәмә җәфаланмасын дип, чынлыктан ерагайтып яза торган идек. Ни үкенеч! Лагерьның кырыс, ямьсез чынбарлыгы, сугыш чорында көчсез малай булып җәфа чиккән буынның, үсеп җиткәч, колхоз рәисләрен, явыз коммунистларны, вәкилләрне рәттән

пычакка алуларын, лагерьларда милләтләрнең бер-берсен кырулары, шушы уч төбе кадәр лагерьларда бөтен илләрдән тоткыннар булуын, аларның ачыгуларын, нужаларын, унар-унбишәр ел илләре белән багланышка керә алмауларын хатларда язып булмады. Өйдә әти укытучы, абыем Азат та мәктәптә укыта, энекәшләр институтларда, шулар өчен куркылды. Безнең лагерьлардан котылып чыккач та өйгә кайту юк иде, иң зур күпчелек кайту, котылу турында уйламый да, һәркемгә егерме бишәр ел төрмә, биш ел сөрген, бишәр ел хокуксыз яшәүне чәпәгәннәр... Чыккан хәлдә дә мәңгелеккә Красноярск урманнарына урман кисәргә озаталар. Аларны анда балта-пычкы гына түгел, лагерь надзирательләреннән дә кабахәтрәк кансыз комендантлар, махсус җәзачылар көтә. Киләчәк язмышым өчен дә борчылганмындыр инде.

Кирпеч заводы өч сменалы, сигезәр сәгать эшләргә кирәк. Көндезге сменада без эшләсәк, кичке, иртәнге сменада хатын-кызлар килә. Алар өч меңнән артык хатын-кыз тоткыннар, безгә якын гына землянкаларда яшиләр, зонада. Мин озак вакытлар ике кыз белән хат алыштым. Украин кызы Лена Иваненко белән латыш кызы Дзидра миңа өзлексез хат язып тордылар. Мин дә байтак хатлар яздым аларга, хатларым көчле, тәэсирле булгандыр. Теодор Августович Цеплитисның якташы, иректән үк белеш ханым, көннәрдән бер көнне: «Синең тәбәнәк дустың безнең зонада давыл кубарды, кызлар аның өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер торалар», — дип язды. Хатларымны хатын-кыз зонасында кулдан-кулга йөртеп, җыйнаулашып кычкырып укыганнарын үземә дә ишеттерделәр. Ул хатлар сакланмады, зоналарда зур күпчелек мине Алексей Михайлович Неон дип белеп калды, лагерьда синең чын исемең юк, син номер, теләсә нинди исем сайлап ала аласың. Мәсәлән, мин Абдулла Али-казының ахирәт дусты Диманы Сергей Курский дип кенә белә идем. Илле дүртнең августында Кингир восстаниесенә катнашучыларны Казакъстаннан Ванин бухтасына төркем-төркем озатканда, без аның белән Чиләбе төрмәсендә очраштык. Восстание вакытында Кингир зонасында газета редакторы булган очлы борынлы, кара күзлеген бер дә салмаган батыр егетнең чын фамилиясен белми дә калдым...

Карабас, Актас, Волынка лагерьлары минем өчен аерата истәлекле, аерата якын. Актаста мин ике тапкыр яшәдем, зур мәктәп үттем, акыллы юлдашларым аша мин илленче еллар башында ук Ленин-Сталин тәгълиматының җимергеч көчен, социализм теориясенең нигезендә халыкларны хайванга әйләндерү максаты ятканын да азмы-күпме белә идем инде. Без булган каты режимлы лагерьларда тел иреге яшәде, сүз өчен эзәрлекләү дигәнне мин хәтерләмим. ВКП(б)ның «Второе крепостное право большевиков» икәнен мин Солженицыннан укып түгел, үз җилкәмдә татып аңладым. Лагерьлар, төрмәләр, кырылышлар мине язучы итеп ныгытты. Бер үк вакытта системадан, властьтан курку көчен дә сеңдерде. Бу авыр мәктәп сине бөгә, законнан, власть вәкиленнән курку хисе бүгенгәчә миндә саклана, инде аннан котылмак юк. Курку хисе ул — тирән тән ярасы, йөрәк җәрәхәте. Курку, сагаю, түбәнсенү, буйсыну, тәлинкә тоту дүрт йөз утыз сигез ел дәвамында империянең иң түбән катламында яшәргә мәҗбүр ителгән татарга шулкадәр сеңгән, «явыз Иван укыткан әбҗәт» һич кенә дә каннан китми, ул буыннан буынга тотрыклы рәвештә күчә, бәлки, хәлләр үзгәреп, ике-өч буын куркаклыктан арынганнан соң, балаларыбыз, оных-нәбирәләребез канында чын болгар, кыпчак горурлыгы, чын татар гайрәте уяныр. Ай-һай, даими һәм дәвамлы, тирәнтен дәлилләнгән, ышанычлы программа белән үткәрелгән селекция кирәк булачак әле моңа.

Мең ел буена кешелек тарихы татарны хурлык баганасына кадаклап, әллә кемнәрнең явызлыгын, кансызлыгын аңа яккан, әле соңгы елларда гына татар белән янәшә яшәгән халыклар, үз милләтләрен югары күтәрер өчен, татар исемен аяк астына салып таптыйлар, татарның милли казанышларын ипләп-ипләп урлыйлар да үз язмышларының нигез ташлары итәргә тырышалар. Мең ел каһәр ишеткән милләттәшләребезнең үз татарлыгыннан борын чөерүенең җитди бер сәбәбе шунда түгел микән?!

Атаклы сәяхәтче Марко Поло «Дөньяның төрлелеге хакында китабы»ның соңгы юлларын 1298 елның икенче яртысында Генуя төрмәсендә язып тәмамлаган. Сәяхәтен Венециядән башлап Судак, Үкәк, Сарай, Болгар җирләрен үтеп, Урта Азия, Ерак Көн-

чыгыш, Япония, Корея, Һиндстан һ.б. бик күп илләрне, шәһәрләрне кичкән сәях ике юлының берендә «татар» дигән сүзне куллана, бик күп милләт вәкилләрен «татар» дип тамгалый һәм алар кылган яхшылык һәм яманлыкны «татарларга» йөкли бара. Яманлык ташка язылса, яхшылыкның комга язылганын без бик борыңгыдан татып киләбез, нәни генә вакыт дулкыны да яхшылыкны юа, оныттыра. Әрмәнстанда да, Грузиядә дә татарлар «Большая страна Персия, а в старину она была еще больше и сильнее, а ныне татары разорили и разграбили ее», «Балх — большой, знатный город, а прежде он был больше и лучше, татары грабили его и разрушили» һ.б., һ.б. Заманында Урал аръягында йөзләрчә кабиләләр «татар» исемен йөрткәннәр. Кавказ-Кырым Татар иле булган, кабиләләр югалган, беткән, ә алар кылган явызлыклар Казан татарларына сыланып калган. Бу буталыш кайчанга кадәр дәвам итәр, ләкин аның чиге бер булырга тиеш ләбаса!

Заводның шактый озынга сузылган юеш, тузанлы бинасыннан чыгып, түбәнгәрәк, без барындагы балчык карьерлары тирәсенә төшеп барам. Күз тирә-якны сөрә, бер ноктада тукталып тора алмый, нидер эзли, капшый... Заманында, төзелә башлаган дәвердә, мин кочегар булып эшләгән шахта ягыннан кап-кара болытмы, дегеттәй төтенме ага. Кара төтен, кайда гына очратсаң да, күңелгә шөбһә, шик-шомнар китерә. Элеккеге балчык ваклау тегермәннәре юк, алар урынында кырык терәүгә калган тишек-тошык сарай хәрабәсе утыра. Завод белән карьерны тоташтырган ябулы галерея да беткән, тәүлек буе безнең канны суырып, кара елан булып шуышкан транспортерлар да калмаган. Карьер әкияти сигезаякның кармавычлары булып ермач-ермач җәелгән, тирәнәйгән, кая карама убылып-убылып киткән котсыз, пычрак авызлы кыеш-мыеш чокырлар. Элек монда, без барында, зонаның зур бер өлешендә тип-тигез дала иде. Безнең бригаданың бер өлешен (бригадирыбыз Федор Лобков, урыс егете) кирпечтән төрле шәкелдәге блоклар ясарга куйдылар. Эссе җәй, карьерның балчыктан бушаган ачык базларына язгы сулар җыелып калган. Без профессор Ростислав Илечко белән ташчыларга — блок җыю осталарына — носилка белән измә ташыйбыз. Теодор Ав-

густович Цеплитис — ташчыларның кәттәсе — мине эшкә өйрәтә. «Туфтить итәргә генә өйрәтимме, әллә чын эшне беләсең киләме?» — дип сорый. Мин, аптырап: «Ни-чек алай була ул?» — дип куям. Теодор Августович иренмичә мине завод бинасы янына ук алып менә. Заводның беренче чиратын япон, немец әсирләре сала башлаган, икенче чиратына Европа илләреннән һәм Россиядән үзебезнең ватандашлар кайтып җиткән. Японнар, немецлар күтәргән стеналар күзгә кебек тигез, кирпечләрнең җеге җеккә тоташып, көлеп тора. «Күр, әсирләр чит җирдә, дошманнарына, урыска эшли-без дип тормаганнар, эшне җиренә җиткереп коеп куйганнар... Ә россияннар салган диварны үзең дә күрәсең...» Теодор Августовичның күзе үткенлегенә сокландым. Хә-ер, илдәшләр салган диварны, кирпечләрнең исеректәй чалыш-мылыш ятуын, күп кул-ланган измәнең дәү-дәү кутыр булып касмакланып катуын күрми калу да мөмкин тү-гел иде...

Хәзер дала юк, бу тарафның кайчандыр тип-тигез булганын да күз алдына китерү кыен. Кайда ул озак вакыт аш бүлешкән немец Гейнц Бем белән шампиньон гөмбәсе җыйган уйдык урыннар? Ни генә юк бу пәри кырында? Күптән түгел генә телевизор-дан чыгыш ясап, металлургия комбинатларының берсенең директоры металл калдык-ларының җыелмавын, комбинатның ике-өч көнлек запасы калганын әрнеп, ачынып сөй-ләгән иде. Сүзе рас, әле шушы тар гына мәйданда йөзләрчә тонна металл күгәреп, череп, әрәм булып ята. Дәү-дәү моторлар, трактор чылбыры, өр яңа арматура бәйләм-нәре, төрле размердагы тимерчыбык көлтәләре, калҗайган, кыйшайган өр-яңа станок-лар, мин исемнәрен белмәгән әлләниләр, әллә ниләр... Безне алыштырган буынны эш сөя дип әйтеп булмый, кая ул... Каян килгән шушы кадәр тимер-томыр, нинди кыры-лышлардан ятып калган?

Мастерыбыз «вольняшка» Эдуард Иванович Шатшнейдер җитәкчелегендә кирпеч блокларны кышын да әзерләрлек итеп шактый зур цех бинасы сала башлаган идек. Шуның подвалына төшеп барганда, маңгаем аркылы салынган тимер өрлеккә орынды, күтәрелеп карасам, кемнеңдер акбур белән эре хәрефләрдән «О, милая!» дигән язуын

күрдем. Җаным тетрәнеп китте...

Бүген монда җимерекләрдән торган бушлык, алай да тимер өрлек аша миңа дәшкән гашыйк күңелне хәтерләдем. «О, кеше!» дип иңрәде күңелем, син дә шушы бер сүзең, бер ымың белән мине язучы итеп әзерләштең, юксызларны кызганырга, шәфкатьле булырга, яратырга өндәдең. Рәхмәт сиңа! Синең шигъри ымың кемгә төбәлгәндер, анысын белмим, эндәшең миңа туп-туры килеп иреште, аны мин кабул иттем, җан авазың миңа, мөлдерәмә тулган күңелемә көч, акыллы хис бирде. Бүген, 1990 елның 20 августында, синең бер өнең җир тетрәткән бинаның эзен эзлим. Ул юк, аны да вакыт йоткан.

Актасның таныш күгеннән тып та тып тамчылар егыла башлады, янымдагы букчамнан зонтигымны алмыйм, үз халәтемне берничек тә үзгәртәсем килми. Беләм, рәслый алам, кеше җаны да, агач үзәге төсле, бер-берсенә сарган боҗралардан тора. Туксанынчы ел Актасы сискәндереп, илертеп, тынычлана башлаган бәгыремне өзеп, җан үзәгемә тирән, киң истәлекле боҗра ясамыймыни?!

Калҗайган тимер-томырларны яңгыр кыйный, дөньяның бөтен чүп-чарын җыйган аклы-соры ярларны шәбәртә... Һич хәтеремә төшерә алмыйм, безнең заманда текә ярларда керәшә оялары бар идеме? Әллә мин үткәннәрдән юкны да эзләп маташаммы?..

Яңгыр ныгытып ук ява, дымлы җиргә, меңләгән язмышларның тирән эз-җәрәхәте убылган шушы ноктага минем күз яшьләрем дә тавышсыз гына тама, тонык яшьләр — күз көче кимегән, офыгы якынайган өлкән кеше яшьләре...

Ә шахта ягыннан җилфердәгән сөремле, кара ял тагын да җиргә якыная, заводның теге янын миннән яшерә, уйламасын дип бугай, игътибарымны үзенә генә алырга теләп, һаман көчәя...

Ак балчык базларына сөенеч, юаныч эзләп төшмәгән идем, мәгәр күзгә кычкырып кереп торган тоташ вәхшилек, табигатьне бозу, җирнең саф йөзен ерту, хуҗасызлык җан ярасын тирәнәйтте, элеккеге җәрәхәткә тозның иң ачысын, иң зәһәрен сипте. Теге

заманда да, бу заманда да Казакъстан җиренең төп хуҗалары империалистлар, басып алучылар, колонизаторлар икәнлеген тагын бер кат раслады.

Иртән дә, әбәдтән соң да өзлексез язып утырдым. Иртәгә, иншалла, Волынканың таш базлары белән кавышуны теркәп куярмын. Карабаска барып җитәрменме, көннәр ару торса, яумаса, Актас тирәләрен тагын бер урармын әле! Барасым килә! Хәзер җирле вакыт 18.40. Көндез шәһәр белән танышкалап йөрдем. Карагандага күз ияләшә төште. Уртага матур гына күл уеп, су тутырганнар. Күгәрченнәр коенырга озын улак сузганнар, өстә чиста гына күренгән агымның түбән башында күгәрчен мамыгы гына ага. Димәк, бүтән тарафта күгәрченнәр коенырлык су юк, бар булганнары бу тирәгә җыела икән. Әбәдкә мәгълүм ресторанга кердем. Каршыма тап-таза, базык, байларча киенгән ике адәм утырды. Шикле шикләнер дигәндәй, сак колагымны сузып, тегеләрнең әңгәмәсенә елыштым. Нигәдер тыңлыйсым, ишетәсем килә! Ишетелә. Украинадагы ирек, азатлык өчен көрәшүче «Рух»ны сүгәләр. Безгә гаҗәеп якын «рух» сүзе безнеңчә «хәрәкәт» дигәнне аңлата. Зарланалар тегеләр. «Ленин һәйкәлләрен сүтәләр», «Бетсен КГБ!» — дип акыралар... «Әгәр Сталин исән-сау булса, нишләтергә белер иде! Хәзер илдә ул идарә итсә, кешечә яшәр идек!» КГБ кешеләреме? Уртакул хуҗалармы? Монда, миллионнар имгәтелгән төбәктә, Сталинны тагын кем юксынсын? Яшьтән үк пешеп өлгергән, пионердан комсомолга, комсомолдан партиягә шуышкан фирка әһелләреме? Утырам, өстәлнең икенче ягындагы кешеләр күз алдымда бергә кара, шомлы шәүләгә әйләнәләр, һәм ул яктан миңа кара су ага. Ашавым ашау булмады.

Кичке сигез булып килә. Җылы, чалт аяз. Тамак тук! Хәзерге заманда бу инде әз нәрсә түгел! Кунакханәдән ерак китәргә куркып, карана-карана йөреп килдем. Утырып тордым. Хатын-кызлар бездәгегә караганда затлырак киенгән монда, кыяфәтләре байларча. Олы чуар төркем булып инглизләр чыгып басты. Затлы киенгән кәттә казакъ ирләре белән япон автобусында японнар кайтып төште. Кемнәр? Нишләп йөриләр? Эшлекле адымнары, олысымак кыяфәтләре, җитди чырайлары ял итүчеләр тү-

геллеген раслый. Кыяфәтләренә, мөмкинлекләренә, үз-үзләрен тотышларына кызыгып карап торам. Затлылар! Иреклеләр! Байлар! Дөньяның теләсә кай почмагына чыгып китә алалар, рухи ирекleләр... Хәзер япон әсирләренең кайда күмелүләре турында сүз куерып килә, бәлки, алар да эзсез югалган илдәшләренең ак сөякләрен эзлиләрдер? Арада Саттаро Тогуч юкмы? Юк, болар яшьләр, чибәрләр, затлы токымлылыклары чәчрәп күзгә керә. Спасск лагерында туксан биш мең япон әсире күмелгәнне беләләрме болар? Спасск газеталарында күренмәде, бу санның әлегәчә матбугатта күзгә чалынганы юк, аны миңа Спасскидан Актаска килгән бер төркем бандеровчылар — Иван Копас, Федор Попежук һәм Митя (фамилиясен онытканмын) сөйләгәннәр иде. Булган анда хәлләр!..

Караганда асылда өч зур лагерь идарәләреннән тора иде. «Степлаг» — җәһәннәм. Җизказган, Кингир лагерьлары — бакыр рудниклары, шахталар һ.б. «Степлаг»та кешеләр озакка чыдамыйлар, ике-өч елдан соң «доходяга»га әйләнеп, Спасск шифаханәсенә кайтып егылалар. Спасскида утыз биш мең ятып авыручылар гына була. Утыз биш мең! «Доходяга» — тонкий, звонкий, прозрачный, имеет макаронную походку...» Шулай диләр иде бездә. Авыруларның яртысы Спасскида ятып кала, икенче яртысын, әз-мәз «рәткә китереп», «Луглаг»ка куалар. Мин, күзлекле тоткын буларак, «Степлаг»ка эләкмәдем, турыдан-туры «Луглаг»ка тап булдым. «Спасскидан соң Актас — оҗмах!» диләр иде Копач белән Попежук.

Заманалар үзгәреп, тоткыннарны тараткач, Газиз Кашапов бер төркем офицерлар белән Спасск лагерь хуҗалыгын корылмалары, бараклары белән бергә МВДга кабул итәргә барган. Кызганыч, Газиз Кашаповның күзе ачылып җитмәгән чак була, ул ми-



ңа телгә кертерлек берни дә сөйли алмады. Бер фактка игътибар итәргә кирәк: лагерь тоткыннардан бушаса да, биналарны, хуҗалык йортларын бүтән бер оешмага бирмәгәннәр, МВД балансында калдырганнар... Нәрсәне күздә тотканнар икән?..

Күңелем сүрән — сизәм, Нәкыя сәфәремнең барышын уйлап борчыла. Иртәгә тагын телеграмма сугарга кирәк. Килүемнең гыйбрәтле, файдалы һәм үтә дә зарур икәнен ул да белеп торсын. Архивка гына кереп булмады. Биргән телефон белән шалтыратып карадым, тагын шул җавап: вакытлары юк, эшләре бик тыгыз. Ни өчен гаскәр керткәннәр Караганда җиренә, билгесез. Газеталар һаман бер чүбекне чәйни: план, үтәлеш, ярыш... Әле алар үзгәргәнче! Гәрчә мин күрешеп, сәлам биреп чыгарга дип кергәч, «Индустриальная Караганда» газетасының баш редакторы Э.А.Широкобородов: «Безне гел әрлиләр, бик тиз суллаштыгыз дип гаеплиләр!» — дип сөйләп утырды. Сәяхәтем хакында мәкалә язуымны үтенде. Ашыкты: ни язасымны, иманымның кайсы тармагын ныгытасымны әле үзем дә белеп бетермим, күңел яктылыкка, чынлыкка омтыла. Якты дигәнең хәзерендә караңгы булып чыгар, чынлык исә бик күпләргә бөтенләй кирәк түгел! Гаскәр керткәннәр икән — бу чиксез зур вакыйга, сәбәбен халыктан яшерәләр икән, бу — советларның яраткан эш ысулы, хәлләр шәптән түгел дигән сүз! Тирә-ягымда нидер кыймылдый, нидер оеша, нәрсәнедер таркатырга, кемнедер җәзаларга, куарга, таратырга җыеналар. Совет гаскәре соңгы вакытларда бары шундый яман сыйфатларга гына ия булып калды да... Тирә-якта, караңгыда нидер өлгерә, үсә, калка, ә мин — гафил! Мин әлегә кунакханә коридорларында бугаз ертып акырган бер төркем сәрхушләрнең күмәк тилерүен тыңлап ятам. Булса да булыр икән тынгысыз бина! Төнката лапыр-лопыр чабалар, ишекләрен ачык калдырып, лыбыр-лыбыр төрле телләрдә сөйләшәләр. Гадәттән тыш хәл уртасында калган кунакханә-утрауда бер-



кемнең ваемы юк, һичнигә исләре китми, миннән бүтәннәр артык дәрәҗәдә бәхетлеме әллә?! Күршеләрме, каршыларымы, аерып булмый, хатын-кызлар белән утырдылар.

Хатын-кыз кунаклары тел белми, ахрысы, чинашып, шаркылдап, тырмашып, аяк тибеп, кул чабып аңлаштылар. Мәчеләр андый чакта ямьсез мыраулаша, табигатьләре шундый, адәм улларына таңга кадәр биржа маклерлары сыман тик тормаска, үкерешергә калдымыни?.. Без, лагерьларда ничә милләт балалары, тел белмәгән очракларда да тын гына аңлаша, җаннарны уртага салып уртаклаша идек. Шулай, кайгыда тын яши белгән адәм балалары шатлыкта чыдаша алмыйлар, үкерәләр, сикерәләр... Гаҗәп!

Таңда нык суытты, бүлмәм сап-салкын, балкон ишегем шар ачык, ә минем түшемнән бөрчек-бөрчек эре тир ага... Шигәеп уяндым. Ашказаным сулыгып-сулыгып сыкрана. Кичтән бер шешә кефир эчкән идем. Шулмы? Кыска гомерле кефирны бездә озайтып саталар. Әллә бүтән сәбәбе бармы? Ходаем, читтә чирләргә язмасын. Төрле тарафка тырыш уемны йөгертеп, чирнең сәбәбен эзләп карыйм. Көн яктырганчы җанымны тәнем буенча йөгертеп йөрттем, баш авыртып уяндым. Бишенче катка менеп каймак, ике күкәй ашап, бер тустаган сыек чәй йоттым да автовокзалга чаптым.

Юлым Волынкага, таш базларына...

Волынкада мин озак булмадым. 1953 елның мартында Сталин үлгәч, амнистия игълан иттеләр дә, кайбер лагерьлар, димәк, эшче көчләр таралып, эш урыннары бушап калды. Волынкада таш базларында эшләүчеләрне тулаем азат иткәннәр дә аларга алмашка 600 кешене Актастан этапка озаттылар. Арага мин дә эләктем. Май башлары иде. Кешесез, тып-тын калган, Актаска караганда күп кечкенә бу лагерьга кичкырын гына килеп урнаштык. Җәмгысы мин анда ун ай чамасы булдым. 1954 елның мартында безне янәдән Актаска кайтардылар. Амнистиягә эләккән бандитлар, караклар, кеше үтерүчеләрне яңадан китереп тутырдылар дигән сүзләр йөрде. Ун айлык ирек тәме аларга җитеп ашкан булып чыкты. Актаска кайткач, мине төзелеп яткан шахтага кочегар ярдәмчесе итеп җибәрделәр, урысча бер авыз сүз белмәгән, белергә дә теләмәгән яшь, озын, каратут чырайлы литвалы белән мин кочегаркада эшләдем. Кирпеч заводына кайтмадым.

Сталинсыз чор башланды.

Яңа урын, яңа эш төрләре, монда эш кирпеч заводыннан да авыррак. Җитмеш-сиксән метр тирәнлектә җәенке бер чокыр, төрле калынлыктагы таш катламнары. Тигез диярлек төптә пәрәвез җепләр булып тар тимер юллар кисешкән. Уртадагы җиз төсенә кергән ермакта теш сындырырлык салкын су саркып тора. Төрле яктан текә таш кыялар белән камалган чокырда эссе көннәрдә һава чыдап була алмаслык кыза, яндыра. Башка эссе каба. Чыдый алмыйча ятып су эчкәннәрдән байтак кеше шунда һәлак булды. Эштән кайта, вагонкасына менеп ята, иртәнгә җан тәслим кылган бичара!..

Тазарак тоткыннар авыр, саллы перфораторлар белән таш катламын тишәләр, шурфлар ясыйлар. «Вольняшкалар» без югында, аулакта, шурфларга динамит стаканнарын тутырып, ташны шартлаталар. Тоткыннар авыр калуннар, ломнар, тимер чөйләр белән таш кантарларын адәм күтәрерлек ипкә китереп, ваклап вагоннарга тутыралар. Норма алты вагон. Вагоннарны тар тимер юллардан этеп уртага китерәсең, санап баручыга тапшырасың, ул вагон кабыргасына тамга сала. Вагоннар авыш эстакадага менә һәм бер-бер артлы, каз бәбкәләре кебек тезелеп, өскә менә. Өстә дә вагоннарны саныйлар, таш эскерт өстенә, биеккә менгереп бушаталар. Аста бүтән бригадалар, алар ташны, машиналарга төяп, төзелешләргә озаталар. Ул чакта тимер-бетон плитәләр кулланышка кермәгән, йорт-корылма фундаментларына без чыгарган «бут ташны» тутыралар иде. Ташның бер өлеше зонадагы ваклаучылар кулына барып эләгә, алар, дәү, түгәрәк ваклагычлар аша үткәреп, ике төрле вак таш ясыйлар: эреләре «жебень» дип атала, вагы — «кленец». Вак ташлар бетон ясарга тотыла.

Эш чамасыз авыр. Сменалар юк. Бер караңгыдан икенчесенә кадәр «надо упираться рогами», «пахать»!

Ничек, нәрсә булганның ваклыкларына кадәр хәтерләмим, мине тагын күзлек коткарды, килүгә үк таш арасына төшмәдем. Безне кабул итеп алган чыгынкы яңаклы, саргылт чәчле өлкән лейтенант Фунтиков, минем Актаста бригадир булуымны белгәч:

«Монда да бригадир булырсың!» — диде, читтәрәк басып торырга кушты. Фунтиков ППЧ начальнигы икән. (ППЧ — планово-производственная часть.) «Читтәрәк торырга кушылганнар» тора-бара байтак җыелдык. Һәр лагерь, этап озатканда, көчсез-хәлсезләрдән, гарип-горабадан, филен-ялкаулардан, хулиганнардан, эшлексезләреннән котылырга тырыша. Бригадалар оешып беткәч, Фунтиков кызарынып-бүртенеп сүгенергә тотынды: «Аналарын... аталарын... аллаларын... Актасны әйтер идем. Җыен гарип-горабаны, аксак-туксакны, күзлекле шайтаннарны төяп җибәргәннәр!» Ул, беркемнең дә исемен атамыйча гына, озаклап, тәмләп, катлы-катлы сүгенде. Без мыштым гына тыңлап тордык... 60–70 инвалидны җыйдылар да мине бригадир итеп куйдылар. Иң әүвәл зонаны ныгыта башладык. Халыкның кан коеп, тир түгеп тапкан акчаларын кайларга гына чәчмәдек инде без! Юлбасарларга, каракларга, сугыш чукмарларына чәнечкеле тимерчыбыктан турыга койган бер койма да яраган, ә безгә койманың буеннан-буена машиналар үтеп чыга алмаслык авыш чокырлар казырга кушылды. Без, «яңа заман башлана, озакламый өйдә булачакбыз!» дип, таң саен өмет яңартабыз, ә югарыдан килгән начальство, полковниклар, подполковниклар һаман бездән шүрлиләр, үзгәрешләрне бөтенләй сизмиләр. Чокырны башта сиксән сантиметр тирәнлектә дигәннәр иде, аннан метрга арттырдылар, бер генерал карап киткәннән соң, чокырларны метр да егерме сантиметр казый башладык. Әле ул гынамы сиңа, койма итәгенә буйдан-буйга «Бруно спирале» дигән чәнечкеле чыбыктан түгәрәк өзмәс бөҗралар таратып чыгарга кирәк иде. Ике кеше, колга кертеп, чәнечкеле чыбык йомгагын эләктереп ала да бөҗралар ясап сүтеп бара. Бөҗралар өстенә өстәмә авыш койма да ясала. Кем чокыр казый, кем чыбык сүтә, карьерның биләмәләре зур, әле әйтергә онытканмын, бер кырыйда известь яндыра торган зур-зур мичләр бар, ниндидер биналар төзелеп ята, шунда ук квартиралар да булачак, имеш. Зонаны чит-читләп ныгыткач, безне шул төзелешләргә күчерәчәкләр икән, имеш...

Түгәрәк известь мичләренә «Берегись козла!» дип, эстакаданың буеннан-буена «Берегись орла!» дип язып кадакланган. Мичнең яндыру режимы бозылса, таш чытырдап

эри икән, күмәк төер булып оеша, мич стенасыннан куптарып алу искиткеч авыр эш икән! Шул эреп аккан таш-төер «кәҗә» дип атала икән. Түбәндә таш төялгән вагоннар, махсус ыргаклар белән корыч троска тагылып, авышлыгы кырык биш-илле градус эстакада буйлап бер-бер артлы өскә үрмәлиләр, янәшә рельслардан буш вагоннар аска төшә. Сирәк-мирәк таш төялгән авыр вагоннар, тростан ычкынып китеп, түбәнгә ыргылалар. Шул вагон «бөркет» дип атала. Аны күрергә язмасын, Ходаем! «Бөркет» үз артыннан ияреп килгән бүтән вагоннарны тростан йолкып ала, рельстан чыккан йөкле вагоннар бушларына барып сылана. Алар да үз чиратында, бер-берсен ияртеп, түбәнгә очалар. Аркылы-торкылы убылган, ауган вагоннардан ат башы дәүмәлеге ташлар ядрә кебек оча, бәрелүдән очкыннар чәчри, буш вагоннар, йөкләләр астына калып коймак булып изеләләр, чиныйлар. Аста эшләүчеләр куркып акырыша-акырыша якякка чабалар. Унлап-егермеләп вагон түбәнгә төшеп сылангач, җир тетри. Җилсез, эссе чокырда тузан болыты әкрен генә, озаклап иңә... Эш туктала, карьер гүли, чиный, акыра...

Известь төягән чаклар күп булды, җәһәннәм газабы, әмма «кәҗә»нең ничек төшкәнен күргәнем булмады. Әле сүрелеп тә өлгермәгән эреп ябышкан таш-төер янына кысылып мичкә кергән, көннәр буе лом белән, чүкеч-чөйләр белән җәфаланган тоткыннарның кан төкереп ютәлләүләре, туктаусыз су чөмереп эч китеп җәфаланулары хәтеремдә. «Бөркет» очканны бер күреп калдым, бүтән күрергә язмасын, Ярабби...

Очып барган буш вагон ян басмадан ваемсыз гына төшеп барган ике тоткынның измәсен изгән иде. Кайларда гына сагаламый адәм баласын лагерьда әҗәл?!

Чәнечкеле авыш койма өчен дә, «Бруно спирале» өчен дә бик яхшы түлиләр; норма үтәлә, норма үтәлмәсә, лагерь хуҗалары аксак-туксакның җанын алыр иде! Күмер, цемент, агач төягән вагоннар килгәндә, безне чакырып алалар, бушатабыз, әвеш-тә-

веш китерәбез, әмма төп эшебез һаман зонаны ныгыту. Безнең эш бара, таш чыгару нормасы гына үтәлми! Алты вагон таш төяү җанны ала торган, җелекне суыра торган норма. Такы-токы ашап, ел тәүлегендә юньле ял күрмәгән «доходягалар» тагын да шыраеп калды, кабыргаларын әллә каян санарга була! Безнең бригаданы да карьерга төшерделәр. Без дә ломнар, киркалар алдык, чагыштырмача яшьрәкләр, тазараклар таш вата, таш төйи, чуттан чыкканнар вагоннарга таш катламнар арасыннан чыккан туфрак-балчыкны төяп озата. Бер атна эчендә бригада күтәрәмгә калды. Техноругыбыз Штуккерт дигән немец беркөнне бригадирларны эстакадага, санаучы утыра торган бүлмәгә җыеп алды. Литвалы Эдуардас Бринклис, бандеровчы Илья Марусяк, бүтән бригадирлар бар, арага мин дә кысылдым...

План үтәлми, тоткыннар 1953 елның җәе икәнен, язмышларында кискен үзгәреш буласын сизенәләр, эленке-салынкырак эшләргә, саулыкларын сакларга тырышалар, филонить итәләр.

Технорук Штуккерт, печән кибәне хәтле гәүдәсен як-якка авыштырып йөри торган Идел буе немецы, үзе дә сөрелгән адәм, күзәтү астында яшәүче кош, безгә мондый тәкъдим ясады: «План үтәлми, план! Аны үтәмәскә безнең хакыбыз юк. Болай итәбез: арадан җиде-сигез егетне сайлап аласыз, кулларына күсәк тоттырасыз, бригадаларга бүленеп, алар арада йөреп торалар. Элеккеге тоткыннар белән без гел шулай эшли торган идек. Күсәк ул... бөтен планнарны үтәтә!» Мондый сүзне ишетеп бригадирлар бер мәлгә югалып калдылар. Күсәк белән тукмаганны моңарчы безнең күргән юк иде. 1953 елда, тиран Сталин үлеменнән соң, бер-беребезне тукмап эшләтәбезме? Колыманы, Жизказган, Кингир, Магадан лагерьларын үткән, сыналган эшчеләрне ярабызмы?!

Бригадамның карт-корыларын карьерга куып төшергәне өчен болай да ачуыма буылып, Фунтиков белән әреплешеп йөри торган мәлем иде, каян күзем төшкәндер,

каян кулыма эләккәндер, берзаман балта тотып, яман сүгенә-сүгенә каһәрләп Штуккертны эстакада буйлап өерләп куа башладым. Шөкер, егетләр тиз тотып алдылар. Штуккерт та егет икән, зонага белдермәде, моннан соң безнең бригада тирәсендә бик күренеп тә йөрмәде. Бригадамдагы җимерек кашлы, бөтен битен мамык-йон сарган Чуянов дигән бәндә Фунтиковка әйткән әйтүен, ул да эшне зурга җибәрмәде. 1953 ел! Үзгәрешләрнең беренче карлыгачлары килгән көн: чит ил тоткыннарына Красный Крест аша илләренә хат язарга рөхсәт булды, ә лагерьга ак кәгазь, каләм, кара китереп тутырдылар. «Үз эшегезне карауларын сорап җирле прокурорлардан башлап Генеральный прокурорга кадәр дәгъва сүзегезне яза аласыз», — дип белдерделәр. Волынкада күпчелегебез яшьләр идек, асылда бандеровчылар, литвалы «яшелләр» иде. Аерым кисkенлекләрне искә алмаганда, без үзара тату яшәдек, дияргә була.

Вакыт — әйткәнемчә, берчакта да адәм акылы ирешә алмаган берәмлек ул. Вакытның башы-азагы юклыгы адәм акылын һәр заман түндергән. Гасырлар, формацияләр алышынып торса да, беркем Вакытка хуҗа була алмаган, аны иярләргә тырышкан тираннарның да Вакыт серен ачарга гомерләре җитмәгән. Вакыт — көчкә, акылга, ихтыярга, тылсымның барлык төрләренә баш бирми торган каты берәмлек ул. Бу хакыйкатьне Казакъстанда йөргәндә аермачык аңладым. Казакъстан бу юлы тагын бер ачы хакыйкатьне каныма сеңдереп озатты...

Милләтнең иң зур байлыгы — ХӘТЕР. Уртак хәтерсез милләтләр, милләт булудан туктап, гавам, халык төркеменә әйләнәләр. Уртак ХӘТЕР уртак җир булганда гына сакланадыр, мөгаен. Милләтләр туктаусыз уртак хәтерләрендә эзләнәләр, Хәтер шаһиты булырлык гап-гади чүлмәк китекләренә дә табыналар, усал заманнар чәчкән хатирәләрне берәмтекләп җыялар. Милләт яшәешендә буыннарның төрлесе булып узган, берәүләр милли дан хәзинәләрен иҗат иткәннәр, алмаш буыннар уй-байлыкны ишәйткән, тарихның авыр юлларыннан бар булганны түкми-чәчми алга эткән. Тарихның иң аяусыз мизгелләрендә империяләр, тираннар Хәтернең үз властьларына комачаулаган өлешен таптап изәргә, күмәргә тырышканнар. Һәм күп очракларда максат-

ларына ирешкәннәр. ХӘТЕР — чәрексез* хәзинә! Октябрь революциясеннән соң усал-

лыкта бары тик коммунистлар партиясе белән генә янәшә куярлык коммунистларның төп эше шул булды: алар, көчләп, алдап-йолдап, куркытып, асып-кисеп, ялган вәгъдәләр биреп, милләтләрнең ХӘТЕРЕН аста, коммунистик кара дулкын астында калдырдылар.

Хәтер югалтуларның иң аяусыз мисалы — бериш халыкларның үз илләреннән чит җирләргә сөрелүе. Үз илләренә кайтырга рөхсәт ителгән төп масса әллә кайчан ата-бабаларының җиренә кайтып урнашкан, ә мин Караганда якларында, автобус тукталышларында байтак кына ирле-хатынлы, бала-чагалы чеченнарны күрдем. Калганнар, яшиләр. Авызларына сугып аңлатып булмый...

Караганда — килмешәкләр шәһәре. Шәһәрнең үз төсе, үз мәгънәсе юк. Мин барында шахтерлар бәйрәме үтте. 26 август иде. Бәйрәм — әмма милли бәйрәм түгел. Корама халык. Вокзалдагы сыман очраклы гына җыйналган гавам. Зәңгәр бәрхет камзуллар кигән өч-дүрт татар хатыны. Шундый ук камзул кигән гармунчы ир, әниләренең күтәрмә үкчәле күн итекләрен сөйрәгән, аксыл чырайлы, баз бәрәңгесенең үсентеләренә охшаган ике малай күренеп калды. Чыгышларыннан соң яннарына барырмын дип көтеп торганда, җитез генә бер марҗа килде дә тегеләрне өерләп каядыр озатты. Күздән югалдылар. Бәйрәм гел урысча барды, бөдрә чәчләрен картуз астыннан тузгытып җибәргән казакъ егетләре арасында, шулай ук лампаслы чалбарлар кигән җирле казакълар да казакъларның уен җырларын җырладылар, менәргә атлары булмаса да, чыбыркы шартлаттылар. Профсоюз вәкиле вата-сындыра казакъча ике сүз әйтте дә, шуннан ары казакъча ник бер җыр, ник бер көй яңгырасын...

Килмешәкләрнең беравык уртак язмышлары булуы ихтимал, аларның уртак хәтере генә була алмый. Чөнки Хәтернең һәрчак милли төсмере була... Казан татарларын Сталин чорында сөрмәделәр. Гәрчә 1943 елда, Кырым татарларын куып җибәргәч, Казан татарларын да Урал аръягына сөрергә дигән карар кабул ителгән булган. Нидер

тоткарлаган, кемдер тыйлыктырган. Моны ачу, ачыклау киләчәк буыннар эше. 1944 елда, татарның язмышы кинәт үзгәреп, университетта татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ачыла, консерватория, татар театр училищесы, театрлар гөрләп эшли башлый. Газеталарда урыс маршалларының, генералларының, татар солдатларының гайрәте, антка турылыклы булулары хакында хәбәрләр даими күренә башлый. Озакламый Фәннәр академиясенең чираттагы сессиясенә «Казан татарларының килеп чыгышы» дигән махсус чыгышлар әзерләнә. Казан татарларының тарихын бүтәннәрдән аералар. Шул ук чакта Казан татарларына каршы килүче төркем дә тик ятмый. Үзәк Комитетның карарында татарның милли Хәтеренә нык кына кизәнеп алалар. Милли Хәтер бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала һәм буыннар дисбесенең бөтенлеген, тулылыгын саклый.

Караганда — килмешәкләр шәһәре. Анда яшәүчеләрнең уртак Хәтере юк. Моңарчы алар моны белми. Белсәләр, аңласалар, шәһәр казакъ милләтенә, ил хуҗаларына йөз тотар иде.

Килмешәк халыкның хәтере кыска! Җирле халык та килмешәкләр белән тыгыз аралашкач, аның да хәтере җуела, ул үзе дә сизмәстән хәтерсезгә, килмешәккә әйләнә бара! Ярты сәгать вокзалның иң кайнаган җирендә әйләнәм-тулганам, ничәмәничә кешедән сорашам, берәүнең дә «Волынка таш базлары» дигәнне күргәне дә, ишеткәне дә юк икән. Иңнәрен генә җыералар, белмиләр. Затлы гына киенгән зыялы кыяфәтле ике хатын кызып-кызып төзелешләр, нормативлар турында сөйләшәләр иде, яннарына барып сүзләрен бүлдердем. Йа Ходай, кирәкле кешеләр, төзелеш материалларына караган ниндидер идарәдә эшлиләр икән. Алар да кырт кисте: «Юк, булганы да юк Волынкада карьерның!» — диләр. «Киров урамында, фәләненче йортта, нерудный материаллар белән җитәкчелек итүче бүлек бар, алар янына барып карагыз... Гәрчә өлкәдә унөч карьер бар, Волынкада таш чыгару урыны юк!»

* Ч ә р е к — башмак (диал.).

«Волынка!» — дигәч, диспетчер кыска гына: «146 нчы автобус!» — диде. Кассада да икеләнеп тормадылар, билет тоттырдылар. Бу ни хәл? 146 нчы автобусны көтүчеләр янына бардым, сораша башладым, тегеләр дә аптыраашта калды. «Волынкада карьер юк та юк, якын-тирәдә дә юк, Волынкада дуңгыз үрчетү комплексы гына бар», — диләр. «Нинди карьер? Нинди төрмә? Каян килсен анда лагерь? Бутыйсыз, гражданин!» Берсе юантык кына марҗа, икенчесе сынык тешле казакъ хатыны (ире бүләгеме?): «Ундүрт ел шунда дуңгыз багабыз, бернинди дә карьер юк анда, бушаган урыны да юк!» — дип чатнатып торалар. Җыелган халык безне урап алды. Хәрбиләр бар, кызыл чырайлы, куна җилкәле полковник янында ике капитан, туклар бар, ябагайлар. Утызлап кеше булдык, беравыздан: «Юк таш базлары!» — дип ышандырырга тырышалар. «Тоткын чагымда үзем шунда эшләдем!» — дип әйтеп карыйм, тегеләр миңа айдан төшкән сурәбәткә карагандай карыйлар... Арадан кемдер: «Сарань тирәсендә андый нәмәрсә юкмы икән?» — дип, кыюсыз гына әйтеп куйды. Бу сүзне мыекка чорнадым.

41 нче номерлы Актаска йөри торган автобус шоферы белән киңәшеп карарга куштылар. Анда чаптым. Шофер тар маңгаен каты җыерып озак кына уйланды, өзеп сүз әйтә алмады. Бик озак эзләнгәч, РТИ заводын телгә алды, «Зират артында андый нәмәрсә юкмы икән?» — дип куйды. Монысын да истә тотарбыз.

Кая югалды бу таш базлары? Меңнәрчә кешеләрнең язмышын үз учында тоткан, япон, немец әсирләре ачып җибәргән дәһшәтле Волынка карьеры халык хәтерендә калмаган иде. Карьерның язмышы — килмешәкләр кулында. Теше сынык хатыннан башка җыелганнар арасында бер генә казакъ та, төрки дә юк иде. Нибарысы утыз алты ел үткән, мин карьердан 1954 нең мартында киттем. Миннән гөрләп эшләп калды... Онытканнармы? Оныттырганнармы? Дөньяда мин барын искәрмәгәннәр алар! Язучы — илләрнең, җирләрнең, милләтләрнең Хәтер сакчысы икәнен абайламаганнар!..

Урынга барып җиткәч күз күрер дип, 146 нчы автобуска кереп утырдым. Халык ишле, тыгыз, яныма баскан полковниктан кыйммәтле Париж исләре килә, димәк, акчаны мул ала... Барабыз, барабыз... Шул ук чокыр-чакырлар, исемсез чокырлар, исемсез басулар, исемсез сукмаклар. Юк инде монда Карама-куыш урманнары, Басу артлары, Чуал, Чүке үзәннәре... Мөхәммәт Мәһдиев җырлаган Масра кыры да юк, Кесмәс үзәннәре дә юк. Монда инде шигъри җанлы затлар тумый, килмешәкләр, тормышны тапкырлау җәдвәле генә үлчи алырлык кәрлә җаннар туа. Байлык коллары, җәзачылар, караклар, көчләүчеләр күбрәк килмешәкләр арасыннан чыга да. Килмешәк рухына баш биргән, иманын алыштырган адәмнәрдән кемне көтәсең?! Барабыз, барабыз, күз тукталып сокланырлык бөтен бер җир юк, иген кырлары да күренми, ватык-потык, актарылган, кантарланган ертык җирләр, ызаннар...

«Волынский агрокомплекс» дип язылган такта сулда калды, автобус бераз тәгәрәде дә мин Ново-Дубовка дигән авыл каршысында төшеп калдым.Авыл исеме җанымны җылытмаса да, тактада «Волынка» дигән таныш сүз бар лабаса! Казакъстан уртасында авылга «Ново-Дубовка» дигән шөкәтсез, тешкә тия торган битараф исем биргәннәр.

Юлда килгәндә автобуска ике егет утырганнар иде, минем белән алар да төште. О бәхет! Икесе тиң карьерда таш тишкән егетләр икән! «Тоткын идегезме?» — дип сорарга базмадым. И бәхет! Дөнья йөзендә Волынка карьерын белүче дә калган икән әле! «Сарань тирәсендә түгелме, РТИ заводы ягасындамы?» — дип эзләшкән шәфкатьле җаннар да кыек атып туры тидерә язганнар, шулай икән, таш базлары шунда икән! Тиз генә Актаска кайтып, аннан 90 нчы автобус белән башта Сараньга барырга кирәк икән миңа...

Киттем. Актас уртасында басып торам. Дубовка егетләре таш базларының урынын аңлатсалар да, куанычтанмы, мин алар сызган картаны ачык кына күз алдына китерә алмадым. Аннары ташландык карьерга ничек, нинди юллар белән барырга була? Сараньга баручылар шактый җыелдык, авызым тик тормый, туктаусыз сорашам, һәм,

иң гаҗәбе, тагын шул ук «белмәүчеләр» боҗрасына кереп батам. Күпчелеге Са-

рань кешеләре, урыс-улак, бүтән милләтләр, казакълар берәү дә юк, берсе дә Волынканы белми, карьер турында ишеткәннәре дә юк икән. Мондый туң, килмешәкләр төркемендә һәрчак миһербанлы, ярдәмгә атлыгып торучы бер җан була. Төсе-бите белән яһүдкә бик тартым, чал чәчләрен матур итеп баш очына өеп куйган бер ханым кычкырып уйлана башлады. «Таксистлардан сорашып карагыз, алар белсә беләр... РТИ заводын искә алдылармы?.. Ай-һай, белмим...» Карчык РТИ заводына ничек-ничек барырга икәнен аңлатты, автобус номерларын кат-кат кабатлады.

Автобуста бер нәрсәне ачыкладым: «Мин зек-тоткын идем, үзем шунда эшләдем», — диюгә, юлдашларымның мие түнеп китә икән, берьюлы аңгыраялар... «Нинди лагерь булсын анда? Язмаганны...» Үзем булган лагерьларны санап күрсәтәм, тегеләрне ышандырырга телим, кире нәтиҗәгә генә ирешәм. «Карагандада Федоровка, Михайловка лагерьларында булдым», — дигән идем, бер ир аламасы мине гаепләргә үк керешге! «Илле ел Михайловкада яшим, бернинди лагерь-төрмәләрне белмим. Булганы юк аларның. Әнә Долинкада лагерь булган, хәзер дә бар!» Авызына сугасыңмыни, «Михайловкадан ГШО заводына эшкә йөрдем», — дип әйтеп карыйм, ышанмадылар, тәки ялганчы булып калдым.

Беркем бу тирәләрдә тоташтан дәһшәтле, канлы лагерьлар булуын хәтерләми, адәмнәр бүгенге, кичәге өзелмәс ыгы-зыгылар белән чикләнеп, хәтерсез, тарихсыз йомылып яшәп, үзләренең хайван хәленә төшүләрен искәрмәгәннәр. Өченче көнгә әйләнеп кайту, тарих сабакларын тәкрарлап акыл алу юк, аны кирәксенмиләр дә. Хәтер югалган, күмелеп калган. Моның өчен бичара адәм балаларына үпкәләргәме? Әллә аларның бүгенге кадерсез заманда тарихка, үткәннәренә төкереп карауларын хаклы дип санаргамы? Бүгенге нужалы тормыш тәбәсендә тырпылдаган халык әгәр үткәннәрнең карасын да җыеп сакласа, аның йөрәге ничекләр чыдар? Шулаен шулай, хәтерсез калган, үткәннәрнең ачы сабагын оныткан ил өстенә тагын бер явыз тиран менеп атланса?

Тираннар хәтерсез: алар буталышларны яраталар һәм шундый болганчык суның дулкыннары булып өскә калкалар да! Тар маңгайлы Язов диктатор булу турында уйламыймы? Нәкъ үзе инде, коеп куйган, төс-кыяфәте белән ахмакларга охшаган...

Лагерьларда чакта үзем дә томана сарык булганмын, Актастан Карагандага чаклы ничә чакрым, дип тә сорамаганмын инде! «Сарань, Сарань!» дип мең тапкыр колагымны ярып керсә дә, кайда ул төбәк, кай тарафларда урнашкан, белми калганмын. Безне һәрчак конвой — почетлы эскорт каршылаган, җилкәгә мылтык терәп шулар озаткан, ә без, Сталин сарыклары, кая кусалар, баш иеп, сөрлегеп барганбыз да барганбыз. Юк, бөтенебез сарык булганбыз, димим, көфер сүз ычкындырдым! Актастан качкан теге төркемне хәтерлисезме? Үткен, елгыр казакъ егете К., төбәкне нык белүче, халык белән үз телендә сөйләшүче. Зонегин диңгезче түгел иде микән? Литвалы шофер, теләсә нинди машинаны йөртә. Толя Кузовкин кыю, чая, тәвәккәл! Ялгышмасам, Абдулла Али-казы япон шпионы иде, ул ике тапкыр совет чиген үтеп кереп кире чыга алган, өченчесендә килеп капкан батыр егет иде! Алар Актасның да, Сараньның да кайда икәнен картографлардан да шәп белгәннәрдер, мөгаен!

Салмак акыллы шул мин, яхшы уйлар һәрчак соңарып килә. Күт астындагы карьерның нәни генә координатын да белмә инде! Ә яһүдә юл буе минем өчен борчылып барды, исенә төшерде: туганнарыннан кемдер «җәйге ялын карьер янындагы күл янында үткәргән икән» дип, тагын бер мәгълүматны хәтерләде. Ял урыны? Волынка?..

Теге Дубовкада очраган егетләр нидер бутаганнар, ахрысы, таш базларына дип, мине Казакъстан курортына җибәргәннәр икән! Нинди ял?

Юлдашларым җанланды, автобус бәхәс учагына әйләнде, сорашу китте, тегеләй диләр, болай диләр, берсе әйткәнне икенчесе юкка чыгара, баш буталды!

Сарань кешеләреннән берсе дә мин эзләгән лагерьны белми иде.

Ниһаять, безнең Әлмәт, Лениногорскиларны хәтерләткән төссез шәһәргә барып җиттек. Сарань икән. Уртакул йортлар: ике-өч катлы, ян бакчаларында көнбагышлар үсә, автовокзаллары моңсу гына... Яһүдә мин күрмәгәнне күреп алган: «Әнә такси

килә!» — дип кычкыра-кычкыра артымнан теркелди. Таксист ике сүз белән табышмакны чишеп бирде: «Монда бик күптәннән таш чыгармыйлар. Барын бар...» — «Барыйк!» — дип ялварам. Карагандага кайта икән, ашыга. Тукталышка ирле-хатынлы икәү килде, телләренә колак салам: чеченнар... Чечен хатыны да карьерны белә икән: «Ерак түгел, монда гына ул!» — ди.

Хәзер мин тыныч, яһүдә карчык һаман мине күзәтә икән, баш орып аңа рәхмәт укыдым...

Менә мин такси яллап карьерга юл тотам. Чечен хатыны шоферга юлны өйрәтә. Килешенәбез: бару-кайтуга икеләтә түләргә булдым. Тар, җимерек асфальт юлдан барабыз. Каралмаган ташландык юл. Сулда шактый зур мәйданны биләгән зират кала. Дәү-дәү тәреләр, хачлар. «Ә мөселман зираты кайда?» — дип сорыйм шофердан. Ул аптырап миңа борыла: «Нинди мөселман?» — «Казакълар, татарлар да күп ич монда. Әнә чеченнар да бар икән!» Шофер елмая: «Һәммәсе бергә аралашып яталар, бездә халыкларны аеру юк». Нигә бу Караганда, Сарань-Актаслар шушы кадәр котсыз дисәм, мәсьәлә ачыкланды: әйе, бу төбәк шәһәрләренең милли төсе юк. Чиркәү-мәчетләр юк монда! Тарихны отып калган ташлар, биналар да юк — әллә адәм уллары яши торган кала, әллә җен-пәриләр аймагы... Иман нуры таратып утыручы, яныннан үткәндә сабырланырга, дөньяның фани икәнен искә төшерергә мәҗбүр итүче гыйбадәтханәләр юк икән бу яңа калаларда! Җаннарын җир белән күк арасында адашып йөрергә очырган догасызлар зиратларда көрмәкләшеп, бергә укмашып яталар икән! Бу имансыз рәт араларына фәрештәләр ничек кунсын? Айлы төннәрдә әрвахлар ягаларыннан кубарылып чыккач, кяферләрне күреп ни уйларлар? Берзаман Казакъстанның күмерен чыгарып көл итеп бетерерләр, уран запасы Җир шарында исәпләнгән, күпкә бармас, шәһәр урамнарына тагылган исемнәрнең кем шәрәфенә тагылуы онытылыр... Ни калыр алдагы буыннарга? Әнә ич, кайчандыр төбәкне таш, известь, вак таш белән тәэмин итүче атаклы карьерны утыз-кырык елдан соң берәү дә белми...

Зиратны узгач, уңга, чокыр-чакырлы юлга борылдык. Сулда җәелеп яткан зур күл

ялтырый. «Балыклы», — дип аңлата шофер. Күлнең аргы ягында РТИ заводы. Без ава-түнә, чайкала-чайкала барабыз. Юл аулак, дала буш. «Караганниклар кая китеп бет-те?» — дип сорыйм. «Себеркегә тунап бетерделәр, калмады». Як-ягыма каранам, ма-шинаны узып алга карыйм, бер таныш сызык, нокта эзлим. Күккә багам, анда да ят болытлар чайкала. Поселок та юк, японнар салган иде аны, шуннан беләм, без килгән-дә, поселоктагы мичләр, корым, сөремгә тончыгып, өйдәге һаваны бозып утыралар иде. Эзләп караганнар, якын-тирәдәге бер генә мичче дә японнарның серенә төшенә алмаган. Бригадабызда Романас фамилияле сабыр гына латыш бар иде. Хикмәт иясе иде, валлаһи, белмәгән эше юк... Япон осталары чыгарган мичләргә бер-бер артлы җан өреп чыкты...

Дөрес барабызмы без?

Каршыдагы тауга борылганда, уңда, агачлар арасында, таштан салынган, өсте җи-мерек, тәрәзә урыннары төтеннән каралып торган корылма калды. Чәчрәп исемә төш-те: «Бу без сала башлаган кибет түгел микән, кайтканда тукталырбыз әле», — дидем. Алдыбызда нинди ят тау бу? «Карьер шунда булырга тиеш», — дип аңлатырга тырыш-ты шофер. Шунда? Таш базлары тауда түгел иде ләбаса? «Теге бинаның алгы ягында ике аркасы булса, кибет булыр ул, без нигезен салып, стеналарын күтәрә башлаган идек», — дим, һаман шул таш хәрабәгә кайтып. Бүтәнчә монда миңа таныш, мин белгән бер генә нәрсә дә юк. Юл, борылып-сарылып, текә үргә менә башлады, үлән сарган балчык-таш таучыкларны үттек һәм машинабыз текә, биек яр өстенә үк менеп туктады. Мин машинадан төштем дә телсез калдым...

«Телсез калдым» дип моңарчы да язганым бардыр, бүтәннәр дә адәм баласының соң дәрәҗәдә киеренке, гайре табигый мизгелләргә дучар вакытын шушы сүз белән аңлата торганнардыр. Безнең тормышта андый хөкем чыгарырга җай табылып кына тора. Ләкин мин үз гомеремдә беренче тапкыр телсез калдым. Халәтемне, шул минут-лардагы тәэссорат көчен нинди сүзләр белән аңлатырга? Моңарчы мин кулланган сүз-ләрнең бүген егәре җитәрлекме? Басым көчләре калганмы?.. Сүзләр хыянәтче дә алар,

син бер нәрсә әйтергә җыенасың, алар, бозылып, икенче мәгънә төсмере биреп ишетеләләр. Бүген мин сүзләрдән корыч коярга тиеш, җөмләләрем авыр, саллы һәм үтемле булсын!.. Бүген мин укучымның мине аңлавын сорыйм. Үтенәм! Тәңрем, бүген миңа укучым белән уртаклык бир! Тагын кайда аңлаша алабыз без икәү?! Чын, хак, гадел сүзләремне монда әйтмәсәм, мин кайда әйтәм?! Әгәр укучым мине шушы хәлдә аңламый икән — тагын нигә өметләнергә мөмкин? Җанымның тәнемнән аерылып, баш очында мең нур җебенә таркалып янып торуына укучым ышанырмы? Хак, мин мәтәлеп каядыр очтыммы, әллә күз алдымдагы шомлы упкынга төшеп киттемме, аңышмый калдым. Күз күнеккән, 1954 тә хушлаша алмыйча да китеп барган таш базы шушы хәлгә җиткәндер дип уйламаганмынмы, белмим, мәгәр минем андый дәү, төпсезтирән чокырны күргәнем юк иде. Иң гаҗәбе, шушы чиксез зур, тын, кешесез чокыр хәзер җанлы иде, аның текә-текә ярлары зәңгәрсу рәшә булып тирбәләләр, меңнәрчә ермаклардан, астан, миңа таба мең төрле тавышлар илереп үрмәли иде. Перфоратор чүкечләр гөрли, таш яңакларына чап-чап калуннар очып төшә, вагоннар, рельсларны сытып, такта эстакаданы изеп, елаша-елаша өскә менәләр... Шушы җәһәннәм авазлары арасында өрәк сыман тын гына йөзләгән кешеләр эшләп йөри... Күземне кысып йомып, тавышларны сүндердем, алай да колагым, тирә-ягымдагы көчле басымга чыдый алмыйча, озак кына чыңлап торды.

Аңыма килдем, мин биектә, биектә, текә ярлар өстендә, очып китәргә талпынып, хәлсезлектән канатларын кага алмаган карт бөркет шикелле талпынып торам. Әгәр бер читкәрәк китеп шым гына чүгәләгән шофер һәм кызган тимер исе чәчеп торган машина булмаса, мин үземне бүтән бер планетада дип уйлар идем. Аста күзем колачына сыймаган, киноларда гына күргән вулкан кратерымы, җир убылганнан калган тирән-тирән күл җәйрәп ята. Күл уртасына җыелган акчарлакларны тиз генә абайламадым, әле тирә-якның бер чагылышын да аерып күреп булмый: дөнья — җир вә күк — күзләремә тоташ кереп бетә; таш-балчык, үләннәр — һәммәсе, сыеклыкка әйләнеп, күзләремә ага... Әллә елыйм инде?.. Юк икән, мин елый да алмыйм — елый алу,

җиңеләю тойгысы да югалган... Бераз иялəшкәч, шәп-шәрә ярларны аердым, ташбазның биек, түгәрәк тау уртасында, төптә калганын аңладым. Таш чыгарганда артып калган балчык-комнардан өелгән икән бу ялган тау. Шушы кадәр балчык артсын өчен күпме таш чыгарырга кирәк булгандыр?!

Без эшләгән чактагы таш базыннан ник, ичмасам, бер багана, ник бер бина, ник бер хатирә калсын — бөтенесе җимерелгән, кырылган, югалган, күмелгән, сүтелгән, ташылган — юкка чыгарылган!.. Ялгыштыр ла, без эшләгән карьер түгелдер бу, миңа юл эзләшкән йөзләгән җылы җаннар онытканнардыр, саташалардыр гына!.. Карт күзләремнең соңгы өмет нурларын түгеп эзлим, эзлим, уңда, зәңгәрсу ераклыкта, тау артында үзәндә, шакмак-шакмак дача йортлары тирбәлеп утыра. Миражмы? Саташаммы? Теге яһүдә карчык: «Ял иткәннәр... күлдә коенганнар!» — дигән иде. Әллә шунда төшеп сорашыргамы?.. Анда да шул х ә т е р с е з гавам-килмешәкләр оя кормаганмыни?! Таш базын япон-немец әсирләре ачканын белми булыр алар... Йөзләрчә солдат, офицерларны сыйдырган поселокны да алар башлап җибәргән, Алла каһәрләгән шушы ташландык җәһәннәм чокырында меңнәрчә тоткыннарның күп еллык хәсрәте убылып калганын уйламый да булыр дачник килмешәкләр! Рәхәт, ваемсыз яшиләрдер алар! Әгәр мин дә шушы таш базның төбендә сөзелеп калган авыр серләрне белмәсәм, йөземне кояшка куеп, шаккатып, ерак офыкларга таң калып тормас идеммени? Монда булып үткән елларның, шул еллар кол иткән буыннарның, үлгән, чирләп егылган, җәфаланган йөзләрнең язмышы минем иңемне басып тормаса, бәлки, мин дә бүтәнчә уйлар идем. Кеше бер минутлык ләззәт белән алданып яши, күпләр үткәннәр һәм киләчәк турында уйлап карамыйлар, бәлки, бу сыйфат адәм улларының иң зур бәхетедер?

Күңелем ничәмә-ничә еллар иңемә басып торган котылгысыз хатирәләрдән котылырга теләп илереп елый, күз алдым ачыла дисәм, тагын да куерак караңгылана, мин, аска мәтәлеп төшүдән шүрләп, артка тайчынам. Күкне кояш биләгән, болытсыз, җылы. Күл көзге кояшның уклы нурларын миңа таба кайтара, мин, сукыраеп, күзләремне

чытырдатып йомам; йомсам да, тирә-як, минем һәм йөзләгән тоткыннарның гомере, яшьлеге ап-ачык күренеп тора. Бер тавыш, хәрәкәт, кош-корт юк. Ятып, үрмәләп, тураеп үскән әремнәр, чәнечкеле үләннәрдән таралган исләр, тирбәлә-тирбәлә, миңа килеп җитәләр, тирбәтәләр, сабырланырга өндиләр. Шофер ярга якынрак килгән иде, йодрык таш аска тәгәрәде, әмма суга төшеп җитә алмады, арып, чокырчыкларның берсенә сеңеп оялады. Акчарлаклар мине каршылар өчен теге күлләрдән дә килгәнме? Алар шактый күп, түгәрәк ясап, борыннарын уртадагы буш боҗрага сузып тирбәләләр. Диңгез акчарлаклары давылларда һәлак булган морякларның җаны, диләр. Әллә болары шушы якларда әҗәл тапкан тоткыннарның җаннары микән?..

1953 ел. Канлы тиран — Сталин инде дөньялыктан китсә дә, әле иске лагерь тәртипләре алышынмаган иде, кеше тулысынча кол иде.

Таш базлары! Таш җәһәннәм! Җәй! Кояш ярдәмче түгел, дошман! Таш үзе дә чамасыз кыза, тимер ломнар, чүкечләр, чөйләр ут булып яналар. Һава хәрәкәтсез, таш тузаны, бер күтәрелгәч, тиз генә утырмый, борын тишекләре, ирен читләре, күз тирәләре касмакланып ката. Кеше, таш базына төшеп ярты сәгать эшләгәннән соң, вакыт берәмлеген югалта, ул үзе дә ташкурчакка әйләнә. Сүз әйтсәң ишетми, өскә күтәрелеп карамый, күңелдә уй юк, анда да төссез бушлык, коллык кына... Ачлык эшләтә тоткыннарны, монда патша — ачлык. Бер генә кеше нормасын үтәмәсә дә, бригаданың паегын кисәләр, берәүнең дә иптәшләрен ач калдырасы килми, ул шушы җәһәннәм мичендә егылганчы яки җан биргәнче эшли. Кирәкми Штуккертның күсәкле егетләре, һәркем яшәргә, гомерен саклап калырга тырыша. Еллар үзгәрер, бәлки, туган илләргә исән-аман кайтып егылып булыр... Ачлыкка түзә алган кеше юк, озак еллар туя ашамаган кеше үзенең кешелек сыйфатларын берәм-берәм югалта...

«Телсез калдым», — дидем...

Ә мин ни көткән идем соң? Ни белән очрашырга омтылган идем? Гомумән, ни эзлим мин бу ташландык сукмаклардан? Булган-кичкән, үткән-беткән, югалган-онытылган. Әллә минем туймас җаным әнә шул «онытылу» белән килешергә теләмиме?!

Егерме ике яшьтән егерме сигезгә кадәр — аң иң тере чакта, иман иңеп, белем ныгыта торган дәвердә, минем гомер кирпеч заводының газлы, исле цехларында, ташбазларында үтте. Дөрес, ул дәверемне, «тоташ бәхетсезлек чоры» дип тамгалап, сызып ыргытырга җыенмыйм. Нindидер бер дәрәҗәдә мин үземчә бәхетле дә идем. Әти-әнием исән иде, эшләп ашыйлар, минем кулга калмаганнар... Мин илнең шундый елларын үз күзләрем белән күрдем, ил белән бергә газапландым. Бу дәвер тиз генә кабатланмас, еракка барып карый алмыйм, кабатланса да, ул бүтәнчә булачак, башка төсләрдә. Яшь чагымда иректә эзләгәнемне, якын фикердәшләремне үзем булып узган лагерьларда таптым мин. Төрмә-лагерь юлларын кичеп, истәлек-хатирәләр, әсәрләр язган бик күп авторлар: «Без нахакка утырдык, безне ялган, яла аркасында утырттылар», — дигән фикер үткәрделәр. Ә безнең «особый, без право переписки» лагерьларында, кешенең исеме югалып, номер гына тере булып калган каторгаларда, аңлы рәвештә совет властен кабул итмәгән, аның белән көрәшергә, совет системасын бетереп ташлар ләр утыра иде. Җитмеш процентыбыз әлерәк кенә көрәш кырларыннан тотып китерелгән бандеровчылар, украинлылар иде. Хәзер аларны «милли каһарманнар» дип йөртә башладылар. Ә нигә?.. Литвалылар, латышлар, эстоннар! Сталин тираниясенә көчләп кертелгән илләр... Совет империясенә каршы корал тотып чыккан асыл ирләр лагерьларда юк өчен утыра идеме?.. 1951 елның башында Карабас күчеш лагеренда элек ун ел төрмәдә утырып, икенче срогын башлаган грузин Александар Хурадзе миңа болай дигән иде: «Империя җимереләчәк... Совет власте юкка чыгачак! Без лагерьларда бер дә юкка утырмыйбыз...» Рәхмәт сиңа, Хурадзе агай! Синең сөйкемле чыраең, мине карцерга алып чыкканда надзиратель-палачка әйткән каты сүзләрең әле дә истә!..

Үз илләрендә сәяси төрмәләр булмаганга, Рәсәйнең үзәгенә, ташбазларына, рудникларга, шахталарга ябылган мадьярлар, болгарлар, немецлар, румыннар Сталинга баш бирмәгән өчен монда китереп ябылган иде. Иран коммунистлары, чик сакчылары палач-кызылармеецлар, айлык ял һәм биш йөз тәңкә бүләк алыр өчен, чик буе авылы крестьяннары кырда эшләп йөргәндә керәләр дә аларны бу якка сөйрәп чыгаралар.

Алар да безнең арада иде! «Төньякта искиткеч гадел, бай ил бар, ул Советлар иле!» дигән ялганга ышанып чикне үтеп чыккан Кытай крестьяннары! Бер чит тел белмәгән, укымаган, надан кытайларны егерме бишәр елга хөкем итеп особый лагерьларга тутырганнар иде. Якын дустым Хан-Жубо! Синең исемнән украин кызларына ничәмәничә хат яздым мин. Кайда икән син? Исәнме? Квантун армиясенең соңгы офицерлары! Власов армиясендә хезмәт итеп, Совет властеның ни икәнен нечкәлегенә кадәр аңлаган урыс егетләре! Сугыштан соң илгә кайткан шанхайлылар: Константин ага Добржанский, Юрка Кириллов, Спирин! Европадан илгә кайткан урыс дворяны Уклейн, Казачий генерал улы Сидоров!.. Сез ярата идегезме совет режимын? Кыскача гына бәяләгәндә, без барыбыз да Сталинның, Ленинның, Ленин нигез салган совет системасының дошманнары идек. Без үзара һәрнәрсә хакында һич куркусыз, ачыктан-ачык сөйләшә идек. Бу минем өчен бәхетле мәктәп булды.

Иректә чакта ук допросларга йөртеп мине шулкадәрегә китереп җиткергәннәр иде, үземне кулга алырга килгән КГБ полковнигы Катерлига: «Тизрәк төрмәгә илтеп тыгуларын үзем дә тели идем», — дигәч, ул күзен алартып бер карады да: «Дурак!» — диде. Газраил Катерли сүзләремне хәтерләми булыр, алай да кайткач очратып бер сөйләшергә дип йөрдем. Туры килмәде, башта исән икәнен белмәдем, соңыннан мәгълүм булды, моннан бер ай элек кенә Катерли үлеп китте. КГБ архивларында еллар буе казынып утырган профессор Литвин: «Явызларның явызы, кансызларның кансызы булган Катерли», — дип бәяләде. Бу өлкәдә аның белән килешмәү мөмкин түгел. Әйе, җүләр заманнарда акыллы булу кыен, җүләрлекләр дә булды, ялгыш-хаталар да ясалды, авыл малае, тәҗрибә юк, күп нәрсәне белеп тә бетермәгәнмен, әмма лагерь юллары күпне бирде, күпне татыдым, искиткеч аңлы, акыллы адәмнәр белән аш бүлештем.

1950 елның декабрендә Казаннан Карабаска этап белән барганда, Чиләбе, Свердловск, Петропавловск төрмәләрен үтеп, мин дөнья хәлләрен шактый тулы аңлый идем инде: Сталинның канлы тиран икәнен дә, Кировны ни өчен үтерүләрен дә, Серго Орджоникидзеның ни өчен үзенә кул салуын да ап-ачык белә идем. Вагондашларым мәскәүле

Яков Борисович Цудечкис, сөйкемле яһүд профессор Хинчин, гомере буе Тышкы сәүдә министрлыгында хезмәт итеп, гел-гел болытларга утырып йөргән карт яһүд Ольгерт, шикләнмичә, курыкмыйча, дөньяның икенче ягын ачып күрсәттеләр миңа. Юлда барганда, берзаман вагонның өченче сәкесеннән озын, какча буйлы, сеңердән генә торган нәзек муенлы, ләкин искиткеч сөйкемле, ачык чырайлы, татлы телле урыс, рязаньлы Митя Афанасьев килеп төште. Аның авызыннан Власов, власовчылар хакында байтак мәгълүмат алдым. Әсирлектән күп җәфалар чиккән язучы Әнәс Галиев, күптән түгел бер очрашканда, «Идел-Урал» легионын телгә алып: «Күпме татарны саклап калды Шәфи Алмаз!» — диде. Шәфи Алмазларны, Власовларны без бик бер яклы аңлап вә аңлатып киләбез. «Идел-Урал» легионы тарихы һәм аны оештыручыларның берсе Шәфи Алмаз үз өйрәнүчеләрен көтә. Алар хакында тарих үз сүзен әйтеп бетермәде әле.

Свердловск күчеш төрмәсенең тимер читлек-камераларын телгә алган идем инде. Үзеңнән тыш әллә ничә читлек тоткыннарын күрәсең анда. Безнең этап — сәяси тоткыннар читлегендә. Караклар шундый ук янәшә читлектә. Аларның тотышларын, кыяфәтләрен күреп, сүзләрен ишетеп хәйран калган, гел-гел чит илләргә йөреп эшләгән, эче-тышыннан затлылык бөркелеп торган карт яһүд Ольгерт, төймәләре киселгән, арык тәнендә асылынып торган чалбарын күтәрә-күтәрә, күзлеген рәтләп: «И эти люди наши, советские!» — дип имәнеп киткән иде. Каракларның берсе, читлек тимерләре аша кулын тыгып, аның борынына чиртте дә: «Не горюй, папаша, смерть Сталина всем нам принесет свободу!» — дип кычкырды. Игътибар итегез: бу хәл 1950 елның декабрендә булды...

Инде байтак еллар узгач, лагерьдан котылып Казанга кайткач, 1955 нең көзендә, хөрмәтле Ибраһим ага Нуруллин белән Ленин бакчасында очрашып (кирәк бит, урыны — ЧК бинალары каршысында!), мин аңа лагерь сабакларының кайберләрен сөйләп биргән идем. Ленин-Сталин хакындагы кайбер фикерләремне әйттем мин аңа, Киров, Орджоникидзе, миллионнарның язмышына кагылышлы фактларны телгә алдым, орто-

доксаль Ибраһим Нуруллинның чырае каралганнан-карала барды, ахырда ул түзмәде:

«Үзгәрмәгәнсең икән, лагерь сине төзәтмәгән!» — дигән нәтиҗә ясады.



Ибраһим ага! Әле синең «лагерьлар төзәтә!» дип ышана торган наив чагың иде. Мондый хөкем чыгаруыңа үпкәләмим, рәнҗемим дә, мине аңлавыңа гына сөенәм. Әйе,

бергә укыган елларда ук син минем уй-фикерләремнең кая таба юнәлгәнен белә идең,

минем хакта сорашырга сине Черек күлгә чакырмый калмаганнардыр. Ләкин син безнең барыбыз каршысында да якты йөзле булып калдың. Беребезнең эшендә дә синең гаепләү күрсәтмәләрең юк. Бу фикеремне монда калган иптәшләрнең күзе ачылсын дип

теркәп китәм...

Волынкада минем бригадада гаҗәеп шәхесләр бар иде. Маршаллар да, генераллар да юк иде югын, әмма Глинканың «Сомнение»сен үткәзеп җырлаучы аксак, табак битле, күзлекле Каськ Мееме Оскарович үзе ни торырлык егет иде! Кулыннан килмәгән эше юк: балта остасы, ташчы, буяучы... Аның кулалмашы эстонлы Койк! Аз сүзле горур латыш Романас! Мадьярлар Иштван Полачек, Немеш! Литвалы якыннарым: Борис Меркс, Людгарис Пакарклис, Медишаускас Йозос Йона! Кулын кесәләренә яшереп җил-җил йөргән яшь шагыйрь Буре! Синең «Как никогда» шигырен укуың һаман да колак төбемдә... Мине улы кебек итеп кадерләп йөрт-

кән сөйкемле, тыйнак урыс Лапаев!

Сезне юксынып килдемме шушы җәһәннәм авызына?! Мөгаен, шулайдыр. Ниһа-

five, килеп җиттем, эзләп таптым. Әле зиһенем ачык. Хәтерем нык, бик күп юлдашла-

рымның исемнәрен, төс-битләрен хәтерлим. Лагерьда берәүгә дә ачылып үткәннәрне

сөйләү юк, сорашмыйлар да, ләкин мин белгән кадәресе дә җитәрлек... Әгәр минем

күз алдымнан үткән вакыйгаларның төбенә төшеп, анда катнашкан шәхесләр үткән

юлны бәян итә калсаң... Юк, юк, бу бер кеше кулыннан килә торган хезмәт түгел.

Тарихның дәһшәтле җилләре безне дала дүңгәләкләрен өерләп йөрткән кебек йөртте.

Көне килде — без тагын күрештек менә.

Уйларыма йомгак ясап, җылы җил бөтерелеп алды, сирәгәйгән чәчләремне күземә

төшерде. Тирә-ягым ачы әрем генә. Аларның биек-биек үскәннәре бар, үрмәләгәннә-

ре аягыма урала. Төрлесеннән учыма учма-учма сындырып алып, түшемә кысам, тү-

шемә кысам!.. Кыргый дала исләрен саклаган әремнәр күңелемне нечкәртәләр. Мин,

егылып китмәс өчен, ярдан читтәге таучыкка бөгелеп, илереп үксеп елыйм. Тыелып

булмый, тыелырга теләмим дә. Тоткын иптәшләремнең күбесе инде бу дөньяны куй-

ганнардыр... Арада өлкәннәр, чаллар, нужа камытын күпме еллар муеннарыннан тө-

шермәгәннәр бар иде. Дога укып аларның бәхиллек көткән җаннарын җылыта алма-

дым. Мөселманнар, христианнар, католиклар, лютераннар, Иегова шаһитлары, шимбәгә баш оручылар — Букоемский белән Безродный, буддистлар! Мине ишетәсезме?! Шушы җәһәннәм чокыры өстендә очып йөргән саф җаннарыгыз хөрмәтенә мин бүген сезгә татарча гына эндәшәм! Саумысыз, туганнарым! Кадерлеләрем! Мин сезне сагынып килдем монда!

Уйладым: Ежов, Ягода, Берия-Рюминнар төзегән җәза системасы адәмнәрнең аңнарын юк итәр өчен яралган.

Уйладым: җәзачылар бер нәрсәне исәпләп бетерә алмаганнар: аңлы, уйлы дөнья

Аяз Гыйләҗев яңадан студент. 1956

балаларының бердәмлеген, бердәмлеккә омтылышын санга сукмаганнар. Төрмәләр Сталин чорының университетлары да иде!

Уйладым: әгәр бүген украин, литва, латвия, эстон халыклары империя коллыгыннан котылып баралар икән — төрмә-сөргеннәр үткән баһадирларның бу юнәлештә роле искиткеч зур. Төрмәләрдән котылып чыга алганнарның зур өлеше бу дөньялыктан күчсә дә, төрмә-зинданнарда да яши алган азатлык хисе халык улларында бетмәгән, җимерелмәгән дигән сүз! Әгәр бүген татар, якут, чечен халыклары тарих агышында үз милли дәрәҗәләрен исбатлап, офыкларына империя элгән караңгы хәтерсезлек пәрдәләрен каерып ташлап, азатлык даулыйлар икән — безнең, төрмә-зинданнар аша узганнарның, бу җәһәттә өлешләре юкмы әллә?!

Ирекккә омтылу хисен меңнәр төрмә-зинданнар кысынкылыгында саклап калмадымы әллә? Казакъстан чүл-далаларында, Колыма-Магадан туңлыкларында да ятып калганнар Әүлиялар иде, Әүлиялар!..

Дога көтеп, гүрләрендә һич җылына алмыйча зарыгып ятучы татар әүлиялары!..

Кара елларда, каргалган юлларда миңа юлдаш булган, күңелләренә сыендырган тоткыннар кебек үк якын сез миңа!.. Урыслар, яһүдләр, японнар, немецлар, балкарлар — дөньяның бөтен якларыннан большевизм камаган бәхетсезләр! Мин сезгә, һәрбарчагызга, искиткеч рәхмәтлемен: минем рухым бөтенлеген сез саклап калдыгыз, җаным-

ның Аллаһы Тәгалә биргән бөтенлеген ваттырмадыгыз.

Уйладым: сезнең белән — исәннәр вә күчкәннәр белән — уртак фикергә илтә торган мәңгелек хакыйкать бар икән, ул — вөҗдан һәм намус сакчысы изге китабыбыз Коръәни Кәрим. Ярты ел шул изге китаптан җанымның тартышларына җавап эзләп утырдым мин, бик күп ак фикерләр, юлымны яктыртырлык бөек эндәшләрне шуннан таптым. Җөмләдән берсен бүген теркәп китәм.

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Күчкәннәр вә калганнар рухына, йәгез, бер дога!

«Әләм тәрә кәйфә зарабаллаһу мәсәлә кәлимәтә тайибәтән кәшәҗәрәтин тайибәтин әслуһа сабит вә фәргуһа фис-сәмаи». («Ибраһим» сүрәсе, 29 нчы аять.)

Татарчасы болай:

«Гыйбрәтләрне мисалга китергәндә, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтле яхшы сүз әйтүен искәрмәдеңмени? Яхшы сүз таза агач кеби ул, тамыры нык, тирәнгә киткән, ә ботаклары күккә ашкан!»

Нинди бөек сүзләр!

Зирәк укучым, сизгәнсеңдер, сизми калмагансыңдыр: хәтеремә иңгән иптәшләрем, юлдашларым, фикердәшләрем, көрәштәшләрем хакында мин, Алла кушканча, ЯХШЫ, дустанә сүзләр генә әйтергә теләдем. Кабул кыл, Тәңрем!

Караганда—Казан—Переделкино

Август—октябрь, 1990



Үземчә яшәдем

Гомеремнең иң авыр елларын да сагынам

Рәмис Аймәт әңгәмәсе

— Син, Рәмис парин, миннән әңгәмә алыр-

га соңаргансың. Мин инде хәзер элеккеге Аяз

түгел...

Татарстанның халык язучысы Аяз Гый-

ләҗев белән әңгәмәбез нишләптер әнә шун-

дый, минем өчен көтелмәгәнрәк нотада баш-

ланып китте.

Аяз ага белән аның фатирында сөйләшеп

утырабыз. Ул йомшак кәнәфигә сөялеп

утырган да, телевизор белән идарә итү пуль-

тының төймәләренә салмак кына, иплэп ке-

нә баскалап, гомер сәхифәләрен алыштыр-

гандай, телевидение каналларын күчерә.

Хәсрәтне беләме балачак?

— Аяз ага, әйдәгез, әңгәмәбезне ерак-

тан — серле сукмакларда уралып калган ба-

лачактан башлыйк әле. Сез нишләптер әсәр-

ләрегездә гомерегезнең әлеге нарасый да, бә-

хетле дә булган мизгелләре хакында аз яза-

сыз. Бөтенләй юк, дисәм дә ялгышмам...

— Балачак дисәм, хәтеремә бер кызык вакыйга килеп төшә.

Җәйләрнең берсендә әнием ындыр түрендәге кыяр түтәлләре арасына барып кер-

гән. Мин, терсәкләремә таянып, артымны туңкайтып, борын очым белән җир сөреп,

чәнти бармак кадәрле үскән кыяр «малаен» кимереп ятам икән... Әни, соң дәрәҗәдә

гаҗәпләнеп: «Улым, кыярны нишләп ятып ашыйсың?» — дип сораган. Мин, аллыкүкле янып: «Үзең өзмәскә куштың ич!» — дип җавап биргәнмен, имеш... Җавабымны үзем хәтерләмим, әни сөйләвеннән исемдә калды, ул ышанып сөйләгәч, шул вакыйга балачагымның иң истә калган хатирәсе булып күңелемдә саклана.

Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән. Шулай уйлыйм.

Хәтергә нык сеңеп калган вакыйгалар шуны сөйли.

Әти урта мәктәптә химия, биология укыта. Иртә-кич бакчада казынырга нык ярата иде. Әнием Мөгаттәрә Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында туып үскән. Әти Минзәләдә педучилищеда укый башлаган, әнием шунда ук кызлар мәктәбендә белем алган. Минзәләдә танышканнар алар. Әтине эшкә Сарман районындагы Чукмарлы авылына билгелиләр. Әти әнине шунда, Сөләйман бабамның рөхсәтен ала алмагач, «ябыштырып» (урлап) алып китә. Сөләйман бабам, «кызыл кеше» дип, куркып ризалашмаган була. Соңыннан ул әтиемне бик хөрмәт итте. Әни бер-бер артлы өч малай табып өйдә утыра. Әтине, яшь мөгаллим дип, район читендәге Югары Баграж авылына укытырга күчерәләр. Авыл Зәй районы карамагына күчкәч тә безнең гаилә шунда калган.

Их, ул балачак хатирәләре!..

Иҗат, тәхет, тәнкыйть һәм... хакимият

— Мәгълүм гыйбарә: әдәбият ул — тормышның көзгесе. Ни генә булмасын, ул заман белән бергә атлый. Сез, Аяз ага, әдәбиятның үсешен һәрвакыт күзәтеп барасыз. Татар әдәбияты, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйлаганда, Сезне күбрәкниләр борчый, хафага сала?

— Дөресен әйткәндә, әдәбият хакындагы фикерләремне чыгарып салырга куркам. Чөнки әдәбиятка мин бик берьяклы карыйм. Әйтик, мәктәп дәреслекләренә кергән, мактап, күкләргә чөеп йөртелә торган бик күп әсәрләрне мин кабул итмим. Мәсәлән, Габдрахман Әпсәләмов әсәрләрендә Ибраһимны Игнат дип, Сәләхетдинне Сергей дип үзгәртеп чыксаң, аның чын татар әсәре булуына сагаеп каласың.

Әдәбиятның нигезендә миллилек ята. Милли булмаган әдәбият фальсификация ул. Әгәр язучы татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән — ул инде татар әдәбияты түгел. Бу уңайдан мин ике замандашымны — Әмирхан Еники белән Мөхәммәт Мәһдиевне аерып куям, аларны зур талантлар дип саныйм. Татарны ярату дигәндә, аны мактап телгә алу гына билгеләмә була алмый, аны сүгү-битәрләү дә язучының битараф булмавын билгеле ич.

...«Йөгез, бер дога!» минем соңгы китабым булды. 1994 елда инсульт кичердем. Шуннан бирле эш әзрәк әкренәйде. Замана да үзгәрде. Укучы да калмады. Татар халкы аракыга һәм телевизорга сатылды. Авылларда ничектер, шәһәрдә татар китабын укучылар көннән-көн азая, кызганычка каршы.

— Аяз ага, нинди генә чор булмасын, тәнкыйть, әдәбиятның юл күрсәтүче маягы булып, гел алгы сафта барган. Сез язмаларыгызда тәнкыйтьнең кирәклеге, аның әдәбиятны үстерүдәге урыны турында еш яздыгыз. Ә үзегезне иҗат гомерегездә тәнкыйть артык иркәләмәде бугай...

— Мине изәргә бик тырыштылар. Ләкин мин алай гына бирешә торган булмадым. Архивымда бер папкам бар. Ул «Мин гомер буе тәнкыйтьчеләргә азык булдым» дип атала. Мине алар рәхәтләнеп, ләззәтләнеп, тирән канәгатьләнү белән тәнкыйтьләделәр. Егерме ел дәвамында обком да иҗатымны тискәре яктан бәяләгән мәкаләләр язуда аларга һәрьяклап таяныч булды. Иң беренче сәхнә әсәрем — «Җиз кыңгырау» дөнья күргәч, редакциягә аны тәнкыйтьләп 35 бәяләмә килә.

Кем генә кыйнамады Аяз Гыйләҗевне. Сыер савучы да, тегүче дә бар иде алар арасында. Ә «Өч аршын җир» повестем «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргәч, аны чын тәнкыйть утына тоттылар. Журналның баш мөхәррире Газиз Мөхәммәтшинны хәтта, советка каршы әсәр бастыргансың, дип, көн-төн обкомга чакырттылар. Ә инде повестьны китап итеп бастырып чыгару? Шушы вакыйгадан соң нәшрият аны якын да китермәде. Әсәр Мәскәүдә Искәндәр Гыйззәтуллин тәрҗемәсендә «Дружба

народов» журналында рус телендә басылып чыкты һәм, елның иң яхшы әсәре буларак, махсус премиягә лаек булды. Хәтта ул Мәскәүдә аерым китап булып тиз генә нәшер дә ителде. Шуннан соң унбиш еллар үткәч кенә әлеге әсәрем җыентыгыма кертелде.

— Сез әңгәмәләрегезнең берсендә, ярым шаяртыпмы, прозаик буларак тән-кыйтьли башласалар, драматургиягә күчеп тордым, драматург буларак «дөм-бәсләсәләр», прозага күчтем, дип сөйләгән идегез. Шулай да, әйтегез әле, кайсы жанрны иярләү җиңелрәк булды: прозанымы, әллә драматургиянеме?

— Чын күңелдән әйткәндә, утыздан артык пьеса язсам да, мин драматург була алмадым. Мин сәхнәне тормышны өйрәнә торган университет дип аңладым. Аны ха-лыкны тәрбияләү чарасы итеп кулланырга алындым. Шуңа күрә Чехов, Шоу кебек акыллы драматургларны үземә остаз итеп алдым. Баксаң, театр тамаша икән ул. Мин тамаша кора белмәдем.

— И җ а т һәм т ә х е т! Болар арасында уртаклык бармы?

— Болар арасында уртаклык бик күпләрдә бар. Чөнки күпләр иҗатларын тәхеткә баскыч итеп кабул иттеләр һәм хәзер дә шулай яшиләр. Мин үзем беркайчан да, бер-ninди дә мөнбәрләргә үрелмәдем, аңа омтылмадым да. Хакимиятнең никадәр куркы-ныч көч икәнен бик күптән аңладым. Шулай булмаса төрмәгә дә керми идем һәм баштан кичкәннәрем хакында документаль әсәр дә язмый идем. Төрмә минем өчен зур бәхет булды. Ул миңа тормышның нәрсә икәнен аңлатты. Ә менә Хәсән ага Ту-фан, мәсәлән, шигъри күңелле кеше буларак, төрмәнең нәрсә икәнен аңлый алмады. Төрмәдән чыккач та, «Ал мине, партия!» — дип, коммунистларга мәдхия җырлады. Ибраһим ага Салахов та бер телевизион тапшырудагы әңгәмәсендә: «Мин утырып чык-тым, әмма бу режимны каралтмадым», — ди. Беркатлылык инде... Татарның саф кү-ңеллелеге, самимилеге...

— Сер булмаса әйтегез әле, моңарчы дөнья күрмәгән мирасыгыз күпме?

— Утыз том. Мин аларны киштәгә тезеп, өсләренә «100 еллыгымда гына ачып карый аласыз» дип язып куйдым. Бөтен архивым Нәкыя кулында кала. Барысы да аның

ихтыярында.

Балта кем кулында?

— Аяз ага, чын язучы — милләтнең намусы, йөз аклыгы. Сезне бүген милләт мәсьәләсендә күбрәк нәрсәләр борчый, шомландыра, уйга сала? Татарның язмышы. Кем кулында ул? Бармы аның киләчәге?

— Әлбәттә, соңгы ун ел эчендә «Без милләт өчен кайгыртабыз! Милләт язмышы безнең кулда!» дип шәрран ярып сөйләүче аерым кешеләр төркеме калкып чыкты. Ләкин күпме генә сөйләсәләр дә, татар язмышы мәктәп кулында.

Минем хатыным Нәкыя гомер буе мәктәптә укытты. Сентябрь аенда, укулар башлангач, Нәкыя мәктәптән кайтып керүгә беренче соравым шул була торган иде: «Класста ничә Айрат? Ничә Айдар? Ничә Руслан? Ничә Альбина бар?» Кызганыч, пәйгамбәрләребезнең исемнәрен ишетергә туры килмәде. Элек бит Коръәндәге исемнәр генә исем булып саналганнар. Исем бит ул күп нәрсә хакында сөйли.

— Аяз ага, фараз кылып карыйк әле: татар халкының язмышын тагын 6–7 елдан ничек күз алдына китерәсез?

— Мин күрәзәче түгел. Шуны гына әйтә алам: хакимияткә Путин килде — Сталин чоры яңадан кайтыр кебек. Бүген балта Путин кулында.

— Моннан берничә ел элек Сезне Казанда югалтып тордык. Зәйнең элеккеге хакимият башлыгы Рәшит Хәмәдиев Сезгә туган якларыгызда яшәргә мөмкинлекләр тудырды. Зәйне үз итмәдегезме, Казан сагындырдымы, нишләптер кайтырга булдыгыз?

— Балалар монда. Картайдык. Кайттык. Зәй безгә һәрьяктан да бик нык ярдәм итте. Мең рәхмәт аларга! Рәшит Сәет улы Хәмәдиев, бүген Чаллы шәһәре хакимияте башлыгы булуына карамастан, хәзер дә игътибарыннан ташламый. Зәйдә үткән гомеребезне матур бер төш итеп кенә күз алдына китерәбез.

— Узган гомерегезнең кайсы чорын күбрәк сагынасыз?

— Мин гомеремнең иң авыр елларын да сагынам.

«Шәһри Казан»



Тәкъдирдә язганы шул булгандыр...

Беренче класста гына укыса да, кинәт үсеп киткән нәзек, курач кызыкай Нәкыянең тездән түбән төшеп торган ак ыштан балагыннан чеметеп тартып: «Әй, кызый, минем тирәмдә бик чыркылдап йөрмә, берзаман кайтып өйләнермен әле үзеңә», — дигән идем мин — унынчы класста укучы егет.

Ник тарттым икән ыштан балагыннан?! Соңыннан, байтак еллар үткәч, язмышлар безне гомерлеккә кавыштыргач, исем китеп, еш кына уйланган мизгелләрем булды. Шул уй-фикерләремә йомгак ясап, сезгә дә ачарга булдым күңел сандыгымны, кадерле укучым...

Ир-атлар фронтта. Сугыш еллары хатын-кыз укытучыларны да кайсын кая таратып бетерде. 1944 елның көзендә мин укыган Югары Баграж урта мәктәбен дә яптылар. Мин унынчы классны ата-бабамның туган төяге Сарман мәктәбенә кайтып тәмамларга ниятләдем һәм шулай булды да. Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында әнием Мөгаттәрәнең төп йорты. Ире Сөләйманны 1942 елда соңгы юлына озатып калган сөекле әбием Зөләйха хәзер йорт башы. Нык хуҗалыклы, чамасыз тырыш, мал кадерен белгән бабам дөньяны куйса да, Сөләйманнар нигезе авылда бердәнбер диярлек иде. Йорт-җир хәзер Сөләйманнарның төпчеге Мирзаһит кулында. Ул бабамның вафатыннан соңгы кышта (1942) фронттан каты яраланып кайткан.

Мин, Зөләйха әбиемнәрдә яшәп, Сарман мәктәбенә укырга йөри башладым. Авыл аралары якын гына, мул гына сулы Минзәлә елгасы аша салынган басманы чыгасың да Сарманга барып керәсең.

Чын татар авылын күреп калуым белән бәхетлемен! Сугышка кадәрге Югары Әхмәт татарның мең еллык канунын саклап торучы гүзәл бер авыл иде. Керәшенстан үзәге Зәй төбәгеннән килеп, Айтуган күперен чыгуга, борынга бик үзенчәлекле төтен исе килеп бәрелә. Кыр ягы исе бу, урманнар юк бу тирәләрдә. Югары Әхмәт халкы сазламыктан торф чыгарып ягулык әзерли, ел дәвамында җыелган тиресне елга буена ташып өя дә өмә ясап тирес суга. Янган кизәк исе борынгы бабаларыбызны, аларның

күчмә чакларын, кылган җай гына тирбәлгән иркен болыннарны, һау-һаулап елкы кө-
түләрен куган бүз егетләрне, Сабан туйларын, туклык бөркелеп торган көзге җыен-
нарны искә төшерә. Айтуган күпереннән Югары Әхмәткә барып җиткәнче мин әллә
нинди серле, сихерле дөньяда яшәп алам, үсмер егет каны уйный, тамырлардан җитез-
рәк ага башлый. Менә Сөләйман бабайларның
яшеллеккә күмелгән ындырлары шәйләнә, мәчет-
манара араларында бәхәсләшеп очкан чәүкәләр-
нең тавышы колакка керә. Егерме биш чакрым ара-
ны җәяү узган арыганлык онытыла, абына-сөрте-
нә ашыгасың. Саумы, Югары Әхмәт! Саумы,
Уралның койрыгы булган Текәй таулары! Шул тау-
ларның күкрәгеннән бәреп чыккан Бузат чишмә-
се! Исәнме, Ялгыз каен! Йомшак эңгер каплаган
тарлавыклар! Мин сезнең арагызга киләм! Букчам-
да китап, дәфтәрләр арасында шигырьләрем, тәү-
ге зәгыйфь хикәяләрем дә кереп кысылган.
Монда бер нәрсәне ачыклап үтәргә кирәк. Мир-
заһит абыемның хатыны Наҗия, минем җиңгәм,
кырык дүртенче елда бәбәй алып кайткан икән, кыз
бала. Сөйкемле булса да, елаграк кызчык. Шул бә-
бинең бишеге тирәсендә мин җиде-сигез яшьләр-
дәге тал чыбыгыдай нәзек, кара күзле икенче кы-
зыкайны шәйли башладым. Булачак кәләшем Нә-
кыя шушы кыз иде инде.
Аяз — студент. 1944
Без дүрт малай үстек, гаиләбездә кыз бала күргәнем юк. Нәкыянең җиңел сөякле,
үтә җитез булуына игътибар иттемме, әллә аның бишектәге бәбигә ихлас мәхәббәте

сокландырдымы, әмма туганнан бирле үзен язучы итеп тойган яшь егет кызны җентекләбрәк күзәтә башлады. Нәкыя мәктәбеннән кайта да безгә йөгерә: килә, керә, биткулларын юып, бәби кыз бишегенә тотына. Бәби йокламаган булса, аның бармакларын берәмтекләп үбә, бәби дә аны зарыгып көткәндәй елмая, көлеп тә куйгалый. Берберсенә сүзсез тартылган ике җылы җанны күзәтеп мин дә сөенәм. Сугыш елларында боеккан өй эче яктырып, нурланып китә.

Мин инде Әхмәттә күп нәрсәләр беләм. Нәкыянең әнисе — тол хатын Нәүбаһар

түти белән дә таныш. Ике малаен һәм Нәкыяне тәрбия итүче бу тол хатын, ире Илһаметдин төрмәдә үлгәннән соң, йорт-җирен, хуҗалыгын менә дигән итеп алып бара. Кышлык ягулыгы да җитәрлек аның, бәрәңге-яшелчәсе дә уңа, лапас-куралары да каралган, иреннән ятим калган бал кортлары балны ташып кына торалар.

«Әнкәсенә карап кызын ал!» дип акыл беркеткән безнең бабайлар. Яшь аермабыз шактый булса да (тугыз ел!), Нәкыягә күз салуымның төп сәбәпләре шулардыр дип уйлыйм: Зөләйха әбиемнәрнең изге нигезе, мохит, җылы күңелле ихлас татар дөньясы, бишек тирәсендәге соклангыч гамәлләр, әнкәсенең уңганлыгы, чисталыгы, авылча ашсуга осталыгы.

Һәм көннәрдән бер көнне ачыктан-ачык, туп-турыдан мәхәббәт аңлату: «Күп чырылдап йөрмә, кайтырмын да өйләнермен!»

Фәрештәләрнең дәррәү «Амин!» дигән чагына туры килдеме, яшьлегемдәге дуамал хыялларымның күпчелеге тормышка ашты. Мин Нәкыягә өйләнеп, без уртак тормыш корып җибәрдек. Ләкин аңа кадәр әле...

Мин Казан дәүләт университетына өч тапкыр кереп, биш ел укып нибарысы өч

курсны тәмамладым. Ул елларның сикәлтәле бусагаларын бәян итеп мин «Йәгез,

бер дога!» исемле роман-хатирәмне яздым. Роман аерым китап булып басылып та

чыкты. Кызыксынган укучылар аның белән таныша алалар. Шәп роман, монда инде

минем бөтен барлыгым, кырыс язмышымның хас дөреслеге... Шуның өчен ул елларны йөгереп кенә үтәм. Нәкыянең һич көтмәгәндә язмышыма кереп китүен үзегез

күрерсез.
Икенче курста укып йөргәндә, 1950 елның 22 мартында, мине кулга алдылар һәм Черек күл төрмәсенә илтеп яптылар. 17 декабрьдә Петропавел пересельный төрмәсеннән язган хатымда болай дигәнмен: «Юлдан беренче хатым. 7 декабрьдә Казаннан киттем. Кая барып урнашу билгеле түгел, шулай да Казакъстанда, Караганда тирәсендә калдырырлар кебек. Китте башлар, әллә көнгә, әллә айга, әллә гомерлеккәме?..»
1954 елның сентябрендә, һич көтмәгәндә, сискәндереп, мине Казанга кайтардылар. Тагын этап, Чиләбе, Свердловск төрмәләре, ниһаять, Черек күл! Туган якның төрмәсе дә сөйкемле күренде миңа. Сентябрь башында кайтып төштем дә 2 ай буена «одиночка»да утырдым. Энем Алмаз ул чакта медицина институтында укый иде. Мин аның белән күрештерүләрен үтендем. 1954 ел! Сәяси тоткыннарның эшләре яңадан карала башлаган чак, телгә реабилитация дигән яңа сүзләр килеп керде. Кайтуыма ике атна дигәндә Алмаз белән күрештек. Сүзләрнең төрлесе булгандыр, әмма бер соравым алдагы тормышымда үтә әһәмиятле булып калды, язмышымны яңа якка борып җибәрде.
1948 елда гына оешкан безнең лагерь-каторгадан котылып чыккач та илгә кайтулар юк иде. Лагерьдан соң сине этап белән мәңгелек сөргенгә озаталар иде. Киләчәктә гаилә кору хакында уйлаган мизгелләр булдымы икән? Хәтерләмим.
Черек күл төрмәсенең беренче катындагы «одиночка»да мин Нәкыяне исемә төшердем һәм энем Алмаз белән күрешкәч тә: «Ул кыз кайда? Кияүдәме?» — дип сорадым.
Кияүгә чыкмаган икән, Аллага шөкер! Унынчы классны тәмамлап, медицина институтына имтиханнар биреп караган да үтә алмаган, хәзер Иске Әлмәт мәктәбендә укыта икән...
Ике айдан артык Казан төрмәләрендә ятканнан соң, мине үзем чыгып киткән ла-



герьга кайтардылар. Анда кайтуымның икенче көнендә үк, 1954 нең 22 ноябрендә, Нәкыягә хат язып салдым. Ике арада хатлар йөри башлады. Менә аларның берсе:

«6 февраль, 1955 ел.

Караганда — Федоровка.

«Сагынасыңмы?» — диләр,

Хисләр өчен

Бу сүз, дуслар, бик-бик кечкенә.

Мин: «Сагынам!» — дисәм,

Бу авазда

Җир тетрәгән тавыш ишетелә...

Нәкыя!

Хатыңны алдым. Озак, бик озак көттем мин синнән хатны. Ниһаять, ниһаять... Менә ул хат. Синең җитди, кечкенә рәсемеңнән зурларча таләпчән, җиткән кыз — бөтенләй ят, таныш түгел кыз карый. Мин озаклап синең рәсемеңә карап торам да үткәндәге кечкенә Нәкыяне күз алдына китерергә тырышам. Хатыңны соңарып алдым, чөнки күптән түгел генә яңа урынга күчтем һәм бу да күптән көтелгән хатны бераз тоткарлады. Рәхмәт сиңа, сеңлем, зур рәхмәт. Син хатыңны русча язсаң да, мин татарча гына җавап бирергә булдым. (Лагерьга хатларны бары тик рус телендә генә язарга рөхсәт итәләр иде.)

Үзем хакында: сау-сәламәтмен, тазалыгым яхшы, биш ел инде төрмәдә булсам да, авыр эш белән интегеп җәфа чигәргә туры килмәде. Инде быел өйдә булырмын дип уйлыйм. Бик күп укыйм. Инглиз телен өйрәнүемне дәвам итәм. «Ялгыз йортта сагыш» исемле 4 пәрдәлек пьеса, «Чык бөртеге» исемле повесть язам.

А.Гыйләҗев төрмәдән кайткач Багражда туганнары арасында. Икенче рәттә уңнан икенче — Нәкыя.

1955

Минем гомер шулай буталчыклы булды ки, тирә-яктан караганда. Кешеләр миңа гаҗәпләнә торганнардыр. Дөрес, ата-анама зур хәсрәт ясасам да, аларның вакытсыз картаюларына сәбәпче булсам да, үземнең бу авыр юлга төшүемә артык үкенгәнем юк. Бу авыр еллар мине тормышны танырга, аның катлаулы сәхифәләрен укырга өйрәттеләр. Бу авыр еллар миңа кешеләрне аңларга ярдәм иттеләр. Бу авыр еллар мине ата-анамны, туганнарымны, дусларымны бәһаләргә өйрәттеләр. Бу авыр еллар миннән җитди кеше ясадылар. Кемнәрне генә очратмадым мин бу авыр елларда! Тузанлы заводларда, кысан, тынчу вагоннарда, кечкенә, ярым караңгы төрмә камераларында кемнәр белән генә бер сынык икмәкне бүлешмәдем мин! Тормыш никадәр кыен булса да, аның саен яшисе килә. Тормыш никадәр ямьсез булса, аның саен тормышка гашыйк буласың. Дөрес, авыр көннәрдә дә үзеңчә ниндидер ямь табасың, язлар килеп, дала өстендә җылы җилләр уйнаганда, үзеңнең кемлегеңне онытып, ерак офыкка озаклап-озаклап карап торасың... Үткән көннәр хакындагы җылы истәлекләр акрын гына уяналар да кайтасы килә, кайтасы... Сагындым мин, бик сагындым ямьле Зәй, Сарман буйларын! Сеңлем, синең бәхетле булуыңа, яшь булуыңа куанам. Син еракта. Әниең, туганнарың белән, син беркайчан да мин яшәгән җирнең сөремле, җыерчыклы йөзен күрмәссең. Сезнең белән мин дә үткән көннәрнең авыр хатирәләрен онытырмын, ял итәрмен... Шуңа күрә минем синнән хатлар аласым килә. Әгәр инде минем хатлар синдә авыр уйлар уятсалар, ачуланма. Тормыш — кырыс, ул кешеләр күңеленнән чакма ташы ясый. Әмма туган ил хакында, синең хакта уйлаганда, миндә иң җылы фикерләр генә уяналар. Син минем өчен әле һаман да кечкенә генә, ябык кына шаян кызчык булып калгансың. Синең инде урта мәктәп бетерүеңә, укытучы булып йөрүеңә мин авырлык белән генә ышанам...

Нәкыя! Эшең бик авыр түгелме? Институтка хәзерләнәсеңме? Укыйсыңмы? Хат яз.

Кулыңны җылы кысып, Аяз».

27 февральдәгесендә мин ипләп кенә «һөҗүмгә күчкәнмен» һәм хатымны дус кы-

зы Әминә исеменә юллаганмын...

«27 февраль, 1955 ел.

Караганда — Федоровка.

Нәкыя! Исәнмесез!

Бу хатымны Сиңа Әминә аркылы җибәрәм. Сәбәбе: бу хатымның Синең туганнарың кулына төшүен теләмәс идем мин. «Нигә?» — диярсең. Гаҗәпләнмә. Бу хатка булачак җавапны Син ялгыз гына хәл итсәң иде. Син бу хаттан минем Сиңа яза башлавымның бер максатсыз түгеллеген аңларга тиешсең. Ә ул максатны мин артык нык кадерлим. Һәм ул хакта Синең генә белүеңне теләр идем. Кереш сүзсез ачыктан-ачык яза алмыйм. Чөнки минем хатлар әлегә Сине куркытып җибәрмәдеме икән? Һич тә көтмәгәндә мин ерак даладан Сиңа дәштем, Синнән рөхсәт тә сорап тормастан, Сиңа үземнең сагышлы тормышымны сөйли башладым. Ачуланма, сеңлем! Тормышның һәр минуты, һәр сәгате минем өчен кадерле. Әле дә яшьлегемнең иң кадерле елларын мин бер максатсыз җилгә очырдым. Миңа 27 яшь, бу инде уен түгел, бу яшьтә кешеләр тормышның җитди проблемаларын хәл итәләр. Һәрбер үткән минут, үткән көн мине яшьлекнең буталчык хыялларыннан айныта, мин киләчәккә омтылам, яшәргә тырышам. Әле моннан бер ел элек кенә минем илгә кайту мәсьәләсе бик шикле иде. Әмма хәзерге шартлардан чыгып, 1955 елда мин өйдә булырмын дип уйлыйм. Сиңа булган мөнәсәбәтем минем киләчәк елларга бәйләнешле булганга күрә, мин, ирекккә чыкканчы ук, Синең белән өр-яңадан танышырга карар иттем. Мин белгәндә Син әле нечкә аяклы, көләч кенә нәни кызчык идең. Синең хатларың буенча мин Синең җитди кыз булып китүеңне күрдем. Әмма Синең яшәешең, Синең тормышың, фикерләрең, теләкләрең минем өчен әлегә табышмак. Сүзсез фотоңа көн саен карый-карый, мин ул табышмакны чишәргә азапланам, хыялларымда ул сүзсез рәсемгә җан бирәм...

Сине тудырган, Сине үстергән, тәрбияләгән тирәлек, мәктәп һ.б. минем дә яшьлегемнең бишеге иделәр. Шулай да ул бишектә ала кешеләр дә, кола кешеләр дә үсә-

ләр. Кем Син? Бу сорау мине борчый, җанымны бимазалый. Шуңа күрә дә мин бер-бер артлы Сиңа хатлар язам, шуңа күрә дә мин бер эчке калтырау белән Синнән хатлар көтәм. Язышырга теләрсеңме Син минем белән, бу тулысынча Синең ихтыярда. Син минем нинди хәлдә икәнлегемне беләсең. Шуңа күрә мин кыюсызлык белән күзлә-ремне күтәреп Сиңа карыйм. Гаҗәпләнмә Син минем хатларга, мин ниндидер сихри маҗаралар эзләмим, мин кеше эзлим. Мин игътибар эзлим, Нәкыя! Дөрес, Син: «Хат язарга да вакытым юк», — дип язасың. Яшьлекнең татлы назларыннан Синең дикъка-теңне аерып үземә игътибар сорыйм икән, мине рухи хәерче дип уйлама! Тик яшисе килә, кадерле сеңлем! Яшәүне бер максатсыз булмый, диләр бит! Ә мин нинди максат белән яшим соң?! Балалык, яшьлек хыяллары — искиткеч сәяхәтләр, данлы-шанлы хезмәтләр — тормышның реаль кыяларына бәрелеп юкка чыктылар. Аек башта ро-маннар, пьесалар белән ачыктан-ачык бер генә теләк калды. Ул теләк — семья. Буш-буйдак булып ничә еллар каңгырып йөрдем, бу еллар җанны алҗыттылар. Җан тыныч-лык сорый. Кайдадыр анда, Идел буенда, челтәрле тәрәзәле йорт, йорт янында гаҗәеп исле төнге фиалкалар, тыныч хезмәт, хатын, бала-чагалар... Хәсрәтле юлда арыган кешеләр өчен бу искиткеч бәхет, яшәү максаты. Күп еллар хатын-кыз назыннан мәх-рүм булган ирләр генә семьяның чын кадерен аңлыйлардыр кебек...

Менә болар һәммәсе дә минем Сиңа булган хатларны туганлык рамкаларыннан чыгаралар, менә шуңа күрә дә мин бу хатның башкалар кулына төшүен теләмәс идем. Уйлама, әгәр Син миңа җавап язмасаң да, мин Синең хакта иң яхшы, иң саф фикердә калырмын. Минем күңел катылыкка күнекте: нинди генә җавап бирсәң дә, мине «акылдан язган» дип атасаң да, күз яшьләремне күрмәссең Син!

Урамда яз! Түбәләрдән чарылдап су ага. Бүген ял көне. Көндез «Фанфан-тюльпан» дигән кинофильмны карадым. Көндезге аштан соң мин Сиңа хат язам. Сиңа соңгы хатымны 7 февральдә язган идем. Һәр көн эштән кайту белән почтага йөгерәм... Ә Син, бәлки, бөтенләй язмассың?! Кем белә?

Сәламәтлек яхшы. Бу лагерьда да озак булмабыз, диләр. Киткәнгә кадәр берәр хат

ала алсам иде...

Кулыңны кайнар кысып, Аяз

8 Март — Хатын-кызлар бәйрәме белән котлыйм үзеңне! Якыннарга сәлам.

Әминә! Хөрмәтлем! Иң элек Сезне 8 Март бәйрәме белән котлыйм. Бу хатны Нәкыягә тапшырыгыз. Эчтәлеген башкаларга чыгармагыз. Мин Сезгә ышанам, сеңлем!»

Һәм... Ниһаять! «Исеңдәме, «кайтып өйләнермен» дигән сүзләрне онытмадыңмы? Шул көннәр килеп җитә. Син ничек, ризамы?»

Нәкыянең җавабын алгач, мин тигез җирдә тәгәрәп киттем. «Мин «риза» дисәм, ә син кайткач үзгәрсәң?!» — дип язган иде ул.

Илдә үзгәрешләр башланса да, миллионлаган сәяси тоткыннарның алдагы язмышы билгесез иде. Җиде юл чатында аңгыраеп басып торганда чәчәк кебек кызның «риза» дигән сүзе чамасыз зур бәхет иде.

Моны тәкъдир димичә ни дисең?!

1955 нең көзендә мин илгә кайттым. 1956 ның февралендә зур мәшәкатьләр чигеп университетның икенче курсында укый башладым. Нәкыяне университетка керергә күндергән идем. 1956 ның сентябреннән ул — беренче курста, мин өченчедә укый башладык. Бәхетле, гөнаһсыз, сөенечле көннәр! Мин Островский урамында фатирда торам, ул Колхоз базары янында яши. Күрешмәгән көнебез юк, сагынышып очрашабыз да өметләребезне ныгытып аерылышабыз. Мин хикәяләр яза башладым. Пьесалар язам. Укыйм. Театрларга бергә йөрибез.

«Чаян» журналының фельетоннар бүлеге мөдире Шәүкәт Галиев мине эшкә чакыргач, тиз үк ризалаштым. 1957 ел, 2 марттан журналда эшли башладым. 4 мартта Нәкыяне үзебезгә алып кайттым. Якын дусларым Фәрваз Миңнуллин белән Зиннур





Гыйззәтуллин, энекәшләр безне пилмән

пешереп көтеп торганнар.

Безнең өйләнешү студентлар арасын-

да нәни генә сенсация булды. Бишенче

курсның сазаган кызлары беренче курста

кияүгә чыккан «дурочка»ны күрер өчен

махсус күзәтеп йөргәннәр...

Ике яктан да курсташлар «Туй!»,

«Туй!» дип өзми-куймый тыкырдата баш-

лагач, өч көн туй иттек. Беренче көнне туй-

да студентлар булды, икенче көнне чаян-

чылар, күз күргән агай-энене дәштек.

Өченче көнгә урыс-улак, күрше-тирә кал-

ды. Туй үзе дә гаҗәп кызык, шау-шулы

булды, аның хикмәтләрен дус-ишләр әле

дә легенда итеп сөйләп йөриләр.

Мин, өченче курсны тәмамлагач, уку-

ымны ташладым. Алты елга сузылган мәк-

тәптә «белем» алгач, марксизм-ленинизм

нигезләре миңа бер әкият булып кына кал-

ды.

1958 елның 31 августында Искәндәр

улыбызны алып кайттык.

Язуымны өзеп торырга туры килде,

кульъязмамны Нәкыя сорап алды. Тиз ара-

да укып чыгып, әйләнеп тә керде: «Мак-

танчыклыгың яшь чагыңда да бар иде, хәзер дә бетеп җитмәгән икән, — диде. —

Укучылар «Бу бала 1 нче класста ук Аяз абыйсына гашыйк булган түгелме соң?» дип уйларлар! Бер нәрсәне ачыклап кит! Син яшәгән йортта Мирзаһит абыйның хатыны Наҗия апа минем әнкәйнең сеңлесе иде ич! Оныттыңмыни? Ярата идем мин апамны. Шуңа күрә барып йөри идем».

Юк, онытмаган идем. Нәкыям мин сикертеп кенә үткән елларны сагынып кына искә төшерде: «Искәндәребезне без Яңа бистәдәге Күл урамындагы бер фатирга алып кайттык. Йортның бүрәнәләре череп-муртаеп беткән, идән такталары кырык биш гра-

Алты айлык Искәндәре белән. 1959

Искәндәр (сулда) һәм

Мансур әтиләре коча-

гында. 1963





дуска авышкан. Бихисап авыр вагоннар сөйрәгән поездлар терәлеп диярлек узалар. Өй дер селкенә иде. Суны ерактан ташыйбыз, өйне мич ягып җылытабыз. Алай да Яңа бистәдә үткәргән көннәребез иң бәхетле, шатлык, сөенечләр тулган көннәр булып хәтердә саклана. Кунаклар килеп тула. Мин укыйм. Бер кулымда китап, икенчесендә бала. Әле ярый авылдан әнкәй килеп җитте. Бәхетле чаклар! Баграждан Әхмәткә көн аралаш килеп йөрүләреңне ник язмадың? Яңгыр, кар дип тормый идең, утыз чакрым араны эһ тә итмичә җәяү уза идең! Ә хатларың. Көненә икешәр хат язган чакларың була иде. Хат ташучы Халидә: «Ниләр яза икән ул егетең шулкадәр?» — дип бик

Гыйләҗевләр гаиләсе.

1973

Гаиләдә бергәләп фотоальбомнан нәсел җепләрен эзләү бара... 1964





Гыйләҗевләр оныклары Галия белән. 1986

Гыйләҗевләрнең оныклары. Сулдан уңга Мансурның улы Муса һәм кызы Зифа, Искәндәрнең кече кызы Миләү-

шә, олысы Галия һәм Рәшатның улы Сәлимҗан. 1999





Уллары Рәшатның улы Сәлимҗан белән. 1997

Оныклары арасында. 1998



гаҗәпләнә иде».

Хатлар димәктән, хатларны сан-

сыз-исәпсез яздым мин. Нәкыягә

язган йөзләрчә хатларым архивым-

да саклана. Переделкинога барып 24

көн торсам, иң кимендә 30 хат яза

торган идем.

Искәндәрне багарга килеп җит-

кән Нәүбаһар әбиебез безнең гаи-

ләгә бәхет, татулык алып килде.

Авылча зур тормыш мәктәбе узган,

тормышның ачысын-төчесен кат-

кат татыган бу изге җан балаларга,

безгә бар көчен, ихлас мәхәббәтен

багышлап 31 ел бездә яшәде. 87

яшенә җитеп дөнья куйды.

Бала... Тәҗрибәмнән чыгып әй-

тәм, чын кеше булсын өчен кеше,

һичшиксез, әби-бабай җылысын да

татып калырга тиеш. Искәндәрдән

соң Мансурны алып кайттык. Олы

улыбызга 10 яшь дигәндә төпчеге-

без Рәшат туды. Әби балаларны кө-

теп алды, һәммәсен дә тигез ярат-

ты. Балалар да әбиләрен чиксез

яраттылар. Вафатыннан соң ак мәр-

мәр ташын да алар куйдылар һәм

һәрвакыт әбиләре җәсәденә барып

зират кылып торалар.

Нәкыя авырга узгач та мин ма-

лай көттем. Туганчы ук һәрберсе-

нең дә исемнәре дә бар иде. Нәкыя

дә малайлар гына табарга теләде, һәм Аллаһы Тәгалә безнең теләкләрне кабул итте.

Малайлар үсте, укыдылар, үз вакытын белеп кенә татар кызларына өйләнделәр.

Киленнәребез алмаш-тилмәш оныкнәбәрәләр алып кайттылар. Менә без, әби-бабай

булып, шактый ишле балаларыбызга ияреп, XXI гасырга керергә җыенабыз. Онык-

нәбәрәләребез: Галия, Миләүшә, Зифа, Сәлимҗан, Муса — саф татар балалары. Тел-

ләре татарча ачылды. Җирдә ямаулы татарлар гына калса да, безнең балаларыбыз ата-

бабалары кемнәр икәнен онытмаслар дип ышанам.

«Үзем турында язу авыр» дип бер язып чыккан идем инде. Кырык дүрт ел бергә

яшәгән, кулга-кул тотынышып гаилә корган хатының турында язу тагын да катлаулы-

рак икән. Мактап кына торсаң, «арттыра» диярләр, кимчелекләрендә казынсаң, «вак-

чыл» диярләр. Безнең гаилә үрнәк түгел. Гомумән, үрнәк гаиләләр була алмый дип

исәплим мин. Ә болай мин Нәкыямә чиксез рәхмәтлемен! Шактый дуамал, мыжык

язучының хатыны булып 44 ел яшәү үзе бер батырлык ул.

Нәкыя ханымның өстәмәсе

Аяз абый лагерьдан кайткач, беренче күрүдә мин аны тамчы да ошатмадым. Тәбә-

нәк кенә, күзлекле, кырыс кына икән мин «риза» дип хат язган егет. Минем ризалы-

гым кемгәдер җиңел акыллылык булып тоелырга да мөмкин. Асылда, моның җитди

сәбәпләре дә бар иде. Аязның әтисе (Мирсәет җизни дип йөртә идек без аны) затлы,

укымышлы кешеләрдән иде. Ә Мөгаттәрә апаны (минем булачак кайнанамны) Кәшер

кызлар мәдрәсәсендә укыганда ук «Бәләкәй остазбикә» дип атап йөрткәннәр. Аларга,

Аяз Гыйләҗевкә 70 яшь тулган көннәрдә

җизниләр яшәгән Урта Багражга, мин еш барып йөри идем. Бәйрәм-сәйрәмнәрдә дә аларда булам, көзләрен чикләвек җыеп, атналар буе аларда ятам. Икесенең дә сөйләшкән сүзләре Аяз турында гына: сагыналар, елыйлар, кызганалар. Аязның хатларын кычкырып укыталар. Аңа зур киләчәк юрыйлар. «Язучы булыр әле, үзен танытыр», — дип юрыйлар. Бу сүзләр әкрен генә аңыма җыела бардылар. Аяз абыйдан беренче хат килгәндә, мин инде аның тормыш хәлләрен шактый ачык күзаллый идем. Шулар өстенә җизни белән Мөгаттәрә апаны кызгану хисләре тоткын егетне миңа якынайттылар. Аяз абыйның хатлары кайнар өермә булып мине урап алдылар да яңа давыллы хисләр дөньясында яшәтә башладылар. Тора-бара егетемнең күзлеге дә, тәбәнәк буе да онытылды. Минем янымда әйткән сүзендә нык торучы, эшләгәндә ару-талуны белмәгән, ата-анасына игътибарлы, көчле рухлы, талантлы егет калды. Аны ничек яратмыйсың! Без әкрен-әкрен үзебез корган планнарны тормышка ашыра бардык. Һәм менә 44 ел гомер үтеп тә киткән. Тормышта гел генә баллы яңгыр яумый. Беренче чорда Аязны кагып-сугып рәнҗетеп йөрттеләр. Ул елларда мин аңа ышанычлы дус, терәк булырга тырыштым. Хәзер без балалар-оныклар белән бергә җыелабыз да, гомеребез бушказаяга узмады, дип сөенешәбез. Олыгайган саен, хатыннарның дәрәҗәсе арта икән, Аяз мине элеккедән дә ныграк ярата дип уйлыйм.

«Таһир-Зөһрә»

1999, № 2(14)

Аяз белән Нәкыянең өйләнешкән елларында А.Гыйләҗевнең энеләре Альберт (сулдан өченче) һәм Алмаз

белән. 1958

Заман мине узып бара

Без инде бу соңгы егерменче гасырны, гасыр башыннан алып бүгенге көнгә кадәр, бөтенесен күз алдына китерә алабыз. Һәркем үз урынын тапкан, шушы гасыр әдәбиятының нигезен ныгыткан, ниргәләрен биеклеккә күтәргән әдәбият ул Тукайдан баш-

ланган. Ул Фатих Әмирханнан башланган. Шулай дәвам итеп, килеп җиткән Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәшировка. Татар әдәбияты, халыкның күңеленә урнашып, гомер-гомергә укучыны яктылыкка өндәгән. Аның аңына асыл әхлак кагыйдәләрен, тормыш итү кануннарын сеңдерә килгән.

Соңгы ун ел татар әдәбиятының иң авыр еллары булды. Чөнки без әдәбиятның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә күтәреп барган бик зур талантларны югалттык. Иң соңгы югалту Гариф Ахунов булды. Инде җае чыккач, Гариф турында берничә сүз әйтмичә кала алмыйм. Кайбер алап авызларга ияреп, без Гарифны әзрәк кенә кимсетеп килдек. Аны җиңелрәк яши торган кеше дип үзара сөйләшкәләп йөрдек. Хәзер менә Гариф киткәч уйланам: Гариф татар халкының бик күренекле, бик олы улы булган икән. Ул озак еллар Татарстан Язучылар берлеген җитәкләде. Берлекне җитәкләү ул бит әдәбиятны җитәкләү генә түгел, ул бик күп кешеләрнең язмышын да хәл итү. Кайберәүләр Гарифны Мәскәүдән килгән кешеләргә тәлинкә тотуда гаепләделәр. Ләкин бит Мәскәүдән килгән кеше кунак ул, башка республикалардан килгән кеше дә кунак. Аны кемдер кабул итәргә тиеш. Кемдер аңа хезмәт күрсәтергә тиеш. Ниһаять, кемдер аның тамагын кайгыртырга тиеш. Менә шундый эшләрне Гариф соң дәрәҗәдә югары итеп оештыра белде. Үзебезнең язучылар өчен дә күп эшләде. Үзен-үзе жәлләмәде. Һәм, гомумән, Гариф Ахуновның кылган яхшылыклары турында без бик озак елларга кадәр кайта-кайта сагынып сөйләрбез әле.

Гариф ач-ялангач елларда укыды. Бик яшьли үз көнен үзе күрде. Ләкин ул берчакта да язмышыннан зарланмады, тормышның ямен-тәмен таба белде, тапканын кадерләп тотарга өйрәнде. Искиткеч тыйнак, кеше сүзенә һәм гамәленә игътибарлы бу егетебез берзаман күтәрелеп китте. Бик яшьли Язучылар берлегенә кабул ителде. Берсеннән-берсе мавыктыргыч әсәрләр иҗат итте. Ике мәртәбә партия съездларына делегат итеп сайланды. Ике чакырылышта Югары Совет депутаты булды. Ни кушсалар — шуны үтәде. Ләкин берчакта да үзенең гражданлык йөзен югалтмады, татар халкының олы бер улы булып кала белде. Мең мәшәкате өстенә туктаусыз иҗат итте, үз укучы-

сын тапты.

Менә бу көннәрдә татарның шушы зур әдибе Гариф Ахуновка 75 яшь тулган булыр иде. Әмма озак еллар янәшә яшәгән дустым бу юбилеен уздыра алмады.

Мин инде хәзер әдәбиятны элекке шикелле бөтенесен укып бара алмыйм. Әмма мин беләм: яшьләр арасында да кыю гына язып килүчеләр бар. Ләкин Мөхәммәт Мәһдиев кебек, Гариф Ахунов кебек якты, зур шәхесләр әлегә юк. Әдәбиятта ниндидер бер торгынлык чоры. Заманында, әйтик, Мөхәммәт Мәһдиев ни генә язса да, ул шунда ук үз укучысын таба иде. Язучылар арасында да үзара теләктәшлек уята торган иде. Хәзер андый кеше бармы ул? Әйтә алмыйм. Әдәбият вакланды, дисәң дә дөрес булыр. Әдәбият кечерәйде, дисәң дә хата булмас. Ләкин табигать бушлыкны сөймәгән кебек, әлбәттә, безнең урынга да кемнәрдер килер...

Бүгенге әдәби процессның төп казанышы татар тарихының яңа ачылган фактик материалларына таяну булыр дип өметләнәм. Без дөрес татар тарихын белмичә үстек. Бер генә мисал: урыс шовинистларына ияреп, аларга ярарга тырышып, бөек дәүләтебез Алтын Урданы пычракка батырып, тузга язмаган сүзләр сөйләп йөрдек. Тарих белән ныгытылмаган әдәбият, әдәби әсәрләр белән көчәйтелмәгән тарих берчакта да халыкның иманы була алмый. Әдәбият тарихка иң ышанычлы терәк булып хезмәт итә һәм киресенчә.

Ни кызганыч, безнең буын әдипләре бөек тарихыбыздан мәхрүм булып яшәде.



Хәзер татар әдәбияты кискен борылыш ясарга бурычлы. «Кубрат хан» романы белән дәрәҗәсен бик югары күтәргән М.Хәбибуллин, тарихи романнары белән кыю эш итә башлаган Флүс Латыйфи, Вахит Имамовларга кызыгып карыйм. Нинди иҗади киңлекләр ачылды алар өчен. Яз да яз гына. Акыллы ханнар да булган татарда, зирәк дин эшлеклеләре дә яшәгән. Һәр буын үз батырын тудырган. Моңарчы без аларны күрә генә белмәгәнбез.

Мин күбрәк проза турында уй йөртәм. Чөнки шигърият дөньясының көче кимегәне юк. Төрледән-төрле шагыйрьләрнең иҗаты күз алдыбызда чәчәк ата. Исемнәрен санамыйм. Поэзия яши, алга таба да яшәр дигән өметтә калам.

Ни кызганыч, соңгы ун елда татар әдәбияты күп укучысын да югалтты. Моның сәбәбе берничә. Беренчедән, без кара тартма — телевизор белән ярыша алмыйбыз. Хәзер иң ерак авылларга да телевизор барып керде. Һәм ул мавыгучан татар халкын йотып кына алды. Хәзер инде татар апалары, бергә очрашып сөйләшә башласа, татар әдәбиятының соңгы сулышы йә булмаса «Сөембикә» журналында басылган хикәяләр турында сөйләшмиләр. Алар бүген арзанлы сериаллар, төче ялганга корыл-

ган, бик җиңел кабул ителә торган һәм бик тиз онытыла торган фильмнар турында сөйләшәләр. Чөнки алар, шул фильмнарны карап, үзләренең әдәбиятка булган ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр.

Дөрес, халыкның кесәсе саегу, ә китап-журналларның бәясе арту да сәбәп булгандыр халыкның аз укуына. Әле безнең татар бераз булса да укый. Ә урыслар, гомумән, укымый. Урыс басмаларының тиражы ул әле алар укыган өчен түгел. Аларны, нигездә, яһүдләр укый. Шулар яза, шулар языла һәм укый. Урысның әдәбиятын, мәдәниятен Рәсәйдә бүген яһүдләр күтәреп бара.

Халык кабат кайтырмы китапка? Моны әйтүе бик кыен. Бу хакта «Казан утлары» журналында Равил Фәйзуллинның бик акыллы мәкаләсе булды. Ул татар китабының язмышы турында бик борчылып яза. Халык, гомумән, бер татарда гына түгел, башка милләтләрдә дә бизде китаптан. Шулай да мин элекке кебек ябырылып укыган чорлар яңадан кайтмас димим.

Яңа тарихи шартлар, яңа икътисади мөнәсәбәтләр, яңа дәүләтләр бөтенләй яңа татарларны тудырачак. Әдәбиятта да, ниндидер яңа формалар туып, әхлакый-әдәп нормалары яңача яктыртылачак.

Инде үзем турында берничә сүз. Байтак еллар язмыйм. Шуңа күрә мин хәзер кайта-кайта үткәннәрем, язган әсәрләрем турында уйлыйм. Кыю булырга тырышылган. Намуслы булып калырга омтылганмын. Менә хәзер, мин батыр идем, дип бик күкрәк кагасы килә, әмма күкрәккә сугарга йодрык йомшак, күкрәк читлеге дә ул кадәр каты, нык түгел.

Соңгы ике романым — «Йөгез, бер дога!» һәм «Балта кем кулында?»да мин тыелып килгән фикерләремне, әйтергә теләп тә телемне тешләп, туктап калган уйларымны ачыктан-ачык, һич үзгәрешсез яза алдым дип ышанам. Аларның басылуы да дөньяның әзме-күпме үзгәрешләр башланган чорына туры килде. Урыс әдәбиятында да

Аяз Гыйләҗев. 1998

бик зур үзгәрешләр башланган иде бит инде. Урыслар, үзләренең чит илләрдәге язучыларын кайтарып, әдәбиятларын яңарттылар, баеттылар.

Уйланган әсәрләрем бар, әлбәттә. Ике-өч повестем, бер романым уйланган килеш тора. «Аръякта, басма чыккач та» дип исемен дә куйган бик шәп повестем бар. Инде һәр ягы уйланылган. Ләкин мин инде аларга керешә алмыйм. Кереп китә алмыйм мин аңа. Чөнки кемгә адреслыйм мин ул уйларымны? Бүген мин аны кабул итә торган укучыны күрмим. Мин монда бер халыкны гына, укучыны гына гаепләмим. Монда минем үземнең дә гаебем бардыр. Мин, бәлки, заманга ияреп бара алмыймдыр. Заман мине үтеп киткәндер. Бу халәт язучы өчен үзе бер фаҗига. Гомумән, безгә замана авыр килде. Инде язарга тулы иркенлек ачылды, офыклардан кара болытлар тарала башлады гына дигәндә, халык үзгәрде дә куйды. Югалттык без укучыны.

Форсаттан файдаланып, бер фикеремне әйтеп калдырыйм әле. Заманында, үзем яшьрәк вакытта, мин әдәбият турында, әдипләр турында бик кискен фикерләр әйткәнмен. Кайбер кешеләрне хаксызга кимсеткәнмен. Мин бөтен кешене дә үзем шикелле итеп күз алдына китергәнмен, күрәсең. Ялгыш фикерләр дә киткән. Бигрәк тә драматурглар хакында. Сәет Шәкүров гомере буена миңа үпкәләп йөрде. Аңа карата мин дә хаксыз булганмын. Сәет Шәкүров бит ихлас драматург иде. Бар иде аның зур гына пьесалары. Хәй Вахитка да минем бик үк дөрес булмаган бәяләр биргән чакларым булды.

Шуңа күрә мин үзем язган әсәрләремне, истәлекләрне, язган хатларның күчермәләрен саклыйм, аларны хәзер үз киштәмдә генә тотам.

Мин бит ниндидер бер дәрәҗәдә рәнҗетелгән әдип идем. Бервакыт иптәшләрем-чордашларымнан ике кеше — инде минем «Өч аршын җир»ем язылган, пьесаларым бар (бик җитди «Киек Каз Юлы» пьесасы да язылган) — чираттагы премияләрен алгач, миңа: «Аяз, сиңа да бүләк алырга чират җитә, әйеме?» — диләр. Менә ничек карыйлар иде бит. Димәк, миңа әле чират җитмәгән булган... (Ә алар үзләрен миннән өстен итеп сөйләшүләре иде.) Дөрес, соңрак, бер ун ел эчендә, мин бөтен премияләрне дә алып

бетердем. Ләкин соңрак килгән бәхет әзрәк күңелне китекләндереп өлгергән иде шул. Бәлки, мин шуңа күрә кемнәргәдер рәнҗеп, исемнәрен атамыйча гына, шул рәнҗешләремне көндәлекләремдә, язган хатларымда беркетеп барганмындыр. Гаепләштән булмасын, чордашлар, мин кайберләрегездән гафу сорыйм.

Мин, дөньяны аңларга тырышкан кебек үк, һәркемне аңларга тырышам. Һәм нинди дер бер дәрәҗәдә әдәбиятка безнең барыбызның да кирәкле икәнлегебезне тоеп яшим. Әдәбият тигез дәрәҗәдәге талантлардан гына тормый. Ул әнә шул әдәбиятны сөюче энтузиастлардан да тора. Алар да кайвакытта бик кыйммәтле фикерләр әйтәләр. Шуның өчен әдәбият тарихчылары, тәнкыйтьчеләр, акны карадан аерып, чын талантларга үз бәяләрен биреп, энтузиастларга да игътибарлы булсалар икән. Әдәбият өчен бу гаять файдалы булыр иде.

«Заман-Татарстан»

22 сентябрь, 2000



Казан дигән татар шәһәрен салып ятабыз

Соңгы вакытларда Рәсәйдә Татарстанның суверенлыгын күпсенүчеләр калкып чыкты. Саклап калып булырмы ул суверенитетны? Татарстанны киләчәктә нәрсә көтә? Болар хакында мин бик еш уйланам. Әйе, дөньяны тиз генә үзгәртеп булмый икән шул. Бигрәк тә Рәсәй кебек каткан кара империядә. Мөстәкыйльлек алдык, дип сөендек. Мин ул кадәр күтәрелеп бәрелмәсәм дә, республикада барган уңай үзгәрешләр миңа да тәэсир итми калмады, әлбәттә. Ни дисәң дә куанычлы үзгәрешләр байтак бит. Ерак барасы түгел, менә шушы Казан каласына гына күз салыйк. Казан төзекләнә, Казан, ниһаять, башкалага охшый башлады. Аннан, Кама аркылы күпер салып ятабыз... Казан Кремле уртасында Кол Шәриф мәчете өлгереп килә. Ул да бик зур куаныч бит. Кремль эчендә, Кремль тирәсендә бара торган үзгәрешләр гаҗәеп зур. Мин үзем 45 елдан бирле Казанда яшим бит инде. Хәтерлим әле, сугыштан соңгы Кремль эче уртак бер бәдрәфне хәтерләтә иде. Кая карама җимерекләр, сугыш узган диярсең. Кайчан да булса анда Кол Шәриф мәчете манаралары калкыр, күгәреп-күксеп беткән чиркәүгә дә сулыш өрерләр дип күз алдына да китерми идек. Хәлләндек, көчәеп барабыз, Казан дигән татар шәһәрен салып ятабыз бит!

Төптән уйлап караганда, болар бөтенесе дә әнә шул үзебезнең суверенитетны игълан итүнең җимеше бит, әзме-күпме Татарстанның үз байлыгына үзе хуҗа булуның нәтиҗәсе.

«Заман» газетасында Төркия турында байтак кына хатирәләр язып чыккан идем. Шунда бер төп фикерне әйтмичә калганмын. Төркиядәге соңгы үзгәрешләр, аның дөрес икътисади юлга кереп китүе турыдан-туры аларның Тургут Өзал дигән президенты исеме белән бәйләнгән. Ул үзе иртә мәрхүм булды. Ләкин үз илен дөрес юлга бастырып калдырды.

Аяз Гыйләҗевкә 70 яшь тулган көннәрдә аны Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте.

1998

Илләр язмышын хәл иткәндә, халыкларның ролен һич тә киметмичә, илнең икътисады, тоткан сәясәте, ахыр чиктә илнең абруе турыдан-туры һәм тулаем илбашының шәхси характерына, белеме һәм егәренә, тәрбиясенә, ниһаять, күңел байлыгына барып тоташа. Дөньяда моның бик ачык мисаллары бар. Берзаман, Советлар иленнән беренчеләрдән булып Испаниягә дә барган идек. Анда да без элек каһәрләп-сүгеп йөргән генерал Франконың искиткеч тапкыр икътисадчы булуын, белемле, төпле кеше икәнлеген белеп кайттык. Хәзер менә еш кына: «Их, безнең Рәсәйгә дә Тургут Өзал килсә икән!» — дип уйлап куям. Соңгы баруымда шаккатып кайттым мин Төркиядәге үзгәрешләргә. Әлбәттә, Татарстан Президенты Тургут Өзал була алмый. Ни дисәң дә без һаман шул Рәсәй империясе кысаларында яшәүче ирекә чикләнгән дәүләт. Һәм ул шулай булып калачак та. Безгә бервакытта да тулы ирекне бирмәячәкләр, чөнки Рәсәй нәкъ менә шул үзе кайчандыр яулап алган регионнар исәбенә яши. Аның җире казылма байлыкларга бик тә ярлы. Рәсәйнең бердәнбер байлыгы-мактанычы торф инде аның. Безнең кайбер коллегалар югары җитәкчеләрне мактаганны сөймиләр. Шулай да минем, җае чыкканда, Минтимер Шәриповичны яхшы сүз белән искә алып үтәсем килә. Бигрәк тә шушы ун ел эчендә ул үзен чын татар, гайрәтле татар итеп күрсәтә алды. Һәм шушы юл белән барганда әле Татарстанның киләчәге өметле дип саныйм. Менә Рәсәйгә дә яңа президент сайлап куйдык. Бик зур пафос белән. Кемнәрдер, бик нык өметләнеп, күптән көткән кешебез килде, илнең батыры шушы инде, дип аны мактап та өлгерде. Әмма Путин әфәнде үзгәрешләрне һич көтмәгән яктан башлап җибәрде. Рәсәйне 7 регионга бүлде. Алар башына генералларны утыртты. Бер безнең регионда гына Путин вәкиле хәрби кеше түгел бит. Тагын шуны да искә төшереп үтик: безнең Президентыбызга да тәкъдим иттеләр бу вазифаны, әмма аның Рәсәй Президентының бу хактагы тәкъдименә каршы төшәргә көче җитте. Мин моны да зур батырлык дип саныйм. Чөнки Путинның кем икәнен әле бүгенге көнгә кадәр берәүнең дә белеп бетерә алганы юк. Шуңа күрә мин Президентыбыз Минтимер Шәрипович бул-

ганда, безнең Татарстан бара торган юлыннан тайпылмас дип ышанам.


Менә шушы арада гына Мәскәүдә бер төркем зыялылар яңа бер оешма төзеп йөриләр. Моның башында безнең бик мәгълүмебез Василий Аксенов тора. Дөрес, аның янында Березовский кебек яманаты чыккан яһүднең утыруы бераз мине шиккә төшерде төшерүен. Ләкин бу оешма әлегә авторитар режимга каршы барачак бердәнбер көч буларак төзелә. Димәк, Рәсәйдә авторитар режимның кабат калкып чыгуы һәм җиңүе бик мөмкин. Рәсәйдә инде диктатура була алмый, диючеләр күп, тик Рәсәйдә, көтмәгәндә-уйламаганда, әллә ни дә килеп чыгарга мөмкин. Бигрәк тә сәясәт өлкәсендә. Әле алдагы көндә кемнәрнеңдер калкып чыгып, кемнәрнең идарә органнарына үрмәләвен беркем дә алдан әйтә алмый. Шуңа күрә минем үземдә дә авторитар режимның җиңеп чыгуы бик ихтимал дигән шик ята.

Шул ук диктатура, шул ук чикләүләр, шул ук җәза системасының калкып чыгуы ихтимал. Әлбәттә, ул хәзер Сталин режимнарын ук кабатламас. Аның төсе икенче булыр. Ләкин аның асылы шул ук — кеше хокукларын чикләү, кешегә яшәү-иҗат даирәләрен тарайту, кешене ниндидер бер дәрәҗәдә колга әйләндерү, буйсындыру булачак. Гомумән, мондый зур империянең тыныч кына яши алу мөмкинлеге юк. Ул гел сугышырга ашкынып тора, дәгъвалар белән бөтен дөньяга үзен танытырга тырыша. Чөнки әлегә яңа икътисад законнары чыгарып, Рәсәйне алга илтер кеше күренми. Парламентка да өмет-ышаныч бик аз. Мин аның утырышларын карыйм: гел юк-бар тирәсендә бәхәсләшеп гомер уздыралар. Ә бит бер генә үзгәреш тә, халык өчен итәк кисеп җиң ямаудан башка бер генә яхшылык та юк. Ә Рәсәйдә халыкның тормышы шактый кыен.

Илгә күпме бәла-каза китергән Чечня сугышының тукталганы юк, урыс генераллары, халыкны кырып кына аның азагына чыгып була, дип ышандырырга тырышалар. Юкка көчәнәләр. Басып алу сугышларының бер илгә дә яхшылык китергәне юк. Халыклар ирекле һәм горур булырга тиеш.

«Заман-Татарстан»

25 август, 2000



Хөрмәтле укучыларым! Пьесалар ничек туа?

Бүгенге көнгә кадәр мин утыздан артык сәхнә әсәре яздым. Романымны, байтак хикәя-повестьларымны сезнең кулга тапшырдым. Әдәбият сөючеләр һәм тамашачылар белән булган очрашуларда миңа еш кына мондый сорау бирәләр: «Нигә сез ике жанрны сайладыгыз? Нигә йә проза, йә драматургия белән генә шөгыльләнмисез? Жанрлар бер-берсенә комачауламыймы? Гомумән, сезнең әсәрләр ничек туа?»

Ике жанрны сайлавым хак. Тик менә «ни өчен алай»? Бу сорауга бер сүз белән генә җавап бирүе кыен, мөмкин дә түгел.

Жанрлар бер-берсенә комачауламый гына түгел, алар миңа һәрдаим ярдәм итеп киләләр. Проза нәфислеккә, сүзнең кадерен белергә өйрәтсә, драматургия характерлар төгәллегенә, кыскалыкка, кискенлеккә, конкрет дөреслеккә өйрәтә. Бу сыйфатлар проза өчен дә искиткеч әһәмиятле! Бары тик төгәлләнгән ачык характерлар ярдәмендә генә автор әсәрдә чын тормышчан конфликт тудыра ала! Ул конфликт аша сюжет кискенлегенә, ә сюжет аша укучы күңелен тетрәндерерлек нәтиҗәләргә ирешә. Минем берчакта да: «Бу әсәремне повесть итим микән, әллә пьеса итеп кенә языйммы?» — дип икеләнеп торганым юк. Повестьларым повесть булып туа, ә сәхнә әсәрләремне беренче тонык шәүләләреннән үк пьеса итеп күз алдыма китерәм. Әлбәттә, язучының иҗаты тулаем бербөтеннән тора, прозада күренгән мотивлар сәхнә әсәрләрендә дә чагылып-чагылып китә. Ә драма әсәрләрендәге кайбер фикерләр повестьларда да яңгыраш таба. «Җомга көн, кич белән...» повестеннан соң, шул чордарак, мин «Ефәк баулы былбыл кош» драмасын яздым. Аһәң, эчке яңгыраш, борчылулар бер тирәдәрәк килеп чыкты.

Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗановның үтенече буенча «Өч аршын җир» пьесасын яздым. Юк, бу очракта да мин повестьны меха-

ник рәвештә әйләндереп чыкмадым, проза әсәре нигезендә бөтенләй яңа сәхнә әсәре туды! Өр-яңа! Моның шулай икәнлеген «Театральная жизнь» журналында үзе дә икърар итеп чыкты.

Режиссерлар дигәннән, сәхнә осталарының, актерларның, гомумән, театрның драматург иҗатына турыдан-туры көчле тәэсир итә алуын җитди бер мәсьәлә итеп искәртеп узарга кирәк. «Пьесалар ничек туа?» дигәндә, бу мөһим йогынтының ифрат зур икәнлеген тагын бер тапкыр расларга ярый. Драматург бары тик сәхнәдә генә туа, шунда үсә, шунда аның эш алымнары ныгый, чарлана һәм үзенең билгеле бер төсен ала. Драматург Туфан Миңнуллинның иҗаты үзенчәлекле, аны башка берәү белән бутау мөмкин түгел. Ә аның иҗат юлы бары тик режиссеры М.Сәлимҗанов бе-

А.Гыйләҗев. 1998





Уфадан кунаклар килгәч. (Беренче рәт-
тә сулдан) Аяз Гыйләҗев һәм Туфан Миң-
нуллин; икенче рәттә Илшат Йомагулов,
Рифкать Исрафилов, Сөендек Сәгый-
тов. 1980 еллар

Аяз Гыйләҗев, Шәриф Хөсәенов, Туфан
Миңнуллин Г.Камал исемендәге театр-
ның яңа бинага күчкән көннәрендә. 1987

лән янәшә барганда гына табылды, дисәк тә, һич ялгышмабыз. Спортта тренер нинди мөһим урын тотса, драматург язмышында режиссер да шул югарылыкта торадыр. Үз режиссерын табу драматург өчен иң бөек бәхет ул! Режиссер — драматургның киңәшчесе, ярдәмчесе, көрәштәше, фикердәше! Әгәр ул юк икән, драматург никадәрле генә талантлы булмасын, ул сәхнәдә зур һәм даими уңышка ирешә алмый. Һәм, киресенчә, үз драматургы табылмаган режиссер да гомере буе ятимлек кичерә. Замандаш режиссеры яки драматургы булган сәхнә әһелләре генә төпле җиңү юлына чыгалар! Бу уңайдан мин төрле елларда, иҗатымның төрле юлларында үземә бик якын булган олы затларны — хөрмәтле Габдулла абый Юсуповны (бу гүзәл, саф кешегә мин «Урталыкта» исемле повестемны багышладым), таләпчән һәм ярдәмчел Равил Тумашевны, озак еллар Әлмәт театрын җитәкләгән, гомеренең бар көчен бары тик сәхнәгә генә бирә алган Гали Хөсәеновны искә алыр идем. Башкортстанның атаклы сәхнә остасы Рифкать Исрафилов белән күзгә-күз сәхнәдә еш очрашмасак та, ул куйган спектакльләр минем яшәешемдә көч бирүче даими чыганаклар булдылар.

Театр драматург белән аралашып яши. Терсәкне терсәккә куеп эшли. Мәсәлән, әгәр Г.Хөсәенов булмаса, «Әгәр бик сагынсаң...», «Әткәй җырлый да, җылый да...» пьесаларым язылмый иде.

Кайчагында шулай да була ала икән: иҗат эше формадан башлана. Тынгысыз җан-

лы эзләнүчән Г.Хөсәенов татар драматургиясендә эпистоляр жанр юклыгына байтактан ачынып йөрде һәм миннән «хатлардан гына торган» пьеса язып каравымны үтенде. Ике ел вакыт узгач, мин аңа, бөтенләй хатлардан гына тормаса да, күпчелек өлеше Әсфан белән Фәүзиянең язышуларыннан гыйбарәт драмамны тапшырдым. «Әгәр бик сагынсаң...»ның язмышы бәхетле булды. Әлмәт актерлары аны илебезнең бик күп почмакларына алып барып җиткерделәр. Һәм, иң кызыгы... тамашачылар пьесаның тәмамлануы белән бер дә килешмәделәр. Конференцияләрдә, миңа язган хатларында Әсфан, Фәүзия язмышларының дәвамы белән тирәнтен кызыксынуларын белдерделәр. «Геройларның язмышы болай ярты юлда кала алмый!» — диделәр алар беравыздан. Г.Хөсәенов бу пьесаның дәвамын язуымны үтенде һәм «Өткәй җырлый да, җылый да...» драмасы дөньяга туды. Әгәр режиссер, актерлар белән һәм, иң мөһиме, тамашачылар белән бер сулышта булмасак, бу пьеса язылмый иде... Димәк, кайчагында тамашачылар, укучылар төпле фикерләре, урынлы таләпләре белән язучыны алдан көтелмәгән сукмакларга да этәрә алалар икән!

Тамашачылар (ул сез инде, кадерле укучыларым) спектакльләрне карагач, конференцияләрдә, аерым сөйләшүләрдә автор өчен бик кыйммәтле тирән фикерләр әйтәләр, теләкләрен белдерәләр. Беркетмәләрне укып, тамашачыларның зәвыгы нинди сизгер, нечкә, саф икәнлеген күреп, мин таң калам. «Их! — димен мин кайчагында. — Нигә шул телдән яңгыраган фикер-теләкләрнең кайберләрен авторның үзенә дә язып җибәрмәскә!» Тик тамашачы дуслар, кызганычка каршы, драманың авторы да барын онытып җибәрәләр: «Менә театр килгән иде, Дәмирә Кузаева искиткеч акыллы уйнады... Камил Вәлиев тә көчле характерлар тудыра ала! Рамазан Ихсанов һич картаймый!.. Во! Земфира Досаева көлдереп эчебезне катырып бетерде... «Яланаяклы кыз» — Луиза Солтанова — бу юлы Мәдәния әби ролен башкарды!» — дип, үзара тәмләп-тәмләп сөйләшәләр. Пьесаны бөтен нечкәлекләре белән анализлыйлар. Беләм, ишетеп торам, болары өчен дә мең-мең рәхмәт! Тик кайчагында сез, кыйммәтле замандашларым, пьесасын театрга тапшырганнан бирле сезнең фикерне көтеп, әле дулкын-

ланып, әле борчылып яшәгән бер кешене — ягъни мине, драматургны да онытып бетермәгез! Фикерләрегезне, теләкләрегезне, тәнкыйть сүзләрен турыдан-туры аңа да юллагыз! Укучысы, тамашачысы белән тыгыз арадашлыгы язучыга көч, дәрт бирә, илһам өсти!

16 июнь, 1983

Аяз Гыйләҗевнең театр тарихына кагылышлы кайбер

фикерләре һәм хатлары

Үткәнен онытkan милләт тә, гаилә дә мантый алмаганын һәркайсыбыз чамалыйдыр кебек тоемлап, 60 нчы еллар да үткәнебез булып тарихка кереп бара ич, дип, Аязның шул елларда язылган хатларын, фикерләрен теркәштереп ятуым.

Татар театры тарихында үзенең кабатланмас ихлас хезмәте белән кереп калган режиссер Габдулла абый Юсупов Аязны театр сәнгате дөньясына җитәкләп алып керүчеләрнең тәүгесе булды, дисәм, башка режиссерларны рәнҗетмәмдер микән дип тә шикләнәм. Аязга иҗаты дәвамында бик күп режиссерлар белән эшләргә туры килде. Режиссерлардан Равил Тумашев, Гали Хөсәеновлар, Аяз белән кайнар бәхәсләргә керәкерә, байтак спектакльләр чыгардылар. Иң беренче Аязны Г.Камал исемендәге Академия театры сәхнәсенә «Җиз кыңгырау» (октябрь, 1958) спектакле белән Равил Тумашев аяк бастырды, аннан соң да алар кулга-кул тотынышып байтак спектакльләр иҗат иттеләр. Ә менә Габдулла абый белән алар хатлар алышып, фикердәшләр булып яшәделәр. Габдулла абыйның җылы хатлары Аязның архивында кадерләп саклана. Аяз үзе дә театр сәнгатенә кагылышлы фикерләрен Габдулла абыйга мул итеп җиткерә торган.

«Сәхнә» журналын мин бик яратып укып барам. 1 нче саныннан һәрберсен өемә яздырып алып торам. Аяз белән Габдулла абый арасында язышкан хатлар бик күп алар, мин аларның һәммәсен дә журналга тәкъдим итәргә уйламыйм. Шулай да: «Журналның бертөрле генә чыгуы укучының эчен пошыра башлар ич, әйдә әле мин бераз

үзгәреш кертергә талпынып карыйм», — дип язып утыруым. Габдулла абый Аяз белән элемтәгә кергән елларында Әлмәт театрының баш режиссеры вазифаларын башкара иде. Ул анда озак еллар дәвамында бик яратып эшләде. Аннан соң аны Г.Камал театрына да баш режиссер итеп күчерделәр дип беләм. Ничек кенә булмасын, Габдулла абый Аязның «Көзге ачы җилләрдә» пьесасын щепкинчыларның беренче чирканчык алу спектакле итеп 1961 елның 18 ноябрендә сәхнәгә чыгарды. Шул спектакльдә уйнаган яшь-яшь егет-кызлар — Нәҗибә Ихсанова, Ринат Таҗетдинов, Наил Дунаевлар — бүгенге көн театрыбызның умыртка баганалары булып торалар ич. Габдулла абыйны һәм Аяз Гыйләҗевне искә төшерүебез — безнең үткәнебезгә дә бер караш буладыр кебек.

Нәкыя Гыйләҗева

26 ноябрь, 1964

Ялта

Кадерле Габдулла абый!

Сәлам сезгә Кара диңгез ярларыннан!

Рәсәйнең кырык ягыннан кырык кешене Ялтага чакырганнар. Килүчеләр арасында яшьләр аз, шактый гына өлкәннәр бар. Новосибирскидан В.Лаврентьев та безнең кебек үк «семинарист», аңа быел 50 яшь тулды. Җитәкчеләр: В.Пименов, Ю.Чепурин, Н.Громов, И.Вишневская, Л.Зорин һ.б. Мин А.Крон группасында. Әле очрашып сөйләшкән дә юк. Чөнки минем пьесаның русча тәрҗемәсе әзер түгел. Мин «Яланаяклы кыз»ны бик ныклап үзгәртеп, бөтенләй яңабаштан карап утырам. Социаль яңгырашын көчәйтергә телим. Әлмәткә баргач та Роза, Закир рольләрен башкаручылардан оялып кына йөргән идем, аларны да кешегә әйләндереп, бу тормыштагы урыннарын билгеләргә азапланам. Никадәрле уңышлы барып чыгар, белгән юк әле. Русча «Яланаяклы кыз» әйбәт яңгырамый, аннары мин эчтәлекне дә яңачарак ачмакчы булам. Шуңа күрә русча яңа исем куеп тәкъдим итәргә булдым. «Глухие не слышат грома» дип куйдым әле. Соңга таба нишләр? Мин халык хәсрәтен, кеше кайгысын ишетми торган кеше-

ләрне көчәйтмәкче булам. Уйлап карасаң, безнең заман кешелек сыйфатларыбызны



шулай нык бетерде, без кайгы-хәсрәтне, ил хәсрәтен ишетмәс дәрәҗәгә килеп җиттек. Таймураз кебекләр хәтта «күк күкрәгән кебек яңгыраган хәсрәт авазларын» ишетмәс дәрәҗәгә җиттеләр, дип язмакчы булам.

Шактый зур үзгәрешләр була!

Миңа Казанда чакта Сезгә әйтү уңайсыз булган иде. Хәзер инде бу пьесаның бернидәр «төс» үзгәрешләре күзгә чалына башлагач, оялмыйча әйтергә була. Әгәр Шәриф пьесасын куюны үз өстегезгә алмыйсыз икән, нигә минем пьесаны Академиядә куймаска?! Сезнең белән эшләү минем өчен зур бәхет булыр иде. Мин пьесаны бозган дип ачуланмассыз инде. Яхшылыкның, осталыкның аның чиге юк. Бәлки, чыннан да, мин үзем теләгән тирәнлеккә ирешеп кайтырмын.

Менә шушы ун көн эчендә беренче пәрдәне тәмамлап, русчага тәрҗемә итеп (анысы да мәшәкать бит әле аның) А.Кронга һәм П.Деминга укып карыйм. Нәрсә диярләр. Пьесалар юк. Әйбәт пьесалар гомумән юк. В.Блинов исемле яшь рус драматургы бар монда. Аның «Перед судом» исемле әйбәт кенә пьесасы бар, имеш. 9 кешелек. Үзендә әлегә юк. Соратты. Җибәрә алсалар, мин, укып чыгып, Сезгә язып җибәрермен. Казакъ, кыргыз дуслардан бик йомшак кешеләр килгән. Кыргызы эчүдән бушый алмый да әле. Аннары без үзаралай бик нык танышып та өлгермәдек. Мин Сезнең наказны хәтердә тотам, аны үтәргә тырышырмын.

Белеш, танышлар шактый җыелдык.

Тик монда бик яңгырлы-пычрак көннәр. Беркая чыгып-йөреп булмый. Җил, җил!

Нинди зур өч катлы йортны дер селкетә. Тауларда кар, тауларда болыт...

Килгән көннәрне бераз климат алыштырып, сырхаулап йөрдем. Ике көн инде әйбәт кенә эшлим. Укыйм. Китапханә бай гына. Тыныч.

Китәр алдыннан Сезгә хат җибәргән идем. Алдыгызмы? Казан белән хәбәрләшәсезме? Гөлчәһрә апалар ни хәлдә? Туфанның пьесасына җан өрдегезме инде?

Сездән берәр хат ала алсам, бик шат булыр идем.

Г.Камал театрының яңа бинасында беренче спектакльдән соң. 1987



Дусларга сәлам!

Шәриф белән сөйләшү ничек бетте? Аның бүген туган көне. Утыз биш тула. Да, яшьләр үсә... Туган көне белән котлап телеграмма җибәрдем, һәм менә хәзер хат та язам...

Хушыгыз, кадерле Габдулла абый!

Сезне һәрчак сагынып, Аяз

7 сентябрь, 1965

Казан

Кадерле Габдулла абый!

Риза абый мине җыелышка чакырырга кергәч, мин болай дигән идем: «Культура министры һәм Тутаев анда булаламы?» Риза абый: «Булалар, булалар! Бик дәрәҗәле сөйләшү оеша!» — дип вәгъдә кылган иде. 31ендә мин, Тутаевның да, Гыйззәтуллин-ның да булмаячагын белешеп, җыелышка эз дә басмадым. Һәм бик дөрес эшләгәнмен икән. Чыннан да, алар берсе дә язучылар янына килмәгәннәр! Коточкыч ялыктыргыч, эчпошыргыч лыгырдавык кына килеп чыккан. Ничә кешене күрдем, берсе дә юньле нәрсә сөйли алмадылар. Ни турында сүз баруын да хәтерләп кала алмаганнар. Иң элек Риза абый ике сәгатьлек речь сөйләгән. Сезне әйбәт сүзләр белән искә алган, яшьләр белән бик нык эшли, дигән. Равил Тумашевны нык кына теткән. Менә шул. Аннары Илялова, чыгып: «Яшьләр өчен языгыз! Курчак театры өчен языгыз! Хәзер аларга түләү дә артты», — дип, язучыларга ялкынлы лозунг ташлаган... Чыгып сөйләүчеләр-нең нотыкларын сөйләп бетергәнче утыра алган кешеләрне очрата алмадым әлегә...

Бу якшәмбедә Баян абыйларның бакчасына барып кайттык. Озак кына сөйләшсәк тә, җыелыш турында хәтердә калырлык мәгънәле сүзгә тап булмадым.

Аяз Гыйләҗев Башкортстанда үткән очрашуларның берсендә чыгыш ясый



Татарстанның халык язучылары Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах

Бармаган өчен Сез мине ачуланмыйсыздыр бит? Яратмыйм шул буш сөйләшүләрне! Кешеләр аерым-аерым гына сөйләшкәндә фикер әйтә алалар, ә бергә җыелгач, без һаман Яшин рычагларына әйләнеп китәбез. Куркыныч бер дәрәҗәдә чирлибез бит шул чир белән! Кешеләр, газетада Рәшидә апаның мәкаләсен күрдек, ул «Идият Абдулловның пьесасын куярга уйлыйбыз» дигән, дип бик шаккаталар. Безнең Академия театры шул дәрәҗәгә үк барып җиттемени инде?! Ә бер зур гына иптәш: «Мин Академия театрының тагын да ныграк аска тәгәрәвен телим, югыйсә шунсыз югарыдагы иптәшләр акны карадан аера алмыйлар. Инде бөтенләй егылгач, бәлки, күзләре ачылыр дип уйлыйм», — дип куйды. Бусы куркыныч...

Мин ай ярымнан артыграк Самат Шакирның повесте белән утырдым. Мин аның махсус редакторы да, әдәби эшкәртүчесе дә. Шактый вакытым һәм көчем шуңа китте. Кичә шуны бетереп, бүген җиңел сулап Сезгә хат язам. Тагын бер айлык эшем бар дип саныйм, аннары пьесага утырам. Тик бу зур сер, аны берәүгә дә әйтмәгез. Шушы арада ялга чыгып Бигешкә кайтып китәргә дип торам. Ничек булыр.


Сездәниләр бар?

Әлмәтле дусларның һәммәсенә сәлам. Сезгә саулык, сәламәтлек, иҗади дәрт теләп калам.

Көннәр бик матур, көз әйбәт килә, Сезнең дә кәефләр шәп булсын инде, Габдулла абый!

Кулыгызны кысып, Сезне сагынып, Аяз





# Аяз Гыйләҗев — драматург



ГАЛИ АРСЛАНОВ

«Өч аршын җир»

Минзәлә татар дәүләт драма театрының Казандагы гастрольләре афишасында Аяз Гыйләҗев пьесасы буенча куелган «Өч аршын җир» спектакле күренекле урыннарның берсен алып тора. Башта повесть итеп язылып та, соңрак сәхнәгә менгән бу әсәр Бөек Октябрьнең 70 еллыгына багышлап куелуы белән генә түгел, бәлки күтәрелгән проблемаларының зурлыгы, актуальлеге, үзәк геройларның масштаблылыгы, сурәтләнгән вакыйгаларның киеренкелеге белән дә тамашачыларның җитди игътибарына лаек. Кылган гамәлең өчен ил, халык алдында, туган җир каршында җаваплылык темасы бүгенге үзгәртеп кору чорында иң кискен куелган проблемалардан саналырга хаклы.

Алдан ук шуны әйтеп үтик, әсәр республика җәмәгатьчелегенә повесть буларак та, Г.Камал исемендәге Татар дәүләр академия театры спектакле буенча да шактый яхшы таныш. Шулай булса да, минзәләлеләр хезмәте башкалабыз тамашачыларында зур кызыксыну уятты.

Спектакльне сәхнәгә театрның баш режиссеры Фаил Ибраһимов куйган. Аның фикеренчә, бу әсәр, трагедиянең кайбер традицион алымнарын кулланып язылуга карамастан, күбрәк драма таләпләренә җавап бирә. Шунлыктан режиссер тамашаның жанрын драма дип билгели, һәм аның әлеге фикере спектакль барышында раслана да.

Режиссер бу очракта художник хезмәтен дә үз өстенә алган. Ул тәкъдим иткән

сәхнә бизәлеше тормыш ваклыкларын бөтен нечкәлекләренә кадәр чагылдыруны максат итеп куймый. Киресенчә, аерым күренешләрдә (әйтик, Шәйхеразый карт йорты, Мирвәлинең тегермәндә эшләү чорында торган квартирасы) көнкүреш билгеләре шактый тулы саклanса да, гомумән алганда, художник күп мәгънәлелеккә, вакыйгалар урынын шартлы рәвештә билгеләүгә йөз тоткан. Шуңа да тамаша тукымасында сәхнә бизәлешенең аерым детальләренә төрле-төрле бурыч йөкләнгән, һәм алар күп чакта бара торган вакыйгаларга яңа мәгънә өстиләр.

Мисал өчен байтак күренешләрдә сәхнәдә булган зур урам капкасын гына алыйк.

Иң беренче ул артистлар һәм тамашачылар арасында торган үзенчәлекле капка-пәрдә, «спектакль капкасы» булып тоела. Ул ачылып китә һәм тамаша башлана. Бераздан шушы ук деталь Шәйхеразый карт хуҗалыгының йорт-җиренә ут төртүче Мирвәли ташлап чыккан авыл капкасы — зур дөньяга юл хезмәтен үти. Ә иң соңыннан, спектакль финалында, шушы ук деталь инде картайган, авыр гаебе аркасында гомере буе читтә яшәргә мәҗбүр булып та, ахыргы көннәрендә ил алдына кайтып егылган Мирвәли каршында торган туган җир капкасы буларак кабул ителә.

Шушындый ук мәгънә үзгәрешләрен спектакльнең башыннан ахырына кадәр сәхнәдә торган ат арбасын файдалануда да күзәтергә мөмкин. Беренче эпизодларда ул авыру Шәмсегаянны авылга алып кайта торган гадәти ат арбасы. Алга таба — вагон сәкесе, яшьләр түшәге, Мирвәлинең шәһәрдәге квартирасындагы койка һ.б. Ә икенче — гомумиләштерү, метафора яссылыгында ул — кая гына барсаң да, кара сакалың кебек арттан калмыйча, теләр-теләмәс кенә шыгырдый-чыелдый сөйрәлә торган, майланмаган, шулай булса да, тартып барырга кирәк булган язмыш арбасы. Кайгыда да, шатлыкта да Мирвәли белән бергә. Тик, ай-һай, җиңел түгел шул ул арба. Тормыш

сикәлтәләре аны төрлечә ыргыта, ега. Ә иң ахырдан ул, геройның үзе кебек, ярым җимерек хәлендә туган җир капкасына кайтып сөялә...

Аңлашылганча, спектакльнең үзәгенә ике язмыш — башта авылның урта хәлле

крестьяны, соңрак ерак Себер якларындагы бер тегермән эшчесе Мирвәли (артист Р.Муллин) һәм аның хатыны Шәмсегаян (артистка Р.Харисова) язмышлары куелган. Бу гаиләдә ир — баш, хатын — муен. Шулай булса да, гаилә башлыгы гаебе өчен Мирвәли дә, Шәмсегаян да бертигез түли. Хәтта Шәмсегаян күбрәк тә түлидер кебек. Чөнки аның сагынулары, кичерешләре көчлерәк һәм тирәнрәк. Чит җирләрдә күңел юатыр өчен Мирвәлинеке кебек эше дә, башка төрле онытылырлык мөмкинлеге дә юк шул аның. Бары тик китаплар да, туган җир кырларын карта дәрәҗәсендә төгәл сурәтләгән чигүле сөлге генә бераз ярдәм итә. Сагыш, сагыш, сагыш... Шул сагыш, сагыну Шәмсегаянны авыруга сабыштыра, вакытсыз гомерен өзә. Ә бит ничек матур башланган иде аларның тормышлары.

Спектакльдә Мирвәли-Р.Муллин һәм Шәмсегаян-Р.Харисованың яшь чактагы аңлашу күренеше, өйләнешкәч төп йорттан китеп Тайфә әбидә тору эпизодлары ниндидер бер күтәренке рух, лирика, эчке җылылык белән сугарылганнар. Ул чорда кем генә аларга сокланып карамады икән дә, кем генә бәхетле тормыш теләмәде икән. Тик озын гомерле булмаган икән шул яшьләрнең бәхете...

Арага салкынлык керткән иң беренче әче җил Мирвәли кулына мал кергәч, әтиәни үлеп, йорт-җиргә ул хуҗа булып калгач исеп китә. Иренең мирас сандыкларын ничек актаруын аптырап карап торган Шәмсегаянга Мирвәли нигәдер артыграк шатлана, чамадан тыш кабалана төсле тоела. Ирен җаныннан артыграк күреп яраткан хатын кабалануның сәбәбен бик тиз ачыклый. Көтелмәгән дәрәҗәдә мал ярата, байлык ярата икән бит аның Мирвәлие!!! Шушы вакыйгадан соң әлегә кадәр шактый салмак булган спектакль тизрәк ага башлый, хуҗалыкка ут салып, авылны ташлап китү спектакльдә исә үзенең кульминациясенә күтәрелә.

Спектакльнең икенче пәрдәсе вакыйгаларга артык бай түгел. Ул тулысы белән диярлек Мирвәли белән Шәмсегаянның чит җирдә ничек сагынып яшәүләрен, аларның газаплануларын күрсәтүгә багышланган. Бәлки, шуңа күрәдер дә соңгы пәрдәдә Р.Муллин һәм Р.Харисовалар уенында бертөрлерәк төсмерләр, интонацияләр кабатлана баш-

лый. Артистларга бу өлештә үз рольләрен җанландыру, баету, бертөрлелектән китү юлларын эзләргә кирәктер. Әлегә алар уенындагы җитешмәүчелек бөтен икенче пәрдәне озын, сузынкы итеп күрсәтә.

Әсәрдәге Хәдичә, Шәйхеразый, Тайфә карчык, Айдаш, Хәйдәр, Фельдшер кебек персонажлар төп геройларны теге яки бу яктан ачыклау өчен хезмәт итәләр.

Композитор Р.Яхинның спектакль өчен язган музыкасы да игътибарга лаек. Вакыйгалар агышында музыка шактый күптөрле эш башкара: геройларның эчке кичерешләре турында сөйли, вакыйгаларга тиешле атмосфера тудыра, артистлар уенына кирәкле темп-ритм бирә. Танылган композиторның театр белән элемтәсе һәр ике як өчен дә файдалы икәнен билгеләп үтү зарури.

«Социалистик Татарстан»

2 июль, 1988



ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВ

Ил өстендә торган томан

аның акылын томалый ал-

мады

Безнең яшьлек сугыш елларына туры кил-

де. Мин бит Аязның яшьтәше. Ул чор балала-

рының язмышлары охшаш булып, алар җәм-

гыятьтә барган үзгәрешләр тәэсирендә иртә

өлгерергә мәҗбүр ителделәр. Шәт шулай

икән, бер үк идеологик тәрбия алган буын фи-

керләү юнәлешендә дә бер ызанда үскәнбез

булып чыга бит инде. Бу хакыйкать өстән ге-

нә фикер йөртеп уйлаганда шулаен шулай, лә-

кин шәхес дигән гыйбарә дә бар бит әле. Аяз

— үзенчәлекле, үзенә бер төрле, Ходай Тәга-

лә тарафыннан иңдерелгән талантка ия бул-

ган кабатланмас шәхес иде.

Мин, Аязның үткәндәге тормышы белән, иҗатындагы күпчелек әсәрләре белән танышa барган кеше буларак, үземнең 1970 елда булган беренчел диярлек кискен борылыш алган тәэссоратым турында язудан башлыйсым килә. Шул елларда, Татарстан радиокомитетына чакырып, миңа Аязның «Кызлар хатлары» дигән повестен радиода укырга тәкъдим иттеләр. «Әһә, мин әйтәм, наконец, Аяз да кызлар белән егетләр арасындагы мөнәсәбәтне мәхәббәт хатлары аша тасвирларга алынган икән», — дим. Монда инде ул әллә нинди проблемалар күтәрә алмагандыр кебек тоелды миңа. Юк икән шул: анда ул зур проблемалар күтәргән булып чыкты. Мине гаҗәпләндергән беренче тәэсирле тәрбия шул булып чыкты. Сәнгать әсәренең төрле төрләре аша да ил мәнфәгатьләрен кайгыртып язып була икән дигән нәтиҗә ясадым. Ул әсәрне мин

радиода бик яратып укыдым. Хәзер дә радио фондында сакланадыр дип уйлыйм.

Мин 1945 елда Казан театр училищесына укырга кердем. Бу инде безнең яшьтәш-ләрнең егетлеккә кереп барган чоры: фәкыйрь тормыш та рухыбызны йөгәнли алма-ган, бәхетле киләчәккә ашкынган халәттәге дөнья! Шул елларда, дөресрәге 1944 елдан, Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылган иде. Театр училищесы студентлары белән университет студентлары ныклы элемтәгә кер-деләр. Моның сәбәпчесе Латыйф Җәләй булды. Ул тел һәм әдәбият галиме булып танылган профессор булса да, хезмәтләренең күпчелеге татар теленең диалектологи-ясе, тарихи фонетика һәм грамматикасы, орфоэпия һәм стилистикасына кагылышлы иде. Көч-куәте ташып торган бу яшь кенә галим (1894–1966 елларда яшәде), татар яшьләрен бер тирәгә туплап, үзенә алмаш әзерләү максатыннандыр дип уйлыйм, түгәрәк оештырды. Университеттан Аяз, тагын байтак егетләр бар иде анда. Ә театр училищесыннан Мәүлә, Шамил Бикчуриннар шул түгәрәкнең чын бирелеп, иҗат дәрте белән янып йөрүчеләре булдылар. Мин аерылып торганнарына гына тукталам. Мәү-лә — чәчрәп торган мишәр егете, Ходай тарафыннан бирелгән талантка ия зат. Ул татар тарихын каян шулкадәр төптән өйрәнеп җиткергән булгандыр, коеп куйган тарихчы галим иде ул. Такташ, Тукай иҗатын яттан белүе белән бергә шәп итеп тамашачыга җиткерергә дә сәләтле иде. Мәүлә Колый иҗаты аның өчен нык якын иҗат булып кабул ителде, чөнки алар адашлар. Ул түгәрәкләрдә мин үзем бик актив йөрүче булып исәпләнмәгән булсам да катнаштым. Университеттан әдәбият буенча Хатип Госман, безгә лекцияләр укып, чын әдәби әсәрләрнең асылын аңларга өйрәт-те. Шул сөйләшүләр барышында Шамил Бикчурин белән Мәүләләр Аязны инде өметле үсеп килүче язучы итеп тасвирлыйлар иде. Л.Җәләй, Х.Госман, Н.Исәнбәтләр бу талантларны гел күз уңында тотарга тырыштылар. Аларның ничектер Н.Исәнбәт бе-лән рәсми булмаган элемтәгә кереп, өенә дә барып йөрүләре исемдә калган минем. Н.Исәнбәт, профессиональ язучы буларак, алар белән аралашып яшәде, рухи ярдәм

күрсәтергә теләде дип беләм. Ләкин бу яшьләр, ул елларның фәкыйрь тормышында яшәү чыганагы таба алмыйча, төрлесе төрле якка таралыша да башладылар. 1946 елларда Аяз Казанда күренми башлады. Л.Җәләй театр училищесында укытуын да дәвам итеп, түгәрәк эшен дә алып барды, ләкин Аяз барындагы күтәренкелек сүрелә төште кебек. Мәүлә дә, укуын да тәмамламыйча, Әлмәт театрына китте, Шамил Бикчурин да язучылыкка өстенлек бирде. Алга таба мин Мәүләнең язмышын Аязның «Йәгез, бер дога!» романын укыгач белдем. Ул үзен-үзе Нижгар төрмәсендә үтергән дип аңладым...

1946–1955 еллар арасында минем күз уңымнан Аяз югалып торды. Үзем дә, 1953 елда армия хезмәтеннән кайткач, Г.Камал исемендәге Академия театрында эшләвемне дәвам иттем. (1949 елдан, театр училищесын тәмамлаганнан соң, мин анда эшли башлаган идем.)

Ни хикмәттер, миңа шулай тоела, 1950–1960 елларда сәнгать дөньясына яңа буын килеп керде. Алар өлгергән рәссамнар иде. В.Аксеновның «Коллегалар»ы Большой театрда куела башлады. Ул яңарышлар башлануның хәбәрчесе кебек кабул ителде. Андрей Вознесенский, Евгений Евтушенко, Белла Ахмадулиналар яңарыш булып әдәбият мәйданына калыктылар. Туфан Миңнуллин, яшьрәк булса да, соңрак — шулар турында дип кабул иттем мин — «Хушыгыз» дигән әсәрен язды...

Менә шул 60 нчы елларда Аяз да татар театры дөньясына бер нурланыш булып килеп керде. Ул «Җиз кыңгырау» пьесасы белән башланды. Пьесаны сәхнәләштерү эшенә Равил Тумашев алынды. Аязның әсәрләрендә исем төп мәгънә чыганагы булып тора. Әсәр «Җиз кыңгырау» дип аталса да, ул бит кыңгырау турында түгел иде. Җиз кыңгырау яңалык хәбәрчесе вазифасын башкаручы ич, миңа калса. Әсәрдәге төп образ Хөрмәтулланы Фатих Колбарисов башкарды. Хөрмәтулла анда мәчет төзергә йөрүче. Бу бит ул чор өчен бөтенләй колакка ят аһәң. Иманга кайту идеясен Аяз кыю рәвештә күтәрде. Равил Тумашевның да яшь вакыты. Пьесада Аяз өчен кадерле зат — Мәүлә образы да исем тапкан иде. Аяз аны дустының рухына дога булып барсын дип атаган-

дыр дип фараз кылырга гына кала. Мин анда авыл егете Гәрәй ролен башкардым. Люция Фарсина төп героиня — Разия ролендә уйнады. Аның матур итеп җырлаган җырлары хәзер дә колагымда яңгырап саклана. Люция Фарсина якты талантка ия актриса иде. Җылы сүзем, якты хисләрем аңа дога булып барып ирешсен, Раббым! Күңелемә аның җырлары язып куелган. Менә шул җырны җырлап та алам әле.

Чәчәкләр күп, ләкин чәчәк өзмим,
Табу өчен шундый ислесен.
Мин тапканчы шундый бик ислесен,
Гөл үсмәсен.
Җил дә исмәсен...
Яшь наратка сөялеп көтәм сине,
Чәчләремне сыйпап җил исә.
Дулкынланып китә чәчәк исе,
Акрын атлап янга син килсәң...

Ул пьесада Мәсгут Имашев Мәүлә ролендә, авыл карты ролендә Габдулла Фәтхуллиннар уйнадылар. Бу инде драматургиядә яңа сүз иде. Бүтән язучылар совет хөкүмәтенең кылган эшләрен тулысынча хуплап язып ятканда, бу гайре табигый кылану кебек яңгырады. Бу спектакльне куярга рөхсәт бирсәләр дә, бик хупламадылар, кызганыч, шуңа озак бармады.

«Җиз кыңгырау» спектакле сәхнәгә чыккач, безне Равил Тумашев кунакка чакырды. Мәҗлес дустанә, бик күңелле узды. Мәҗлеснең хуҗабикәсе — Равил Тумашевның хатыны атаклы галимә Диләрә ханым Тумашева — мул өстәл әзерләгән иде. Ул еллар өчен бу да бик мул күңелле кешеләр тарафыннан гына оештырыла торган гамәл иде. Шунысы мине гаҗәпләндерде: Аяз ул мәҗлестә ләм-мим эндәшмичә диярлек утырды. Халык шау-гөр килеп бәхәсләште, сөйләште, көлеште. Аяз, калын күзлеген күтәргәләп урынына куя-куя, гел тыңлап кына утырды. Ә бит Аяз

спектакль чыкканчы җанлы киңәшче, фикерле язучы, әйтер сүзен шартлатып сәхнәгә чыгып әйткән кеше иде. Ни мактап, ни хурлап сүз әйтмәде. Димәк, аның сүзе артистларга үтеп кермәгәнлеген аңлаган ул! Кайтырга чыктык. Анда да мин аның ник эндәшмәвенең сәбәбен сорадым — ул җавап бирмәде. Равил Тумашев та сак эш иткәндер, без дә аңлап җитәрлек булмаганбыздыр. Ә Аяз ГУЛАГ «тәрбия»се алып кайткан кеше...
1960 елның көзендә «Җиз кыңгырау» спектаклен чыгаруга, 1961 ел башына безгә Аяз «Киек Каз Юлы» пьесасын өлгертеп куйган иде. Аны Ширияздан Сарымсаков режиссерлыгында куярга алындык. Анда төп рольдә Хәлил Әбҗәлилов булды. Художнигы — Әнәс Тумашев. Бу инде Ширияздан ага өчен чын-чын ачыш булды. Таҗи Гыйззәтләр буыныннан соң ташкын булып драматургиягә килеп кергән Аяз Гыйләҗев ул еллардагы режиссерлар тарафыннан «Яңа фикер» иясенең килүе итеп кабул ителсә дә, нәтиҗәләр аяныч була торды. Аязның әйтергә теләгән проблемалы фикерләрен тамашачыга җиткерерлек режиссерлар табылмады. Ширияздан Сарымсаков югары рухта куярга дип дәртләнеп тотынса да, көтелгән нәтиҗә булмады. Әсәр бит күктәге Киек Каз Юлы турында түгел — фәлсәфи әсәр иде ул. Нәфис хисләр аша гына аны тамашачыга җиткерергә була шул. Язмыш юлы — Киек Каз Юлы иде ул. Бу әсәрнең куелышына да, фикер юнәлешләрен тикшерүгә дә обком әгъзалары кул тыкты. Нәтиҗәдә әсәр начар яңгыраш тапты. Аяз әсәрләрен нык эшләнеп беткәч кенә безгә тәкъдим итте. Ул: «Мин сезгә чиле-пешле әсәр китермим, уйланып беткәч кенә ташка басам, монда үзгәртерлек фикер юк», — дия иде.
1961 елда «Көзге ачы җилләрдә» язылды. Бу әсәргә җан өрергә Мәскәүдән яшь талантлар — яшь көчләр кайтты. Щепкинчыларның куйган беренче әсәре «Көзге ачы җилләрдә» булды. Аны Габдулла абый Юсупов үзенең җитәкчелегендә Мәскәүдә укып кайткан студентлары белән куярга алынды. Яшьләр белән арадашлыкта өлкәннәрдән бары тик Галимә апа Ибраһимова, Хөсәен абый Уразиков, Вера Минкина һәм Камал III ләр генә катнаштылар. «Көзге ачы җилләрдә» аша Габдулла ага Юсупов

белән Аяз Гыйләҗев фатихасын алып, щепкинчы яшьләр театр дигән зур сәнгать дөньясы бусагасын атлап, алга таба мөстәкыйль, кулларыннан җитәкләп торучы булмаган хәлдә дә иҗат итә алачакларына ышанычлы «юллама» алып, чын артистлар булып әвереләләр. Аяз Гыйләҗевнең бу пьесасы чын сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрелеп тамашачыга җиткерелде. Ул, 300 мәртәбәләп безнең театр сәхнәсендә уйналып, халыкның яратып кабул иткән спектакле булды. Автор бу пьесасында да зур проблемалар күтәрә: яшьлек хисләренең ялгыш юлга кереп китүе дә бар, аңа тәҗрибәле өлкәннәрнең ярдәме дә кирәк. Хәзерге театрның кендеге булган яшьләр шунда чирканчык алдылар.

«Җиргә тапшырылган серләр» әсәрен Рәфкать Бикчәнтәев сәхнәләштерде. Бу инде тирән фәлсәфи әсәр иде. Күргәнебезчә, Аязның пьесалары «каты токым» кебек тоелгандыр, ахры, аны куярга алыну-алынмау катлаулы мәсьәлә булып торгандыр режиссерлар өчен. Бер әсәрен куеп авыр сабак алсалар да, икенчесенә тәвәккәлләүчеләр күренми.

Равил Тумашев безнең театрдан ул вакыттагы Күчмә театрга баш режиссер итеп билгеләнде. (Хәзерге көндәге К.Тинчурин исемендәге Драма һәм комедия театры.)

Равил Тумашев белән алар кулга-кул тотынып бик күп сәхнә әсәрләре иҗат иттеләр.

Аяз бөтенләй башкача юнәлештә фикер йөртүче автор иде. Аны шуңа күрә режиссерлар да ачып җиткерә алмады.

Заказной пьеса дип әйтү гадәте бар бит инде. Октябрь революциясенең 50 еллыгы уңае белән 1967 елда театрда спектакль чыгарылырга тиеш иде. Ул пьесаны Аяз, Марсель заказы буенча Шамил Усмановка багышлап, «Шамил Усманов» дип атап язды. Бу спектакль әйбәт куелды, әйбәт яңгыраш тапты. Мин Куйбышевны уйнадым. Шамил



Усманов ролендә Н.Дунаев булды.
Дунаевның зур уңышы булды бу роль. Самарада булган хәлләр тасвирланган иде анда.
1971 елда «Эңгер-меңгер» пьесасы Празат Исәнбәт тарафыннан сәхнәләштерелде. Мин бу спектакльдә Таштимер ролен башкардым. Аяз, характерга яраклаштырып, рольгә дә исемне җиренә җиткереп бирә торган иде. Бу спектакльдә Гөлсем Исәнгулова, Илдар Хәйруллин, Ибраһим Гафуров, Гали Надрюковлар уйнады. Әйбәт спектакль иде. Аның фикеренә төшенеп җитсәк тә, авыр иде куярга. Таштимер башта таш-тимер булган, тора-бара, яши-яши, тормыш аны куркак бер җан иясенә әверелдергән, заман үзгәрткән. Әсәрнең исемендә иде хикмәт: кояш та чыкмый, төн дә түгел, ә юлыңны табарга кирәк. Бару юлы билгеләнгән иде кешенең — мәгънә шунда. Менә нинди табышмак! Шәп әсәр иде ул.
«Кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла» дигән гыйбарә ята иде аның

әсәрләренең төбендә.

Марсель юкка гына Аязга тар-

тылмый иде шул. Марсель Аязда

үзенең фикердәшен таба иде. Мар-

сель безнең театрга килгәч тә Аяз

белән чын дус булып китте. Алар гаилә дуслар булып аралаштылар. Марсель, ялгыз яшәгәндә, Гөлнарга өйләнгәнче, гел Аязларга барып йөрергә ярата иде.

1965–1967 еллар тирәсе булды микән, төгәл анысын хәтерләмим, Марсель миңа: «Әйдә, Шәүкәт, Аязларга барып кайтабыз», — дип, мине ияртеп аларга алып китте. Аязларның ул вакыттагы Ленин районының Воровский урамындагы ике бүлмәле «хрущевка» фатирларына киттек. Марсель мине нинди максат белән ияртkәндер, анысын да белмим, хәтерләмим, хәтеремдә шунысы: өйдә алты һәм сигез яшьләр тирәсендәге ике малай кайнаша иде. Алар Искәндәр һәм Мансур булып чыктылар. Ә Марсель ул өйдә чит кеше түгеллеге аларның аралашуыннан аңлашылып тора иде. Өлкәннәр өйдә булмагач, без аларда озак тоткарланып тормадык, кайтып киттек. Бу инде чәй эчәргә генә бару түгел иде.

Аязның табигатькә мөнәсәбәте дә үзенчә булды. Ул елның һәр фасылын яратып, көтеп ала торды: аның байлыгыннан файдаланганда рәхмәт укый-укый, Ходайга ялварып, тагын шундый мизгелләрнең кабатлануын, балаларына да дәвам итүен сорый торган иде. Ул, язга чыгу белән, урманга барып, балтырган җыеп, тәмле аш пешерүне көтеп алды. Җәен урманга барып, шома көпшә, кәҗә сакалы һ.б. үләннәрне яратып, белеп ашавының ләззәтен сөйләп, безнең һушыбызны ала иде. Җәйләрен Иделгә йөреп балык тоту Аяз өчен җәннәт түре булып саналды. Көзләрен урманга йөреп гөмбә җыйдылар алар. Аязлар тозлаган гөреҗдәне ашау Марсель өчен иң затлы деликатес санала иде. Аяз, гөмбә тозлау ысулларын фәнни китапларда дөрес аңлатмауларын, ә аның хатынының алардан бик күп мәртәбәләргә артыграк белемле булып эш итүен сөйләп, мактанып, безнең авызлардан су килергә мәҗбүр итә иде.

В.Миншин һәм Р.Таҗетдинов «Көзге ачы җилләрдә» спектаклендә. 1961

Безнең дәвердә генә дә табигатебезнең экологик чисталыгына зур зыян салынганлыгы һәммәбезнең күз алдында. Аяз өчен — нечкә хисле, самими рухлы зат өчен — мондый тискәре күренешләрне янмый-көйми генә үткәреп җибәрү мөмкин хәл булмаган, билгеле. Аның дөньядагы һәр тискәре күренешкә реакциясе булып торды. Ул шушы тискәре күренешләргә битараф булмавын белдергән «Китмәгез, тургайлар!» дигән пьеса язды. Аны Марсель сәхнәләштерде. Ул спектакльдә мин Сәймән образында уйнадым — кыйммәтле мехлы җәнлекләрне аулап сатучы тискәре кеше ролен башкаручы булдым. Аның әсәрләренә салынган фикер тирән эчке борчылулар аша бирелгәнлеге аңлашылса да, тамашачыга җиткерү бик авыр булды. Ул көлке өчен язмады: милләтне, халыкны үтемле сүз көче белән тәрбияләргә тырышты.

«Өч аршын җир» әсәрен сәхнәләштерү театр тарихы өчен үзе бер маҗаралы этап булды, дисәм, дөресрәк булыр дип уйлыйм. Марсель, гомумән, дөнья әдәбиятын укып, күзәтеп барды. Ә инде татар әдәбиятына килгәндә, аны ул энәсеннән җебенә кадәр укып торды. Алар Аяз белән дус булып яшәгәнгә, аның эчке кухнясыннан да хәбәрдар булып яшәде. Марсель Аязның «Өч аршын җир» әсәрендәге фикерләргә режиссер күзлеге аша карап, аны сәхнәдә күрергә теләп янып йөри башлады. Аяз белән үзара сөйләшүләре, сәхнәләштерүгә алыну турындагы әңгәмәләре берничә елларга сузылды булса кирәк. Бу әсәр матбугатта «Совет әдәбияты» журналында 1962 елда ук чыккан иде бит инде. 1970 еллар тирәсендә Аяз аны Марсельгә сәхнәләштереп китерде. Марсель, аны яратып, куярга планнар корып, фантазиясен шуңа төбәде. Ригадан рәссам чакыртып, эскизларын ясатты. Марсельнең бу планнары обком тарафыннан хупланмады, эш туктатылды. Шулай итеп, Аязны монда да рәнҗеттеләр!!! Шулай итеп, бу әсәр озак сандыкка салып куелды. 1986 елларда Марсель бу мәсьәләгә тагын кире кайтты. Ләкин инде проблеманың кискенлеге сүрелә төшкән иде. Марсель аны куйды,

бөтенсоюз күләмендәге аренага да чыгарды, Мәскәү телевидениеләреннән күрсәттеләр. Әсәр тамашачы тарафыннан да бик яратылып каралды, ләкин, ни кызганыч... Аяз да, Марсель дә еллар алган гомерләренә бирешә төшкәннәр иде шул!

Ниһаять, Аязның зур проблемалар күтәреп язган, ачы җан авазы белән язылган «Югалган көн» әсәре турында әйтәсем килә. Бу әсәрне безгә кадәр Качалов исемендәге Рус драма театры да сәхнәләштергән иде. Бездә аны Дамир Сираҗиев режиссерлыгында сәхнәләштерделәр. Мин анда Карт ролендә уйнадым. Әсәрдәге фикер бер көн турында түгел, гомум ил күләмендәге фаҗигагә бәйле итеп тасвирлана. Ил өстендәге томан кешеләрнең акылын томаламасын иде дигән катгый борчылу авторны бу әсәрен иҗат итәргә алындырган. Андагы Картның монологы мине тетрәндергән иде. Ул: «Кая барыйм мин? Нишләп йөрим? Йөрмәсәм дә, кешеләрнең аз-маз үзгәргәнен чамалый идем... Иртәдән бирле күзәтәм, аңламыйлар мине. Кайда безнең борынгы туганлык? Нужалар гына түгел, күңелләр дә уртак иде. Алар да мине таный иде...» Геологлар аңа: «Яшәгәнсең инде, җиткән!» — диләр. Бу вакыйгалар аэропортта бара. Һәркем үз мазасы белән кая барып бәрелергә белми. Ә бит безнең бай илебез — Бөек Совет иле — алай яшәргә тиеш түгел иде! Автор аны кешеләр рухы аша тасвирларга тырыша. Менә Аязның мондый янып-көюләре югарыдагыларга бик ошап җитмәде шул. Актуаль әсәр булса да...

Аяз һәрдаим ил язмышы өчен, милли хәзинәләребез өчен янып яшәде. Ул ШӘХЕС булды. Аның күзлегенең дә хикмәте бар кебек тоела иде миңа: калын күзлеге аша без абайламаганнарны күреп, мәгънә тапты. Аның белән әңгәмәләшеп йомгак ясаганда, һәрвакыт бер яңалык әйтеп сискәндереп куя иде. Мисал итеп шуны китерә алам: еш кына Мәүлә турында сөйләшә идек. «Мәүлә язмышы — идеология корбаны» дия иде ул.

Аяз татар халкының язучысы гына түгел, ул милләтебезнең ӘДИБЕ булды. Толстойны «богоискатель» дип әйтү гадәте бар бит инде. Бу дөньялыкта кешенең җаваплылык хисе дип аңлыйм мин. Аязга килгәндә дә шул ук күренеш, ул кешеләрне ачарга,

тәрбияләргә тырышты. Аяз милләтнең узганы, хәзергесе турында гына кайгыртмады, аны киләчәк язмыш борчыды. Ул милләтне рухи яктан баетып кына матди байлыкка ирешеп булганлыгын аңлап яшәде. Шул юлда дәвам итүчеләрен калдырырга тыры-



шып, яше-карты белән аралашып, әдәбият-театр мәсьәләләрендә үзәктә торырга тырышып эшләде. 60 нчы елларда иҗат дөньясына килеп кергән Аяз Гыйләҗев, Хәй Вахит, Шәриф Хөсәенов, Юныс Әминовлардан талантлы иҗатчылар калды. Туфан Миңнуллин, Рабит Батулла, Ризван Хәмид, Рөстәм Мингалим, Юныс Сафиуллин, инде килеп тагын да яшьрәкләр — Зөлфәт Хәким, Ркаил Зәйдулла, Данил Салихов, Рәдиф Сәгъди, Мансур Гыйләҗевләр — шул буынның дәвамчылары итеп кабул ителәләр.

Аяз нәкъ дәвамчылар калдыру теләге белән янып яшәде дә инде. «Бездән соң дәвамчылар булмаса, безнең яшәвебезнең мәгънәсе нүл», — дия иде ул. Аяз да, Марсель белән фикердәш булып, киләчәк буыннарны дәртләндереп калдырырга тырыштылар. Аларның фикерләре дә аваздаш булды. Мин хәтерлим, Марсель Ркаил Зәйдулланы дәртләндереп пьеса язарга чакырды. Ркаил язды. Ә Аяз Ркаилны Марсельгә фикерле язучы итеп, аны театрга тартырга кирәклеген әйтеп пропагандалый иде. Мансур Гыйләҗев — Аяз Гыйләҗевнең улы. Мансурда Аязның турыдан-туры каны дәвам итә. Мансурны Аяз сәхнәне аңлап эш итә ала торган зур драматург итеп кабул итте. Сөйләшүләреннән ишеткәнемчә, Аяз үзе сәхнә законнарын төшенеп җитә алмавыннан интеккән, ә Мансур әйтәсе сүзен, проблемаларны сәхнә законнарын төгәл белгән драматург булып яза. Марсель үзе дә, Аязның бу сүзен раслап, Мансурны яратып кабул итте. Аның «Баскетболист» әсәрен мавыгып, бирелеп сәхнәләштерде. Бу инде Марсельнең соңгы иҗат җимеше булды. Бу җимешне мин Ходай Тәгалә тарафыннан иңдерелгән символик җимеш дип кабул итәм. Драматургиянең хәзерге көндәге үсеше нәкъ аларга барып тоташа. Театрларыбыз драматургларга кытлык кичермәве мәңгелеккә күчкәннәребезнең фатихасы итеп кабул ителергә тиештер! Милләтебез сагында сәнгатьпәрвәр торсын! Аязлар шуны теләгән ич. Амин!

11 ноябрь, 2005

Дуслар җыелган җирдә... Балтачта әдәбият көннәрендә катнашучылар



ДАНИЯ ГЫЙМРАНОВА

## Бай иҗат мирасы калдыр-
## ган әдип

Халык язучысы Аяз Гыйләҗев былтыр 13 мартта 75 нче яшендә вафат булды. Көн артыннан көн уза. Тормыш та, болытлар да агымсудай ага тора. Яше белән олыгая килсә дә, күңеле белән ул әле һаман да шул ук яңа гына әдәбият, сәнгать, иҗат дөньясына чумган, бик күпне күргән яшь Аязны хәтерләтә иде. Үлем аның өчен көтелмәгән хәл түгел иде, шунлыктанмы ул яшәргә ашыкты. Менә хәзер дә өермәдәй, буран уйнатып килеп керер дә трибунага басар, уйлаганын, үзенекен ашыга-ашыга өздереп әйтеп, шикләнергә урын калдырмыйча, аннан «менә сезгә сүзем шул» дип төшәр дә залда утыручыларны чыгышы белән «йокыларыннан» уятып алыр кебек. Ул ашыгып яшәде, әйтерсең лә үзенә билгеләнгән вакыт бирәмлегендә мәңгелек тарафларына, милләт тарихына үзендә булган рухи байлыкны биреп җиткерә алмам дип курыкты һәм халкына баштан ашкан иҗат мирасы калдырды. Ул чын мәгънәсендә аттай эшләде һәм дөньяны колачларга омтылды. Ул заманыбызның фаҗигале, драматик вакыйгаларын үз язмышында татыды һәм чорыбызның бер-берсенә ятышмый торган күренеш-үзгәрешләрен үзенең кайнар сулышы, хак сүзе, очлы каләме белән җылытуы, бар нәрсәгә, һәркемгә — кешеләргә, табигатькә, җәмгыятькә битараф булмавы, аларга карата каршылыклы фикерләр уята алуы белән безгә — үзенең укучыларына һәм тамашачыларына кадерле иде.

Аның шәхси иҗат архивында бүгенге көндә 38 пьеса саклана. Аларның күбесе республикабыз театрларында куелдылар. Аның өстәвенә алар урыс, башкорт, чуаш милли театрлары репертуарларында да урын биләделәр һәм киң яңгыраш алдылар.

Драматург буларак Аяз Гыйләҗев театр сәхнәсенә 60 нчы елларда килеп керде һәм, әйтергә кирәк, аның пьесалары буенча сәхнә күргән беренче спектакльләре уңышсызлыкка дучар ителде. Г.Камал театрында аның 1960 елда режиссер Р.Тумашев һәм 1961 елда режиссер Ш.Сарымсаков сәхнәләштергән «Җиз кыңгырау» һәм «Киек Каз Юлы» драмалары куелды һәм шунда ук репертуардан төшеп тә калды. Ләкин бу «һәлакәт» 32 яшьлек драматургның җиңелүе түгел, киресенчә, аның җиңүе иде.

50 нче еллар ахырында илебез театрларында үзенә күрә бер җанлану процессы башлана. Бу актер уены стилистикасы һәм спектакльләрнең куелышындагы кискен борылыш процессы белән бәйле иде. Әйтик, 40–50 нче елларда образны сәхнәдә гәүдәләндергәндә ул, шәхес буларак, конкрет бер идеянең, аерым бер хиснең чагылышын белдерсә, аннан соңгы елларда кеше үзенең каршылыклы диалектик берлегендә ачыла башлый. Кешенең рухи дөньясына тагын да тирәнрәк үтеп кереп, җентекләп өйрәнү үзәккә чыга. Образның психологик тирәнлеге, тулылыгы, характерның үсештә чагылуы төп критерийга әйләнә. 50–60 нчы еллар башында бу процесс әле башлангыч хәлендә була. Драматургиянең мондый торгынлык халәте театр әһелләрен нык борчый. Мәсәлән, күренекле артист Габдулла Шамуков, драматургия алдында шул чорда үзенең катгый таләпләрен куеп, болай дип язды. «...Әйбәт спектакльләр тудыру өчен иң элек югары сыйфатлы әсәрләр кирәк. Безнең эштә бу иң беренче шарт. Чөнки актер иҗаты тулысынча драматургиягә бәйле. Начар әсәрдән яхшы спектакль тумый». Бу язмадан ук күренгәнчә, театр әһелләрен шул еллардагы



драматургиянең торышы, аның тормыштан артта калуы, гражданлык эчтәлегенең сай-лыгы борчый.
Аяз Гыйләҗев пьесаларында конфликт проблема дәрәҗәсенә күтәрелде, характер-ларга исә психологик тирәнлек хас иде. Ләкин монда үзенә бертөрле каршылык та килеп туды. Авторның мондый зур проблемалы әсәрләрен кую бик мөһим булса да, театрның әлегә моңа әзерлеге юк иде, шунлыктан аның беренче әсәрләре — «Җиз кыңгырау» (1958), «Киек Каз Юлы» (1959) спектакльләре — җәмәгатьчелектә киң кызыксыну уятсалар да, уңыш казана алмадылар.
1961 елны Г.Камал театрына щепкинчылар кайтты. Алар катнашуында Г.Юсупов яшь авторның «Көзге ачы җилләрдә» драмасын сәхнәләштерә һәм бу юлы уңыш алар-га елмаеп куя. Яшь артистлар Р.Таҗетдинов, Н.Ихсанова, Н.Дунаев, өлкәннәрдән Х.Уразиков, Г.Ибраһимова, Р.Җиһаншина, бердәм көч булып, гаҗәеп шигърият-моң-га төрелгән, яшьлеккә хас «мәхәббәт һәм нәфрәт» хисләре белән сугарылган моңсу бер драма иҗат итәләр. Боз кузгалды! 1964 елда Республика күчмә театрында аның режиссер Р.Тумашев тарафыннан «Кара күзле кызлар» комедиясе куела һәм шул ва-кыттан алып А.Гыйләҗевнең бу режиссер белән булган иҗади дуслыгы ныгый, һәм ул аның тагын биш әсәрен сәхнәләштерә. Алар арасында «Шомырт чәчәк атканда», «Син дөньяда берәү генә», «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Шикәрем син, балым син», «Ефәк баулы былбыл кош» пьесалары бар.
Гомумән, Аяз Гыйләҗев драматургиясенең иң урталыгында авторның әйтергә те-ләгән фикере ята. Образлар системасы шуңа буйсына, әйтик, башка авторлар сюжет-ны, сәхнәдә уен стихиясен алгы планга чыгарырга омтылсалар, А.Гыйләҗев пьесала-рында исә чынбарлыкның актуаль проблемалары алгы планга чыга. Мисал өчен 1967 елда камаллылар сәхнәсендә режиссер Р.Бикчәнтәев куйган «Җиргә тапшырылган сер-ләр» драмасына гына тукталыйк. Аның үзәгендә дә заман темасы, җитди проблема, тормышның бер кысадагы күренеше — автор чыгарылыш класс балаларының уй-фи-керләре белән кызыксына. Алар исә «мәктәпнең тышы иске, эче ялган» дигән нәтиҗә-

гә килгәннәр. Ни өчен? Төп сәбәп — бу балаларны укыткан укытучыларның тормыш принципларында. Мәктәп директоры Самат — үзе үк тормышның бөтен уңай һәм уңай-сыз якларына җайлашкан кеше. Аның кылган эшләре сөйләгән сүзләреннән аерыла.

«Китмәгез, тургайлар!» спектаклендә Д.Нуруллина, Ф.Халитов, Һ.Солтанов. 1978



Алар исә фикер йөртүче, эзләнүче, ялгыша торган яшьләр. Аларның характеры формалашу чорын гына кичерә әле. Илшат, Рәдиф, Шәрифҗан, Зәнәләрнең тормышка карашлары каршылыклы мизгел кичерә, аларның үзгәрү-үсүләрен сәхнәдә күрсәтү театр өчен җиңел түгел иде.

Аннан соң куелган «Шамил Усманов» (Альберт Яхин белән берлектә), «Эңгер-меңгер», «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз», «Китмәгез, тургайлар!», «Көйсезләнгән сәфәр» пьесалары, шулай ук камаллылар өчен уңышлы яки уңышсыз булуларына карамастан, гади генә куелып, артистлар һәм тамашачылар күңелендә эзсез генә узган спектакльләр түгел иде.

Драматург Аяз Гыйләҗевнең Әлмәт драма театры белән иҗади бәйләнеше ул үзе үк аның тормышында һәм драматургиясендә аерым бер урын били, дисәм, ялгышмамын. Ул бу коллектив белән бик тыгыз аралаша, һәр артистны якын, үз итә иде. Моның сәбәбе, мөгаен, күп еллар театрның сәнгать җитәкчесе булган режиссер Гали Хөсәенов белән дуслыгына барып тоташадыр.

Әлмәт театры сәхнәсендә дә аның 10 пьесасы куелды. Һәркайсы диярлек театрның сәнгать тормышында аның эстетик эзләнүләрен чагылдырды. 1964 елда Г.Юсупов куйган «Яланаяклы кыз» драмасы Әлмәт сәхнәсе өчен шулай ук яңалык иде. Кешеләрнең эчке матурлыгына, сафлыгына дан җырлаган бу спектакльдә яланаяклы кыз Гөләндәм роле белән бүген бу театрның йолдызы саналган артистка Луиза Солтанованың халыкка танылуы башланды, ул үзе үк легендага әверелде.

Әлеге театр репертуарында аның тагын ике әсәре эзле булып калды. Болар эпистоляр жанрдагы «Әгәр бик сагынсаң!..» һәм «Әткәй җырлый да, җылый да» драмалары. Беренчесендә авыл укытучысы Фәүзиянең фатир хуҗалары Гайса бабай белән Мәдәния әбинең төрмәдә утыручы уллары Әсфан (ул кайчандыр колхоз милкенә кул суздан) белән хат аша танышып, бер-берсенә рухи якынаюлары, гашыйк булулары үзәккә алып карала, сюжет динамикасын тәшкил итә. Тәүге карашка бу сюжет баналь мелодрамага корылган сыман тоела, тик пьесаның төп мәгънәви эчтәлеге бөтенләй

башка нәрсә хакында тәкрарлый. Ул кешегә ышаныч күрсәтү, аның турында борчылу, аңа ярдәм кулы сузу хакында сөйли. Әсфан ялгышлык белән җинаять кылган, хәзер ул җаны белән ирексез кеше, аның рухы бәйдә, тик ул да үзен җәмгыятьнең тулы хокуклы шәхесе итеп тоярга омтыла — әсәр йөрәктәге әнә шул «бозлавыклар»

«Әгәр бик сагынсаң!..». Әлмәт театры спектакле. Л.Солтанова, К.Вәлиев. 1979



хакында, ә спектакль исә бу «бозлавыклар»ның ничек эрүен тасвирлый. Бу спектакльдә ул вакытта әле яшь артистлар Дамира Кузаева һәм Камил Вәлиев әсәрне югары ноктага күтәреп, романтик рухта башкарып чыктылар һәм драматик кичерешләргә бай спектакль тудырдылар. «Мәхәббәт — язмыш ул» дигән фикерне аныкладылар.

Шулай ук бу театр сәхнәсе өчен читрәк тоелган «Без уникe кыз идек» драмасы да язмышлар турында бәян итүе белән кызыклы иде. Бүген бергә дус булып үскән 12 кыздан 5 есе генә бергә җыела алган. Вакыт аларны төрлесен төрле якка чәчкән. Вакыт кына микән?.. Бер-береңә карата миһербансызлык, игътибарсызлык, кирәк чакта ярдәм кулыңны суза алмау якыннарыбызны һәлакәткә илтми микән?

Режиссер Г.Хөсәенов бу пь-

есаны, авторның фикердәше
буларак, аның драматик алымы-
на, стилистикасына таянып, ин-
теллектуаль-психологик драма
итеп куйган иде. Тормыш-көн-
күреш темасына драма һәм комедияләр уйнаган артистлар өчен мондый жанрда чы-
гыш ясау үзенә күрә бер гадәти рамкалардан чыгып, публицистик рухтагы спектакль
тудыру иде, һәм ул аларның уен рәвешләрен чарлау өчен кызыклы җирлек булды.
Шулай ук бу театр сәхнәсендә дөнья күргән «Җан җылысы», «Кар астында кайнар
чишмә», «Җанның җиденче тамыры», «Биш бармакта биш балдак», «Көттереп искән
җил» спектакльләре, заман таләпләреннән чыгып, мөнәсәбәтләр үзгәргән саен, конф-
ликтлар тормышның эченәрәк яшеренә, проблемалар катлаулана барган саен, кеше
җанының пульсы да үзгәрүе турында сөйләделәр. Образлар уйнар өчен җиңел түгел
иде, тик бу әсәрләрнең һәркайсында фикер кайнарлыгы өстенлек ала һәм авторның
позиция ачыклыгы ярылып ята иде.

80 нче елларда Минзәлә драма театры да Аяз Гыйләҗев әсәрләренә мөрәҗәгать
итте. Драматургның «Тын урамда гауга», «Баласын җуйган болан эзеннән» һәм «Өч
аршын җир» драмаларын ул вакыттагы театрның баш режиссеры Фаил Ибраһимов
сәхнәләштерде. Бу режиссерга катлаулы әсәрләрне үзе аша үткәреп, бик кыю, заман-
ча укылышта куя белү хас.

Шунысы кызыклы, авторның әсәрләре никадәр генә иҗтимагый проблемаларны
югары күтәрмәсеннәр, аларның берсе дә шул чорда хакимлек иткән идеология шаукы-
мы астында язылмаганнар, алар моннан азатлар. Югыйсә бу пьесаларның күбесенең
төп геройлары колхоз, производство темасына караган (ул заманда бөтен совет театры
репертуарын производство темасына караган әсәрләр биләп алган иде бит), тик драма-
тург аларны психологик драма күзлегеннән чыгып хәл итә, иң әүвәл аның рухи халә-
тен үзәккә ала һәм төп конфликт дәрәҗәсенә күтәрә иде.

Әлмәт театрының «Күтәреп искән җил» спектакленнән күренеш. Рольләрдә Г.Хисмәтуллина, Л.Абдуллаева. 1986



Инде килеп «Өч аршын җир» әсәренә тукталыйк. Бу повесть аның җан кыйпылчыгы иде. Ул «Дружба народов» журналында басылганнан соң, театрлар аны сәхнәгә куюю теләген белдерделәр. Тик җитәкче даирәләр әллә нигә бу әсәрдән өректеләр, сәхнәләштерергә рөхсәт бирми тилмерттеләр. Казанда гына түгел, хәтта Мәскәүнең К.Станиславский театры куярга алынгач та, партия обкомы, шалтыратып, аны куюдан тыйды.

Әлеге әсәр бары тик 1987 елда гына (1961 елда язылган) Г.Камал һәм Минзәлә театрларында сәхнә күрде, ә язучының исә бу җан бәгыре иде. Өч аршын җир... Кешенең бөтен гомер юлы шуңа таба — шул өч аршын җиргә таба бара. Шул мәрхәмәтле өч аршын җиргә һәркайсыбызның хокукы булырга тиеш. Мирвәли һәм аның хәләл җефете Шәмсегаянның дистәләрчә еллар дәвамында читтә яшәп, үләр алдыннан туган җирләренә, туган туфракларына, авылдашлары алдында тез чүгеп гафу үтенүләре ике театр сәхнәсендә дә тирән фаҗигагә ия кыйсса булып яңгырады. Мондагы кичерешләр, уй-тойгылар үзләренең аерым нечкәлекләрендә, киеренке тартылышларда чагылдылар. Шуның белән алар кеше күңелендә иң тирән яшеренгән хис-тойгыларын ачып салды һәм гыйбрәтле язмышлар аша сәхнәдә, авторның үз рухына ятышлы проза әсәре театрда куелырга хаклы икәнлеген тагын бер тапкыр раслады.

Аяз Гыйләҗев прозасы тәнкыйтьчеләр тарафыннан һәрьяклап өйрәнелгән булса да, драматургиясе ни сәбәптәндер бүгенгә кадәр бер читтә кала килә. Дөрес, академик Азат Әхмәдуллин үз хезмәтләрендә бу бушлыкны берникадәр тутыра. Авторның «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» дигән сорау куйган китабы бар. Миңа калса, Аяз Гыйләҗев үзенең гомере буена 40 ка якын драма әсәрләрендә әнә шул сорауга җавап бирергә тырышты.

«Шәһри Казан»

31 гыйнвар, 2003

Әлмәт драма театры Казанга гастрольгә килгәч



НАИЛ ДУНАЕВ

Олпат әдип

Минем өчен Аяз абый Гыйләҗев — бөгел-

мәс-сыгылмас, үзе инанган кыйбласына турылык-

лы, юк-барга вакланмас кырыс табигатьле, көч-

ле рухлы һәм гаделлек үрнәге. Ә якташым була-

рак (мин дә Зәй районыннан), үз төбәктәшләре-

нең ирешкән уңышларын күреп алып, шуңа якын

туганнарыдай куанып, шуларны хуплап, аларның

тагын да зуррак эшләр башкаруларын теләп,

тулы тормыш белән яши белгән олы җан иде.

Йомшаклык сизсә, һәрчак үз асылында булды,

бер дә кәнфитләнеп тормыйча, бу хакта төртте-

реп тә, турысын әйтеп салырга да тайчынып тор-

мады.

Нурихан Фәттахның «Кол Гали» трагедиясе-

нә репетиция бара. Мин казначы малае Шәмсет-

дин ролендә ханның уң кулы булган баш карачы

Актайга, минем язмышымны хәл итәчәк, «ыргыт-

кан» вәгъдәсенә башымны иеп, билемне бөгеп:

«Бай бул, Актай!» — дип, аны зурлыйм. Залда

Аяз абый утырган икән. (Аның ара-тирә репетициядә утыра торган гадәте бар иде.)

Репетициядән соң минем яныма килде дә, эзопча үтә мәгънәле итеп: «Бай бул, Актай!»

дип кенә булмый ул», — дип, күңелне кузгатырлык реплика ташлады. Ни әйтергә

теләде ул?! Кабатлап әйтәм, ишарә зур иде. Театрдагы положение турында әйткәндер

инде, мөгаен...

Гомумән, Аяз абый үзенең саллы, бай телен әдәби әсәрләрендә дә, көнкүреш сөй-

ләмнәрендә дә гаҗәп төгәл, матур итеп, нәкъ урынында, иң әһәмиятлесе — үзенә генә хас оригинальлек белән, оста итеп куллана белде. Башкалардан ишеткән, уңышлы кулланылган афоризм, фраза, сүзләргә куана, аларны файдалануны яклый иде. Мәсәлән, мин А.Островскийның «Свои люди — сочтемся» комедиясен тәрҗемә иткәндә Подхалюзинның йомышчы малай Тишкага әйткән сүзләрен: «Каян килгән Әпчи карчык», — дип язуымны: «Менә бит, әдәби телдә юк, ә характерлау өчен нинди отышлы табылган», — дип хуплаганы хәтеремдә. Ә пьесаның татарча аталышын «Агай-эне ак мыек» дип куярга да миңа ул, Аяз абый тәкъдим итте. Нинди төгәл аталыш!

Минем белүемчә, Аяз абыйга үз заманында «нәчәлниклык» итәргә насыйп булмады шикелле. Шуңа күрә яңгыравыклы озын-озын докладлар белән зур залларны гөрләтергә дә туры килмәгәндер аңа. Әмма ул «коеп куйган» язучы, драматург кына түгел, оста оратор да иде — авызыннан ут чәчә иде ул.

Минем 50 еллыгымны Камал театры Аяз абыйның «Өч аршын җир» трагедиясендәге баш роль Мирвәлине башкаруым белән билгеләп үтәргә булды. Спектакль алдыннан мин — юбиляр турындагы төп тантана сүзен язучы Гариф абый Ахунов сөйләргә тиеш иде. Кичәне башларга вакыт җитте, ә Гариф абый юк. Киләме ул, юкмы? Нәрсә булган Гариф абыйга? (Ул заманнарда кесә телефоннары юк иде әле.) Нишләргә?! Шунда Аяз абый: «Әйдәгез, сәхнә алдына үзем чыгам, сөйләргә күпме вакыт бирәсез?» — диде. «Син әзерлексез бит, булдыра алганча тырышырсың инде», — дигәнгә ул: «Мин Дунай турында, керәшеннәр турында кич буе сөйли алам, тантананы спектакль ахырына калдырмыйбыз», — дип, мине һәм тәбрикләргә килгән кешеләрне сәхнә алдына алып чыгып китте. Шунда мин аның гаҗәеп тел остасы икәнен күреп хәйран калдым. Кайбер каләм осталары, шундый шәп язучы булуларына карамастан, үз фи-





Н.Дунаев (сулда) һәм Н.Әюпов «Шамил Усманов» спектаклендә. 1967

А.Гайнуллина һәм Н.Дунаев «Өч аршын җир» спектаклендә. 1987

керләрен җыеп әйтә алмыйча, меҗе-меҗе килеп аптырап бетәләр. Ә Аяз абый — оратор! Яшьли гомерем умарталыкта үтсә дә, умартачының кем икәнен, һәм умартачы кеше нинди сыйфатларга ия зат булырга тиеш икәнлеген беренче кат мин Аяз абый авызыннан ишеттем. «Аның әтисе умартачы. Наил — атаклы умартачы Бал Ибан малае. Ә бал корты теләсә кемне танымый, оешкан, үтә чиста, пөхтә кешегә генә хезмәт итә ул, шапшак, ордым-бәрдем кешене яратмый. Наил менә шундый гаиләдә тәрбия алып үскән артист», — дип башлап китте Аяз абый сүзен. Аның бөтен залга әтиемне зурлап әйткән шушы сүзләре юбилей тантанасында миңа карата әйтелгән бәяләмәләрнең иң зурысы булгандыр, мөгаен, миңа шулай тоелды.

Аяз абый кырмыска халкы кебек хәрәкәтчән, бал кортыдай эшчән, үтә дә тынгысыз зат иде. Шулай булмаса, бихисап әдәби мирас калдыруы өстенә шундый авыр, хәерче заманда, гаилә башы буларак, сөекле хатыны укытучы Нәкыя ханым белән бергәләп гаҗәеп тату гаиләдә республика даны булган менә дигән өч ул — тарихчы-галим Искәндәрне, язучы-драматург Мансурны, табиб Рәшатны тәрбияләп үстерә алмаган булырлар иде.

Ә язучының әдәбиятка керткән өлешенең биниһая зур икәне әдәбият сөючеләрнең һәркайсына мәгълүм, һәм, иң әһәмиятлесе, һәр яңа әсәре әдәбият, сәнгать дөньясын дөрләтеп, җанландырып җибәрә иде. Ә укучы халкы аларны ашкынып көтеп алып, йотлыгып укый торды. Ничек шулай булмасын?! Әсәрләренең исемнәре, аталышлары гына да ни тора: «Күзге ачы җилләрдә», «Әтәч менгән читәнгә», «Җиз кыңгырау», «Урталыкта», «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Балта кем кулында?» «Яра», «Өч аршын җир», «Кылдан нәзек, кылычтан үткен», «Язгы кәрваннар», «Җомга көн, кич белән...», «Йөгез, бер дога!» һ.б., һ.б. — һәркайсы тирән фәлсәфи мәгънәгә ия. Сарман, Зәй якларына, аның табигатенә, хезмәт сөючән, киң күңелле, сабыр холыклы халкына ка-

рата әсәрләрендә аерым урын, аерым сурәтләү, аерым мәдхия.

Аяз абыйның тагын бер күркәм ягы — ашка каршы аш белән кайтарудыр. Ул, игелекнең кадерен белеп, шуның мәгънәсен гаять зурлап кабул итеп, бер игелеккә мең белән кайтара торган тирән тойгылы зат иде.

Якташларыма, шул исәптән миңа да, Аяз абыйның «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романы бигрәк тә якын. Аны укыгач, автор рухына янә бер кат изге теләк телисе килә. Соңгы вакытларда республиканың күп кенә массакүләм мәгълүмат чараларында керәшен халкы хаксыз рәвештә кимсетелде, түбәнсетелде. Алда әйтелгән бу әсәрендә Аяз абыйның рәнҗетелгән, әмма сабыр холыклы, киң күңелле бу халыкка җылы хисләрен, олы хөрмәтен сагынып, матур хатирәләр аша чын сәнгать югарылыгында әйтеп бирүе күңелләрне айкый.

Болар, әлбәттә, бөек язучының мул иҗатында гуманизм идеяләрен дәлилләүче мисалларның бер чагылышыдыр. Шуңа күрә мин бу фани дөньяда көчле ихтыярлы, гадел кеше, чын мәгънәсендә зур талант иясе белән таныш булуымны, хәтта бераз аралашып яшәвемне миңа язган язмышның бер якты өлешедер дип саныйм.



ФАИЛ ИБРАҺИМОВ

Аяз абый белән танышуым

Аяз абый миңа «Өч аршын җир»е аша ачылды. 1978–1979 елларда Минзәлә театрында куючы режиссер булып эшли идем. Театрның китапханәсендә озак-озак актарына торгач, кулыма бер әсәр юлыкмасынмы! Инде шактый еллар «мине көтеп яткан» бу пьесаның кәгазь битләре кояш нурлары тәэсиреннән ярыйсы гына саргая төшеп, машинкада басылган хә-

рефләр дә тоныкланган

иде. Бер сулышта укып

чыктым кебек истә калган.

Мине әсәрдәге вакыйгалар

үз эченә шулкадәр урап-

урап алып кереп китте:

укыганда ук минем күңе-

лемдә «җанлы» образлар

хасил булды. Әсәрне укый

бардым, шул ук вакытта

күз алдымда ул уйнала да

торды — спектакль итеп

күрдем. Укып чыктым да

шунда ук ул вакыттагы

Минзәлә театрының баш

режиссеры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мулланур ага Мостафин янына йөгердем. «Мулланур абый, ниһаять, мин үземә куярга әсәр таптым», — дидем. Аннан соң пьесаны мин аңа суздым. Пьесага күз төшерде дә әкрен генә, җайлап кына (ул шулай сөйләшә иде): «Әйбәт әсәр тапкансың, әмма дә-ә ләкин куеп булмый!» — ди Мулланур абый. «Ни өчен?» — дим мин. «Шуның өчен, — ди бу, — икебезнең

беребезгә утырырга туры киләчәк. Аяз инде утырып чыккан — бурычын түләгән, аны инде утыртмаслар. Син дә әле яшьрәк — сине дә утыртмаслар, дияргә була. Миңа синә шундый әсәрне куярга юл куйган өчен утырырга туры килер шул. Уйлап кара әле!» — диде. Үзе, соравына җавап көткән күзләрен текәп, елмаеп миңа карап торганы хәзер дә күз алдымда. Ул үзе соравын да, җавабын да бирде ич инде, нишлим соң?..

Соңыннан белдем: Аяз абый аңа ерак сәфәреннән кайткач язган беренче пьесасы — «Давыл артыннан»ны биргән булган. Мулланур абый, пьесаны куярга ниятләп, рольләргә артистлар да билгеләгән икән. Ике еллар дәвамында алар шушы пьесаны сәхнәләштерү планнары белән хыялланып яшәгәннәр. Ул турыда радиолар хәбәр иткән. Бу вакыйга 1955–1956 елларда булган. Ләкин иҗат планнары пыскып кына калган, аны сүндергәннәр... Ул пьеса әлегә кадәр матбугатта чыгарылмаган, бер сәхнәдә дә куелмаган, һәм шулай Аяз абыйның архивын саклый бирә икән...

Ә бәхет дигәне барыбер үзенекен итте. Иң беренче булып «Өч аршын җир» пьесасын мин сәхнәләштердем! Бу вакыйга 1980 елда Актаныш халык театрында булды.

Ул еллар өчен минем тарафтан зур кыюлык эшләнгән, әлбәттә. Спектакльне Казанга алып килүне республиканың Театр җәмгыяте берлеге оештырды. Без, Казанга Химиклар сараена килеп, ул спектакльне театр дөньясындагы иң мәшһүр кешеләргә күрсәтү бәхетенә дә ирештек. Спектакльне карарга Марсель абый Сәлимҗанов, Шириаздан абый Сарымсаков, Г.Камал исемендәге театрның барлык артистлары да килгән иде кебек истә калган. Тамашачы һәм театр белгечләре тамашаны бик җылы кабул итте. Тамаша залы шыгрым тулы булды. Тамаша тәмамланганнан соң, халык озак вакыт безнең артистларны алкышлар белән тәбрикләде, чәчәкләргә күмде! Без Казаннан дәртләнеп, рухланып үз төбәгебезгә кайтып киттек. Аяз абыйның канәгатьлегенә чик-

Аяз Гыйләҗев, Фаил Ибраһимов. 1980



ләр юк иде кебек. Шуннан соң без Аяз абый белән бик җылы мөнәсәбәтләрдә яшә-
дек.
1985 елда мине Минзәлә театрына баш режиссер итеп билгеләделәр. Мин һәрва-
кыт Аяз абыйның иҗатына тартылдым, аның проза әсәрләрен дә мөкиббән китеп укып
бардым. Шул дуслыкның чагылышы булып 1986 елда аның «Баласын җуйган болан
эзеннән» пьесасы сәхнәләштерелде. Аның һәр әсәренең асылында халыкның яшәеше-
нә карата эчкерсез борчылу, үткәнебез һәм киләчәк хакында уйлану мотивлары ята
иде. Җылы мөнәсәбәтләребезнең ныклы дәвамы булып «Тын урамда гауга» драмасы
1988 елда Минзәлә театрында дөньяга килде. Аяз абый премьераларга гел килеп йөрде,
үзенең безгә карата җылы сүзләрен матбугат битләре аша да, турыдан-туры да әйтә
торды.
Яшь аермалары шактый булуга карамастан, Аяз абый гомеренең соңгы көннәренә
кадәр минем белән булган дуслык җепләрен өзмәде: сердәшем, киңәшчем булды. Алар
Зәйгә 1996–1997 еллар тирәсендә яшәргә кайттылар. Шул елларда мин аларга гел
кунакка барып йөрдем. Аяз абый белән киңәшү, сөйләшү рәхәт, күңелле, бәрәкәтле
иде. Мин ул елларда Әлмәт театрларында спектакльләр куеп йөрдем. Мансур Гыйлә-
җевнең «Сафиулла» пьесасын Әлмәт театрында шул елларда сәхнәләштердем. Аяз абый
ул пьесаның сәхнәләштерелү алымнарын бик хуплады, премьерасына килеп, яратып
карады. Аяз абый, ничек кенә булмасын, Казанга тартылды. Аяз абыйның оныклары
белән аралашып яшисе килде. «Менә оныкларым кайтсын дип ымсындырып велоси-
педлар алып кайтып куйдык әле», — диде. Нәкыя апа: «Аяз — Казансыз, Казан Аязсыз
яши алмый!» — дип көлә иде. Зәйдәге ул җәннәт йортын күз алдына китерәм дә
хәйран калам: Нәкыя апа үстергән чәчәкләрнең матурлыгы, җиләк-җимешләрнең ка-
Актаныш районы халык театры «Өч аршын җир»не куйгач. 1980



ерылып уңуы таң калдырырлык иде шул! Зәйлеләрнең аларны хөрмәтләвеннән бик канәгать иде алар! Аяз абый мондый хөрмәткә лаек иде шул! Рәхмәт зәйлеләргә! Ул төбәккә бәрәкәт иңдерсен Ходай Тәгалә! Амин! Без аның белән хатлар аша да, күрешеп тә сагынышып, серләребезне уртаклашып яшәдек. Сәбәпләре дә булып, табылып торды.


Исемдә Мәскәүдә ВТКда укып йөргән вакытларда (1986–1987 еллар), Аяз абыйны сагынып, аның белән очрашып сөйләшергә теләп, язучыларның Мәскәү янындагы иҗат йортына — Переделкинога барганым. Бүгенгедәй күз алдымда ап-ак карны шыгырдата-шыгырдата көне буе аның белән сөйләшеп йөргәннәрем. Бүген дә исемдә генә түгел, колагымда ачык булып чыңлап тора: «Сез, парин, бездән бәхетлерәк буын булып чыктыгыз! Җылы җилләр исә! Үзегезне шул хәлләр алдында лаеклы тота алсагыз ярый инде! Достойный булыгыз, кыю булыгыз! Кадерен белегез!» — диде. Шуннан соң Аяз абыйның «Йөгез, бер дога!» романын укыгач, аның әйткән сүзләренең чын мәгънәсен төплерәк тә аңлый төштем. Безнең афәтләргә юлыкмавыбызны теләгән икән ул.

Аяз абый үзенекен итте — ул Казансыз яши алмады. Дөреслектә дә шулай, Аяз абыйдан башка Казанның әдәбият дөньясы ятимлек кичерә иде кебек! Ул кайткач, тагын әдәбият дөньясы җанланып киткәндәй булды. Кешенең бу фани дөньяда яшәве мәңгелек түгел шул, кызганыч, Аяз абыебыз бакыйлыгына китеп барды. Аңа мең-мең рәхмәт! Ул миннән режиссер ясады! «Өч аршын җир» аша гына режиссура законнарын аңлый алдым! Ул мине чын әдәбиятны аңларга өйрәтте, чын сәнгатькә килергә юл ачты.

Халык язучысы Аяз абыйның мирасы татар халкы өчен генә түгел, бөтен кешелек дөньясы өчен зур хәзинә! Һәм ул Мәңгелек! Аяз Гыйләҗев — киләчәктә иң укылачак, алай гына да түгел, бер кулыңа килеп эләккәч, кат-кат укылачак әдип! Ул — милләтебез горурлыгы!

Гыйнвар, 2006

Аяз Гыйләҗев Зәйдә, район хакимияте башлыгы Рәшит Хәмәдиев белән. 1998



РӘҮФ ИГЪЛАМОВ

## Аяз Гыйләҗев — драма-тург

Соңгы утыз ел дәвамында драматургия-бездә Аяз Гыйләҗев исеме өзлексез күренеп килә. Ул театр сәхнәләренә шактый каршылыклы фикерләр тудырып, әмма үз алдына куйган максатын ап-ачык белеп, үз темасы һәм аһәңе белән килеп керде. Драматургиядә аның авыр, күнегелмәгән катлаулы юл сайлавы беренче әсәрләреннән үк күренде. Бер сезонда Академия театрында Аяз Гыйләҗевнең ике әсәре: «Җиз кыңгырау» һәм «Киек Каз Юлы» драмалары куелды. Нәтиҗәдә вакытлы матбугатта бу спектакльләрне мактаган яки бөтенләй сүтеп ташлаган егермедән артык рецензия басылды.

Ул чакта, илленче еллар азагында, татар драматургиясенең хәле шактый мөшкел иде. Моңарчы пьесалары белән театрларны тоткан, рухи азыкландырган корифейларның күбесе дөнья куйган, утыз җиденче ел корбаннары әле сәхнәгә кайтмаган, татар совет драматургиясен башлап җибәрүчеләрдән Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморатлар пьесаларын торымнан торымга гына язалар иде. Кыскасы, ул еллар матбугаты: «Татар драматургиясе артта кала!» — дип, хаклы рәвештә чаң какты.

Нәкъ шул чорда Мәскәү, Ленинград кебек эре шәһәр театрларында яңача фикерләү рәвеше уянып килә иде. Зарыгып көтеп алынган яшь көчләр сәхнәләрдән үз авазларын ишеттерә башладылар, сәнгать офыгында бик озак сүнмәскә яңа исемнәр шул чорда кабынды: О.Ефремов, А.Эфрос, Н.Львов-Анохин, В.Пансо исемнәре телгә кер-

де. Бу атаклы режиссерлар фикердәш булырдай драматургларны үз якларына тарттылар: В.Розов, А.Хмелик, А.Макаенок, И.Друце пьесалары шаулап-гөрләп бара башлады. Соңгы еллардагы сәхнә тормышына әйләнеп карасак, совет театр сәнгатенең иң зур уңышлары шушы кешеләрнең иҗатына турыдан-туры бәйләнгән икәнен күрербез. Татарстанда исә театрларда һәм драматургиядә яңа шартлар туып өлгермәгән иде әле. Аяз Гыйләҗевкә кадәр берничә еллар элек исемнәре яңгырап киткән Шәриф Хөсәенов, Шамил Шаһгалиләр, тәүге адымнары белән җылы өмет уятсалар да, чорның байракчысы булып китә алмадылар. Яшь авторлар ул чорда хөкем сөргән кануннарга буйсынып диярлек каләм тибрәттеләр. Вак-төяк чаралар белән генә, анда җайлап, монда майлап кына әдәбиятны торгынлыктан чыгарып, аның иң авыр, иң катлаулы тармагын җанландырып булмаслыгы көн кебек ачык иде. XX съезд таләпләре югарылыгында эшне тамырдан үзгәртеп кору, яңа сүз әйтү, моның өчен яшь, моңарчы күрелмәгән көчләрнең мәйдан тотуы үтә зарур иде.

Яңалыкны, гадәттә, бай, гадәти булмаган тормыш юлы үткән, нужа суын җитәрлек эчкән, актан караны ышанып аера торган катлаулы шәхесләр алып килә. Андый кешеләр илебез тарихының каршылыклы адымнарын аңлап, заманча, халык массалары көткәнчә фикри югарылыкта да булырга тиешләр. Кыскасы, аерым шәхесләрнең яшәү рәвешләре аша илдә барган үзгәрешләрне билгели торган яңа персонажларны тудырырлык кеше көтелә иде. Шәриф Хөсәенов бераз соңрак, алтмышынчы еллар уртасында гына әнә шундый егәрен күрсәтә алды...

Олы сүз көтелә, дидек...

Мисалга һәммәбезгә таныш сугыш темасын гына алыйк. Бөтен ил өчен ифрат авыр сынау булган Ватан сугышы, гранит-бронзаларга төренеп, Кызыл мәйдандагы парадлар булып, ничәмә-ничә еллар дәвамында, шигырьләрдән поэмаларга, хикәяләрдән романнарга күчә-күчә, тантана булып әдәбиятта яңгырады. XX съезддан соң ук без сугышның 1945 елыннан алда дәһшәтле 1941 елы барын да искәрә башладык. Брест

вакыйгалары белән таныштык, командованиенең хаталануы аркасында Киев тирәсендә күпме сугышчыбызны югалту фаҗигасен ишеттек, моңарчы исемнәрен әйтү тыелган геройлар утлы көрәш дәвамы булып безнең аңга килеп ирештеләр: Петр Гаврилов, Михаил Девятаев, Муса Җәлил һәм башка бик күпләр... Исән калган батырларның, һәлак булганнарның исемнәре кире кайтты.

Аяз Гыйләҗев сугышта катнашмаган, яше кермәгән. Әмма сугыш ачысын, аның җәфаларын ул җитәрлек дәрәҗәдә татыган булып чыкты. Язучының җаны бик яшьли гаделлек сагына баскан, ул хаксызлыкны бик иртә татыган, авыр сугыш еллары, сугыштан соңгы еллар аның сизгер күңелендә тирән эз калдырган. Ә бит кайбер сәнгать вәкилләре, авырлыкны халык белән бергә күргәндә дә, кешеләр язмышына өстәнрәк карап, тормышны әдәбиятка җиңеләйтебрәк кертеп җибәрделәр. Күренекле драматургыбыз фронтовик Хәй Вахитның тормышта гел ал буяулар, гел яктылык кына күрергә тырышуы моның ачык мисалы...

Чын гуманистик талант ияләрендә халык кайгысын үз итү сыйфаты һәрчак өстенлек ала һәм иҗатларының төп максатларына әверелә. Аяз Гыйләҗевнең бөтен иҗат казанышларында — повестьларында, драма әсәрләрендә — тарихи каршылыклар, бәрелешләр арасында калган ялгыз кеше язмышы ята. Шул чор өчен, шул чорга тап булган кеше язмышы өчен борчылу, кыйналу, җаваплылык хисе тою ята.

Моннан егерме еллар элек язылган «Өч аршын җир» пьесасы бүген генә сәхнә күрде. Трагедиянең уртасына кискен бер мизгелдә хата кылган һәм шул ялгышы өчен гомерлек газапларга дучар ителгән Мирвәли язмышы куелган.

Мирвәли яши башлаган чор — авыр чор: авылда күмәкләшү бара, колхозлар оеша. Бу яңалык авыл халкын кыл икегә бүлә. Мирвәли кулак та, дошман да түгел, ләкин бер мәлдә ул авылдашлары, ил каршында гафу ителмәслек хата эшли. Малмөлкәтен, иген-таруын яндырып, авылдашларын каһәрләп, авылдан кача.

Авылдан чыгып качканда, Мирвәли үз гаебенең дәрәҗәсен аңламый әле, аны ул соңрак, кырык ел үткәч, үләргә яткан хатыны Шәмсегаян белән бергә Карачурага

кайтып барганда аңлаячак. Әнә шул кайту юлында гына ул үзенә һәм тугры Шәмсегаянына китергән җәфаларга дөрес бәһа бирү дәрәҗәсенә күтәреләчәк...

Ә болай, шул каһәрләнгән төнгә кадәр, ул гадел һәм хак яшәгән, яшь чагында ата йортында ялчы хәлендә булган, соңыннан да гомере эш белән үткән, тегермәндә хезмәт иткән, сугышта каты яраланган, орден алган. Сугыштан да ул туп-туры эшкә, хезмәткә кайта, туган ягының исен, төсен сагынып, бодай тулы капчыкларга капланып сыкрый...

Бу кешегә нинди бәя бирергә соң? Гомерлеккә каргаргамы? Кичерергәме? Классик трагедияләрнең герое йә ак, йә кара гына була алмый! Гайрәтле, ярсу күңелле Мирвәли ялгыша, ялгышы өчен югары хак та түли: дөньядагы иң газиз кешесе Шәмсегаянны югалта. Шәмсегаянның бәгыре теге төндә, янгын вакытында ук гомерлеккә телгәләнә. Яралы күңел, җәрәхәтле җан белән гомер иткән бөек рухлы хатынның инде үзе талпынган Өч кое, нарат белән кочаклашып үскән каен белән кавышам дигәндә гомере өзелә. Классик трагедия кануннарына тәңгәл китереп уйласак, Мирвәли ялгыз яши алырга тиеш түгел!.. Ул, хатынының мәетен күтәреп, авылына кайтып җитә. Мәрхәмәтле, шәфкатьле, киң күңелле авылдашлары Мирвәлигә янамыйлар, җәза белән куркытмыйлар, аны гафу итәләр, кичерәләр. Мирвәли шушы мәрхәмәтне күтәрә алмый, үзе басып торган Туган җире белән мәңгегә береккән икәнен соңарып аңлап, егылып үлә...

Драматург Аяз Гыйләҗевнең үзенчәлеге нәрсәдә? Эре характерлар тудыру ягыннан Туфан Миңнуллин да аның белән ярышка чыга ала. Сәхнә интригалары кору җәһәтеннән аксакалны үзеннән соң килгән яшьләр узып та киткәлиләр. Поэтик символлар белән эш иткәндә, Ризван Хәмид тә аңа якынлаша. Әмма заман рухын, аның атмосферасын тулаем аңлау бүгенгә бер Аяз Гыйләҗевкә генә бирелгән. Әсәрләре кайсы чор тормышына багышланып туса да, аның әсәрләренең кайчан язылганын белү читен түгел. Бу җәһәттән А.Гыйләҗевнең өстенлеге бәхәссез. Ул, персонажларының кайсы

сыйныф вәкиле икәнлегенең, кайда, ничек тууының әһәмиятен онытмаган хәлдә, аларны кыю рәвештә заман мохитенә кертеп җибәрә, аның геройлары хакыйкать, гаделлек

һәм гаделсезлек законнарына буйсынып яши башлыйлар. Аның бу сыйфаты җыентыкка кергән байтак пьесаларында чагылыш таба.

Кайбер пьесаларында драматургның йомшак яклары да ярылып ята. Мәсәлән, аның сатирик комедияләре аерым бер уңышка ирешә алмады. Дөрес, ул иң актив иҗат иткән елларда илдә барган тискәре күренешләр — ахмаклык, саранлык, тупаслык, тәкәбберлек, җан сату мотивлары турында «як-ягыңа каранып» кына язарга тәкъдим ителә иде. Гәрчә драматург кыю һәм тәвәккәл иҗатчы булса да («Өч аршын җир» трагедиясен ул торгынлыкның иң азган елларында язган лабаса), Аяз Гыйләҗев сатира өлкәсендә аерым гомумиләштерүгә ирешә алмады, дияргә була. Хакыйкать аерата нык сакланырга тиеш булган тарихи драмаларында да ул кай ара йомшаклык һәм килешүчәнлек күрсәткәләде.

Татарстанның XIX йөздәге язмышына багышланган «Син — минеке, мин — синеке» драмасына күз салыйк. Дәһшәтле еллар! 1861 елгы крестьян реформасы алдыннан авылда чуалышлар күзгә күренеп арта тора. Автор архив саклаган яңа материалларны җентекләп өйрәнгән, авыл чуалышларының асылын аңлатырлык материаллар тапкан. Иң мөһиме шул: автор авыл ярлыларының сыйнфый аң табигатен дөрес билгеләгән. Феодализм чоры крестьян хәрәкәтләренә мәгълүм бер каршылык хас: бер яктан «усал алпавыт, байгуралар» белән көрәшкә чакыру яңгыраса, икенче яктан крестьяннар «мәрхәмәтле патша» килүен ышанычлы өмет белән көтеп торганнар... Крестьян хәрәкәтенең сәбәбен, тамырларын автор ифрат дөрес тотып алган. Монда бер моментка аерым басым ясарга кирәк. Әсәрдә дәүләт крестьяннары язылып алына. Алар алпавытларга беркетелгән крестьяннарга караганда аң ягыннан өстенрәк торганнар. Бу өстенлек оҗмах нигъмәтләре вәгъдә ителгән Төркиягә күчеп китүдән баш тартканда да, Туган туфракта гына явызлыкка каршы көрәшергә кирәклеген алга сөргәндә дә бик ачык күренә. Гомереңне биреп булса да, бәхетне бары тик Туган ягыңда гына көрәшеп алырга кирәк! Пьеса герое Әюбнең иманы әнә шундый.

Автор шушы кайнар көрәш уртасына Төркиядән килгән Кемельне кертеп җибәрә

дә... оттыра. Кемель әсәргә күз күнеккән, без моңарчы белгән «гадәти» мотивлар алып керә. Гыйләҗев, үз иҗат принципларына каршы килеп, Кемель образына гаеп артыннан гаеп өя башлый! Әгәр дә берәү аксак икән, гариплегенә ышандыру өчен аңа бөкре дә тагып куюның хаҗәте бармыни?!

Бу пьесада да тормыш фактлары дөрес сайланган, автор халыкның алдынгы вәкилләрен: Габделнасыйрларны, Әюбләрне җете буяулар белән тасвирлаган, әмма драмага Гыйләҗевчә кискенлек җитенкерәми!

Ниһаять, «Югалган көн» пьесасы битләрен ачабыз. Монда инде һәр диалогта, һәр фикердә Аяз Гыйләҗев чәчрәп тора! Һәр юлы, һәр ноктасы аныкы!

Кайсы гына заманны сурәтләргә алынмасын, автор үзенең югары дәрәҗәсендә кала, фикерен чәйнәп каптырмый, йомгаклау сүзен әйттерми, шәхси тормыш күренешләре аша тасвирланган чорның бөтен каршылыгын, фикер көрәшен, җан тирәнлеген ачып бирә ала. «Өч аршын җир», «Югалган көн» кебек пьесаларда бу сыйфатлар аерым бер раслау табалар.

Әйе, ди автор, Мирвәли яшәгән заман шундый булган, еллар шулай килгән. Әмма Мирвәлинең дуамаллыгын, ярсу характерын да онытмыйк! Шушы дуамаллык, кискенлек тә аны җәфалы юлларга кертеп җибәрмимени? Тарихи чынбарлыкны күз алдында тотып, Мирвәлинең үз характерын ачканда гына аның кемлеген аңлап бетереп була. Бөек җаннар берчакта да гадәти, гади генә яшәмиләр, үзләре кыенлык кичергәндә, янәшәдәге кешеләргә дә байтак җәбер-җәфа, авырлык китерәләр. Аяз Гыйләҗев үз геройларын кыен юлларга кыю рәвештә кертеп җибәрә...

Аязның пьесалары белән танышкач, укучы тыныч кына кала алмас, уйланыр, дөнья гаме белән дә яши башлар дип ышанам. Талантлы драматургыбыз Аяз Гыйләҗев белән һәр очрашу истә калырлык вакыйга ул.

1988



ИЛЬТАНИ ИЛЯЛОВА

«Өч аршын җир»

Язучы Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» исемле повесте 1964 елда ук «Дружба народов» журналында басылып чыккан һәм журналның премиясенә лаек булган иде. Озак та үтмәстән язучы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры өчен шушы повесте буенча инсценировка эшләп тапшырды. Ләкин пьеса алтмышынчы елларда да, җитмешенче елларда да сәхнәдә уйналмады.

КПСС Үзәк Комитетының 1985 елгы Апрель пленумыннан һәм партиянең XXVII съездыннан соң туган яңа иҗтимагый ситуация күп еллар дәвамында архивларда яткан әсәрләргә юл ачты. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Өч аршын җир» спектакле шулар рәтенә керә. М.Сәлимҗанов сәхнәгә куйган бу спектакль коллективның иҗади үсешендә яңа сәхифә булып тора.

Режиссер зур масштаблы полифоник трагедия тудыра. Спектакльнең күп планлы, эпик характерда булуы беренче минутлардан ук — Р.Абдуллин язган фаҗигале, кырыс яңгырашлы музыканы ишетүгә, Р.Газиевнең монументаль һәм шул ук вакытта тотнаклы сценографиясен күрүгә үк үзен сиздерә. Ике ярусль бизәлеш спектакльне символик-образлы итеп аңларга ярдәм итә. Галерея өстеннән сәхнә түренә җиткәнче һәм, ярымтүгәрәк ясап, авансценага кадәр җәйрәп ята торган коңгырт-көрән төстәге шыксыз да, салкын да җир, бәләкәй генә зәңгәр күлләр, ертык болытлар каплаган шомлы, караңгы күк гөмбәзе әйтерсең лә шушы күк астында, шушы коңгырт-көрән җирдә,

сәхнә учында тормыштан китәчәк кешенең авыр, четерекле язмышы турында сөйлиләр.

Пәрдә ачылуга ук спектакльгә эпиклык бирә торган бер нәрсә — хор. Борынгы грекларддагыча, хор вакыйгаларга аңлатма биреп, күптән үткән тарихи мизгелләрне сөйләп тора. Алай гына да түгел. Бу спектакльдәге хор каһарманнарның кылган эшләрен әхлакый бизмәнгә салып тора. Шуңа күрә ул барысын да тыныч һәм битараф сөйләп бару белән чикләнә алмый. Хорның беренче карашка тыныч, эпик хикәятенә кинәт өзгәләнү, нәфрәт, курку бәреп керү дә шуннан. Хор, тагын Җирне һәм Күкне, Урманны һәм Суны, Вакытны һәм Хәтерне, ягъни бер-берләреннән аерылгысыз һәм кешене гомере буе озата бара торган образларны гәүдәләндереп, символик функцияләр дә үти. Шул ук вакытта хор вакыйгалардан күпмедер читтәрәк тә тора.

Бу сынландыру чараларын режиссер вакыйгаларны көнкүреш вак-төякләреннән күтәрү, спектакльгә монументальлек бирү, икенче яктан барлык заманнарда һәм дәверләрдә кешенең төп асылын аның туган туфракка, тарихи хәтергә тугрылыклы булуы тәшкил итүен ассызыклап күрсәтү өчен куллана. Үзенең туган җиренә, Ватанына һәм ата-бабасына хыянәт иткән кеше беркайчан да шәхес булып җитлекмәячәк. Ул, үзенә ни урын, ни тынгы таба алмыйча, вакыт һәм чиксезлек бушлыгында җил уңаена тәгәрәп йөри торган дүңгәләккә әверелә.

Мирвәлинең (Р.Таҗетдинов, Н.Дунаев) әхлакый түбән төшү тарихын, чарасызлыгын, сагышын, үз гаебен һәм һәлакәтен тоеп тору белән тулы кырык еллык гомере —



сәхнәдә бер мизгел. Яхшы күңелле, шаян, киң табигатьле бу егет, бик нык хәтере калган бер минутта кызып китеп, өйләренә ут төртә һәм авылдан чыгып кача, шул рәвешле үзен дә, хатыны Шәмсегаянны да (А.Гайнуллина, Р.Мотыйгуллина) гомере буена читтә каңгырып яшәргә хөкем итә.

Туган туфракка хыянәт итү темасы һәр заман өчен актуаль. Мирвәли белән Шәмсегаянның өметсез гомер кичереп ятуларын күргәч, ирексездән минутлык омтылышка һәм пропагандага бирелеп, революциядән соң илдән чыгып киткәннәр хәтергә килә. Мирвәли илдән үк китмәсә дә, авылдашларының каһәрләве аның өчен гомер буе сызлап, көйдереп тора торган ярага әверелә. Кеше кызган баштан эшләп ташлаган шушы җинаять һәм аның өчен күргән авыр җәза — үз гаебеңне 40 ел буе тоеп яшәү — спектакльнең лейтмотивы әнә шул.

Пьесада һәм спектакльдә аңлашылмый торган бернәрсә бар. Ул да булса: нилектән киң күңелле, кешелекле егет, атасы вафат булганнан соң, аның мөлкәтенә варис булып калуга ук, шултиклем саранга әверелә, хәтта ки 30 нчы елларда кулакларны сөргән чакта, мөлкәтеңне үз ирегең белән колхозга биргәнче, ут төртеп яндыруың артык дигән карарга килә? Чыннан да, бу логик күчеш — характерның эчке үсеше — автор тарафыннан берничек тә акланмаган. Ләкин Мирвәли тормышындагы бу хәлиткеч вакыйганы аңларга тырышып карыйк.

Бу пьесада, Шекспир трагедияләрендәге кебек үк, вакыт үтә тыгызланган һәм аерым фактларны бәйнә-бәйнә аңлату, кайбер эш, адымнарны логик аңлау өчен сәхнә вакыты җитми. Өстәвенә авторга да, театрга да туган җиренә хыянәт иткән кешенең фаҗигасен ачу мөһимрәк булган. Һәм бу бурыч тулысынча үтәлгән. Мирвәли тормышындагы әлеге вакыйга аша ил язмышындагы бер моментка ишарә ясала. Сүз кулаклар белән беррәттән чит җирләргә сөрелгән урта хәлле крестьяннар фаҗигасе турында бара. Мирвәли дә, аның атасы да һич тә изүче сыйныфлар булмаган. Аның бар байлыгы — ике ат, бер сыер, бер өй дә берничә сандык. Ул, үзе әйтмешли, бала чагыннан ук бил бөккән кеше, батрак-фәлән тотмаган.

Р.Таҗетдинов — Мирвәли, А.Гайнуллина — Шәмсегаян. 1987





Шул рәвешле Мирвәлинең шәхси фа-
җигасе авылның урта хәлле крестьяннары-
ның бер өлешенең гомумфаҗигале язмышы
белән уртак булып чыга. Режиссер, шуны
истә тотып, конкрет кеше язмышын ачу бе-
лән беррәттән, күпмедер абстракциягә урын
калдыра, проблеманы киңәйтә. Һәм мөһим
проблеманы сәнгать чараларыннан читкәрәк
тайпылып хәл итә. Артистлар, гадәти көн-
күреш атрибутларыннан аерылып, сәхнәдә
гомумкешелеккә кагылган хисләр белән
яши алсыннар өчен шулай эшләнә бу. Мә-
сәлән, күренешләрнең урыны вагон, шифа-
ханә, өй диварларына, Өч коега карап кына
чамалана.

Мәгълүм булганча, гомумән трагедия-
нең төп асылын геройның үзенең һәм якын-
нарының киләчәк язмышына йогынты яса-
ячак эш-гамәле тәшкил итә. Әсәр героеның
омтылышы дөньякүләм мораль кагыйдәлә-
ре белән каршылыкка керә калганда, вакый-
галар фаҗигале характер ала.

Спектакльдә вакыйгалар сәхнәдәге күренешләрнең төп мәгънәсенә зыян китер-
мәслек итеп төзелә. Ләкин бу һич тә Мирвәли белән Шәмсегаян баштан алып ахырга-
ча ут йотып, газапланып кына утыралар
дигән сүз түгел. Аларның бөтен тормы-
шы сәхнәдә төрле эпизодлар аша күз ал-


дына баса. Монда ихлас, назлы мәхәббәт тә, яшьлек дәрте дә, ата-ана, дуслар, күршеләр белән көрешүләр дә бар. Һәм шушы сурәт-хатирәләр Мирвәлинең кайтуын тагын да фаҗигалерәк итә.

Сәхнә белән бергә арба әйләнә дә әйләнә. Арбада — Шәмсегаян гәүдәсе. Өенә якынлашкан саен, тормышта адашкан Мирвәлинең адымнары авырая, авылдашлары белән көрешү аны ныграк куркыта бара.

Мирвәли образын тудырган артистлар Р.Таҗетдинов һәм Н.Дунаев, йомшак табигатьле, назлы ирнең акрынлап буш, ят кешегә әверелә баруын күрсәтеп, аның эчке дөньясын икесе дә бертөслерәк ачалар. Янып торган күзле, көләч йөзле егеттән берни калмаган. Карашы сүлпән, иңнәре салынган, адымнары авыр, хәтта Шәмсегаянга булган мәхәббәте дә чарасызлык һәм җирсү сагышы астында басылып калган. Бары ике мәр-

Р.Таҗетдинов — Мирвәли

Р.Таҗетдинов, А.Гайнуллина



тәбә генә ул җанын ача — исерек килеш үк- сеп, кулларын бодай тутырылган капчыкка ба- тырып, сагыштан ачыргаланып, туган җирен яратуын әйтә. Нәкъ менә шуңа да ул тегермәндә эшли. Мирвәли үзе ташлап киткән иген басу- ларын, икмәк исен тоям дип хыяллана торган бердәнбер урын ул — тегермән. Һәм икенче- се — алар Шәмсегаян чиккән сөлгене карап кү- ңелләре нечкәргән вакыт. Ә бераздан, Шәмсе- гаянның үзе чиккән сөлгегә төрелгән гәүдәсен күргәч, күзгә яшь тыгыла. Шәмсегаян туган туфрагы белән әнә шулай бәхилләшә.

Туган туфрагыннан аерылган шушы кеше- ләрнең яшәүдән мәгънә, тәм таба алмаулары усал символикага китерә. Аларның балалары юк. Балалары юклыгының сәбәбе — ниндидер табигать законнары түгел, ә әхлак кануннары. Иленә хыянәт иткәннәрнең нәселе корырга ти- еш. Артистларның икесе өчен дә Мирвәли об- разы — зур казаныш.

Иң әүвәл яшьлектән, мәхәббәттән балкы- ган, соңрак аптырап калган, ахырда сагыштан сулып, саргаеп үлгән Шәмсегаян образы да үзәктә тора. А.Гайнуллинаның Шәмсегая- ны кырысрак, корырак, Р.Мотыйгуллинаныкы — йомшаграк, көчсезрәк. Алар икесе дә инде ныгыган, утырган характерларны тудыра алуларын исбатлыйлар.

«Өч аршын җир» спектакле гомумкешелек проблемаларын кузгаткан әсәр, дигән идек. Ләкин гомумиләштерү һич тә милли үзенчәлекләр юк дигән сүз түгел. Артист-

лар тудырган образлар бик халыкчан килеп чыккан, аларның берсен генә дә башка милләт вәкилләре белән бутарлык түгел.

...Мирвәли, бөтен михнәтләргә чыдап, туган туфрагына кайтып егыла. Туган җир һәм анда яшәүчеләр, кече күңеллелек күрсәтеп, Мирвәлине дә, Шәмсегаян гәүдәсен дә кабул күрәләр. Шул чагында дистәләрчә ел буена читтә каңгырып яшәгән кеше бәхиллек алуга егылып үлә. Һәм бәхилләшкән адәм баласы гомере буе хыялланган, тәүбәгә килеп, ялварып сораган өч аршын җирен ала.

...Соңгы нур җирдә яткан Мирвәли гәүдәсен яктыртып ала да сүнә.

Яшьлегендә артык уйлап тормастан зур хаталар ясап, шуның өчен гомер буе үкенеп яшәгән авыр язмышлар турында уйландыра торган гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле спектакль әнә шулай тәмамлана.

«Социалистик Татарстан»

9 май, 1987

Р.Таҗетдинов, А.Гайнуллина



НӘҖИБӘ ИХСАНОВА

Аяз абый

Без, бер төркем яшьләр, 1961 елның 19 августында театрыбызга эшкә алындык. Һәм без бөтен барлыгыбыз белән театр дөньясына чумдык. Чөнки без читтә, Мәскәүдә тәрбияләндек, 5 ел буе Кече театр каршындагы М.С.Щепкин исемендәге мәктәптә белем алдык, укыдык, чын сәнгать белеме тупладык. Казанга кайткач, үз җирлегебездәге шактый мактаулы юл узган театрыбыз белән нык лап танышырга кирәк иде. Сезон ачылуга, һәр көн спектакльләр карый башладык. Ни хикмәт, тамаша залы гел буш була иде. Укыганда, төрле театрларда спектакльләр карый идек, урын булмаса, баскычка утырып булса да карадык. Анда заллар бушлыгы бер дә истә калмаган. Ә монда бөтенләй киресе. Үзебез спектакль карыйбыз, үзебез күзәтәбез: «Нигә зал буш?» Бик тә истә калганы «Киек Каз Юлы» — Аяз абый әсәре. Сәхнәдә язмышлар, артистлар яхшы уйный. Без бик аптырашта калган идек.

Менә без җиң сызганып эшкә тотындык. Аяз абыйның «Көзге ачы җилләрдә» әсәре. Мавыгып эшләдек, яратып һәм 1961 елның 18 ноябрендә премьера булды. Вакыйга — зал шыгрым! Шуннан соң инде без буш залларны күрмәдек. Могҗиза кебек булды ул!

Безне, уйнаучыларны, Аяз абый өенә кунакка чакырды. Мул табын әле дә күз алдында. Хатыны Нәкыя белән якыннан таныштык. Балалар. Өйгә ямь, нур биреп, гаиләне түгәрәкләп тотучы Нәкыянең әнисе белән чөкердәштек. Гомумән, чын үрнәк гаилә

белән очрашу куаныч булды һәм безгә, яшьләргә, бу очрашу кирәк тә булгандыр. Безнең бит әле бар да алда, ничек яшәп китәрбез, билгесез. Без бу спектакль белән беренче сезоннан бик тә билгеле артистлар булып киттек. Тамашачы безне таныды, яратты, үз итте, кабул итте. Аяз абый безне беренче таныштыручы. Без аны рәхмәт хисләре белән искә алабыз. Дөрес, әсәрне сәхнәгә чыгаручы, әсәрне куючы режиссер Габдулла абый алдында да башыбызны иябез.

Инде язын, кар ачылыр-ачылмас, гастрольгә чыгып киттек. 73 спектакль уйнадык. Әсәр безгә тәмам сеңде, шушы көнгә кадәр Гандәлифнең монологы телдә йөри: «Мин яшь бер кыз идем. Син килдең дә: «Мин сине сөям!» — дидең. Беләсеңме, шул чагында кыз баланың күңеле нишләгәнен?! Сине сөяләр, сине! Син кемгәдер бик кирәк...»

Без инде Аяз абыйлар белән гаилә дуслары булып киттек. Бәйрәмнәрне, туган көннәрне бергә каршылый идек. Ә шулай да «Көзге ачы җилләрдә»не туйганчы уйнадык дип әйтә алмыйм. Кинәтрәк туктады. Югыйсә тамашачы бик тә яраткан иде. Әле бүгенге көнгә кадәр спектакльне онытмаучылар бар — Гандәлиф дип дәшәләр. Башка театрларда Аяз абый бик тә күп уйналды миңа калса, ә безнең театрда шактый пауза булды кебек. Аяз абый ургылып прозада иҗат итте. Һәм, ниһаять, «Өч аршын җир» әсәре дөнья күрде, аны сәхнә әсәренә күчерү хәстәре күрелде. 1970 елда спектакль итеп чыгарыласы вариантында. Төп рольләрдә — Р.Таҗетдинов, Н.Дунаев, Н.Гәрәева һәм мин. Кече фойеда эш башланды. Марсель Хәкимович очып йөрде. Эшебез өстәл артыннан артык узмады. Эш туктатылды. Эш ритмы, яшәү ритмы туктады кебек тоелды.

Еллар уза торды. Без олыгая төштек, заман үзгәрде. «Өч аршын җир»гә 1986 еллар тирәсендә янәдән приказ чыкты. Билгеле инде, без хатын-кызлар төшеп калдык. Без заман корбаннары булдык. Үкенечләр, үкенечләр!



Ә Аяз абый иҗатында бер минутка да тукталып тормады. Үзеннән соң күпме иҗади хәзинә калдырды. Менә дигән өч ул бүләк итте. Әле иске театрыбызда эшли идек. План буенча яңа пьеса уку билгеләнде. Автор Мансур Гыйләҗев — Аяз абыйның улы! Минем күңелдә шатлык хисләре! Үзебезнеке! Укый башладык, ошый бит! Беренчеләрдән булып үз фикеремне әйттем. Аяз абыйның улы бит «Рәхәт яшибез!» дигән пьеса язган, бу бит вакыйга! Менә озак көттерми рольләрне бүлеп приказ чыкты. Беренче булып Волчанская ролен ә мине билгеләгәннәр. Шатлык, билгеле, беренчедән — роль биргәннәр, икенчедән — Аяз абый улы язган пьесадан. Режиссер — Дамир Сираҗиев. Бик җилле режиссер. Чыннан да, эш процессы бик кайнар, кызу темплар белән барды. Әсәр геройлары җәмгыятькә яңа туып килүче эшмәкәрләр — ят кешеләр. Безгә, уйнаучыларга, алар барысы да таныш түгелләр иде. Ул спектакль безнең күңелебезгә уйналмаган спектакль булып кереп калды. Күрәсең, әле без әзер булмаганбыз. Хәзер кире кайтырга иде ул әсәргә. Әйтеләсе сүз әйтелмичә калды югыйсә. Нишлисең, шома гына бармый иҗат юлы. Насыйбы булыр әле, дип көтәбез рольне. Менә Мансур «Баскетболист»ны язды, Марсель Хәкимович куярга алынды. Спектакльне куеп чыгу Марсель Хәкимович тарафыннан батырлык булды. Җиңеп чыкты. Әле Мәскәү гастроленә бару бәхетенә дә ирешә «Баскетболист». Тулы зал алкышлар белән карады спектакльне. Безнең куанычыбыз чиксез иде. Марсель Хәкимович, үзенең соңгы васыять спектакле белән Аяз абыйның улы Мансур Гыйләҗевне алга чыгарып, эстафетаны аңа биреп калдырды.


Аяз абый көчле шәхес иде, иҗаты да куәтле булды. Улларында да шул көчле куәт эшләрендә, тормышларында, иҗатларында ышанычлы канат булып тора. Аяз абый дөньяга нигә килгәнен аклап, исбатлап, үзен халкына танытып мәңгелеккә китте.

Язмам тәмам. Ләкин әйтер сүзем бетмәде. Әгәр дә үз вакытында «Өч аршын җир»дә Шәмсегаянны уйнаган булсам (нигәдер уңышлы чыгуына мин шикләнмим дә), минем иҗат юлым бөтенләй икенче юнәлештә киткән булыр иде. Моңа минем иманым камил. Шулай Аяз абый белән башланган иҗат юлым ярты юлда бүленеп калды. Ни кызга-

ныч!..

Февраль, 2006

«Күзге ачы җилләрдә» спектакленнән күренеш. 1961



ИСЛАМИЯ МӘХМҮТОВА

Сезнең белән яшәү куаныч...

Без — бәхетле буын артистлары. Чөнки безне үзләренең тиңнәре итеп, рухландырып, яратып, колач җәеп каршы алырлык язучыларыбыз, композиторларыбыз, режиссерларыбыз һәм артистларыбыз булды. К.Тинчурин исемендәге театр белән ныклы элемтәдә яшәп иҗат иткән З.Шаһиморат, Х.Вахит, А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Ш.Хөсәенов, Т.Миңнуллиннарыбыз булдылар. Шушы авторларның пьесаларында уйнап үскән безнең буын артистлары, үзләренә рухи азык алып, халыкка хезмәт итеп, халкыбыз күңелендәге биеклектә калдык. Олуг рәхмәтлебез аларга! Кызганыч, арабыздан яратканнарыбыз З.Шаһиморат, Х.Вахит, Ш.Хөсәенов, А.Гыйләҗев, И.Юзеевлар мәңгелеккә китеп бардылар. Урыннары җәннәттә булсын, Ярабби!

Инде сүзем безнең труппа тарафыннан бик тә хөрмәт ителгән Аяз абый Гыйләҗев турында булыр. Минем олы сәхнәгә аяк басуымда режиссерым Равил Рәхимович Тумашев белән Аяз абый Гыйләҗевләрнең зур өлеше бар. 1963 елда мине Казан күчмә театрына артистка итеп эшкә алдылар. Режиссерыбыз Равил абый Тумашев миңа Аяз Гыйләҗевнең «Кара күзле кызлар» пьесасындагы ятимә кыз — Гөлләр ролен бирде. Әле авылдан яңа гына килгән, сәхнәнең ни икәнен дә белмәгән 19 яшьлек «артистка» өчен бу рольне башкарып чыгу бик тә күп җаваплылык сораган сынау булды. Җитмәсә җырларга да кирәк. Бу спектакль өчен көйне Мирсәет Яруллин язып китерде.

Җилләр, исеп, гөлләр исен

Тарата болыннарга.

Кошлар булсам, барыр идем

Син булган урыннарга...

Ничек уйнап, ничек җырлаганымны хәтерләмим. Әмма ләкин Аяз абыйның, балаларга гына хас елмаю белән сөенеп: «Рәхмәт, сеңлем!» —

диеп, аркамнан сөеп, чәчәкләр бүләк иткәнен әле дә хәтерлим, әле дә күз алдымда. «Исламия Мотыйгуллина беренче талпынуда ук рольгә кереп китә алуы белән шатландырды. Гөлләрнең иң нечкә хисләрен ачык итеп чагылдырды. Сәхнәгә аяк баскан яшь көч өчен бу уңышлы һәм өметле башлангыч», — дип язып чыктылар «Социалистик Татарстан» газетасында.

Кыюсыз хәрәкәт, беренче иҗат газабы, беренче чәчәкләр һәм менә... беренче иҗат шатлыгы. Һәм менә шуннан иҗади дуслык башланды да инде Аяз абый белән безнең арада.

Аяз абый Хәлил белән минем матур парлар булуыбызга сокланып, яратып карады. Безнең өчен дип махсус пьеса язарга вәгъдә итте.

Хәлил һәм Исламия Мәхмүтовлар

1973 елда безнең театр «Син дөньяда бер генә» спектаклен чыгарды. Мин Аяз абыйның бу пьесасындагы Рәхилә ролен башкардым. Бу спектакльне без бик озак уйнадык. Тамашачы безне үз итте, яратты, бертуктаусыз рәхмәтләрен җиткереп тордылар.

Инде килеп, 1974 елда Аяз абый безгә багышлап язам дигән пьесасын тапшырды.

Ул пьеса «Сары чәчәк ата көнбагыш» дип атала иде. Хәтта образның исеме дә Хәлил дип аталып язылды. Бу спектакльне тамашачылар бүген дә яратып искә төшерә, хәтер-

ли. Бу спектакльдәге Анна ролен башкаруымдагы «Сары чәчәк ата көнбагыш» җыры Татар дәүләт радиосының алтын фондында саклана. Режиссерыбыз Равил Тумашев «Сандугачлар килгән безгә» (И.Юзеев), «Үзебез сайлаган язмыш» (Т.Миңнуллин), «Сары чәчәк ата көнбагыш» (А.Гыйләҗев) пьесаларын сәхнәгә куйган өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясен алды. Әйбәт язылган, саф мәхәббәт, киләчәк тормыш өчен көрәш — «Сары чәчәк ата көнбагыш» спектакле өчен уңыш булды... Бу спектакльне бөтен Татарстан, чит республика авылларында, шәһәр клубларында уйнап чыктык. Шул рольләребезне тамашачы үз итте, яратты. Хөкүмәтебез дә спектакльгә югары бәя бирде. Без үзебез дә бик яратып уйнадык, чөнки ул безнеке, без бик тә тәңгәл килдек.

Агыйделкәйләргә без лә төшәрбез,
Колачларны җәеп йөзәрбез.
Сары чәчәк ата көнбагыш (2 кат),
Сезнең белән яшәү куаныч.

Менә шулай җырлый Анна Хәлиленә.

Бу җыр Мәсгут Имашев эшкәртүендә халкыбызның яраткан җырына әйләнде. Аяз абый да читтә калмады: безгә булган хөрмәтне тамашачыларыбыз газета-журналлар аша да җиткерә торды. «Исламия керәшен кызы монашка Анна ролен башкарды. Күңел көче, ireклеккә омтылышының ачыклыгы, олылыгы белән ул бу образны трагик югарылыкка күтәрә алды. Анна-Исламиянең тар монастырь хөҗрәсеннән чыгып, явыз көчләргә каршы турыдан-туры кулына мылтык алып, сөйгәне өчен көрәшләрнең алгы сафына чыга алуына һичшиксез ышанасың. Һәр кешенең гомере бер генә. Сәнгать, чыннан да, халыкныкы. Ә сәнгатьнең гомерен санау мөмкин түгел. Матурлыкка омтылу, моңга, яхшылыкка омтылу — мәңгелек!

Дөньяның сәхнә дип аталган изге бер почмагы бар. Менә сәхнәгә яңа кеше, яңа артист килә. Ул үзе бер кеше, аның җаны йөзләгән кеше ролен башкара. Бүген ул ягымлы, сөйкемле кыз, иртәгә исә ул ялгыз карчыкка әйләнә. Кемне генә уйнаса да,

ул үзе булып кала. Артистның — чын талант иясенең — күңеле чиксез диңгез, күк йөзе кебек үзгәрүчән була...» — дип язды Аяз абый «Азат хатын» журналына. Ярата иде ул артистларны. Премьералардан соң, барыбызны бергә җыеп, кафе, рестораннарга түгел, үз өенең җылы түренә, ризыклардан сыгылып торган өстәленә чакыра иде. Нәкыя апа белән Аяз абый катына барырга без дә ярата идек. Алар безне үз тиңнәре кебек яратып каршы алдылар, хөрмәт иттеләр. Без труппабыз белән:

Сары чәчәк ата көнбагыш,

Сезнең белән яшәү куаныч... —

дип җырлаштык.

Көләч йөзле, бик тә гади, бик тә кырыс һәм беркемгә дә башимәс горур иде безнең

Аяз абый Гыйләҗев.

12 декабрь, 2005



ЮНЫС САФИУЛЛИН

Җитди дә, шаян

да...

Кешеләр күп вакытта очрак-

лы гына танышып китәләр. Без-

неке очраклы гына башланма-

ды.

Туфан Миңнуллинның Аяз

Гыйләҗевкә 50 яшь тулу уңае бе-

лән язган бик ихлас мәкаләсен

алып карасак, — ул «Яшь ленин-

чы»да 1978 елның 14 гыйнварын-

да «Кайнар чишмә» исеме белән

басылган иде, — мондый юллар белән очрашырбыз: «Республика күчмә театрының

япь-яшь артисты Ю.Сафиуллинның трагикомедия язганын иң беренче булып Аяздан

ишетәбез, ул инде аны укыган, өмет чыгарга тиеш бу малайдан дип куанып йөри».

Туфан абый мәкаләдә аның гаҗәеп ягын күрсәтә — «куанып йөрүен». Кеше уңышы

өчен куана белүчеләр бик сирәк. Аяз абый исә, мәшһүрлекнең ак атына очраклы гына

менмәгән илаһи зат, яшьләргә ярдәм итте, алар уңышы милләт уңышына әйләнсен

өчен зур көч салды.

Безнең яшьлек милләткә хезмәт итүчеләр өчен куркыныч булган чорга туры кил-

де. Шуңа, беренче пьесамны язгач, аны кемгә ышанып тапшырып була дип уйлана

башладым. Шунда келт итеп Габдулла Шамуковның «Казан утлары» журналында ба-

сылган «Сөембикә манарасы безнеке» дигән мәкаләсе искә төште. Журналны армиягә

соратып укый идем. Әлеге мәкалә бөтен дөньямны үзгәртте. Соңрак, әлеге мәкаләне

искә төшереп утырганда, Марсель Сәлимҗанов та: «Шул мәкаләсе өчен күпме кирәк

изделәр инде аны, ничаклы вакыт СССРның халык артистын да бирми интектерделәр»,

— дип куйган иде. Г.Шамуков белән элек тә күп гастрольләрдә бергә йөрдек. Ул мине 1964 елны Сәмәркандта Аксак Тимер табуты янына алып төште, бөтен мәчетләрне күрсәтеп, үзе үк сөйләп тә йөргәннән соң, Олугбәк обсерваториясенә дә алып менде. Әнә шундый милләтпәрвәр шәхескә беренче балам кебек кадерле күргән пьесамны ышанып тапшырдым. Ул, аны укып чыгуга ук, Аяз абыйга шалтыраткан. «Бар тизрәк Аяз абыең янына, ул сине көтә, шуны бел, сиңа ярдәм итәрлек бердәнбер кеше ул», — диде. Шулай итеп, безне Габдулла абый үзе таныштырды. Аяз абыйны ул бик хөрмәт итә, ярата, үзеннән дә артыграк ышана иде.

Восстание урамына баштарак бик еш барып йөрдем. Аяз абыйның күп бүлмәле фатиры миңа җәннәт булып тоела иде. Кайчан гына килсәң дә, анда сине өстәл тулы сый-нигъмәт, ихлас хөрмәт көтә. Нәкыя апа белән әнисе гөл кебек тоткан, исәбе дә, саны да юк кебек тоелган зур-зур бүлмәләр, берсеннән-берсе талантлырак булып үсеп килүче малайлары — Искәндәр, Мансур, Рәшат, иң мөһиме, минем чүлдәге кешедәй сусаган нәрсәм — затлыдан да затлы итеп халык һәм хаклык турында беркемнән дә курыкмый сөйләшүләр бар иде. Әмма ләкин соңга табарак, бирегә миннән башка тагын да бик күпләрнең килеп кунак булып йөрүен күреп, миннән берүк туя күрмәсен бу затлы гаилә дип, барып йөрүләремне сирәгәйттем. Шуның белән күпме нәрсәдән мәхрүм калдым... Хәзер дә үкендерә, әмма балачактан шулай тәрбияләнгән кеше, үкенсә дә, үзенә каршы баралмый. Яшьләргә риясыз ярдәм итү инде гадәтенә кергән, какшамас яшәү халәтенә әверелгән Аяз абый мин ахмак тыйнакны барыбер үз янына китертү җаен таба иде. Аның белән әле дачасында, әле театрда, һич булмаса, Мәскәү янындагы

Рузада үткән семинарларда очраша тордык. «Мәрмәр»е һәрчак куен кесәмдә йөри торган, инде мин күптән ятлап бетергән гүзәл шигырьләр авторы Равил Фәйзуллин белән дә мине Аяз абый үзенең дачасында махсус таныштырды. Икебезнең дә ком гарәбенеке кебек каралган гәүдәләребезгә карап торды да: «Игезәкләр кебек икәнсез, яле, Равил абыең белән Иделдә дә ярышып кара», — диде. Һәм мин, үземнең кумиры-

ма ияреп, Идел уртасына кадәр йөзеп кереп киттем. Равил абый шаккатарлык шәп йөзә иде. Без уртага кереп җиткәч, ул, минем шатлыгымны тагын да көчәйтеп: «Монда бер мин генә йөзәргә яратам дип йөрсәм, әле Юныс та бар икән, икәү булдык», — дип куйды. Бу да Аяз абыйның пәйгамбәрлеге. Әнә шундый юллар белән дә минем рухи дөньямны ныгыта барды.

Оештыру сәләте аның канында иде. Рузада барлык татар драматургын, бер йодрыкка туплап, бергә йөртә белде ул. Туфан абый гына кайчак, «көтүдән аерылып», берничә көнгә югалып тора иде, мин, аның Мәскәүдә туганнары барын белмәгәнгә: «Аяз абый, Туфан абый күренми», — дим. Ә ул нишләптер Илдар Юзеевка күз кыса. Тегесе лириктан шундук сатирикка әйләнә: «Туфан абыең иҗат итә, Горький өлкәсендәге авылдан тракторист хатын-кыз килгән иде, шуның образы өстендә эшли, Мәскәүнең үзендә...» — дип көлдерә. Ашханәгә барганда да без таралып-югалып йөрмәдек. Гел бергә утырып шаяра-көлә ашый идек. Андый семинарлардан соң бик зур бай банкет та була иде. Анда да Аяз абыйның зирәклеген күреп шаккаттым. Табында буш калган барлык рюмка, фужер, графин ише нәрсәләрне үз каршыбызга, ягъни Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев, Нәҗип Әсәнбаев һәм мин утырган өстәлгә җыйдырта да кара урман кебек күренеп торган шешәләрдәге хәмерләрне әлеге буш савытларга бушаттыра. «Хәзер генә күп булып күренә алар, банкет башлануга, мәскәүлеләр килеп җитү белән, каядыр юкка чыгып бетәләр», — ди. Аяз абыйдан башка гына үткән банкетларда булырга туры килде, чыннан да шулай икән, әллә шулай тиз эчеп бетерәләр, әллә сумкаларына тутыралар, сыпырып ташлагандай, бик тиз юкка чыга иде шешәләр. Шуннан соң инде эчәргә ният иткән язучылар аракы эзләп чабыша башлый иде. Ә менә алдан күрүчән Аяз абый банкетның буеннан-буена, горур хан кебек, туп-тулы фужерлар артында утырыр, «Аракыгыз юкмы?» — дип ялынучыларга да көлемсерәп кенә өлеш чыгарудан ләззәт алыр иде.

Аның Әмирхан абый белән таныштыруы да бик истә калган. «Менә бу егетне арабызга алдык, авангардист, абсурдист», — диде. Аксакал: «Бик әйбәт, зур әдәбиятта

берсе дә артык түгел», — дип хуплады. Ә инде Әмирхан ага, «Юныс өчен!» дип күтәреп эчеп куючыларга үземнең кушылмавымны күреп, Аяз абыйга сораулы караш ташлагач: «Эш атыбыз ул безнең, эчертмибез дә, ашатмыйбыз да егетне әлегә», — дип яклап чыкты. Соңыннан Аяз абыйның бу тапкыр сүзләрен М.Сәлимҗанов 20 елдан соң, ягъни 1994 елны, икенче мөһим очракта — «Идегәй» премьерасыннан соң Президент белән таныштырганда файдаланды.

Минем кечкенәдән «Бәхетле бул!» дип әйтә торган гадәтем бар. Аяз абый аны да әйләнешкә кертте. Хәер, анысы да булган хәл бит. Туфан абый май урталары тирәсендә помидор күчерергә савытларны дачасыннан барып алырга ниятләгән. Шунда ул, такси чакыртып, үзенә иптәшкә Аяз абыйны, мине, Ризван Хәмидне дә алды. Мин инде, сумка тутырып, үзем эчмәгәч, чамасын белмичәрәк, «Экспресс» дигән акбашларны алган идем. Барганда бик күңелле булдык. Туфан абый дачасында да көн бик күңелле узды. Хәтта безнең «көтү»гә Аяз абый дача күршесе булган Хәсән Сарьянны да чакырып кушты. Ә менә кайтырга чыккач, болай да аяк батып керә торган язгы җиргә чиләкләп яңгыр коя башлагач башланды хәлләр. Поезд тукталышына кадәр юл урман аркылы иде. Беренче генә килүем булганга, юлны белмим. Аяз абый да, Туфан абый да, Ризван да көчкә атлап килгән җирдән бөтенләй бара алмас булдылар. Мин генә берсеннән икенчесенә, тездән пычракны ерып, чапылт-чопылт китереп чабып йөрим. Поезд тавышы ишетелми микән дип тыңланып, хәтта агач башларына үрмәләп менеп карап та төшкәлим. Аяз абыйны, кулын җилкәмә салдырып, күз күреме кадәр җиргә алып барып, агачка сөяп куям. Аяз абый хәлсез генә мине мактый: «Менә бит, — янәсе, — янында эчми торган бер аек кеше булу ничек файдалы!» Шундук Туфан

абыйга йөгерәм... Ризван гына, башкалардан аерылып калмас өчен, алпан-тилпән килеп, бата-чума, мүкәләп дигәндәй сөйрәлеп килә. Шунда безне үзенең дус хатыны белән Гөлшат Зәйнашева күреп алып, безнең пычрак өс-башларыбызга күз төшергәч, нык кына сызгырып куйды. Төп башына кунаклап безнең ничек алга баруыбызны кү-

зәтте дә: «Ничего, мондый егетләрегез булганда, батып калмыйсыз инде, Аяз. Юк», — дип мактап озатты. Казанга кадәр поездга утырып кайттык. Аяз абый такси тотарга кушты. Аяз абыйны өенә алып кайтып, таң калган Нәкыя апага: «Бәхетле булыгыз, Нәкыя апа!» — дигән идем, арып беткән Аяз абый да рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Һәм бу очракны бөтен җирдә дә сөйләп көлдерә башлады.

Яшьләргә хәерхаһ булуына мисал итеп, аның миңа язган хатын да тәкъдим итәм.

23 ноябрь, 1977

Казан

Юныс!

Мин бу хатны 19 ында ук, премьераңның икенче көнендә үк язарга тиеш идем, әмма ике сәбәп минем итәктән тотты. Берсе: сине 19 ында кайтып җитә икән, диделәр. Мин, җүләр баш, кайтып җиткәч шалтыратыр әле, утырып бер яртыны «сындырырбыз» дип, синнән звонок көтеп ятам. Икенчедән, Туфан Миңнуллинның пьесалар җыентыгына сүз башы язасым бар иде. Шактый авыр һәм җитди эш булып чыкты ул. Аны язган, моны язган, дип кенә санап чыгарга ярамый иде. Туфан хәзер малай-шалай түгел, әдәбиятта нык басып торучы һәм әдәбиятта кала торган егет. Һәм, минемчә, сүз башы барып та чыкты сыман. Кичә шуны Шәүкәт Галиевкә илтеп бирдем дә бүген, яраларымны ялап, урын өстендә ятам. Көн яман әшәке, башны изә.

Премьераң Куйбышев исемендәге клубта булды. Урамнан ук билетлар сорап торалар иде, һич шаяртмыйча әйтәм, пьесаңның исеме бик тартымлы икән, зал шыгрым тулы иде. Туфан белән Равил Тумашев, сәхнә алдына чыгып, синең кем булуың, ничек, нинди юллар белән сәхнәгә килүең турында сөйләп, сөенечләрен уртаклаштылар. Туфан: «Менә без күптән көткән көн килде, без бүген үз арабызга яшь драматургны алабыз. Бәлки, беренче белен төерле дә булыр, әмма Юныс Сафиуллин исемен хәтерләп калыгыз, без аның белән әле бер генә очрашмабыз!» — дип, халыкны гөрләтеп кул чаптырды. «Ак тәүбә, кара тәүбә»не телевизордан карагач, Күчмә театр артистларының уен осталыгы турында бик түбән, яман фикердә идем, анда Туфан әсәрен телә-

гәнчә изделәр алар. Ә монда, турысын әйтергә кирәк, ярыйсы гына, төерсез генә белен килеп чыккан. Иң мөһиме: фикер сакланган, фикер халыкка барып җитте. Люция белән Назлыгөл Латыйпова бик әйбәт, алар күренүгә, сәхнә җанланып китә. Наил Шәйхетдинов та ярыйсы, образ тудырырга маташа, малай! Әле шомалык, осталык җитенкерәми, текстны да бутап җибәрә, әмма ул да ярыйсы. Гөллине уйнаучы кыз да, аз-маз үз көченә ышана төшсә, яхшы гына уйнап китәр. Егетләр йомшаграк, ансамбльдән ычкынып-ычкынып китәләр. Луараны Равил куя алмаган, табалмаган, апасы Рәисәне кабатлап кына бара торган иткән. Рәисә дә бертөрлерәк уйнады, әмма ул ышандыра.
«Их!» — дип тамак төпләре кычытканчы кычкырдык, так что котлыйм! Озак яшә!
Илеңне, кем булуыңны, дусларыңны онытма!
Икенче көнне радиодан, беренче программадан, «С добрым утром» тапшыруын тыңлап утырам...Татар юмористы Ризван Хәмидуллинның хикәясен укыйлар бит, малай... Теге инде, теге, акыл өйрәтеп, тәрбияле булырга кушып мунчасыз калган ахмак турында... Әйбәт кенә тапшырдылар, бигрәк тә «татарский юморист» дигәне ошады.
Егетләрнең исеме яңгыраса, без карт-корының йөрәгенә сары май була инде!..
Җитәкчең минем якын дус Роальд Викторович икән. Миннән күп сәлам тапшыр.
Костя Скворцовка да күп сәлам әйт. Ну, Турга... Анысын үзең беләсең!..
Ярар, Ризван белән тату йөрегез, сынатмагыз. Аңа да чуктин-чук сәлам!
Аяз



ГӨЛНАР СӘЛИМҖАНОВА

Сагынып искә төшерәм

Марсель белән танышуыбызның беренче көннәрендә үк диярлек, дөресрәге 1971 елның февраль башларында, без Аязларга кунакка киттек. Бу вакыйга безнең ярәшүебезнең алноктасы һәм хәлиткеч мәхкәмәсе дә булганлыгын мин еллар үткәч кенә белдем. Шушы мизгелдән безнең тәкъдиребездәге үзгәрешләр чынлыкка аша башлаганга, Аяз турындагы сүземне дә шул очрашу тәэсирләреннән башлыйсым килә.

Аяз белән Марсель 1965 еллардан бирле нык аралашып яшәгән булганнар икән. Аяз Марсельнең буйдак булып йөрүен бер дә хуп күрмәгән. Кайнатам буласы Хәким Йосыф улы — Марселемнең әтисе дә, Аяз белән бер фикердә булып, аны өйләндерү чарасын күрергә тырышканнар. Аяз гаиләсе безне ул вакыттагы Ленин районындагы Воровский урамының 19–14 адресындагы ике бүлмәле «хрущевка» фатирында чын якты хисләре балкышында каршы алды. Кунакчыл, киң күңелле Аязны әле минем беренче күрүем иде. Алар безне мул табын әзерләп көтеп торганнар. Беренче сүзләренең үк мәгънәсе: шундый да тугры ир булырлык Марсельнең гаилә корып җибәрүен тизләтергә өндәү иде. Миңа аның образлы итеп Марсельнең затлы нәсел дәвамчысы булуын, иҗат юлында таяныч булырлык парга әле юлыга алмыйча нәүмизләнеп йөрүен аңлатуы хәтеремдә калган. Сүз арасында шаяртып та, турыдан-туры да минем үткәнемә, киләчәк планнарыма кагылышлы сораулар белән элемтәгә кереп торды. Без аларга көндезге сәгать икеләр тирәсен-

дә барган булсак, төнге сәгать ун-унберләр тирәсендә генә кайтып киттек кебек. Марсель гел Аязның малайлары белән мәш килеп сөйләшеп тә, Аяз белән иҗат эшләре, укылган китаплары турында сөйләшеп тә вакытын уздырды. Ә Аязның миңа сораулар биреп, тикшеренеп сөйләшкәнен ишетсә дә, Марсель ишетмәгәнгә салышып кыланды бугай. Ничек кенә булмасын, бу мәҗлес, Марсельнең ризалыгы белән, Аязның үз гаиләсенә тиң аралаша алырга лаек пар эзләү максатыннан оештырылган иде. Аяз очрашуның ахырына таба, мине ярыйсы гына ияләштерә төшкәч әйтеп куйды: «Син Марсель янәшәсендә безнең гаиләгә аяк баскан кызларның беренчесе түгел, белеп тор, һәм соңгысы булырсың дип беләм. Марсель бу юлы нәкъ тиңенә тап булган дип ышанам», — диде. Бу очрашу мизгеле минем яшәү гомеремдә якты хатирә булып күңелемә язылып калды. Без менә шулай, Аяз Гыйләҗев гаиләсенә барып утырып, аның хәер-фатихасы белән 1971 елның 18 февралендә язылышырга булдык.

Еллар үтә торды. Без бу гаилә белән ризык бүлешеп аралашып яши бирдек. Никадәр ешрак очрашсак, шулкадәр Аязның гаҗәеп үзенчәлекле кеше булуына игътибарым, сәерсенүем арта торды. Кечкенә гәүдәле бу кешегә шулкадәр гайрәт, шулкадәр зиһен ачыклыгы, кырыслык, артык туры сүзлелек (шул сыйфаты аркасында никадәр җәфа чиккән булса да), авырлыклар алдында да куркып кала белмәү, көч, кешеләргә карата мөнәсәбәттә ихласлык чыганагы нидән, каян килә икән, дип, мин сорауларыма җавап таба алмый яшәдем. Марселем, аннан үзгә буларак, кешеләр белән аралашуда дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырып яши белә торган кеше иде. Ничек кенә булмасын, алар уртак тел табып, фикердәшләр, дуслар булып гомер кичерделәр. Алар икесе дә тормышны, кешеләрне яраттылар, гаилә алар өчен изге бер кәгъбә урыны булып саналды. Икесе дә фанатларча балык тотарга йөрергә яраттылар. Сүзләрен балык тоту



турындагы татлы әңгәмәләрдән башлап җибәрәләр иде дә дөнья әдәбияты яңалыкларына тоташтырып, татар сәнгате үсешенә бәйле мөнәсәбәттәге кайгыртучанлыклары, борчылулары белән дә тәмамлыйлар иде кебек. Тагын бер йомшак охшашлыкларына тукталып китмичә булдыра алмыйм. Аяз да, Марсель дә, кая барсалар да, затлы бутылкалардагы кыйммәтле эчемлекләр җыеп кайтырга яраталар иде. Алар безгә килсә, без аларга барсак, шкаф-барларын ачып, бер-берсенә күрсәтешеп мактанышалар иде. Өстәл артына кайсы затлы коньякны куярга икәнен киңәшләшеп, бер фикергә килгәч, тәмләп 2–3 рюмка коньякны эчеп тә куялар...

Минем хәтеремә бик нык язылып калган бер маҗаралы вакыйганы язып үтәсем килә. Бу хәл 1979 елның гыйнвар башында булды. Без үзебез Марсель белән икәүләп балыкка йөрергә яратканга күрә, дусларыбызны да кузгатып, шул ләззәтле халәтне аларга да татытырга теләдек. Бу эшне оештырырга алынучы мин булдым. Мин, Туфан Миңнуллинга, Николай Дунаевка, Аяз Гыйләҗевкә шалтыратып, кышкы балык тотарга барырга күндердем. Барысы да «30 градуслы салкын кыш алар өчен ничто» дигән фикердә булды. Аяз Гыйләҗевләрнең Займищедагы җәй көне генә яшәр өчен тактадан төзелгән йортларына барып тукталырга булдык. Вокзалда җыйналышып электричкага утырдык та карлы салкын кышның гыйнвар аенда кичкырын сәфәргә кузгалдык. Гаҗәп калын кар көртләрен ерып-таптап, Аязларның ике катлы дача-йортларына барып җиттек. Без барыбыз да зур бүлмәгә кереп урнаштык. Янәшәдәге бүлмәләрдә язу өстәлләре, стенага көйләп эшләнгән китап киштәләре, зур гына кухня булса да, без аларга күз генә салдык. Без, шул бер бүлмәдә яшәп, җылы саклап, буржуйкага ягып аш-су әзерләп, шунда ук өстәл дә әзерләп, кичне уздырырга булдык. Хатын-кыз аш-су әзерләү хәстәрен күрде. Ә ир-атлар иртәнгә таба Иделгә балыкка чыгарга ниләр кирәк булачагын уйлашып планнарын кордылар. Нәкыя мичкә ягып җибәрде. Өйдә җылылык, ямь хасил булды. Күңелләр күтәрелде: без шат, без бәхетле! Мин шунда да Аязның тышкы кыяфәтенә игътибар итеп караганымны хәтерлим. Киң, үз сүзендә нык торучан кешеләргә генә хас сөзәк маңгай, нечкә керфекләре аңа ялыкканлык, арыган-

лык кыяфәте биргән кебек тоелды миңа. Шулай булуга да карамастан безнең кичке мәҗлесебез мул табын артында сөйләшеп күңелле узды. Керосин лампасы яктысында сөйләшеп утыруның үз хозурлыгы булгандыр, безгә рәхәт булды. Бик соң гына йокларга яткан булдык. Буржуйканың җылысы арба таудан түбәнгә тәгәрәгәндә генә тәгәрәтә торган булып чыкты. Без йокларга ниятләп әйләнгәләгәндә, аның күмерләрендәге ут яктысы сирпелеп кенә җемелди иде. Урамда зәмһәрир кыш салкыннары, җит-

М.Сәлимҗанов

Аяз дустын

70 яшьлек юби-

лее белән кот-

лый. 1998



мәсә, Дунаевлар көзгечәрәк кенә итеп, җи-
ңелчә генә киенгәннәр булып чыкты. Без,
Марсель белән икәүләп, кыш көне дә туң-
дырмыйча җылы саклый ала торган йокы кап-
чыгыбызга кереп чумдык. Аяз белән Нәкыя
дә, Туфан да ярыйсы гына кышкыча киен-
гәннәр. Тик менә Дунаевларның җиңелчә
киенгән булулары безне пошаманга салды.
Йокларга яттык. Черем итеп алган кебек бул-
дык.

Аязда артистлык шаукымы ярылып ята
иде. Үзенә генә хас тәэсирләнүчәнлек, зи-
рәклек бар иде аңарда. Бу сыйфатлар аңарга
геннардан, тумыштан килгәндер күрәсең, аны
кешегә тәрбия чаралары белән генә сеңде-
реп булмыйдыр дип уйлыйм мин, хәзерге ба-
шымны сискәндереп. Ул чын мәгънәсендә-
ге шәхес булган. Шәхесләрне бизи торган
сыйфатларның барысын да аңа табигать бү-
ләк иткән иде. Ул салкынга түзә алмыйча
сикереп торды да, йон чолкәләр* кигән ая-
гын тыпырдатып килеп, минем аяк үкчәм-
нән тарткалап: «Тор, чукынчык, бу синең тарафтан китереп чыгарылган мутлык. Шу-
шындый суыкта кеше җылы өеннән чыгып китәме? Тор, тор да мичкә як. Ә сез үзегез
анда җылы капчык эчендә мәхәббәт уены уйнап ятасыздыр әле...» — диде.

Буйсынмыйча хәлем булмады. Марсельне уятмаска тырышып, шыпырт кына капчык
эченнән чыктым да, буржуйканы кабызып, өйне җылытырга керештем. Буржуйканың эчен-

дә, мин барып ачып караганда, бөтенләй җылылык әсәре юк иде, киресенчә, тимер кәүсәле бу мич дип аталган нәрсә өйдәге җылылыкны суырып кына утыра иде. Өйгә җылылык иңде, рәхәтлек кайтты. Мин инде яңадан йокларга ятарга омтылмадым да. Калын шәлгә төренеп, мәхәббәт турында, аның сихри көче турында уйланып утырдым. Аяз белән Нәкыянең кочаклашып яткан хәлдә берсенең җылысын икенчесенә биреп бүлешүләре турында уйландым. Аларның мәхәббәтле тормышта яшәүләренә сокландым. Мин үзем аралашкан кешеләр арасыннан Аязга тиң гаилә дип ашкынып яшәгән кешене табып әйтергә авырыксынам. Алар икәүләп чын мәгънәсендә җәмгыятебез, милләтебез горурланырлык өч баһадир ир-егет үстерделәр. Аяз алар өчен үрнәк ата була белде. Әгәр шулай әйтергә яраса, Ил горурлыгы булырлык Уллар үстерде ул.

Без шулай җәйләрен дә алар белән балыкларга йөрдек, йортыбызда кунак-кунак уены уйнаштык, аралаштык. Аяз белән Марсель сәясәт хакында нык уртак фикердәшләр булдылар. Аяз ул өлкәгә кагылышлы фикерләрен, язып чыгып, трибуналардан сөйләп, халыкка җиткерә торды. Марсель, әйткәнемчә, сак кеше иде, дипломатлык саклады.

2002 ел безнең гаиләләр өстенә кайгы пәрдәсен бөркәде. Аяз 2002 елның 13 мартында вафат булды. Марсель дә авыр хәлдә урын өстендә ята, мине бер генә секундка да үзенең янәшәсеннән җибәрми. Аязның вафаты хәбәрен ишеткәч, аның үзен тотышындагы үзгәрешләрне хәзер дә, күз алдына китерсәм дә, язып биреп, әйтеп аңлата алмыйм. Мондый халәтне тасвирлау өчен Аязча талантка ия булырга кирәктер шул. Марсель миннән, Аязның мәете янына барып, аның исеменнән һәм үземнең исемемнән баш июемне үтенде. Мин шулай эшләдем дә... 26 мартта Марселем мәңгелегенә мине бу фани дөньяда калдырып китеп барды. Урыннары җәннәттә булсын!

20 ноябрь, 2005

* Ч ө л к ә — йон оекбаш (диал.).

Марсель Сәлимҗанов



РАВИЛ ТУМАШЕВ

## Аяз турында истәлекләр

Аяз белән безнең беренче танышуыбыз бик кызыклы, һич тә онытылмаслык, мәзәкле булган иде. 1958 елның җәй көннәрнең берсендә Диләрә белән без танышу өчен Аязны бакчабызга, әле яңа, салынып та бетмәгән, Васильево поселогының Казанга таба сузылган тимер юлы буендагы урманлыктагы кечкенә генә бер түгәрәк күлгә бердәнбер күршесе булып урнашкан дачабызга чакырган идек (Аязның хәләл җефете Нәкыя ул көннәрне бала табу йортында булганга, ул килә алмады). Аязга безнең бакчабыз һәм салына торган җәйге йортыбыз ошады шикелле. (Дөресен әйтергә кирәк: алар безнең үзебезгә дә бик ошый иде. Җәннәт иде инде. Үзебезнең дә яшь чаклар, матур гына дүрт яшьлек кызыбыз Ләйсән сүзгә оста татар кызы булып үсә һәм барыбызны да шатландыра иде.) Өстәл алдында ук башланып киткән әңгәмәбез, әлбәттә, Аязның яңа гына тәмамланган «Җиз кыңгырау» исемле әсәре турында булгандыр. Бераз гына бәхәсләшеп тә алдык шикелле. Табын алдыннан торып, һава суларга дип бакчага чыктык. Нәкъ Тукайның әкиятендәге кебек, шул «бик матур бер айлы кичтә» безнең бәхәс бераз кызган булса кирәк, үзебез дә сизмәстән без эләгешеп алдык, кочаклашып көрәшә дә башладык, «хәтфәдән юрган» булган яшел үләндә тәгәрәшеп көч сынаштык. Беребезнең дә бирешәсе килми: беребез авыл малае булса, икенчебез — детдом баласы. Ахыр чиктә көлешеп, шаярышып, эшне әллә ни куертып җибәрмәдек. Мәңге онытылмаслык булып истә генә калды. Менә хәзер кирәге дә чыкты. Әллә ни булмаса да, театр дөньясында автор белән режиссерның иҗат мәсьәләләрен шул рәвештә хәл итү мисаллары сирәктер.

Аязның беренче сәхнәләштерелгән әсәре «Җиз кыңгырау» иде. Ул 1959 яисә 1960 елны Татар дәүләт академия театрында уйналды. Төп рольләрне башкаручылар: Хөрмәтулла — Фатих Колбарисов, Разыя — Люция Фарсина, Мәүлә — Мәсгут Имашев, Гәрәй — Дэллюс Ильясов.

Шуны да әйтеп китәсем килә — ул елларда Академия театрында артист булып эшли башлаган бүгенге танылган композиторыбыз Мәсгут Имашевның спектаклебездәге Мәүлә образы аның артист буларак сәхнәгә беренче аяк басуы һәм театр сәнгатендә уйналган беренче роле дә иде.

Әмма «Җиз кыңгырау» Аязның беренче сәхнә әсәре түгел.

Миндә сакланган пьесалар арасында Аязның 1956 елда машинкада басылган «Давыл артыннан» исемле 4 пәрдәле пьесасының супер тышлыгында аның үз кулы, үз каләме белән язылган, ул елларны инде Республика күчмә театры баш режиссеры булган минем әнигә юлланган мондый сүзләр бар:

«Кәшифә апа!

Мин берничә мәртәбә Сезне күрергә тырыштым.

Бүген инде пьесаны калдырырга булдым.

Укып, пьесага һәм миңа игътибарлы карашыгызны көтәм.

Аяз.

2/11–56 ел».

Бу вакыйгадан соң ярты гасырга якын вакыт узса да, Аязның бу әсәренә дә, аның үзенә дә әниемнең ул вакытта җитәрлек дәрәҗәдә игътибарлы булуы һичшиксез. Әсәрне укып чыкканнан соң, ул аны, озакка сузмыйча, Министрлык каршындагы реперткомга тапшырган һәм 1957 елның апрелендә үк әсәргә карата уңай фикер, куела алуына рөхсәт итү хатын алган. Әсәрнең ни өчен шул ук вакытта куелмаганын хәзер әйтүе кыен, ләкин моңа, әлбәттә, берничә сәбәп булгандыр дип уйлыйм. Иң элек бу Аязның

беренче драма әсәре булганлыктан, анда авторның үзен дә канәгатьләндермәгән яклар булуы мөмкин. Бәлки, алар турында әсәр белән танышкан иптәшләре дә әйткәндер. Һәрхәлдә, Аяз, ул әсәре өстендә эшен дәвам итеп, хәтта Переделкино семинарларында Мәскәү драматурглары белән фикерләшкәннән соң, шул ук персонажларын (Разыя, Мәүлә, Хөрмәтулла, Чәчкә, Гәрәй) яңа драмада — «Җиз кыңгырау» әсәрендә яшәртергә булган.

Әгәр югарыда әйтелгән сәбәпләр булмаса, әни, бәлки, бу яшь драматург белән дә җиң сызганып эшли алган булыр иде. Нәкъ шушы елларда яңа гына Республика күчмә театрына баш режиссер булып билгеләнгәч, ул, аңа хас җитезлек белән, театрының репертуарын яшь драматурглар әсәрләре белән баетырга керешкән иде һәм беренче сәхнә әсәрләре буларак Хәй Вахитның «Яшерен эзләр», Зәйни Шаһиморатовның «Хәзрәт үгетләргә килә», Гамир Насрыйның «Яшел эшләпә», Шакир Мәҗитовның «Рәзидәкәй» исемле һәм тагын күп кенә пьесаларын сәхнәгә менгезде.

Ул елларны мин, әнинең эшен дәвам итеп диярлек, Татар дәүләт академия театрына режиссер булып кайткач, башта классик драматургия әсәрләрен сәхнәләштерү белән бераз мавыккан идем. Әмма бу хәл мине һич тә канәгатьләндермәде. Бүгенге көн репертуары турында миңа да уйланырга туры килде.

Менә шул елларда безнең Аяз белән очрашуыбыз һәм иҗади хезмәттәшлегебез дә башланды. Әгәр беренче сәхнәләштергән әсәре «Җиз кыңгырау» Академия театрында уйналса, калганнары, мин соңыннан Татар дәүләт республика күчмә театрында эшли башлагач, шул театрның сәхнәсендә куелды. Менә аларның еллары һәм исемнәре:

1964 — «Кара күзле кызлар»;

1968 — «Шомырт чәчәк атканда»;

1973 — «Син дөньяда берәү генә»;

1974 — «Сара чәчәк ата көнбагыш»;

1981 — «Шикәрем син, балым син»;

1982 — «Ефәк баулы былбыл кош».

Язучылар, тәнкыйтьчеләр арасында драматургия жанрына карата аның иң авыр, катлаулы жанр булуы турындагы фикере мәгълүм. Моның дөреслеге безгә драматурглар белән (бигрәк тә яшь драматурглар белән) эш иткәндә күренә. Әйтмичә кала алмыйм: Аяз белән башланган иҗади эшем дәверендә миңа башка яшь драматургларны да сәхнәгә чыгарырга мөмкинлек булды.

Беренче очрашуларыбыздан алып соңгы вакытларга хәтле без Аязның үзе белән дә, гаиләләребез белән дә якын дуслар идек, тормышларыбызның кайсыдыр вакытлары аеруча җылылык белән төсмерләнеп, туганлык төсләрен алып үтә иде: әйтик, кызыбыз Ләйсән белән Рөстәм киявебез туенда Аяз, тамада булып, ул мәҗлесне онытылмаслык вакыйга итеп алып барды. Аязның шуклыгы, шаянлыгы, һәр эштә уңганлыгы, тапкырлыгы көндәлек тормышыбызда да ярылып ята иде. Аның кешелеклеге һәм ярдәмчеллеге турында да әйтмичә кала алмыйм. Бервакыт минем йортыбызда баз казып газаплануымны күреп, ул шундук минем белән бергә эшкә тотынды, үзенең бу эштә булган тәҗрибәсен күрсәтте. Шуның белән бергә Аязның искиткеч оста оештыручы булуын әйтеп китәргә кирәк. Минемчә, бу сыйфатлары аның «Давыл артыннан» дигән беренче әсәренең геройларында да чагылыш тапты. Ул әсәрне яңадан кайтып-кайтып укыганнан соң, аның сафлыгына сокланып, яңадан аның матурлыгына биреләсең һәм, ниһаять, аны сәхнәләштерү турында хыялланып куясың. (Урыслар мондый чакта «А чем черт не шутит?!» дип тә куялар.)

Аяз белән безнең арада төрле вакытлар булгандыр, әлбәттә, ләкин асылда без фикердәшләр булмасак, ул миңа һәрвакыт яңадан борылып кайтмас иде. Мине дә аның прозаик буларак иҗат иткән кайбер әйберләре тынгылык бирмичә уйландырмаслар иде. Бервакыт мин аның «Язгы кәрваннар»ын сәхнәләштерү теләге белән хыялланып йөрдем, ләкин табигатемнең кыюсызлыгы миңа бу хыялымны тормышка ашырырга бирмәде. Шунысы гына өметләндерә: «Өметсез шайтан гына» диләр бит, әле вакыт узмаган.

Аязның драматург буларак сәхнә әсәрләрен язу осталыгына килгәндә, минемчә, ул гел үсә барды. Бу истәлекләремдә мин бар әсәрләренә җентекләп анализ ясарга җыенмыйм һәм алынмыйм да, әмма мисал итеп шуны гына китерә алам: 1973 елны сәхнәбездә куелган «Кечке әңгәмәләр» драмасы (без аны «Син дөньяда берәү генә» дип атап уйнадык) шактый үзенчәлекле фәлсәфи тирәнлеге белән аерылып тора иде. Без аны үзебезчә аңлый да идек шикелле, әмма тамашачыларга ул ничек барып җиткәндер, әйтүе кыен иде. Менә берзаман театрыбыз бригадаларының берсе яңа гына куелган шушы спектакльне маршрут планы буенча Малмыж клубы сәхнәсендә уйнарга тиеш иде. Спектакльнең барышын, тамашачының аны кабул итүен күрер өчен мин Малмыжга барып чыгарга булдым. «Казан — Малмыж» автобус рейслары булганга, бу артык кыенлык тудырмый иде. Шуның өстенә Малмыжда минем туганнарым да яши иде. Аларда тукталырга да җайлы.

Бригадабызның исән-сау килеп төшүен белгәч, декорацияләрен сәхнәдә дөрес урнаштырылганнарын күргәннән соң, туганнарымны эзләп киттем. Таптым. Алар минем туганнан туган энемнең гаиләсе һәм якын туганнары иде. Әлбәттә инде, кичке спектакльне карарга билетлар да алып куйганнар. Минем килеп чыгуыма бик тә куанганнар иде. Менә берзаман җыелышып клубка киттек.

Спектакльнең әзерлеген тагын бер барлап чыкканнан соң, залдагы утлар сүнгәч, мин, бер буш урынга урнашып, залдагы тамашачыларның артистларымның уйнауларын кабул итүләрен кичереп утырдым. Гомумән, мондый чакта режиссерның хәле һич кызыгырлык түгел, чөнки, спектакль ничек кенә бармасын, артистлар ничек кенә уйнамасын һәм тамашачылар ничек кенә кабул итмәсеннәр, бернәрсәне дә үзгәртеп булмый инде (үзең генә чыгып уйнамасаң шунда). Нәкъ шулай булып чыкты да!

Беренче пәрдәнең беренче күренеше уйналганнан соң, кыска гына бүленеш вакытында, минем янга киендерүче кызыбыз килеп, мине сәхнә артына чакырды: Фәридон аганың хәле начар, диде. Килеп керсәм, олы артистыбыз Фәридон ага Юнысов тезеп куелган дүрт-биш урындыкка сузылып яткан.

— Хәлем начар бит, Равил Рәхимович, ни эшләрбез икән? Йөрәк, — ди бу.

— Борчылмагыз, Фәридон ага. Сезнең бит тагын дүртенче күренештә генә. Үзем уйнап чыгармын. Сез тынычланыгыз, борчылмагыз гына. Яле, кепкагызны бирегез, ярыймы икән, килешәме икән?

Дарулар бирдек, врач чакырттык, спектакльне дәвам иттек, тамашачыларга сиздермәдек. Дүртенче күренештә уң яктагы болдыр янындагы эскәмиягә утырдым да Миассар ролен (исемен ялгышмасам) уйнап чыктым. Бик тырышып, авторның әйтергә теләгән фикерләрен, образның хис-тойгыларын, «Кичке әңгәмәләр» сүзләренә салынган хисләрне кичерергә тырышып уйнадым. Ярый әле спектаклебезнең «Син дөньяда берәү генә» дигән көе дә бар иде, тамашачыны бигрәк шул җәлеп итә иде кебек.

Спектакль беткәннән соң, кепка белән курткамны салып тапшыргач, туганнарым белән өйгә кайтырга чыктык. Үзем көтәм инде: минем уеным турында нәрсә әйтерләр? Тик берәү дә бер генә сүз дә дәшми. Шуннан соң үзем сүз каттым, Фәридон абыйның авыр хәлдә больницага озатылуы турында әйттем. Моңар, әлбәттә, шаккаттылар. Әле шуннан соң да сораулар булмагач, ниһаять, үземнең сәхнәгә чыгуымны әйттем. Гаҗәпләнүләр булса да, мактау сүзләре булмады. «Кара син аны, без танымадык та. Тавышың начар ишетелде шул, сүзләре аңлашылып бетмәде», — диделәр. Менә шулай да була икән.

Аязның моннан башка да безнең театрыбызда куелган спектакльләре турында сөйләү озакка сузылыр дип куркам...

Гыйнвар, 2006



ӘЗһӘР ШАКИРОВ

Киләчәккә карап фикерләде

«Әйе, наданлыгы өчен туган халкыма рәнҗим.

Әгәр ул мине кочагына алып, әз генә иркәләп үстерсә дә, мин бөек кеше буласы идем! Бирмәгәнме табигать миңа талантны? Мул биргән, юмарт өләшкән. Тик мин табигатьнең ышанычын акламадым! Тәңрем рәнҗесә дә була! Мин татарны аңламадым! Аңламаган кешеләр белән югары дәрәҗәдә күңелем ачылганчы сөйләшә алмадым.

Сагынып, Аяз».

«Ни чыкмаса — шуннан чыгар» дип, холкы, фикере, кешеләргә булган мөгамәләсе белән башкалардан аерылып торган кешегә әйтү гадәте бар.

Аяз абый, йөгерек карашлы, зәвыклы, тирән фикер йөртә алу сәләтенә ия кеше буларак, безнең чор зыялылары арасында аерылып тора иде. Еллар узгач кына, узган сукмакларыбыздагы эзләр тарих битләренә кала барганда гына без: «Кара әле, бу бит нинди шагыйрь иде... Янәшәбездә нинди әдип яшәгән икән... Ничек абайламый калганбыз соң?» — дигән кебегрәк фикерләрне үзара да, трибуналардан әйтеп тә чөбәләнгән булабыз...

Аяз абый үзенең яшьлегенә кагылышлы истәлекләрендә иртә яшьлегендә үк яшәү мәгънәсенең серләренә төшенергә тырышу ихтыяҗы белән янганлыгын тасвирларга тырыша. Шулай итеп, безнең күз алдыбызга гади кеше түгел, катлаулы шәхес килеп баса. Чыннан да, язмыш аны, колак белән тыңлаганны акыл күзәнәкләре аша үткәргәндә, җанны тетрәтерлек сынаулар алдында калдыра. Тормышының иң ямьле булырга тиешле чорын ул төрмә-лагерь диварлары артында уздыра. Бер уйласаң, әгәр аның тормышы шундый булмаса, язмышын шундый сынаулар аша узарга туры килмәсә,

бәхетсезлекнең чигенә барып чыкмаса, бәлки, без белгән, без күргән Аяз Гыйләҗев бөтенләй башка язучы булыр иде. Без, кешенең язмышы маңгаена язылган инде ул, дип әйтергә күнеккәнбез. Аяз абыйга да сынар өчен Ходай Тәгалә шундый язмышны тәгаенләгәндер!..

Минем күңелемә Аяз абый киң күңелле, үзенең кем икәнен белә торган туры сүзле, бик тиз кызып китә торган, мәҗлеснең уртасында булырга яратучы, сөйләгәндә кешене үзенә җәлеп итә белүче гаҗәп тә үзенчәлекле кеше булып язылып калган. Хәер, аның төрмәдә утырулары хакында мин соңыннан гына, иҗатына мөкиббән китеп таныша башлагач кына белдем. Ул, үзенең бәхетсез язмышы, караңгы үткәне турында сөйләп, кешене шаккатырмый иде.

Аяз абыйның иң матур гадәтләреннән берсе: ул, әгәр яшь кешедә әз генә сәләт чаткысы күрсә, шуңа, нинди юллар белән генә булмасын, ярдәм итәргә тырыша иде. Мин үзем аны бик күп яшь шагыйрьләргә, прозаикларга тирән хөрмәт белән дәртләндергеч, таләпчән, рух күтәрергә этәрә торган мәкаләләр бастырып чыгарган язучы буларак хәзер исемә төшереп утырам. Никадәр башлап язучы яшь авторлар, аның хәер-фатихасын алып, киң әдәбият мәйданына кереп киттеләр. Без бит күп вакытта үзебезнең фикерләребезне әйтергә куркабыз, уңайсызланабыз. Ә инде ул заман, безнең яшьлегебез заманы, үзенә бер үзенчәлекле чор иде шул. Син язган һәрбер сүзең өчен партия органнары алдында җавап тотарга тиешсең! Кеше партиялеме, партиясезме — син әйткән сүзеңнең хаклыгын акларга тиеш. Шулай итеп, мәкаләне язган авторның тетмәсен тетәләр иде. Аяз абый сүзне куркып әйтмәде, әйтә белеп, курыкмыйча әйтте. Бу урында яшьләргә мөнәсәбәтен билгеләп үтәсем килгән булса, өл-



кәннәргә карата булган мөнәсәбәтендәге үзенчәлегенә дә тукталасым килә. Анысы да бит әле аның аерым игътибарга лаек. Татарның күренекле язучысы Ибраһим Салахов белән Аяз абый бертөрле язмыш кичергән кешеләр буларак укучылар күңеленә кереп калдылар кебек тоела миңа. Ибраһим Салахов 1911 елда Казакъстан дәүләтенең Күкчәтау шәһәрендә дөньяга килеп, татар мәктәбен дә шунда тәмамлаганнан соң, 1928 еллардан башлап язмышы аны Казан каласына алып килә. Мин аның тормыш юлын җентекле белмим дә диярлек, алай да 1938 елдан башлап 1956 елларга кадәр фаҗигале икәнлеген матбугат битләреннән укып белдем. Хәзер уйланам да шакларга катам, Аяз абый үзе ниндидер югары мөнбәрдә утыра торган дәрәҗәле кеше түгел, ә Казакъстанда яшәп ята торган, язмыш тарафыннан кыерсытылган кешегә Казаннан хатлар яза башлый. Аяз абый Ибраһим Салаховның нәшрият тарафыннан кире кагылган «Имәннәр тамыр җәйгәндә» әсәренең язмышы өчен борчыла. Минем уйлавымча, ул язмышы белән үз язмышына аваздаш кешегә ярдәм кулы сузарга тырышып элемтәгә кергәндер. Гарәп шрифтында да, латин шрифтында да кулъязма хәлендә кулдан-кулга йөртелеп таушалып беткән бу 800 ләп биттән торган романны үзе сорап алып эшкәртергә алына. Нәтиҗәдә Аяз абый эшкәртүендә «Имәннәр тамыр җәйгәндә» дигән роман 1986 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Бу Күкчәтау якларындагы татарлар тормышын тарихи яссылыкта гаҗәп тә мавыктыргыч итеп язылган роман укучылар тарафыннан җылы кабул ителде. Романга Аяз абый кул салмаган булса, яңадан баш калкытуы шикле булган булыр иде дип уйлыйм. Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре», «Тайгак кичү» әсәрләренең уңай язмышы өчен дә Аяз абый ихлас җан атып йөргән кеше булды. Ибраһим Салаховның өлкән яшьтәге кеше буларак, мәңгелегенә китеп барганчы дип, күңелен күреп калырга тырышырга чакырып, бөтен җәмәгатьчелекне кузгатты. Романны «Казан утлары» журналында һәм китап нәшриятында бастырып чыгару өчен кирәкле оешмаларга мөрәҗәгать итеп, тешетырнагы белән авторга ярдәм итәргә тырышты. Нәтиҗәсе дә озак көттермәде: 1990 елда Ибраһим Салаховның бу әсәре республикабызның иң югары бүләге — Г.Тукай

Г.Камал театрының яңа бинасы ачылган көн истәлеге



исемендәге премиягә лаек булды. Язучылар берлеге идарәсе, Аяз абыйның фикерләрен хуплап, бертавыштан Ибраһим Салаховны шушы бүләккә лаек дип тәкъдим иткәннәрен хәтерлим. Никадәр ихласлык, никадәр фидакарьлек үрнәге булган ич Аяз Гыйләҗев шәхесе.

Аяз абыйның өлкәннәргә мөнәсәбәте үрнәге итеп тагын бер язучыны искә аласым килә. Ул — Себердә яшәп иҗат иткән татар язучысы Якуб Зәнкиев. Бу турыда матбугатта күп язылды. Аяз абый берничә язучы белән бергәләп 1960 еллар тирәсендә Себер якларына татар укучылары белән очрашуга баралар. Шул якларда яшәп гомер кичергән, Тобол өлкәсенең Хуҗайлан урта мәктәбенең директоры булып эшләгән, татар әдәбиятын эзлекле укып барган математика укытучысы Якуб Зәнкиев белән алар гомерлеккә дуслашалар. Аяз абый аңа Себер ягы татарлары турында үзе белгәнчә итеп язып карарга тәкъдим ясый. Шулай итеп, Якуб абый да «әсәр язу чире» белән авырый башлый, үзенең кульязмаларын Аяз Гыйләҗевкә юллый тора. Аяз абый аны эшкәртеп роман хәленә китерә. 1994 елда «Иртеш таңнары» исеме белән Татарстан китап нәшриятында чыккан роман шул дуслыкның җимеше дип беләм мин. Бу роман да 2002 елда, Аяз Гыйләҗевнең вафаты елында, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Әсирлек михнәтләрен кичеп кайткан Әнәс Галиевнең әсәрләрен дә Аяз абый эшкәртеп дөньяга чыгарды дип беләм. Әнәс абый, әсирлектән котылып кайтканнан соң, ирекле совет илендәге җәфалануларын һәм финанс эшендәге эчке агымны күрсәтергә тырышып әсәрләр яза башлый. Ләкин аның каләменең куәте әсәрләрен китап дәрәҗәсенә җиткереп чыгарырлык булмый. «Намус кушканча» һ.б. әсәрләрен чыгаруда Аяз Гыйләҗевнең кулы уйнаган.

Әйтәсе килгән сүзем шул: яшьләргә карата да, өлкәннәргә карата да Аяз Гыйләҗев гаҗәеп игътибарлы язучы булган икән, дип уйланам хәзер. Аяз абый татар милләтенең язмышы өчен борчылган, аның географик картасының киңәюен теләгән зат булган икән. «Имәннәр тамыр җәйгәндә» романы Казакъстанда яшәгән татарлар турында

булса, «Иртеш таңнары» Себердә яшәгән татарлар турында тарихка хәбәр калдыралар

ич!

А.Гыйләҗевне 70 яшьлек юбилее белән И.Шакиров котлый. 1998



Аяз абый кечкенәдән бик күп укырга яраткан булуы белән аерылып торган. Ул үзе бу турыда күп мәртәбәләр язып та чыкты, очрашканда үзенең М.Ф.Достоевский әсәрләрен ничек укуын безгә көлдерә-көлдерә сөйләгәне дә бар. Урысның бу бөек язучысының әсәрләрен ул тыныч кына укый алмаган: укый торган җиреннән китапны ыргытып бәреп, сулкылдап-сулкылдап елап алган. Елап арыганнан соң, яңадан барып алып, тагын укый башлый торган булган. Ул үзенең әсәрләрен дә шушы бөекләргә тиң итәргә тырышып язгандыр. Ул үзен татарның Достоевские, Чеховы, Куприны һ.б. дәрәҗәсенә күтәрелдерергә талпынгандыр. Үзенең әсәрләренә шулар күзлегеннән чыгып бәя бирергә тырышкандыр. Син язган әсәрләр дөнья күләмендә яңгыраш алсын өчен, чыннан да, бөек булып туарга кирәк. Аның өчен бер генә юл бар: ул да булса татарның чын йөзен, мәгънәсен, үткәнен, киләчәген, фаҗигасен бөтен тирәнлеге белән үзенә ачып күрсәтү! Карагыз, менә кем ул татар! Әлбәттә, мондый биеклектә үз-үзеңә андый сораулар бирү ул заманда мөмкин түгел иде. Ләкин җаннарында, уйларында, фикерләрендә, шәмдәге ут кебек бер калкып, бер сүнеп, татар язмышы язучыларыбызны гел борчып торды. «Татарның үз дәүләте булырга тиеш» дигән фикер гомер бакый милли рухлы кешеләрнең күңеленнән китмәгән. Гаяз Исхакыйлар шул фикерне куәтләгәннәр. Дәүләтсез халыкның киләчәге юклыгын аңлаганнар алар. Дәүләтсез милләтнең язучысы дөнья киңлекләренә аваз салып ничек чыгып китә алсын соң?.. Сораулар, фаразлар, уйланулар...

Совет власте хакимлек иткән заманда шушы бөек, гадел фикерне безнең язучыларыбызның әйтеп бирергә мөмкинлеге бар идеме? Әлбәттә, юк! Мондый хәлдә яшәсә, татарның милләт буларак киләчәге юк, дип әйтерлек язучыларыбыз бармак белән генә санарлык иде шул. Аяз абый совет властен бөтен күңеле, җаны, рухы белән кабул итә алмады. Җәмгыятьтә гаделлекнең булмавы, бәхетсез халыкның язмышы аның рухын, бәгырен кимерде. Бер сүз әйтеп кара син совет властена — партиягә каршы кеше санап, конвой белән яңадан таныш юлларыңнан чыгып китәреңне көт тә тор! Ә бит чын язучы табигате белән гаделсезлекне, намуссызлыкны күтәрә алмый. Шуңа күрә Аяз абыйга үзе

яшәгән җәмгыять белән көрәшергә туры килде. Ул үзенчә көрәшче була белде! Аның

Татар зиратында А.Гыйләҗев кабере

җанында, акылында цензор утыргандыр: менә болай язсаң, сине гомердә басмаячаклар, калган гомереңне яңадан төрмәдә үткәрәчәксең, гаиләңне, балаларыңны ятим итәчәксең дигән уй-фикер үзе үк бугазыннан буып торгандыр. Мондый фикергә килүемнең асылында әңгәмәләр вакытында булган тәэсирләнүләр ятадыр дип уйлыйм.

Аяз абый турында яза башлагач, күңелемдә әллә нинди уйлар, фикерләр уянды; юк, моны мин алдан уйлап язмадым, бу үзеннән-үзе килеп чыкты. Аяз абый кеше буларак, әйткәнемчә, киң күңелле, кешеләргә бик зур хөрмәт белән карый торган шәхес иде. Мине ресторанга алып кереп берничә мәртәбәләр сыйлаганы булды. Аның белән сөйләшеп туеп булмый иде. Беренчедән, ул бөтендөнья әдәбиятыннан, рус әдәбиятыннан хәбәрдар. Икенчедән, ул дөньяда бара торган вакыйгаларга карата мөстәкыйль фикергә ия кеше иде. Өченчедән, ул минем уйнаган рольләремнең һәммәсен дә белеп тора — монысы инде минем өчен иң заруры, кадерлесе! Ул синең эшләгән эшеңә зур хөрмәт белән карый, күңелдә аңа рәхмәт хисләре уяна! Ләкин бер гадәте бар: социализмга, коммунизмга, колхоз системасына ышанган иптәшләренең иҗатын объектив кабул итә алмый. Шуның аркасында үзенә дә бик авыр сүзләр ишетергә туры килде!..

Хәзер минем күз алдымда Аяз абый Гыйләҗевнең 70 яшенә багышланган зур бәйрәм кичәсе тора. Аяз абыйны сәхнәгә култыклап Нәкыя апа алып чыкты. Күренеп тора, Аяз абыйның хәле чыннан да әйбәт түгел. Без барыбыз да борчылып утырабыз, бәйрәм матур гына узса ярар иде, дибез. Кунаклар, берәм-берәм сәхнәгә чыгып, Аяз Гыйләҗевнең бөеклеген, киләчәк буыннар да аның әсәрләрен яратып укыячакларын шундый хөрмәт белән, күтәренке рухта сөйләделәр. Аяз абыйның күзеннән яшьләр ага, йөзе-кыяфәте үзгәрде, күңелендә яшәү өмете уянды кебек булды. «Өч аршын җир» спектакленнән өзекне уйнап күрсәткәч, ул бөтенләй җанланып китте. Безнең дә күңелләребез, җаннарыбыз тынычланды. Ләкин Аяз абый Аяз абый булып кала! Үзе-

нең язмышын ишәк язмышы белән тиңләп, җан ачысы белән залга авыр сүзләр дә әйтте. Бөтен кеше дә Аяз Гыйләҗев була алмый шул. Ул үзенә бер төрле илаһи көчкә ия зат иде!

Аяз абыйның иҗаты катлаулы, чөнки ул ак белән карадан гына тормый. Ул кешеләрнең яшәү рәвешендәге каршылыкларны төрле чарпылышларда күрсәтергә тырышты. Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәре генә дә аны татар әдәбиятында мәңгелеккә кертеп калдырачак. Ул әсәрнең нинди илдә, нинди чорда, кемнәргә төбәп язылганын аңларга тырышып карагыз. Шуны аңласагыз, Аяз абыйның татар милләте, татар халкы өчен кем икәнен аңларсыз.

Аяз абыйның әсәрләрен укыганнан соң бик озак уйланып йөрисең, ул бер нәрсә турында яза, ә фикри мәгънә бөтенләй икенче; әсәрнең асыл төпкеле тирәндәрәк ята. Менә шунда мәгънәсен аңлап алгач, синең күңелеңдә язучыга рәхмәт хисләре уяна. Кара әле, менә нәрсә ята икән бит моның төбендә, дип сөенеп куясың.

Аяз абый үзенең вафаты алдыннан сөйләшүләрнең берсендә: «Мин язуын яздым, менә шуларны укырлык татар кешесе булыр микән? Менә нәрсә борчый мине», — диде. Бу сүзләр әле дә булса минем күңелемне әрнетеп тора! Безне милләт буларак алда көткән фаҗигане ул бик тирән мәгънәдә аңлады. Телебезне, яшәү рәвешебезне, гореф-гадәтләребезне юкка чыгара баруыбызны күреп, әрнеп бу якты дөньядан китеп барды.

P.S. Бүген мин Аяз абыйның якты истәлеген мәңгеләштерү максатында янып яшәгәне өчен Нәкыя апага чын күңелемнән рәхмәтләр укыйм. Әйтәсем килә, ничә еллар Аяз абыйны шулхәтле карадың, Ходай Тәгалә үзеңә дә шундый игелекле балаларың белән бергә яшәргә якты гомерләр бирсен! Мин сине, Нәкыя апа, Аяз абыйдан һич аерым итеп күз алдыма китерә алмыйм — сез икегез бербөтен булдыгыз, синең җаның, рухың аның белән бергә булды. Татарда бер сүз бар: ир — баш, хатын — муен. Аяз абый башыннан кичкән авырлыклар, шатлыклар синең өчен дә үз иде.

Аяз абыйның якты истәлеген сагынып сөйләргә генә калды.

3 февраль, 2006

Литературно-художественное издание

Составитель Гилязов Искандер Аязович

Аяз Гилязов

Воспоминания

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском и русском языках

Әдәби-нәфис басма

Төзүчесе Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы

Аяз Гыйләҗев

Истәлекләр

Татар һәм рус телләрендә

Мөхәррире Р.Х.Корбанов

Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире Р.Г.Шәмсетдинов

Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы Т.В.Гредюшко

Корректорлары Р.Н.Шакирова, Г.Г.Гарифуллина

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.10.2006. Форматы 70

×100 1/16. Офсет кәгазе.

«Times» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 22,1 + форз. 0,33.

Шартлы буяу-оттиск 90,35. Нәшер-хисап табагы 23,78 + форз. 0,53. Тиражы 3000 д. Заказ 3-816.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru

e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Китапта А.Андронов, З.Бәширов, В.Зотов, М.Козловский, Н.Кочнев, Н.Седов,

А.Такташ, М.Шакирҗанов, Р.Шәмсетдинов, Р. Якупов һ.б.ның

фоторәсемнәре файдаланылды.

Авантитулда Аяз Гыйләҗевнең

Рушан Шәмсетдинов ясаган портреты. 1998